КАЗАНСКИЙ ФЕДЕРАЛЬНЫЙ УНИВЕРСИТЕТ
НАБЕРЕЖНОЧЕЛНИНСКИЙ ИНСТИТУТ

А.Г. ХАЙРУЛЛИН

Милли җитәкчеләрнең көндәлек әсбабы

мантыйк | фәлсәфә | сәясәт фәне | менеджмент | психология

Настольная книга национального руководителя

логика | философия | политология | менеджмент | психология

НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
2023

УДК [001:005.9]=512.145
ББК 65.291.6-21(2Рос.Тат)в05я91
Х15

Рецензенты:
доктор педагогических наук, профессор **А.Г. Мухаметшин**;
доктор философских наук, профессор **А.Г Сабиров**

Х15 **Хайруллин А.Г.**
Настольная книга национального руководителя : учебное пособие / А.Г. Хайруллин. – Набережные Челны : Изд.-полиграфический центр, 2023. – 615 с.

Книга представляет собой научный и практический материал в сфере логики, философии, политологии, менеджмента и психологии. Предлагаемый автором труд позволяет обеспечить современному региональному руководителю эффективную научно-практическую поддержку в сферах, где использование татарского языка вызывает сложности, которые часто заставляют отказываться от использования регионального языка в официально-деловой, административной и бизнес среде.

УДК [001:005.9]=512.145
ББК 65.291.6-21(2Рос.Тат)в05я91

© Хайруллин А.Г., 2023
© Издательско-полиграфический центр, 2023

Профессор Ә.Г. Хәйруллинның укучыга беренче тапкыр әлеге форматта татар телендә тәкъдим ителә торган «Милли җитәкчеләрнең көндәлек әсбабы» хезмәте хәзерге заман төбәк җитәкчесе һәм белгеченә стратегик мөһим өлкәләрдә кирәкле белем һәм мәгълүмат чыганагының уникаль үрнәге булып тора.

Эшнең кыйммәте, безнең карашка, аның ике зур максатны тормышка ашыруга юнәлтелгән булуыннан гыйбарәт. Беренчедән, автор тарафыннан татар телендә тәкъдим ителгән форматта (нигездә, таблица, матрица һәм схемалар) фәлсәфә, менеджмент, икътисад һәм мантыйк өлкәсенә караган фәнни белемнәрне системалаштыру һәм гомумиләштерү материалны киң һәм нәтиҗәле куллану өчен уникаль җирлек тудыра.

Икенчедән, әлеге китап, татар телен югары интеллектуаль өлкәләрдә – иң мөһиме нәзари юнәлештә генә түгел, гамәли яктан да белемнәрне системалаштыру коралы буларак куллану тәҗрибәсен тәкъдим итә, татар теленең социаль статусын күтәрү һәм тотрыклы итү максатына хезмәт итә.

Бүгенге уңышлы җитәкче – ул алдан күрү сәләтенә ия булган лидер, ә аңа исә, һичшиксез, абстракт, фактик һәм практик өлкәләрнең мөһимлеген тирәнтен аңлау һәм танып белү нәтиҗәсендә генә ирешелә.

Шуңа бәйле рәвештә әлеге эшнең актуальлеге шик тудырмый. Фәлсәфә, мантыйк, икътисад һәм менеджмент өлкәләрендә бердәм хезмәткә тупланган фәнни һәм гамәли материал, басманың заманча һәм кыска форматын исәпкә алып, хәзерге заман төбәк җитәкчесе һәм белгеченең өстәл китабы була ала. Китапның укучыга татар телендә тәкъдим ителүе аның гамәли аспектын арттыра һәм нәтиҗәле гамәли кулланырлык чыганаклар булмау сәбәпле, еш кына татар телен куллануда кыенлыклар очрый торган тармакларда заманча төбәк җитәкчесенә фәнни-гамәли ярдәм күрсәтергә мөмкинлек бирә.

Хезмәт бурычлары буенча коллективлары һәм киң аудитория алдында чыгыш ясаучы, халык белән аралашучы һәм киңәшмәләрдә катнашучы җитәкчеләр, рус теле белән беррәттән, татар теле кулланылганда, махсус терминологияне файдалану һәм аңлауда кыенлыклар кичерергә мөмкиннәр. Мондый пробле-

малар рәсми-эшлекле, административ һәм бизнес даирәсендә еш кына әлеге телне белгән җитәкчеләрне дә төбәк телен кулланудан баш тартырга мәҗбүр итә. Профессор Ә.Г. Хәйруллинның китабы бу проблеманы хәл итәргә мөмкинлек бирә. Авторның әлеге китапны әзерләү һәм бастыру тәҗрибәсенең тагын бер мөһим ягы шунда: аны РФнең башка милли төбәкләрендә РФнең башка төбәк телләрендә мондый төр эшләрне әзерләүдә кулланырга мөмкин.

Билингвизм (икетеллелек) һәм полилингвизм (күптеллелек) бүгенге көндә һәм, гомумән, РФ һәм Татарстанның үсеш тарихында – ил һәм җөмһүриятнең көндәлек тормышының гармонияле (килештерелгән) һәм гадәти өлеше. Күп милләтле Россиядә тел төрлелеген яклауның югары дәрәҗәдә гамәлгә ашырыла: Россия Федерациясе Президенты В.В. Путин инициативасы белән 2019 ел башында Россия Федерациясе халыкларының милли байлыгы һәм тарихи-мәдәни мирасы булган туган телләрен саклау һәм өйрәнү фонды булдырылды. Безнең карашка, профессор Ә.Г. Хәйруллин китабы төрендәге хезмәтләр Россия Федерациясенең тел сәясәте идеяләренә хезмәт итә, Россия халыкларының тел төрлелегенә хөрмәт принципларын алга этәрә, һәм иң мөһиме – телләрне үстерү һәм аларга ярдәм итү өлкәсендә РФнең игълан ителгән өстенлекле юнәлешләрен гамәлгә ашыруга өлеш кертә. Безнең карашка «Милли җитәкчеләрнең көндәлек әсбабы» китабы җитәкче һәм белгечләрнең һөнәри күнекмәләрен үстерү өчен, шулай ук республика лидерларының татар телендә ышанычлы һәм нәтиҗәле һөнәри аралашу өлкәсендә ярдәм итү өчен дә, һичшиксез, бай чыганак булачак.

Филология фәннәре докторы, профессор Җәмилә Насыйх кызы Мостафина

МАНТЫЙК

Хайруллин А.Г.

Абыем Рашат Гафиятулла улы
истәлегенә багышлана

Кереш сүз

Мантыйк ул борынгы фәннәрнең берсе һәм аңа соңгы елларда кызыксыну арта бара. Бу китап югары уку йортлары студентларына һәм, гомумән, мантыйкый хезмәтләр белән кызыксынучы укучыларга тәкъдим ителә.

Кагыйдә буларак, мантыйк фәнен яки русча логиканы татар яшьләре күп еллар дәвамында рус телендә язылган китаплардан гына үзләштереп килделәр. Иң бай телләрнең берсе мантыйктагы тирән мәгънәле, катлаулы тәгълиматларны укучыга аңларлык итеп җиткерә алган – рус теле.

Әмма рус телендә әзерләнгән бу дәреслекләр, фән буенча киң теоретик һәм практик белемнәр бирә алсалар да, татар укучысында үз телендә мантыйкый фикерләүдә, фикри нәтиҗәләр ясауда кыенлыклар тудыра. Мәгълүм булганча, фикерләү төп телгә нигезләнә. Төп телгә нигезләнмәгән фикерләү псевдофикерләүгә (ялгыш фикерләү) әйләнә. Телнең төп дип билгеләнүе аның сүз байлыгының киң күләмдә үзләштерелгән булуы белән бәйле.

Ни кызганыч, бүген татарлар өчен төп рольне һәрчак туган тел уйнамый. Мәсәлән, мәктәптә бала туган телдә фикер йөртергә өйрәнә, югары уку йортына кергәч, рус теленә күчәргә мәҗбүр була. Бу – бик катлаулы күренеш. Фикерне сөйләмгә әйләндерү процессы ике өлештән тора: аңда әле генә туган уй аерым элементларга бүленә, аннары алар сүзләр аркылы яңадан торгызыла. Монда кыенлык туа: белдерергә теләгән төшенчә белән аңдагы сүзләрнең мәгънәсе туры килмәсә, эчтәлек бутала. Андый кыенлыкларны бетерер өчен, ягъни яңа телне үзләштереп, аны төп телгә әйләндереп, фикер йөртүне үзгәртеп корыр өчен, кимендә дүрт-биш ел вакыт кирәк. Шул сәбәпле, сәләтле татар балаларының да фикерләү үсешендәге камилләшү процессы тоткарлана.

Шуңа күрә татар телендә язылган мантыйкый һәм фәлсәфи китапларга ихтыяҗ артканнан-арта бара. Татарстан Республикасында татар теле дәүләт теле дәрәҗәсенә күтәрелгәч, аның әһәмияте тагын да артты.

Мантыйк бүлеге

Беренче карашка, мантыйк фәнендәге тәгълиматлар, законнар – гади, һәм аларны өйрәнүдә файда юк кебек, чөнки күп кеше мантыйкый фикерләүдән башка, әлеге фикерләрне башкаларга мантыйкый аңлатып җиткерергә тиеш. Кешеләрнең аралашу телендә мантыйк күпчелек очракта теге яки бу сәбәпләр аркасында яшерелгән була. Мантыйкның бурычы – эмоциональлекне, хисләрне читкә этәреп, сөйләмгә ачыклык кертү. Безнең фикерләүнең һәртөрле хәрәкәте мантыйкый законнарга таянып эш итәргә тиеш.

Мантыйк теле барлык милләт кешеләренә дә җиңел түгел. Монда каралган объектлар һәм проблемалар үзенчәлекле, абстракт булып торалар. Фикерләү эшчәнлегенең принципларын аңлау – белемнең иң кыйммәтлеләреннән берсе.

Бу китапның максаты – мантыйкны татар телендә өйрәнеп, татарча фикер йөртергә һәм үз фикерләребезне татар телендә башкаларга җиткерергә өйрәтү. Мантыйк фәне барлык төгәл фәннәргә нигез булып тора икән, татар телендә бирелгән мантыйк фәне дә татарча фәннәр тудыруга этәргеч булып калыр дип ышанабыз.

Беренче бүлек. Мантыйк предметы

Тема 1. Гомуми характеристика

§1. Мантыйкның килеп чыгышы

Аристотель мантыйгы (безнең эрага кадәр IV гасыр)

Дедуктив логика (силлогистика), модальлек мантыйгы яралгылары.

Урта гасыр схоластик мантыйгы (V-XV гасыр)

Аристотельнең мантыйгын, модаль мантыйкны (логиканы) үстерү, камилләштерү. Фикерләү (высказывание) мантыйгының барлыкка килүе һәм үсеше.

Яңа вакыт мантыйгы (XVI гасыр – XIX гасыр башы)

— Фәндә индуктив алымның барлыкка килүе һәм үсеше. Фрэнсис Бэкон (1561-1626).

— Индуктив мантыйкның формалашуы һәм үсеше. Джон Стюарт Милль (1806-1873).

Математик мантыйкның килеп чыгышы һәм үсеше

— Г.В.Лейбницның (1646-1716) эзотерик фәлсәфәсендә кибернетика һәм математик мантыйк идеяләре.

— XIX гасырда Джордж Буль (Англия), Готлоб Фреге (Германия), Чарлз Пирс (АКШ) хезмәтләрендә математик мантыйк идеяләре килеп чыгышы һәм үсеше.

— Бертран Рассел һәм Альфред Норт Уайтхед (1910-1913).

Мантыйкның заманча үсеш этабы

— Заманча мантыйкның бердәмлеге, гомумилеге һәм күп төрлелеге: классик һәм классик булмаган мантыйк; күп мәгънәле, модаль, конструктив.

— Формаль исәпләү, төзү ысуллары.

— Компьютер теле (алгоритмик).

§2. Фикерләү. Фикерләү белән тел арасындагы бәйләнеш

Мантыйк (грек. λογική, logikē) – «дөрес фикерләү турында фән», «фикерләү сәнгате» – фәлсәфәнең бүлеге, норматив фән интеллектуаль гыйлем туплау эчшәнлегенең формалар,методлар һәм кануннар турындагы фән.

Фикерләү мантыйгы (фикерләүнең логикачылыгы)

Фикерләү – гамәли эшчәнлек процессында барлыкка килгән, кеше миендә чынбарлыкны уртаклаштырып һәм гомумиләштереп чагылдыручы төшенчә.

Мантыйк фәне

Мантыйк – фикерне дөрес төзүнең законнары һәм формалары турындагы фән ул.

§3. Фикерләүнең эчтәлеге һәм формасы

Фикерләүнең мантыйкый формасы – уйларның структурасы, аның элементларының үзарабәйләнү ысулы ул.

Төшенчә (понятие)

— Әйберләр яки күренешләрнең әһәмиятле сыйфатлары, элемтә һәм мөнәсәбәтләр берлегенең төшенүдә чагылышы; берәр сыйныф әйберләрен алар өчен уртак һәм үзенчәлекле сыйфатлар буенча билгеләүче һәм йомгаклаучы фикер яки фикерләр системасы.

— Мәсәлән, **агач турында** уйлаганда, без билгеле бер агач – каен, чыршыны түгел, ә агачларның гомуми характерын, аларга гына хас үзенчәлекләрен күз алдына китерәбез. **Нинаять, «адвокат» дигәндә,** без конкрет шәхес турында түгел: ә адвокат Салаватов, Шакиров, Исмәгыйлевләрне күздә тотып, адвокатларга хас үзенчәлекләр турында уйлыйбыз.

Хөкем (суждение)

— Фикерләр эчтәлеге белән бер-берсеннән тагын да күбрәк аерыла. Әмма монда уртаклык та күзгә ташлана: биредә аларның һәрберсендә уйның нәрсә турында икәне һәм нәрсә белдергәне күрсәтелә.
— Мисал өчен берничә катлаулырак фикерне алыйк: «Барлык планеталар да көнбатыштан көнчыгышка әйләнә», «Барлык агач та – үсемлек», «Барлык адвокатлар да – юристлар».
— Әгәр хөкемгә кергән төшенчәләрне мантыйкта кабул ителгән формулада күрсәтсәк, S (субъект) һәм P (предикат), без гомуми S – P формуласын китереп чыгарабыз. Монда S белән P – хөкемгә кергән төшенчәләр, «–» билгесе алар арасындагы бәйләнешне аңлата. Хөкем бәйләнешләрнең чагылдыру ысулы булып та, раслау яки инкарьләү формасында күрсәтелгән чынбарлыктагы предметларның мөнәсәбәте булып та тора.

Фикри нәтиҗә (умозаключение)

Фикерләр эчтәлеге, байлыгы һәм төрлелеге белән аерыла. Шуңа да карамастан, аларда уртаклык та юк түгел. Монда билгеле рәвештә бер-берсе белән бәйләнгән ике фикердән өченче фикер чыгарыла.

Барлык агач та – үсемлек

Имән – агач

↓

Димәк, имән – үсемлек.

Барлык адвокатлар да – юристлар

Янбарисов – адвокат

↓

Димәк, Янбарисов – юрист.

§4. Фикерләү законы

Фикерләү законы – фикер йөртү процессында уйлар арасындагы билгеле бер бәйләнеш белдерә торган эчке, зарури канун.

Өченчене читләштерү

Әгәр бездә бер-берсе белән каршылыклы ике фикер булса, ягъни берсендә (А) нәрсә булса да расланып, икенчесендә шул ук әйбер (А түгел) инкарь ителсә, без ахыр чиктә берсен булса да хак дип таныйбыз. Икенче төрле әйткәндә, каршылыклы фикерләрнең икесе дә ялган була алмый.

Каршылыксызлык

Ике фикернең (А һәм А түгел) ахыр чиктә берсе булса да ялган була, икенче төрле әйткәндә, бер-берсенә каршы килүче фикерләрнең икесе дә чын була алмый. Бу – шулай ук мантыйк законы.

Бердәйлек

Фикер йөртү процессында ачыклык саклаучы төшенчәләргә дә кагыла (бер төшенчәне икенчесе белән алмаштырмау һәм төрле мәгънәле сүзләрне буташтырмау).

Җитәрлек дәрәҗәдә дәлилләү

Шулай ук билгеле бер таләп, дөрес фикерләвебезнең зарури шарты булып тора. Ул шуннан гыйбарәт, әгәр дә танып белү процессында теге яки бу хөкем, фикер җитәрлек дәрәҗәдә, ягъни тиешенчә дәлилләнсә генә аны дөрес дип танырга була.

§5. Мантыйкның әһәмияте

Әһәмияткә ия булган мантыйкның төп аспектларын атыйк:

Фәнни-теоретик әһәмияте

Мантыйк барлык фәннәрнең дә гомуми фәнни методы булып тора.

Гамәли фәнни-техник әһәмияте

Мантыйк конкрет фәннәрнең мәгълүматларын мантыйкый анализлау өчен кулланыла, әйтик, фәнни билгеләмәләрне, исбатлауларны төзү, конкрет фактларны системалаштыру, гипотезаларны барлыкка китерү һ.б.

Прагматик әһәмияте

Фикерләү культурасын үстерү. Мантыйк телдәге һәм язмадагы чыгышларның страте-гия һәм аргументация кертү тактикасын, эшлекле әңгәмәләрне, сөйләшүләрне төзү структурасының аерылгысыз элементы булып тора.

Тема 2. Мантыйк тарихы

§1. Мантыйкның барлыкка килүе һәм үсеш этаплары

Логика бүлекләре

Традицион мантыйк

(безнең эрага кадәр IV гасыр – XIX гасыр башы)

Традицион мантыйк дөрес фикерләүне, гадәттә, табигый телгә таянып өйрәнә. Традицион мантыйк формализацияләү, математика аппаратын, исәпләүләрне бөтенләй кулланмый диярлек.

Һәм эзлеклелек, фикер (хөкем), төшенчә, алар өстеннән үткәрелгән операцияләрне өйрәнү белән шөгыльләнә.

Классик мантыйк

(XIX-XX гасыр)

Логиканың заманча кисәге, бүлеге (математик, символик). Үз эченә класс ик предикатларны, үз фикереңне әйтү, җиткерү логикасын ала.

Классик мантыйк икемәгънәлелек принцибына нигезләнә. Аның нигезендә теләсә кайсы фикер (үзфикер) чын (дөрес) яки ялган була.

Классик булмаганмантыйк

(XIX гасыр ахыры –XX гасыр)

Заманча логиканың нигезендә ятучы (релевант логика, күпмәгънәле логика, модаль логика һ.б), идеяләрнең алга таба үсеше һәм өстәмәсе (кушымтасы) булып торучы логик теорияләр җыелмасы.

Вәкилләре:

Аристотель (б.э.к.348–322);

Ф. Бэкон (1561–1626);

Д. С. Милль (1806–1873) һ. б.

Д. Буль (1815–1864);

А. де Морган (1806–1871);

Ч. Пирс (1839–1914);

Г. Фреге (1848–1925);

Б. Рассел (1872–1970) һ. б.

Л. Брауэр (1881–1966);

К. И. Льюис (1883–1964);

Я. Лукасевич (1878–1956) һ. б.

Икенче бүлек. Төшенчә

Тема 1. Гомуми характеристика

§1. Төшенчәнең барлыкка килүе

Төшенчә ул – чынбарлыктагы аерым предметлар, күренешләрнең әһәмиятле билгеләре турында кеше аңындагы уй, фикер.

Анализ

Төшенчә барлыкка килүнең бу этабы анализ (грек сүз. analysis – таркату, бүлү, аеру) яки предметның фикерләүдә аерым билгеләргә бүленүе дип атала.

Абстракция

Билгеләрне, үзенчәлекләрне яки бәйләнешләрне предметтан тыш кына, аерым объект итеп тикшерү, күз алдына китерү абстракция (латин сүз. abstactio – аерып алып карау) дип атала.

Чагыштыру

Бу этап чагыштыру яки әйбернең төп һәм төп булмаган билгеләре, сыйфатлары буенча охшаш һәм охшаш булмаган якларын табу дип атала.

Синтез

Бирелгән күплек предметларының билгеләрен кушып, бер билге чыгару синтез дип атала. Синтез ярдәмендә без катлаулы билге булдырабыз, анда тупланган билгеләр «һәм», «яки» дигән теркәгечләр яки өтер билгесе белән бәйләнгән булалар.

Анализ

Төрле объектларның барысына да хас булган билгеләренә карап, берләштерүне танып белүле гомумиләштерү дип атыйлар.

§2. Төшенчә һәм тел

Тамга (знак)

Тамга дип, танып белүдә аңда предметны алмаштыра алган яки, аралашканда, объектның күчермәсе итеп кулланыла торган, теләсә нинди тоеп беленә торган предметка әйтәбез.

Индекс тамгалар

Күз алдына китерелә торган объектларны нәтиҗә сәбәпләре ашакүрсәтәләр

Мәсәлән, төтен – ут барлыгын әйтә торган тамга; кешедә югары температура – аның авырганын; терекөмеш баганасының биеклеге үзгәрүе – басымның артуы һ.б.

Сурәт тамгалар

Сурәт-тамгалар күз алдына китерә торган объектлар турындагы мәгълүматны үзләрендә күрсәтәләр, чөнки алар билгели торган объект белән охшашлык мөнәсәбәтендә булалар.

Мәсәлән, аларга сызым, карта, рәсем, фотография, сурәт һ.б. керә.

Символ тамгалар

Символ-тамгалар билгеләүче предметлар белән охшаш булмыйлар.

Мәсәлән аларга эмблемалар, гербларга, сигнал-тавышлар һ.б. керә.

Фикерләү формасы буларак, төшенчә танып-белү процессында түбәндәге мәсьәләләрне чишә:

Безне кызыксындырган объектларны барлык башка объектлардан **аера**.

Безне кызыксындыра торган күплектән объектны **гомумиләштерә**.

Бирелгән күплектән объектның асылын **чагылдыра**.

Төшенчә

Төшенчә ул – исемнең уйдагы сурәте.

Ялгыз

Ялгыз төшенчәләр дип, без бер генә булган, бердәнбер предметларга әйтәбез.

Мәсәлән: «Татарстандагы иң зур мәчет», «Татарстан башкаласы», «бу – китап». Ялгызлык төшенчәләргә ялгызлык исемнәр дә керә, мәсәлән: «Тукай», «Казан», «Татарстан».

Гомуми

Бер төркем, бер класска кергән предметларны яки күренешләрне һәм алар арасындагы охшаш булган төшенчәләрне **гомуми төшенчәләр** дип атыйлар.

Мәсәлән, уртак исем яки гомуми төшенчә күплектәге барлык объектларны аңлата, мәсәлән: «шәһәр», «урындык», «Н. Думави әсәрләре», «хәрәкәт», «матурлык»,«тойгы».

Амфиболия

Әгәр бер үк сүз бер үк вакытта төрле мәгънәдә кулланыла ала икән, мондый күренешне мантыйкта **амфиболия** (ике мәгънәле) дип атыйлар.

Исем

Исем ул – объектны белгертә торган тамга.

Төшенчә (уйдагы сурәт)



Исем (тамга) **Объект (мәгънә)**

§3. Төшенчәнең эчтәлеге һәм күләме



Рәсемдә зур түгәрәк «агач» төшенчәсенең күләмен символлаштыра. Әгәр түгәрәк эчендә башка түгәрәкләрне ясасак, без бу күләм эченә башка күләмнәрнең кергәнен күрсәтәбез. Рәсемнән күренгәнчә, «агач» күләменә «имән», «каен» һ.б. керә. Шулай ук кечкенә түгәрәкләр эченә тар булган күләмнәрне кертергә була.

Мәсәлән, каеннарның аерым төрләрен яки индивидуаль каеннарны кертергә була. Киң күләмдәге төшенчәне, аның эченә кергән тар күләмдәге төшенчәгә карата, ***ыруг*** *дип атыйлар. Тар күләмдәге төшенчәне бу очракта* ***төр*** *дип атыйлар. Киң күләмдәге төшенчәне гомуми төшенчә дип тә атарга була.*

Безне кызыксындырган күплектән предметны аерырга һәм гомумиләштерергә ярдәм иткән билгеләрне төшенчәнең эчтәлеге дип атыйлар. **Эчтәлек ул – уйланыла торган төшенчәдә предметка хас булган барлык билгеләрнең җыелмасы.**

— *Мәсәлән, кеше аң, ихтыяр, тоюга ия: киң тырнаклы, башында чәч катламы, ике күзле, койрыксыз, канатсыз һ.б билгеләргә ия булган җан иясе. Төшенчәнең эчтәлеге төрле карашка, белемнең күләменә карап төрлечә булырга мөмкин.*

— *Мәсәлән, «шикәр» төшенчәсендә химик бертөрле эчтәлекне (мәсәлән, аның төзелешен), ә химик булмаган кеше башка эчтәлекне уйлый.*

Шулай итеп, **төшенчәнең эчтәлеге күбәйгән саен, аның күләме кими, һәм, киресенчә, күләм зурайган саен, эчтәлек кими бара.**

§4. Билге төшенчәсе

Билге (признак)

Безгә билге төшенчәсен ачыграк аңлау өчен, мантыйкый онтологияне карап үтәргә кирәк. **Онтология ул – дөнья турында фикерләү һәм аны телдә чагылдыру шартларын төзүче, чынбарлыкның төрләре турындагы тәгълимат.**

Предметлар

Предмет – үзлеккә ия булырга һәм мөнәсәбәткә керергә мөмкин, әмма үзеүзлек яки мөнәсәбәт була алмый.

Кызыл, мәсәлән, кызылрак яки ачык кызыл булырга мөмкин. Әгәр аңлатманың икенче өлешен язмаган булсак, безгә үзлекләрне һәм мөнәсәбәтләрне предметдип санарга туры килер иде.

Үзлекләр һәм мөнәсәбәтләр

Мөнәсәбәт ул – ике яки күбрәк әйберләр арасындагы бәйләнеш.

Мәсәлән, «арада тору», «энесе булу», «эленеп тору», «зуррак булу» – болар барысы да мөнәсәбәтне белдерә торган кушымталар. Күргәнегезчә, мөнәсәбәттә, аз дигәндә, ике әйбер булырга тиеш: «Айрат – Булатның энесе» – ике, «Мамадыш Казан белән Чаллы арасында тора» өч әйбернең булуын таләп итә.

Билге

Билге ул – үзлекнең яки мөнәсәбәтнең булуы яки булмавы.

Мәсәлән, «ак булу», «ак булмау», «профессор булмау» – болар барысы да гади билгеләр.

Гади

Гади билге ул – объектның, анда булган яки булмаган үзлекне яки мөнәсәбәтне күрсәтә торган характеристика.

Катлаулы

Катлаулы билге ул – гади билгеләрнең «һәм», «яки», «әгәр дә ..., мондый ...» һ.б. теркәгечләр, өтер ярдәмендәге кушылмасы.

§5. Билге төрләре

Гади билгеләр

Уңай һәм тискәре билгеләр

Әгәр дә объектның үзлеге яки мөнәсәбәте булу турында сөйләнсә, бу **уңай билге** дип атала.

Мәсәлән, «зәңгәр», «кызыл», «гадел», «әти булу», «урамда басып торган» – болар барысы да уңай билгеләр.

Әгәр объектның үзлекләре яки мөнәсәбәтләре юклыгы турында сөйләнсә, бу **тискәре билге** дипатала.

Мәсәлән, «койрыксыз», «икегә бүленми торган», «баласыз», «сәләтсез», «урамда тормаган» –тискәре билгеләр.

Төп һәм иярчен билгеләр

Төп билгеләр предметның табигатен күрсәтәләр, алардан башка бирелгән төшенчәне күз алдына китереп булмый.

Мәсәлән, «ромб» төшенчәсенең төп билгесе – аның яклары тигез булган параллелограмм булуы, ә калган, дүрт яклы булуы – квадрат булмавы кебек билгеләр әһәмиятле түгел, ә иярчен билгеләргенә.

Барлык булган объектлардан безне кызыксындыра торган объектлар күплеген аерырга җитәрлек булган билгене төшенчәнең **төп билгеләре** дип атыйлар, ягъни алар төшенчәнең **төп эчтәлеген** барлыкка китерәләр. Ә калган билгеләрне, бу төп билгеләр янына төркемләнгән билгеләрне, **иярчен билгеләр** дип әйтәләр.

Аера торган һәм аермый торган билгеләр

Бирелгән төшенчәнең күләменә кергән объектларга гына хас билгене **аера торган билге** дипатыйлар.

Мәсәлән, без химияне әйберләрнең төзелешен өйрәнә торган фән дип әйтсәк, монда «әйберләрнең төзелешен өйрәнә торган» билге бу фәнне башка фәннәрдән аерырга ярдәм итә.

Билге бирелгән төшенчә күләменә кермәгән объектларга да хас булса, бу **аермый торган билге** дип атала.

Мәсәлән, урындыкның артлы булуы – аермый торган билге, чөнки бу билге белән аны кәнәфидән, диванннан аерып булмый.

Катлаулы аера торган билге ул – гади аермый торган билгеләр кушылмасы.

Тема 2. Төшенчә төрләре

Барлык төшенчәләрне түбәндәге билгеләр буенча бүләргә була:

Билгеләр характеры буенча бүлү.	Төшенчә күләмендәге элементлар саны буенча бүлү.	Күләмдәге элементларның характеры буенча бүлү.

§1. Билгеләрне характеры буенча бүлү

Билгеләр характеры буенча бүлү

Уңай һәм тискәре төшенчәләр

Әгәр төп эчтәлегендә уңай билгеләр генә очраса, бу **уңай төшенчә** була. Әгәр төп эчтәлегендә бер генә булса да тискәре билге очраса, бу **тискәре төшенчә** була.

Мәсәлән, «бәхетле бала» – төшенчә буларак та, күренеш буларак та уңай, ә «бәхетсез кеше», – киресенчә, ике мәгънәдә дә тискәре.

Абсолют һәм чагыштырмача төшенчәләр

Әгәр төшенчәнең төп эчтәлегендә үзлек-билгеләр генә очраса, бу **төшенчә абсолют** дип атала.

Әгәр инде төп эчтәлектә бер генә булса да мөнәсәбәт-билге очраса, бу **чагыштырмача төшенчә** була.

Мәсәлән, квадрат ул – дүрт ягы тигез булган турыпочмаклы дүртпочмак. Бу төшенчәнең эчтәлегенә үзлек-билгеләр генә керә. Шуның өчен квадрат абсолют төшенчә була.

Мәсәлән, «ата-аналар» төшенчәсе балаларның барлыгын күздә тота: ата-аналарны балалардан башка күз алдына китереп булмый; «укытучы» төшенчәсеукучылар булуын күздә тота.

§2. Төшенчә күләмендәге элементларны саны буенча бүлү

Буш төшенчә

Буш төшенчә дип, күләмендә юклык күплеге булган, ягъни үз эчендә бер элемент та былмаган төшенчәне атыйлар.

Мәсәлән, бу төшенчәләргә мәңгелек двигатель, түгәрәк, квадрат, Су анасы, Шүрәле һ.б. керә.

Тулы төшенчә

Төшенчәнең күләмендә бер генә элемент булса да, ул **тулы** төшенчә дип атала.

Ялгыз төшенчә

Тулы төшенчәләр икегә бүленәләр: күләмендә бер генә элемент булган ялгыз төшенчә.

Мәсәлән, «Казан», «Тукай», «беренче китап».

Гомуми төшенчә

Күләмендә бердән артык элемент булган гомуми төшенчә.

Мәсәлән, «шәһәр», «шагыйрь», «китап».

§3. Күләмдәге элементларны характерлары буенча бүлү

Күләмдәге элементларны характеры буенча бүлү

Гомуми җыючы һәм аера торган төшенчәләр

Җыючы

Җыючы термин бертөрле берәмлекләрдән торган төркемне аңлата.

Мәсәлән, әгәр без «полк», «урман», «китапханә», «йолдызлык», «класс» терминнарын бертөрле элементларның җыелмасы итеп күрсәтсәк, бу вакытта терминнар җыючы була.

Аеру

Еш кына төшенчәләрне кулланганда, безнең раслаулар теге яки бу предметлар төркеменә кергән һәрбер берәмлеккә кагылырга мөмкин. Төшенчәләрне шул рәвешле куллану – аеру мәгънәсендә куллану дип атала.

Мәсәлән, «бөтен эшчеләр дә арыды» дигән җөмләдә, «бөтен» сүзе аеру мәгънәсендә кулланыла, чөнки монда эшчеләрнең бары-сының да арыганлыгын күз алдында тотабыз.

Абстракт һәм конкрет төшенчәләр

Абстракт

Абстракт төшенчәләр дип, күләмнең элементлары булып, үзлек һәм мөнәсәбәт торган төшенчәгә әйтәләр.

Мәсәлән, абстракт термин-нар булып, «авырлык», «күләм», «фор-ма», «катылык», «кыюлык», «аклык», «намуслылык», «гаделсезлек» һ.б. кулланыла.

Конкрет

Конкрет төшенчә дип, күләмнең элементлары предметлар гына булган төшенчәгә әйтәләр.

Мәсәлән, «квадрат», «ялкын», «өй», «сугыш», «куркү» – болар барысы да конкрет төшенчәләр.

Тема 3. Төшенчәләр арасындагы мөнәсәбәтләр

§1. Мөнәсәбәт төрләре

Мөнәсәбәт төрләре

— Әгәр A һәм B төшенчәләре эчтәлегендә бер генә уртак билге булса, алар чагыштырмалы булалар.

Мәсәлән, кызыклы китап белән яшел яфрак эчтәлегендә дә уртак билгеләр табарга була, чөнки алар мантыйкый онтология буенча предметлар категориясенә керәләр. Монда шуңа да игътибар итәргә кирәк: бу мөнәсәбәттә төп эчтәлеге турында түгел,ә төшенчәнең барлык эчтәлеге турында сүз бара.

— Әгәр A һәм B төшенчәләренең эчтәлегендә уртак билгеләр булмаса, алар чагыштырмасыз була.

Монда шуны гына әйтеп үтәргә була: безнең онтологиядә шундый чагыштырмасыз төшенчәләргә «предмет» һәм «үзлек» керә.

Ике чагыштырмалы A һәм B төшенчәләре

Әгәр бу төшенчәләрнең күләмендә бер генә уртак элемент булса, A һәм B төшенчәсен **чагыштырмалы** дип атарбыз.

Әгәр бу төшенчәләрнең күләмендә уртак элементлар булмаса, A һәм B төшенчәләрен **чагыштырмасыз** дип атарбыз.

§2. Чагыштырмалы (сравнимые) төшенчәләр арасындагы мөнәсәбәтләр

Чагыштырмалы төшенчәләр арасындагы мөнәсәбәтләр

Тигез мәгънәле төшенчәләр һәм алар арасындагы мөнәсәбәт

Әгәр А һәм В төшенчәләренең күләмнәре бер үк элементлардан торса, бу төшенчәләр **тигез мәгънәле (равнозначные)** була.

Бу мөнәсәбәтне аңлату өчен, мисал итеп, ике төшенчәне: «инглиз халкын» (А) һәм «беренче диңгез гизүчеләрне» (В) алыйк. «Инглиз халкы» дигәндә, без инглиз халкын, инглизләрне күз алдында тотабыз. «Беренче диңгез гизүчеләре» дигәндә, без шулай ук инглизләр турында уйлыйбыз.

Тигез мәгънәле

Төрле эчтәлекле бер күләмдәге ике төшенчә бердәйлек мөнәсәбәтендә тора.



Бердәйлек мөнәсәбәтен ике түгәрәкнең (ике күләмнең) бергә кушылуы итеп күрсәтергә була. Төшенчәләр эчтәлегенең төрле булуы, түгәрәк эчендәге ике төрле хәреф белән (А һәм В) билгеләргә була.

Буйсына торган төшенчәләр һәм алар арасындагы мөнәсәбәт

Әгәр бер төшенчә (В) икенче төшенчәгә (А) юрыгтагы төр буларак керсә, ягъни бер төшенчә икенче төшенчәнең күләменә кереп, аның кисәге булган очракны төшенчәнең буйсынуы дип атыйлар.



«Агач» (А) төшенчәсен һәм «каен» (В) төшенчәсен алыйк. Соңгы төшенчә беренче төшенчәнең күләменә керә, ягъни В төшенчәсе А төшенчәсенә буйсына.

Кисешә торган төшенчәләр һәм алар арасындагы мөнәсәбәт

Әгәр ике төшенчәнең эчтәлекләре төрле, әмма күләмнәренең берникадәр өлеше туры килсә яки уртак билгеләре булса, бу төшенчәләрне кисешә торган төшенчәләр дип атыйлар.



А – студентлар һәм В спортчыларны алыйк. «Студентлар» төшенчәсенең күләменә «спортчылар» күләме керә, ягъни күп кенә спортчылар студентлар булырга мөмкин, һәм, икенче яктан, студентлар да спортчы булырга мөмкин, ягъни укучыларның бер өлеше – спортчы, ә спортчыларның бер өлеше укучы.

Мантыйк бүлеге

Чагыштырмалы төшенчәләр нинди мөнәсәбәттә торганын белү өчен, А белән В төшенчәсенә түбәндәге сорауларны бирергә кирәк:

— Барлык А лар да В буламы?

— Барлык В лар да А буламы?

«Әти» белән «бала» арасындагы мөнәсәбәтне карыйк.

Барлык бала әти була аламы? – юк.
Барлык әти бала була аламы? – әйе.

Бу очракта «әти» төшенчәсе «бала» төшенчәсенә буйсына.

Чагыштырмалы төшенчәләрнең бүленеше түбәндәге схемада күрсәтелгән:

Чагыштырмалы төшенчәләр

Тигез мәгънәле | **Буйсына торган** | **Кисешә торган**

§3. Чагыштырмасыз төшенчәләр арасындагы мөнәсәбәтләр

Чагыштырмасыз төшенчәләр арасындагы мөнәсәбәтләр

Чагыштырмасыз буйсынучы төшенчәләр һәм алар арасындагы мөнәсәбәт

Әгәр киңрәк булган күләмдәге төшенчәгә бер чамадагы түбәнрәк ике яки берничә төшенчә керсә, бу төшенчәләрне **тиңдәшсез буйсынучы** төшенчәләр дип атыйлар.



«Агач» (А) төшенчәсенең күләменә «каен» (В) һәм «имән» (С) төшенчәсе кергән.

«Каен» (В) һәм «имән» (С) төшенчәләре тиңдәшсез буйсына торган булалар.

Капма-каршы (противоположный) төшенчәләр һәм алар арасындагы мөнәсәбәт

А һәм В төшенчәләре каршыдаш мөнәсәбәттә торалар, әгәр А һәм В төшенчәләре, өченче С төшенчәсенә буйсынып, ниндидер сыйфатның иң каршы яклары булып торсалар, шуңа күрә капма-каршы төшенчәләрне чагыштырмалы буйсына торганнарның бер төре итеп карарга була.



«Төс» төшенчәсенә кергән төрләрне югарыдагы ысул белән бер рәткә тезеп карыйк. Бу төшенчәнең күләменә барлык төсләр, төсмерләр керә: кызыл, яшел, ак, күк һ.б. Әгәр аларны охшашлыклары буенча бер-берсенә якын итеп куйсак, без якынча мондый рәт барлыкка китерербез: ак, аграк, аксыл, күк, соры, кара-соры, карасу, карарак, кара.

Каршылыклы (про- тиворечивый) төшен- чәләр һәм алар ара- сындагы мөнәсәбәт

Әгәр ниндидер төшенчә- не А дип билгеләсәк һәм аңарга карата А булмаган В (А-түгел) төшенчәсен алсак, бу төшенчәләр арасындагы мөнәсәбәт каршылыклы була.



«Ак» һәм «ак түгел», «биек йорт» һәм «биек булмаган йорт» каршылыклы төшенчәләр булалар. Берсе икенчесеннән «түгел», «булмаган» сүзләре яки «-сез» кушымчасы ярдәмендә барлыкка килгән ике термин каршылыклы мөнәсәбәттә булалар.

Мантыйк бүлеге



«Монархия» (A) һәм «республика» (B) төшенчәләре каршылыклы төшенчәләр булып торалар, чөнки алар чагыштырмасыз һәм икесе дә «дәүләт белән идарә итү формасы» (C) төшенчәсенә буйсыналар һәм монархия белән республикадан башка төрле идарә итү формалары юк.

Шулай ук кешеләр (C) арасында (гермофродитларны санамаганда) «ирләр»(A) белән «хатын-кызлар» (B) каршылыклы төшенчәләр булып торалар.

Шулай итеп, без чагыштырмасыз мөнәсәбәттә торган төшенчәләрнең классификациясен чыгардык:

Чагыштырмасыз төшенчәләр

Чагыштырмасыз буйсына торган

Капма-каршы

Каршылыклы

Тема 4. Төшенчәләр белән ясалган операцияләр

§1. Төшенчәләрне чикләү һәм гомумиләштерү

Төшенчәне чикләү

Киң гомуми төшенчәдән тар гомуми төшенчә барлыкка килү процессын **төшенчәне чикләү** дип атыйлар. Төшенчәне чикләү – киң күләмле, аз эчтәлекле төшенчәдән тар күләмле, зур эчтәлекле төшенчәгә күчү.

Мәсәлән, «агач» төшенчәсеннән таррак гомуми «имән» төшенчәсен барлыкка китерү өчен, без имәнгә хас билгеләрне кушарга тиешбез: яфрак төрен, ботак төзелешен, чикләвегенең формасын һ.б.

Төшенчәне гомумиләштерү

Кире процессны, таррак гомумилектәге төшенчәдән киңрәк гомуми төшенчәгә күчүне **төшенчәне гомумиләштерү** дип атыйлар. Төшенчәне гомумиләштергәндә, зур эчтәлекле, тар күләмле төшенчә киң күләмле, аз эчтәлекле төшенчәгә күчә.

Мәсәлән, «урыс» төшенчәсеннән – «славян» төшенчәсенә,

«славян» төшенчәсеннән «кеше» төшенчәсенә күчү.

«Россия Федерациясенең Конституциясе»ннән – «конституция»гә күчү.

Категорияләр

Һәртөрле гомумиләштерүнең үз чиге була, без ахырда киң күләмле булган һәм шуннан ары гомумиләштереп булмый торган төшенчәләргә киләбез. Мондый гомумиләштерүче төшенчәләрне **категорияләр** дип атыйлар.

Мәсәлән, фәлсәфәдә «материя», «хәрәкәт», «фәзак» һ.б.; төгәл фәннәрдә – «элемент» (химия); социаль фәннәрдә – «җәмгыять», «хокук» (юриспруденциядә).

Ыруг төрләрдән гомумиләштерү нәтиҗәсендә барлыкка килә һәм, киресенчә,төрләр ыругтан чикләү нәтиҗәсендә барлыкка килә. Бу процессларны түбәндәге схема ярдәмендә күрсәтергә була:



Мәсәлән, безнең А (фән) дигән төшенчә бар, ди. Без аңардан төрдәге аеру билгесе а ярдәмендә Аа (математика) төре барлыкка китерәбез; Аа га В (фәзак мөнәсәбәтләрен билгели торган) төрдәге аерманы кушып, геометрияне Аab барлыкка китерәбез. Бу төргә с билгесен (яссылыктагы фәзак мөнәсәбәтләрен билгели торган) кушып, без планиметрияне чыгарабыз.

§2. Төшенчәләрнең билгеләнүе

Билгеләмә (определение)

Билгеләмә ул – төшенчәнең эчтәлеген ачучы мантыйкый операция.

Барлык билгеләүләрне түбәндәге төрләргә бүләләр:

Номиналь һәм реаль билгеләү

Номиналь билгеләнү (nomen дигән латин сүзеннән – исем) дип, яңа чыгарылачак төшенчәнең эчтәлеген чыгаруга әйтәләр. Төшенчәнең **реаль билгеләнүе** дип, аның бу билгеләнүгә кадәр эчтәлеге һәм күләме билгеле булса әйтәләр.

Мәсәлән, «электрон массасына ия булган уңай элементар кисәкчә позитрон дип атала». Монда позитрон сүзе беренче тапкыр кулланыла.

Мәсәлән, грек галиме Платон кешегәреаль билгеләмә биргән.

Ачык һәм ачык булмаган билгеләү

Ачык билгеләнү дип, түбәндәге тигезлеккә әйтәләр:

$A =_{df} B$

Ачык булмаган билгеләмә – ул **A =** **B** тигезлегенә ия булмаган билгеләмәгә әйтәләр.

Ачык билгеләмә түбәндәге структурага ия:

Тулаем тигезлек **билгеләмә** дип атала; df (**definitia**) – латин сүзе «дефиниция» билгеләмәне аңлата

Билгеләүгә дучар ителә торган төшенчә **билгеләнә торган** дип атала. Бу очракта А төшенчәсе билгеләнә торган

Төшенчәне билгеләргә ярдәм иткән икенче төшенчәне **билгели торган** дип атыйлар. Буочракта – В төшенчәсе

Ачык булмаган билгеләмәләр ике төргә бүленәләр:аксиоматик һәм контекстуаль

Әгәр төшенчәнең эчтәлеге аксиомалар системасы белән бирелгән булса, бу **аксиоматик билгеләмә** була.

Мәсәлән, Евклид геометриясендә «нокта», «туры», «яссылык» төшенчәләренең эчтәлеге геометрия системасындагы аксиомалар белән билгеләнә.

Контекстуаль билгеләмә дип, билгеләнә торган төшенчәләрнең берникадәр кулланыла торган контексты икенче билгеләнә торган **төшенчәгә кермәгән, контекстка тигезләүгә әйтәләр.**

Мәсәлән, арифметикада квадратка күтәрү операциясе контекстуаль билгеләнгән: $a^2=aha$.

§3. Билгеләү кагыйдәләре

1. Чамадан артмау (соразмерность) кагыйдәсе

Билгеләмә чамалы булырга тиеш, ягъни **билгеләнә торган һәм билгели торган төшенчәләрнең күләме тәңгәл килергә** тиеш, алар икесе дә бер киңлектә булырга тиеш:

A = $_{df}$B,C

Мисал өчен атның билгеләмәсен карыйк. Әгәр «ат – йорт хайваны» дисәк, билгеләмә бик киң була, монда билгели торганның күләме билгеләнә торганына карата киң тора (йорт хайваннарына аттан башка сыерлар, сарыклар, кәҗәләр һ.б керә).

A < $_{df}$B

Әгәр билгеләнә торган төшенчә күләме (А) билгели торган төшенчә күләменең (В) өлеше генә булып торса, билгеләмә бик киң була. Эйлер түгәрәкләре белән «бик киң билгеләмәне» түбәндәгечә сурәтләргә була:



A,C > $_{df}$B

Әгәр билгели торган төшенчәнең (В) күләме билгеләнә торган төшенчә күләменең (А) өлеше генә булып торса, билгеләмә бик тар була.



2. Түгәрәкне тою кагыйдәсе (порочный круг). Тавтология

Бу кагыйдә буенча **билгеләнә торган төшенчә билгели торган төшенчә аша күрсәтелгәндә, билгели торган төшенчә үзе билгеләнә торган төшенчә аша күрсәтелергә тиеш түгел.**

Мәсәлән, «әйләнү ул – күчәр тирәли хәрәкәт» дигән билгеләмәне карыйк.

Билгеләмәдәге түгәрәк дип, А төшенчәсе – В төшенчәсе, ә В төшенчәсе, үз чиратында, А төшенчәсе аша билгеләнсә, мантыйкый хата була.

3. Тискәре (отрицательный) булмау кагыйдәсе

Билгеләмәдә билгели торган төшенчәнең тискәре, аңа хас булмаган билгеләрмөмкин кадәр аз яки бөтенләй булмаска тиеш. Төшенчәгә хас булмаган билгеләрбик күп, ләкин алар безгә мөһим түгел.

Мәсәлән, «театр ул – яшәү өчен җайлаштырылган йорт түгел» дигән билгеләмәдә А тору өчен яраклы йорт булса, А-түгел тору өчен яраклы булмаган йортлар чиксез күп була.

4. Ачыклык кагыйдәсе (ясность)

Билгеләмә анык булырга тиеш, билгеләмәләрдә ике мәгънәле, метафорик һәм, гомумән, аңлашылмый торган төшенчәләр кулланылырга тиеш түгел.

Билгеләнә торган сүзләр мөмкин кадәр анык булырга, алар арасында метафорик яки башка образлы тәгъбирләр кулланылырга тиеш түгел.

Билгели торган төшенчә итеп кулланыла торган сүзләр, билгеләнә торган сүзгә карата, күпчелеккә таныш булырга тиеш.

§4. Билгеләмәләрне алмаштыра торган алымнар

Билгеләмә биш шартны үтәргә тиеш:

1. Күрсәтү

Билгеле төшенчәне таныштыру ысулын күрсәтү дип атыйлар.

Мәсәлән, әгәр кемне дә булса теге яки бу төс, тавыш һ.б. белән таныштырырга теләсәк, без аны «тотып» күрсәткән очракта гына аңлата алабыз, ягъни кешене тоеп сизәргә, әйберне күрергә мәҗбүр итәбез.

2. Тасвирлау

Бу ысул индивидуаль предмет яки берәр әйбергә хас үзенчәлек белән таныштырганда кулланыла. Тасвирлауда предмет, күренешләр, вакыйгаларның билгеләре бик тулы һәм төгәл итеп күрсәтелә.

Мәсәлән, Г. Кутуйның «Тапшырылмаган хатлар» әсәрендә геройларның образлары агачлар, кошлар белән чагыштырыла. Җинаятьчеләрне эзләгәндә, аларның тышкы кыяфәтләрен тасвирлап бирәләр. Химия яки биологиядә процессларны яки реакцияләрне тасвирларга була.

3. Характеристика

Характеристика – нинди дә булса предмет яки күренешнең танылган билгеләрен, кеше, күренеш, предметка хас булган билгеләрне санап үтү.

Мәсәлән, К. Маркс Аристотельне «борынгы заманның бөек фикер иясе» дип атый.

4. Чагыштыру

Бу ысулда теге яки бу предмет, күренеш, вакыйга турындагы төшенчәне ачыграк итеп күрсәтү өчен, аңарга охшаш төшенчә чагыштырма итеп файдаланыла

Мәсәлән, биология дәреслә рендә түбәндәге чагыштыру бирелә: «Медузаның тәне дерелдәвекле, зонтикка охшаган», «Бөерләр – ногыт борчагына охшаган парлы органнар». Әлбәттә, беренче чагыштыруда «медуза» төшенчәсе «зонтик» төшенчәсенә карата ыруглык төшенчәсе була алмый. Зонтик медузаларга хас булган билге түгел. Ләкин медузаны зонтик белән чагыштыру аның бер үзенчәлеген аңларга мөмкинлек бирә.

5. Аеру

Аеру, чагыштырмадан аермалы буларак, төшенчәнең эчтәлеге белән таныштырганда, билгеле булган төшенчәне чагыштырып, аның бу төшенчәдән аерылып торган якла- рын күрсәтә.

Әгәр игътибар итсәгез, аеру ысулының билгеләмәсендә аеру ысулы кулланылган, монда аеру чагыштырмадан аерып күрсәтелә. Икенче мисал: «энтузиазм фанатизмнан вәҗданлык булу һәм уртачалык чигеннән узмавы белән аерыла».

Әлеге теманы үзләштергәндә, билгеләү белән алымнарны бутарга ярамый.

§5. Төшенчәләрне бүлү

Бүлү ул – төшенчәләрнең күләмен ача торган мантыйкый операция.

Структурасы өч өлешкә бүленә:

Бүленә торган төшенчә (totum dividendum) дип, күләмендә мөмкин кадәр төрләрнең бүленә алуы атала.

Бүлә торган әгъзалар (membra divisionis) дип, бүленә торган төшенчәнең күләмен бүлә торган төрләрнең төшенчәләре атала.

Бүлү нигезе (fundamentum divisionis) дип, бүленә торган төшенчәдән бүлә торган әгъзаларны бүлгән билгегә әйтәләр.

Физик бүленеш

Физик бүленеш ул – уйда бербөтен предметны кисәкләргә бүлү.

Мәсәлән, әңгәмәне керешкә, төп өлешкә һәм йомгаклауга, елны айларга бүләргә була. Бу физик бүленеш, чөнки керешне яки төп өлешне әңгәмә, айны ел дип кенә әйтә алмыйбыз.

§6. Бүленү төрләре

Бүленү төрләре

Билгеләрнең үзгәрүе буенча бүлү

Билгеләрнең үзгәрүе буенча бүлү – бүленүнең нигезе булган билгенең төрле дәрәҗәдәге бүленгән барлык объектларга хас булган очрак.

Мәсәлән, кешеләрне яшь буенча төркемнәргә бүләргә була. Монда «яшь» бүленүнең нигезе буларак, бүленгән төрләрнең барысы да керә.

Дихотомик бүлү

Дихотомик бүлү («дихотомия» сүзе грекчадан «ике өлешкә киселеш» дип тәрҗемә ителә) – төшенчәдә ниндидер билгенең булу-булмавы аша күләмне каршылыклы ике төргә бүлү.

Мәсәлән: «Матдәләр органик һәм органик булмаганнарга бүленәләр», монда органик бер төркемгә хас, икенче төркемгә хас билге түгел.

Гади дихотомик бүленүнең нигезендә бер генә билге тора.

Катлаулы дихотомик бүленүнең нигезендә бер үк вакытта бердән артык билге тора.

§7. Классификация

Классификация – өзлексез рәвештә күп баскычлы бүлү ярдәмендә, бирелгән күплектәге элементларны системалаштырып, классларга бүлү.

Почмакларның зурлыгы буенча өчпочмаклар (ӨП) кысынкы (КӨП), җәенке (ҖӨП) һәм турыпочмаклы булалар (ТӨП).

Якларының нисбәте буенча тигезъяклыларга (ике ягы тигез) (ТгяӨП) һәм төрле яклыларга (ТряӨП) бүленә.



Классификация төрләре

Классификациянең нигезен сайлап алу бик мөһим. Төрле нигез бер үк төшенчәгә төрле классификация бирә.

Классификациядә нигез булып предметның табигатен чагылдыра торган төп билге алынса, мондый классификацияне **табигый классификация** дип атыйлар.

Мәсәлән, китапларны төп билгесе буенча әдәбиятка, фәнни китапка һәм уку әсбабына бүләләр. Мондый классификациянең фәндә һәм практикада әһәмияте бик зур.

Әгәр классификациягә нигез итеп классификацияләнә торган предметларның табигатен чагылдырмый торган билге алынса, мондый классификация **ясалма яки ярдәмчел классификация** дип атала.

Мәсәлән, китапханәләрдәге каталогта китаплар исеме һәм автор фамилияләре алфавит буенча бүленәләр.

§8. Бүленү кагыйдәләре һәм бүленүдә очрый торган хаталар

Бүленү түбәндәге кагыйдәләргә буйсынырга тиеш:

1. Чамадан артмау кагыйдәсе. Әгәр нинди дә булса бүленү нигезендә яки ыругтагы төр принцибында бүлгәндә, без барлык төрләрне төгәл итеп, аларның санын арттырмыйча да, киметмичә дә санап чыгарга тиешбез. Бүлү билгеле бер нигез буенча башкарылырга тиеш. **Бүлә торган әгъзаларның күләмнәре кушылмасы бүленә торган төшенчәнең күләме белән тигез булырга тиеш.**

Бу кагыйдәне үтәмәгәндә, ике хата барлыкка килергә мөмкин:

Тулы булмаган бүленү. Бу – бирелгән билге буенча бүленгән әгъзалар санында берәр төре җитмәгән очрагында барлыкка килә.

Мәсәлән, өчпочмакларны кысынкы почмакларга һәм җәенке почмакларга бүләләр, ә турыпочмакны күздән ычкындыралар.

Киңәйгән бүленү. Әгәр бүлә торган әгъзалар арасында күләмендә бүленә торган төшенчәнең күләменә кермәгән предметлар булса яки башка нигез белән бүленгән әгъза очраса, бу – киңәйгән бүленү хатасы була.

Мәсәлән, шул ук өчпочмакларны төрле яклы, тигез яклы һәм тигез кырлыга (өч ягы да тигез) бүләләр. Тигез кырлы өчпочмак – артык әгъза, чөнки тигез кырлы өчпочмак кысынкы тигез яклы өчпочмакның аерым очрагы булып тора, тигез кырлы өчпочмак җәенке дә, туры почмаклы да була алмый.

2. Читләштерү кагыйдәсе. Монда бүленә торган төшенчәнең күләмендәге һәрбер элементы бер бүленү әгъзасына төгәл итеп керергә тиеш. Бүленә торган төшенчәнең берәр элементы бер үк вакытта, ким дигәндә, ике бүлә торган әгъзага керсә, хата барлыкка килә.

Мәсәлән, әгәр без, студентларны яхшы укый торганнарга, өлгерүчеләргә һәм өлгерүчеләргә бүлсәк, бу – дөрес булмый, чөнки яхшы укый торганнар өлгерүчеләр күплегенә керә.

3. Бер нигез кагыйдәсе. Бу кагыйдә билгеләрнең үзгәрүе буенча бүлү төренә генә кагыла. Бүлү бер нигез буенча башкарылырга тиеш. Бүлү нигезе булып һәрвакытта бер генә билге кулланылырга тиеш.

Мәсәлән, ишек материалы буенча без ишекне агач, тимер, пластикка бүлә алабыз; ишек буялган, тышланган булырга мөмкин. Бу – ишекнең өстәмә сыйфатлары. Әмма бу билгеләрне бутарга ярамый һәм «ишек тимер, агач һәм буялган», дигән бүлү дөрес булмый.

4. Өзлексезлек кагыйдәсе. Бу кагыйдә күпбаскычлы, өзлексезле бүленүгә кагыла. **Бүлү бер-бер артлы булырга тиеш, ягъни бүленү процессында якындагы төрләргә күчәргә һәм аларны сикереп үтәргә ярамый.** Бу кагыйдәне бозу «бүлүдәге сикереш» дип атала.



Әгәр А төшенчәсенә төр, ә В төшенчәсенә ыруг була торган ниндидер С төшенчәсе булмаса, В төре А га карата якындагы төр дип атала, Эйлер түгәрәкләре белән аларны сурәтләргә була. Мәсәлән, «тереклек үсемлекләргә, умырткалы хайваннарга һәм умырткасыз хайваннарга бүленә» дигән бүленеш дөрес түгел. «Тереклек үсемлекләргә һәм хайваннарга бүленә, үсемлекләр – берьеллык һәм күпьеллыкларга, хайваннар умырткалылар һәм умырткасызларга бүленә» дисәк, бу – дөрес була.

Өченче бүлек. Хөкем

Тема 1. Гомуми характеристика

§1. Хөкемнең мәгънәсе

Хөкем

Формаль мантыйкта хөкем дигәндә, фикерләү формасын күздә тоталар. Анда раслау яки инкарь белән предмет билгеләренең бәйләнеше итү һәм алар арасындагы мөнәсәбәтләр күрсәтелә.

«Көн», «төн», «кояшлы көн» яки «кояшсыз көн» мисалларын карыйк. Хөкемдә исә фикерләү предметлары арасындагы нинди дә булса мөнәсәбәткә игътибар юнәлтелә:

«көн кояшлы», «көн кояшсыз», «көн үтте». Юридик мисалларны карасак, «закон» – төшенчә, «закон бастырылган» – хөкем; «басылып чыккан закон» – төшенчә, ә «басылып чыккан закон эшли башлады» – хөкем.

Мантыйкны өйрәнгәндә, җөмләнең мәгънәсе итеп, ике мөһим ситуацияне: чынны һәм ялганны алырга була.
Таблица ярдәмендә бу схеманы түбәндәгечә күрсәтеп була:

Тамга	**Исем**	**Җөмлә**
Уйдагы сурәт	Төшенчә	Хөкем
Мәгънә	Объект	Чын/ялган

§2. Хөкем һәм җөмлә

Хөкем – предмет һәм аның билгесен, предметлар арасындагы мөнәсәбәтләрне, предметның булу фактын раслый торган һәм инкарь итә торган фикерләү формасы; хөкем йә чын, йә ялган була.

Хөкемнең бер мантыйкый өлеше хөкем булмаса, **гади хөкем** дип атала.

Хөкемнең кайсыдыр мантыйкый өлеше хөкем булса, **катлаулы хөкем** дип атала.

Мәсәлән, «Кояш балкый». Бу тулысынча безнең билгеләмә буенча гади хөкем. Әмма гади хөкем дип, без мондый хөкемнәрне дә санарбыз: «һәрбер студент – шат күңелле кеше» («һәрбер» яки «кеше» сүзләрен алып ташлагач, яңадан хөкем барлыкка килүенә карамастан).

Без, катлаулы хөкем дип, мондый хөкемнәрне атарбыз: «һәрбер студентның шат кеше булуы дөрес түгел» яки «һәрбер студент шат күңелле һәм зирәк кеше». Бу мисаллардан күренгәнчә, безнең билгеләмәдә «өлеш» дигән термин теләсә нинди түгел, ә хөкемнең мантыйкый өлешен генә уйда тота.

§3. Хөкемнең дөреслек һәм чынлык төшенчәсе

Гади хөкемнәрнең чын һәм ялган төшенчәләре

Әгәр объект белән билге арасындагы бәйләнеш расланса һәм ул чынбарлык-та булса, яки бәйләнеш инкарь ителсә, чынбарлыкта булмаса, хөкем чын була.	Әгәр объект белән билге арасында бәйләнеш расланса һәм ул чынбарлыкта булмаса, яки бәйләнеш инкарь ителсә, ул чынбарлыкта булса, хөкем ялган була.

§4. Хөкемнең төзелеше

Берәр нәрсәгә карата әйткән әйберне яки нәрсә турында сүз бара торган объектны **хөкемнең иясе яки субъекты** (латин сүзе subjectum – нигездә ятучы) дип атыйлар.

Әйбергә карата әйтелгән нәрсәне яки субъект турындагы билгене **хөкемнең хәбәр яки предикаты** (латин сүзе praedicatum – әйтелгән) дип атыйлар.

Бәйләвеч (связка)

Субъектны һәм предикатны бер хөкемгә бәйләүчене **бәйләвеч** дип атыйлар.

Мәсәлән: «роза – ул чәчәк», дигән хөкемдә «роза» төшенчәсе – субъект, «чәчәк» – предикат һәм «ул» бәйләвеч булып тора.

Квантор

Хөкем структурасының соңгысы, дүртенче элементы булып, **квантор** (латин сүзе – ничә) тора. Ул «барлык», «һәркем», «бернинди дә», «күбесенчә» кебек сүзләр белән чагылдырыла. Ул хөкемнең сан яки микъдар буенча характерын күрсәтә, гомуми яки хосусый икәнен белдертә.

Мәсәлән, «барлык имезүче хайваннар – умырткалы», «оранжерея – үсемлекләр үстерә торган йорт» (монда барлык оранжереяләр дә икәнен чамаларга була).

Әгәр төшенчә-субъектның күләме өлешчә генә булса, безнең алда хосусый хөкем була.

Мәсәлән, «кайбер студентлар – спортсменнар».

Татар телендә хөкемне чагылдыра торган җөмләнең структурасы еш кына хөкемнең структурасы белән туры килми. Бер үк фикер телдә төрлечә әйтелергә мөмкин:

Мәсәлән, «Габдулла Тукай – бөек шагыйрь» хөкем структурасы, мондый җөмләләр белән белдерелергә мөмкин:

1. Габдулла Тукай – бөек шагыйрь («ул» бәйләгече сызык белән алмашынган).

2. Габдулла Тукай бөек шагыйрь булып тора («ул» бәйләгече «булып тора» сүзе белән алмашынган»)

3. Габдулла Тукай бу бөек шагыйрь (монда бәйләгеч төшеп калган, предикат субъекттан алдарак куелган).

Тема 2. Гади хөкемнәр

§1. Гади хөкем төрләре һәм аларның төзелеше

Гади хөкемнәр түбәндәгеләргә бүленәләр

Атрибутив хөкемнәр билге-үзлекнең булуы яки булмавы белән бәйләнгән (латин сүзе attribuo – өстәп бирү).

Атрибут дигәндә, гадәттә, предметның нинди дә булса билгесе күз алдына китерелә, берәр үзлекнең булуы яки булмавы чагыла.

Мәсәлән, «Татарстан суверен республика булып тора». Бу – атрибутив хөкем, чөнки «Татарстан» предметына «суверен республика» үзлек-билгесе тагылган.

Һәрбер атрибутив хөкем субъект (мантыйкый ия) белән предикат (мантыйкый хәбәр) һәм бәйләвеч белән кванторлар-лардан (еш кына бәйләвеч белән квантор уйда гына була) тора. Әгәр субъектны **S** (subjectum сүзенең беренче хәрефе) хәрефе белән, предикатны **P** (praedicatum сүзенең беренче хәрефе) хәрефебелән тамгаласак, атрибутив хөкемнең структурасын түбәндәгечә язарга була:

Раслый торган хөкем:
S-P, S P булып тора яки
S ул P

Инкарь итә торган хөкем:
S-P түгел, S P түгел.

Реляцион хөкемнәр билге-мөнәсәбәтенең булуы яки булмавы белән бәйләнгән (латин сүзе Relatio – мөнәсәбәт).

Гади хөкемнең бер төре булып, реляцион яки мөнәсәбәтле хөкем тора. Бу хөкемдә предметлар бер-берсенә карата ниндидер мөнәсәбәттә торалар.

Мәсәлән, «Мамадыш Чаллы белән Казан арасында урнашкан». Монда «урнашу» мөнәсәбәте һәм өч предмет «Мамадыш», «Чаллы», «Казан» тора. «Камил – Булатның әтисе», бу мисалда «әти булу» мөнәсәбәте тора.

«Казан Чаллыдан зуррак», монда – «зурлык мөнәсәбәте».

Хөкемдәге мөнәсәбәтләр-не **R** (латин сүзе Relatio – мөнәсәбәт) белән, ә андакергән элементларны **a, в, c, ...** хәрефләре белән тамгалыйлар. «Камил – Булатның әтисе», дигән мисалда «әтисе» – R, «Камил» – a, «Булат» – b дип тамгаласак, бу хөкемнең структурасыболай була:

a R b яки R (a,b)

Экзистенциаль хөкемнәр предметның булу яки булмавын күрсәтә торган хөкем. Бу хөкемне өстәмә килешүләр белән атрибутив яки реляцион хөкем итеп карарга була.

Түбәндәге мисалларны карыйк:

1. Айрат – шат күңелле;

2. Айрат – тапкыр;

3. Айрат бар (яки Айрат монда).

Беренче һәм икенче хөкемдә «Айрат» предметының аерым үзлекләре характерлана, ә өченче хөкем предмет турында тулаем алып сөйли. Еш кына хөкемдә «була», «бар» сүзләре предикатта әйтелми, ә күңелдә тотыла.

Экзистенциаль хөкемнең структурасы, атрибутив хөкемнеке кебек, ягъни бер субъекттан һәм бер предикаттан тора.

Реляцион хөкемнең субъекты *ул – бер-берсе арасында мөнәсәбәт булуны раслый якиинкарь итә торган объектлар төшенчәсе.*

Реляцион хөкемнең предикаты *ул – хөкемдәге раслау яки инкарь итү бәйләнеше.*

§2. Гади хөкемнәрне сыйфат һәм сан буенча бүлү

Мантыйкта югарыда караган гади хөкемнәрне «сыйфат» һәм «сан» бүлү нигезе буенчаике төргә бүләләр.

Хөкемнәрне сыйфат буенча бүлү

Әгәр предикат субъектныкы булса, бу раслый торган хөкем була.

Әгәр предикат субъектныкы булмаса, бу инкарь итә торган хөкем була.

Мәсәлән, «әрем – дару үләне» – раслый торган хөкем, монда «дару үләне» предикаты «әрем» субъектыныкы булып тора. «Әрем кыяклы үсемлек түгел» бу – инкарь итә торган хөкем, чөнки монда «кыяклы үсемлек» әремгә хас түгел. Ә «әрем – кыяксыз үсемлек» мисалында безгә нинди хөкем икәнен белү өчен, аның бәйләвечен карарга кирәк. Әгәр бәйләвечтә «түгел» кисәкчәсе булса (яки уйланылса), ул инкарь итә торган хөкем була.

Раслый торган хөкемне ике төргә бүләргә була:

Уңай төшенчә белән бирелгән предикатлы хөкем.

Мәсәлән, «ул гаепле».

Тискәре төшенчә белән бирелгән предикатлы хөкем.

Мәсәлән, «ул гаепсез».

Инкарь итә торган хөкемне дә ике төргә бүләргә була:

Уңай төшенчә белән бирелгән предикатлы хөкем.

Мәсәлән, «ул гаепле түгел».

Тискәре төшенчә белән бирелгән предикатлы хөкем.

Мәсәлән, «ул гаепсез түгел».

Хөкемнәрне сан буенча бүлү

Хөкемнең саны ул – хөкемнең субъекты нинди күләмдә булуын билгели торган хөкем характеристикасы. Хөкемнәрне сан буенча ялгыз, шәхси һәм гомумигә бүләрбез:

Гомуми (общее) хөкем

Гомуми хөкемдә предикат субъектның барлык күләмен уйда тотып әйтә.

Гомуми хөкемнәрнең үзләрен ике төргә бүләргә була: аеручыга һәм аермаучыга.

Аера торган хөкемнәр татар телендә «гына», «генә» кисәкчәләре ярдәмендә әйтеләләр.

Мәсәлән, «Кешеләр генә җир йөзендә аңлы тереклек ияләре». Бу җир йөзендә башка аңлы тереклек ияләре юк икәнне аңлата.

Әгәр бирелгән төркемгә хас билгене, башка төркемнәргә дә карата әйтеп булса, бу **аермый торган хөкем** була.

Мәсәлән, «Барлык адвокатлар – юристлар», бу – юристлар булып, прокурорлар да, судьялар да була алганын аңлата.

Шәхси (частное) хөкем

Хосусый хөкемдә предикат субъектның күләмендәге кайбер элементларына гына кагыла.

Хосусый хөкемнәрне дә төрләргә бүләргә була. Алар билгеле һәм билгесезгә бүленәләр.

Билгеле хосусый хөкемнәрдә предметлар төркеменең кайсыдыр өлеше турында гына әйтелә һәм төркемдәге башка предметларга карата моны әйтеп булмый. Монда кулланыла торган «кайбер» сүзе «кайберләре генә» мәгънәсендә тора.

Мәсәлән, «Кайбер кешеләр озын буйлы», монда кешеләр озын буйлыларга һәм кыска буйлыларга бүленүе күз алдында тотыла.

Билгесез хосусый хөкемнәрдә предметлар төркеменең өлешенә кагыла торган билгене төркемдәге барлык предметларга да әйтеп була. Монда «кайбер» сүзе
«кайберсе» яки «барысы да» мәгънәсендә кулланыла.

«Кайбер студентларда мантыйк китабы бар», монда мантыйк китабы барлык студентларда да булырга мөмкин, бәлки без кайбер студентларда китапның булганын күрмәгәнбездер генә.

Төшереп калдыра торган хөкемнәр – гомуми хөкемнәр, аларда предметларның бер өлеше төшереп калдырыла, чөнки алар каралган класс предметларындагы билгеләргә ия түгел.

Мәсәлән, «борынгы община строеннан кала, һәртөрле җәмгыять класслы була». Бу хөкем ике хосусый хөкемнең синтезы буларак барлыкка килгән: «Кайбер җәмгыятьләр класслы була» һәм «Кайбер җәмгыятьләр классыз була».

Төшереп калдыру хөкемнәре барлыкка килгәндә, төгәлсезрәк белемнәрдән төгәлрәк белемнәргә күчелә. Бу хөкемнәр танып белү процессында мөһим роль уйныйлар.

Ялгыз (единичное) хөкем

Ялгыз хөкем ул – аерым фикер предметына карата әйтелә торган хөкем. Татар телендә алар
«бу» яки ялгыз исемнәр, ялгызлык төшенчәләр белән биреләләр.

Мәсәлән, «бу – Кремль», «Яр Чаллы – машина төзүчеләр шәһәре».

Ялгыз хөкемнәрне дә, хосусый һәм гомуми хөкемнәрне кебек, төрләргә аерырга була.

Аларның берсе – **индивидуаль** предметлар турындагы хөкем.

Мәсәлән, «Бу – Кояш», «Ай – планета түгел».

Һәм икенчесе – **күплек**, ягъни җыючы төшенчә ярдәмендә бербөтен итеп карала торган предметлар күплеге турындагы хөкем. Күплек хөкемдә, ким дигәндә, бер субъект предметлар классы булып тора.

Мәсәлән, «кояш системасы – безнең Галактикада бердәнбер планеталар системасы түгел».

§3. Категорик (безусловно) хөкем һәм аның төрләре

Дүрт категорик хөкем төрен чыгарабыз:

1. A – гомуми раслау хөкеме (латинча affirmo ягъни «раслыйм» сүзенең беренче сузык хәрефе).
2. I – шәхси раслау хөкеме (affirmo сүзенең икенче сузык хәрефе).
3. E – гомуми инкарьләү хөкеме (латинча nego, ягъни «инкарьли» сүзенең беренче сузык хәрефе).
4. O – шәхси инкарьләү хөкеме (nego сүзенең икенче сузык хәрефе).

Категорик хөкемнең каноник формасын чыгарабыз:			
A: «Барлык S P»	**E: «Бер генә S P түгел»**	**I : «Кайбер S P була»**	**O: «Кайбер S P түгел»**
A: «Барлык кешеләр музыкага сәләтле җан ияләре».	E: «Бер генә кеше дә музыкага сәләтле җан иясе түгел».	I: «Кайбер кешеләрмузыкага сәләтле җан ияләре».	O: «Кайбер кешеләрмузыкага сәләтле җан ияләре түгел».

Әгәр S белән P арасындагы мөнәсәбәт түбәндәгечә булса, **A** бу хөкем чын була:

а)



б)



Әгәр S белән P арасындагы мөнәсәбәт түбәндәгечә булса, **E** тибындагы хөкем чын була:







Әгәр S белән P арасындагы мөнәсәбәт түбәндәгечә булса, **I** тибындагы хөкем чын була:

а)



б)



в)



г)



Әгәр S белән P арасындагы мөнәсәбәт түбәндәгечә булса, **O** тибындагы хөкем чын була:







§3. Хөкемдә иянең (S) һәм хәбәрнең (P) күләмнәре

Хөкемнең иясе яки хәбәре мәгълүм бер класстагы предметларның барысын да түгел, ниндидер бер өлешен генә чагылдырган очракларда, ия яки хәбәр бөтен күләмендә алынмаган, яки бүленмәгән диләр.

Мәсәлән, «Кайбер самолетларда реактив двигательләр була» дигән хөкемдә ия бүленмәгән, чөнки анда барлык самолетлар турында түгел, кайберләре турында гына әйтелә.

Ә инде ия шул класстагы барлык предметларны чагылдырган очракларда, ия бөтен күләмендә алынган, яки бүленгән диләр. *Мәсәлән, «Барлык самолетлар һавадан авыр булалар» дигән хөкемдә ия бүленгән, чөнки анда барлык самолётлар турында әйтелә.*

Гомуми раслау хөкемнәрендә, хосусый раслау хөкемнәрендә, гомуми ин- карьләү хөкемнәрендә һәм хосусый инкарьләү хөкемнәрендә иянең һәм хәбәрнең күләмнәрен тикшереп карыйк.

1. (А) Гомуми раслау хөкемнәрендә ия бүленгән. Моның шулай икәнлеге хөкемнең формуласыннан ук **(«барлык S лар P булалар»)** күренеп тора, чөнки анда теге яки бу классның барлык вәкилләре турында әйтелә.

Мәсәлән, барлык автомобильләр двигательле булалар» дигән хөкемдә ия бөтен күләмендә алынган яки бүленгән: автомобильләрнең барысының да двигателе була.



Гомуми раслау хөкемнәрендә хәбәрнең күләме иянең күләменнән киңрәк булса, мондый хөкемнең хәбәре бүленмәгән була.

Барлык галогеннар – химик элементлар» дигән хөкемдә хәбәр бөтен күләмендә алынмаган, чөнки хөкемдә барлык химик элементлар турында әйтелми (барлык химик элементлар – галогеннар диелмәгән); башкача әйткәндә, мондый хөкемдә хәбәр бүленмәгән. Бу хөкемдә ия – төр, ә хәбәр – ыруг.

Гомуми раслау хөкемендә хәбәрнең күләме иянең күләменә тигез булса, мондый хөкемдә хәбәр бүленгән була.

«Барлык снайперлар – аеруча төз, бик яхшы атучы, ату, маскировка һәм күзәтү осталыгын бик яхшы үзләштергән кешеләр» дигән хөкемдә хәбәр бөтен күләмендә алынган, чөнки аеруча яхшы атучы, ату, маскировка һәм күзәтү осталыгын бик яхшы үзләштергәннәрнең барысы да снайперлар, һәм, димәк, хөкемдә аеруча оста атучыларның барысы турында да әйтелә.

2. (I) Хосусый раслау хөкемнәрендә ия бүленмәгән. Мондый хөкемдә иянең бүленмә- гән булуы бу хөкемнең формуласыннан ук күренеп тора: **«кайбер S лар P булалар».** Хөкемдә сүз барлык предметлар турында түгел, бу предметлар классының бөтен күләме турында түгел, бәлки кайбер предметлар турында гына бара.

Мәсәлән, кайбер хикәяләр кызыклы иде дигән хөкемдә бу шулай. Хикәяләрнең бары-сы да түгел, тик бер өлеше генә кызыклы икәнлеге ап-ачык күренеп тора. Димәк, ия бөтен күләмендә алынмаган, ул бүленмәгән.



Хосусый раслау хөкемнәрендә хәбәрнең күләме иянең күләменнән киңрәк булса, мондый хөкемнәрдә хәбәр бүленмәгән була.

Кайбер галимнәр – Сталин премиясе лауреатлары» дигән хөкемдә ия генә түгел, хәбәр дә бүленмәгән. Хәбәрдә без галимнәрнең барысы турында да түгел, бер өлеше турында гына беләбез. Хәбәр бөтен күләмендә алынмаган, ул бүленмәгән.



Хосусый раслау хөкемнәрендә хәбәр иянең күләменә кертелгән булса, мондый хөкемнәрдә хәбәр бүленгән була.

Мәсәлән, «Кайбер язучылар – драматурглар» дигән хөкемдә хәбәр бүленгән, чөнки сүз драматургларның барысы турында да бара.

3. (Е) Гомуми инкарьләү хөкемнәрендә ия дә, хәбәрдә бүленгән була.

Мәсәлән, мондый хөкемне алыйк: «Бер генә металл да органик җисем түгел». Биредә ия бүленгән, чөнки без барлык металлар турында, алар органик җисемнәр түгел, дип раслыйбыз. Бу гомуми инкарьләү хөкеменең формуласыннанук ***(бер генә S та P түгел)*** *ачык күренеп тора, чөнки* ***«бер генә S та»*** *дип әйтү* ***«барлык S лар»*** *дию белән бер үк.*

Бу хөкемдә хәбәр дә шулай ук бүленгән. Әгәр бер генә металл да органик җисем түгел икән, ул чакта бер генә органик җисем дә металл булмый. Бу хөкемдә сүз барлык металлар турында бара.



4. (О) Хосусый инкарьләү хөкемнәрендә ия бүленмәгән була. Моның шулай икәнлеге хөкемнең формуласыннан ук күренеп тора: **«Кайбер S лар P түгел».** Биредә сүз теге яки бу класстагы предметларның бер өлеше турында бара.

Мәсәлән, «Кайбер спортсменнар шахматчы булмыйлар» дигән хөкемдә ия бөтен күләмендә алынмаган, чөнки без спортсменнарның барысы турында да түгел, кайберләре турында гына сөйлибез.



Терминнарның А, Е, I, О хөкемнәре таралу (распределенность)таблицада болай чагыла:

Терминнар	**Терминнарның төрләре**			
	А	**Е**	**I**	**О**
S	+	+	–	–
P	–(+)	+	+(–)	+

Монда «+» терминның таралганын, «–» таралмаганын аңлата.

Бу таблицаны, үз чиратында, түбәндәге кагыйдә белән гомумиләштерергә була: Гомуми хөкемнәрдә – субъект, ә инкарь итә торганнарда предикат таралган була.

§4. Категорик хөкемнәр арасындагы мөнәсәбәтләр

Системалаштыру һәм ачык итеп күрсәтү өчен, бу мөнәсәбәтләрне, урта гасырда ук уйланып чыгарылган **мантыйкый квадрат** аша күрсәтергә була:

Тиңдәш хөкемнәр

Буйсынучанлык

Буйсынучанлык мөнәсәбәте саннар төрле, ә сыйфатлар бер булган хөкемнәр арасында була, ягъни А белән I һәм Е белән О арасындагы мөнәсәбәтне характерлый. Монда хосусый хөкемнәр гомуми хөкемнәргә буйсыналар (А, Е – буйсындыра торган хөкем, ә I, О – буйсына торган хөкем).

а) буйсындыра торган хөкем үзенең чынлыгы буйсына торган хөкемнең чын булуына шарт булып тора, *ягъни әгәр «барлык бөек кешеләр тәбәнәк буйлы» (**А**) хөкеме чын булса, димәк «кайбер бөек кешеләр тәбәнәк буйлы» (**I**)чын була. Шулай ук бу **Е** белән **О** га да кагыла.*

чын (А) → чын (I) чын (Е) → чын (О)

Бу ике очракта шарт кире якка булмаска да мөмкин, ягъни I, О чын булса, А, Е чын була дигән сүз түгел. Алар ике очракта да йә чын, йә ялган булырга мөмкин. *Мәсәлән, «Кайбер бөек кешеләр тәбәнәк буйлы» (I) хөкеме чын булса, ул – «Бөтен бөек кешеләр тәбәнәк буйлы» (А) хөкеме чын була ала дигәнне аңлатмый (бөек кешеләрнең озын буйлылары да булырга мөмкин), ягъни ул чын да, ялган дабулырга мөмкин.*

б) буйсына торган хөкемнең ялганлыгы буйсындыра торган хөкемнең ялган булуына шарт булып тора, *ягъни «Кайбер бөек кешеләр тәбәнәк буйлы» ялган булса, (ягъни тәбәнәк буйлы бөек кешеләр юк), димәк, әлбәттә, «Барлык бөек кешеләр дә тәбәнәк буйлы» ялган булып чыга.*

ялган (I) → ялган (А) ялган (О) → ялган (Е

в) буйсындыра торган һәм буйсына торган хөкемнәр икесе бер үк вакыта ялган булырга мөмкиннәр, ягъни бер-берсенә бәйле булалар. *Мәсәлән, «Бер кеше дә үлемгә дучар түгел» (Е) ялган булса, «Кайбер кешеләр үлемгә дучар түгел» хөкеме дә ялган була.*

ялган (А) → ялган (I) ялган (Е) → ялган (О)

Өлешчә тиңдәшлек

Бу мөнәсәбәт бер сандагы, әмма төрле сыйфат-тагы хөкемнәр арасында була, безнең очракта I белән О арасындагы мөнәсәбәтне характерлый.

Хөкемнәр өлешчә тиңдәшлек мөнәсәбәтендә торалар, әгәр алар икесе дә берьюлы ялган була алмасалар.

ялган (О) ≠ ялган (I)

I һәм О арасындагы капма-каршылык мөнәсә-бәтен түбәндәгечә истә калдырырга була:

чын (I) ↔ чын (О)

ялган (I) → чын (О)

ялган (О) → чын (I)

Тиңдәшсез хөкемнәр

Әгәр хөкемнәр икесе берьюлы ялган да, берьюлы чын да була ал масалар, алар каршылык мөнәсәбәтендә торалар.

Каршылыклык (контрадикторлык). Хөкемнәр каршылыклык мөнәсәбәтендә торалар. Каршылыклык мөнәсәбәтендә А белән О, Е белән I хөкемнәре торалар.

чын (А) ≠ чын (О)
чын (Е) ≠ чын (I)
ялган (А) ≠ ялган (О)
ялган (Е) ≠ ялган (I)

Мәсәлән, «Бөтен бөек кешеләр тәбәнәк буйлы» һәм «Кайбер бөек кешеләр тәбәнәк буйлы түгел» хөкемнәре каршылыклык мөнәсәбәтендә торалар.

Аларның берсе чын булса, икенчесе һәрвакытта ялган була, һәм киресенчә.

Каршылыкларны түбәндәгечә характерларга була:

чын (А) → ялган (О)
чын (Е) → ялган (I)
ялган (А) → чын (О)
ялган (Е) → чын (I)
чын (О) → ялган (А)
чын (I) → ялган (Е)
ялган (О) → чын (А)
ялган (I) → чын (Е)

Каршыдашлык. Әгәр Aһәм В хөкемнәре ике- се берьюлы чын була алмасалар, алар кар- шыдашлык мөнәсәбәтендә булалар:

чын (А) ≠ чын (Е)

чын (Е) ≠ чын (А)

Монда аларның икесенең дә ялган була алганын күрергә була. Каршыдашлык мөнәсәбәтенә А һәм Е хөкемнәре керә.

Мәсәлән, «Барлык бөек кешеләр тәбәнәк буйлы» һәм «Бер генә дә бөек кеше тәбәнәк буйлы түгел» хөкемнәре каршыдашлык мөнәсәбәтендә торалар.

Монда,

ялган (А) → ялган (Е)
ялган (Е) → ялган (А)
чын (А) → ялган (Е)
ялган (Е) → чын (А)
аша күрсәтергә була.

Категорик хөкемнәр арасындагы мөнәсәбәтләр

Тема 3. Катлаулы хөкемнәр

§1. Катлаулы хөкемнәр

Катлаулы хөкемнәр дип, гади хөкемнәрнең мантыйкый теркәгечләр ярдәмендә төрлечә кушылулары атала.

Бәйләгечләрне түбәндәгечә тамгалыйлар

Теркәгеч	Тамгасы
... һәм ... – куша торган теркәгеч яки **конъюнкция**	∧
... яки ... (…, ягъни …) – аера торган теркәгеч яки **дизъюнкция**	∨
йә ..., йә ... (яки …, яки …) – төгәл аера торган теркәгеч яки **төгәл дизъюнкция**	$\underline{\vee}$
әгәр ... , ... идең-, -чак- – шартлы теркәгеч яки **импликация**	→
әгәр ... , шул чагында гына – тигезли торган теркәгеч яки **эквивалентлык**	≡
... юк, юклык кушымчалары (татар телендә фигыльдә -сез, -сыз, -ма, -мә кебек кушымчалар кулланыла) – **инкарь итү**	¬

Хөкемнең алмаша торган элементларын, безнең очракта гади хөкемнәрне, латин хәрефләре p, q, r, s, p_1, q_1, r_1, s_1 …. белән тамгалыйлар.

Мәсәлән, «Кайчан сез бирелгән мәсьәләләрне чишәсез һәм лекциядә шаулап утырмый-сыз, шунда гына сез мантыйктан яхшы билге алачаксыз» мисалын мантыйк формасынакитерәбез.

Гади хөкемнәр:

— «Сез мантыйктан яхшы билге алачаксыз» – **p**,

— «Сез бирелгән мәсьәләләрне чишәсез» – **q**,

— «Лекциядә шаулап утырмыйсыз» – **r** белән билгеләнә.

Бәйләвечләр:

— «кайчан, шунда гына» – ≡ (эквивалентлык)

— «һәм» – ∧ (конъюнкция)

— «-мыйсыз» – ¬ (инкарь итү).

Шулай итеп, түбәндәге мантыйкый форманы чыгарабыз: p≡(q∧¬r).

§2. Катлаулы хөкем төрләре һәм теркәгечләрнең мәгънәсе

Ике гади хөкемнән һәм мантыйкый теркәгечләрдән төзелгән катлаулыхөкемнәрне карап үтик.

1. Куша торган хөкем – конъюнкция.

«һәм» теркәгеченең мәгънәсен аңлау өчен, түбәндәге мисалны китерик. Мәсәлән, сез дустыгызга: «Иртәгә мин укырга барам һәм икәү теннис уйнарбыз» дисәгез, сез кайчакта вәгъдәгезне үтисез, ә кайсы очракта – юк? Беренче очракта, әлбәттә, безнең «һәм» теркәгече белән төзелгән хөкемне дөрес дип уйлап карыйбыз, икенче очракта – ялган.

Хөкемнәрне гомумиләштерү өчен, «Мин иртәгә укырга барам»-ны p аша, ә «икәү теннис уйныйбызны» – q аша билгелик.

Төзи торган бу хөкемнәрнең дүрт чыгыш комбинацияләрен карыйк:

1) *Сез укырга барасыз* һәм *дустыгыз белән теннис уйныйсыз*. Шулай итеп, p хөкеме дә, һәм q хөкеме дә – чын. Бу очракта сез, берсүзсез, вәгъдәгезне үтәдегез, димәк, безнең катлаулы хөкем чын булырга тиеш. Без таблицада беренче юлны язабыз:

p	**q**	**p ^ q**
Ч	Ч	Ч

2) *Сез укырга барасыз*, ягъни p – чын, әмма *дустыгыз белән теннис уйнамыйсыз*, ягъни q – ялган. Бу очракта сез вәгъдәгезне үтәмисез, димәк, катлаулы хөкем ялган була. Таблицаның икенче юлын чыгарабыз:

p	**q**	**p ^ q**
Ч	Я	Я

3) *Сез укырга бармыйсыз*, әмма *дустыгыз белән теннис уйныйсыз*. Бу очракта да вәгъдәгезне үтәмисез. Безнең катлаулыхөкем дә ялган.

		p

4) *Сез укырга да бармыйсыз* һәм *дустыгыз белән теннис тауйнамыйсыз*. Бу очракта инде, берсүзсез, сезнең вәгъдәгез үтәлмәгән була.

		p

Шулай итеп, без p **^** q хөкеменең, аны төзи торган хөкемнәрнең чыгыш комбинацияләре өчен чынлык чыгышларын билгеләдек. Нәтиҗәне без түбәндәге таблицага яза алабыз:

p	**q**	**p ^ q**
Ч	Ч	Ч
Ч	Я	Я
Я	Ч	Я
Я	Я	Я

Монда шуны әйтергә була: әгәр p һәм q хөкемнәре икесе дә берьюлы чын булса, конъюнкция чын була, калган очракта хөкем ялган була.

2. Аера торган хөкем – дизъюнкция

Әйтик, сез дустыгызга «Мин иртәгә укырга барам яки «икәү теннис уйнарбыз» дип вәгъдә бирәсез.

1) *Сез укырга да барасыз* һәм *дустыгыз белән тенниста уйныйсыз*. Бу очракта сез вәгъдәгезне икеләтә үтәдегез дияргә була. Монда «яки» теркәгече икесенең берсен генә эшләргә ярый дигән мәгънәдә түгел, ә икесенең берсен эшләсәң дә, икесен эшләсәң дә «ярый» мәгънәсендә карала. Шуңа күрә бу хөкем чын була:

p	q	p ˅ q
Ч	Ч	Ч

2) *Сез укырга барасыз*, әмма *дустыгыз белән теннис уйнамыйсыз*. Сез аңарга вәгъдәгезнең икесенең берсен генә эшли алганыгызны белдерәсез. Шуңа күрә сез вәгъдәгезне үтәдегез, бу катлаулы хөкем чын икәнне аңлата.

p	q	p ˅ q
Ч	Я	Ч

3) *Сез укырга бармыйсыз*, әмма *дустыгыз белән теннис уйныйсыз*. Бу очракта да, икенче очрактагы кебек, катлаулы хөкем чын була.

p	q	p ˅ q
Я	Ч	Ч

4) *Сез укырга да бармыйсыз, дустыгыз белән теннис та уйнамыйсыз.* Бу – вәгъдәгезнең үтәлмәгәнен аңлата, димәк, катлаулы хөкем ялган була.

p	q	p ˅ q
Я	Я	Я

Шулай итеп, түбәндәге таблицаны чыгарабыз:

p	q	p ˅ q
Ч	Ч	Ч
Ч	Я	Ч
Я	Ч	Ч
Я	Я	Я

Монда гомумиләштереп шуны әйтергә була: әгәр А һәм В хөкемнәре икесе дә ялган булса, дизъюнкция ялган була, калган очракта хөкем чын була.

3. Төгәл аера торган хөкем – төгәл дизъюнкция

Монда катлаулы хөкемне төзүчеләр, гадәти аера торган хөкемнән аермалы буларак, тиңдәш булмыйлар, ягъни, чын булсын өчен, хөкемнең икесенең берсе генә үтәлергә тиеш. Мәсәлән, безнең мисалда, «йә мин иртәгә укырга барам, йә икәү теннис уйнарбыз». Әгәр икесен дә эшләсәгез, хөкем ялган була, чөнки бу хөкемне әйткәндә, сез эшнеңикесен дә башкара алмаганыгызны уйда тотасыз. Мондый хөкемнәргә икесен дә берьюлы эшләп булмаган яки мөмкин вариантлы хөкемнәрне кертергә була. Мәсәлән, «Бу язучы Казанда яки Чаллыда туган». Кеше ике шәһәрдә дә берьюлы туа алмый. Әгәр кеше Казанда да, Чаллыда да туган дисәк, бу хөкем, күргәнегезчә, дөрес булмас иде. Шуңа күрә төгәл аера торган хөкем гади аера торган хөкемнән беренче юлы белән генә аерылып тора:

p	**q**	**p ⊻ q**
Ч	Ч	Я
Ч	Я	Ч
Я	Ч	Ч
Я	Я	Я

4. Шартлы хөкем – импликация

Шартлы хөкемнәр сәбәп һәм нәтиҗәнең бәйләнешен күрсәтәләр. Мәсәлән, сез мондый вәгъдә бирдегез, ди: «**Әгәр** мин иртәгә укырга бар**сам**, икәү теннис уйнар**быз**».

1) *Сез укырга да барасыз*, һәм *теннис та уйныйсыз*. Бу – сезнеңсүздә торганыгызны аңлата, димәк, хөкем чын була.

		p

2) *Сез укырга барасыз*, әмма *теннис уйнамыйсыз*. Бу – сезнеңсүздә тормаганыгызны аңлата, димәк, хөкем ялган була.

		p

3, 4) *Сез укырга бармыйсыз*. Монда сез вәгъдәнең шартын үтәмисез, ягъни вәгъдәдән азат ителәсез. Сез теннис уйнасагыз да, уйнамасагыз да, вәгъдәгезне боза алмыйсыз, димәк, сез сүздә торган буласыз.

p	**q**	**p → q**
Я	Ч	Ч
Я	Я	Ч

Нәтиҗәдә мондый таблица килеп чыга:

p	**q**	**p → q**
Ч	Ч	Ч
Ч	Я	Я
Я	Ч	Ч
Я	Я	Ч

5. Тигезли торган хөкем – эквивалентлык.

Әгәр сез түбәндәге вәгъдәне бирсәгез: «Мин иртәгә укырга барсам **гына**, икәү теннис уйнарбыз», мондый таблицаны чыгарырга була:

p	**q**	**p ≡ q**
Ч	Ч	Ч
Ч	Я	Я
Я	Ч	Я
Я	Я	Ч

6. Инкарь итә торган хөкем.

Инкарь итү бер хөкемгә генә кагыла. Шуңа күрә аның таблицасы болай булыр:

p	**¬ p**

Шулай итеп, без мантыйкый теркәгечләрнең мәгънәсен ачыкладык. Бу таблицалардан файдалану өчен, без төп сорауга җавап бирергә тиешбез: *катлаулы хөкемнәрнең чынлыгы яки ялганлыгы монда керә торган хөкемнәрнең ялганлыгы яки чынлыгына ничек бәйле?* Моның өчен безгә ирекле катлаулы хөкемнәрнең чынлык таблицасын төзергә өйрәнергә кирәк.

§3. Чынлык таблицасын төзү

Чынлык таблицасын төзү өчен, бер мисалны алыйк: «Әгәр мин яхшы укыган булсам яки көннәремне бушка үткәрмәгән булсам, мин бу эштә эшләмәгән булыр идем». Монда гади хөкемнәрне «мин яхшы укыган булсам» – p, «көннәремне бушка үткәрмәгән булсам» – q һәм «мин бу эштә эшләмәгән булыр идем» r белән тамгалалар-быз. Таблицаны төзегәндә, кереш өлешенә хөкемнәр арасындагы барлык мөмкин булган чынлык чыгышларын язарга һәм таблицадагы юллар санын билгеләргә кирәк. Таблицадагы юллар саны яки комбинацияләр түбәндәге формула белән табыла:

$$k=2^n,$$

монда n – хөкемнәр (алына торган элементлар саны), 2 – хөкемнең чыгышын күрсәтә (чын, ялган). Безнең **(p ∨ ¬q) → ¬r** мисалында катлаулы хөкемдә – 3 хөкем, димәк, алырарасында 8 комбинация булырга мөмкин.

Комбинацияләрне таблицада төзегәндә, аларның кабатланмавы шарт булып тора. Комбинацияләрне дөрес чиратлаштыру өчен,

$$m=2^{l-1},$$

формуласын кулланырга була, монда l – таблицадагы баганалар саны, m – l баганадагы чын белән ялганның чиратлашуы (яки бүленүе дип тә карарга була, беренче багананы m-га бүләбез). Шулай итеп, таблицаны болай тутырырга була:

	p		**q**		**r**	
l	1		2		3	
k	*m*	чыгыш	*m*	чыгыш	*m*	чыгыш
1	1	**Ч**	2	**Ч**	4	**Ч**
2		**Ч**		**Ч**	4	**Я**
3		**Ч**	2	**Я**	4	**Ч**
4		**Ч**		**Я**	4	**Я**
5	1	**Я**	2	**Ч**	4	**Ч**
6		**Я**		**Ч**	4	**Я**
7		**Я**	2	**Я**	4	**Ч**
8		**Я**		**Я**	4	**Я**

Чыгыш өлешен язганда, кечерәк дәрәҗәдәге хөкемнән башлыйлар. Мантыйкта гади хөкемнәр 0 (ноль) дәрәҗәсендә, инкарь итә торган хөкемнәр дәрәҗәсе – 1, парлы хөкемнәр – 2. Иң зур дәрәҗә n булса, катлаулы хөкемнең дәрәҗәсе n+1 була.

Безнең **(p ∨ ¬q) → ¬r** очрагында, **¬q, ¬r** – 1-нче дәрәҗәдә, **p ∨ ¬q** – 2-нче дәрәҗәдә, димәк, **(p ∨ ¬q) → ¬r** – 3-нче дәрәҗәдә.

Мантыйк бүлеге

Башта ¬q, ¬r хөкемнәренең чынлык чыгышларын языйк:

p	q	r	¬q	¬r
Ч	Ч	Ч	Я	Я
Ч	Ч	Я	Я	Ч
Ч	Я	Ч	Ч	Я
Ч	Я	Я	Ч	Ч
Я	Ч	Ч	Я	Я
Я	Ч	Я	Я	Ч
Я	Я	Ч	Ч	Я
Я	Я	Я	Я	Ч

Икенче дәрәҗәдәге p ∨ ¬q хөкеменең чынлык чыгышын язабыз:

p	q	r	¬q	¬r	p ∨ ¬q
Ч	Ч	Ч	Я	Я	Ч
Ч	Ч	Я	Я	Ч	Ч
Ч	Я	Ч	Ч	Я	Ч
Ч	Я	Я	Ч	Ч	Ч
Я	Ч	Ч	Я	Я	Я
Я	Ч	Я	Я	Ч	Я
Я	Я	Ч	Ч	Я	Ч
Я	Я	Я	Ч	Ч	Ч

Өченче дәрәҗәдәге хөкемне язабыз, бу безнең бирелгән хөкем.Бу безнең башта бирелгән катлаулы хөкем:

p	q	r	¬q	¬r	p ∨ ¬q	(p ∨ ¬q) → ¬r
Ч	Ч	Ч	Я	Я	Ч	Я
Ч	Ч	Я	Я	Ч	Ч	Ч
Ч	Я	Ч	Ч	Я	Ч	Я
Ч	Я	Я	Ч	Ч	Ч	Ч
Я	Ч	Ч	Я	Я	Я	Ч
Я	Ч	Я	Я	Ч	Я	Ч
Я	Я	Ч	Ч	Я	Ч	Я
Я	Я	Я	Ч	Ч	Ч	Ч

Бу – безнең нәтиҗә таблицасы. Игътибар итегез: соңгы импликацияне исәпләгәндә, беренчесе итеп, **p ˅ ¬q** ны санарга кирәк, чөнки бу импликациянең шарты (антецедентасы),ә икенчесе булып **¬r** санала, чөнки бу монда импликациянең нәтиҗәсе (консеквента).

Күргәнебезчә, безнең хөкем биш очракта чын һәм өч очракта ялган. Иң мөһиме: без хәзер хөкемнәр чын яки, киресенчә, ялган булсын өчен, дөнья нинди булырга тиешлеген беләбез.

Икенче катлаулы хөкемне карыйк: (((p→ q) ^ p) → q). **Таблица төзелешенең алгоритмын уйда гына тотып төзербез, нәтиҗәне түбәндә язабыз:**

p	**q**	**p → q**	**(p → q) ^ p**	**((p → q) ^ p) → q**
Ч	Ч	Ч	Я	Ч
Ч	Я	Я	Я	Ч
Я	Ч	Ч	Я	Ч
Я	Я	Ч	Я	Ч

Күргәнебезчә, нәтиҗәдәге чыгышлар барысы да чынга тигез. Бу хөкем, гади хөкемнәрнеңбарлык чыгышлары нинди булуына карамастан, чын була.

Тагын бер мисалны карыйк: ¬((p ^ q) → p):

p	**q**	**p ^ q**	**(p ^ q) → p**	**¬((p ^ q) → p)**
Ч	Ч	Ч	Ч	Я
Ч	Я	Я	Ч	Я
Я	Ч	Я	Ч	Я
Я	Я	Я	Ч	Я

§4. Катлаулы хөкемнәр арасындагы мөнәсәбәтләр

A һәм B хөкемнәренең уртак таблицасы түбәндәгечә төзелә:

p	q	r	¬q	p ∨ ¬q	¬p	¬p ∨ r
Ч	Ч	Ч	Я	Ч	Я	Я
Ч	Ч	Я	Я	Ч	Я	Я
Ч	Я	Ч	Ч	Ч	Я	Я
Ч	Я	Я	Ч	Ч	Я	Я
Я	Ч	Ч	Я	Я	Ч	Ч
Я	Ч	Я	Я	Я	Ч	Я
Я	Я	Ч	Ч	Ч	Ч	Ч
Я	Я	Я	Ч	Ч	Ч	Я

A = p ∨ ¬q һәм **B = ¬p ∧ r** хөкемнәрен карыйк. A һәм B дагы гади хөкемнәрнең күплек җыелмасы {p, q, r} була. Димәк, таблицаның керешен өч гади хөкем өчен төзибез, ә аннары A һәм B өчен аерым чынлык чыгарылышын исәплибез.

Әгәр A һәм B катлаулы хөкемнәр өчен төзелгән уртак таблицада чынлык чыгарылышларының кушылмалары арасында барлык комбинацияләре дә очраса, **хөкемнәр чагыштырмасыз** дип атала.

Әгәр A һәм B катлаулы хөкемнәр өчен төзелгән уртак таблицада чынлык чыгарылышларының кушылмалары арасында берәр комбинациясе очрамаса, **хөкемнәр чагыштырмалы** дип аталалар.

Чагыштырмалы катлаулы хөкемнәрне дә тиңдәшкә һәм тиңдәшсезгә бүләләр

Тиңдәш хөкемнәр дип, икесе бер үк вакытта чын яки таблицаның барлык юлларында да бер үк чыгарылышны алган хөкемнәргә әйтәләр.

1. Эквивалентлык

Әгәр A һәм B хөкемнәре өчен төзелгән таблицадагы барлык юлларда бер үк чыгарылыш алынса, алар эквивалентлыдип аталалар.

Эквивалентлык түбәндәгечә языла:

¬(A ∧ B) ~ ¬A ∨ ¬B

2. Өлешчә тиңдәшлек

Әгәр A һәм B хөкемнәренең уртак таблицасында берьюлы (ЯЯ) чыгыш комбинациясе очрамаса, ә башка барлык комбинацияләре очраса, алар **өлешчәтиңдәш** дип аталалар.

p	q	p	p → q
Ч	Ч	Ч	Ч
Ч	Я	Ч	Я
Я	Ч	Я	Ч
Я	Я	Я	Ч

Сезгә иптәшегез үзе белән булган хәлне сөйли: «Мин кичә әнигә укырга барам дип вәгъдә биргән идем, ә дустыма әгәр иртәгә укырга барсам, кичкә кинога барырбыз, – дигән идем. Хөкемнәрне «Мин дәрескә барам» – p аша, «Синең белән кинога барабыз» – q аша күрсәтик, бу хикәядәге шартлы хөкем p → q аша күрсәтелә. Иптәшегез әйтүе буенча p хөкеме дә, p → q берүк вакытта ялган.

Тиңдәшсез хөкемнәр дип, икесе бер үк вакытта чын булмаган һәм таблицаның барлык юлларында бер үк чыгарылышны алмаган хөкемнәргә әйтәләр.

1. Каршылыклык

Әгәр A һәм B хөкемнәре икесе дә берьюлы чын да, ялган да була алмасалар, алар **каршылыклы** мөнәсәбәттә торалар.

p	q	p ∧ q	¬p ∧ ¬q
Ч	Ч	Ч	Я
Ч	Я	Я	Я
Я	Ч	Я	Я
Я	Я	Я	Ч

«Наполеон – бөек кеше» – p аша, *«кылган барлык эшләре яхшы»* q аша билгелик. Беренче хөкем – p ∧ q, ә икенчесе – ¬p ∧ ¬q.

2. Каршыдашлык

Әгәр A һәм B хөкемнәре өчен төзелгән уртак таблицада (Ч Ч) комбинациясе очрамаса, ә башка мөмкин була алган комбинацияләр очрасалар, хөкемнәр **каршыдашлык** мөнәсәбәтендә торалар.

3. Буйсындыру (мантыйкый иярту)

Әгәр беренче хөкем чын, ә икенчесе ялган була алмаса, A һәм B хөкемнәре **мантыйкый иярту** мөнәсәбәтендә булалар.

p	q	¬p ^ q	¬p → q	¬p → ¬q
Ч	Ч	Я	Ч	Ч
Ч	Я	Я	Ч	Ч
Я	Ч	Ч	Ч	Я
Я	Я	Я	Я	Ч

Мәсәлән, түбәндәгеләр бирелгән вәгъдәнеүтәү өчен мәҗбүриме:

а) «Әгәр мин дәрескә бармасам, синеңбелән киноға барам» яки

б) «Әгәр мин дәрескә бармасам, синеңбелән киноға бармыйм».

Аларның формалары:а) ¬p → q

б) ¬p → ¬q.

Тема 4. Модаль хөкемнәр

§1. Хөкемнәрнең модальлеге һәм аларның төрләре

Хөкем, фикерләү формасы буларак, ике мәгълүматны үз эченә ала:

Төп мәгълүмат

Төп мәгълүмат хөкемнең субъектында, предикатында, мантыйкый бәйләвечтә һәм кванторда ачык чагылышын таба.

Өстәмә мәгълүмат

Өстәмә мәгълүмат хөкемнең мантыйкый яки фактик статусына бәйле булган үзенчәлегенә кагыла.

Модальлек – хөкемнең дәлилләнү дәрәҗәсе турындагы ачык яки ачык булмаган өстәмә мәгълүмат, мантыйкый яки фактик статусы, бәяләү турында, регулятив һәм башка характеристикалар турында өстәмә белдерү.

Модальлек буенча аерганда, аларны типларга бүләләр, ә һәрбер тип эчендә модаль төрләр була. Киң таралган модальлекләр арасында түбәндәге типларны аерып күрсә-тергә була:

Алетик модальлек

Деонтик модальлек

Эпистимик модальлек

Аксиологик модальлек

§2. Алетик модальлек

Башка хөкемнәрнең эчтәлеген тасвирлаганда, андагы хәлне зарурилык, очраклылык, мөмкинлек, ихтималлылык сыйфаты белән характерлау юлы белән барлыкка килгән хөкемнәрне алетик (грек сүзеннән «алетея» – чынны, шартлы булуны аңлата) хөкемнәрдип атыйлар.

Мантыйкый модаль төшенчәләрне белдерү өчен, түбәндәге символларны кулланалар:

L – кирәкле; M – мөмкин; C – очраклы.

Фактик модаль төшенчәләрне белдерү өчен, түбәндәге символларны кулланалар:

■ – кирәкле;

♦ – мөмкин;

▼ – очраклы.

Алетик модаль хөкемнәрне өч төрле хөкемгә бүләргә була:

Аподиктик (толкование) хөкем, ягъни әйтем ниндидер күренешнең, хәлнең, вакыйганың зарурилыгын чагылдыра. Монда модаль операторлар булып, «зарури», «һичшиксез», «кирәк»һ.б. сүзләр кулланыла.

Мәсәлән, «Зур уку йортларында күп укырга кирәк» «Рәсәйдә телләр турында закон кертү зарури». Символик рәвештә: ■(S-P) яки ■p.

Проблематик хөкем, нәрсәнеңдер мөмкинлеге турындагы әйтем яки ышанычсыз, шикле хөкем. Модаль операторлар булып, «мөмкин», «бәлки» һ.б. сүзләр кулланыла.

Мәсәлән, «Рәсәйдә телләр турында закон чыгарга мөмкин» Символик рәвештә: ♦(S-P) яки ♦(p).

Ассерторик (действительность) хөкем – нәрсәнеңдер чынбарлыкта булуы, факт турындагы хөкем. Мондый хөкемнәрдә модальлелек объектив детерминизм белән бәйле, аның чынлыгы яки ялганлыгы чынбарлыкта булган хәл, вакыйга белән билгеләнә. Мондый хөкемнәрдә модаль-лелек чагылдырылмаска да мөмкин.

Мәсәлән, «Рәсәй телләр турында закон чыгара» яки «дөрестән дә», «чыннан да» кебек сүзләр белән билгеләнергә мөмкин. Мәсәлән, «Чыннан да, Рәсәй телләр турындазакон чыгара». Символикрәвештә: ▼(S-P) яки ▼p.

§3. Деонтик модальлек

Деонтик модальлек (грек сүзе «deonte» – ничек булырга тиеш, бурычны аңлата) – хөкемдәге киңәш, боерык, теләк, кешене конкрет гамәлләргә этәрүче тәкъдимнәр чагылышы. Бу модальлек кешеләр эшчәнлегенә, аларның җәмгыятьтәге әхлак һәм хокукнормаларын тотышына гына кагыла.

Деонтик модальлек түбәндәге операторлар белән белдерелә:
О – мәҗбүри; F – тыюлы; Р – рөхсәтле.

Хокук нормалары арасыннан хокукый мәҗбүр итү, хокукый тыю, хокукый рөхсәт итүгә аерырга була:

Хокукый мәҗбүр итү нормалары «тиеш», «бурычлы», «кирәк» сүзләре ярдәмендә формалаша.

Мәсәлән, «Рәсәй гражданнары Рәсәй дәүләт законнарын үтәргә тиеш», символик формада – Od (dгамәл).

Хокукый тыю нормалары «тыела», «ярамый», «җибәрелми» кебек сүзләр белән формалаша.

Мәсәлән, «Кызыл утка урам аша чыгу тыела», символик формада – Fd.

Хокук нормалары «хокукы бар», «ярый», «мөмкин», кебек сүзләр белән формалаша.

Мәсәлән, «Һәрбер кеше иреккә һәм шәхси кагылгысызлыкка хокуклы», символик формада – Pd.

§4. Эпистемик модальлек

Эпистемик модальлек (грек сүзе «episteme» – белем) – хөкемдәге дәлилләнү дәрәҗәсе турындагы мәгълүматны чагылдыра. Аның операторлары булып, «билгеле»,
«билгесез», «исбат ителгән», «булырга мөмкин» кебек сүзләр тора. Хөкемнәр ышанугаһәм белемгә, кеше фикеренә һәм исбатлауга нигезләнергә мөмкин.

Мәсәлән, «Мин яхшы тормыш башлануга ышанам», «Шаһитләрнең мәгълүматы буенчаГалимов әйбер урлауда катнашмаган».

Белемнәрнең дәлилләнү дәрәҗәсенә карап, хөкемнәр ышанычлы һәм ышанычсыз (проблематик) булырга мөмкин:

Ышанычлы хөкемнәр – җитәрлек дәлилләнгән чын яки ялган хөкемнәр. Мондый хөкемнәрнең модальлеге ике оператор ярдәмендә чагыла: исбат ителгән (тикшерелгән, верификацияләнгән) – V һәм кире кагылган (фальсификацияләнгән) – F.

Мәсәлән, «Исбат ителгән: Галимов – җинаять не оештыручы», символик рәвештә – V (S-P) яки V p, яисә «Исбат ителгән: Галимов – җинаять кылмаган» – V (S-P түгел) яки V ¬p. «Галимовның җинаять кылганлыгы исбат ителмәгән» – (S-P) яки F p.

Проблематик хөкемнәр – дәлилләнүе җитәрлек булмаганлыгы аркасында, дөрес дип санарга ярамаган хөкемнәр. Хөкемнәрнең проблематикасы «ихтимал», «бәлки», «булырга мөмкин», «мөгаен» кебек сүзләр белән әйтелә. Бу модальлек операторы Р белән тамгалана. Проблематик хөкемнәрнең ихтималлык дәрәҗәсе булырга мөмкин: нульдән алып, аз ихтималлы, тигез ихтималлы, ... дөрес булуга кадәр.

Мәсәлән, «Бәлки Галимов югары уку йортына керер». Символлар ярдәмендә Р (S-P) яки Рp.

§5. Аксиологик модальлек

Аксиологик модальлек матди һәм рухи байлыкларның мөнәсәбәтен чагылдыра. Ак- сиологик модальлек абсолют яки чагыштырма бәя чагылдырырга мөмкин һәм «яхшы», «начар», «барыбер», «искитмичә», «салкын караш белән», «ярый әле», «начаррак»кебек сүзләрне үз эченә ала.

Мәсәлән, «Кеше дәүләт милкенә салкын карый», «Ярый әле мин укырга соңга калма-дым» һәм «Студент укуга соңга калса, начар».

Модальлекнең характеристикасы		Көчле уңай модальлек	Көчсез нейтраль модальлек	Көчле тискәре модальлек	Көчсез уңай модальлек
Алетик	**Фактик (онтологик)**	Фактик кирәклелек	Фактик очраклык	Фактик мөмкин булмаганлык	Фактик мөмкинлек
	Мантыйкый	Мантыйкый кирәклелек	Мантыйкый очраклык	Мантыйкый мөмкин булма-ганлык	Мантыйкый мөмкинлек
Деонтик	–	Мәҗбүрилек, зарурилык, кирәклелек	Барыберлек, аермасыз	Тыюлык	Рөхсәт ител-гәнлек
Эпистемик	**Ышанычлы, дөрес (Белемле)**	Исбат ителгәнлек (верифик)	Чишелмәгәнлек, тикшереп булма-ганлык	Дөрес түгеллеге исбат ителгәнлек. Кире кагылганлык (фальсификаци-ялөнгәнлек).	Чамалау (гипо-тетик)
	Проблематик	Чамаланганлык, ихтималлы (булырга мөмкин)	Шикле, ихтималлыгы аз.	Кабул итмәү, кире кагу	Яраганлык, рөхсәт итү
Аксиологик	**Абсолют**	Яхшы	Аксиологик барыберлек, аермасызлык	Начар	–
	Чагыштырма	Яхшырак	Барыберлек, аермасызлык	Начаррак	–

Дүртенче бүлек. Фикри нәтиҗә

Тема 1. Гомуми характеристика

§1. Фикри нәтиҗәнең килеп чыгышы һәм әһәмияте

Фикри нәтиҗә – бер хөкемнең икенче хөкемнән өзлеклексез чыгуы ул.

Фикри нәтиҗәнең килеп чыгышы

Хөкемгә караганда, фикер йөртүнең тагын да катлаулырак формасы булып, фикри нәтиҗә тора. Фикерләүнең башка формалары кебек үк, фикри нәтиҗә дә безнең аңыбызда материаль чынбарлыкны чагылдыра. Аның төзелеше хөкемнәрдән гыйбарәт (димәк, төшенчәләрдән дә), әмма ул аларга кайтып калмый, ә тагын билгеле бер бәй-ләнешне күз алдында тота.

Фикри нәтиҗәнең килеп чыгышын һәм асылын аңлау өчен, безнең тормыш эшчәнлеге процессында кулланыла торган ике төрдәге белемне – турыдан-туры һәм чыгарылган белемне кararга кирәк.

Турыдан-туры белем ул – безнең тою һәм сизү әгъзалары ярдәмендә алына: күрү, ишетү, сизү һ.б.

Мәсәлән, «агач яшел», «кар ак», «кош сайрый» һ. б. кебек хөкемнәр аша белдерелә. Алар безнең белемнәребезнең зур өлешен алып тора.

Башка белемнәр аркылы алынган белемнәр яки **чыгарылган** белемнәр дипатыйлар.

Мәсәлән, 250-300 млн еллар элек Мәскәүөлкәсен диңгез сулары юган. Аларны чыгарганда, мантыйкый форма булып, фикри нәтиҗә хезмәт итә.

§2. Фикри нәтиҗәнең төзелеше

Һәртөрле фикри нәтиҗәдә түбәндәге элементларын аерырга була

1. Соңгы хөкемне чыгарган хөкемнәр.
2. Моннан алдан килгән хөкемнәрдән чыгарылган хөкем.
3. Беренче һәм икенче хөкем арасындагы бәйләнеш.

Фикри нәтиҗәнең элементлары

Фикри нәтиҗәнең беренче элементын (яки элементларны) **алшарт** дип атыйлар. Алшарт бирелгән һәм шул ук вакытта билгеле белем, фикри нәтиҗәнең нигезе булып хезмәт итә, ягъни, соңгы хөкемне чыгаруда катнашучы хөкем (бер яки берничә хөкем булырга мөмкин).

Икенчесе, ягъни төгәлләнүче элементы фикри нәтиҗәнең чыгарылышы яки **нәтиҗәсе** дип атала. Нәтиҗә – алшартлардан чыгарылган, аларның нәтиҗәсе булып торган яңа белем, ягъни алдагы хөкемнәрдән чыгарылган хөкем.

Фикри нәтиҗәләрне анализлаганда, уңайлы булсын өчен, фикри нәтиҗәнең мантыйкта кабул ителгән формасы түбәндәгечә языла:

Барлык Рәсәй гражданнары укуга хокуклы – **алшарт**

Сыраев – Рәсәй гражданы – **алшарт**

Димәк, Сыраев укуга хокуклы – **нәтиҗә**

Әгәр ике шарт үтәлсә, нәтиҗә чын була:

а) әгәр эчтәлекләре буенча алшартлар чын булса;
б) әгәр фикри нәтиҗә үзенең төзелеше буенча дөрес булса.

Мәсәлән:

— Барлык рәссамнар да табигатьне тоя беләләр.
— Р. Сыраев – рәссам.

— Димәк, Р. Сыраев табигатьне тоя белүче. (нәтиҗә)

Монда ике алшарт та чын, ә фикри нәтиҗә дөрес төзелгән. Димәк, нәтиҗә чын була. Моны рәсем аша да күрсәтергә була.



Монда,
A – Р. Сыраев,
B – рәссам,
C – табигатьне тоя белүче.

Һәм, кире очракта, нәтиҗә ялган була:

а) әгәр эчтәлекләре буенча алшартлар берсе генә булса да ялган булса; б) әгәр фикри нәтиҗәнең төзелеше дөрес булмаса.

Монда ике чын алшарттан мәгънәсез нәтиҗә чыгарыла:

— Барлык балыклар да суда йөзә.
— Кеше дә суда йөзә.

— Димәк, кеше – балык.

Мондагы хата булып, A һәм B элементларының уртак эчтәлекләренең булмавы тора.



Монда,
A – балык,
B – кеше
C – суда йөзүчеләр.

§3. Фикри нәтиҗә һәм җөмлә бәйләнеше

Башка фикри формалар кебек, фикри нәтиҗә дә телдә чагыла. Төшенчә – аерым сүз (яки сүзтезмә) белән, ә хөкем – аерым җөмлә (яки җөмләләр яраклашуы) белән белде-релсә, фикри нәтиҗә исә һәрвакыт берничә (ике яки артыграк) җөмләнең бәйләнеше белән белдерелә. Югарыда әйтелгәнчә, татар телендә бу бәйләнеш «димәк», «шулай итеп», «чөнки» һ.б. сүзләр белән бирелә. Фикри нәтиҗәнең телдә чагылуның гому-

ми кагыйдәсе мондый: әгәр нәтиҗә алшартлардан соң торса, аның алдыннан мондый сүзләр куела: «димәк», «шуңа күрә», «шулай итеп» һ.б.

Мантыйкый һәм тел конструкцияләренең түбәндәгечә мөмкинлекләрен карап үтәргәбула:

1. *«Барлык рәссамнар да табигатьне тоя беләләр, Р. Сыраев – рәссам, димәк, ул таби-гатьне тоя белә» (нәтиҗә ахырда);*
2. *«Р. Сыраев табигатьне тоя белә, чөнки ул рәссам, ә барлык рәссамнар табигатьне тоя белә-ләр» (нәтиҗә башта);*
3. *«Барлык рәссамнар табигатьне тоя белә-ләр, димәк, Р. Сыраев табигатьне тоя белә, чөнки ул рәссам» (нәтиҗә уртада).*

§4. Фикри нәтиҗә төрләре

Төзелеше буенча барлык фикри нәтиҗәләр гади һәм катлаулыга бүленәләр

Гади фикри нәтиҗә дип, нәтиҗәнең элементлары фикри нәтиҗә булып тормасалар әйтәләр.

Катлаулы фикри нәтиҗә дип, нәтиҗә ике яки күбрәк гади фикри нәтиҗәдән торса әйтәләр.

Фикри нәтиҗә алшартлар саны буенча **тулы-дан-тулыга** (бер алшарттан торган) һәм **тулы-дан-тулы булмаганга** яки **чыгарылганга** (ике һәм күбрәк алшарттан торган) бүленәләр.

Мантыйкый иярту характеры буенча барлык фикри нәтиҗәләр **зарурига** һәм **ихтималлыкка** бүленәләр. **Зарури фикри нәтиҗәләрдә** чын нәтиҗә һәрвакытта чын алшартлардан күчеп килә, ягъни мантыйкый иярту мондый чыгарылышта мантыйкый закон булып тора. Зарури фикри нәтиҗәләргә дедук- тив фикри нәтиҗәләрнең барлык төрләре һәм тулы индук-тив фикри нәтиҗә керә.

Тема 2. Дедуктив фикри нәтиҗә

§1. Дедуктив фикри нәтиҗә һәм аның төрләре

Дедукция (латин сүзе deductio – чыгару) хөкем йөртүнең, фикри нәтиҗәгә килүнең төп алымнарыннан берсе, фикри тикшерү ысулы; гомумидән хосусыйга бара торган мантыйкый нәтиҗәле йомгак.

Дедуктив фикри нәтиҗәне, алшартлар санына карап, аерырга була

Турыдан-туры (бер алшарттан торган)

Турыдан-туры булмаганга яки **чыгарылганга** (ике яки икедән артык алшарттан торган)

Гади хөкемнәрдән торган турыдан-туры булган фикри нәтиҗәләр, үз чиратында, фикри нәтиҗәләргә бүленәләр

Атрибутив (категорик) хөкемнәрдән торган

Реляцион хөкемнәрдән торган

Категорик хөкемнәрдән торган дедуктив фикри нәтиҗәләрнесиллогизмнар дип атыйлар

Ике алшарттан торган силлогизм – гади категорик силлогизм

Икедән артык алшарттан торган силлогизм **катлаулы силлогизм** яки **полисиллогизм**

§2. Турыдан-туры силлогизмнар

Мантыйкта категорик хөкемнәрнең мәгънәләрен ачыклау өчен, махсус **турыдан-туры силлогизмнар** дип аталган ысуллар төзелгән.

Турыдан-туры булган фикри нәтиҗәләрдә хөкемнәрнең үзгәрүе аша нәтиҗә ясала. Бу үзгәрешләргә **әверелдерү, әйләндерү, предикатка каршы кую, субъектка каршы**һәм **мантыйкый квадрат буенча нәтиҗә керә.**

1. Әверелдерү (превращение)

Әверелдерү – ул бирелгән хөкемне сыйфаты буенча – каршыдашка, предикаты буенча каршылыклыга үзгәртеп, турыдан-туры фикри нәтиҗә ясау.

Категорик хөкемнәрнең барысын да яңа хөкемгә әверелдерергә була. Аларның һәрберсенаерым карыйк.

Гомуми раслый торган (А) хөкемне әверелдерү:

Барлык тарихчылар да кызыксынучан була	Барлык S – P була	
Бер генә тарихчы да кызыксынмаучан түгел	Бер генә S – -P түгел	

Гомуми инкарь итә торган (Е) хөкемне әверелдерү:

Бер генә кеше дә камил түгел	Бер генә S – P түгел	E
Барлык кешеләр камилләшмәгән була	Барлык S – -P була	A

Шәхси раслаулы (I) хөкемне әверелдерү:

Кайбер кешеләр гадел була	Кайбер S – P була	I
Кайбер кешеләр гаделсез түгел	Кайбер S – -P түгел	O

Шәхси инкарь итүче (О) хөкемне әверелдерү:

Кайбер студентлар укуда игътибарсыз түгел	Кайбер S – -P түгел	
Кайбер студентлар укуда игътибарлы була	Кайбер S – P була	

Мантыйк бүлеге

Әверелеш

Предикатка төрле мөнәсәттә торган кеше (субъект) хөкемнең әлеге предикатка өстәмә булган аерым мөнәсәбәте белән тигезләшә. Әверелеш булсын өчен, капма – каршы бәйләнеш һәм әлеге хөкемнең предикатына аның микъдари характеристикасын үз- гәрешсез калдырып алыштыру җитә.

Барлык гомуми раслаучы хөкемнәр гомуми кире кагучыга әйләнә, һәм, киресен- чә, (үзгәрешкә мөнәсәбәттә торган хөкемнәрне горизонталь сызык аерып тора).

Мәсәлән:

Барлык S да – P — *Һәркемгә дә кемне дә булса ярату хас*

Бар S да P түгел — *Беркемгә дә кемне дә булса яратмау хас түгел*

Бөтен S да – P — *Һәркемгә дә кемне дә булса яратмау хас*

Бер S да P була алмый — *Һәркемгә дә кемне дә булса ярату хас түгел*

Бөтен S да – P — *Уңышсызлар төрле хәлләргә сылтарга яраталар*

Бер S да P була алмый — *Бер уңышсыз да төрле хәлләргә сылтарга яратмый*

Бөтен S да – P — *Барлык уңышсызлар да үзе булмаганнарны гаепләргә ярата*

Бер S да P була алмый — *Бер уңышсыз да үзен гаепләргә яратмый*

Гомуми раслаучы өлеш кебек кенә хөкемнәр өчен бер мисал китерәбез:

S гына P була — *Таулар гына таулардан яхшырак була*

S гына P була алмый — *Таулар гына таулардан яхшырак була алмый*

Барлык аерым раслаучы хөкемнәр аерым кире кагучы хөкемнәргә әйләнә,һәм, киресенчә:

Мәсәлән:

Кайбер S, P була — *Кайберләребезгә хаталану хас*

Кайбер S, P була алмый — *Кайберләребезгә хаталанмау хас түгел*

Кайбер S, P була — *Кайбер дөрес булмаган карарлар безгә кыйммәткә төшә*

Кайбер S, P була алмый — *Кайбер дөрес булмаган карарлар безгә очсыз була алмый*

Кайбер S, P була — *Кайбер дөрес булмаган карарлар кичерүгә лаек түгел*

Кайбер S, P була алмый — *Кайбер дөрес булмаган карарларны кичерү мөмкин түгел*

Өлештән генә торучы аерым хөкемнәргә мисал китерик:

Кайбер S гына P	*Кайберләргә генә бәхет елмая*
Кайбер S гына P тугел	*Кайберәүләр бәхет елмаймаучы кешеләр була алмый*

Китерелгән мисаллардан шул аңлашыла, әверелеш симметрик үзгәрешне тәшкил итә. Мондый симметриянең сәбәбе шунда, бәйләмне үзенә каршы торучыга алмаштыру предикатның үзенә каршы торучыга алмаштыруга тиң. Шуңа күрә, әгәр дә ике алмаштыруны да тормышка ашырсаң, без тагын «кире кагу – кире кагылу раславы» принцибыннан торган башлангыч хөкемгә килеп чыгабыз.

2. Әйләндерү (обращение)

Әйләндерү ул – бирелгән хөкемнең сыйфатын үзгәртмичә, предикат белән субъектныңурыннарын алмаштыру аша турыдан-туры фикри нәтиҗә ясау.

Әгәр әйләндерү бирелгән хөкемне сан буенча үзгәрүенә китерсә (баштагы гомуми хөкемнән яңа хосусый хөкем барлыкка килә), бу әйләндерү**чикле әйләндерү** дип атала.

Әгәр әйләндерү бирелгән хөкемнең санын үзгәртмәсә, мондый әйләндерүне **чиксез яки гади әйләндерү** дип атыйлар.

Исегезгә төшерәбез:

Е хөкеменең субъекты да, предикаты да таралган, I хөкеменең субъекты да, предикаты да таралмаган

Әйләндерүнең дөреслеген тикшерү, субъект белән предикатның таралганлыгын һәммөнәсәбәтен күз алдында тоту өчен, Эйлер түгәрәкләрен куллану да файдалы.

Гомуми инкарь итүче (Е) хөкемне әйләндерү

Бер генә кеше дә камил булмый	Бер генә S – P булмый
Бер генә камил җан ияседе кеше булмый	Бер генә P – S булмый

Шәхси раслауры (I) хөкемне әйләндерү:

Кайбер кешеләр гаделбула	Кайбер S – P була
Кайбер гадел җан ияләре кешеләр була	Кайбер P – S була

Гомуми раслауры (А) хөкемне әйләндерү:

Барлык тарихчылар да кызыксынучан була	Барлык S – P була	A
Кайбер кызыксынучан кешеләр тарихчы була	Кайбер P – S була	

Мөрәҗәгать

Һәрбер мөрәҗәгать (өндәмә) үзе белән һәрвакыт туры килмәгән һәм аннан торучы кирәкле кире мөнәсәбәттән тора. Кешенең предикатка туры һәм кире мөнәсәбәте билгеле булмаса, логик эчтәлекнең анализы тулы була алмый. Субъектның предикатка билгеле мөнәсәбәте аша аңа киресен табу буенча, мөрәҗәгать үзгәреш булып күзаллана. Моның өчен кеше һәм предикатны кирәк булган урыны буенча, хөкем йөртү күләме билгесен үзгәртергә кирәк.

Гомуми раслаучы хөкемнәр мөрәҗәгате ике очракта таркала:

Субъект һәм предикат күләме туры килә

Мәсәлән:

S гына P була — *Куанычлы хәл тиз бетә*

P гына P була — *Тиз беткән хәл генә куанычлы*

S гына P була — *Кеше үзеннән өстен булганнар белән килешә алмый*

P гына S була — *Үзләреннән өстен булганнар белән килешә алмаучылар кеше була*

S гына P була — *Яшь булудан туктагач кына мөмкинлекләр ычкындырылганын аңлыйсын*

P гына S була — *Мөмкинлекләр ычкындырылганын аңлаганнар, яшь түгел инде*

S гына P була — *Ярата белмүчеләр гынә киң күңелле була алмыйлар*

P гына S була — *Киң күңелле була белмәгәннәр, ярата белмиләр*

Предикат күләме субъект күләмен үзенә кертә, ләкин аңа тигез түгел.

Мәсәлән:

Барлык S – P — *Барлык көзге көннәр быел болытлы*

Кайбер S – P — *Кайбер болытлы көннәр быел – көзге*

Барлык S – P — *Акыллы кешеләр башкалар алдында үзләренең өстенлекләрен күрсәтәләр*

Кайбер P – S — *Башкалар алдында үзләренең өстенлекләрен күрсәтмәүчеләр – акыллы кешеләр*

Барлык S – P — *Барлык гадел булмаганнар – куркак*

Кайбер P – S — *Кайбер куркак кешеләр, гадел түгелләр*

Барлык S – P — *Кайда йөзәргә белмәүчегә, шул якка исүче җил юк*

Кайбер P – S — *Шул якка исүче җилгә ия булмаучылар кая йөзәргә икәнен белмиләр*

Гомуми кире кагучы хөкемнәр мөрәҗәгате симметрик үзгәрешне тәшкил итә

Мәсәлән:

Бер S да P түгел — *Бер яхшы эш тә онытылмый*

Бер S да P түгел — *Бер онытылмаучы эш тә яхшы була алмый*

Бер S да P түгел — *Бер кайгы да сәбәпсез түгел*

Бер S да P түгел — *Бер сәбәпсез хәл дә кайгы була алмый*

Бер S да P түгел — *Бер бушка узган көн дә юкка түгел*

Бер S да P түгел — *Бер юкка узган көн дә бушка түгел*

Бер S да P түгел — *Бер күңелсезлек тә проблемасыз*

Бер S да P түгел — *Бер проблемасыз ситуация дә күңелсез була алмый*

Аерым раслаучы хөкемнәр мөрәҗәгате өч очракка бүленә («кайберәүләр») интерпретация сүзе нигезендә:

1) Кайберәүләр яки бөтенесе

Мәсәлән:

Кайберәүләр (яки барлык) S – P — *Кайбер яшь кешеләр шаярырга ярата*

Кайберәүләр (яки барлык) S – P — *Кайбер шаярырга яратучылар – яшьләр*

2) Кайберәүләр, ләкин бөтенесе дә түгел

Мәсәлән:

Кайберәүләр (ләкин барысы да түгел) S – P — *Кайбер яшь кешеләр классик музыка яраталар*

Кайберәүләр (яки барысы) S – P — *Кайбер классик музыка яратучылар – яшь түгел*

3) Кайберәүләр генә

Мәсәлән:

Кайбер S лар гына P була — *Безнең бәхетебез берничә мизгел генә була ала*

Барлык S, P була ала — *Безнең бәхет – мизгел*

Аерым кире кагучы фикерләр, кагыйдә буенча, мөрәҗәгать итмиләр Кеше һәм предикатны урынары белән алмаштыру башлангыч фикерне боза.*Мәсәлән:*

Кайбер кешеләр алдакчы түгелләр

Кайбер алдакчылар кеше була алмыйлар

Әлеге авырлыкларны җиңәргә була, әгәр дә кире кагучы фикерләрне башта аерым раслаучыга әйләндерсәң, кире кагуны бәйләмнән предикатка күчерү ярдәмендә һәмшуннан соң гына мөрәҗәгать итәргә була.

1) Кайбер кешеләр алдакчы түгелләр (рөхсәтителү).

2) Кайбер кешеләр алдакчы булмаучылар (1.Әверелеш).

3) Кайбер алдакчылар – кешеләр (2. Мөрәҗәгать, өндәмә).

Аерып чыгарылучы аерым кире кагучы фикерләр мөрәҗәгате күрсәтелгән алымярдәмендә башкарыла.

Мәсәлән:

Кайбер кешеләр генә алдакчы була алмыйлар

Барлык алдакчы түгелләр – кешеләр

3. Предикатка каршы кую (противопоставление)

Предикатка каршы кую ул – әверелдерү һәм әйләндерү ысулларын чиратлаштырыпкулланылуы.

Әгәр әйләндерү бирелгән хөкемне сан буенча үзгәрүенә китерсә (баштагы гомуми хөкемнән яңа хосусый хөкем барлыкка килә), бу әйләндерү **чикле әйләндерү** дип атала.

Әгәр әйләндерү бирелгән хөкемнең санын үзгәртмәсә, мондый әйләндерүне **чиксез яки гади әйләндерү** дип атыйлар.

Категорик хөкемнәрнең барысын да яңа хөкемгә әверелдерергә була. Аларның һәрберсенаерым карыйк.

Гомуми раслаучы торган (А) хөкеменең предикатына каршы кую:

Этап 1. Әверелдерү:

Барлык тарихчылар да кызыксынучан була	Барлык S – P була	A
Бер генә тарихчы да кызыксынмаучан түгел	Бер генә S – -P түгел	E

Этап 2. Әйләндерү:

Бер генә тарихчы да кызыксынмаучан түгел	Бер генә S – -P түгел	E
Бер генә кызыксынмаучан кеше тарихчы түгел	Кайбер -P – S түгел	E

Гомуми инкарь итүче (Е) хөкеменең предикатына каршы кую:Этап 1. Әверелдерү:

Бер генә кеше дә камил түгел	Бер генә S – P түгел	E
Кайбер кешеләр камилләшмәгән була	Барлык S – -P була	A

Этап 2. Әйләндерү:

Кайбер кешеләр камилләшмәгән була	Барлык S – -P була	A
Кайбер камилләшмәгән җан ияләре кешеләр була	Барлык P- – S була	I

Шәхси инкарь итүче (О) хөкеменең предикатына каршы кую:Этап 1. Әверелдерү:

Кайбер студентлар китапсыз укымыйлар	Кайбер S – -P түгел	O
Кайбер студентлар китап белән укыйлар	Кайбер S – P була	I

Этап 2. Әйләндерү:

Кайбер студентлар китап белән укыйлар	Кайбер S – P була	I
Кайбер студентлар китаптан укыйлар	Кайбер P – S була	I

4. Субъектка каршы кую

Субъектка каршы кую – предикатка каршы куюның киресе: башта әйләндерү, аннарыәверелдерү ысулы кулланыла, монда яңа хөкем барлыкка килгәндә, хөкемнең сыйфаты үзгәрә; предикат субъектка каршылыклы булган төшенчәгә әверелә, ә субъект бирелгән хөкемнең предикаты була.

Мантыйк бүлеге

Гомуми раслый торган (А) хөкеменең субъектына каршы кую:

Этап 1. Әйләндерү:

Барлык адвокатлар юрист була	Барлык S – P була	A
Кайбер юристлар адвокат була	Кайбер P – S була	I

Этап 2. Әверелдерү:

Кайбер юристлар адвокат була	Кайбер P – S була	I
Кайбер юристлар адвокат түгел	Кайбер P – Sтүгел	I

5. Категорик хөкемнәрнең нәтиҗәләрен мантыйкый квадратта теркәлгән хөкемнәр арасындагы мөнәсәбәтләр ярдәмендә чыгарырга була. Аларны түбәндәге төрләргә бүләргә була:

1. Буйсыну мөнәсәбәте нигезендәге нәтиҗә;
2. Өлешчә тиңдәш мөнәсәбәт буенча нәтиҗә;
3. Каршылыклык мөнәсәбәте буенча нәтиҗә;
4. Каршыдашлык мөнәсәбәте буенча нәтиҗә.

Турыдан-туры фикри нәтиҗәләрнең төрләрен мантыйкый квадрат буенча аерып карыйк:

1. Буйсыну мөнәсәбәте нигезендәге нәтиҗә. Монда ике төрдәге нәтиҗә булырга мөмкин: а) буйсындыра торган хөкемнең чынлыгыннан буйсына торган хөкемнең чынлыгы чыга.

б) буйсындыра торган хөкемнең ялганлыгыннан буйсына торган хөкемнең ялганлыгы чыга.

Фикри нәтиҗәләр чыннан чынга:

Бу фикри нәтиҗәләр **А**–дан (буйсындыра торган хөкемнән) **I**–ка (буйсына торган хөкемгә) һәм **Е**–дан (буйсындыра торган хөкемнән) **О**–га (буйсына торган хөкемгә). (Таблицаның 2б-нчы баганасын кара).

Барлык адвокатлар юрист була	А Буйсындыручы	Чын
Кайбер адвокатлар юрист була	I Буйсынучы	Чын
Бер генә кеше дә гөнаһсыз түгел	Е Буйсындыручы	Чын
Кайбер кешеләр гөнаһсыз түгел	О Буйсынучы	Чын

Монда, киресенчә карасак, буйсына торган хөкем чын булганда, буйсындыра торган хөкем чын да, ялган да булырга мөмкин; ягъни, кире урнашуда дөрес нәтиҗә ясап булмый.

Фикри нәтиҗәләр ялганнан ялганга:

Бу – фикри нәтиҗәләр **I**–тан (буйсына торган хөкемнән) **A**–га (буйсындыра торган хөкемгә) һәм **O**–дан (буйсына торган хөкемнән) **E**–га (буйсындыра торган хөкемгә).

Кайбер кешеләр тарих барышын үзгәртергә мөмкиннәр	I Буйсынучы	Ялган
Барлык кешеләр тарих барышын үзгәртергә мөмкиннәр	A Буйсындыручы	Ялган
Кайбер кешеләр үз-үзен камилләштерүгә сәләтле түгел	O Буйсынучы	Ялган
Бер генә кеше дә үз-үзен камилләштерүгә сәләтле түгел	E Буйсындыручы	Ялган

Монда да киргә таба карасак, буйсындыручы хөкем ялган булганда, буйсынучы хөкем чын да, ялган да булырга мөмкин.

2. Өлешчә тиңдәш мөнәсәбәте буенча нәтиҗә. Мондый мөнәсәбәтләр I һәм O хөкемнәре арасында була. Мондагы нәтиҗә буенча берсенең ялганлыгыннан икенчесенең чынлыгы гына чыгу мөмкин, чөнки бу хөкемнәр икесе дә берьюлы ялган була алмыйлар,әмма икесе дә чын була алалар.

Кайвакытта дәрескә соңга калырга ярый	I	Ялган
Кайвакытта дәрескә соңга калырга ярамый	O	Чын
Кайбер кешеләр усал түгел	O	Ялган
Кайбер кешеләр усал	I	Чын

Монда беренче хөкемнәр чын булган хәлдә, нәтиҗә ялган да, чын да булырга мөмкин,ягъни нәтиҗә билгесез була.

Әлбәттә, югарыда чыгарылган нәтиҗәләр бик үк көчле түгел. Мәсәлән, шундый ук алшартлардан каршылыклык мөнәсәбәтен кулланып, көчлерәк нәтиҗәләр чыгарырга була. Шуңа күрә өлешчә тиңдәшлек мөнәсәбәте кешеләрнең табигый фикерләвендә сирәк кулланыла.

3. Каршылыклык мөнәсәбәте буенча нәтиҗә. Бу нәтиҗәләр дә ике төркемгә бүленә:

а) ниндидер хөкемнең ялганлыгыннан икенче хөкемнең чынлыгы чыга. б) ниндидер хөкемнең чынлыгыннан икенче хөкемнең ялганлыгы чыга.

Фикри нәтиҗәләр ялганнан – чынга:

Барлык кешеләрнең дә җинаятькә кагылышы бар	A	Ялган
Кайбер кешеләрнең җинаятькә кагылышы юк	O	Чын
Тарих барышына кайбер кешеләр тәэсир ясамыйлар	O	Ялган
Тарих барышына барлык кешеләр тәэсир ясыйлар	A	Чын
Бер генә кешенең дә җинаятькә кагылышы юк	E	Ялган
Кайбер кешеләрнең җинаятькә кагылышы бар	I	Чын
Кайбер кешеләр җәзага тартылырга тиеш	I	Ялган
Бер генә кеше дә җәзага тартылырга тиеш түгел	E	Чын

Фикри нәтиҗәләр чыннан – ялганга:

Барлык адвокатлар да – юристлар	A	Чын
Кайбер адвокатлар юрист түгел	O	Ялган
Кайбер бөек кешеләр тәбәнәк буйлы түгел	O	Чын
Барлык бөек кешеләр тәбәнәк буйлы	A	Ялган
Бер генә ялкау кеше дә мактауга лаек түгел	E	Чын
Кайбер ялкау кешеләр мактауга лаек	I	Ялган
Кайбер студентлар мантыйктан бишле алды	I	Чын
Бер генә студент та мантыйктан бишле алмады	E	Ялган

4. Каршыдашлык мөнәсәбәте буенча нәтиҗә. Мондагы нәтиҗә бер типта гына булырга мөмкин: чыннан – ялганга, чөнки каршыдашлык мөнәсәбәтендәге хөкемнәр икесе дә чын була алмыйлар, ә икесе дә ялган була алалар.

Барлык студенлар да зирәк кешеләр	A	Чын
Бер генә студент та зирәк кеше түгел	E	Ялган
Бер генә ялкау кеше дә мактауга лаек түгел	E	Чын
Барлык ялкау кешеләр дә мактауга лаек	A	Ялган

Турыдан-туры фикри нәтиҗәләр категорик хөкемнәрнең мәгънәләрен тулысынча чыгаруөчен ярдәм итә.

Капма-каршы куелыш (контрапозиция)

Субъект һәм предикатның барлык мөнәсәбәтләрен күрсәтүче, әверелеш белән мөрәҗәгатьне бәйлә үче һәм синтезлаучы логик яңадан коралу яши. Бу капма-каршы куелыш, яки контрапозиция дип атала.

Мәсәлән: Әгәр дә әлеге вакытта мин китапханәдә булсам, һәм «Үзгәрү китабын» укыйм икән, бу китапханәдәге кешеләр, ләкин әлеге китапны укымаучылар, мин була алмый.

Әверелеш + мөрәҗәгать + әверелеш = капма-каршылык.

Төрле хөкемнәр өчен капма-каршы булган мисаллар карыйк:

Гомуми раслаучы хөкемнәр

Предикат күләме субъект күләменнән зуррак булган гомуми раслаучы хөкем өченшундый мисаллар бар.

Барлык S – P

Барлык P – S

Барлык песиләр дә нәзакәтле

Барлык нәзакәтле булмаучы хайваннар песи түгел

Субъекты һәм предикаты тиңдәш булган гомуми раслаучы хөкемнәрдән субъектның предикатка кире кагылуы гына каршы куела, ләкин предикат та субъекттан кире кагыла.

А гына В була

Барлык P – S

Барлык S – P

Бакалар гына бакылдый

Барлык бакылдаучылар бака түгел

Барлык бака түгелләр бакылдамый

Аерым раслаучы хөкемнәр

Кагыйдә буларак, аерым раслучы хөкемнәр капма-каршылыкка дучар ителмиләр. Бу еш кире кагучы хөкемнәр мөрәҗәгате авырлыклары ярдәмендә аңлатыла һәм башлан-гыч хөкем субъектның капма-каршы куелучы хөкемне сыйфатында өстәмә предикат алу авырлыгында күренә.

Мәсәлән, «Кайбер S – P» хөкеменнән без «Кайбер P, S була алмый» хөкемен генә чы-гара алабыз. Бу, әлбәттә, әлеге яңа корылу максатына туры килми.

Мантыйк бүлеге

Гомуми кере кагучы хөкемнәр

Кире кагучы хөкемнәр капма-каршылыгы түбәндәге схема буенча эшләнә:

1. Бер S да P була алмый (рөхсәт ителү)

2. Барлык S – P (1, әверелеш)

3. Кайбер P – S (2, мөрәҗәгать)

4. Кайбер P, S була алмый (3, әверелеш)

Әлеге схема ярдәмендә башкарыла торган капма-каршылык, **чикләүле капма-кар- шылык** дип атала, чөнки әлеге яңа корылуда рөхсәт ителү гомуми, ә нәтиҗә аерым.

Мәсәлән:

Бер кысла да чуртан түгел

Кайбер чуртан булмаганнар кысла булмаучы түгелләр

Аерым кире кагучы хөкемнәр

Аерым кире кагучы хөкемнәр капма – каршылыгы түбәндәге схема буенча башкарыла:

1. Кайбер S, P түгел (рөхсәт ителү)

2. Кайбер S – P (1, әверелеш)

3. Кайбер P – S (2, мөрәҗәгать)

4. Кайбер P – S түгел (3, әверелеш)

Берничә мисал карыйк:

Кайбер S, P түгел

Кайбер P – S түгел

Кайбер рәхәтлекләр кирәк түгел

Кайбер кирәк гамәлләр рәхәтлек булып саналмый

Аерылып торучы аерым кире кагучы хөкемнәр капма-каршылыгы схема буенча башкарыла:

Кайбер S гына P түгел

Бер P да S түгел

Кайбер кошлар гына кеше тавышына охшамыйлар

Кеше тавышына охшарга тырышмаучы бер әйбер дә кош түгел

Күптармаклы базислы хөкемнәр

Алдагы күптармаклы базислы хөкем бирелсен:

1. Барлык S, P.
2. Барлык S – P.
3. Барлык S – P.
4. Бөтен S – P.
5. Бер S да P түгел.
6. Бер S да – P түгел.
7. Бер – S – P түгел.
8. Бер – S, P – түгел.
9. Кайбер S, P була.
10. Кайбер Алар – P.
11. Кайбер – S, P була.
12. Кайбер – S, – P була.
13. Кайбер S, P түгел.
14. Кайбер – S – P түгел.
15. Кайбер –S, P түгел.
16. Кайбер –S, – P түгел.
17. Барлык S, P.
18. Барлык S – P.
19. Барлык – S, P була.
20. Барлык – P – S.
21. Бер P да, S түгел.
22. Бер P да – S түгел.
23. Бер P да – S түгел.
24. Бер P да – S була алмый.
25. Кайбер P, S була.
26. Кайбер P – S.
27. Кайбер P – S була.
28. Кайбер – P, S була алмый.
29. Кайбер P, S түгел.
30. Кайбер P – S була алмый.
31. Кайбер – Рлар, S була алмый.
32. Кайбер – Рлар, S түгел.

Китерелгән мисаллардан 1нче хөкем дөрес дип карыйк. Алайсан, 6, 20 һәм 23 хөкемнәр шулай ук дөрес, чөнки алар беренчесенә тигез . 9, 12, 14, 15, 25, 28, 30 һәм 31 шулай ук дөрес, чөнки алар беренчесенә буйсына. 2, 5, 18, 21 хөкемнәр ялган чөнки алар беренчесенә **каршыдашлар**. 10, 13, 27, 32 хөкемнәр ялган чөнки алар беренчесенә **каршылар**. Хөкемнәрнең хаклы статусы билгесез кала.

9 нчы хөкемне дөрес дип карый. Алайсаң 14, 25, 30 хөкемнәр дөрес, чөнки алар 9 нчысына тигез. 2, 5, 18 һәм 21 хөкемнәр ялган, чөнки 9 нчысына капма – каршы. Калган хөкемнәрнең хаклыстатусы билгесез булып кала.

Нинди дә булса хөкемнең ялганыннан кайбер хаклы әһәмияте билгеләнә. 11нче хөкемне ялган дип карыйк. Алайсан 16, 26, 29 хөкемнәр ялган, чөнки алар 11 нчесенә тигез. 4, 7, 17, 22 хө- кемнәр дөрес, чөнки алар 11 нчесенә капма– каршы тора. 12, 15, 25, 28, 30, 31 хөкемнәр хас, чөнки ялган булган 11нчесе белән өлешчә туры килә. Калган хөкемнәрнең хаклы статусы билгесез булып кала.

§3. Гади категорик силлогизм

Гади категорик силлогизм ул – ике категорик хөкемнән яңа категорик хөкем чыгарылган дедуктив фикри нәтиҗә.

Силлогизмның төзелеше

Силлогизмның төзелешен гади мисалда күрсәтик:

Барлык кешеләр дә үлемгә дучар.Сократ – кеше.

Димәк, Сократ үлемгә дучар.

Яңа хөкем чыгарылган хөкемнәр **силлогизмның алшартлары** дип атала. Алшартлардан чыгарылган хөкемне **силлогизмның нәтиҗәсе** дип атыйлар.

Алшартларга яки нәтиҗәләргә кергән төшенчәләрне бирелгән силлогизмның **терминнары** дип атыйлар.

Силлогизмда гадәттә өч термин була:

Кечкенә термин дип, нәтиҗәнең субъекты алынган. Ул «S» хәрефе белән тамгалана.

Зур термин дип, нәтиҗәнең предикаты алына һәм ул «P» хәрефе белән тамгалана.

Урта термин нәтиҗәгә түгел, ә алшартларга керә һәм, алар арасында мантыйкый бәйләнеш булдырып, нәтиҗәнең булу мөмкинлеген тудыра. Урта термин «M» (лат. medius – урта) хәрефе белән белдерелә.



Югарыда күрсәтелгән силлогизмда «Сократ» – кечкенә термин (S), «үлемле» – зур термин (P), «кешеләр» – урта термин (M). Силлогизмдагы терминнар сан билгесе буенча аерылмыйлар.
Мәсәлән, «кеше» (берлек сан) һәм «кешеләр» (күплек сан) бер үкурта термин була.

Алшартка зур термин керсә, **зур алшарт** дип атала, ә кечкенә термин керсә, **кечкенә алшарт** дип атала.

Гадәттә силлогизмнарда башта зур, ә аннары кечкенә алшарт языла. Әгәр дә югарыдагы бирелгән силлогизмдагы терминнарны аларның тамгалары белән алмаштырсак, аның схемасы түбәндәгечә языльір:

Барлык M – P була
Барлык S – M була

Барлык S – P була

Мондагы сызык «димәк» сүзен алмаштыра.

Силлогизмның формасы дип, терминнар арасындагы бәйләнешкә әйтәләр.

Силлогизм аксиомасы

Силлогизмның мәҗбүрилек үзенчәлегенең нигезе булып мантыйкта силлогизм аксиомасы тәгъбир ителә. Силлогизм аксиомасы, фикерләүнең күпгасырлык практикасы чагылышы булып, миллиард тапкыр бер үк фикерләү конструкциясенең кабатлануынаярдәм итә.

Алшартларның күләм яки эчтәлек буенча ике билгеләмәсен аералар:

Dictum de omni et de nullo (сүз бөтен нәрсә турында һәм бернәрсә турында да түгел): Бербөтен күплеккә карата нәрсә расланса, бу раслау күплекнең һәрбер кисәгенә кагыла, һәм бөрбөтен күплеккә карата нәрсә инкарь ителсә, бу инкарь ителү күплекнең һәрбер кисәгенә кагыла.

Nota notae est nota rei (билгенең билгесе ул – әйбернең билгесе): билгенең билгесе ул шулай ук әйбернең билгесе, әгәр дә әйбернең билгесенә карата нәрсә инкарь ителсә, бу әйбернең үзенәкаратада инкарь ителә.

Силлогизм аксиомасының инкарь итү өлеше буенча да шундый ук ышандырырлык силлогизм төзергә була:

Бер генә сәясәтче дә ахырга кадәр үзен намуслы итеп тота алмый.

Барлык президентлар – сәясәтчеләр.

Бер генә президент та ахырга кадәр үзен намуслы итеп тота алмый

Әгәр бу силлогизмда «сәясәтче» терминын M белән тамгаласак, «ахырга кадәр намуслы кеше» – P аша, «президент» терминын S аша билгеләсәк, без түбәндәге схеманы чыгарабыз:

Бер генә M – P түгел
Барлык S – M

Димәк, бер генә S – P түгел

Монда P билгесе барлык M күләме өчен инкарь ителә, димәк, силлогизм аксиомасы буенча M күплегенең теләсә кайсы кисәге өченбу билге инкарь ителә, шулай ук S өчен дә.





§4. Гади категорик силлогизмның гомуми кагыйдәләре

Гади категорик силлогизмның төзелүе берничә кагыйдәгә буйсына. Аларны үтәмичә, чын булган алшартлардан да мантыйкый зарурилык белән дөрес нәтиҗәләр алып булмый. Бу кагыйдәләр җидәү: өчесе – терминнар кагыйдәләре, ә дүртесе – алшартлар кагыйдәләре.

Терминнар кагыйдәләре

Силлогизмда өч кенә термин булырга тиеш (S, P һәм M).

Бу кагыйдәне бозу мантыйкый хатага китерә һәм ул «quaternio terminorum» (терминнарның дүрт булуы) дип атала. Әгәр бездә урта термин белән бәйләнештә булмаган төрле эчтәлекле ике хөкем булса, бу очракта нәтиҗә ясап булмый.

Мәсәлән, «эт ишек алды буйлап йөгерә» һәм «мәчеагачта утыра», дигән алшартлардан бернинди дә нәтиҗә чыгарып булмый, чөнки монда дүрт термин, ике субъект һәм ике предикат. Ике хөкемне бәйләүче урта термин юк.

Урта термин алшартларның берсендә генә булса да, таралган булырга тиеш.

Әгәр бу кагыйдә үтәлмәсә, зур һәм кечкенә терминнар арасындагы бәйләнеш билгесез була.

Барлык рәссамнар (P) табигатьне тоя белүче (M)

Сыраев (S) табигатьне тоя белә (M)

Димәк, Сыраев (S) –рәссам (P)

Нәтиҗә билгесез, чөнки Сыраев рәссам булмаска да мөмкин. Билгесез булуның сәбәбе шунда: урта термин (M), зур һәм кечкенә алшартларда урын алып, икесендә дә таралмаган, чөнки алар икесе дә раслау хөкемнәре, ә раслау хөкемнәрендә предикат, кагыйдә буларак, таралмаган була.

Әгәр зур яки кечкенә терминнар алшартларда таралмаган булсалар, алар нәтиҗәдә дә таралган була алмыйлар, ягъни нәтиҗәдә таралган термин, алшартта да таралырга тиеш.

Барлык дәреслекләр (M) – файдалы (P).

Барлык дәреслекләр (M) – китаплар (S).

Димәк, барлык китаплар (S) файдалы (P).

Бу мисалда «Барлык китаплар файдалы» дип ник әйтергә ярамый? Чөнки, монда нәтиҗәнең субъекты «китаплар», кечкенә алшартта предикат урынын алган һәм ул таралмаган, чөнки алшарт – раслый торган, ә раслый торган хөкемнәрдә предикат таралмаган була.

Шуның өчен ул нәтиҗәдә дә барлык күләмдә алына алмый.

Алшартлар кагыйдәләре

Ике инкарь итә торган алшарттан билгеле нәтиҗә ясап булмый.

Берсе булса да, раслый торган хөкем булырга тиеш.

Мәсәлән:

Пыяла(M) электр тогы үткәрми (P).

Резина (S) – пыяла түгел (M).

Димәк, резина (S) электр тогы үткәрә (P).

Нәтиҗә ялган. Әгәр дә «резина» урынына «металлны» куйсак, ул чын булып чыгачак. Нәтиҗәдәге билгесезлек алшартларның инкарь булуы белән бәйле, чөнки бу очракта урта термин субъект белән предикатны бәйли алмый.

Әгәр алшартларның берсе инкарь итү булса, нәтиҗә дә инкарь итүбула.

Мәсәлән:

Һәртөрле җинаять (P) закон бозу була (M).

Әхлакый хата (S) закон бозу булмый (M).

Димәк, әхлакый хата (S) җинаять булмый (P).

Ике шәхси алшарттан билгеле нәтиҗә ясап булмый. Алшартның берсе булса да, гомуми хөкем булырга тиеш.

Мәсәлән: Кайбер депутатлар (M) – юристлар (P).

Кайбер артистлар (S) – депутатлар(M).

Димәк, кайбер артистлар (S) – юристлар (P).

Монда нәтиҗә билгесез, чөнки артистлар юристлар булмаска да мөмкин, йә, киресенчә, барысы да юрист булырга мөмкин.

Әгәр алшартларның берсе хосусый булса, нәтиҗә дә хосусый була.

Мәсәлән:

Кайбер пенсионерлар (P)эшлиләр (M).

Барлык эшләүчеләр (M) эш хакы алалар (S).

Димәк, кайбер эш хакы алучылар (S) – пенсионерлар(P).

Мантыйкта шулай ук фигуралар өчен дә кагыйдәләр эшләнеп чыгарылган, бу һәрбер фигура өчен фикри нәтиҗәнең дөреслеген билгеләргә ярдәм итә. Бу кагыйдәләрне киләсе параграфта карабыз.

§5. Гади категорик силлогизмның фигуралары һәм модуслары

Гади категорик силлогизм төрлелеккә ия, һәм алар силлогизмның фигуралары дип аталалар. Фигураларның төрлелеге урта терминның (М) алшарты урнашуы белән бәйле. Мондый фигуралар дүртәү.

Беренче фигура

Беренче фигура зур алшартта урта термин субъектныңурынын ала һәм предикат урынын кечкенә алшартта алуы белән характерлана.

График сурәте:



Мисалы:

Һәртөрле җинаять (М) закон бозу була (Р).

Урлау (S) – җинаять (М).

Димәк, урлау (S) закон бозу була (Р).

Кагыйдәсе: **Беренче фигурада фикри нәтиҗәләрдә зур алшарт гомуми булырга тиеш, ә кечкенә алшарт – раслый торган.**

Икенче фигура

Икенче фигурада урта термин зур һәм кечкенә алшартларда предикат урынын ала.

График сурәте: Р



Мисалы:

Бөтен юристлар (Р) мантыйкны белүләр (М).

Вәлиев (S) мантыйкны белми (М).

Кагыйдәсе: **Зур алшарты – гомуми, ә икенче алшарты инкарь итә торган булырга тиеш.**

Өченче фигура

Өченче фигурада урта термин зур һәм кечкенә алшартларда субъект урынын ала.

График сурәте:



Мисалы:

Барлык дәреслекләр (М) –файдалы (Р).

Барлык дәреслекләр (М) – китаплар (S).

Димәк, кайбер китаплар (S) файдалы (Р).

Кагыйдәсе: **Кечкенә алшарты раслый торган булырга тиеш, ә нәтиҗә – хосусый.**

Дүртенче фигура

Дүртенче фигураның урта термины зур алшартта – предикат урынын, ә кечкенә алшартта субъект урынын алуы белән характерлана.

График сурәте:

Мисалы:

Кайбер пенсионерлар (Р) – эшләүчеләр (М).

Барлык эшләүчеләр (М) эш хакы алалар (S).

Димәк, кайбер эш хакы алучылар (S) – пенсионерлар (Р).

Кагыйдәсе: **Дүртенче фигура практикада сирәк кулланыла, ә кагыйдәсе аның күпкә катлаулы, шуңа күрә ул монда каралмый.**

Һәрбер фигураны төргә аерырга була, алар модуслар (лат. сүзе modus – ысул) дип атала. Һәр алшарт гомуми раслау (А), гомуми инкарь итүче (Е), хосусый раслау (I) һәм хосусый инкарь итүче (О) була ала. Шуңа күрә бер фигурада 16 (4х4) модусның булуы мөмкин.

Мәсәлән, әгәр зур алшарт гомуми раслый торган (А) икән, аның модуслары болай була: АА, АЕ, АІ, АО. Зур алшарт гомуми инкарь итә торган булган очракта: ЕА, ЕЕ, ЕІ, ЕО, һ.б. Шулай ук ІА, ІЕ, ІІ, ІО; ОА, ОЕ, ОІ,

ОО. Шулай итеп, дүрт фигурада 64 модус (16х4) булырга мөмкин.

Фигураларның дөрес модусларын түбәндәгечә тезәргә була:
I фигура: ААА, ЕАЕ, АІІ, ЕІО;
II фигура: ЕАЕ, АЕЕ, ЕІО, АОО;
III фигура: ААІ, ІАІ, АІІ, ЕАО, ЕОА, ЕІО;
IV фигура: ААІ, АЕЕ, ІАІ, ЕАО, ЕІО.

§6. Энтимемалар

Фикри нәтиҗәдә берәр алшарт яки нәтиҗә төшерелеп калдырылган, яисә кыскартылган категорик силлогизм **энтимема** (грек сүзе en tume – уйда дигәнне аңлата). Энтимеманың өч төрен аерырга була:

Зур алшарты төшереп калдырылган силлогизм

Мәсәлән: «Сыраев – адвокат. Димәк, ул – юрист». Монда: «Барлык адвокатлар – юристлар», дигән зур алшарт уйланылып төшерелеп калдырыла.

Кечкенә алшарты төшереп калдырылган энтимема

Мәсәлән: «Барлык адвокатлар – юристлар. Димәк, Сыраев – юрист». Монда «Сыраев – адвокат» булу уйланыла.

Төшереп калдырылган нәтиҗәле энтимема

Мәсәлән: «Барлык адвокатлар – юристлар. Сыраев – адвокат». Монда «димәк, ул – юрист» дип уйланыла, Сыраевның да юрист булуы хакындагы нәтиҗә төшерелеп калдырылган.

Энтимемадан силлогизмның тулы формасын төзү – энтимема төзү операциясенә караганкире операция. Ул берничә этаптан тора:

Силлогизмның төшерелеп калдырган элементларын билгеләү: алшартын яки нәтиҗәсен.

Әгәр дә энтимемада «димәк», «шуңа күрә», «чөнки» кебек сүзләр булмаса, димәк, монда нәтиҗә төшерелеп калдырылган булырга тиеш.

Тулы силлогизмда булырга тиеш терминнарны билгеләү: урта термин, зур һәм кечкенә термин.

Силлогизмның фигурасын һәм алшартларның тәртибен бил геләү.

Силлогизмны тулы формада тәгъбир итү.

Мисал өчен «Колларны тоткынлыкта тотарга ярамый, чөнки алар кешеләр» энтимемасын карыйк:

Силлогизмның нәтиҗәсе – «чөнки» сүзеннән алдан килә торган хөкем; икенче хөкемдә, нәтиҗәнең субъекты буларак, «коллар» термины катнаша, бу – кечкенә алшарт, димәк, зур алшарт төшерелеп калдырылган

Энтимеманы төзегән хөкемнәр категорик хөкемнәрнең каноник формасында тормаганга күрә, аларны шул формага китерергә кирәк. Каноник формада алар болай языла: «Бер генә колны да тоткынлыкта тотарга ярамый», «Барлык коллар – кешеләр».

Силлогизмның терминнары булып:
«коллар»
− кечкенә термин,
«кемнәрне тоткынлыкта тотарга ярамый»
− зур термин, ә нәтиҗәдә очрамаган «кешеләр» термины
− урта термин.

Тулы нәтиҗә ике **фигура буенча** булырга мөмкин: беренче һәм икенче фигура (кечкенә алшартның төзелешен кара). Монда фигураны сайлауга урта терминның урнашуы үзгәрә: беренче фигурада ул зур алшартның субъект ролен үти, ә икенче фигурада – зур алшартның предикатын.

§7. Полисиллогизмнар

Категорик хөкемнәрдән торган фикри нәтиҗәләр һәрвакытта да, ике алшартны гына үз эченә алып, гади силлогизм формасында гына тормый. Ул, бер-берсе белән билгеле рәвештә бәйләнгән, берничә силлогизмнан торган катлаулы категорик силлогизм формасында да булырга мөмкин. Мондый фикри нәтиҗә **полисиллогизм** (грек сүзе poly – күп) яки катлаулы силлогизм дип атала.

Мәсәлән:

Барлык үсемлекләр – тере организмнар.

Барлык чәчәкләр – үсемлекләр.

Димәк, барлык чәчәкләр – тере организмнар.

Ачык алшартлары төшерелеп калдырылган силлогизм, катлаулы силлогизмның кыскартылган төре **сорит** (грек сүзе soros – өем) дип атала. Ул класс предметлар тезмәсе арасындагы бәйләнешләрне карап үтәргә кирәк булганда кулланыла.

Мәсәлән:

Барлык үсемлекләр – тере организмнар.

Барлык чәчәкләр – үсемлекләр.

Роза – чәчәк.

Димәк, роза – тере организм.

Нигаять, полисиллогизмда ике алшарты да энтимема булырга мөмкин, ягъни кыскартылган гади силлогизмнан торырга мөмкин. Мондый полисиллогизм **эпихейрема** дип атала.

Мәсәлән, зуррак алшарт итеп, Р. Декартның фәлсәфи нигезләмәсен кулланыйк: «Мин уйлыйм, димәк, мин яшим» («Cogito, ergo sum»).

§8. Катлаулы хөкемнәрдән турыдан-туры фикри нәтиҗәләр

Турыдан-туры фикри нәтиҗәнең алшарты гади хөкем генә түгел, ә катлаулы хөкем дә булырга мөмкин.

Мисал өчен шартлы хөкемне алыйк (импликация):

«Әгәр иртәгә көн кояшлы булса, без урманга барабыз».

Турыдан-туры фикри нәтиҗәне конъюнкциядән дә чыгарырга була.

«Казан Идел ярында урнашкан һәм УльяновсктаИдел ярында урнашкан» хөкеме чын булса, нәтиҗә: «Ульяновск Идел ярында урнашкан һәм Казан Идел ярында урнашкан» хөкеме дә чын була.

Конъюнкциядән һәм дизъюнкциядән төзелгән турыдан-туры булган фикри нәтиҗәләр нигезендә аларның урын алмаштыру үзенчәлеге яки коммутативлык тора.

Әгәр дә «Эшнең яхшы баруы эш коралларының яхшы булуына яки эшченең уңганлыгына бәйле» хөкеме чын булса, «Эшнең яхшы баруы эшченең уңганлыгына яки эш коралларының яхшы булуына бәйле» хөкеме дә чын була.

Шундый ук фикри нәтиҗәләрне төгәл дизъюнкциягә һәм эквивалентлыкка нигезләнеп ясарга була.

§9. Катлаулы хөкемнәрдән чыгарылган фикри нәтиҗәләр

Бәйләнешләрнең үзлекләреннән чыгып, катлаулы хөкемнәрдән чыгарылган фикри нәтиҗәләрне **шартлы** һәм **аера торганга** бүләләр.

1. Шартлы фикри нәтиҗә

Әгәр алшартның берсе булса да шартлы хөкем булса, фикри нәтиҗә шартлы дип атала. Фикри нәтиҗәдә бер яки ике шартлы хөкем булуына карап, шартлы хөкемнәрне ике төргә: **шартлы категорик** һәм **чиста шартлыга** бүләләр.

1.1. Шартлы-категорик фикри нәтиҗә. Шартлы-категорик фикри нәтиҗә бер шартлы һәм бер категорик алшарттан тора. Нәтиҗә бу очракта категорик хөкем була. Шуны истә тотарга кирәк: монда категорик хөкем булып гади хөкем, дөресрәге, гади атрибутив хөкем карала. Мондый фикри нәтиҗәгә мантыйкый нигез булып шартлы хөкемнең **сәбәбе** (антцедент) һәм **нәтиҗәсе** (консеквент) арасындагы билгеле бәйләнеш хезмәт итә.

Шартлы-категорик фикри нәтиҗәләрдә фикер йөртү түбәндәге юнәлешләр буенча барырга мөмкин:

1. Сәбәпне раслаудан – нәтиҗәне раслауга;
2. Сәбәпне инкарь итүдән – нәтиҗәне инкарь итүгә;
3. Нәтиҗәне раслаудан – сәбәпне раслауга;
4. Нәтиҗәне инкарь итүдән – сәбәпне инкарь итүгә.

Шуңа күрә, фикер юнәлешенә карап, теоретик рәвештә, дүрт төрдә шартлы-категорик фикри нәтиҗә чыгарырга яки модуслар булырга мөмкин.

Әмма гади категорик силлогизмда 64 модусның 19 гына дөрес булган кебек, монда дадүртесеннән икесе генә дөрес.

Беренчесе – **modus ponens – раслый торган модус**, фикер сәбәпне раслаудан нәтиҗәне раслауга юнәлә.

Мәсәлән:

Әгәр көн кояшлы икән (p) – сәбәп, нарат урманыннан сумала исе килә (q) – нәтиҗә.

Көн – кояшлы (p). – сәбәп раслана

Димәк, нарат урманыннан сумала исе килә (q). – нәтиҗә раслана

Схематик рәвештә: p → q, p

q

Икенчесе – **modus tollens – инкарь итә торган модус**, фикер нәтиҗәне инкарь итүдән нигезне инкарь итүгә юнәлгән.

Мәсәлән:

Әгәр көн кояшлы икән (p) – сәбәп, ул чакта нарат урманыннан сумала исе килә (q) – нәтиҗә. Нарат урманыннан сумала исе килми (p) – нәтиҗә инкарь ителә.

Димәк, көн кояшлы түгел (p) – сәбәп инкарь ителә

Схемасы: p → q, ¬q

¬p

Ни өчен бу ике модус кына дөрес була ала? Аларның дөреслеге чынбарлыкта сәбәп һәм нәтиҗә арасындагы объектив үзара мөнәсәбәтләр белән билгеләнә. Әгәр сәбәбе булса, нәтиҗәсе дә булырга тиеш, ә нәтиҗәсе булмаса, димәк, сәбәбе дә юк.

Нишләп соң модусларның калган икесе дөрес түгел? Чөнки сәбәп һәм нәтиҗә арасындагы үзара мөнәсәбәтләр бер мәгънәдә түгел. Бер үк нәтиҗә төрле сәбәпләр аркасында булырга мөмкин (күп сәбәплелек), ә бер үк сәбәп төрле нәтиҗәләр чыгарырга мөмкин (нәтиҗәләрнең күплеге).

Шуның өчен, бирелгән сәбәп юк икән, бу әле бирелгән нәтиҗәнең юк дигәнен аңлатмый: ул гел башка сәбәпнең нәтиҗәсе булырга мөмкин.

Мәсәлән:

Әгәр мин салкын тидерсәм (p) – сәбәп, ул чакта авырыячакмын (q) – нәтиҗә.

Мин салкын тидермәдем (p). – сәбәп инкарь ителә.

Димәк, мин авырмаячакмын. – нәтиҗә инкарь ителү дөрес түгел.

Әлбәттә, мондый нәтиҗә алшартлардан мантыйкый зарурилык белән чыкмый. Мин агуланып, йогышлы чир эләктереп, һ.б чир белән авырырга мөмкин. Икенче яктан караганда, әгәр нәтиҗә булса, бу әле бирелгән сәбәп белән генә барлыкка килә, дигән сүз түгел.

Мәсәлән:

Әгәр мин салкын тидерсәм (p) – сәбәп, ул чакта авырачакмын (q) – нәтиҗә.

Мин авырдым (p). – нәтиҗә раслана.

Димәк, миңа салкын тигән. – сәбәп раслану дөрес түгел.

Әлбәттә, мондый нәтиҗә дә мәҗбүри түгел.

Моннан чыгып, шартлы-категорик фикри нәтиҗәләрнең дүрт кагыйдәсен күрсәтергә була. Бу кагыйдәләрне үтәгәндә, алшартларның чын булуы нәтиҗәнең чын булуына китерә.

Сәбәпне раслаудан нәтиҗәне раслауга таба фикер йөртергә кирәк. Нәтиҗәне инкарь итүдән сәбәпне инкарь итүгә таба фикер йөртергә кирәк.

3. Сәбәпне инкарь итүдән нәтиҗәне инкарь итүгә таба фикер йөртергә ярамый.

4. Нәтиҗәне раслаудан сәбәпне раслауга таба фикер йөртергә ярамый.

Соңгы ике очракта ихтималлы нәтиҗәләр генә чыгарга мөмкин. Раслый торган һәм инкарь итә торган модусларның дөреслеген шулай ук чынлык таблицасы аша күрсәтергә була.

1.2. Саф шартлы фикри нәтиҗә Исеменнән күренгәнчә, бу фикри нәтиҗәгә шартлыхөкемнәр генә керә.

Ике алшартында һәм нәтиҗәсендә шартлы хөкем булган фикри нәтиҗәне саф шартлы фикри нәтиҗә дип әйтәләр.

Монда да шартлы-категорик фикри нәтиҗәдәге кебек, алшартның «әгәр» дип башланган өлеше **антецедент яки нигез** дип атала. Алшартның «ул чакта» кебек сүз белән башланган өлеше **консеквентом яки нәтиҗә** була. Шартлы силлогизмда нәтиҗә икедән генә түгел, ә күбрәк алшартлардан да алынырга мөмкин. Мондый фикри нәтиҗәләр сүзләргә карыйлар, аларга түбәндәге схема туры килә:

$(A \rightarrow B) \wedge (B \wedge C) \wedge (C \rightarrow D) \ldots (E \rightarrow S)$

Саф шартлы фикри нәтиҗәгә мисал:

Әгәр бу эш караклык икән, (p) – сәбәп, ул чакта бу – җинаять (q) – нәтиҗә.

Әгәр ул җинаять икән, (q) – сәбәп, ул чакта закон җаваплылыкка тартырга тиеш (r) – нәтиҗә.

Димәк, әгәр бу эш караклык икән, (p) – сәбәп, ул чакта закон җаваплылыкка тартырга тиеш (r) – нәтиҗә.

Схематик рәвештә болай языла:p → q, q → r

p → r

Монда түбәндәге кагыйдә туры килә: **нәтиҗәнең нәтиҗәсе сәбәпнең нәтиҗәсе була.**

2. Аера торган фикри нәтиҗә

Әгәр фикри нәтиҗәдә бер алшарты аера торган хөкем (дизъюнкция) булса, бу аера торган фикри нәтиҗә дип атала. Икенче алшартның характерына карап, аның өч төп төрен күрсәтергә була: аера торган-категорик, аера торган-шартлы һәм саф аера торган.

2.1. Аера торган-категорик фикри нәтиҗә. Аера торган-категорик фикри нәтиҗә аера торган һәм категорик алшарттан тора. Аның нәтиҗәсе булып категорик хөкем тора.

Фикер йөртүгә бәйле аера торган-категорик фикри нәтиҗәдә ике модусны аерып чыгарырга була:

1)модус ponendo tollens – раслый торган-инкарь итә торган модус, мондагы фикернең башта мөмкин була алган бер вариантны раслаудан икенче вариантны инкарь итүгә күчү юнәлеше.

Мәсәлән:

Җинаять, йә алдан уйлап эшләнелә (p) яки саксызлык нәтиҗәсендә эшләнелә (q).

Бу җинаять алдан уйлап эшләнелгән (p). – беренче вариант раслана

Димәк, ул саксызлык нәтиҗәсендә эшләнмәгән (¬q) – икенче вариант инкарь ителә.

Схематик рәвештә:p ˅ q, p

¬q

2)модус tollendo ponens – инкарь итә торган-раслый торган модус, монда фикер бер вариантны инкарь итүдән икенчесен раслауга күчә.

Мәсәлән:

Суд карары гаепләүле яки аклаулы булырга мөмкин.

Бу эш буенча суд карары гаепләүле түгел.

Димәк, ул аклаулы була.

Бу модусның схемасы:p ˅ q, ¬p

q

Аера торган-категорик фикри нәтиҗә түбәндәге кагыйдәләргә буйсынырга тиеш:

а) хөкем төгәл аера торган булырга тиеш (төгәл дизъюнкция кулланылырга тиеш). Аера торган хөкемдәге хөкемнәрнең икесенең берсе генә чын булырга тиеш, ягъни мөмкин була торган вариантлар бер-берсен төшереп калдырырга тиешләр, әгәр бу кагыйдә бозылса, мантыйкый ялгышлар килеп чыга.

Мисал:

Китаплар кызыклы яки файдалы булалар.

Бу китап файдалы.

Димәк, бу китап кызык түгел.

Нәтиҗә: мантыйкый зарурилык белән чыкмый, чөнки дизъюнкция төгәл түгел, ә гади:китаплар бер үк вакытта файдалы да, кызык та булырга мөмкиннәр.

б) дизъюнкция тулы булырга тиеш, ягъни барлык мөмкин була торган вариантлар да каралырга тиеш. Бу кагыйдәне бозу шулай ук ялгышка китерә.

Мәсәлән:

Китаплар фәнни яки әдәби була.

Бу әдәби китап түгел.

Димәк, бу фәнни китап.

Бу нәтиҗә дөрес булыр иде, әгәр дә китаплар фәнни һәм әдәби генә булсалар, әмма тагын болардан башка дәреслекләр, сүзлекләр була. Шуңа күрә безнең нәтиҗә ялганбулырга да мөмкин.

в) төгәл дизъюнкциядә «артык» әгъзалар булырга тиеш түгел. Мәсәлән:

Безнең ил сәясәтчеләре дестабилизаторлар, нормализаторлар яки стабилизаторлар булырга мөмкин.

Бу сәясәтче – нормализатор.

Димәк, ул дестабилизатор да түгел, стабилизатор да түгел.

Монда мәгънәсезлек килеп чыга: сәясәтчеләр ике төп каршылыклы төшенчәләр белән генә чикләнәләр: «стабилизаторлар» яки «дестабилизаторлар», ә «нормализаторлар» – артык әгъза.

2.2. Аера торган-шартлы фикри нәтиҗә

Исеме буенча бу фикри нәтиҗәләрдә ике типтагы хөкем очрый: беренче алшарты – шартлы хөкем, икенче – аера торган. Нәтиҗә монда категорик яки аера торган хөкем булырга мөмкин. Аера торган-шартлы хөкемнең тагын бер исеме – лематик (грек сүзеннән lemma – чамалауны аңлата).

Аера торган фикри нәтиҗәләрдә, аера торган алшартта ике альтернатива булса, ул – дилемма, өч – трилемма, дүрт яки күбрәк булса, полилеммалар дип атала.

Фикерләү практикасында дилеммалар ешрак кулланыла, шуның өчен аларга зур игътибарбирербез.

Дилеммаларны ике нигез буенча бүләргә була:

а) Нәтиҗәдә башкарыла торган актның сыйфаты буенча (раслый торган яки инкарь итә торган): дилеммалар конструктивка (төзи торганга) һәм деструктивка (җимерә торганга) бүленәләр.

Әгәр нәтиҗәгә шартлы алшартларның нәтиҗәсе (консеквент) керсә, бу конструктив дилемма дип атала.

Әгәр нәтиҗәдә шартлы алшартларның сәбәбе инкарь ителсә, бу деструктив дилемма дипатала.

б) Нәтиҗәгә керә торган хөкемнең катлаулыгы буенча (дизъюнкциянең барлыгы яки юклыгы) гадигә һәм катлаулыга бүленә.

Әгәр нәтиҗәдә шартлы алшартларның нәтиҗәсе булса яки шартлы алшартларның сәбәбе инкарь ителсә, бу гади дилемма була.

Әгәр нәтиҗәдә шартлы алшартларның нәтиҗәсенең дизъюнкциясе торса яки шартлы алшартларның сәбәбе инкарь ителсә, бу катлаулы дилемма була.

Бу ике бүленеш нигезендә катлаулы дихотомик бүленү төзергә була, нәтиҗәдә дилеммаларның түбәндәге классификациясе чыга:



Гади конструктив дилемма

Гади конструктив дилеммада шартлы алшартлардан нәтиҗә ике шарттан (ике сәбәптән) чыгу мөмкинлеге күрсәтелә. Аера торган алшарт бу ике сәбәп белән генә чикләнә, һәм нәтиҗәдә шартлы хөкемнәрнең нәтиҗәсе раслана.

Мисал:

Әгәр дәүләт банкы акчалар эмиссиясен күбәйтсә, (p) – *сәбәп*, инфляция үсәчәк (q) – *нәтиҗә.* Әгәр дәүләт банкы табыш бирә алмый торган предприятиегә льготалы кредитлар бирсә, (r) – *сәбәп*, инфляция үсәчәк (q) – *нәтиҗә*. Дәүләт банкы акчалар эмиссиясенкүбәйтә (p) яки табыш бирә алмый торган предприятиеләргә льготалы кредитлар бирә (r). Димәк, инфляция үсәчәк (q) – *нәтиҗәдә алшартларның нәтиҗәсе*.

Фикерләү схемасы:p → q

r → q

———

p ˅ r

q

Гади деструктив дилемма

Гади деструктив дилеммада шартлы алшартларда бер сәбәп аркасында ике нәтиҗә чыгу мөмкинлеге күрсәтелә. Аера торган алшарт мөмкин була торган нәтиҗәләрнең берсе инкарь ителә һәм нәтиҗәдә шартлы хөкемнәрнең сәбәбе инкарь ителә.

Мисал:

Әгәр минем буш вакытым булса, (p) – *сәбәп*, мин китап өстендә эшләгән булыр идем (q) –*нәтиҗә.* Әгәр минем буш вакытым булса, (p) – *сәбәп*, мин картина язар идем (r) – *нәтиҗә.*Мин китап өстендә эшләмәдем (¬q) яки картина язмадым (¬r). Димәк, минем буш вакытымбулмады (¬p).

Фикерләү схемасы:p → q

p → r

———

¬q ˅ ¬r

¬p

Искәрмә: монда ике шартлы хөкем бер-берсе белән конъюнкция мөнәсәбәтендә торалар (p →q ∧ p → r, ягъни p → q ∧ r), безнең мисалда: «Минем буш вакытым булса, мин китап өстендә эшлим һәм картина язам» язу формасы дөресрәк булыр иде. Исегездәдер, конъюнкциядә катлаулы хөкем чын булсын өчен, аны төзегән хөкемнәр икесе дә берьюлы чын булырга тиеш. Безнең очракта нәтиҗәнең берсе генә үтәлмәсә дә, сәбәп булмаганлыкны аңлата.

Катлаулы конструктив дилемма

Катлаулы дилеммаларга мисаллар гына китерәбез:

Әгәр җинаятьчеләр акылга зәгыйфьләнгән кешеләр икән (s1), аларны җәмгыятьтән аерым урнаштырырга кирәк (p).

Әгәр җинаятьчеләр үз акылларында икән (s2), аларны җәзага тартырга кирәк (q). Һәрбер җинаятьче йә акылга зәгыйфь (s1), йә үз акылында (s2).

Димәк, җинаятьчеләрне йә җәмгыятьтән аерым урнаштырырга кирәк, йә җәзага тартырга кирәк.

Структурасы:

s1 → p

s2 → q

s1 ∨ s2p ∨ q

Катлаулы деструктив дилемма

Мисал:

Әгәр ул акыллы икән (s1), хатасын күрер (p). Әгәр ул эчкерсез икән (s2), хатасын таныр (q).

Ул йә хатасын күрми (¬p), йә хатасын танымый (¬q) Димәк, ул йә акыллы түгел (¬s1), йә эчкерсез түгел (¬s2).

Структурасы:s1 → p

s2 → q

¬p ∨ ¬q

¬s1 ∨ ¬s2

Тема 3. Индуктив фикри нәтиҗә

§1. Индуктив фикри нәтиҗә һәм аның роле

Индукция

Индукция (латин сүзе induction – тикшерү ысулы), фактларга нигезләнеп, гомуми нәтиҗә чыгару типларының берсе. Индукция проблемасын ачыклауга Ф. Бекон, Г. Галилей, И. Ньютон һәм башкалар зур өлеш керткәннәр.

Фикри нәтиҗә системасында индуктив фикри нәтиҗә ялгыз гына тормый. Ул дедукция белән тыгыз бәйләнештә. Бу бәйләнешне кагыйдә белән әйтергә була: «Индукциядән башка дедукция, дедукциядән башка индукция юк».

§2. Индуктив фикри нәтиҗә төзелеше

Монда да дедукциядәге кебек, бирелгән башлангыч хөкемнәр **алшартлар** дип атала. Дедукциядә алар урынына гомуми яки хосусый хөкемнәр керсә, индукция өчен ялгыз яки берлек хөкемнәр характерлы, чөнки аларда белемнәр аерым предметлар турында була (аерым төркемнәр турында да белемнәр булырга мөмкин).

Мантыйкый юл белән чыгарылган хөкем шулай ук **нәтиҗә** дип атала. Төп аерма шунда: ул гомуми булуы белән характерлана (берәр класс предметының өлеше буларак хосусый да булырга мөмкин), дедукциядә ул хосусый да, ялгыз да булырга мөмкин.

Факт ул – тою нигезендә кабул ителгән һәм ялгызлык хөкемендә чагылган белем.

Фактлар гади һәм катлаулы булырга мөмкиннәр.Гади факт – ялгыз хөкемдә чагылган факт.

Катлаулы факт – ялгыз хөкемнәренең конъюнкциясендә чагылган факт.

Мәсәлән, «Бу кәгазь ак» фактын, «бу кәгазь» терминын а аша тамгаласак, ә предикат «акбулу» –

Р аша, без түбәндәге формада язарбыз: Р(а).

§3. Индуктив фикри нәтиҗә төрләре

Тулы индукция ул – ниндидер күплектәге предметларның ниндидер билгегә хас булуы нигезендә бу билгенең барлык предметларына да хас дигән индуктив фикри нәтиҗә ясау.

Индуктив фикри нәтиҗә төрләре. Алар арасында, бигрәк тә гомумиләшкәннәрдән, тулы һәм тулы булмаган индуктив фикри нәтиҗәләр була.

Тулы индуктив фикри нәтиҗә

Мәсәлән: Гади очракта тулы индукцияне түбәндәге мисал белән күрсәтеп була. Мәсәлән, без һәркөнне һава торышын күзәтәбез, һәм ниндидер вакыт арасында бер атна буе кояшлы көн булуын билгеләп барабыз. Күзәтүләр нәтиҗәсендә һәр көн кояшлы булуын раслыйбыз. Бу тикшеренүләр безгә гомуми нәтиҗә чыгарырга ярдәм итә: атна буе кояшлы көн булды. Бу мисалдан без индуктив фикри нәтиҗәнең үзенчәлекле форма алуын күрәбез. Өйрәтү максатыннан, аны түбәндәгечә күрсәтеп була:

Дүшәмбе – кояшлы көн.
Сишәмбе – кояшлы көн.

Көн n *– кояшлы көн.*
Дүшәмбе, сишәмбе … көн n *атнаның барлык көннәрен дә тулыландыралар.*

Димәк, атна кояшлы булган.

Әгәр дә күплек A (атна) = (a1, a2, ..., an (көннәр)) дип карасак, бу мисалны түбәндәге формула белән дә күрсәтеп була:

a1 – P билгесенә хас a2 – P билгесенә хас an – P билгесенә хас
a1, a2 ... an ... A классына тулысынча керәләр.

Димәк, барлык A – P билгесенә хас.

Предикатлар мантыйгы телендә бу схема түбәндәгечә языла:

P(a1)
P(a2)
P(a3)
…
P(an)
xP(x)

Монда x ның билгеләнү өлкәсе A күплеге.

Тулы индукциядә нәтиҗә чын һәм ялган булырга мөмкин:

— Чын

Әгәр эчтәлекләре буенча барлык алшартлар да чын булса һәм нәтиҗә белән алар арасында мантыйкый эзлеклелек булса, ул чын була.

— Ялган

Әгәр бу шартлар үтәлмәсә, тулы индукция ялган була.

Тулы булмаган индукция

Тулы булмаган индукция ул – күплектәге барлык предметлар турындагы нәтиҗәне бирелгән күплекнең предметларын өлешчә өйрәнү нигезендә барлыкка килгән индуктив фикри нәтиҗә.

Тулы булмаган индукциянең формуласы:a1 – P
a2 – P
…..
an – P
a1, a2, … an … A классының өлешен алалар.

Димәк, барлык A – P билгесенә хас булырга мөмкин.

Схематик рәвештә:P(a1)
P(a2)
P(a3)
…
P(an)

□ xP(x)

Тулы булмаган индукциянең ике төре була: популяр һәм фәнни индукция.

Популяр индукциянең тулы исеме – каршылыклы очраклары булмаган, гади санаудан чыккан индукция.

Мәсәлән, кешеләр яңгыр алдыннан карлыгачларның җир өстеннән түбән очканнарын еш күзәткәннәр һәм бу нигездә нәтиҗә ясалган: «Яңгыр алдыннан карлыгачлар һәрвакыт җир өстеннән түбән очалар».

Популяр индукциянең югарыда әйтеп үтелгән кимчелекләре **фәнни индукция** ярдәмендә үтәлә. Фикри нәтиҗәләрдә, алшартлардагы күренешләрнең билгеләре кабатлануыннан башка, бу билгеләрнең килеп чыгу сәбәбе турында мәгълүмат та бирелә. Шуның ярдәмендә аерым очраклар күзәтелеп кенә калмый, ә тикшерелә: «Ник болай, ә башкача түгел?», дигән сорауга җавап табыла.

Мәсәлән, карлыгачлар яңгыр алдыннан түбән очалар, чөнки алар ашый торган черкиләр түбән оча; ә черкиләр түбән оча, чөнки аларның канатлары яңгыр алдыннан авырая. Шуның аркасында тулы булмаган индукция нәтиҗәсенең чын булу ихтималы арта.

Математик индукция

Математикада индукциянең махсус төре буларак, математик индукция тора, аны да еш кына тулы индукция дип атыйлар.

Математик индукция натураль саннар рәтенең төзелешенә һәм үзлегенә нигезләнә. Натураль саннар рәте чиксез булуга карамастан, ул гади закон нигезендә төзелгән: һәрбер киләсе сан элеккеге саннан нәкъ бергә зуррак. Бу натураль саннарның үзлегебезгә гомуми раслауларны исбатларга мөмкинлек бирә.

Мәсәлән: Мәсәлән, башта безне кызыксындырган үзлек натураль рәт саннарының беренче әгъзасы 1 санына хас итеп карыйбыз һәм бу үзлекне ниндидер ирекле санга да хас дип чамалыйбыз, аны n дип атыйк, моннан бу киләсе n+1 санына да хас булу мөмкинлегечыга. Шулай итеп, безне кызыксындырган үзлек теләсә нинди натураль сан өчен хас диписбатлый алабыз.

Математик индукцияне схематик рәвештә түбәндәгечә язарга була:

Монда P – безне кызыксындырган натураль санның үзлеге булсын, шулай булгач,P(1) һәм P(n) →

P(n+1) ⊢ ▯ xP(x).

Монда P(1) – индукциянең базисы, P(n) – индуктив чамалау, ә импликациянең нигезләнүеP(n) → P(n+1) индуктив адым дип атала.

§4. Индуктив тикшеренү методлары

Индуктив тикшеренү методлары

Күренешләр һәм предметлар арасындагы сәбәпле күренешләрне ачыклау өчен, индуктив тикшеренүләрнең төрле методлары кулланыла.

Охшату методы

Аның асылы төрле фактларны чагыштырып, әлеге фактларда теге яки бу мөнәсәбәттә охшашлыкларны табудан гыйбарәт.

Мәсәлән, без салават күпере барлыкка килүнең сәбәбен ачыкларга телибез һәм моның өчен аның барлыкка килү очракларын күзәтәбез: яңгыр вакытында, иртәнге чыкта, шарлавык янындагы су тузанында, кояш нуры пыяла призма аркылы үткәндә һ.б. Күргәнебезчә, алар арасында зур аерма булуга карамастан, аларның нәрсәсе булса да охшаш – кояш нурының билгеле формадагы үтә күренмәле әйбер аркылы үтүе.

Бу салават күпере барлыкка килүнең сәбәбе турында нәтиҗәясаганда, мантыйкый нигез була. Түбәндә охшашлык методы нигезендәге индуктив тикшеренүләрнең формуласы бирелгән:

ABC ... – a
ACД ... – a
AEI ... – a

A сәбәп a

Охшашлык методының танып белүдә әһәмияте зур. Фән, тәжрибәләр һәм күзәтүләр ясаганда, аның белән бик еш файдалана.

Әмма чын белемне бу метод бирмәскә дә мөмкин. Мәсәлән, «А» ның барлык күренешләре түгел, ә бер өлеше генә «а» нәтиҗәсен чыгарырга мөмкин. Мәсәлән, «халык медицинасында мышьяк сихер белән бергә генә бизгәк авыруыннан терелтә ала», дигән караш яшәгән. Ә соңрак мышьякның үзенең генә дә авырудан дәвалый алуы ачыкланган.

Аеру методы

Күп мөнәсәбәтләрдә охшаш булган предметлар һәм күренешләр үзара аерылып торы-рга да мөмкин. Ә бу аерма теге яки бу нәтиҗәләрнең барлыгы яисә юклыгына бәйле. Бер аеру методы фәнни индукция ысулларының иң ышанычлысы дип санала.

Мәсәлән, нормаль һавада шәм яна, ә кислород булмаган һавада, ягъни һаваны аерып алсак, шәм сүнә. Димәк, моннан шундый нәтиҗә ясап була: һава – яну өчен кирәкле шарт. Тагын бер мисал:

Әгәр һава насосының гөмбәзе астына берәр тереклекне куйсаң, мәсәлән, тычканны, ул яши. Әгәр барлык шартларны калдырып, һаваны суыртып алсак, тычкан үлә. Димәк, һаваның булуы тереклекнең яшәвенә шарт яки сәбәп булып тора. Формула белән күрсәтсәк, болай була:

ABC ... – a
BC ... – a юк

A сәбәп a

Әмма нәтиҗәдәге ихтимал-лык бу очракта да кала.

Мәсәлән, «а»га сәбәп булып «А» үзе генә түгел, ә нәрсә белән дә булса кушылырга мөмкин; мәсәлән, «В» белән булырга мөмкин. Ми- сал өчен «һава насосының гөмбәзе астындагы кыңгырау һава булганда тавыш бирә – һава булмаса, тавыш бирми». Әмма тавыш бирүнең сәбәбе: һава үзе генә түгел, ә кыңгырау белән бергә кушылмуы.

Аермалылык һәм охшашлыкның кушма методы

Охшашлык һәм аермалылык методларын бергә куллану аермалылык һәм охшашлыкның кушма методын бирә: әгәр ике яисә күбрәк очракта бирелгән күренеш барлыкка килсә, бергенә очракта охшаш булып, шул ук вакытта ике яки күбрәк очракта бу күренеш булмаса, бирелгән очракның булмавы белән аерылалар икән, бу очрак каралган күренешнең сәбәбе булуы ихтимал. Бу методта сәбәп бәйләнешләрен тикшерү түбәндәгечә үтәлә:

ABC – a
ADE – a
BC – a юк
DE – a юк

A сәбәп a

Мондый фикри нәтиҗәләрдә ихтималлык күбәя, чөнки монда ике метод та кушыла.

Иярчен үзгәрешләр методы

Бу методның исеме үк үзе турында әйтә: бер халәтне үзгәртеп, без бу үзгәрү ниндиүзгәрешләр барлыкка китерүен күзәтәбез.

Мәсәлән, әгәр маятникны озынайтсак, аның хәрәкәте акрыная, тагын озынайтсак, хәрәкәт тагын да кими. Димәк, маятникның билгеле бер озынлыгы аның билгеле бер хәрәкәт тизлегенең сәбәбе була. Формула:

A1 BC... – a1

A2 BC ... – a2

A3 BC ... – a3

A сәбәп a

Иярчен үзгәрешләр методы шулай ук фикерләү практикасында бик еш кулланыла. Әмма бу метод буенча нәтиҗә шулай ук – ихтималлы. Маятник хәрәкәтенең тизлеге озынлыгы- на гына карап билгеләнмәскә мөмкин, чөнки аның озынлыгы белән бергә авырлыгы да үзгәрә.

Калдыклар методы

Калдыклар методы фәнни индуктив методларының иң көчсезе булып санала. Бу метод буенча индуктив фикерләүне схематик күрсәтсәк, түбәндәгечә була:

Әмма кайбер очракларда ул да үзенең кулланышын таба

ABC... – авс
BC... – вс

A сәбәп а

Мәсәлән, бу методны кулланып, Нептун планетасы ачыла. Уран планетасының хәрәкәте бу планетаның төгәл санап чыгарылган орбитасына туры килмәве фактын ачыклаудан башлана. Башка планеталар белән чагыштырып караганда, Уран планетасының орбитасыкүбрәк тайпылган булып чыга. Димәк, калдык сәбәпкә ия булырга тиеш. Леверье Уранга кадәр мөмкин булган планетаның урнашу урынын санап чыгара, ә Галле бу орбитада Нептун планетасын телескоптан таба.

Үзенең исбат итү көче буенча калдыклар методы аеру методына тиң булырга мөмкин.Әмма нәтиҗә бу метод буенча да ихтимал гына була ала. «А» – бердәнбер «а» сәбәбе, сәбәпнең өлеше яки, киресенчә, үзендә сәбәпне тотарга мөмкин.

Фәнни индукциянең мантыйкый хаталары булырга мөмкин. Иң таралганнарының берсе:

Сәбәп һәм вакытның өзлексезлек күренешләрен тиңләштерү хатасы

Мантыйкта бу ялгыш «моннан соң, димәк, моның сәбәбе буенча» («poct hoc, ergo propter hoc») дигән исем ала. Күренешләрнең сәбәп бәйләнеше аларның вакыттагы өзлексезлекләре белән дөрес тиңләштерелмәгән очракта барлыкка килә. Һәртөрле сәбәпле бәйләнешнең вакыттагы бәйләнеш булуы игътибарга алынмый, әмма вакытта-гы һәртөрле бәйләнеш сәбәп бәйләнеше була дигән сүз түгел.

Мәсәлән: әйтик, төн артыннан көн килә, әмма төннең сәбәбе – көн дию дөрес түгел, яки: карлыгачлар очып килделәр дә, яз җитте, димәк, карлыгачларның очып килүе – яз җитүнең сәбәбе дип уйлау, шулай ук, мантыйкый хатага китерә.

Тема 4. Традукцив фикри нәтиҗә

§1. Традукциянең асылы

Традукция ул – бер объектның ниндидер билгеләргә хас булганлыгы, башка ниндидер объектка охшашлыгы нигезендә чыгарылган фикри нәтиҗә.

Традуктив фикри нәтиҗәләрнең нигезендә охшашлык төшенчәсе ята. **Охшашлык ул – карала торган объектлар арасындагы уртак билгеләр булу мөнәсәбәте.** Предметларның охшашлыгы ике фактор белән билгеләнә:

Предметларның уртак билгеләр саны

Предметларда уртак билгеләр күбрәк булган саенһәм аларның әһәмиятлелек дәрәҗәләре арткан саен, бу предметларның охшашлык дәрәҗәсе дә арта бара.

Мәсәлән, «урындык» һәм «язу өстәле» күп уртак билгеләргә ия булып торалар. Алар икесе дә: а) өйҗиһазы предметлары; б) агачтан ясалган; в) дүрт аяклы; г) өсләре тигез горизонталь һ.б.

Билгеләрнең әһәмиятлек дәрәҗәсе

Предметлар үзләренең әһәмиятле билгеләре буенча аерылып торалар.

Мәсәлән, урындык – утыру өчен, өстәл – язу өчен; урындыкның арка сөялгече бар, ә өстәлнең – юк һ.б.

§2. Традукциянең төзелеше

Традукциядәге алшартлар – билгеләре тәңгәл булмаган, ә бары тик охшашлыклары гына булган ике яки төркем предметлар турындагы хөкем.

Традукция структурасыннан түбәндәге элементларны аерып чыгарырга була:

Билгесе башка объектка күчерелгән объект традукциянең **үрнәге** дипатала.

Билге күчерелә торган объект традукциянең субъекты дип атала.

Үрнәк һәм субъект традукциянең терминнары булып торалар.

Үрнәктән субъектка күчерелә торган билге **күчерелмә билге** дип атала.

Традукциянең үрнә- генә һәм субъектына хас булган билгене һәм безне кызыксындырган билгене күчерү нигезен традукциянең **нәтиҗәсе** дип атыйлар

Традукция структурасына түбәндәге хөкемнәр керә:

Үрнәктә традукциянең нигезе булу турында хөкем.

Субъектта традукциянең нигезе булу турында хөкем.

Традукциянең үрнәгендә күчерелмә билгенең булуы турында хөкем.

Традукциянең субъектында күчерелмә билгенең булуы турында хөкем.

Беренче өч хөкем традуктив фикри нәтиҗәнең алшартлары булалар, ә дүртенче хөкем –аның нәтиҗәсе.

§3. Билге буенча традукция төрләре

Күчерелмә билге төренә карап, традуктив фикри нәтиҗәне ике төргә бүләләр:

Үзлек традукциясе ул – күчерелмә билге ролен билге-үзлек үтәгән традукция буенча фикри нәтиҗә.

Мәсәлән, яктылык белән тавышта турыбуенча таралу, кире кайтарылу, сыну үзлекләре охшашлыгын табарга була. Әмма тавыш өстәмә дулкын үзлегенә дә ия. Шуның нәтиҗәсендә яктылык та
дулкын үзлегенә ия, дигән фикри нәтиҗәясалган.

Югарыдагы мисалдан күренгәнчә, үзлек традукциясе структурасына, иң аз дигәндә, ике предмет: a (тавыш) – традукциянең үрнәге һәм b (яктылык) традукциянең субъекты керә. Катлаулы билге P2 ^ P2 ^ ... ^ Pn (безнең очракта n=3)
– традукциянең нигезе һәм күчерелмә билге Q (дулкын) керә.

Үзлек традукциясенең структурасын түбәндәге схема ярдәмендә күрсәтепбула:

a объекты P1, P2, ... Pn, Q билгеләренә ия. b объекты P1, P2, ... Pn билгеләренә ия.

Димәк, b объекты Q билгесенә ия булырга мөмкин.

Монда традукциянең силлогизмнар белән охшаш булуы күзгә ташланыптора.

Мөнәсәбәт традукциясе ул – күчерелмә билге ролен билге-мөнәсәбәт үтәгән традуктив фикри нәтиҗә.

Мәсәлән, Резерфорд, электроннарның атом төше тирәли әйләнү мөнәсәбәтен, планеталар белән Кояш арасындагы мөнәсәбәткә охшатып, атомның планетар моделен төзи. Күргәнегезчә, атом белән Кояш системасы арасында бик зур аерма бар.

Бу фикри нәтиҗәнең структурасын түбәндәгечә күрсәтергә була:

1. Бер яктан, тәртипкә салынган предметлар күплеге бар: планеталар (a) һәмКояш (b), икенче яктан, атом төше (c) һәм электроннар (d) тора.

2. Атом төше (c) Кояшка (b) охшатыла, ә электроннар (d) – планеталарга (a).

3. Кояш (b) белән планеталар (a) арасындагы әйләнү (планеталарның кояш тирәли әйләнү) мөнәсәбәте раслана.

4. Бу раслау нигезендә нәтиҗә ясала: атом төше (c) һәм электроннар (d) арасында да шундый ук мөнәсәбәт бар.

Шулай итеп, мөнәсәбәт традукциясенең схемасын түбәндәгечә күрсәтергә була:

a≈c, в≈d R
(a,b)

Димәк, R(c,d) булуы ихтимал.

§4. Охшашлык дәрәҗәсе буенча традукция төрләре

Традукция төрле формада яки, предметларның охшашлык дәрәҗәсенә карап, төрле булырга мөмкин: төгәл яки төгәл булмаган. Монда төгәл традукция ышанычлы белем бирә, ә төгәл булмаган ихтималлы белем бирә дип санала.

Төгәл традукция

Төгәл традукция күбесенчә фәнни тик- шеренүләрдә, математик исбатлаулар- да кулланыла, шуңа күрә аны еш кына фәнни традукция дип тә атыйлар.

Әгәр p(a)=1 булса, төгәл традукция чын нәтиҗә бирә.

Монда p(a) – a хөкеменең ихтималлык функциясе.

Мәсәлән, өчпочмакларның охшаш булу билгеләре төгәл традукциядә формала- ша: «Әгәр өчпочмакның өч почмагы да икенче өчпочмакның өч почмагы беләнтигез икән, ул вакытта бу өчпочмакларохшаш була».

Төгәл булмаган традукция

Төгәл булмаган традукция күп җирләрдә үзенең кулланылышын таба һәм аны, популяр индуктив фикри нәтиҗәгә охшатып, еш кына популяр традукция дип тә атыйлар.

Әгәр ялган хөкемне 0 аша тамгаласак, әчынны – 1 аша, төгәл булмаган традук- циянең ихтималлык дәрәҗәсе 1 дән 0 кадәр булган интервалда ята:

1>p(a)>0

Төгәл булмаган традукция җәмгыяви-тари- хи тикшеренүләрдә очрый. Шулай ук традукция фәндә модельләштерү методының куллану нигезе буларак та кулланыла.

Ялган традукция

Еш кына ялган традуктив фикри нәтиҗәне дә аерым төр итеп күрсәтәләр, чөнки традуктив фикри нәтиҗәдә чыннары да була.

Ялган традукциянең ихтималлык дәрәҗәсе 0 гә тигез: P(a)=0

Ялгышуларның төп чыганагы булып, фикри нәтиҗә ясаучының, предметларны ча-гыштырганда, аерылып торган билгеләренә игътибар бирмәве тора.

Мәсәлән, ике аюда гомуми билгеләрне күрергә була: аның беренчесе – ата, икенчесе дә ата, беренчесе икенчесеннән агрессиврак, беренчесе физик яктан көчле, икенчесе дә физик яктан көчле. Беренче аюның өстәмә билгесе бар: төсе коба. Моннан «икенче аю да коба», дигән фикри нәтиҗә ясау ялган була, чөнки югарыда күрсәтелгән барлык билгеләр дә төс белән бәйле түгел. Әгәр гомуми билгеләре итеп аларның бер ата-ана- дан булуы, яшәү урыны алынса, «беренче аю коба булганлыктан, икенчесе дә шундый була ала», дигән нәтиҗә ясарга булыр иде. Чөнки ата-аналарының бер булуы яки яшәү урыны төс билгесе белән бәйләнгән.

§5. Традукция һәм модельләштерү

Фәндә модельләштерү (француз сүзе modèle – үрнәк) дигәндә, схема, сызым, мантыйкый-математик тамгалы формула, физик конструкция һ.б. күз алдында тотыла. Модельләштерү методында **модель** үрнәк ролен уйный, ә **оригинал** традукциядә –субъект ролен.

Мәсәлән, модельләштерүне космик объектларда, микрообъектларда, җәмгыятьтә һ.б. киң кулланалар.

Физик модельнең гади формасы булып **макет** тора.

Мәсәлән, төзүчеләр берәр төрле корылмаларны яки плотиналарны төзү алдыннан башта кечерәйтелгән, кыйбат булмаган макет төзиләр һәм анда сынаулар үткәрәләр. Бассейнда булачак корабльнең макетының ныклыгын сыныйлар һәм чын корабль дә шул ук характеристикаларга ия булырга мөмкин, дигән нәтиҗәне чыгаралар.

§6. Традукциянең әһәмияте һәм функциясе

Традукциянең төп функцияләренә түбәндәгеләр керә:

Эвристик функция традукция яңа фактларны ачарга ярдәм итә.

Мәсәлән, спектраль анализ ярдәмендә Кояшта яңа химик элемент барлыгы табыла. Кояш белән Җирнең охшаш билгеләре бар: алар икесе дә бер планетар системага керә, икесе дә билгеле булган химик элементлардан тора (шулай ук спектраль анализ ярдәмендә ачыклана). Бу охшашлык нәтиҗәсендә «Кояшта табылган элемент Җирдә дә булырга тиеш», дигән нәтиҗә ясала. Чыннан да, ул Җирдә табыла һәм гелий дип атала.

Аңлата торган функция традукция күп күренешләрне аңлату өчен хезмәт итә.

Мәсәлән, атом төшенең планетар моделен.

Исбатлый торган функция төгәл булмаган традукцияне исбатлау функциясе көчсез була һәм исбатлау буларак бөтенләйкулланылмый.

Әмма төгәл традукция исбатлау булып торырга яки, аз дигәндә, исбатлауга якын булган аргументация булып чыгыш ясарга мөмкин.

Гносеологик функция традукцияне танып белү ысулы буларак чыгыш ясый.

Бишенче бүлек. Төп формаль-мантыйкый законнар

Тема 1. Фикерләү законнары

§1. Фикерләүнең төп законнары

Мантыйк законнары – мантыйкый формасына карап кына, ягъни хөкемнәрне төзиторган бәйләнешләр нигезендә генә, чын булган хөкемнәр.

Бердәйлек	Каршылыксызлык	Өченчене читләштерү	Тулысынча дәлилләү

§2. Бердәйлек законы

Бердәйлек законы

Төшенчәгә карата бердәйлек законы

Бирелгән фикердә кулланыла торган төшенчә эчтәлеге һәм күләме буенча үзгәрмәскә тиеш.

Хөкемгә карата бердәйлек законы

Кабул ителгән хөкемнең саны һәм сыйфаты барлык фикерләү дәверендә үзгәрмәскә тиеш.

Кабул ителгән хөкемнең мантыйкый бәйләвечләре барлык фикерләү дәверендә үзгәрмәскә тиеш.

Бердәйлек законының формуласы болай языла:А → А яки А ≡ А

А	А → А	А ≡ А
Ч	Ч	Ч
Я	Ч	Ч

Бердәйлек законындагы хаталар.
Төрле уйларны бер итеп һәм бер уйны төрле итеп кабул итәргә ярамый.

Бердәйлек законы бозылу түбәндәге хаталарга китерә ала:

Амфиболия – мантыйкый хатаның нигезендә сөйләмдә ике төрле мәгънәле (омоним) сүзләрне бер үк вакытта куллану.

Мәсәлән: «Тел Киевка хәтле алып бара, дип дөрес әйтәләр. Мин кичә кибеттән озын тел сатып алдым. Ул хәзер мине Киевка алып барачак».

Эквивокация – бер фикердә бер сүзне төрле мәгънәдә кулланылган мантыйкый хата. Чынлыкта сөйләм телендә сүзләр күп мәгънәгә ия булырга мөмкиннәр, шунлыктан, фикер йөртүендә һәм фикерне аңлаганда, һәрвакытта да эквивокация куркынычы яный.

Мәсәлән: «Диңгез бүресе – чынлыкта да бүре. Бөтен бүреләр дә урманда яши. Шулай итеп, диңгез бүресе урманда яши». Мондагы хата болай аңлатыла: беренче җөмләдә «бүре» сүзе метафора буларак килгән, икенчесендә – туры мәгънәдә. Эквивокация еш кына риторик, әдәби ысул буларак кулланыла.

Тезисларны алыштыру – шулай үк мантыйкый хата, моның нәтиҗәсе булып куелган тезисны исбатлау яки кире кагу урынына яңа тезис китереп чыгару тора.

Мәсәлән, «Кар ак» тезисы урынына «Кар 0 градуста эри», дигән тезис исбатлана.

§3. Каршылыксызлык законы

Каршылыксызлык законы мөстәкыйль характерга ия. Әгәр бердәйлек законы дөрес фикерләүнең төп үзенчәлеген – тотрыклылыгын чагылдырса, каршылыксызлык законы аның каршылыксызлыгын чагылдыра.

Әмма барлык охшаш фикерләр дә мантыйкый каршылыклы була алмыйлар. Түбәндәге очракларда, мәсәлән, нәрсәне дә булса бер үк предметка карата раслаганда яки инкарь иткәндә, каршылыклар булмаска мөмкин:

Ике каршылыклы фикер, әмма **төрле предметлар** турында сүз бара. Мондый ике фикер бер үк вакытта да чын булырга мөмкин.

Мәсәлән, «төн кыска», «көн озын».

Әгәр бер үк предмет **төрле вакытта** каралса, ул каршылыктудырмый.

Мәсәлән: «Октябрьдә көн кыска» – «Июньдә көн озын». Монда тагын шундый мисалны китерергә була: «Галимов – КДУ студенты», дигән хөкем билгелебер вакыт арасында гына дөрес була, бу – Галимов КДУда укыган вакыты; әгәр Галимов КДУны тәмамлаган булса, бу хөкем ялган булыр иде. Бу вакытка карата «Галимов КДУ студенты түгел», дигән хөкем дөрес булачак.

Каршылыклы ике хөкемдә бер үк предмет турында сүз барса, һәм хөкемнәр бер үк вакыт аралыгына караса, каршылыклык булмый: әгәр предмет безнең уйда **төрле мөнәсәбәттә яки карашта** каралган булса.

Мәсәлән, «Октябрь көне июнь көненә караганда кыскарак» – «Октябрь көне гыйнвар көненә караганда озынрак». Тагын бер мисал: «Әгәр студент Галимовның белемнәре югары уку йорты таләпләрен канәгатьләндерсә, ул инглиз телен яхшы белә» дип әйтә алабыз.

Әгәр A һәм B хөкемнәре каршылыклы мөнәсәбәттә торсалар, A һәм B хөкемнәрекаршылыклы дип аталалар.

Мантыйкый квадрат A ∧ O һәм E ∧ I хөкемнәрен каршылыклы икәнен күрсәтә.

Мәсәлән, «Барлык бөек кешеләр тәбәнәк буйлы (A), һәм кайбер бөек кешеләр тәбәнәк буйлы түгел (O)» һәм «Барлык каршылыклы хөкемнәр ялган (E), һәм кайбер каршылыклыхөкемнәр ялган түгел (I)».

Моннан каршылык формуласы чыга:A ∧ ¬A

Мәсәлән, (p ∧ q) ∧ ¬(p ∧ q), (p ∨ q) ∧ ¬(p ∨ q), (p → q) ∧ ¬(p→q) хөкемнәре каршылыклы булалар.

Әгәр бу формуланың чынлык таблицасын төзесәк, түбәндәгечә була:

A	A	A ∧
Ч		¬AЯ
Я		Я

Әгәр безнең фикерләүдә каршылыклар булырга тиеш түгел икән, монда **каршылыкларны тыя торган закон яки каршылыксызлык законы** булырга тиеш:

Ниндидер хөкем һәм аның инкарь ителгәне бер үк вакытта чын була алмыйлар.

Каршылыксызлык законының формуласы мондый:

¬(A ∧ ¬A)

Әгәр каршылыксызлык законының чынлык таблицасын төзесәк, ул мондый булыр:

A	¬A	A ∧ ¬A	¬(A ∧ ¬A)
Ч	Я	Я	Ч
Я	Ч	Я	Ч

§4. Өченчене читләштерү законы

Бу закон раславынча, ике каршылыклы хөкем бер үк вакытта ялган була алмыйлар: берсе аның ялган булырга, икенчесе чын булырга тиеш, ә өченчене хөкем булырга тиеш түгел, ягъни чын А яки А– түгел. Монда бер вакыттагы ике раслаубәйләнеше мантыйкый бәйләвеч «яки» – дизъюнкация ярдәмендә языла.

Өченче читләштерү законының формуласын болай язарга була:

$$A \vee \neg A$$

Бу хөкемнәрнең таблицадагы чагылышы түбәндәгечә:

А	¬А	А ∨ ¬А
Ч	Я	Ч
Я	Ч	Ч

Шулай итеп, күргәнебезчә, өченчене читләштерү законы да мантыйкый закон булып тора. Бу законны аңлау өчен, бер-берсенә сыеша алмаган ике пар фикерне китерик:

1. *«Байкал тирән» – «Байкал сай»;*

2. *«Байкал тирән» – «Байкал тирән түгел».*

Игътибар итик: беренче парда предикатлар булып капма-каршы төшенчәләр хезмәт итә («тирән» – «сай»), ә икенчесендә – каршылыклы төшенчәләр («тирән» – «тирән түгел»).

§5. Тулысынча дәлилләү законы

Тулысынча дәлилләү законының алшартлары һәм мәгънәсе.

Лейбницта чынбарлыкның һәм танып белүнең универсаль законы – сәбәплек законы итеп бирелә. Әгәр бу законны фикерләүгә яраштырып әйтсәк, ул түбәндәгечә формалаша: **бернинди фикернең тулы дәлиле булмаса, ул дөрес дип танылмый**. Бу законның исеме дә шуннан килеп чыккан.

Шулай итеп, фикерләрнең нигезләнүе, дәлилләү таләпләре дәлилләү законында чагыл- дырыла: әгәр тулысынча дәлилгә нигезләнсә, һәрбер фикер дөрес дип санала. Әгәр В булса, димәк, аның дәлиле А бар, яки А → В. Әгәр дә шартлы хөкем чын булса, В чынлы-гының җитәрлек дәлиле А була, ә В өчен А ның чынлыгы зарури шарт булып тора.

Алтынчы бүлек. Фәнни фикерләү формалары

Тема 1. Исбатлау

§1. Гомуми характеристика

Чыгарылган белемнәр фикри нәтиҗә белән генә чикләнеп калмый. Бу фикерләү процессын башка төп форма белән – **исбатлау** аша башкарырга мөмкин. **Исбатлау ул – бер хөкемнең (белемнең) чын булуы нигезендә икенче хөкемнең (белемнең)чын яки ялган булуын ачыклый торган фикерләү формасы.**

Иң башта һәркем сизү органнары ярдәмендә кабул иткән **фактлар** чынлыгын карап китик.

Мәсәлән, «агачларда яфраклар яшел» икәнен мин күрәм, «вертолет очканын» ишетәм, «өйдәҗылы» икәнен сизәм һ.б.

Моннан соң, **аксиомалар** (грек сүзе axios – кыйммәтле, ышанычны аклый торган) тора, аларның дөрес булуына кешелек практикасы безне ышандыра.

Мәсәлән: «Өлеш бөтеннән кимрәк».

Һәм соңыннан **постулатлар** (латин сүзе postulatum – таләп ителә торган, алшартлар) – ышанычны яулаган тәгълиматлар.

Мәсәлән: «Теләсә нинди нокта-дан циркульнең ачылу киңлеге белән түгәрәк ясап була»

§2. Исбатлауның төзелеше

Исбатлауның структурасына **тезис, аргумент (дәлилләр яки нигезләнүләр) һәм демонстрация (исбатлау формасы) керә.**

Исбатлауның тезисы

Исбатлауның тезисы ул – чынлыгы яки ялганлыгы исбатлана торган хөкем. Ул исбат-лауның төп элементы булып тора һәм «нәрсә исбатлана?» дигән сорауга җавап бирә.

Геометриядә, берсе икенчесеннән чыга торган һәм азмы-күпме төгәл төзелгән фәнни система булдыра торган теоремаларны (грек сүзе theoreo – төрле яктан уйлап карыйм) атарга була.

Тикшерү үткәргәндә, аеруча зур әһәмиятне алиби (латин сүзе alibi – башка урында) исбатлауга бирәләр, ягъни җинаять башкарылган вакытта шикләнгән кешене башка урында табу.

Тезисның бер төре булып фа- раз, гипотеза (гарәп сүзе фараз, грек сүзе hypothesis – чама- лау) тора. Бу чын да, ялган да хөкем түгел, ә азмы күпме мөмкин булган фаразлар, алар исбатлау предметы булырга мөмкин.

Юридик практикада фаразның бер төре булып версия тора (латин сүзе versio – үзгәрү, борылыш). Ул – судның яки тикшерүченең вакыйганың, фактларның һ.б. булу яки булмавы турындагы фаразы.

Мантыйк бүлеге

Исбатлауның аргументы

Аргументлар – тезисның чынлыгын яки ялганлыгын исбат итә торган хөкемнәр, дәлилләр. Исбатлауда кулланыла торган аргументларга: факт, билгеләмә, аксиома һәм постулатлар, элек исбатланган тәгълиматлар керә.

Факт – чынбарлыкта булган бердәнбер күренеш яки хәл. Факт, теләсә нинди яхшы сүзләргә караганда да, зур ышандыру көченә ия. Фәндә фактлар – күзәтүләр һәм эксперимент нәтиҗәсе.

Күбесенчә суд практикасында фактларга зур әһәмият бирелә. Мондагы фактларга: шаһитләрнең гаепләнүченең үз-үзенең тотышын күзәтү, җинаять эшләнгән урында эзләр калу, тентүдә алынган әйберләр, язылган документлар, фотосурәтләр һ.б. керә.

Исбатлау процессында, фактлардан башка, тагын бер универсаль чара булып билгеләмәләр тора.

Мәсәлән, геометриядә башлангыч төшенчәләрнең билгеләмәләре – нокта, сызык, ясылык һ.б. – алдагы теоремаларны исбатлауда фундаменталь әһәмияткә ия.
Башка фәннәрдә дә билгеләмәләр шундый ук рольне үтиләр.

Барлык фәннәрдә фактлар һәм билгеләмәләр нигез булып кулланылсалар, кайбер фәннәрдә бу рольне аксиомалар һәм постулатлар уйный.

Бу фәннәргә математика, механика, теоретик физика керә.

Исбатлауда зур урынны элек исбатланган тәгълиматлар ала. Алар күп төрле булырга мөмкин. Шулар арасында бигрәк тә фәнни законнар аерым урынны тота.

Мәсәлән, мәңгелек двигательнең мөмкин булмавын энергиянең әверелү һәм саклану законы дәлилли. Органик дөнья эволюциясен исбат итә торган төп дәлил булып организмның һәм тирә – як мохитнең берлек законы тора.

Демонстрация (исбатлау формасы)

Исбатлау барлыкка килсен өчен, дәлилләрнең һәм бу дәлилләрдән чыккан нәтиҗәләрнең эзлекле мантыйкый бәйләнеше булу кирәк. **Демонстрация – тезис белән аргументның мантыйкый нәтиҗәсе.**

Әгәр аргументлар (a1, a2 ... an) исбатлауның нигезе булып торсалар һәм тезис (Т) мантыйкый нәтиҗә булса, исбатлауның структурасын түбәндәгечә сурәтләргә була:

a1 a2 a3 .....

T

Бу схеманы формула ярдәмендә дә күрсәтергә була:a1, a2, a3,... → T, a1, a2, a3,... T

Монда → тамгасы тезис белән аргументның үзара бәйләнешен күрсәтә, ә сызык исбатланган аргументлардан тезиска күчүне аңлата. Демонстрация дедуктив, индуктив һәм традуктив фикри нәтиҗә формасын алырга, алар аерым яки бергә кушылып кулланылырга мөмкин.

§3. Исбатлау ысуллары

Ике төрдәге исбатлау ысулын аерырга була:

Тезисны **исбат итү** яки раслау – тезисның чынлыгын дәлилләү.

Тезисны **кире кагу** яки инкарь итү – тезисның ялганлыгын дәлилләү.

Дәлилләү ысулларына карап, турыдан-туры һәм чыгарылганисбатлауларны аерырга була.

Турыдан-туры исбатлау ул – аргументлардан, тезисның чынлыгын чыгарганда,өстәмә фаразлардан башка исбатлау.

Чыгарылган исбатлау ул – тезисның нигезен, бу тезиска карата тиңдәшсез, өстәмә хөкемнәр ярдәмендә исбатлау.

Апогогик исбатлау (грек сүзе apagogos – читкә алып китүче) – киресеннән чыгып исбатлау, башта бирелгән тезиска каршылыклы тезисның ялган булуын исбатларга тырышу; ул абсурд хәленә, бирелгән хакыйкатьнең каршылыгына хәтле җиткерелә.

Апогогик исбатлау түбәндәге юл белән бара:

Без вакытлыча тезиска каршылыклы хөкемне чын дип уйлыйбыз.

Мәсәлән, безгә «N җинаять эшләмәгән», дигән тезисны (Т) исбат итәргә кирәк. Без вакытлыча «N җинаять эшләгән», дигән антитезисны (¬Т) чын дип фаразлыйбыз. (антитезис – тезиска каршылыклы хөкем).

Антитезисның нәтиҗәләрен чыгарабыз.

Безнең антитезистан түбәндәге тикшерү нәтиҗәләре чыгарга тиеш:
«N бу вакытта җинаять эшләгән урында булырга тиеш» һ.б. (С1, …).



Нәтиҗәләр фактлар белән куелып карала һәм кайберәүләре инкарь ителә.

Безнең очракта берәр шаһит «N ның җинаять эшләгән урында булмаганын» яки башка фактларның булмаганын раслый, ягъни нәтиҗәләр ялган була: ¬С1 ¬С2 ¬С3.

Моннан фикри нәтиҗә төзелә (шартлы-категорик фикри нәтиҗә инкарь итә торган модус формасында):

$$\frac{\neg T \rightarrow C1, C2, C3,; \neg C1\ \neg C2\ \neg C3}{\neg\neg T}$$

Закон буенча икеләтә инкарь итү нәтиҗәсе уңай нәтиҗә бирә, ягъни безнең тезисның чынлыгын раслап була. Схема рәвешендә:

$$\frac{\neg\neg T}{T}$$

Мантыйк бүлеге

Чыгарылган аера торган исбатлау

Аера торган исбатлауның үзенчәлеге булып, мөмкин булган берничә тезистан (алыпташлау методы белән) берсе генә исбатлану тора.

Мәсәлән, бирелгән җинаятьне яки А, яки В, яки С эшләгән (һәм башка беркем дә түгел).

Исбат итү (раслау)

Исбат итү сүзенең мәгънәсен раслау дип аңлау дөресрәк булыр, чөнки монда дәлил-ләр аша тезисның чынлыгы раслана. Фәндә һәм көндәлек тормышта бик күп төрле исбатлаулар нәкъ шушы характерда тора.

Мәсәлән, әгәр астрономия дәреслеген карасак, без анда Җирнең Кояш тирәли әйләнүе турындагы раслауны табарбыз. Бу тезисны раслый торган төп дәлилләр: йолдызлар- ның параллакслары булуы һәм йолдызларның еллык аберацион күчүе тора.

Исбат итү (раслау)

Исбат итү сүзенең мәгънәсен раслау дип аңлау дөресрәк булыр, чөнки монда дәлил-ләр аша тезисның чынлыгы раслана. Фәндә һәм көндәлек тормышта бик күп төрле исбатлаулар нәкъ шушы характерда тора.

Мәсәлән, әгәр астрономия дәреслеген карасак, без анда Җирнең Кояш тирәли әйләнүе турындагы раслауны табарбыз. Бу тезисны раслый торган төп дәлилләр: йолдызлар- ның параллакслары булуы һәм йолдызларның еллык аберацион күчүе тора.

Кире кагу

Кире кагу – тезисның ялганлыгын исбат итү яки элек чыгарылган тезисның ялганлыгын йә дәлилсезлеген исбат итәргә юнәлтелгән мантыйкый операция.

Мәсәлән, Н. Коперник, Птоломейның геоцентрик системасын кире кагу өчен, тулы исбатлаулар системасын төзи. Физикада мәңгелек двигательнең булуын кире кагуисбатлаулары бар.

Кире кагу формалары төрлечә булырга мөмкин. Моңа түбәндәгеләр керә:

Тезисны кире кагу *– тезисның ялганлыгын ачык-лый торган фикер.*

Аргументны кире кагу – тезисның дәлилсезлеген аргументларның ялганлыгын исбатлау юлыбелән ачыклый торган фикер.

Демонстрацияне кире кагу – аргументлардан тезисны чыгаргандагы хаталарны ачыклый торган фикер.

§4. Исбатлау кагыйдәләре һәм исбатлаудагы хаталар

Исбатлауның үзенә генә хас булган хаталар да бар. Алар турыдын-туры исбатлау кагыйдәләрен бозу белән бәйләнгән. Шуның өчен исбатлауның барлык компонентларына да – тезис, аргументка, демонстрациягә кагыла.

Тезиска карата кагыйдәләр

Тезис мантыйкый билгеле, ачык һәм төгәл тәгъбир ителергә тиеш.

Мәсәлән, «Законнарны хөрмәт итәргә кирәк» дигән тезис ачык түгел, монда нинди законар турында сүз булырга мөмкин: табигать законнары турындамы, җәмгыять яки юридик законнар турындамы?

Тезис исбатлауның башыннан ахырына кадәр үзгәрмәскә тиеш.

Тезис яңа фактлар яки каршы аргументлар тәэсирендә генә үзгәрергә яки аңа төгәллек кертелергә мөмкин, әмма үзгәрүләр барысына да җиткерелергә тиеш.

Тезиска карата хаталар

Иң еш очрый торган хаталарның берсе – **тезис алмаштыру**, ул бердәйлек законы бозылу белән бәйле.

Мәсәлән, А.П. Чеховның «Өч сеңел» («Три сестры») пьесасында Соленый доктор белән бәхәсләшә, ул чехартманы сарык ите дип сөйли, доктор аңа каршы черемшаны суган дип раслый. Һәм ике бәхәсче дә бер уртак фикергә килә алмыйлар.

Әгәр тезисны алмаштыру тирән булып һәрчак башка өлкәгә кереп китсә, бу очракта хата **«икенче төркемгә күчү»** дип атала.

Мәсәлән, юридик өлкәдәге исбатлаулар әхлак ягына күчә һәм законсызлык, хокуксызлык урынына әхлаксызлыкны дәлилли башлый.

Шулай ук кискен һәм еш очрый торган тезис алмаштыруга **«дошман эзләү»** не кертергә була.

Мәсәлән, берәр эштә үз өстеннән җаваплылыкны төшерү максаты белән, кайбер җәмгыять эшлеклеләре гаепне башкага, аеруча элегрәк эшләгән кешеләргә тагалар: большевиклар – патшага, демократлар барысы өчен дә большевикларны гаеплиләр.

Мантыйк бүлеге

Аргументка карата кагыйдәләр

Аргументлар хак һәм исбатланган хөкемнәр булырга тиеш

Мәсәлән, «Эшләргә кирәк» дигәнне исбатлап, аргументын «Алла шулай кушкан дисәм», бу аргумент Аллага ышанучыларны гына канәгатьләндерә. Ә атеист өчен бу берни дә тормый.

Тезисларның чынлыгын күрсәтү өчен аргументлар җитәрлек булырга тиеш

Мәсәлән, «N әйберләрне урлаган» тезисын исбатлау өчен түбәндәге аргументлар (фактик дәлилләр) кулланыла: «N урлау турында сөйләгән иде», «N да урланган әйберләр табылган»,

«N ның әйбер югалган җирдә аяк эзләре табылган», «N ны әйбер югалган җирдә күргәннәр».

Аргументларның хаклыгы тезислардан бәйсез дәлилләнергә тиеш

Мәсәлән, «Кеше авырый» тезисы «Аның температурасы югары» аргументы белән исбат ителә, ә «Нигә аның температурасы югары?» дигән сорауга «Чөнки ул авырый» дип җавап бирәләр.

Аргументлар бер-берсенә каршылыклы булырга тиештүгелләр

Бер үк вакытта берәр нәрсәне раслау һәм инкарь итү аларның бер-берсен юкка чыгаруны аңлата, һәм шулай итеп алар, дәлилләү нигезе буларак, функцияләрен югалталар.

Аргументка карата хаталар

Беренче хата

кулланучы аргументларның ялганлыгы

– беренче кагыйдәнең бозылуыбелән бәйле.

Мәсәлән, «Барлык студентлар яхшылыкка омтыла» тезисын исбатлаганда, дәлиле итеп «Барлык кешеләр яхшыга омтыла»ны алсак, «дәлилләрне алдан тану» хатасы килеп чыга, чөнки дәлилләүче хөкем үзе дә дәлилләнүгә мохтаж.

Икенче кагыйдәне бозу аркасында – **иртәрәк исбатлау** яки **артыграк исбатлау** хаталары килеп чыгарга мөмкин.

Яки исбатлауда кайбер дәлилләрнең саны исәптә булмаска яки ялган булырга мөмкин. Яки, киресенчә, артык ялган дәлилләр булырга мөмкин.

Өченче хата – **исбатлаудагы өзлексезлек**.

Бу хатага мисал итеп, еш әйтелә торган әйтемне яза-быз: «Бу булырга мөмкин түгел, чөнки бу беркайчан да булмаячак».

Дүртенче хата – **аргументлардагы каршылык**.

Мәсәлән, суд практикасында шаһитләрнең бер үк вакыйга турында төрле мәгълүматлар бирүе.

Авторитетка карата аргумент – аргумент итеп бөек яки танылган кешеләрнең, ниндидер өлкәдәге белгечләрнең хөкемнәрен куллану.

Халыкка (публикага) карата аргумент – берәр нәрсәне исбатлау процессында халыкны үз ягыңа аудару өчен, аларның хисләренә тәэсир итәргә тырышу.

Шәхескә карата аргумент – кемнең дә булса тезисын кире кагу өчен, аның шәхси сыйфатларын куллану.

Көчкә карата аргумент – берәр тезисны ышандыру өчен көч куллану очрагы.

Демонстрациягә карата кагыйдәләр

Демонстрациядә кулланылган фикри нәтиҗәләр дөрес һәм аларны куллану шартлары үтәлгән булырга тиеш.

Демонстрациягә карата хаталар

Төп хаталарның берсе – **бәйләнмәгәнлек**. Бу хата аргумент белән тезис арасында кирәкле мантыйкый бәйләнеш булмавын һәм барлык фикри нәтиҗәләргә хас булган өзлексезлек кагыйдәсе үтәлмәгәнлектән килеп чыга.

Мәсәлән, укучының Пифогор теоремасын дөрес исбат итә алмавы, бу теорема дөрес түгел дигән сүз түгел.

Мантыйк бүлеге

Тема 2. Фараз

§1. Гомуми характеристика

Фараз, гипотеза *(гарәп сүзе фараз, грек сүзе hypothesia – чамалау, гөманлау, фаразлау, юрау)* – белемдәге җитешмәгән якларны тулыландыру өчен чамалап карау; фәнни төшенчәләргә, эмпирик белемгә, фактны яки фактларны алдан аңлауга нигезләнә, фактларга нигезләнгән тәҗрибә белән исбатлана.

«Фараз» төшенчәсе ике мәгънәдә кулланылырга мөмкин:

Хәзерге вакытта ниндидер сәбәпләр аркасында аерым тикшеренүләрсез табып булмаган фактларга төшенү, сизү, гөман итү.

Фәнни тикшеренүләрдә кулланыла торган махсус төрдәге гипотеза.

Фаразның төрләре: фаразның гомумилек дәрәҗәсенә карап гомумигә, хосусыйга һәм ялгызга аерырга була

Гомуми фараз дип, табигый һәм икътисади күренеш турындагы закончалыкларны фәнни нигезләнгән хөкем атала.

Мәсәлән, М.В. Ломоносовның җисемнең атом төзелешендә булу фаразы соңыннан фәнни теориягәверелә.

Хосусый фараз – табигатьтә, икътисади тормышта карала торган объектлардан аерым бүленеп алынган бер класс объектларының яки объект кисәкләренең килеп чыгуы һәм аларның үзенчәлекләре хакында фәнни нигезләнгән хөкем.

Мәсәлән, вирусология өлкәсендәге фараз хосусый була, чөнки андагы закончалыкларны аңлату өчен аерым, берничә организмнар гына – вируслар гына, аларның да әле аерым төрләре генә карала.

Ялгыз фараз – бер генә була торган фактлар, билгеле вакыйгалар һәм күренешләр турында фәнни нигезләнгән хөкем.

Мәсәлән, археологлар, казу эшләре алып барганда, табылган берәр әйбер турында аның кайда кулланылганы яки кайсы тарихи чор булуы турында фараз коралар.

§2. Фаразны төзү

Фаразны төзү процессы түбәндәге этапларны уза:

1. Хәзерге вакытка кадәр яшәп килгән тәгълиматларга яки фаразларга сыеша алмаган һәм яңа фараз белән аңлатырга тиешле фактлар төркемен, алар арасындагы бәйләнешләрне аеру. Бу этапның максаты – фактларны һәм алар арасында булган аерым, үзенә генә хас үзенчәлекләрне табу.

2. Фактларны тудырган билгесез сәбәпләр турында фараз кору максаты белән гомумиләштерү, фактларны бер системага синтезлау. Бу этапта фараз турыдан-туры формалаштырыла, ягъни фактларны аңлата торган фаразлар корыла.

3. Төп фаразны анализлау һәм бу фараздан килеп чыккан нәтиҗәләрне эшкәртү.

4. Фараздан килеп чыккан нәтиҗәләрне фәнни законнар, күзәтүләр, тәҗрибә ярдәмендә табылган мәгълүматлар белән чагыштыру, тиңләү.

5. Әгәр гипотезадан чыккан барлык нәтиҗәләр дә расланса һәм алар элек билгеле законнарга каршы булмаса, фаразның ышанычлы, чын фәнгә яки тәгълиматка әверелүе тәэмин ителә.

Әгәр дә инде нәтиҗәләр фактлар белән килешсәләр (верификация), фараз тагын даышанычлырак була, андагы фараз ышанычлы белемгә әверелә. Нәтиҗәләр белән фактлар туры килмәгән очракта (фальсификация) фараз йә үзгәртелә, йә кире кагыла.

Верификация процессында зур роль экспериментка бирелә. Эксперимент күбесенчә бер генә фактны түгел, ә күпфактларны истә тота.

Мәсәлән, медицинада авыруның нәтиҗәләренә нинди дарулар оптималь тәэсир итүен тикшерү өчен экспериментбарышы планлаштырыла.

Фараз верификацияләү түбәндәге формула буенча бара:

H → (C1 ∧ C2 ∧ C3 … ∧ Cn),

Монда H – фараз, C1, C2, C3 … Cn – фараздан чыккан нәтиҗә; «∧» нәтиҗәләр җыелмасына фараздан имплекация.
Мәсәлән, H – фараз ителгән авыру (врач куйган диагноз), ә C1, C2, C3 – бу чиргә генә хас булган симптомнар. Әгәр диагноз дөрес куелган булса, фараз расланган була.

Аның структурасы:

А күренеше В белән, яки С белән, яки Дбелән кузгатылырга мөмкин.

А күренеше В белән дә, С белән дә кузгатылмаган.

А күренеше Д белән кузгатылган.

Фаразларны кире кагу бирелгән фараздан чыккан нәтиҗәләргә таянып, каршылыклыфактларны табу юлы белән башкарыла.
Фараздан чыккан нәтиҗәләр, реаль хәлләр белән каршылыклы булган очракта гына фараз кире кагыла.

Фаразны кире кагу структурасы:

Әгәр сәбәп булып фараз H торса, аның C1, C2, C3 дигән нәтиҗәләре дә булырга тиеш.

Әгәр нәтиҗә C1, яки C2, яки C3 яки Cn ялган хөкем булса, фараз H ялган булачак.

ФƏЛСƏФƏ

Авторлардан

Заманча дөнья – катлаулы үсештәге тулы система. Аны берьяклы һәм дөрес аңлау билгеле бер фәлсәфи күзаллауларсыз мөмкин эш түгел. Бу күзаллаулар бөтен закончалыклары һәм каршылыклары белән бүгенге чынбарлыкның үсешен тирәнрәк төшенергә, кешенең заманадагы урынын, тормышның мәгънәсен, башка проблемаларны аңаларга ярдәм итә.

Фәлсәфи культура – кешенең гомуми культурасының бер өлеше, аны формалаштыру бүгенге көннең көнүзәк иҗтыяҗы булып тора. Барган үзгәрешләр шартларында фикерләүдәге һәм практик эшчәнлектәге искергән сте-реотипларны, катып калган догмаларны кире кагу мөһим. Ә моның өчен тәнкыйди конструктив фикерләргә, иҗади һәм гыйбрәтле эшчәнлек алып барырга кирәк. Башкача моны диалекталь фикерләү дип тә атап булыр иде. Бу сәнгатьне үзләштерү өчен, дөнья фәлсәфәсе байлыгын һәрьяклы өйрәнү зарур.

Бу кулланма, һичшиксез, сезгә ярдәмгә килә. Аны әзерләү барышында без бирелгән предмет буенча төп төшенчәләргә аңлатма бирүне, бу фәнне ничек җентекләп өйрәнү юнәлешләрен аныклап бирүне максат итеп куйдык.

Кереш сүз

Теләсә нинди уку-белешмә басма берничә бурычны чишә: үзләштерү дәрәҗәсендәге белемнәр белән таны-штыра, булган проблемаларны ачыклый, ирешә алырлык офыкларны ача. Уку дисциплинасы буларак фәлсәфәнең үз үзенчәлекләре бар. Аны формулалар тупламасы, билгеләмә, кагыйдә итеп «ятлап» булмый. Фәлсәфә – фикернең тере хәрәкәте, монда гади катлаулы, көндәлек тормыш кеше күңеле тирәнлеге белән чиктәш.

XX гасыр Аурупа мәдәниятендәге фәлсәфәче образы чиктән тыш каршылыклы. Кайвакыт фәлсәфәче галим-академик кыяфәтендә, ә фәлсәфә үзе – «кырыс фән». Фәлсәфәче мораль укучы, социаль лидер маскасын да кия ала. Ул иронияле, фәлсәфәдә метафоралар яудыра, киләчәккә күрәзәлек кыла, сәяси көрәш юлына баса. Безнең фәнни әдәбиятыбызда уртак нигез булып калган бердәнбер фәлсәфә фәненең менә шушы күпкырлылыгын ни-чек сыйдырып бетерергә соң? Авторлар «арифметик урталык»ны табарга тырышмыйлар, ә төрле чорларда яшәгән фикер ияләренә, төрле фәлсәфә традицияләре тарафдарларына үз телләрендә сөйләргә мөмкинлек бирәләр.

Авторлар тарафыннан язылган фәлсәфә яшәргә, газапланырга, үләргә сәләтле тереклек иясе проблемалары турында уйлаучының яшәү аңы булып тора. Традицион рәвештә өйрәнелә торган «Яшәеш», «Субстанция», «Диалектика» кебек чиста философик абстракция бүлекләре кешелеклелек мәгънәсе белән тулыландырыла. Кеше үзенең түбән һәм югары чагылышында фәлсәфәнең үзәге, фәлсәфәчел категорияләр куелыгы буларак тасвирлана.

Кеше турында фәлсәфи уйлануларның диапазоны чиктән тыш иркен. Авторлар фикеренчә, аңа кабилә аңы белән яшәүче борынгы кеше дә, гел кулланыга нигезләнгән бүгенге җәмгыятьнең «икътисади кешесе» дә тәэсир ясый. Авторлар тарафыннан табылган шушы бер уртаклыгы булмаган кешеләрнең җәмгыятькә карата ох-шаш мөнәсәбәте укучыларның игътибарын җәлеп итми калмас. Фәлсәфә фәне кеше өчен бернәрсәне дә чиш-ми. Ул бары сайлап алу өчен җирлек тудыра, танып белү өчен «интелектуаль инструментлар» гына бирә. Фәлсәфи фикерләүнең

төп предметлары булган язмыш, бәхет, үлем, яшәү мәгънәләрендә бер үк вакытта кеше-лекнең куркуы, өмете, хыяллары да туплана.

Антик фәлсәфи традиция, рус фәлсәфи фикерләре һәм заманча Европа фәлсәфәсе үзенең төгәл контурларын саклыйлар, ләкин шул ук вакытта чагыштыру, төрле интерпретация, бәяләү объекты да булып торалар.

Фәлсәфә теләсә кайсы махсус белемне тулыландыра һәм төгәлли, белгечкә интеллигентка әверелергә ярдәм итә. Нәрсә соң ул – интеллигент булу? Бу сорау галимнәрне генә борчымый. Аның чишелешеннән безнең мәдәниятебезнең язмышы билгеләнә.

Кулланманың йомгаклау өлешендә интеллигенция проблемасына мөрәҗәгать итеп, авторлар «фәлсәфәгә бирелергә яки яшәргә» альтернативасының ялган булуын күрсәтәләр. Интеллигент кеше фәлсәфәгә мөрәҗәгать итмичә яши, фикерли, эшчәнлек алып бара алмый.

Бу белешмә-кулланма – мәктәп фәлсәфәсенә хас гадиләштерүдән, бөтен әйберне белү дигән ялганнан качу-ның уңышлы талпынышы.

Авторларның иң югары, катлаулы бурычы – укучыларны фәлсәфәнең заманча проблемалары белән таны-штыру, кешелек фикере үсешен бөтен тулылыгы һәм каршылыгы белән күрсәтү.

Үзебезнең уй-фикерләребезне чынга ашырганда чишәргә теләгән төп авырлык катлаулы һәм күләмле мате-риалны кыска, заманча югары фәнни дәрәҗәдә, гади, аңлаешлы телдә бирүдә булды. Без моңа ирешкәнбез дип ышанасы килә.

Беренче бүлек. Фәлсәфәгә кереш

§1. Дөньяга караш

1. Дөньяга караш турында гомуми төшенчә һәм аның төрләре

Дөньяга тулы караш һәм анда кеше урыны.
Кешелек дөньсында билгеләнгән төп өчдөньяга караш формасы

Мифология	Дин	Фәлсәфә

2. Дөньяга караш буларак фәлсәфә

Мифология – әйләнә-тирә чынбарлыкны фантастик һәм шул ук вакытта реалистик кабул итүне үзендә берләштергән иҗтимагый аң формасы.

Мифлар җавап бирергә тырышкантөп мәсьәләләр:

— Галәм, Җир шары һәм кеше барлыкка килүе;

— табигать күренешләрен аңлату;

— кешенең яшәеше, язмышы һәм үлеме; кешенең эшчәнлеге һәм казанышлары;

— намус, бурыч, этика һәм әхлак мәсьәләләре.

Миф сыйфатлары:

— табигатьне сынландыру;

— фантастик аллалар барлыгы, аларның кеше белән аралашуы, үзара бәйләнеше

— абстракт фикерләр юклыгы (рефлексия)

— мифларның конкрет тормыш мәсьәләләрен (хуҗалык, табигать көчләре, һ.б.) хәл итүгә юнәлдерелүе;

— Бертөрлелек һәм мифологик сюжетларның сайлыгы.

3. Дини караш

Дин – кеше гомеренә һәм әйләнә-тирә мохиткә йогынты ясаучы фантастик, гадәттән тыш көчләр булуына ышануга нигезләнгән дөньяга караш формасы. Дини дөньяга караш булганда әйләнә-тирә чынбарлыкны кешегә хисси, образ-тойгылы (рациональ түгел) кабул итү хас. Диндә миф тикшергән мәсьәләләрне тикшерә.

Дөньяның төп диннәре:

— Христиан дине

— Ислам

— Буддизм

Дөньяда киң таралган һәм эре милли диннәр:

— Синтаизм

— Индуизм

— Иудаизм

Дин функцияләре (дөньяга караштан соң):

— берләштерүче (җәмгыятьне идея тирәсендә яки идея хакына бергә туплый)

— культурологик (билегеле бер мәдәнияткә таратуга булыша, мәдәнияткә йогынты ясый)

— әхлакый-тәрбияви (җәмгыятьтә якыныңа мәхәббәт, аны кызгану, намуслылык, сабырлык, тәртиплелек, бурыч кебек идеалларны тарата).

4. Фәлсәфә караш

Фәлсәфә – үзенә бер, фәнни-теоретик дөньяга караш. Ул рациональлеге, системалылыгы, мантыйклыгы һәм теоретик оешканлыгы белән аерылып торган югары дәрәҗәле дөньяга караш төрен гәүдәләндерә.

Фәлсәфи дөньяга карашның дини һәм мифологик дөньяга караштан аермасы:

— белемгә нигезләнгән (әышануда яки уйдырмада түгел);

— рефлексив (уйның үз-үзенә юнәлтелгән булуы);

— мантыйклы (эчке берлек һәм системагаия);

— төгәл төшенчә һәм категорияләргә таяна

Фәлсәфәнең дөньяга караш буларак төп эволюция стадияләре:

— Космоцентризм – нигезендә әйләнә-тирә мохитне, табигать күренешләрен югары көч – Галәмнең (космос) бөеклеге, куәтлелеге, чиксезлеге аша аңлату яткан фәлсәфи дөньяга караш һәм аңа яраш-лы, барлык тереклек Космоска һәм космос цикларына бәйле (бу фәлсәфә Борынгы Һиндстан, Борынгы Кытайга хас, башка Көнчыгыш илләренә, шулай ук Борынгы Грециягә).

— Теоцентризм – нигезендә барлык тереклекне аңлатып биреп бул-мый торган, гадәттән тыш көч – Аллаһ яткан фәлсәфи дөньяга караш төре (урта гасыр Европада таралган була).

— Антропоцентризм – үзәгендә кеше мәсьәләсе торган фәлсәфи дөньяга караш төре (Яңарыш чоры Европасы, Яңа һәм Өр-яңа вакыт, хәзерге фәлсәфә мәктәпләре).

§2. Фәлсәфә белеменең үзенчәлеге

Фәлсәфә белеменең үзенчәлекле сыйфатлары

— Фәлсәфә белеменең төп үзенчәлеге аның ике төрлелегендә, чөнки аның фәнни белем белән уртаклыгы күп, шулай да саф төрдәге фәнни белем була алмый.

— Фәлсәфәнең башка фәннәрдән төп аермасы фәлсәфәнең теоретик дөньяга караш булуына,кешелек тарафыннан алда туплаган белемнәрне гомумиләштерүдән тора.

— фәлсәфә предметы теләсә кайсы аерым фән тикшерүләре предметыннан киңрәк, фәлсәфә гомумиләштерә, башка фәннәрне тулыландыра, әмма аларны йотмый, бөтен фәнни белемне үзенә алмый, аның өстендә тормый.

— катлаулы структурага ия (онтология, гносеология, мантыйкны һ.б. үзенә кертә);

— бик нык гомуми, теоретик характерда;

— башка фәннәр нигезендә ятучы база, нигез булып торучы идеяләр һәм төшенчәләргә ия;

— күпчелек субъектив – үзендә аерым шәхес эзе һәм аерым фәлсәфәчеләр карашлары бар;

— объектив белем һәм кыйммәтләр, үз заманының әхлакый идеаллар җыелмасы булып тора, үзендә чор йогынтысын сыный;

— танып белү предметын гына түгел, танып белүнең үз механизмын да өйрәнә;

— үз-үзен тикшерү сыйфаты бар – фикернең үз-үзенә мөрәҗәгате хас (ягъни белем предметлар дөньясына, үзенә мөрәҗәгать итә);

— алдагы фәлсәфәчеләр эшкәрткән доктриналар йогынтысын үзендә тоя;

— шул ук вакытта хәрәкәтчән – даими үсә һәм яңарып тора;

— категорияләргә таяна – бик нык гомуми төшенчәләр;

— асылы белән иксез-чиксез;

— кешенең танып белү сәләтләре белән чикләнгән (танып белүче субъектның), бүгенге көнне мантыйк юлы белән дөрес хәл ителә алмаган хәл итеп булмаслык, «мәңгелек» проблемаларга ия (яшәеш барлыкка килүе, материя яки аңның беренчеллеге, яшәешнең барлыкка килүе, җанның үлемсезлеге, Аллаһ булуы яки булмавы, аның дөньяга булган йогынтысы.

§3. Фәлсәфә предметы һәм методы

1. Фәлсәфә предметы эчтәлеге

Фәлсәфәнең төп бүлекләре:

— онтология (яшәеш турындагы тәгълимат);

— гносеология (аң турындагы тәгълимат);

— кеше;

— җәмгыять.

Дүрт төп фәлсәфә бүлеге кысаларында өйрәнелгән аерым мәсьәләләр:

— яшәеш асылы;

— яшәешнең барлыкка килүе;

— материя (субстанция), аның формалары;

— аң, аның барлыкка килүе һәм табигате;

— материя һәм аңның үзара мөнәсәбәте;

— аңсызлык;

— кеше, аның асылы һәм яшәеше;

— жан, кешенең рухи дөньясы;

— җәмгыять;

— җәмгыять һәм кеше;

— табигать;

— табигать һәм җәмгыять;

— җәмгыять тормышының рухи өлкәсе;

— җәмгыять тормышының матди-икътисади өлкәсе;

— җәмгыятьнең социаль өлкәсе;

— иҗтимагый-икътисади формацияләр, цивилизацияләр;

— кеше, җәмгыятьнең киләчәге;

— экология, исән калу проблемасы;

— танып белү үзенчәлеге;

— танып белүче субъектның танып белү процессына йогынтысы һәм аның нәтиҗәсе;

— аңның чикләнгәнлеге һәм чиксезлеге;

— хәрәкәт;

— фәлсәфә категорияләре;

— диалектика һәм аның законнары;

— башка мәсьәләләр.

2. Фәлсәфә методларының гомуми төшенчәсе һәм эчтәлеге

Фәлсәфә методлары – юллар, чаралар ярдәмендә тормышка ашырылучы фәлсәфә тикшеренүләре

Фәлсәфәнең төп методлары:

Диалектика – фәлсәфә тикшеренүе методы, ул булганда әйберләр, күренешләр, аларның эчке каршылыкларын, үзгәрешләрен, үсешен, сәбәп һәм нәтиҗәләрен, берлеген һәм каршылыклар көрәшен исәпкә алып сыгылмалы, тәнкыйди, эзмә-эзлекле итеп карала.

Метафизика – диалектикага капма-каршы метод, бу методта объектлар аерымланып карала, мөстәкыйль итеп (ә үзара элемтә карашы ягыннан түгел); хәрәкәтсез (даими үзгәрешләр, үзхәрәкәт, үсеш фактларын игътибарга алмый); бер мәгънәле (абсолют (чикләнмәгән) хакыйкать эзләү бара, каршылыкларга игътибар ителми, аларның берлегенә төшенелми).

Догмачылык – әйләнә-тирә дөньяны догмалар призмасы аша үзләштерү – бер һәм мәңгелеккә кабул ителгән, исбат ителмәслек, «югарыдан бирелгән» һәм абсолют характердагы йөреткән караш. Әлеге метод урта гасыр теология фәлсәфәсенә хас.

Эклектика – аерым-аерым, бердәм иҗади факт, төшенчә, концепция башлангычларын ирекле берләштерүгә нигезләнгән метод, аның нәтиҗәсендә сай, әмма тыштан чынга охшаган, ышанычлы тоелган нәтиҗәләргә ирешелә. Еш кына эклектика масса аңын җәлеп итә торган нинди дә булса карашларны, идеяләрне нигезләү өчен кулланыла, әмма ни онтологик, ни гносиологик реаль кыйммәте һәм дөреслеге юк (урта гасырларда – диндә, хәзерге заманда – рекламада).

Софистика – ялган, әмма оста һәм ялгыш дөреслек дип тәкъдим ителгән фикер, яңа юнәлеш, мантыйк ягыннан чын, тик бу методны кабул итүче өчен эчтәлеге белән ялган булган метод. Софистика Борынгы Грециядә киң тарала, хакыйкать табуны максат итеп куймый, ә бәхәстә җиңү, «теләсә ни, теләсә кемгә» дәлилләүне һәм ораторлык сәнгате ысулы итеп кулланыла.

Герменевтика – текстлар эчтәлеген дөрес уку һәм аңлату методы. Көнбатыш фәлсәфәсендә киң таралган.

Бер үк вакытта фәлсәфә юнәлешләре булган фәлсәфә методлары:

Материалистик метод, чынбарлык реаль итеп кабул ителә, материя – беренчел субстанция буларак, ә аң – аның модусы (төрчәсе) – материянең чагылышы. (Материалистик-диалектик метод совет фәлсәфәсендә хакимлекитә иде).

Идеалистик, метод асылы – идеяне башлангыч сыйфатында һәм аның көчен билгеләүче итеп тануда, ә материя идея чыгармасы буларак, аның гәүдәләнеше итеп тану.

Эмпиризм – танып белүдәге метод һәм юнәлеш, аңа ярашлы танып белү процессы, белем нигезендә хисси танып белү нәтиҗәсендә алынган тәҗрибә ята. («Уй-фикерләрдә моңа кадәр тәҗрибә һәм хисси тойгыларда булмаган бернәрсә дә юк».)

Рационализм – фәлсәфәдәгефәлсәфи метод һәм юнәлеш, аңа ярашлы хак, абсолют дөрес белемгә бары тик акыл ярдәмендә генә ирешеп була (ягъни акылның үзеннән чыгарыла) тәҗрибә һәм тойгылардан башка. (Барысын да шиккә алырга мөмкин, ә теләсә кайсы шик – ул инде фикер, акыл эше.)

§4. Фәлсәфә функцияләре

Фәлсәфә функцияләре – фәлсәфәне куллануның төп юнәлешләре, аның аша максат, бурыч, билгеләнеше тормышка ашырыла.

Дөньяга караш функциясе дөнья турында тулы күзаллау формалаштыруга ярдәмитә, аның төзелеше турында, кеше урыны, әйләнә-тирә мохит белән үзара элемтә принциплары турында күзаллау.

Методологик функциянең асылы фәлсәфәнең әйләнә-тирә чынбарлыктагы танып белүнең төп методларын эшкәртеп чыгаруыннан гыйбарәт.

Фикер йөртү-теоретик функция түбәндәгедән гыйбарәт: фәлсәфә концептуаль фикерләргә һәм теоретик мәсьәләләр турында фикер йөртергә өйрәтә – әйләнә-тирә чынбарлыкны бик нык гомумиләштерергә, фикер-мантыйк схемалар, әйләнә-тирә дөнья системасын төзергә өйрәтә.

Гносеологик – төп нигез салучы функцияләрнең берсе – әйләнә-тирә чынбарлыкны дөрес һәм чын итеп танып белүне максат итеп куя (ягъни танып белү механизмы).

Критик функция роле – әйләнә-тирә дөньяны һәм булган белемнәрне шик астына алу, аларның яңа сыйфатларын, үзенчәлекләрен эзләү, каршылыкларын ачу. Ахыргы бурычы – танып белү чикләрен киңәйтү, догмаларны чишү, белемнең катып калуын, аны модернизацияләү, белемнең дөреслеген арттыру.

Аксиологик функция (грек теленнән axios – кыйммәтле) әйберләрне, әйләнә-тирә дөнья күренешләрен төрле кыйммәтләр күзлегеннән – мораль-әхлак, этика, социаль идеологик һәм башка кыйммәтләрне бәяләүдән гыйбарәт. Максаты – «иләк» булу, аның аша кирәкле, кыйммәтле һәм файдалыны үткәреп, тоткарлаган, гомере узганнарны алып калу. Аксиологик функция аеруча тарихның борылышлы вакытларында көчәя (урта гасыр башы – Рим җимерелгәч яңа (теологик) кыйммәтләр эзләү; Яңарыш чоры; Реформация; XIX гасыр ахыры– XX гасыр башындагы капитализм кризисы һ.б.).

Социаль функция – җәмгыятьне, аның барлыкка килү сәбәпләрен аңлату, эволюция,хәзерге торышы, структурасы, элементлары, хәрәкәт итүче көчләре; каршылыкларны ачу, аларны юк итү яки йомшарту юлларын күрсәтү, җәмгыятьне камилләштерү.

Тәрбияви-гуманитар функция гуманистик кыйммәтләрне һәм идеалларны тарату, аларны кешедә һәм җәмгыятьтә тәрбияләү, әхлакны ныгытуга ярдәм итү, кешегә әйләнә-тирә мохиткә өйрәнергә һәм гомеренең мәгънәсен табарга булышудан гыйбарәт.

Прогностик функция әйләнә-тирәдәге дөнья һәм кеше турындагы булган фәлсәфә белемнәре, танып белү юнәлеше казанышлары нигезендә, материя, аң, белем алу процесслары, кеше, табигать һәм җәмгыять киләчәген фаразлаудан гыйбарәт.

§5. Фәлсәфәнең төп мәсьәләләре һәм юнәлешләре

1. Фәлсәфәнең төп мәсьәләсенә гомуми төшенчә, аның яклары

Фәлсәфәнең төп мәсьәләсе итеп, гадәттә, фикерләүнең яшәешкә, ә яшәешнең фикерләүгә (аңга) карата мөнәсәбәте исәпләнелә.

Үзенчәлекләре

Бу мәсьәләнең мөһимлеге аның Дөрес хәл ителүен нән чыгып, әйләнә-тирә мохит һәм анда кеше урыны турында тулы белем төзелә, һәм бу фәлсәфәнең төп соравы булып тора.

Материя һәм аң (рух) – ике аерылгысыз һәм шул ук вакытта капма-каршы яшәешнең сыйфатланышы. Моның белән бәйле ике як яшәп килә – онтологик һәм гносеологик.

Онтологик һәм гносеологик якларга бәйле төп юнәлешләр булеп чыгарыла – аңа ярашлы материализм һәм идеализм, шулай ук эмпиризм һәм рационализм.

Төп мәсьәләнең ике ягы

Онтологик (яшәеш) як проблеманы куюда һәм хәл итүдән тора: нәрсә беренчел – материя яки аң?

Онтологик (яшәеш) якны караганда шундый юнәлешләрне бүлеп чыгарып була:

— объектив идеализм

— субъектив идеализм

— материализм

— вульгар материализм

— дуализм

— деизм

Гносеологик (танып белү) ягы: дөньяны танып белеп буламы яки танып белеп булмыймы, танып белү процессында нәрсә беренчел?

гносеологик (танып белү)ягы:

— гностицизм

— агностицизм

— эмпиризм (сенсуализм)

— рационализм

2. Фәлсәфәнең төп мәсьләләсенең онтологик ягы

Материализм («Демокрит линиясе» дип аталучы) – фәлсәфә юнәлеше, аның яклылар материя һәм аң мөнәсәбәтендә материя беренчел дип исәпләгәннәр.

Төп фикерләре:

— материя чынлап та бар;

— материя аңга бәйсез рәвештә яши (ягъни фикер йөртүче тереклекләрдән бәйсез рәвештә һәм аның турында кем булса да фикер йөртәме юкмыга карамыйча яши);

— материя мөстәкыйль субстанция булып тора – үзеннән башка бернигә дә мохтаҗ түгел;

— материя үзенең эчке законнары буенча яши һәм үсешә;

— аң (рух) югары оештырылган материянең үз-үзен гәүдәләндерү үзенчәлеге;

— аң материя белән янәшәдә яшәп килә, мөстәкыйль субстанция түгел;

— аң материя (яшәеш) белән билгеләнә.

Үзенчәлекләре:

Материалистик юнәлешкә Демокрит; Милет мәктәбе фәлсәфәчеләре (Фалес, Анаксимандр, Анаксимен); Эпикур; Бэкон; Локк; Спиноза; Дидро һәм башка француз материалистлары; Герцен; Чернышевский; Маркс; Энгельс; Ленин кебек фәлсәфәчеләр карый.

Материализм олы бәяләре – фәнгә таяну, аеруча төгәл һәм табигать фәннәре (физика, математика, химия һ.б.), күпчелек материалистларның положениеләрнең мантыйки ярдәмендә дәлилләнүе.

Материализмның йомшак ягы – аң асылы тиешенчә аңлатылуы, материалистик караштан аңлатып булмый торган әйләнә-тирә дөньядагы күренешләр булуы.

Материализмда үзгә бер юнәлеш бүлеп чыгаралар – вульгар материализм. Аның вәкилләре (Фохт, Молешотт) материя ролен абсолютлаштыра, материяне физика, математика һәм химия карашыннан тикшерү белән шө- гыльләнәләр, аның механик ягын, үзаңны асыл буларак һәм аның материягә җавап бирү мөмкинлеген инкарь итәләр.

Материализм фәлсәфәнең хакимлек итүче юнәлеше буларак, демократик Грециядә, эллинистик дәүләтләрдә, буржуаз революция чоры Англиядә (XVII гасыр), СССР һәм XX гасыр социалистик илләрдә киң тарала.

Идеализм («Платон линиясе») – фәлсәфә юнәлеше, аның яклылар материя һәм аң мөнәсәбәтендә беренчел дип аң (идея, рух) исәпләнгән.

Идеализмда бүленеп чыгарылган мөстәкыйль юнәлешл

Объектив идеализм
(Платон, Лейбниц, Гегель һ.б.);

Төп положениеләр:

— чынбарлыкта тик идея генә яши;

— идея беренчел;

— барлык чынбарлык «идеяләр дөньясы»на һәм «әйберләр дөньясына» бүленә;

— «идеяләр дөньясы» (эйдослар) баштан ук Дөнья Акылында яши(Илаһи Ният һ.б.);

— «әйберләр дөньясына» – материаль дөнья мөстәкыйль яшәеше юк һәм «әйберләр дөньясына» гәүдәләнешебулып тора;

— һәр аерым әйбер – әлеге әйбернең идеяләр гәүдәләнеше (эйдосның) (мәсәлән, ат – гомуми ат идеясе гәүдәләнеше, йорт-йорт идеясе, кораб – кораб идеясе һ.б.);

— «саф идея»не конкрет әйбергә әйләндерүдә зур рольне Тудыручы Аллаһ уйный;

— аерым идеяләр («идея дөньясы») безнең аңнан бәйсез рәвештә объектив яшәп килә.

Субъектив
(Беркли

Төп положениеләр:

— барысы да танып белүче субъект (кеше) аңындагына яши;

— идеяләр кеше акылында була;

— материаль әйберләр образлары (идеяләр) хисси тойгылар аша, шулай ук, тик кеше акылында гына яши;

— аерым кешенең аңыннан тыш материя дә, рух (идеяләр) та юк.

Үзенчәлекләр:

Идеализмның йомшак сыйфаты – «саф идеяләр» булуы һәм «саф идея»нең конкрет әйбергә (материя һәм идея барлыкка килү механизмы хакында) дөрес (логик) аңлату булмавы.

Идеализм фәлсәфә юнәлеше буларак Платон Грециясендә, урта гасырларда хөкемлек итә, хәзерге вакытта АКШта, башка Көнбатыш Аурупа илләрендә киң таралган.

Фәлсәфә юнәлеше буларак дуализмга Декарт тарафыннан нигез салына.

Төп кагыйдәләр:

— ике бәйсез субстанция яши – материаль (дәвамлылык үзенчәлеге булган) һәм рухи (фикер йөртү үзенчәлеге булган);

— дөньяда барысы да чыгарылма (модус була) яки беренче яки икенче күрсәтелгәнсубстанциядән (материаль әйберләр – материальдән, идеяләр – рухидан);

— кешедә бер үк вакытта ике субстанция берләшә – материаль дә, рухи дә;

— материя һәм аң (рух) – бер яшәешнең ике капма-каршы һәм үзара бәйләнешле яклары;

— фәлсәфәнең төп мәсьәләсе (нәрсә беренчел – материя яки аң) чынлыкта исә юк, чөнки материя һәм аң бер-берсен үзара тулыландыралар һәм һәрвакыт бар.

Деизм – фәлсәфә юнәлеше, аның тарафдарлары (күбесенчә XVIII гасыр француз мәгърифәтчеләре) Аллаһ барлыгын таныйлар, ул, алар фикеренчә, бер тапкыр дөньяны барлыкка китереп, инде аның киләчәк язмышына катнашмый, һәм кешеләр тормышына һәм эшләренә йогынты ясамый (ягъни бернинди дә «вәкаләтләре» булмаган Аллаһны таныйлар, ул нибары әхлакый символ буларак хезмәт итәргә тиеш). Деистлар материяне күтәренке рухлы дип санаганнар һәм материя белән рухны (аңны) каршы куймыйлар.

3. Фәлсәфәнең төп мәсьәләсенең гносеологик ягы

Эмпиризм

Үзенчәлекләр:

Эмпиризмга нигез салучы итеп Фрэнсис Бэкон исәпләнелә.

Эмпиристлар танып белү нигезендә тәҗрибә һәм хисси тойгылар гына була дип санаганнар. («Моңа кадәр тәҗрибә һәм хисси тойгыларда булмаган берни дә фикерләрдә (акылда) юк»).

Рационализм

Үзенчәлекләр:

Р. Декарт рационализмга нигез салучы (от лат. ratio – разум) дип санала.

Рационализмның төп идеясе хак (дөрес) белем тик акылдан гына чыга ала һәм хисси тәҗрибәдән тормый. Беренчедән, тик бар нәрсәдә шикләнү генә реаль булуы ихтимал, ә шикләнү – фикер – акыл эшчәнлеге. Икенчедән, акыл өчен бәхәссез һәм тәҗрибә белән дәлилләү таләп ителмәгән хакыйкать (аксиома) бар: «Аллаһ бар», «Квадратның почмаклары туры» һ.б.

Иррационализм аерым юнәлеш сыйфатында бүленеп чыга (Ницше, Шопенгауэр). Аңа ярашлы дөнья тәртипсез, буталчык, эчке мантыйгы юк, димәк, беркайчан да акыл белән танып бетерелмәячәк.

Гностицизм вәкилләре (гадәттәгечә, материалистлар)

Агностицизм теоретикларына Иммануил Кант (1724–1804) та кергән. Кант фикеренчә, кеше акылы зур мөмкинлекләргә ия, тик аларның үз чикләре бар. Кеше акылының танып белү мөмкинлекләренең чикләнгәнлеге аркасында кеше беркайчан да җавабын белмәячәк табышмаклар (каршылыклар) бар. Мәсәлән, Аллаһ бар. Аллаһ юк. Кант барлыгы шундый дүрт каршылык (антиномияләр) бүлеп күрсәтә (карагыз 36 сорау «Имма-нуил Кант фәлсәфәсе»).

Тик Кант буенча, кешенең танып белү мөмкинлекләренә кергәннәр дә барыбер беркайчан да танып бетерәлмәячәк, чөнки акыл әйберләрнең гәүдәләнешен хисси тойгылар аша гына таный ала, ләкин әлеге әйбернең эчке асылына төшенә алмаячак – «әйберләр үзендә».

Төп кагыйдәләр:

— дөньяны танып булмый;

— танып белү мөмкинлекләре кеше акылы мөмкинлекләре белән чикләнә.

4. Фәлсәфәнең төп мәсьәләсенең хәзерге торышы һәм аның киләчәге

Үзенчәлекләре:

Хәзерге вакытта, фәлсәфәчеләрнең меңәр ел эзләнүләренә карамастан, фәлсәфәнең төп мәсьәләсе ни онтологик, ни гносеологик яктан дөрес хәл ителмәгән һәм шуңа да мәңгелек (хәл ителмәс) фәлсәфә проблемасы булып кала.

XX гасырда көнбатыш фәлсәфәсендә бу мәсьәләгә азрак игътибар бүлү башланды, чөнки ул авыр хәл ителә һәм тора-бара үзенең көнүзәк булуын (актуальлеген) югалта.

Ясперс, Хайдеггер, Камю һ.б. киләчәктә башка төп мәсьәлә экзенстенциализм проблемасы барлыкка киләчәк дигән фикергә нигез салалар. Кеше проблемасы, аның яшәеше, рухи дөньясы белән идарә итүе, җәмгыять эчендә һәм җәмгыять белән үзара мөнәсәбәте, аның ирекле сайлау мөмкинлеге, яшәү мәгънәсе һәм тормыштагы урынын эзләү, бәхете.

Икенче бүлек. Фәлсәфәнең төп доктриналары

§6. Кытай фәлсәфәсе

1. Кытай фәлсәфәсенең төп этаплары һәм хас сыйфатлары

Кытай фәлсәфәсенең төп үсеш этаплары

— Безнең эрага кадәр VII гасыр – безнең эраның III гасыр – борынгы милли фәлсәфә мәктәпләре барлыкка килү;

— Безнең эраның III – XIX гасырлары – Кытайга Һиндстаннан буддизмның үтеп керүе (б.э. III гасыры) һәм аның милли фәлсәфә мәктәпләренә булган йогынтысы;

— Безнең эраның XX гасыры – хәзерге этап – Кытай җәмгыятенең йомыклыктан чыгуы, Кытай фәлсәфәсенең Аурупа һәм дөнья фәлсәфәсе казанышлары белән баетылуы.

Кытай фәлсәфәсе

Кытай фәлсәфәсендә чагылдырылган дөньяны һәм әйләнә-тирә чынбарлыкны күрү:

— Үз илен кабул итү – Кытайны – яшәп килгән дөньяның үзәге;

— Аерым вакыйгаларны, тулы тарихны цикллы процесс буларак аңлау;

— Галәм цикларын җирдә дөрес тормышка ашыру өчен күк һәм җир алдындагы җаваплылыкны төшенү;

— Кеше, табигать һәм галәмне бербөтен итеп кабул итү;

— Аң консерватизмы, үткәнгә юнәлдерелгәнлек, үзгәрешләрдән курку;

— Аерым кеше шәхесен коллективтан бүлеп карамау;

— Табигать көчләре белән (елга ташулар, гарасатларга һ.б.) көрәштә аерым кешенең көчсезлегенә төшенү; коллектив хезмәткә өстенлек бирү (бөек кытай стенасын, буалар төзү, каналлар казу, су ташулар белән көрәшү, сугару игенчелеге һ.б.); Моңардан – оештыручы көч – дәүләт алдында хөрмәт һәм калтырану;

— Кеше шәхесен, коллективны, җәмгыятьне һәм дәүләтне бербөтен итеп кабул итү; җәмгыятьтә вертикаль элемтәләр таралуы (хакимият һәм буйсыну), субординация, җитәкчеләрне тыңлау, дәүләт башлыгын (императорны) дәүләтне берләштерүче югары көч итеп кабул итү, ә дәүләт – җәмгыятьне берләштерүче көч итеп, император, аның хакимиятен һәм вазифаны аллалаштыру;

— Мөнәсәбәтләрдәге конформизм, тынычлык һәм эшсезлеккә өстенлек;

— Тормышны иң элек тәнгә төрелгән рух яшәеше итеп аңлау, теге дөньядагы тормышка караганда җирдәгесен өстен күрү, аерым кешенең гомерен җирдә мөмкин кадәр озаккарак сузу омтылышы (үләм, физик күнекмәләр, дөрес яшәү рәвеше һәм әйләнә-тирә чынбарлыкка дөрес мөнәсәбәт ярдәмендә);

— Теге дөнья көчләрен реаль итеп кабул итү, үләләрне җанландыру;

— Ата-аналарга, өлкәннәргә хөрмәт, борынгы әби-бабаларны һәм рухларны ихтирам итү.

2. Кытайның төп милли фәлсәфи тәгълиматлары

Кытайның төп милли фәлсәфи тәгълиматлары

Борынгы милли фәлсәфи тәгълиматлар

— даосизм;

— конфуцианлык;

— легизм.

Азрак таралган тәгълиматлар

— моизм;

— натурфилософия;

— номинализм.

Кытайга буддизм үтеп кергәннән соң Кытай фәлсәфәсенең төп юнәлешләре (безнең эраның III гасыры һәм XIX гасыр ахырына кадәр икенче этап):

— Чань-буддизм (милли Кытай буддизмы, Кытай мәдәниятенең Һиндстан буддизмына йогынты ясаудан килеп чыккан, Кытай тарафыннан үзләштерелгән;

— неодасизм;

— неоконфуцианлык.

XX гасырда милли Кытай фәлсәфәсен баеткан дөнья фәлсәфи фикер казанышлары:

— Христиан дине идеяләре;

— Марксизм идеяләре;

— Алдынгы Европа фәлсәфәчеләре идеяләре;

— Прагматизмның Америка фәлсәфәчеләре идеяләре.

§7. Кытай фәлсәфәсендә һәм мифологиясендә кеше һәм әйләнә-тирә дөнья барлыкка килү мәсьәләсе

Кытай фәлсәфәсендә кеше мәсьәләсе: Кытайда кеше табигать һәм галәм белән тиңләштерелсә дә һәм җәмгыятьтән аерылмаса да, ул Кытай фәлсәфәсендә үзәк урынны алып тора.

Космик (галәм) энергиянең өч төре, Кытай фәлсәфә традициясенә ярашлы, аның куерыгы – ул кеше.

Цзин – барлык тереклекне тудыручы энергия, тере организмның «тамыры», «орлыгы».

Бу психофизик энергиянең ике төре бүленеп чыга:

«Элекке Күк орлыгы» – кешегә тумыштан бирелгән нәрсәләр, генетик программа, физик мәгълүматлар;

«Киләсе күк орлыгы» – кеше гомере буена туплаганмәгълүмат.

Еш кына цзин сексуаль энергия белән тиңләштерелә.

Ци – материаль-рухи энергия, ул барлык тереклеккә «төзелеш материалы» булып хезмәт итә (цзиннан аермалы буларак – барлыкка килү энергиясе).

Ци энергиясе бүленә:

— матди ци, аның аркасында әйберләр һәм тере организмнар материаль форма ала;

— рухи ци – кеше рухы һәм башка тере җаннарның. Рухи ци – кеше яшәешенең нигезе. Уңышлы, физик һәм әхлакый таза кеше «саф», «чиста» цига, чирле, көчсез, уңышсыз – «авыр», «пычрак», «кара» цига ия. Уңышка, физик һәм рухи сәламәтлек, бәхеткә юл – цины артык бар нәрсәдән азат итү, җанны сафландырудан тора.

Шэнь – кешедә булган бетерә алмаслык рух энергиясе, ул кеше шәхесенең «үзәген» тәшкил итә һәм кеше үлеменнән соң да югалмый (цидан аермалы буларак).

Үзенчәлекләре:

— Өч космос энергиясеннән тыш (барлыкка килү энергиясе – цзин; рухи яшәешнең материаль һәм рухи энергиясе – ци; үлемнән соң да калучы даими рух энергиясе – шэнь) Кытай фәлсәфәсе ике төр сексуаль энергияне бүлеп чыгара:

— Барлык тереклек ике капмакаршы башлангычка бүленә – ирләр һәм хатын-кызлар. Бу тере табигатькә дә, (ирләр һәм хатыннарга бүленү, хайваннар арасында да җенес буенча бүленеш), җансыз табигатькә дә (мәсәлән, Кытай фәлсәфәсе актив ирләр башлангычына ян Кояш, күк, көн, корылык, җиңеллекне, ә пассив хатын-кызлар башлангычына инь – Ай, Җир, тигезлекләр, төн, дымны) кагыла.

— Тере һәм җансыз табигатьнең яшәү нигезендә, әйләнә-тирә чынбарлыкта «Тай-цзи» ята – бердәмлек, көрәш, үзара керешеп китү һәм үзара бер-берсен тулыландыру – Ян һәм Инь.

2. Кытай фәлсәфәсендә кешенең үзләштерү үзенчәлеге

Кытай фәлсәфәсендәге кеше үзләштерү үзенчәлегенең Көнбатыш фәлсәфәсеннән аермасы

— Кытай фәлсәфәсе кеше турында аныкт төшенчә бирми, кеше асылына аныкт төшенчәләр чыгару юлы аша түгел, ә аның образын тудыру һәм өйрәнү аша юлы кереп билгели (шуңа да сүзне кеше төшенчәсе турында түгел, ә кеше һәм башка күренешләр турында образ-төшенчәләр дип сөйләү дөресрәк булыр);

— Кеше гомерен туганнан түгел, яралганнан алып саный башлыйлар;

— Кеше мөнәсәбәтләре системасыннан кеше үлгәннән соң сызып ташламыйлар, ягъни кеше (аның рухы, ниндидер тәнгә ия булган – «шэн») кеше мөнәсәбәтләре системасында исәннәр белән беррәттән үлгәннән соң да кала – туклану, хәстәрлеккә мохтаҗ, элеккеге вазифасын сакълый, үрләтергә, бүләкләнергә, вазифадан бушатылырга, җәза алырга мөмкин – аның нәселен дәвам итүчеләр тәртибеннән чыгып;

— Кешенең рухи үзәге сыйфатында баш (ми, йөз, күз һ.б.) түгел, ә йөрәкне билгели;

— Кешене табигать һәм галәмнең бер өлеше итеп кабул итә, кешенең табигатьтән өстен булу идеясе белән килешми, индивидуализм һәм аерым шәхесләрне җәмгыятьтәге калган әгъзаларга каршы куюны өнәми;

— Җирдәге гомер өзегенең кадерен белергә чакыра, аның озынлыгын максималь озынайтырга тырыша.

Озын гомернең төп шартлары (Кытай фәлсәфәсенә ярашлы)

— Ци психофизик энергияне чиста торышта саклау, ул кирәкмәгән борчылулардан азат булуны, яман һәм мәкерле уй-гамәлләрдән баш тартуны, әйләнә-тирә чынбарлыкка дөрес мөнәсәбәт, әйләнә-тирәдәгеләргә һәм өлкәннәргә хөрмәт, тыйнак оптимизм, торак һәм җиһазның дөрес урнашуы, «пычрак» «ци»лы кешеләр белән аралашудан читләшү, «саф» «ци»лы кешеләр белән аралашуны үзэченә ала;

— «Син чун» – тәнең һәм күңелең өстендә эшләү – үзеңне мәдәниятләштерү;

— Язмышың өстендә эшләү, җәмгыятькә файда китерү – «мин чун»;

— Җәмгыять тәртипләрен саклау;

— Дару һәм шифалы үләннәр куллану, дөрес туклану;

— Кытайда яшәү, кытай мәдәнияте белән берләшү, Кытай рухи энергиясе белән сугарылу.

3. Әйләнә-тирә дөнья һәм кешенең барлыкка килүе турында Кытай фәлсәфәсе һәм мифологиясенең аңлатмасы

Әйләнә-тирә дөнья һәм кешенең барлыкка килүе турында Кытай фәлсәфәсе һәм мифологиясенең аңлатмасы

Үзенчәлекләре:

— Борынгы Китай мәдәнияте әйләнә-тирә дөнья һәм кешенең барлыкка килүе хакында фәлсәфи-мифологик аңлатма бирә, ул үзенә берничә эзлекле этапны ала:

— «И-Цзин» Борынгы фәлсәфи әсәр дөнья барлыкка килүне биш беренчел элементларга бәйле дип аңлата – җир, агач, металл, ут һәм су, алар өзлексез әйләнештә тора.

— Борынга Кытай мифологиясе һәм фәлсәфәсе дөнья, табигать һәм кеше, кеше образ-төшенчәсенең, әйләнә-тирәдәге күренешләрне барлыкка килүе турындаберенчел аңлатма бирде, Кытайның танылган фәлсәфә мәктәпләре барлыкка килү өчен нигез әзерләделәр – даосизм, конфуцианство, легизм.

Кытай мәдәниятендә әйләнә-тирәдәге дөнья һәм кешенең барлыкка килү этаплары

— Бөек Хаос, формасы белән бик зур Йомырканы хәтерләткән;

— Йомырка-Хаоста 18000 ел буена яралган барлык тереклекнең Беренче нәсел башлыгы – Пань-Гу гиганты;

— Пань-Гу гигантының Йомыркадан чыгуы, ул йомырка формасындагы Хаосны үлемгә китерүе;

— Барлык җиңел һәм корының күккә-өскә (Күк) һәм авыр, дымлының аска (Җир) ашу юлы белән Хаостан Күк һәм Җир яралуы;

— Пань-Гу гигантының 18000 еллык Күк белән Җир арасында торуы нәтиҗәсендә Күк белән Җир үз урыннарына берегеп калалар;

— Пань-Гу үлеме, барлык тереклекне аның тәненнән ясау: Кояш һәм Айны – күзеннән, яшенне – тавышыннан, җилне – сулышыннан, елгаларны – каныннан, юлларны – кан тамырыннан, таш һәм файдалы казылмаларны – сөякләреннән, тешеннән һ.б.;

— Кешенең Пань-Гу тәнендә шуышкан паразитлардан, яки фантастик беренче нәсел башлыклары Фуси һәм Нюйваның – аждаһакешеләр мәхәббәте нәтиҗәсендә барлыкка килүе.

§8. Даосизм – Кытайның борынгы фәлсәфә тәгълиматы

Даосизм – Кытайның борынгы фәлсәфә тәгълиматы, әйләнә-тирә дөньяның төзелеше һәм яшәешен аңлатырга һәм кеше, табигать һәм галәм иярергә тиеш юлны билгеләргә тырыша. Даосизмга безнең эрага кадәрге VI ахыры – V башы гасырларда яшәүче **Лао Цзы** (Карт Укытучы) нигез сала. Төп чыганаклары – «Даоцзин» и «Дэцзин» фәлсәфә трактатлары, кушып әйткәндә «Даодэцзин».

«Дао» ике мәгънәгә ия: беренчедән, кеше һәм табигать үз үсешендә үтәргә тиешле юл, дөньяның яшәешен тәэмин итүче универсаль дөньяви закон; икенчедән, барлык дөнья барлыкка килгән субстанция, күп сыешлы энергетик бушлыкны гәүдәләндергән башлангыч.

«Дэ» – югарыдан индерелгән рәхәтлек; бу энергиягә бәйле «Дао» әйләнә-тирә дөньяга әйләнә.

Даосизмның төп идеяләре:

— Дөньяда барысы да үзара бәйләнешле, анда башка әйберләр һәм күренешләр белән үзара бәйләнмәгән бер генә әйбер дә, бер генә күренеш тә юк;

— Дөнья ясалган материя бер; табигатьтә материя әйләнеше бар («барысы да җирдән ярала һәм җиргә китә»), ягъни бүгенге кеше үлемнән соң кичә галәмдә булган башка формадагы – таш, агач, хайваннар һәм кеше торган башка тереклек яки табигать күренешләре формалары өчен «төзелеш материалы» булачак;

— Дөнья тәртибе, табигать законнары, тарих барышы какшамас һәм кеше ихтыярыннан тормый, димәк, кешенең төп принцибы – тынычлык һәм эшсезлек («у-вэй»);

— Император шәхесе изге, тик императорның гына Аллаһ һәм югары көчләр белән рухи элемтәсе бар; император шәхесе аша Кытайга һәм барлык кешелек дөньясына «Дэ» – терелтүче көч һәм рәхәтлек төшә; кеше никадәр императорга якынрак торса, шулкадәр күбрәк «Дэ» императордан аңа күчәчәк;

— «Дао»ны танып белү һәм «Дэ»ны даосизм законнарын төгәл үтәгәндә генә алып була, «Дао» – башлангычы белән кушылу – императорны тыңлау һәм аңа якынлык;

— Бәхет, хакыйкатьне танып белү юлы – теләк һәм дәртләрдән азат булу

— Бер-береңә юл куярга кирәк.

§9. Борынгы Кытайның социаль-фәлсәфи мәктәпләре – конфуцианлык һәм легизм

1. Конфуцианлыкның характеристикасы (сыйфатламасы)

Конфуцианлык – борынгы фәлсәфә мәктәбе, ул кешене иң элек социаль тормышта катнашучы буларак карый. Аңа безнең эрага кадәр 551 – 479 елларда яшәүче Конфуций (Кун-Фу-Цзы) нигез сала. Тәгълиматның төп чыганагы – Лунь Юй («Әңгәмәләр һәмфикер йөртү») әсәре.

Үзенчәлекләре:

— Конфунцианлык хәл итә торган төп мәсьәләләр, ничек кешеләр белән идарә итәргә һәм җәмгыятьтә үзеңне тотарга.

— Бу фәлсәфә мәктәбе вәкилләре җәмгыять белән йомшак идарә итәргә кирәк дип исәпли. Мисал: ата кешенең улы өстеннән булган хакимлеге, ә аның төп шарты – буйсынучы улларның җитәкче аталарына булган мөнәсәбәте.

— Конфуцийның кешеләрнең җәмгыятьтәге алтын кагыйдәсе:үз-үзеңә теләмәгәнне, башкаларга эшләмә.

— Конфуций тәгълиматы Кытай җәмгыятен берләштерү өчен зур әһәмият уйный. Автор яшәгән һәм эшләгән вакыттан 2500 ел үтсә дә, ул бүгенге көндә дә көнүзәк булып кала.

Конфуций тәгълиматының төп принциплары:

— Җәмгыятьтә һәм җәмгыять өчен яшәргә;

— Бер-береңә юл куярга;

— Яшь һәм дәрәҗә буенча өлкәннәрне тыңларга;

— Императорга буйсынырга;

— Үз-үзеңне тыя белергә, бар нәрсәдә чама белергә, бер чиктән икенчесенә йөрүдән качу;

— Кеше булырга.

Җитәкче һәм буйсынучылар мәсьәләсе

Җитәкче ия булырга тиешле сыйфатлар

— Императорга буйсынырга һәм конфуций принципларына иярергә;

— Гаделлек нигезендә идарә итәргә («бадао»);

— Тиешле белемгә ия булу;

— Илгә тугрылыклы хезмәт итәргә, илсөяр (ватанпәрвәр) булырга;

— Зур амбициягә ия булырга, югары максатлар куярга тиеш;

— Намуслы булырга;

— Дәүләткә һәм әйләнә-тирәдәгеләргә яхшылык кына эшләргә;

— Көчләүгә караганда үгетләүгә һәм шәхси үрнәккә өстенлек бирергә тиеш;

— Буйсынучыларның шәхси һәм гомумән илнең иминлеге турында хәстәрлек күрергә тиеш.

Буйсынучылар ия булырга тиешле сыйфатлар

— Җитәкчегә карата лояль мөнәсәбәттә булырга тиеш;

— Эшне башкарганда тырышлык күрсәтергә;

— Даими укырга һәм камилләшергә.

2. Легизм характеристикасы (сыйфатламышы)

Легизм (канунчылар мәктәбе, яки Фацзя) – Борынгы Кытайның башка мөһим социаль тәгълиматы

Үзенчәлекләре:

— Нигез салучылар – Шан Ян (б.э. кадәр 390–338 еллар) һәм Хань Фэй (б.э. кадәр 288–233 еллар).

— Император Цинь-ШиХуа (б.э. кадәр III гасыр) чорында легизм рәсми идеологиягә әйләнә.

— Легизмның төп мәсьәләсе. (конфуцианлык кебек үк): җәмгыять белән ничек идарә итү?

— Легистлар җәмгыять белән законга таянучы дәүләт көчен куллану белән идарә итәргә кирәк дигән фикер белән чыгыш ясыйлар.

— Шулай итеп, легизм – көчле дәүләт хакимиятенең фәлсәфәсе.

Легизмның төп постулатлары:

— Кеше асылыннан ук явыз табигатьле;

— Кешене хәрәкәт иттерүче көч – эгоистик ихтыяҗлар;

— Гадәттә, аерым индивидлар ихтыяҗлары (социаль төркемнәр) үзара капма-каршы;

— Законсызлыкны һәм гомуми дошманлыктан качар өчен җәмгыять мөнәсәбәтләренә дәүләт кысылышы зарури;

— Дәүләт (армия, чиновниклар йөзендә) законга буйсынучы гарҗаннарны бүләкләргә һәм гаеплеләрне каты җәзага тарттырырга тиеш;

— Күпчелек кешеләрнең законга буйсынуның төп сәбәбе җәза алудан куркуга бәйле;

— Законлы һәм законсыз тәртипне аеру һәм җәза куллануның төп коралы закон булырга тиеш;

— Закон барысы өчен дә бер булырга тиеш, ә җәза, әгәр дә законны бозсалар, гади кешеләргә дә, югары чиновникларга (дәрәҗәсенә карамыйча) карата да кулланырга тиеш;

— Дәүләт аппараты профессионаллардан тупланырга тиеш (ягъни чиновник вазифаларын тиешле белеме һәм эшлекле сыйфатлары булган кандидатларга бирелергә, ә нәселдән бирелергә тиеш түгел);

— Дәүләт – җәмгыятьнең төп тәртипкә салучы механизмы булырга тиеш, һәм, димәк, аның иҗтимагый мөнәсәбәтләргә, гражданнарның шәхси тормышына катышырга хокукы бар.

§10. Борынгы һинд фәлсәфәсе

1. Борынгы һинд фәлсәфәсен чорларга бүлү

Борынгы һинд фәлсәфәсенең төп үсеш этаплары
(борынгыда да, бүген дә билгеле булган төрле фәлсәфи фикер чыганакларына ярашлы)

Ведик чоры (б.э. кадәр XV – VI гасырлар). Веды (сүзгә-сүз – «белемнәр» – дини-фәлсәфи трактатлар, аларны б.э. кадәр XV гасырда Һиндстанга Урта Азия, Идел буе һәм Ираннан килгән ариецлар кабиләләре төзи. Борынгы һинд фәлсәфәсен өйрәнүчеләрне күбрәк вед-упанишадының (санскриттан – «укытучы аягы астында утыру») йомгак өлешләре кызыксындыра. Биредә Веда эчтәлегенең фәлсәфи аңлатмасы бирелгән.

Ведаларга кертелгән өлешләр

— «Изге язмалар», дини гимннар («самхитлары»);

— Ритуалларны тасвирлау («брахманнар»), брахманнар (кариннәр) тарафыннан язылган һәм дини культларны тәртипкә китерүдә кулланылган;

— Урман дәрвишләре китабы («араньяклар»);

— Ведаларга фәлсәфи аңлатмалар («упанишадлар»).

Бүгенге көнгә килеп җиткән Ведалар

— Ригведа;

— Самаведа;

— Яджурведа;

— Атхарваведа.

Эпик этап (б.э.кадәр VI – II гасырлар), аның киң билгеле ике поэмасы – «Махаб-харата» һәм «Рамаяна» эпослары, аларда чорның күп фәлсәфи мәсьәләләре күтәрелә

Бу чорда ведаларга каршы туды рылучы тәгълиматлар

— Буддизм;

— Джайнизм;

— Чарвана-лакаята.

Бу чорда барлыкка килүчек ведик тәгълиматны («даршаны») үстерүче фәлсәфә мәктәпләре

— йога;
— веданта;
— вайшешина;
— ньяя;
— миманса;
— санкьхя.

Сутр эрасы (б.э. кадәр II гасыр – б.э. VII гасыры) – аерым мәсьәләләрне караучы кыска фәлсәфи трактатлар (мәсәлән, «нама-сутра» һ.б.), – борынгы һинд фәлсәфәсе чорын тәмамлый.

Киләчәктә (урта гасырда һинд фәлсәфәсендә хакимлек итүче урынны Гаутамы Будда тәгълиматы – буддизм яулый.

XVIII – XX гасырларда һинд фәлсәфәсе европа фәлсәфи фикере казанышлары белән байый (атап әйткәндә, инглиз фәлсәфәсе).

2. Борынгы һинд фәләсәфәсе онтологиясе

Үзенчәлекләре:

— Борынгы һинд фәләсәфәсе онтологиясе (яшәеш һәм яшәешнең юклыгы турында тәгълимат) Рит законына нигезләнә – космик эволюция, цикллык, тәртип һәм үза-ра бәйләнешләр.

— Яшәеш һәм яшәеш юклыгы Брахма – Космосның (Тудыручы Алланың) сулыш алу һәм чыгаруы белән ассоциацияләнә. Үз чиратында, Брахма-Космос (Тудыручы – Алла) 100 космик (8640000000 җир) ел яши, аңардан соң үлә һәм абсолют яшәеш юклыгы барлыкка килә, ул шулай ук 100 космик (8640000000 җир) ел дәвам итә –яңадан Брахма туганчыга кадәр.

— Бөтен чиксез тарих – ул Галәм-космос (Маха Манвантара) яшәешенең һәм Абсолютяшәеш юклыкның (Маха Пралйя) бер-берсен 100 космик ел алыштырып, чират- лашып килүе. Һәр туганда Брахма-Космос кабаттан яшәеш барлыкка килә, тик баркамилләшкән формада.

— Дөнья үзарабәйләнешле. Теләсә кайсы вакыйга (кеше хәрәкәте, табигать күрене- ше) Космос яшәешенә йогынты ясый. Эволюция максаты, үсеше – материал форма- ларның даими алмашыну нәтиҗәсендә камил рухка ирешү.

3. Борынгы һинд фәлсәфәсе гносеологиясе

Үзенчәлекләре:

— Борынгы һинд гносиологиясенең фәлсәфәсенең төп үзенчәлеге (танып белү ту-рында тәгълимат) предмет һәм күренешләрнең тышкы (күренеп торган) бил- геләрен өйрәнү түгел (Европа танып белү тибына хас), ә аңда предметлар һәм күренешләр белән бәйләнешкә керү вакытында аңда барлыкка килгән процес- сларны өйрәнү.

— Һинд фәлсәфәсе шушы уңайдан өч төр аңны бүлеп чыгара: «практиклар» – мате- риаль аң, «паруша» – саф аң (Галәм һәм кешеләр барлыкка килгән беренчел энер-гия) һәм «майя» – төш аңы, рәшә.

— Һәр төр аң реаль, һинд фәлсәфәсенә ярашлы, һәм материаль аң һәм ялган яшәеш-не генә кабул итүче европа фәлсәфәсенә караганда, өйрәнүгә лаек.

4. Һинд фәлсәфәсендә җан мәсьәләсе

Һинд фәлсәфәсенә ярашлы җан торган ике башлангыч

— Атмон – кеше җанындагы Брахма-Алланың бер өлеше. Атман беренчел, үзгәрешсез, мәңгелек.

— Манос – гомер барышында барлыкка килүче кеше җаны. Манос даими үсеш кичерә, югары биеклекләргә ирешә яки кеше гамәлләренә, шәхси тәҗрибәсенә, язмышына бәйле начарлана.

5. Сансара, карма мокша һәм архимслар турында гомуми төшенчә

Сансара – мәңгелек һәм җирдәге яшәеш вакытында газаплар чылбыры үтүче җанның үлемсезлеге турында тәгълимат.

Карма – кеше гомере, язмышының алдан билгелүнүе. Карма максаты – җанны камилләштерү һәм югары әхлакый үсешкә – мокшага ирештерү өчен кешене сынаулар аша үткәрү. Бу максатка ирешү өчен җан дистәләгән, йөзләгән җир гомере үтәргә мөмкин.

Мокша – югары әхлакый камиллек, аны ирешүгә җан үсеше (карма) туктый. Мокша урнашуы (җанның эволюцион үсеше туктау) – җирдә яшәгән вакытта ирешеп булган һәр җанның югары максаты. Мокшага ирешкән җаннар чиксез гомердән азат була һәм махатмами – Бөек Җаннарга әйләнә.

Ахимса – җирдәге барлык тереклек формаларының берлеге (димәк, кеше, хайваннар һәм әйләнә-тирә табигате берлеге). Ахимсаларның мөһим принцибы – әйләнә-тирә дәгеләргә зыян салмау (кеше, хайваннарга, тере табигатькә).

§11. Буддизм һәм аның төп идеяләре

Буддизм – Һиндстанда (б.э. кадәр V гасырда), Кытай, Көньяк-Көнчыгыш Азиядә (б.э. III гасырыннан соң) һәм башка төбәкләрдә таралган дини – фәлсәфи тәгълимат.

Үзенчәлекләр:

— Бу тәгълиматка нигез салучы – Гау- тама Будда (Сидхардаха Шакьямуни) (б.э. кадәр 563 – 483 еллар) исәпләнелә, ул Төньяк Һиндстанда князьлар гаиләсендә туа. Будда катлаулы тормыш юлы үтә (тәхет дәвамчысы, аскет-дәрвиш, акыл иясе), шуннан соң «ачышлар» ясый башлый (б.э. кадәр 527 ел) һәм үзенең рухи казанышларын кешеләргә тапшыра.

— Буддизмның төп идеясе – «Уртача юл» ике чик арасында: «рәхәтлекләр юлы аша» (күңел ачу, бәйрәм итү, ялкаулык, физик һәм мораль таркалу) һәм «аскетизм юлы аша» (женси теләкләрне үтерү, авырлыклар, газаплар, физик һәм мораль йончу).

— «Уртача юл» – белем юлы, акыл, акыллы чикләнү, зыялылык, күзәтү, мәгърифәт, камилләшү, боларның ахыргы максаты – Нирвана – югары рәхәтлек.

Буддизмның биш канун-юнәлешләре:

— үтермә;

— урлама;

— гыйффәтле бул;

— ялганлама;

— исерткеч һәм тилерткеч әйберләр кулланма.

Будда ачкан дүрт нәзәкатьле (арияле) хакыйкать

— җир яшәеше газаплар белән тулы;

— газапларның үз сәбәпләре бар – җиңел табыш аласы килү, дан, канәгатьлек алу, яшәү һ.б.;

— газаплардан котылып була;

— газаплардан азат итә ала торган юл – җир теләкләреннән баш тарту, агарту, Нирвана (ыгы-зыгылардан китү).

Буддизм һәр кешегә шәхси камил- ләшү өчен тәкъдим иткән «Сигезле Азат булу Юлы» этаплары – нәтиҗәсе - Нирвана – Бөек Азат булу

— Дөрес итеп күрү – буддизм нигезләренә төшенү һәм үзеңнең тормыштагы юлыңны аңлау;

— Дөрес фикерләү – кеше тормышы аның фикерләреннән тора, фикерләр үзгәргәндә (дөрестән дөрес түгелгә, күркәмгә) тормыш үзгәрә;

— Дөрес сөйләү – кешенең сүзләре, аның сөйләме аның рухына, холкынайогынты ясый;

— Дөрес хәрәкәт – үзең һәм башкалар белән килешеп яшәү, башкаларга явызлык кылмау;

— Дөрес яшәү рәвеше – һәр адымыңны буддизмның кануннарына нигезләнеп башкару.

§12. Борынгы Греция фәлсәфәсе: төр сыйфатлары, чорларга бүлү

Борынгы Греция территориясендә һәм Кече Азия, Урта һәм Кара диңгез буйлары һәм Кырымдагы грек полисларында (сәүдә-һөнәри шәһәр-дәүләтләр), Азия һәм Африка дагы эллинистик дәүләтләр, Рим империясенда яшәүче грек фәлсәфәчеләре тудырган **Борынгы Греция фәлсәфәсе. Еш кына Борынгы Рим фәлсәфәсе йә аның белән «антик фәлсәфә» исеме астында берләштерелә.**

Үзенчәлекләр:

— бу фәлсәфәнең чәчәк атуына полисларның икътисади яктан үсеше материаль нигез була;

— борынгы грек фәлсәфәсе матди җитештерү процессыннан аерылган булган, ә фәлсәфәчеләр физик хезмәт белән авырлык китерелмәгән һәм җәмгыять белән рухи һәм сәяси җитәкчелек итәргә омтылучы аерым бер катламга чыга;

— борынгы грек фәләсәфәсенә космоцентризм хас (Космос алдында курку һәм аңа табыну, материаль дөнья, әйләнә-тирә дөнья барлыкка килү мәсьәләсенә кызыксыну күрсәтәләр);

— соңгы этапларда – космоцентризм һәм антропоцентризм кушылмасы (аның нигезендә кеше мәсьәләсе булды);

— Аллалар булуы ихтималын кире какмый;

— борынгы грек аллалары табигатьнең бер өлеше һәм ул кешеләргә якын;

— кеше әйләнә-тирә дөньядан бүленми, табигатьнең бер кисәге була;

— фәлсәфәнең ике юнәлеше салына – идеалистик («Платон линиясе») и материалистик («Демокрит линиясе»), әйтергә кирәк, бу юнәлешләр чиратлашып өстен позициядә була, Сократка кадәрге вакытта – материалистик, классик чорда – икесе дә бертөрле йогынты ясый, эллинистик – материалистик, римныкында – идеалистик.

2. Борынгы грек фәлсәфәсе этапларына (чорларына) кыскача характеристика

Борынгы грек (антик) фәлсәфәсе фәлсәфәсенең үсеш этаплары

Сократка кадәрге чор (б.э.ның VII – V гасырлары), аның төп мәсьәләләре: табигатькүренешләрен, Космос асылы, әйләнә-тирә дөньяны аңлату, беренчел тереклекне эзләү, ә фәлсәфәләү методы – үз карашларын игълан итү, аларны догмага әйләндерү

Әлеге чорны билгеләүче «сократка чаклы» фәлсәфәчеләр

— Милет мәктәбе – «физиклар» (Фалес, Анаксемандр, Анаксимен);

— Гераклит Эфесский;

— Элей мәктәбе;

— Атомистлар (Демокрит, Левкипп);

— Башка төр фәлсәфәчеләр.

Фәлсәфә бүлеге

Классик (Сократ) чоры (б.э.кадәр V башы – IV гасырлар ахыры) – борынгы грек фәлсәфәсе чәчәк аткан чор (борынгы грек полислары чәчәк ату белән туры килә).

Төп юнәлешләр

— Сократ фәлсәфәсе;

— «Сократ» мәктәбе барлыкка килү;

— Платон фәлсәфәсе;

— Аристотель фәлсәфәсе.

Табигать асылы һәм классик чордагы космосмәсьәләләрен карауда аерымлыклар

— Сократ чоры фәлсәфәчеләре башлангычны эзләү гәаз игътибар итә;

— Алла, табигать һәм космосның барлыкка килү идеясе булу ихтималлыгын кабул итә;

— Тереклекнең килеп чыгышы турында идеалистик юрама тәкъдим итәләр (Платон – реаль дөньяга кадәрге һәм реаль дөнья гәүдәләнеше булган «саф идеяләр» турындагы тәгълимат авторы).

Эллинистик чор (б.э. кадәр IV – II гасырлар) – полистагы кризис чоры һәм греклар һәм Александр Македонский һәм аның варислары җитәкчелегендә Азиядә һәм Африкада эре дәүләтләр барлыкка килүе

Төп юнәлешләр

— Кинилларның җәмгыятькә каршы фәлсәфәсе таралуы;

— Фәлсәфәнең стоик юнәлеше барлыкка килү;

— «Сократик» фәлсәфә мәктәпләре эшчәнлеге: Платон академиясе, Ликей, Аристотель, киренаиклар;

— Эпикур фәлсәфәсе һ.б.

Үзенчәлекләр

— Антик мораль һәм фәлсәфи кыйммәтләр;

— Алла һәм башка гадәттән тыш көчләр алдындагы куркуны киметү; аларга ихтирам;

— Элгәре авторитетларны инкарь итү, дәүләткә һәманың институтларына карата кимсетеп карау;

— Үз-үзеңә физик һәм рухи таяныч эзләү;

— Чынбарлыктан ваз кичүгә омтылу;

— Дөньяга материалистик күзлектән карауны өстенлек бирүе (эпикур);

Аерым кеше бәхете һәм канәгатьләнүен югары байлык итеп кабул итү (физик – киренаиклар, мораль – Эпикур).

Рим чоры (б.э.кадәр I гасыр – б.э.ның V гасыры)

Танылган фәлсәфәчеләр

— Сенека;

— Марк Аврелий (Рим императоры 161 – 180еллар);

— Тит ЛукрецийКар;

— Соңгы стоиклар;

— Беренче христиан-нар.

Үзенчәлекләр

— Борынгы грек һәм борынгы рим фәлсәфәсенең үзара йогынтысы (борынгы грек фәлсәфәсе рим дәүләтчелеге кысаларында үсеш һәм үзендә аның йогынтысын кичерә, ә шул вакытта борынгы рим фәлсәфәсе борынгы грек фәлсәфәсе идеяләре һәм традицияләрендә үсә);

— Борынгы грек һәм борынгы рим фәлсәфәсенең бергә фактик кушылуы антик фәлсәфә;

— Антик фәлсәфәгә яулап алынган халыклар традицияләре һәм идеяләренең йогынтысы (Көнчыгыш, Төньяк Африка һ.б.);

— Фәлсәфә, фәлсәфәчеләр һәм дәүләт институтларының якынлыгы (Сенека Рим император Нейронны тәрбияли, Марк Аврелий үзе император була);

— Әйләнә-тирә табигать мәсьәләләренә зур булмаган игътибар;

— Кеше, җәмгыять, дәүләт проблемаларына зур игътибар;

— Эстетиканың чәчәк атуы (фәлсәфә, аның предметы – кеше фикерләре һәм тәртибе);

— Стоитик фәлсәфәнең чәчкә атуы, аның яклылар югары байлык һәм яшәү мәгънәсе, шәхеснең рухи үсеше, белеме, үз-үзенә китүендә, тынычлыгында (атароксия);

— Идеализмның материализмнан югарырак булуы;

— Күпчелек табигать күренешләрен Аллаһ кушуы буенча баруы белән аңлатыла;

— Үлем һәм теге дөньядагы тормышка кызыксыну арту;

— Фәлсәфәдә христиан динен һәм беренче христианнар ересенә игътибар үсүе;

— Антик һәм христиан фәлсәфәсенең тора-бара кушылуы, аларның урта гасыр технологик фәлсәфәгә әверелүе.

§13. Борынгы Грециянең беренче фәлсәфи(сократка кадәрге) мәктәпләре

1. Сократка кадәрге фәлсәфә мәктәпләренә гомум төшенчә

Сократка кадәрге мәктәпләр б.э.кадәрге VI–IV гасырларда беренче аякка басу процессында булган борынгы грек полисларында барлыкка килә.

Борынгы Грециянең танылганрак беренче мәктәпләре

— Милет мәктәбе;

— Пифагорчылар мәктәбе;

— Гераклит Эфесский мәктәбе;

— Элей мәктәбе;

— Атомистлар

Үзенчәлекләр

— Чагу гәүдәләнгән космоцентризм;

— Табигать күренешләрен аңлату фәлсәфә тәэсиренең артуы

— Барлык тереклекнең беренчелен эзләү,

— Гилозоизм (җансыз табигатьне сынландыру);

— Фәлсәфә тәгълиматының доктриналы (бәхәссез) характеры.

2. Милет мәктәбе («физиклар») – Фалес, Анаксимандр, Анаксимен

Милет мәктәбе Борынгы Грециянең б.э.ның VI гасырында барлыкка килеп, исемен нигез салынган шәһәр атамасыннан ала – Милета – Кече Азиядәге эре сәүдәһөнәри полис.

Үзенчәлекләр

— материалистик позициядән чыгыш ясыйлар;

— фәлсәфә белән генә түгел, башка төгәл һәм табигый фәннәр белән шөгыльләнә;

— табигать законнарын аңлатырга тырышалар(шуның өчен үзләренә икенче атама – «физиклар») алалар;

— әйләнә-тирә дөнья барлыкка килгән беренчел субстанцияне эзлиләр.

Вәкилләр

Фалес (якынча 640–560 еллар) – милет мәктәбенә нигез салучы, танылган грек галимнәренең һәм фәлсәфәчеләренең берсе. Фалес – фәндә һәм фәлсәфәдә тирән эз калдырган шәхес.

Анаксимандр (б.э. кадәр 610–540 еллар), Фалесның укучысы.

Анаксимен (б.э. кадәр 546–526 еллар) – Анаксимандрның укучысы.

Фалесның төп карашлары

— Су бар нәрсәгә беренчел су дип исәпләгән («архэ»);

— Җирне суда яткан тигез диск рәвешендә күзаллаган;

— Җансыз табигать, барлык әйберләрнең җаны бар дип исәпли (ягъни гилозоист булган – бар нәрсәне җанландырган);

— Күп аллалар булу ихтималлыгын иккарь итми;

— Галәм үзәге ул – Җир дип исәпли

— Ел дәвамлыгын төгәл билгеләгән – 365 көн;

— Байтак математик ачышлар ясый (Фалес теоремасы һ.б.).

Анаксимандрның төпкарашлары

— Барлык нәрсәнең башлангычы дип «апейрон»ны исәпли – мәңгелек, исәпләп булмый торган, чиксез субстанция, бар нәрсә аңардан башлана, тора һәм аңа әйләнә;

— материяне саклау законын чыгара (әйберләрнең атомар төзелешен ача дисәң дә була): барлык тереклек, барлык әйберләр микрос-копик элементлардан тора; тере организмнарның үле-меннән соң, әйберләр таркалып, элементлар («атомнар») кала һәм яңа комбинацияләр нәтиҗәсендә яңа әйберләр һәм тере организмнар барлыкка килә;

— Беренче булып кешенең эволюция нәтиҗәсендә башка хайваннардан килеп чыгышы турындагы идеяне тәкъдим итә (Ч. Дарвин тәгълиматын алдан ук күргән).

Анаксименның төп карашлары

— Беренчел сәбәп итеп һаваны исәпли;

— Җирдәге барлык әйберләр – һаваның төрле дәрәҗәдәге оешканлыгы нәтиҗәсендә барлыкка килә дигән идеяне тәкъдим итә (һава кысылганда башта суга әйләнә, аннары ләмгә,алга таба – туфракка, ташка һ.б.);

— Кеше рухы («психэ») һәм һава («пневма») – «космос (галәм) җаны» арасында паралельләр үткәрә;

— Аллаларны табигать көчләре һәм күк җисемнәре белән тиңли.

3. Гераклит Эфесский

Эфестагы Гераклит (б.э. кадәрге VI гасырның икенче яртысы – V гасырның башы) –күренекле борынгы грек материалист-фәлсәфәчесе, фәлсәфә юнәлешенә нигез салучы (иң элек мантыйк мәктәбенә керә)

Төп карашлар

— Барлык нәрсәнең башлангычы – ут;

— Берлек һәм капма-каршылык законын чыгара – диалектиканың төп законы (Гераклитның фәлсәфи ачышларының иң мөһиме);

— Барлык дөнья даими хәрәкәттә һәм үзгәрештә була дип исәпләгән («бер үк елгага ике тапкыр кереп булмый»);

— Табигатьтәге һәр әйбер әйләнештә һәм тарихның цикллы булуын яклый;

— Әйләнә-тирә дөньяның чагыштырмача булуын таный («диңгез суы кеше өчен пычрак, ләкин балыклар өчен чиста», төрле ситуацияләрдә бер үк кеше хәрәкәтеяхшы да яман да булырга мөмкин);

— Бөтенесен эченә ала торган, һәр нәрсәгә иңә алучы алла дип Логосны исәпли –Дөнья Акылы;

— Кеше һәм дөнья җанының материальлеген яклый;

— Әйләнә-тирә чынбарлыкны хисси (материаль) танып белүне яклы;

— Барлык процессларның этәргеч көче ул – көрәш: «Сугыш (көрәш) бар нәрсәгә атада анада».

4. Пифагорчылар

Пифагорчылар – борынгы фәлсәфәче һәм математик Пифагорның варислары һәм дәвамчылары (б.э. кадәрге VI гасырның икенче яртысы – V гасыр башы).

Төп карашлар

— Барлык тереклекнең беренчел сәбәбе сан дип исәплиләр (барлык чынбарлыкны,барлыкка килгәннән һәр нәрсәне санга тоташтырып, саннар ярдәмендә исәпләп була);

— Сан аша танып белү өчен чыгыш ясыйлар (танып-белү вакытында сан хисси һәмидеалистик аң арасындагы урталыктагы төшенчә дип исәпләгәннәр);

— Берне барлык нәрсәнең иң кече кисәкчәсе дип саныйлар;

— «Протокатегория»ләр бүлеп чыгаралар, алар дөньяның диалектик берлеген күрсәтә (җәп – так, якты – караңгы, туры – кыек, уң – сул, ирләр – хатын-кызлар һ.б.).

5. Элеатлар

Элеатлар – элея фәлсәфә мәктәбе вәкилләре, б.э. кадәрге VI–V гасырларда хәзерге Италия территориясендә урнашкан борынгы грек полисы Элеядә яшәгәннәр.

Бу мәктәпнең танылган фәлсәфәчеләре

— Парменид;

— Зенон Элейский;

— Мелисс Самосский.

Төп карашлар

— Танып-белү мәсьәләсен өйрәнәләр;

— Хисси танып-белүне (фикер, «докса») һәм югары рухи идеальгә кискен бүләләр;

— Монизм яклы булалар – күп күренешләрнең барысын да бер башлангычтан чыгаралар;

— Барлык нәрсәләрне идеянең материаль гәүдәләнеше дип исәплиләр (идеализмны алдан хәбәр итүчеләр була).

6. Атомистлар

Атомистлар – материалистик фәлсәфә мәктәбе, аның фәлсәфәчеләре (Демокрит, Левкипп) барлык нәрсәнең «төзелеш материалы», «беренчел кирпече» итеп микроскопик кисәкчекләрне – «атомнар»ны исәплиләр. Демокрит фәлсәфәнең материалистик юнәлешенә нигез салучы дип исәпләнә («Демокрит линиясе» – «Платон линиясенә» капма-каршы – идеалистик юнәлешкә).

Демокрит тәгълиматының төп положениесе

— Барлык материаль дөнья атомнардан тора;

— Атом – барлык нәрсәнең иң кече кисәкчеге, «беренчел кирпече»;

— Атом бүленми (бу фән белән күптән түгел генә инкарь ителде);

— Атомнар төрле зурлыкта (кечкенәдән эреләргә кадәр), төрле формада (түгәрәк, озынча, кыек, «элмәкле» һ.б.) була;

— Атомнар арасында бушлык белән тутырылган киңлек бар;

— Атомнар мәңгелек хәрәкәттә;

— Атомнар әйләнеше бар: әйберләр, тере организмнар яши, таркала, моңардан соң шул ук атомнардан яңа организмнар һәм материаль дөнья предметлары барлыкка килә;

— Атомнарны хисси танып-белү юлы аша «күреп» булмый.

§14. Софистлар һәм Сократ фәлсәфәсе

1. Софистиканың гомуми төшенчәсе

Софистлар – б.э. кадәрге V – IV гасының беренче яртысында яшәгән Борынгы Грециянең фәлсәфә мәктәбе. Бу фәлсәфә вәкилләре фәлсәфәче-теоретик булып кына түгел, фәлсәфәче-педагоглар булып чыгыш ясыйлар, алар гражданнарны фәлсәфәгә, ораторлык сәнгатенә һәм башка төр белемнәргә өйрәтәләр (грек теленнән «софистлар» – акыл ияләре, акыл бирүче остазлар).

Софистлар вәкилләре

— Өлкән софистлар (б.э. кадәрге V гасыр) – Протагор, Горгий, Гиппий, Продик, Антифонт, Критий;

— Кече софистлар – Ликофрон, Алкидамант, Трассимах;

— Сократ рәсми рәвештә бу төркемнәргә керми, әмма софистларның күп идеяләрен уртаклаша һәм софистиканы практик эшчәнлектә куллана.

Үзенчәлекләр

— Әйләнә-тирәдәге чынбарлыкка тәнкыйди мөнәсәбәт;

— Барысын да гамәлдә тикшереп карарга омтылу, теге яки бу дөрес яки ялган фикерне мантыйк ярдәмендә дәлилләү;

— Иске, традицион цивилизация нигезләрен кабул итмәү

— Иске традиция, гадәт, дәлилләнмәгән белемгә нигезләнгән карыйдәләрне инкарь итү;

— Дәүләт һәм хокукның шартлылыгын, аларның камил булмавын дәлилләргә омтылу;

— Әхлак нормаларын абсолют барлык итеп түгел, әтәнкыйть предметы итеп кабул итү;

— Бәяләү һәм фикер йөртүдәге субъектив, объектив яшәешне инкарь итү һәм чынбарлыкның тик кеше фикерендә генә яшәгәнен дәлилләргә тырышу.

Софистларның төп мантыйк ысулы булараксофизм

— Үзләренең хаклы икәнен әлеге фәлсәфә вәкилләре софизмнар – мантыйк ысуллары, әмәлләр ярдәмендә дәлилләгән. Алар ярдәмендә беренче карашка дөрес тоелган сөзем тә ахырда ялган булып чыга һәм әңгәмәдәш үз фикерләрендә бутала.

— Әлеге сөзем тәгә «мөгезле» софизм мисал булып тора: «Нәрсәне син югалтмадың, син шуңа иясең; мөгезеңне югалтмадың, димәк, синең мөгезең бар».

— Әлеге нәтиҗә пародокслар, софизмның логик авырлыгы нәтиҗәсендә ирешелми, ә логик мәгънәле операцияләрне корректкулланмаганлы- ктан килеп чыга. Әйтелгән софизмда беренчесе ялган, тик дөрес дип тәкъдим ителә, моннан нәтиҗә дә инде.

Софистлар эшчәнлегенең әһәмияте (софистларның эшчәнлеге хакимиятнең дә, башка фәлсәфә мәктәпләре вәкилләренең хупланмавына карамастан, алар грек фәлсәфәсе һәм мәдәниятенә зур өлеш керттеләр.

— Әйләнә-тирәдәге чынбарлыкка тәнкыйди карый алдылар;

— Алар грек полисларындагы гражданнарга күп фәлсәфи һәм башка белемнәр тараттылар (моның өчен алар киләчәктә грек мәгърифәтчеләре дип йөртеләчәк).

2. Протагор фәлсәфәсе

Протагор (б.э кадәрге V гасыр) – өлкән софистларның танылган вәкиле.

Үзенең фәлсәфи кредосын Протагор түбәндәге юлларда билгеләгән: «Кеше барлык булган әйберләрнең булганы булган дип, булмаганы бул маган дигән үлчәм» софистлар, бу әйләнә-тирә чынбарлыкны, яхшыны һәм яманны бәһалау критерие буларак, кешенең субъетив фикерен тәкъдим итте.

Протагорның замандашларының берсенә «Ике төрле сөйләм» әсәрен иҗат иткән дип күрсәтелә, ул шулай ук яшәеш һәм танып белүнең чагыштырмалы булуы фикерен китерә («Чир чирлеләр өчен явызлык, ә табибларга бәхет»; «Үлем үлгән өчен явызлык, тик каберче һәм табутчыга бәхет) һәм яшь кешене бәхәстә җиңәргә өйрәтә.

Протагорның аллаларга карата мөнәсәбәте ул вакытлар өчен ори- гиналь һәм революцион яңгырый: «Аллалар турында мин белә алмыйм, бармы алар, юкмы, шуңа күрә мондый белемгә бик күп нәрсә комачаулый – бу мәсьәлә караңгы һәм кеше гомере дә кыска».

Протагорның төп фәлсәфи положениесе

— Кеше аңыннан башка берни дә юк;

— Бүген кеше өчен нәрсә яхшы, шул чынбарлыктагы яхшылык була да инде;

— Бүген яхшы булган иртәгә яманга әйләнә икән, димәк, ул чынбарлыкта зыянлы һәм яман;

— Барлык әйләнә-тирә кешенең хисси кабул итүеннән тора («Сәламәт кешегә татлы тоелган, сырхауга ачы тоелачак»);

— Әйләнә-тирә дөнья чагыштырмача;

— Объектив (хакыйкый) танып белүнеаңлап бетеп булмый;

— Фикерләр дөньясы гына яши.

3. Сократ фәлсәфәсе

Сократ (б.э. кадәрге 469 – 399 гг.) – софистикага мөнәсәбәте булган ихтирамга лаек фәлсәфәчеләрнең берсе.

Үзенчәлекләр

Сократ ул кадәр әһәмиятле фәлсәфи әсәрләр калдырмаган, әмма тарихка күренекле бәхәсче, акыл иясе, укытучы фәлсәфәче буларак кереп калаган.

Төп методы, «майевтика» дип исем алган. Аның асылы – хакыйкатькә өйрәтү түгел, мантыйк ысуллары аша, ишарә сораулары ярдәмендә әңгәмәдәшне мөстәкыйль рәвештә хакыйкатьне табарга юнәлтү.

Сократ үзенең фәлсәфә һәм мәгърифәт эшен халык арасында, мәйданнарда, базарларда ачыктан-ачык алып бара (диалог, бәхәс формаларында), аның шул чорда һәм бүген дә көнүзәк мәсьәләләр булган темалары була: яхшылык, явызлык, мәхәббәт, бәхет, намус һ.б.

Фәлсәфәче этик реализм яклы була, аңа ярашлы:

— теләсә кайсы белем – ул яхшылык;

— теләсә кайсы яманлык, бозыклык белемсезлек нәтиҗәсендә эшләнә.

Сократ рәсми хакимият тарафыннан аңлауга ирешә алмый һәм, гадәттәгечә, җәмгыятьне таркатучы, яшьләрне юлдан яздыручы һәм аллаларны санга сукмаучы софист буларак кабул ителә. Моның өчен ул б.э.кадәр 399 елда үлемгә хөкем ителә һәм агулы цикута эчә.

Сократ эшчәнлегенең тарихи әһәмияте

— Белем таратуга, гражданнарны агартуга булышлык итә;

— Кешелекнең мәңгелек сорауларына җавап эзли – яхшылык һәм яманлык, мәхәббәт, намус һ.б.;

— Заман мәгърифәтендә киң кулланылган майевтика методын ача;

— Хакыйкать табуның диалогик методын кертә – элгәре фәлсәфәчеләре кебек декла-рацияләү аша түгел, ирекле бәхәстә аны дәлилләү юлы аша;

— Бик күп укучылар (аның эшен дәвам итүчеләр) тәрбияләп чыгара, (мәсәлән, Платон), шуларның күбесе «Сократ мәктәпләре» нигезендә тора.

4. Сократ мәктәпләре

«Сократ мәктәпләре» – Сократ идеяләре йогынтысында һәм аның укучылары үстергән фәлсәфи тәгълимат.

Платон академиясе – Платон тарафыннан б.э.кадәр 385 елда төзелгән һәм б.э.ның VI гасырына кадәр яшәүче (мең ел тирәсе) дини-фәлсәфи мәктәп, аның максаты – фәлсәфә мәсьәләләрен тикшерү, Аллаһ һәм музаларны олылау.

Киниклар – фәлсәфи мәктәп, ул җәмгыятьтән тыш, азатлык идеясен дәлилли (асоциаль азатлык). Аның вәкилләре үзләренең фәлсәфи эзләнүләрен үзләрендә тикшерә. Киниклар паразитар, сукбай тормышы алып баралар, гаиләләре булмаган, дәүләткә һәм законга илтифат итмиләр, традицион мәдәният, әхлак, байлыкка каршы нәфрәт кичерәләр, кеше бозыклыгына игътибарны юнәлтәләр. Аларның иң күренеклеләре – Антисфен, Диоген Синопский (Платон тарафыннан «Акылдан язган Сократ» дип аталган).

Кирен мәктәбенә Сократның шәкерте Аристипп тарафыннаң б.э. кадәр IV гасырда нигез салына.

Шушы мәктәп вәкил- ләренең төп карашлары

— Табигатьне өйрәнүгә каршы чыгалар;

— Иң югары рәхәтлек дип ләззәтне исәпләгәннәр;

— Тормыш максаты – ләззәттә, бәхет ләззәт җыелмасы буларак, байлыкны ләззәткә ирешү чарасы буларак кабул итәләр.

Мегар мәктәбенә Сократның Мегардагы Евклид исемле укучысы нигез сала. (б.э. кадәр IV гасыр). Вәкилләре – Евклид, Диодор Крон.

Үзенчәлекләре

— Мегарчылар югары абстракт рәхәтлек бар дип исәп-ли, аны төгәл сурәтләп булмый – Аллаһ, аң, яшәү энергиясе. Югары рәхәтлекнең (абсолют явызлык) капма-каршысы булмый.

— Фәлсәфи теоретик эзләнүләрдән тыш мегарчылар актив гамәли эшчәнлек тә алып баралар (асылда, софистика белән шөгыльләнәләр) һәм «бәхәсчеләр» дигән кушамат алалар.

— Мегар мәктәбе вәкилләре (Евбулид) танылу алган апорияләр авторларын әйләнәләр, ягъни парадокслар (софизмнар белән бутамаска), – «Өем» һәм «Пеләш», алар ярдәмендә санның сыйфатка күчеш диалектикасын аңларга тырышканнар.

— «Өем» апориясе: «Әгәр җиргә орлык ташласаң һәмаңа берәр орлык өстәп торсаң, кайчан бу урында өем барлыкка киләчәк? Орлык тупланмасы бер орлык кушканнан соң өемгә әйләнә аламы?»

— «Пеләш» апориясе: «Әгәр кешенең башыннан берәр чәче төшеп торса, кайчан ул пеләшкә әйләнәчәк? Конкрет чәчне билгеләү мөмкинме, ул төшкәннән соң кеше пеләшкә әйләнәчәк? «Әле пеләш түгел» белән «пеләш инде» арасында чик куюы мөмкинме?

§15. Киниклар һәм стоиклар фәлсәфәсе

1. Киник фәлсәфәсенең гомуми төшенчәсе

Киниклар – Борынгы Грециянең сократ чорындагы фәлсәфә мәктәпләренең берсе. Кинихларның фәлсәфәсенә хас сыйфатлар һәм яшәү рәвеше:

— абсолют асоциаль азатлыкка күтәрелү (ягъни җәмгыятьтән тыш азатлык);

— ирекле читкә кагылганлык, социаль элемтәләрне өзү, ялгызлык;

— даими яшәү урыны булмау, гизүчәнлек;

— паразитар яшәү рәвеше, теләнчелек;

— иң яман тормыш шартларына, иске, таушалган киемгә өстенлек бирү. Гигиенагатүбәнсетеп карау;

— физик һәм рухи ярлылыкны мактау;

— чиксез аскетлык;

— йомыклык;

— башка фәлсәфи тәгълиматларны инкарь итү һәм тәнкыйтьләү, аеруча идеолистикларны;

— авторитетларны кабул итмәү;

— үз карашыңны һәм тормыш рәвешеңне яклаганда сугышка әзер булу һәм агрессия;

— бәхәскә тискәре карау, әңгәмәдәшне басарга тырышу;

— патриотизм юклыгы, теләсә кайсы җәмгыятьтә үз законнары буенча яшәргә әзертору;

— игътибарны җәмгыятьнең бозыклыгына, кешенең яман сыйфатларына юнәлтү;

2. Синоп Диогены

Синоп Диоген (яшәү еллары төгәл билгеле түгел, б.э. кадәр IV гасыр, Александр Македонский замандашы) – киник фәлсәфәсенең билгеле теоретигы һәм практигы. Бу фәлсәфә мәктәбенә исемне дә ул биргән дип исәпләнелә (чөнки Диогенның тагын бер кушаматы – «кинос», «эт», ул грекча «киник» сүзенә аваздаш). Чынбарлыкта исә – «Киносарг» сүзеннән – Афинадагы калкулык һәм гимназия.

Диоген фундаменталь фәлсәфи хезмәтләр калдырган, тик тарихка үзенең анекдотлы, җәнҗаллы холкы һәм яшәү рәвеше белән, шулай ук әйткән сүзләре һәм идеяләре белән кереп калган:

— мичкәдә яшәгән;

— патша Александр Македонскийга әйткән: «Кырайчарак кит һәм миңа кояшны каплама!»;

— лозунг чыгара: «Общинасыз, йортсыз, ватансыз» (ул аның һәм дәвамчыларның тормыш һәм фәлсәфә кредосына әйләнә);

— «дөнья гражданины» (космополит) төшенчәсен чыгара;

— никахны кире кага;

— традицион тормыш рәвеше яклылардан ачы итеп көлә;

— табигать законнарыннан тыш, бернинди дә законнарны танымый;

— теләнче булып яшәп, тышкы дөньядан бәйсез булуы белән горурлана;

— борынгы кеше һәм хайваннарны идеальләштерә.

3. Стоиклар фәлсәфәсенә гомуми характеристика

Стоиклар фәлсәфә мәктәбе, аның барлыкка килүе һәм үсеше киниклар идеясе таралуына җавап була («Стоя» – Афинадагы бина исеме). Зенон Китайский аңа нигез сала (Зенон Элейский белән бутамаска, «апорий» – парадокслар авторы).

Стоик фәлсәфә үз үсешендә берничә этап үтә.

— яшь стоя (б.э. кадәр III – II гасырлар), вәкилләр – Зенон, Клеанф, Хрисипп һәм башкалар;

— урта стоя (б.э. кадәр II – I гасырлар) – Панеттий, Посидоний;

— соңгы стоя (б.э. кадәр I гасыр – ю.э. III гасыр) – Сенека, Эпиктет, Марк Аврелий.

Стоиклар фәлсәфә мәктәбенең төп идеясе (киниклар фәлсәфәсенең төп идеясе белән охшаш) – тышкы дөнья йогынтысыннан азат булу. Әмма тышкы дөнья йогынтысыннан азат булуны традицион мәдәният кыйммәтләреннән, асоциаль яшәү рәвешеннән (теләнчелек, сукбайлык, һ.б.) баш тарту дип билгеләгән киниклардан аермалы буларак, стоиклар бу максатка ирешүне башка юлны таба – даими камилләшү, традицион мәдәният казанышларын кабул итү, акыл.

Тышкы дөнья йогынтысыннан, тормышның мәшәкатьләреннән мәгърифәтлелек, белем, гаделлеге һәм ваемсызлыгы, эчке бәйсезлеге аркасында котылган акыл иясе стоиклар идеалы була.

Стоик фәлсәфәсенең үзенчәлекле сыйфатларына түбәндәгеләр керә:

— табигать һәм Дөнья Галәм Акылы (Логос белән) килешеп яшәүгә чакыру;

— саф күңеллелек – югары байлык, әбозыклык – бердәнбер явызлык;

— саф күңеллелекне яхшылык һәм явызлык буларак билгеләү һәм яхшылык артыннан бару;

— саф күңеллелеккә җанның даими торышы һәм әхлакый ориентир буларак өндәү;

— рәсми законнарны һәм дәүләт хакимиятен алар гадел булганда гына кабул итү;

— дәүләт тормышына катнашмау (үзен үзе чыгару), законнарны, традицион фәлсәфә һәм мәдәниятне инкарь итү, әгәр дә алар явызлыкка хезмәт итә икән;

— үз-үзенә кул салучыларны аклау, әгәрдә алар гаделсезлеккә, явызлыкка һәм бозыклыкка каршы эшләнелсә;

— байлык, сәламәтлек, матурлык белән соклану, дөнья мәдәниятның иң яхшы казанышларын үзләштерү;

— уйларда һәм гамәлләрендәге югары эстетизм;

— хәерчелекне, чирләрне, сукбайлыкны, сораучанлыкны, кеше бозыклыкларын гаепләү;

— бәхеткә омтылуны кешенең иң югары максаты итеп тану.

4. Сенека и Марк Аврелий фәлсәфәсе

Стоик фәлсәфәнең иң танылган вәкилләре – Сенека и Марк Аврелий

Сенека (б.э. кадәр 5 ел – б.э.ның 65 елы) – күренекле рим фәлсәфәчесе, Нерон императорының тәрбиячесе, аның идарә итү чорында ул дәүләт эшләренә көчле һәм уңай йогынты ясый. Нерон яман сәясәт алып бара башлагач, Сенека дәүләт эшләреннән китә һәм үзенә кул салып үлә.

Төп карашлары:

— саф күңеллелек, гаделлек идеяләрен тарата;

— җәмгыять тормышында катнашмаска һәм үзендә генә, рухи халәттә тотырга чакыра;

— тынычлык һәм күзәтүне хуплый;

— дәүләткә сизелми торган, әмма индивидка шатлыклы булган тормыш яклы була;

— кешенең һәм, гомумән, кешелекнең чиксез үсешенә ышана, мәдәни һәм техник прогрессны күзаллый алган;

— дәүләт белән идарә итүдә фәлсәфәчеләр һәм акыл ияләренең әһәмиятен арттырып җибәрә, гади һәм надан кешеләрне, «көтү»не күрә алмый;

— әхлакый идеал һәм кеше бәхетен югары рәхәтлек дип санаган;

— фәлсәфәдә теоретик система түгел, ә дәүләт, җәмгыять процесслары, тормышта кешеләрнең бәхеткә ирешү буенча гамәли җитәкчелек белән идарә итү.

Марк Аврелий Антонин (б.э.ның 121 – 180 еллары) – күренекле рим стоик-фәлсәфәчәсе, 161 – 180 елларда – Рим императоры. «Үз-үземә» фәлсәфи әсәрен язган.

Төп идеяләр:

— Аллаһка карата тирәнтен шәхси хөрмәт мөнәсәбәте;

— Аллаһны югары дөнья башлангычыитеп тану;

— Аллаһны бөтен дөньяны берләштерүче һәм аның барлык өлешләренә үтеп керә алучы матди-рухи көч буларак аңлау;

— әйләнә-тирәдәге барлык вакыйгаларны Илаһи Теләк белән аңлату;

— һәр дәүләт башлангычы, шәхси уңыш, бәхетнең уңышының төп сәбәбе Илаһи көчләр белән хезмәттәшлегендә дип күрү;

— кеше акылына буйсынмаучы тышкы дөньяны һәм кеше хакимлегендәге генә булган эчке дөньяны бүлеп карау;

— аерым кеше бәхетенең төп сәбәбе– аның эчке дөньясын тышкы дөньябелән яраштыруга китерү;

— җан һәм акылны бүлү;

— тышкы хәлләргә каршы тормаска чакыру, язмышка буйсыну;

— кеше гомеренең чикле булуы турында фикерләү, мөмкин кадәр тормышның кадерен, кыйммәтен белергә өндәү;

— әйләнә-тирә чынбарлыкка карата пессимистик караш өстенлеге.

§16. Платон фәлсәфәсе

1. Платон шәхесе һәм иҗатына гомуми характеристика

Платон (б.э. кадәр 427 – 347 еллар) – иң күренекле Борынгы Греция фәлсәфәчесе, Сократның укучысы, үз фәлсәфә мәктәбенә – Академиягә нигез салучы,фәлсәфәнең идеалистик юнәлешенә нигез салучы.

Үзенчәлекләр:

— Платон – үзе артыннан тулы зур фәлсәфә әсәрләре авторы беренче борынгы грек фәлсәфәчесе. Аның язмалары арасында иң күренекле әсәрләре – «Сократ Апологиясе», «Парменид», «Горгий», «Федон», «Дәүләт», «Законнар».

— Күпчелек Платон әсәрләре диалог формасында язылган.

— Платон идеализмга нигез салучы.

Аның идеалистик тәгълиматының төп кагыйдәләре:

— матди әйберләр үзгәреп тора, даими түгел һәм вакыт белән үзенең яшәешен туктата. Идеалистик тәгълиматының төп положениеләре түбәндәгечә

— «әйләнә-тирә дөнья» («әйберләр дөньясы») шулай ук вакытлы гына һәм үзгәрешле һәм чынбарлыкта аерым субстанция буларак бар булмый;

— реаль нибары саф («тәнсез») идеяләр (эйдослар) генә яши;

— саф (тәнсез) идеяләр хак, мәңгелек һәм даими;

— теләсә кайсы әйбер беренчел идеянең (эйдосның) материаль чагылышы була (мәсәлән, атлар туалар да үләләр, тик алар атлар идеясенең чагылышы гына, ул мәңгелек һәм үзгәрешсез һ.б.);

— бар дөнья саф идеяләр (эйдослар) чагылышы.

2. Платонның триада турындагы тәгълиматы

Платонның триада (өч өлеш бердәлелеге) турындагы тәгълиматына ярашлы барлыкхакыйкый әйберләр өч субстанциядән тора

«Бердәм»

Үзенчәлекләр:

— теләсә кайсы яшәешнең нигезе була;

— бернинди билгеләре юк (башлангычы да, ахыры да, өлеше дә, тулылыгы да, формасы да, эчтәлеге дә һ.б.);

— һични түгел;

— теләсә кайсы яшәештән, фикерләүдән, хис-тойгыдан югарырак;

— бар нәрсәнең – барлык идея, әйбер, күренеш, үзенчәлекләр (кеше күзлегеннән яхшы яки яман булган һәрнәрсәнең) башлангычы.

«Акыл»

Үзенчәлекләр:

— «бердәмнән» барлыкка килә;

— «бердәм» белән аерылган;

— «бердәмгә» капма-каршы куелган;

— барлык әйберләрнең асылы булып тора;

— Җирдәге һәр тереклекнең гомуми нәтиҗәсе була.

«Рух»

Үзенчәлекләр:

— хәрәкәтчән субстанция, ул «бердәм – һични»не һәм «акылбар тереклек»не берләштершә һәм бәйли, шул ук вакытта бөтен әйберләрне һәм күренешләрне үзара бәйли;

— Платонга ярашлы җандөньяви һәм аерым кеше җаны булырга да мөмкин; гилозоик (җанлы) якынаю юлы булганда әйберләр һәм җансыз табигать тә җанлы булырга мөмкин;

— кеше җаны (әйберләр) дөнья җаныныңбер өлеше;

— җан үлемсез;

— кеше үлгәндә тик тәне генә үлә, җан, үзенең җирдәге гамәлләре өчен теге дөньяда җавап тотып, яңа тән кабыгы ала;

— җанның даимилеге һәм тән формалары алмашы – Галәмнең (Космос) табигый законы.

3. Платон фәлсәфәсендә дәүләт мәсьәләсе

Дәүләт мәсьәләсе (Платон фәлсәфәсендә мөһим роль уйный. Фалес, Гераклитның «Сократка кадәргеләргә» һ.б., дөньяның башлангычын эзләү һәм әйләнә-тирә табигать күренешләрен аңлату белән шөгыльләнә, әмма җәмгыятьне түгел).

Платон буенча яшәп килүче дәүләтләр төрләре:

— монархия – бер кешенең гадел хакимлеге;

— тирания – бер кешенең гадел булмаган хакимлеге;

— аристократия – азчылыкның гадел хакимлеге;

— олигархия – азчылыкның гадел булмаган хакимлеге;

— демократия – күпчелекнең гадел хакимияте;

— тимократия – күпчелекнең гадел булмаган хакимияте, хәрби башлыклар, армия хакимияте.

Тирания, олигархия һәм тимократия гадел булмаган дәүләт белән идаре итү рәвешле булганга күрә, ә демократия бик сирәк очракта гына гадел була һәм, гадәттә, тираниягә, олигархиягә яки тимократиягә әверелә, шуңа күрә дәүләт белән ике төрле генә стабиль һәм оптималь идарә рәвеше бар. Алар аристократия һәм монархия.

Платон тәкъдим иткән дәүләт төзелеше планы:

— дүәләтнең (полисның) барлык халкы өч катламга бүленә – фәлсәфәчеләр,хәрбиләр, эшчеләр;

— эшчеләр (крестьяннар һәм һөнәрчеләр) физик хезмәт белән шөгыльләнә, материаль байлыклар тудыра, чикләнгән күләмдә хосусый милеккә ия була ала;

— сугышчылар физик күнекмәләр белән шөгыльләнәләр, дәүләттә тәртип тоталар, кирәксә – хәрби хәрәкәтләрдә катнашалар;

— фәлсәфәчеләр (акыл ияләре) – фәлсәфи теорияләр эшләп чыгаралар, дөньяны танып беләләр, өйрәтәләр, дәүләт белән идарә итәләр;

— фәлсәфәчеләр һәм хәрбиләр хосусый милекле булырга тиеш түгел;

— дәүләттә яшәүчеләр бергә буш вакытларын үткәрә, бергә ашыйлар,бергә ял итәләр;

— никах юк, хатыннар һәм балаларуртак;

— коллар хезмәтен куллану хуплана, кагыйдә буларак, алар кулга алынган варварлар.

4. Платон фәлсәфәсенең әһәмияте

Платон академиясе – Платон тарафыннан 387 елда Афина янында төзелгән дини-фәлсәфи мәктәп, 1000 ел тирәсе яши (б.э. 529 елга кадәр).

— Түбәндәгеләр академиянең күренекле тәрбияләнүчеләре булды: Аристотель (Платонда укый, үз фәлсәфә мәктәбен төзи – Ликей), Ксенократ, Кратет, Аркесилай, Клитомах Карфагенский, Филон Ларисский (Цицеронның укытучысы).
— 529 елда византия императоры Юстиниан тарафыннан мәҗүсилек һәм «зыянлы» идеяләр таратучы буларак академия ябыла. Әмма үз тарихында платонизм һәм неоплатонизмның әйдәүче аурупа фәлсәфәсенә әйләнүенә ирешә.

5. Платон академиясе

Платон фәлсәфәсенең тарихи әһәмияте

— беренчегә фәлсәфәче тарафыннан тулы фундаменталь әсәрләр җыентыгы калдырыла;

— идеализмга башлангыч салына («Платон линиясе» дип аталган – материалистик «Демокрит линиясенә» капма-каршылык);

— беренчегә табигать кенә түгел, җәмгыять мәсьәләләре дә – дәүләт, закон, һ.б. тикшерелә;

— аңлы фикерләүгә нигез салына, фәлсәфи категорияләрне бүлүгә омтылыш ясала (торгынлык – үсеш, мәңгелек – вакытлы, тынычлыкта тору – хәрәкәт итүче, бүленми торган – бүленә торган һ.б.);

— фәлсәфи мәктәп төзелә (Академия), 1000 елга якын яшәп килә, биредә Платонның күренекле варислары үсеп чыга (Аристотель һ.б.).

§17. Аристотель фәлсәфәсенең

1. Гомуми кагыйдәләр

Аристотель (б.э. кадәрге 384 – 322 еллар) – классик чорның борынгы грек фәлсәфәчесе, Платон укучысы, Александр Македонскийның тәрбиячесе. Иң танылган әсәрләре «Органон», «Физика», «Механика», «Метафизика», «Җан турында», «Хайваннар тарихы», «Никомахов этикасы», «Риторика», «Политика», «Афина политаясы», «Шигърият».

Аристотель эшчәнлегенең төп этаплары

— б.э. кадәрге 367 – 347еллар (20 ел) – 17 яшеннән алып Платон академиясендә эшли һәм аның укучысы була (Платон үлгәнчегә кадәр);

— б.э. кадәрге 347 – 335еллар (12 ел) – Пелледә яши һәм эшли – Македония дәүләтенең башкаласында Филипп патша чакыруы буенча; Александр Македонскийны тәрбияли;

— 335 – 322 еллар – үз фәлсәфә мәктәбен төзи – Ликей (перипатетик мәктәп) һәм үлгәнчегә кадәр шунда эшли.

Аристотель бүлеп чыгарган фәлсәфә төрләре

— теоретик, яшәеш, яшәешнең төрле өлкәләре, барлык тереклекнең барлыкка килү, төрле күренешләр барлыкка килү мәсьәләләрен өйрәнә («беренчел фәлсәфә» исемен ала);

— практик – кеше эшчәнлеге, дәүләт төзелеше турында;

— поэтик.

— фәлсәфәнең дүртенче өлеше буларак Аристотель мантыйкны билгели дип исәпләнелә.

Аристотель фәлсәфәсенең тарихи әһәмияте

— «саф идеяләрне» тәнкыйтьләп, Платон фәлсәфәсенә төзәтмәләр кертә;

— дөнья һәм кешенең барлыкка килүенә материаль аңлатма бирә;

— 10 фәлсәфи категория бүлеп чыгара;

— яшәешкә категорияләр аша билгеләмә бирә;

— материя асылын билгели;

— 6 төр дәүләт бүлеп чыгара һәм идеаль тип – политиягә билгеләмә бирә;

— мантыйк үсешенә өлеш кертә (дедуктив метод төшенчәсен аңлата – аерымнан гомумигә, силлогизм системасын нигезли).

2. Аристотельнең Платонның «саф идеяләр» (эйдослар) турындагы тәгъли-матын тәнкыйтьләве. Яшәеш асылын аңлату ысулы буларак

Аристотель категорияләре

Аристотельнең Платонның «саф идеяләр» (эйдослар) турындагы тәгълиматын тәнкыйтьләве

Үзенчәлекләр:

— Яшәеш мәсьәләсен караганда, Аристотель Платон фәлсәфәсен тәнкыйтьләп чыгыш ясый, аңа ярашлы әйләнә-тирә дөнья «әйберләр дөньясына» һәм «саф идеяләр дөньясына» бүленә, әйберләр дөньясы гомумән һәм аерым алганда, «саф идея»нең материаль чагылышы гына була.

— Аристотель буенча, Платон идеяләр дөньясын реаль дөньядан тартып алган һәм саф идеяләрне әйләнә-тирә чынбарлыкка бәйсез карый, ә ул үзе дә бай характеристикага ия – озынлык, тыныч лык, хәрәкәт һ.б.

— Аристотельгә ярашлы, чынбарлык белән бәйләнмәгән саф идеяләр юк, аның чагылышы булып барлык әйберләр һәм материаль дөнья предметлары һәм әйберләре була.

— Мондый әйберләр индивидуум (тәрҗемәдә бүленешсез) дип атала, ягъни конкрет урында конкрет ат кына бар, ә ат гәүдәләнешен чагылдырган ат идеясе түгел, конкрет урында торган конкрет урындык, ә урындык идеясе түгел.

— Индивидуумнар башлангыч нигез була, ә индивидуумнарның төрләре һәм кавеме икенчел.

— Яшәеш саф идея (эйдослар) һәм аның материаль чагылышы (әйберләр) түгел икән, дигән сорау туа: «Нәрсә ул яшәеш?». Бу сорауга җавапны Аристотель яшәеш турындагы әйтем, ягъни категорияләр аша бирергә тырыша.

— Аристотель буенча яшәеш – ул күләм, урын, вакыт, мөнәсәбәт, хәлторыш, хәрәкәт, газап үзен-чәлекләренә ия асыл. Кеше яшәешнең аның асылынтүгел, үзенчәлекләрен генә үзләштерә ала.

Аристотельгә ярашлы категорияләр – ул әйләнә-тирә чынбарлыкны югары чагылдыру һәм гомумиләштерү, аңардан башка яшәеш үзе мәгънәсез

Аристотель бүлеп чыгарган 10 категория, алар яшәеш турындагы сорауларга җавап бирә, шул ук вакытта бер категория яшәеш нәрсә икәнен әйтә, ә калганнары аны характерлый.

— Асыл (субстанция)

— сан

— сыйфат

— мөнәсәбәт

— урын

— вакыт

— дәрәҗә

— хәл-торыш

— хәрәкәт

— газап

Аристотель фәлсәфәсендә материя, җан һәм кеше мәсьәләләре

Материя мәсьәләсе

Аристотель буенча материя – ул форма белән чикләнгән потенция.

Үзенчәлекләр:

— Җирдәге һәр асыл потенциягә һәм формага ия

— Бер бәләкәй генә сыйфатын үзгәртү дә предметның асылын үзгәртүгә китерә

— Чынбарлык – ул материядән формага һәм форманың материягә эзлекле күчеше

— Потенция – ул пассив башлангыч, форма – актив

— Барлык асылның югары формасы – дөньядан тыш яшәеше булган Аллаһ

Җан мәсьәләсе

Аристотель буенча җан аң ия-се һәм шул ук вакытта организм функцияләрен алып бара

Аристотель күрсәткәнҗанның өч дәрәҗәсе

— Үсемлек җаны, ул туклану, үсеш һәм үрчү функцияләре өчен җавап бирә

— Хайвани җан, шул ук фукцияләргә һәм шуңа кушып тою һәм теләү фукцияләренә җавап бирүче

— Акыл җаны, барлык функцияләрне җыеп фикерләү һәм уйлау функцияләрен дә алып бара

Кеше мәсьәләсе

Үзенчәлекләр

— Аристотель кеше мәсьәләсенә материалистик яктан якын килә. Ул кеше үзенең биологик асылы буенча хайваннарның бер төре булып тора дип исәпли, тик алардан акылы һәм фикерли белүе белән аерыла.

— Аристотель фикеренчә, кешедә тумыштан үзенә охшашлар белән бергә яшәү тартымлыгы бар һәм нәкъ шушы сыйфат күп санлы кеше тупланган җәмгыять барлыкка килүгә китерә, материал байлыклар җитештерүче һәм аларны бер территориядә яшәүчеләр һәм тел уртаклыгы, туганлык һәм мәдәни бәйләнешләр белән берләшкән халык арасында бүлү белән шөгыльләнгән.

— Җәмгыятьне тәртипкә салучы механизм булып дәүләт чыгыш ясый.

4. Аристотель фәлсәфәсендә дәүләт мәсьәләсе

Аристотель фәлсәфәсендә дәүләт мәсьәләләре

Аристотель бүлеп чыгарган алты төрдәүләт

— Монархия

— Тирания

— Аристократия

— Чикле олигархия

— Охлократия (халык төркеме хакимияте, чикле демократия)

— Полития (уртача олигархия һәм уртача демократия катнашмасы)

Үзенчәлекләр

— Платон кебек үк Аристотель дәүләтне «начар» (тирания, чикле олигархия һәм охлократия) һәм «яхшы» (монархия, аристократия и полития) дәүләт формаларына бүлә;

— Иң яхшы дәүләт формасы итеп ул политияне күрсәтә: уртача олигархия һәм уртача демократия җыелмасы, «урта сыйныф» дәүләте (Аристотель идеалы)

§18. Эпикур фәлсәфәсе

Эпикур (б.э. кадәрге 341-270 еллар) – борынгы грек материалист-фәлсәфәчесе

Эпикурның табигать һәм космос турындагы тәгълиматы (физика)

Төп положениеләр:

— Бер нәрсә дә юктан килеп чыкмый һәм бер нәрсә дә юк була алмый, чөнки аңа керердәй һәм үзгәртә алырдай Галәмнән башка бернәрсә дә юк;

— Галәм мәңгелек һәм чиксез;

— Барлык әйберләр атомнар һәм бушлыктан тора;

— Атомнар һәм бушлык мәңгелек;

— Атомнар даими хәрәкәттә;

— «Саф идеяләр дөньясы» юк;

— Галәмдә күпләгән материаль дөньялар бар.

Эпикурның танып белү турындагы тәгълиматы (каноника)

Төп идеяләр:

— Әйләнә-тирә дөньянытанып белеп була;

— Танып белүнең төп төре хисси танып-белү;

— Нинди дә булса идея яки күренешләрне «акыл белән күзәтү» мөмкин түгел, әгәр дәки алдыннан хисси танып-белү һәм тойгылар булмаса;

— Тойгы-хисләр танып-белүче субъектның тормыштагы предметлар сәбәпле барлыкка килә.

Эпикурның кеше һәм аның тәртибе турындагы тәгълиматы (эстетика)

Төп положениеләр:

— Үзенең дөньяга килүе белән үз-үзенә бурычлы (ата-аналарына);

— Кеше биологик эволюция нәтиҗәсе ул;

— Аллалар, мөгаен, бардыр, тик алар кешеләр тормышына һәм җир эшләренә берничек тә кысыла алмыйлар;

— Кеше язмышы аның үзеннән һәм хәл-вакыйгаларга бәйле, әмма аллаларга бәйле түгел;

— Җан – материянең үзенчәлекле төре ул;

— Җан, тән кебек үк үлә;

— Кеше җирдәге тормышында бәхеткә омтылырга тиеш;

— Кеше бәхете ләззәталудан тора;

— Ләззәт сүзе астында газаплар юклыгы, сәламәтлек, яраткан эш белән шөгыльләнүне аңлыйлар;

— Акыллы чикләү (теләк, ихтыяҗ), тыныч булу һәм рәхәтлек, акыллылык тормыш нормасына әверелергә тиеш.

§19. Урта гасырның теологик фәлсәфәсе

1. Урта гасыр теологик фәлсәфәнә гомуми төшенчә һәм төп сыйфатлары

Урта гасырлар теологик фәлсәфә – Европада V-XVI гасырларда таралучы әйдәүче фәлсәфә юнәлеше, ул Аллаһны югары башлангыч сыйфатында, ә әйләнә-тирә дөнья – аның иҗаты дип кабул итте

Үзенчәлекләр

— б.э.ның I-V гасырларда яшь христианлык, дин кануннарына каршы чыгу һәм антик фәлсәфә нигезендә Рим империясендә үк ярала. Үзенең иң югары үсешен б.э.ның V-XIII гасырларында ирешә.

— Үз-үзенә йомылу, традиционлыгы, үткәннәргә юнәлтелгән булуы, реаль дөньядан аерылган булуы, сугышчанлыгы, үгет-нәсыйхәтлеге белән аерылып тора.

Иң күренекле вәкилләре

— Тертуллиан Карфагенский(160-220);

— Хозур Августин (Блаженный) (354-430);

— Боэций (480524);

— Бөек Альберт (Великий) (1193-1280);

— Фома Аквинский (12251274);

— Ансельм Кентерберийский (1033-1109);

— Пьер Абеляр(1079-1142);

— Уильям Оккам (1285-1349);

— Отрекурийский Николай(XIV гасыр).

Төп сыйфатлары

— Теоцентризм (барлык нәрсәнең асылы сәбәбе, югары чынбарлык, фәлсәфәнең төп өйрәнү предметы дип Аллаһны исәплиләр);

— Космосны, табигатьне, әйләнә-тирә күренешләрне өйрәнүгә игътибар аз бирелә, чөнки алар Аллаһ иҗаты итеп кабул ителә;

— Догматлар хөкем итә (дәлилләүне таләп итмәгән хакыйкатьләр) иҗат турында (барысы да Аллаһтан) һәм ачышлар (Аллаһ үзе турында үзе – Библиядә);

— Материализм һәм идеализм арасындагы каршылыкларны шомарту;

— Кеше табигатьтән бүленеп чыга һәм табигать өстендә торучы Алла иҗатыитеп кабул ителә;

— Кешене киләчәктә (Аллаһка ярашлы яшәгән хәлдә) мәрхүмнәр арасыннанкабаттан терелтү идеясе дә тәкъдим ителә;

— Дөньяны Алланы танып белү аша гына танып белеп була дип исәплиләр, ул Аллаһка ышану аша гамәлгә ашырыла.

2. Иҗат һәм ачышлар идеяләре (догматлар).
Урта гасыр теологик фәлсәфәдә яхшылык һәм явызлык мәсьәләсе

Урта гасырлардагы теологик фәлсәфә

Төп нигезле догматлар

Иҗат итү догматынаярашлы

— Аллаһ әйләнә-тирә дөньяны юктан яраткан (барлыкка китергән);

— Дөньяны барлыкка китерү Илаһи ихтыяр нәтиҗәсе ул;

— Дөнья чиксез куәтле Аллаһ ярдәшмендә тудырылган;

— Табигать үзен үзе тудыра алмый

— Галәмдәге бердәнбер иҗади башлангыч ул – Аллаһ;

— Аллаһ мәңгелек, даими һәм бар нәрсәгә керә ала;

— Чын яшәеш ул тик Аллаһ;

— Аллаһ һәм аның иҗаты арасында төгәл чик юк.

Ачыш догматына ярашлы

— Дөньяны Аллаһны аңлаганнан соң гынатанып була

— Аллаһны танып белү мөмкин түгел

— Аллаһны танып булмаса да, ул үзен Библия ачышлары аша таныпбелергә рәхсәт итә

— Аллаһны һәм барлык асылны танып белүнең бердәнбер ысулы — Библия аңлатмалары

— Аллаһны гадәттән тыш юл белән, кешенең үзенчәлекле сәләте – ышану аша гына танып була

Иҗат итү идеясеннән чыгып яхшылык һәм явызлык мәсьәләсен хәл итү

— Әйләнә-тирә дөнья Аллаһ белән яратылгын (барлыкка китерелгән);

— Аллаһ яхшылык һәм гаделлек җыелмасы һәм таратучы ул;

— Димәк, әйләнә-тирә дөнья баштан ук яхшылык белән тулы;

— Явызлыкны дөньяга иблис (шайтан) алып килә – Аллаһка каршы күтәрелүче бозык фәрештә;

— Дөньяда иң элек явызлык булмаганлыктан, ул еш кына кара максатлары белән яхшылык астына яшеренә;

— Дөньяда даими рәвештә яхшылык һәм явызлык көрәше бара, тик дөнья Аллаһ иҗаты булганга һәм Аллаһ яхшы булганга, яхшылык һәрвакытта да явызлыкны җиңәчәк.

Урта гасыр теологик фәлсәфәсенең яхшылык һәм явызлык мәсьәләсе оптимистик характерлы.

3. Урта гасыр теологик фәлсәфәсендә асыл һәм барлыкны бүлеп карау

Урта гасырлардагы теологик фәлсәфә

Урта гасыр теологик фәлсәфә (антиктан аермалы буларак) материя һәм идеяне, материализм һәм идеализмны капма-каршы куймый диярлек. Әмма шул ук вакытта борынгы грек фәлсәфәсендә бердәм асыл – яшәешне исәпләгәнне, теологик фәлсәфә дә уртаклаша.

Экзистенциягә (яшәеш, барлык) – бөтенләй әйбер бармыюкмы икәнен күрсәтә.

Эссенциягә (асыл), әйберне характерлаучы

— Нәрсә ул әйбер?

— Нинди әйбер?

— Нәрсә өчен ул бар?

Урта гасырның теологик фәлсәфәсенең төп положениеләре:

— Асыл һәм барлыкны өзелмәс берлектә караган, бердәм асыл – яшәеш ул дигән антик фәлсәфәчеләрдән аермалы буларак, теологик фәлсәфәгә ярашлы, асыл яшәештән башка да була ала.

— Башка төрле әйткәндә, тәнсез асыл Алла аңыннан укый һәм аның ихтыяры белән һәм аңа гына хас булган иҗат итү сәләте аркасында гына материаль яшәеш була ала.

— Барлык хисси тойгылар, тәҗрибә белән (бар булган һәм танып белерлек) өйрәнелә, асыл исә – тик акыл белән.

— Аллаһта гына асыл һәм барлык туры килә

4. Схоластика, номинализм, реализмның гомуми төшенчәсе.

Схоластика – урта гасыр теологик фәлсәфәнең хөкем итүче төре, аның аермалы сыйфатлары – реаль чынбарлыктан аерым булуы, йомыклыгы, консерватизм, чикле догматизм, тулы һәм берсүзсез дини идеяләргә буйсыну, схемалылык, үгет-нәсыйхәтлелек, укытучанлык.

Хас сыйфатлар

«Схоластика» атамасы латин телендәге schola (мәктәп) сүзеннән барлыкка килә, чөнки бу төр фәлсәфә берничә йөз ел мәктәпләрдә һәм Европа университетларында укытыла. Шулай итеп, схоластика үзе белән иҗади эзләнү белән шөгыльләнүче фәнне генә түгел, ә мөгаен, дини тәгълимат һәм чиркәү догматларын фәлсәфи нигезләргә максат куйган катып калган мәктәп-университет фән төрен гәүдәләндерә (моның өчен ул «Фәлсәфә – дин тәгълиматы хезмәтчесе» кушаматына ия була).

Схоластика өчен Библияне каты норматив текст, абсолют хакыйкать буларак үзләштерү хас.

Схоластика белемне ике төргә бүлә:

— гадәттән тыш, ачышларда бирелүче (ягъни Библиягә теге яки бу фикерне кертер алдыннан Аллаһ ни уйлаган, шул);

— табигый, кеше акылы белән эзләп табыла торган (ягъни кеше Библиядән аңлауга ирешә алган, ул Аллаһ идеяләрен ничек аңлаган).

Шул уңайдан схоластлар күпләгән бәхәсләр алып бара, йөзләгән фәлсәфи томнар яза, аларда Библия юлларында яшеренгән Аллаһ идеяләрен дөрес аңларга тырышалар. Бәхәс предметы булып Аллаһ идеясенең асылы түгел, ә төшенчәләрнең, билгеләмәләрнең дөреслеге һәм төгәллеге, икенче төрле әйткәндә дини тәгълиматның тышкы, формаль-логик ягы.

Урта гасыр теологик фәлсәфәсендә (схоластикада) ике капма-каршы юнәлешләр бүленеп чыгая – **номинализм һәм реализм.**

Реализм – телогик фәлсәфә юнәлеше, аның яклылар әйберләрне үзләрен түгел, ә аларның гомуми төшенчәләрен – универсалияләр (мәгънәсе буенча реализм Платонның «саф идеяләр» турындагы тәгълиматына якын) бир дип билгели.

Реализмның күренекле вәкилләре – Ансельм Кентерберийский, Шамподан Гильом.

Номинализм (от лат. nomen – исемнәр) – теологик фәлсәфә юнәлеше, аның яклылар конкрет әйберләнең үзләрен генә реаль булган дип таныйлар, ә шул ук вакытта гомум төшенчәләрне (универсалияләр) әйберләр исемнәре дип кабул итәләр. (Мәгънә ягыннан номинализм «саф идеяләрне» инкарь иткән һәм материаль әйберләрне билгеләүче «индивидуум»нарны реаль дип исәпләгән Аристотель тәгълиматына якын). Номиналистларга ярашлы, универсалияләр әйберләргә чаклы түгел, алардан соң бар була, ә әйберләр хисси тәжрибәбелән танып беленә.

Номиналистларга Росцелин, Пьер Абеляр, Дунс Скот керә.

5. Урта гасыр теологик фәлсәфә әһәмияте

Урта гасыр теологик фәлсәфәнең киләчәк фәлсәфә үсеше өчен әһәмияте түбәндәгеләрдә:

— антик фәлсәфә һәм Яңарыш чоры, яңа вакыт фәлсәфәсе арасында бәйләүче буын булды;

— антик фәлсәфә идеяләрен саклады һәм үстерде, чөнки ул антик фәлсәфәнең христиан тәгълиматы нигезендә барлыкка килде;

— фәлсәфәне яңа өлкәләргә таркатуга булышлык итә (тулысынча антик фәлсәфә белән кушылган онтология – яшәеш турындагы тәгълиматтан тыш, гносеология – танып белү турындагы мөстәкыйль тәгълимат бүленеп чыга);

— иделаизмның объектив һәм субъективка бүленеүенә булышлык итә;

— киләчәктә эмпиристик (Бэкон, Гоббс, Локк) һәм рациональ (Декарт) фәлсәфә юнәлешләре барлыкка килүгә нигез сала. Номиналистлар эшчәнлегенең нәтиҗәсе буларак, алар тәжрибәгә таяну (эмпиризм) һәм үзаң мәсьәләсенә кызыксынуга (Мин-концепция, рационализм) бик нык таяна;

— тарихи процессны аңлауга кызыксыну уята;

— яхшылыкның яманлыкны җиңүе һәм кабаттан терелү ышанычында чагылган оптимизм идеясен тәкъдим итә.

§20. Хозур Августин (Блаженный) фәлсәфәсе

Аврелий Августин (Блаженный) (354 – 430) – христиан теологы, Гиппон шәһәре епископы. (Төньяк Африка, Рим империясе), шул чордагы христиан диненең төп юнәлеше булган католицизмга нигез сала.

Яшь схоластикага нигез салучыларның берсе була. Хозур Августинның (Блаженный) төп әсәре – «Аллаһ йорты турында» – йөзләгән еллар өчен дини-фәлсәфи трактат була, аңа урта гасыр теологлары схоластиканы өйрәнгәндә һәм укыт-

Төп положениеләр

— Тарих барышы, җәмгыять тормышы – ул ике капма-каршы патшалыклар – Җир (гөнаһлы) һәм Илаһ көрәше;

— Җир патшалыгы дәүләт учреждennияләрендә, хакимият, армия, бюрократия, закон, императорда гәүдәләнә;

— Илаһи патшалык дин әһелләре – христиан Чиркәвенә берләштерелгән, бәрәкәт бүлеп бирелгән һәм Аллаһка якын булган аерым кешеләр;

— Җир патшалыгы гөнаһларга һәм мәҗүсилеккә баткан һәм иртәме-соңмы Илаһи патшалыктан җиңеләчәк;

— Моңа бәйле күпчелек кешеләр гөнаһлы һәм Аллаһтанерак, алар дөньяви (дәүләт) хакимият кирәк һәм алга таба да яшәячәк, тик дини хакимияткә буйсына;

— Корольләр һәм императорлар үз ихтыяры белән христиан чиркәвенә генә белдерергә һәм буйсынырга тиешләр, ә тагы да турыдан-туры Рим Папасына;

— Чиркәү – дөньяны берләштерә алырлык бердәнбер көч;

— Хәерчелек, башкаларга бәйлелек (ростовщиклар, җир хуҗалары һ.б.) Аллаһка яраклы түгел, тик әлегә ул күренешләр яшәп килә, аның белән килешергә һәм түзәргә, яхшыга ышанырга кирәк;

— Югары рәхәтлек – кеше бәхете, ул үз-үзеңә тирәнәю,хакыйкатьне төшенү итеп аңланыла;

— Хыянәтсез, тәкъва яшәүчеләр үлгәннән соң Аллаһтан бүләккә теге дөньядагы тормыш алачак.

Хозур Августин (Блаженный) фәлсәфәсе

Аллаһ турында фикерләве

— Аллаһ бар;

— Аллаһ барлыгының төп дәлиле – аның барлык нәрсәдә булуында, зур кодрәт һәм камиллеге;

— барлык нәрсә – материя, җан, киңлек һәм вакыт – Аллаһ иҗаты;

— Аллаһ дөньяны гына яратмаган, әле дә иҗат итүен дәвам итә, киләчәктә дә иҗат итәчәк;

— белем (хисләр, фикерләр, тойгылар, тәҗрибә) реаль һәм үз-үзенә җитәрлек, әмма югары, хакыйкый, кире какмаслык белем бары тик Аллаһны танып белү аша гына ирешелә.

Хозур Августин (Блаженный) фәлсәфәсе әһәмияте

— тарих мәсьәләсенә зур игътибар бирелә (ул чор өчен сирәк күренеш);

— Чиркәү (еш кына дәүләт хакимлегендәге һәм Рим империясе тарафыннан әзерлекләнгән) шулай ук дәүләт хакимияте тарафыннан хакимият итеп игълан ителә (ә дәүләт элементы түгел);

— Чиркәүнең дәүләт өстеннән хакимлеге нигезләнә, ә Рим Папасы – монархлардан – төп идея, аны тәкъдимиткән һәм тормышка ашырылуы өчен Чиркәү Августин Блаженныйны хөрмәт итә һәм Аллаһ урынына күрә, аеруча урта гасырларда;

— тәкъдим ителгән социаль конформизм идеясе (фәкыйрьлек һәм чит хакимият белән килешү), бу шулай ук Чиркәүгә дә, дәүләткә дә отышлы;

— кеше, аның матурлыгы, көче, камиллеге данлана (ул чор өчен сирәк була һәм барысына да ошый);

— бер үк вакытта кешегә җенси теләкне бетерергә, рухны үстерергә һәм данларга, Аллаһны танып белергә һәм буйсынырга тәкъдим ителә.

§21. Фома Аквинскийның фәлсәфәсе

Фома Аквинский фәлсәфәсе

Фома Аквинский (1225 – 1274) – доминикана монахы

Урта агсыр теологик фәлсәфәнең күренекле фәлсәфәчесе, схоластиканы системага китерүче, томизм авторы – католиклар Чиркәвенең хөкем итүче юнәлеше.

Фомы Аквинскийның төп әсәрләре: «Теология суммасы», «Философия суммасы» («Мәҗүсиләргә каршы»), Библиягә, Аристотель әсәрләренә аңлатмалар.

Фома Аквинский Алла барлыгының онтологик дәлилләүне җитәрлек түгел дип исәпли (ягъни Хозур Августин (Блаженный) исәпләгән Аллаһ барлыгы аның иҗат иткәннәреннән чыгарылган «бәхәссез» дәлиле – әйләнә-тирә).

Фома Аквинскийның Аллаһ барлыгы турындагы биш үз дәлиле

— хәрәкәт: нәрсә хәрәкәт итә, шул кемтарафыннандыр хәрәкәт иттерелә (нәрсә беләндер) – димәк, барысын да беренчел хәрәкәт иттерүче – Аллаһ;

— сәбәп: нәрсә бар, аның үз сәбәбе була – димәк, беренчел сәбәп ул –Аллаһ;

— очраклылык һәм зарурилык: очраклы зарурига бәйле – димәк, беренчел зарурилык ул Аллаһ;

— сыйфат дәрәҗәләре: нәрсә бар, төрле дәрәҗәдәге сыйфатка ия (яхшырак, яманрак, зуррак, кимрәк һ.б.) – димәк, иң югары камиллек – Аллаһ яшәргә тиеш;

— максат: әйләнә-тирә дөньяда нин- ди дә булса максатка ия, максатка юнәлә, мәгънәсе бар – димәк, бары- сын да максатка юнәлтүче ниндидер акыллы башлангыч бар, ул барысына да мәгънә бирә – ул Аллаһ.

Фома Аквинский фәлсәфәсе

Шулардан чыгып, Фомага ярашлы:

— бар нәрсә материя формаларыннан тора (идеяләр) – һәр әйбернең асылы – форма һәм материя берлеге;

— форма (идея) билгеләүче башлангыч була, ә материя төрле формалар савыты;

— форма (идея) бер үк вакытта әйбер барлыкка килү максаты да;

— теләсә кайсы әйбер идеясе (форма) өч кисәктән тора: Илаһи акылда, әйбернең үзендә, кешенең үзләштерүендә (хәтерендә) яши.

Яшәеш мәсьәләсен тикшереп, Фома Аквинский

— асылны бүлешә (эссенция) һәм бар булуны (экзистенция). Аларның бүленеше – католиклыкның иң төп идеяләренең берсе;

— асыл (эссенцияләр) әйбернең яки күренешнең сыйфатында «саф идеяне» күз уңында тота, Аллаһ акылында (Илаһи Ният) яшәгән билгеләр, сыйфат, билгеләнеш җыелмасы;

— бар булу сыйфатында әйбернең яшәү фактын күзуңында тота;

— теләсә кайсы әйберне, күренешне асыл дип кабул итә, ул Аллаһ ихтыяры белән яшәү ала (ягъни «саф идея», ул Аллаһ ихтыяры көче белән материаль форма ала);

— яшәеш һәм рәхәтлекләр элекке хәленә кайтарылуындәлилли, ягъни Аллаһ, асылга яшәеш бирүче, аны яшәүдән мәхрүм дә итә ала, димәк, әйләнә-тирә дөнья фани һәм үзгәрүчән;

— асыл һәм яшәү бары тик Аллаһта гына бердәм, димәк, Аллаһтан кире качып булмый – Ул мәңгелек, чиксез куәтле һәм даими, башка тышкы факторларгабәйле түгел.

Фома Аквинский фәлсәфәсе

Танып-белү мәсьәләсен тикшереп, Фома Аквинский түбәндәгенәтиҗәләргә килә:

— ачыш һәм акыл (ышану һәм белем – бер үк нәрсә түгел (Августин Блаженный исәпләвенчә), ә төрле төшенчәләр;

— ышану һәм акыл бер үк вакытта танып-белү процессында катнашалар;

— ышану һәм акыл хак белем бирә;

— әгәр кеше акылы ышануга каршы төшә икән, ул хак булмаган белем бирә;

— дөньяда рациональ (акыл белән) танып булганга һәм акыл белән танып булмаганга бүленә;

— акыл белән Алла булуын аңлап була, Алла бер-легән, кеше җаныныңүлем-сезлеген һ.б.;

— дөнья барлыкка килү, беренчел гөнаһ, Алланың өч кисәктән торуы рациональ (акыл белән) танып белүгә буйсынмый, димәк, Илаһи ачыш аша гына танып була;

— фәлсәфә һәм теология – төрле фәннәр;

— фәлсәфә акыл белән танып булганныгына аңлата ала;

— калган барысын да (илаһи ачыш) теология генә танып-белә ала.

Фома Аквинский фәлсәфәсенең тарихи әһәмияте (иң элек католиклар Чиркәве өчен) аның түбәндәгеләрне тәкъдим итүеннән гыйбарәт:

— Аллаһ барлыгының биш дәлиле бирелә;

— схоластика системалаштырыла;

— эссенцияләр һәм эзистенцияләр бүленеше теркәлә (асыл һәм яшәү), бу Аллаһның куәтен һәм аңардан тулы бәйлелекне дәлилли, аның ихтыярына бәйлелекне күрсәтә;

— идеализмның материализмнан өстенлегенең дөреслеге дәлилләнә (католиклар күзлегеннән): әйберләргә кадәрге булган Илаһи идеяләр өстенлеге яшәгәнлеге – материя өстеннән хакимлек (димәк, Алланыңәйләнә-тирә дөнья өстеннән хакимлеге);

— белемнең хакыйкый идеясе тәкъдим ителә, ул акылның ышануга тиңләшү вакытында алынган очрагында;

— яшәеш өлкәсе билгеләнә, аларны нибары ачыш вакытында гына таныпбелергә мөмкин;

— фәлсәфә һәм теология бүленә, әйтергә кирәк, фәлсәфә теологиягә карата буйсынучы хәлендә;

— теология һәм схоластиканың берничә положениесе логик дәлилләнә

1878 елда Фома Аквинский тәгълиматы Рим Папасы карары белән католицизм идеологиясе итеп рәсми кабул ителә.

Әлеге вакытта неотомизм – Фома Аквинский идеяләренә нигезләнгән фәлсәфи-дин тәгълиматы киң тарала.

§22. Яңарыш чоры фәлсәфәсенең төп юнәлешләре һәм аның сыйфатлары

Яңарыш чорындагы гомуми төшенчә һәм алшартлар

Яңарыш чоры фәлсәфәсе дип XIV–XVII гасырларда Европада барлыкка килгән һәм үсешкән фәлсәфә юнәлешләре җыелмасы атала. Ул чиркәүгә һәм схоластикага каршы юнәлешләрен, кешегә омтылучынлык, аның бөек физик һәм рухи потенциалына ышаныч, оптимистик характерын берләштерә.

Барлыкка килү алшартлары

— хезмәт кораллары һәм җитештерү мөнәсәбәтләрен камилләштерү;

— феодализм кризисы;

— һөнәрчелек һәм сәүдәнең үсеше;

— шәһәрләрне ныгыту, аларны сәүдә-һөнәрчелек, хәрби, мәдәни һәм сәяси үзәкләргә әйләндерү, феодаллар һәм Чиркәүгә бәйсез;

— Европа дәүләтләрен ныгыту, үзәкләштерү, дөньяви хакимиятне ныгыту;

— беренче парламентларның барлыкка килүе;

— тормыштан артта калу, Чиркәү һәм схоластик (чиркәү) фәлсәфә кризислары;

— Европада белем дәрәҗәсен арттыру;

— Бөек географик ачышлар (Колумб, Васко да Гама, Магеллан);

— фәнни-техник ачышлар (дары, ату коралы, станоклар, домна миче, микроскоп, телескоп, китап басу, медицина һәм астрономия, башка фәнни-техник казанышлар).

2. Яңарыш чоры фәлсәфәсенең төп юнәлешләре һәм аңа хас сыйфатлар

Яңарыш чоры фәлсәфәсе

Төп юнәлешләр:

— **гуманистик** (XIV XV гасырлар., вәкилләр: Данте Алигьери, Франческо Петрарка, Лоренцо Валли һ.б.) – үзәккә кешене куя, аның яхшы яклары, бөеклеген һәм куәтен данлый, Чиркәү догматларыннан мыскыл итеп көлә;

— **неоплатоник** (XV гасыр уртасы – XVI гасырлар), вәкилләр – Николай Кузанский, Пико делла Мирандола, Парацельс һ.б. – Платон тәгълиматын үстерәләр, табигатьне, Космосны һәм кешене идеализм күзлегеннән танып белергә тырышалар;

— **натурфилософик** (XVI – XVII гасыр башы), вәкилләре – Николай Коперник, Джордано Бруно, Галилео Галилей һ.б., Чиркәүнең Аллаһ турындагы берничә положениесен һәм галәм нигезләре турындагы астрономик һәм фәнни ачышларга таянып, сүтәргә тырышалар;

— **реформацияле** (XVI – XVII гасырлар), вәкилләр – Мартин Лютер, Томас Монцер, Жан Кальвин, Джон Усенлиф, Эразм Роттердамский һ.б.
– чиркәү идеологиясен, ышанучылар һәм Чиркәү арасындагы мөнәсәбәтләрне яңабаштан төптән карарга омтылалар;

— **сәяси** (XV – XV гасырлар), Николо Макиавелли) – дәүләт белән идарә итү мәсьәләсе, хакимнәр тәртибен өйрәнә;

— **утопик-социалистик** (XV – XVII гасырлар, вәкилләр – Томас Мор, Томмазо Кампанелла һ.б.) – хосусый милек юклыгына һәм гомуми идарә итүгә нигезләнгән, дәүләт хакимияте ягыннан тоталь тәртипкә көйләнгән җәмгыять һәм дәүләт төзүнең идеаль-фантастик формаларын эзләде.

Хас сыйфатлар:

— антропоцентризм һәм гуманизм – кешегә кызыксыну өстенлек итү, аның чиксез мөмкинлекләренә ышану;

— Чиркәүгә карата һәм чиркәү идеологиясенә оппозиционлык (ягъни динне, Аллаһны үзен кире кагу түгел, ә Аллаһ белән ышанучылар арасында арадашчы булган оешмаларны, шулай ук догматик, Чиркәү ихтыяҗларына хезмәт күрсәтүче кире кагу фәлсәфәне – схоластиканы);

— төп игътибарны идеянең формасыннан аның эчтәлегенә күчерү;

— әйләнә-тирә дөньяны принципиаль яңа, фәнни-материалистик аңлау (Җирнең шарга охшаганлыгы, ә яссылыкка түгел, Җирнең Кояш тирәли әйләнүе, ә киресенчә түгел, Галәмнең чиксезлеге, яңа анатомик белемнәр һ.б.);

— социаль мәсьәләләр, җәмгыять һәм дәүләткә карата зур кызыксыну;

— индивидуализм тантанасы;

— социаль тигезлек идеяләрен киңтарату

§23. Яңарыш чорының юнәлешләре буларак гуманизм, неоплатонизм, натурфилософия

1. Яңарыш чоры фәлсәфәсе юнәлешләренең гомуми төшенчәләре

Яңарыш чоры фәлсәфәсенең төп юнәлешләре (XIV-XVII гасырлар):

— гуманистик

— неоплатоник

— натурфилософия

— реформацион

— сәяси

— социалистик-утопик

Соңгы өч агымны бер исем – «социаль-сәяси юнәлеш» дип атау кабул ителгән. Аларның өйрәнү предметы буларак җәмгыять, дәүләт һәм Чиркәү мәсьәләләре тора.

2. Гуманизм

Үзенчәлекләр:

— Фәлсәфә юнәлеше буларак XIV-XV гасыр уртасында Европада тарала. Аның үзәге Италия була.

— Үзенең жанры буенча гуманистик фәлсәфә әдәбият белән кушыла, кинаяләп сөйләнелә һәм әдәби формада;

— Ныграк танылган гуманист фәлсәфәчеләр бер үк вакытта язучылар да булган: Данте Алигьери, Франческо Петрарка, Лоренцо Балла.

Төп сыйфатлар:

— Чиркәүгә каршы һәм схоластикага каршы юнәлешләр;

— Аллаһның чиксез куәтлелеген киметергә һәм кешенең үзкыйммәтендәлилләргә тырышу;

— антропоцентризм – кешегә аеручы игътибар итү, аның көчен, бөеклеген, мөмкинлекләрен данлау;

— Тормышчанлык белән сугарылган характеры һәм оптимизм.

Танылган гуманист-фәлсәфәчеләр

Данте Алигьери (1265 1321) – «Илаһи комедия» авторы

Үз әсәрләрендә Данте:

— христианлыкны данлый, тик бер үк вакытта каршылыклар һәм аңлатып булмаган хакыйкатьләрдән (догмалардан) көлә;

— кешене мактый;

— кешене илаһи зат итеп аңлатудан читләшә;

— кешедә бер-берсе белән гармониядә булган илаһи һәм табигый башлангычларын таный;

— кешенең бәхетле киләчәгенә, аның баштан ук яхшы булуына ышана

Дантеның башка әсәрләре дә шушы ук рухта язылган («Яңа тормыш» һ.б.).

Франческо Петрарка (1304 1374) – «Җырлар китабы», «Дөньяга җирәнеп карау турында»трактататы авторы (лат. телендә) һ.б. хезмәтләр.

Петрарка мәдәнияткә схоластикага ят булганидеяләр кертә:

— кеше гомере бер тапкыр гына бирелә һәмул уникаль;

— кеше Алла өчен яшәргә тиеш түгел, ә үзе өчен;

— кеше шәхесе ирекле булырга тиеш – физикяктан да, рухи яктан да;

— кешенең ирекле сайлау мөмкинлеге бар һәм ул үзен аңа ярашлы күрсәтә ала;

— кеше бәхетне үзенә һәм үз көченә таянып кына яулый ала, моның өчен тиешенчә потенциалы да җитәрлек;

— теге дөньядагы тормыш юк, үлемсезлеккә тик кеше хәтерендә генә ирешеп була;

— Кеше үзен Аллаһка корбан итәргә тиеш түгел, ә тормыштан тәм табып яшәргә һәм яратырга тиеш;

— Кешенең тышкы кыяфәте һәм эчке дөньясы гүзәл.

Лоренцо Балла (1507– 1557), «Хак рәхәтлек буларак ләззәт турында»трактаты авторы.

— чиркәү авторитетларын төшерми;

— схоластиканы ясалмалылыкта, уйдырмалылыкта һәм ялганлыкта тәнкыйтьли;

— галәм үзәгенә кешенекуя;

— кешенең мөмкинлекләренә һәм аның акылына ышана;

— аскетизм һәм дәрвишлеккә бирелүне инкарь итә;

— актив гамәлләргә, көрәшкә, дөньяны үзгәртүдә кыюлыкка чакыра;

— ирләр һәм хатын-кызлар тигезлеге ягында була;

— югары рәхәтлек дип матди һәм әхлакый ихтыяҗларны канәгатьләндерүдән барлыкка килгән ләззәт дип исәпли.

3. Неоплатонизм

Неоплатонизм – идеалистик юнәлеш, ул Платон тәгълиматын җитди системалаштыруны үз максаты итеп куя, аңардан каршылыкларны юк итү һәм аның киләчәк үсешен тәэмин итү. Неоплатонизм аеруча үсешне Яңарыш чорында XV гасырда ирешә.

Неоплатонизм теоретиклары үз әсәрләрендә:

— Схоластик фәлсәфәгә Платон идеяләрендәге яңа фәлсәфә системасын каршы куялар;

— Яңа дөнья күренешен тәкъдим итәләр, монда Аллаһ әһәмияте кими һәм башлангыч идеяләр әһәмияте ныгый;

— Кешенең илаһи табигатен инкарь итми, тик шул ук вакытта аны мөстәкыйль микрокосм итеп карыйлар;

— Элгәре фәлсәфә постулатларын яңабаштан аңлауга һәм тулы дөнья фәлсәфи системасын төзүгә өндиләр, ул бар фәлсәфи юнәлешләрне яулап, килештерер иде.

Неоплатонизмның күренекле вәкилләре

Николай Кузанский (1401 – 1464) – рухани, дин белгече, тик новатор карашларга таяна. Яшәеш һәм танып белүгә яңааңлатма бирә, **аңа ярашлы:**

— дөнья бер, ә Аллаһ һәм Галәм – бер үк төшенчә;

— «бер» (Аллаһ) и «чиксез» (аның иҗаты) минимум һәм максимум буларак (капма-каршылыклар) кагылышлы, алар туры килә;

— капма-каршылыклар туры килү законы: аларның туры килүеннән форма һәм материя тәңгәллеге килеп чыга (асыл һәм бар булу өзелмәс, һәм яшәеш бер генә);

— идея һәм материя бердәм;

— актуаль чиксезлек реаль бар (башкаларны йоту аша);

— Галәм чиксез, башы да, ахыры да, үзәге дә юк, Җир Галәмуртасы түгел;

— Галәм – ул хисси үзгәреп торган абсолют һәм тәмамланган Алла, (дөнья, бар нәрсә Аллаһка кертелгән, ә Аллаһ әйләнә-тирәдә);

— чиксезлек үзе үк капма-каршылыкларны берләштерә, бу математик дәлилләнә;

— танып белү чиксез;

— абсолют белемгә ирешеп булмый, белем арттыру укымышлылыкка китерә, әмма хак белемгә түгел (Н. Кузанский буенча – «белемле белмәүгә»

Шулай итеп, Н. Кузанский, идеалистик юнәлеш фәлсәфәчесе буларак, әйләнә-тирәне (Галәмне) материалистик аңлатуга якын килә һәм натурфилософия тәгълиматы өчен нигез әзерли Н. Коперник, Дж. Бруно, Г. Галилео һ.б.

Джованни Пико делла Мирандола (1463 – 1494) билгеле булган дини һәм «900 тезис» дип аталган эклектик әсәрендә фәлсәфи тәгълиматларны берләштерергә тырышып карый.
— кешене күтәрергә һәм әйләнә-тирә дөньядан аерырга, аны аерым чынбарлык итеп кабул итәргә (космосның «дүртенче дөнья»сы);

— кешенең ирекле сайлау мөмкинлеген таный;

— барлык фәлсәфи тәгълиматларны кушып, аларны килештерү юлы белән
«алтын урталыкны» табарга.

4. Натурфилософия

Натурфилософия (Яңарыш чорында (XVI–XVII гасырларда) Европада тарала (аеруча Италиядә). Аның төп сыйфатлары:

— дөньяга материалистик карашны нигезләү;

— фәлсәфәне теологиядән аерырга тырышу;

— фәнни дөньяга теологиядән азат караш формалаштыру;

— дөньяның яңа сурәтен тәкъдим итә (Аллаһ, Табигать һәм Галәм бердәм, ә Җир – Галәм үзәге түгел);

— дөньяны хисси танып белү һәм акыл аркасында (ә Илаһи ачыш аша түгел) танып була.

Андреас Везалий фәлсәфәсе (1514 – 1564). Андреаса Везалий хезмәтләренең әһәмияте:

— Дөнья барлыкка килүне материалистик яктан аңлата, аның үзәгендә кеше;

— Гален чорыннан (130-200) – хайваннарны тикшерүгә нигезләнеп, кеше төзелешен сурәтләгән Борынгы Рим табибы, медицинада хакимлек иткән карашларны кире кага;

— Үз нәтиҗәләрен анатомик экспериментлардан чыгып әйтә һәм «кеше анатомиясен сурәтләү аша кеше тәненең төзелеше турында» китабын чыгара.

Николай Коперник (1473 – 1543), астрономик тикшеренүләргә таянып, башка төр яшәеш күренешен тәкъдим итә:

— Җир Галәм үзәге түгел (геоцентрим кире кагыла);

— Кояш – Җиргә карата үзәк (гелиоцентризм),Җир Кояш тирәли әйләнә;

— Барлык Галәм җисемнәре үз троекториясе буенча хәрәкәтитә;

— Космос (Галәм)чиксез;

— Космостагы процесслар табигать күзлегеннән аңлатыла һәм «изге» мәгънәгә ия түгел.

Джордано Бруно (1548 – 1600) Коперникның идеяләрен үстерә һәм тирәнәйтә:

— Кояш – Җиргә карата үзәк, тик Галәм үзәге түгел;

— Галәмнең үзәге юк һәм ул чиксез;

— Галәм галактикалардан тора

— Йолдызлар – күк җисемнәре, Кояшка охшаш һәм үз планета системалары бар;

— Дөньялар саны чиксез;

— Һәр җисем хәрәкәт итү сәләтенә ия;

— Галәмнән аерым Аллаһ, Аллаһтан аерым Галәм юкбергә кушылган.

Галилео Галилей (1564 – 1642) гамәлдә Николая Коперник һәм Джордано Бруно идеяләренеңдөреслеген раслый:

— Телескоп уйлап чыгара;

— Күк җисемнәре траектория һәм үз тирәли хәрәкәт итүен дәлилли;

— Кояштагы тапларны һәм Айдагы төрле ландшафтны ачыклый;

— Башка планеталарның юлдашларын ача;

— Җисемнәрнең төшү динамикасын тикшерә;

— Күп дөньялар булуын дәлилли

Фәнни тикшерү ысулын тәкъдим итә, ул түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

1) күзәтү;

2) гипотезалар тәкъдим итү;

3) Гипотизаны гамәлдә тормышка ашыру исәп-хисабы;

4) Гипотизаны практикада тәжрибә белән тикшерү

§24. Яңарыш чорының социаль-сәяси фәлсәфәсе

1. Яңарыш чорының социаль-сәяси фәлсәфәсенең гомум төшенчәләре һәм аның төп юнәлешләре

Яңарыш чорының социаль-сәяси фәлсәфәсе

Проблематика

— дәүләт мәсьәләсе;

— Чиркәү һәм дәүләт институтлары, дин тотучыларның үзара мөнәсәбәте.

Төп юнәлешләр

— Реформация фәлсәфәсе;

— фәлсәфә сәясәте

— социалист-утопистлар фәлсәфәсе.

2. Реформация фәлсәфәсе, аның юнәлешләре, әһәмияте

Реформация фәлсәфәсе

Максатлар

— Капитализм реформасы;

— Чиркәүне демократлаштыру;

— Алла, чиркәү һәм дин тотучылар арасында гаделрәк мөнәсәбәт урнаштыру.

Барлыкка килү алшартлары

— Феодализм кризисы;

— сәүдә-җитештерү буржуазия катламының тууы һәм ныгуы;

— феодаль бүленгәләнүне киметү, европа дәүләтләре формалашуы;

— әлеге дәүләт җитәкчеләренең, сәяси элитаның, милли дәүләт өстеннән, гомумевропа Рим Папасы хакимияте һәм католиклар Чиркәвенең артык кызыксынмаучанлыгы;

— кризис, католиклар Чиркәвенең әхлакый тарканлуы, аның халыктан аеруылуы, тормыштан артта калу, индульгенция бирү практикасы;

— Европада гуманизм идеяләре таралуы;

— шәхесләрнең үзаңнары үсеше, индивидуализм;

— католикларга каршы булган дини-фәлсәфи тәгълиматлар, дин кануннарына каршы чыгу, мистика,гусизмның йогынтысы үсеше;

Төп агымнары

— бюргер-евангелиеле (аның лидерларыМ. Лютер, У. Цвингли, Ж. Кальвин);

— халык (Т. Мюнцер, анабаптистлар, диггерлар һ.б. хәрәкәте).

Бюргер-евангелие Реформациясе лидерлары

Мартин Лютер(1483-1546)

Реформациягә нигез салучы итеп дин белгече докторы Мартин Лютер (1483 – 1546) исәпләнелә. 1517 елның 31 октябрендә Германиядәге Виттенберг замок чиркәвендәаның тарафыннан индульгенциягә каршы 95 тезис тәкъдим ителә, ул католицизмга каршы идеологик (ә кайбер илләрдә кораллы да) көрәш башлануга нигез була. М. Лютерның төп идеяләре түбән- дәгеләргә кайтып кала:

— Аллаһ һәм дин тотучылар арасындагы аралашу турыдан-туры барырга тиеш;

— Алла һәм дин тотучылар арасында католик чиркәве булырга тиеш түгел;

— йолаларны тәртипкә салырга;

— Чиркәү демократикка әйләнергә, ә йолалар – кешеләргә аңлаешлы булырга тиеш;

— башка илләргә Рим Папасы һәм католик руханиларның йогынтысын киметергә мотлак;

— дәүләт институтлары һәм дөньяви хакимиятнең абруе кайтарылырга тиеш;

— Аллаһка хезмәт итү – һөнәр генә түгел, аны руханилар монопольләштерде, шул ук вакытта дингә ышанучы христианнарның гомерлек функциясе дә;

— мәдәният һәм мәгарифне католик догмаларыннан азат итәргә кирәк;

— Индульгенцияләрне тыю.

Жан Кальвин (1509-1564)

Ул Лютер эшен дәвам итә һәм аның идеяләрен системалаштыра.

— протестантизмның төп идеясе – язмыш идеясе,алдан билгеләнүчәнлек;

— Бу идеянең мәгънәсе кешегә алдан ук Аллаһ тарафыннан йә коткарылу, йә үлү карала;

— Бар кеше дә үзен коткаруга алдан билгеләнгән дип ышанырга тиеш;

— кешенең Җирдәге яшәү мәгънәсе булып һөнәр була:

— һөнәр – ул акча эшләү генә түгел, Аллаһка хезмәтитү урыны да;

— үз эшеңә намуслы карау – исән калуга юл;

— Эштә уңышка ирешү – Аллаһ тарафыннан сайланылу билгесе;

— Эштән тыш тыйнак һәм аралашмаучан булырга кирәк.

Моңардан тыш, Кальвин протестантизмныгамәлгә кертә

— Женевадагы реформацион хәрәкәтне җитәкли;

— рәсми сыйфатта реформацияләнгән (кальвинист) чиркәүне тануга ирешә, Женевада католик Чиркәү һәм Рим Папасы хакимиятен кыскарта (үзе Кальвин «Женева Папасы» дигән кушамат ала);

— кальвинист Чиркәвенә дөньяви хакимиятне буйсындыра;

— үз Чиркәве эчендә реформа ясый, шулай ук шәһәрдә дә:бай католик йолалар, бәйрәм, чагу кием, күңел ачулар, бизәнгечләр йөртү, биюләрне тыю, халык өстеннән катгый пастор күзәтүе урнаштырыла, аның максаты – гражданнарны дәрвишлек, пуританизм, эшкә намуслы караш рухында тәрбияләү.

Кальвинның теоретик тикшеренүләре һәм аның практик эшчәнлеге реформаның универсальләшүе,тар немец теленнән халыкара күренешкә әверелде.

Реформациянең халык юнәлешен җитәкләде

Томас Мюнцер (1490 – 1525) җитәкләде. Рухани буларак, ул башта Лютерга килеп кушыла, аның яклы була, әмма 1520 елда, Реформация башлануга өч ел булгач,укытучысы белән араларны өзә. Лютер белән килешеп, Мюнцер үзенең дә Реформация идеяләрен тәкъдим итә, аларның мәгънәсе түбәндәгечә:

— Чиркәүне генә түгел, җәмгыятьне дә тулысынча реформалаштыру кирәк;

— җәмгыятьне үзгәртү максаты – гомум гаделлеккә ирешү, җирдәге «Аллаһ патшалыгы»

— барлык явызлыкның да төп сәбәбе – тигезсезлек, сыйнфый бүленеш, аның нигезендә хосусый милек һәм шәхси кызыксыну ята;

— шәхси кызыксынуны бастырырга кирәк, барысы да гомум булырга тиеш (күз алдында иң элек милек, җитештерүнең яңа ысуллары тора);

— кешенең тормышы һәм эшчәнлеге тулысынча җәмгыять интересларына буйсынырга тиеш, чөнки ул Аллага кирәк;

— хакимият һәм милек гади халыкка – «һөнәрчеләр һәм игенчеләргә» булырга тиеш.

1524 – 1525 еллар. Томас Мюнцер Германиядәге католик һәм революциягә каршы Крестьяннар сугышын җитәкли. Сугыш отыла, ә Мюнцер үзе үлә.

Реформация фәлсәфәсенең әһәмияте

Чиркәү реформасы һәм католицизмга каршы сәяси һәм кораллы көрәшнең идеологикбилгеләнеше буларак хезмәт итә. Ул киләчәктә Европаның күп кенә илләрендә XVI гасыр буена дәвам итә.

Бу көрәшнең нәтиҗәсе күп кенә дәүләтләрдәге католицизмның җимерелүе һәм Европадагы дини аерылуларга китерә.

— Төньяк һәм Үзәк Европада – Германиядә, Швейцариядә, Бөек Британиядә, Голландиядә, Даниядә, Швециядә, Норвегиядә протестантизмның төрле юнәлешләренең җиңүе (лютеранлык, кальвинизм һ.б.);

— Көньяк һәм Көнчыгыш Европа илләрендә – Испаниядә, Франциядә, Италиядә,Хорватиядә, Польшада, Чехиядә һ.б. илләрдә католицизмны саклау.

3. Никколо Макиавеллинең сәяси фәлсәфәсе

Үзенчәлекләр

— Аллаһ, Чиркәү, кеше һәм дәүләт арасындагы мөнәсәбәтләр Реформация фәлсәфәсеннән аермалы буларак, сәяси фәлсәфә реаль булган дәүләт белән идарә итү мәсьәләсе, кешеләргә йогынты ясау ысуллары, сәяси көрәш алымнарын тикшерә;

— әйләнә-тирә чынбарлыкка реалистик мөнәсәбәткә Урта гасыр һәм аннан соң килгән чордагы сәясәтчеләр өчен җитәкчелек була.

Никколо Макиавелли (1469 – 1527) итальян (Флоренция) сәяси эшлеклесе, фәлсәфәче һәм язучы

Макиавелли фәлсәфәсе түбәндәге төп нигезләләләргә таяна:

— кеше баштан ук яман табигатьле була;

— кеше гамәлләрен хәрәкәтләндерүче мотивлар ул эгоизм һәм шәхси табыш алуга омтылу;

— әгәр дә һәркайсысы үз эгоистик ихтыяҗларын гынакуса, кешеләрнең бергә яшәүләре мөмкин түгел;

— кешенең түбән холкын, эгоизмын тезгенләр өчен, махсус оешма – дәүләт төзелә;

— хаким буйсынучыларның түбән табигате турында онытмыйча дәүләт белән идарә итәргә тиеш;

— дәүләт башлыгы юмарт һәм намуслы булып күренергә тиеш, тик чынлыкта андый буларга тиеш түгел, чөнки чынбарлык белән чәкәлешкәндә бу сыйфатлар капма-каршы нәтиҗәгә китерәчәк (башлык рәхимсез көрәштәшләре яки дошманнары белән төшереләчәк, ә казан – туздырылачак);

— җитәкче кешеләрнең милкенә һәм шәхси тормышына орынырга тиеш түгел;

— илне илбасарлардан азат иткәндә аның бәйсезлеге хакына барлык чаралар да шул исәптән мәкерле һәм аморальдә кулланыла ала.

4. Социалист-утопистлар фәлсәфәсе

Үзенчәлекләр

— төп игътибарны бу фәлсәфәчеләр идеаль дәүләт проектларын төзүгә юнәлтәләр, биредә бөтен социаль каршылыклар юкка чыгарылачак һәм социаль гаделлек җиңәчәк

— аларның проектлары чынбарлыктан читләшкән һәм асылда тормышка ашырылмаслык булганга, әләге фәлсәфәчеләр тарихка социалист-утопистлар буларак керә.

Социалист-утопистлар фәлсәфәсенең әһәмияте

Яңарыш чорында тәкъдим ителгән социалист-утопистлар идеяләре, урыны булмаган социаль гаделсезлеккә җавап буларак туа. Бу юнәлешнең Яңарыш чорында һәм соңыннан да тарафдарлары күп була.

Танылган социалист-утопистлар

— Томас Мор (1478 – 1535) утопик социализмга нигез салучы. Аңа сәяси эшчәнлек белән шөгыльләнүче буларак, реаль дәүләт мәсьәләләре бик таныш була: парламент әгъзасы, община палатасы рәисе, Бөек Британиянең лорд-канцлеры (1535 елда католицизм тарафтары буларак җәзалап үтерелә: Рим Папасыннан корольгә ант бирүдән баш тарткан өчен);

— Томмазо Кампанелла (1568 – 1639).

Томмазо Кампанелла фәлсәфәсе «Кояш Шәһәре» әсәрендә бирелә. Вакыйга фантастик Кояш Шәһәрендә бара, аның кешеләре – солярийлар – социаль гаделлеккә нигезләнгән идеаль җәмгыять төзегән, тормыш һәм хезмәттә ләззәт алып яшиләр. **Кампанелле буенча, Кояш Шәһәрендә:**

— хосусый милек юк;

— бар гражданнар җитештерү хезмәтендә катнаша;

— Хезмәт нәтиҗәләре җәмгыять милкенә әверелә, һәм җәмгыять әгъзалары арасында тигез бүленә;

— Хезмәт бер үк вакытта өйрәнү белән бергә бара;

— солярийлар тормышы кечкенә ваклыкларна кадәр бүленә, торудан йоклап китүгә кадәр;

— Соляриялəр барын да бергә эшлиләр: эшкә бергә баралар, ашыйлар,ял итәләр, җырлар җырлыйлар;

— тәрбиягә зур игътибар бирелә – туганнан алып бала әти-әнисеннән алына һәм махсус мәктәпләрдә тәрбияләнә, биредә ул фәннәрне үзләштерә һәм коллективта яшәргә өйрәнә, Кояш Шәһәренең башка кагыйдәләренә өйрәнә;

— Кояш шәһәренең башында гомерлек башлык тора (солярийлар белән сайланылган) – үз чорының барлык белемнәрен һәм барлык һөнәрләрне белүче Метафизик.

Т. Мор фәлсәфәсе «Утопия» әсәрендә чыгылдарлыган. Утопия (греч. – урын, беркайда да булмаган) – идеаль дәүләт урнашкан уйлап чыгарылган утрау. Т. Морга ярашлы Утопиядә:

— хосусый милек юк;

— бар гражданнар җитештерү хезмәтендә катнаша;

— хезмәт гомуми хезмәт бурычына таянып башкарыла;

— барлык җитештерү продуктлары (хезмәт нәтиҗәсе) җәмгыять милкенә күчә (җәмгыять келәтләре) һәм утопиянең барлык әгъзалары арасында тигез бүленә:

— хезмәт белән барысы да шөгыльләнгәнгә күрә, тәэмин итү өчен алты сәгать эш көне дә җитә;

— фәнгә карата аеручы зур сәләтлелек күрсәткән кешеләр хезмәт эшчәнлегеннән азат ителә;

— иң пычрак эшләрне коллар башкара – әсирләр һәм хөкем ителгән җинаятьчеләр;

— җәмгыятьнең беренчел ячейкасы итеп кантуган гаилә түгел, ә «хезмәт гаиләсе» (чынында – хезмәт коллективы) була;

— бөтен вазифалы затлар сайланыла – турыдан яки читләтеп;

— ирләр һәм хатын-кызларда тигез хокуклар (тигез бурычлар кебек үк);

— халык Аллаһка ышана, диннәргә тигезкараш яши.

§25. Урта гасыр гарәп (гарәп телле) фәлсәфәсе

1. Гарәп (гарәп телле) фәлсәфәнең гомуми төшенчәләре һәм аны чорларга бүлү

Гарәп (гарәп телле) фәлсәфә дип, гарәпләр һәм гарәпләрнең мәдәни һәм сәяси йогынтысында булган Якын һәм Урта Көнчыгыш халыклары тудырган фәлсәфәне атыйлар.

Гарәп фәлсәфәсе үз үсешендә ике төп этап үтә

— VII – IX гасырлар – гарәп фәлсәфәсе туган чор;

— IX – XV гасырлар – гарәп фәлсәфәсенең борынгы грек фәлсәфәсен үзләштерү чоры, гарәп фәлсәфәсенең гарәп-грек фәлсәфәсенә әйләнүе.

2. Яшь гарәп фәлсәфәсе

Яңарыш чоры гарәп фәлсәфәсенең төп юнәлешләре

Мөтәкәллимнәр мәктәбе

Мөтәкәллимнәр радикаль ислам тарафдарлары була. Бу мәктәп вәкилләре исламның дини догмаларын фәлсәфи нигезлиләр һәм чынлыкта гарәп-схоластлар ролен башкаралар

Мөгътәзилиләр мәктәбе

Мөгътәзилиләр («аерымланганнар») шулай ук ислам фәлсәфәчеләре була, әмма алар тәгълиматының бер өлеше чагыштырмача материалистик характер йөртә

— күп ислам догмаларын кире кагалар (дәлилләп булмый торган башлангыч хакыйкать): дөнья, кеше барлыкка килүе, язмышның алдан билгеле булуы һәм мәсьәләне рационализм һәм материализм карашы ягыннан аңлатырга тырышалар;

— Аллаһ турындагы антропоморф күзаллауны кире кагалар (аңа ярашлы, Аллаһ кеше йөзендә булган)

— Аллаһ һәм Галәмне тиңләштерәләр;

— кешенең акыл көченә ышаналар;

— кеше әйләнә-тирә дөньяны акыл аша танып белә ала.

Суфичылык

Суфичылык вәкилләре (суфичылар, от суфйон, кыл кием; Аль-Бируни фикеренчә, «суфи» сүзенә аһәңле кеше өчен иң югары рәхәтлеккә ирешү өчен әйләнә-тирә дөньядан ирекле баш тарту, аскетлык, үз-үзеңә кереп китү, күзәтү, мистика хас.

3. Прогрессив гарәп фәлсәфәсе

Прогрессив гарәп фәлсәфәсенең яңа этабы (IX гасырдан башлап)

Хас сыйфатлар

— Материалистик идеяләр йогынтысы нығуы (бу медицина һәм табигый фәннәр өлкәсендәге ачышларга китерә);

— Европа фәлсәфәсеннән идея алынмалары, аеруча борынгы грек фәлсәфәсеннән, гарәп фәлсәфәсен гарәп-европа фәлсәфәсенә әйләндерү (гарәп-грек).

Яңа юнәллеш вәкилләре

— Әл-Кинди (800 – 879)

— Әбү Гали ибн Сина (980–1037)

— Әбү Насыйр Әл-Фараби (870 – 950)

— Әбү Вәлид бине Рөшд (Аверроэс) (1126–1198)

Әл-Кинди фәлсәфәсе

Прасубстанцияләр турында тәгълимат

Әл-Кинди прасубстанцияләргә кертә (категория аналогларына)

— материяне;

— форманы;

— хәрәкәтне;

— киңлекне;

— вакытны

Дөньяны танып була алу турындагы идея

Әл-Кинди фәнни танып белүнең өч баскычын билгели

— логик-математик;

— табигый фәнни;

— метафизик

Әл-Кинди фәлсәфәсенең әһәмияте

— Әл-Кинди гарәпләр өчен борынгы грек фәлсәфәсен аерым алганда Аристотель әһәмиятен ача. Аристотель идеяләре йогынтысы астында гарәпфәлсәфәсенә күп кенә материалистик идеяләр, категория төшенчәсе, мантыйк, танып белү турындагы тәгълимат керә.

— Әл-Кинди прасубстанцияләр турындагы үз тәгълиматын тәкъдим итә (категориянең гарәп аналогы).

— Фәлсәфәче ул вакыт өчен революцион фикер тәкъдим итә – кеше акылы белән дөньяны танып белү мөмкин. Моны мөтәкәллимнәр (ортодоксаль «ислам схоластлары») кире кага.

— фәнни танып белүнең өч баскычын бүлеп чыгара, хакыйкый белемгә ирешер өчен алар аша эзлекле үтү булырга тиеш.

— гарәп фәлсәфәсенә аристотелизм традицияләрен индерә (көнчыгыш перипатетикасы) һәм аны Европа һәм Азиядә иң прогрессив фәлсәфәгә әйләндерү өчен алшартлар төзи (урта гасыр схоластикасы белән чагыштырганда).

Фәлсәфә бүлеге

Әл-Фараби фәлсәфә хезмәтләренең әһәмияте

— Әл-Фараби Аристотель фәлсәфәсен системалаштыра һәм аны гарәп шартларына җайлаштырырга тырыша.

— «Эманацияләр» һәм Аллаһның чиксез куәтле түгеллеге турында беренче булып идея чыгара.

— Аның идеяләре Әбүгалисина (Ибн-Сина, Авиценна) фәлсәфәсенә нигез салырга ярдәм итә.

Әбүгалисина (Ибн-Сина, Авиценна) гарәп фәлсәфәсен яңа прогресс дәрәҗәсенә чыгара. Фәлсәфә буенча төп хезмәтләре: «Савыгу китабы» («Коткару китабы»), «Белем китабы», аларда Әбүгалисина

— ислам теологларының догматизмыннан көлә;

— фәлсәфәне диннән аерырга тырыша (замандашлары фәлсәфәнең дин каноннары белән тыгыз бәйли);

— фәлсәфәдә – дин аерым фән, ул кеше акылы казанышларын гомумиләштерергә тиеш;

— күп кенә фәлсәфә идеяләрен табигый фәннәр казанышларында нигезли (мәсәлән, үзенең медицина буенча ачышларында);

— Аллаһ барлыгын инкарь итми, ләкин куәтлеген танымый;

— әйләнә-тирәдәге күп нәрсә Аллаһ ихтыярыннан башка эшләнә дип исәпли;

— дөнья барлыкка килүнең сәбәбен «эманацияләрдә» – дөньяның Аллаһтан чыгуын, әмма Аллаһ ихтыяры белән түгел, ә табигый кирәклек буенча;

— «беренче төртеп җибәрү» идеясенә каршы чыга, хәрәкәт турындагы идея белән алмаштыра, материянең аерылгысыз үзенчәлеге дип саный;

— бар нәрсә материаль дип исәпли (Аллаһ та, әйләнә-тирә дөнья да);

— җанны аерым үзенчәлекләргә ия дип билгели – идеальлек (материя белән яшәү) һәм мәңгелелек;

— Аллаһ та, әйләнә-тирә дөнья да мәңгелек.

4. Аверроэса (Ибн-Рушда) фәлсәфәсе һәм аның Европа өчен әһәмияте (схоластикага каршы тору үзәге)

Ибн-Рушда фәлсәфәсе (аверроизм)

Төп положениеләр

— иҗат итү теориясе кире кагыла (дөнья мәңгелек, ул тудырыла алынмый һәм юкка чыгарылмый);

— Алла булу ихтималлыгы булырга мөмкин, әмма аның артында материянең беренчеллеге танылмый (Алла һәм әйләнә-тирә материаль дөнья мәңгелек төшенчәләр»);

— Алланың мөмкинлекләре чикле, аларның төп мөмкинлеге – материягә форма бирү;

— Алла һәр нәрсәне хәрәкәткә китерә дигән идея инкарь ителә;

— хәрәкәт – материянең үз-үзендә ябылган мөстәкыйль үзенчәлеге дәлилләнелә;

— каты детерминизм идеясе тәкъдим ителә (табигатьтәге бәйләнгәнлек һәм кирәклелек);

— җанның үлемсезлеге мөмкинлеге инкарь ителә (тәннең үлүе берсүзсез җанның үлүе, тик коллектив акыл – барлык кешелек акылы, аерым кешенең акылы аның бер өлеше, – үлемсез);

— «ике төрле хакыйкать» идеясе тәкъдим ителә – фәлсәфи һәм дини хакыйкатьләр бүленгән; диндә хак булган, фәлсәфәдә ялган булуы ихтимал һәм киресенчә.

Барлыкка килү һәм үсеш үзенчәлекләре

— Аверроэс гарәпләр хакимияттә булган Испаниядә яшәгән һәм эшләгән,һәм Көнбатыш – Европа фәлсәфәсе вәкиле була.

— Аның тарафыннан аверроизм фәлсәфәсе төзелә, ул Европада киң таралу ала, католицизм һәм схоластикага каршы тора.

— Аверроэс фәлсәфәсе үзенең асылы буенча материалистик була һәм алдынгы гарәп фәлсәфәсе (вәкилләре Әл-Кинди, Әбүгалисина) һәм системалаштырылган иҗади эшкәртелгән Аристотель тәгълиматы кушылмасы буларак туа. Материалистик, Аверроэсның дингә каршы фәлсәфәсе европа фәлсәфәсенә зур йогынты ясый. Аверроизм киң таралу ала, университетларда укытыла, схоластикага каршы торучы фәлсәфи тәгълиматларны тарату үзәге була

— Киләчәктә күренекле католицизм һәм схоластикчы Фома Аквинский аверроизмны тәнкыйтьләүче һәм Аверроэс фәлсәфи идеяләренә каршы көрәшүче була: аның хезмәтләре арасында «Аверростларга каршы акыл бердәмлеге турында» хезмәте бар.

§26. Фәлсәфә юнәлеше буларак рационализм һәм эмпиризм

Рационализм (лат. ratio – акыл) – фәлсәфә юнәлеше, аңа ярашлы, яшәеш һәм таныпбелүнең нигезе акыл була.

Онтологик рационализм

— Яшәеш нигезендә акыл башлангычы ята (ягъни яшәеш акылга ия). Бу очракта рационализм идеализмга якын (мәсәлән, Платонның «саф идеяләр турында« тәгълиматы, ул материаль дөньягакадәрге һәм ул әлеге материаль дөнья гәүдәләнеше була да инде).

— Рационализм идеализмга тиң түгел, чөнки рационализм мәгънәсе материягә (яшәешкә) карата беренчел булуда түгел, ә яшәешнең акылга ия булуда.

— Шулай итеп, илаһи яки башка акыл булуына, яшәешнең эчке мантыйлыгына инанганматериалистлар, рационалистлар була (Демократ, Эпикур һ.б.)

Гносеологик рационализм

— Танып белү нигезендә шулай ук акыл ята.

— Димәк, гносеологик рационалистлар урта гасыр теологиясе һәм схоластикасына каршы чыгыш ясый, аларның вәкилләре танып белүне Илаһи ачышта күрә һәм акылны инкарь итә.

— Моның белән беррәттән рационалистлар эмпиристлар – схоластларга каршы чыгыш ясаган яңа вакытта таралган фәлсәфә юнәлеше тарафдарларының оппонетлары була. Алар танып белү нигезендә ачыш түгел, ә белем һәм тәжрибәдә күрә.

Этика рационализмы

Аның асылы шунда ки, этика, тәртип нигезендә акыл ята.

Эмпиризм – фәлсәфә юнәлеше, аның яклылар танып белү нигезендә тәжрибә ята дип исәпли: «акылда моңа кадәр тәжрибәдә (хисләрдә) булмаган һич ни юк», «белем – көч»

— XVII гасыр Англиядә киң таралыш ала һәм аннары АКШта.

— Фрэнсис Бэкон эмпиризмга нигез салучы дип исәпләнелә.

— Танылган вәкилләре – Томас Гоббс, Джон Локк, Джон Дьюи (АКШ) була.

— Эмпиристлар, кагыйдә буларак, рационалистларның оппонентлары була.

§27. Декартның рациональ фәлсәфәсе.

Субстанция турында тәгълимат

1. Декарт фәлсәфәсе әһәмияте

Күренекле француз фәлсәфәчесе һәм математика галиме Рене Декарт (1596 – 1650) рационализмга нигез салучы дип исәпләнелә.

Декарт фәлсәфәсеәһәмия-те

— танып белүдә акыл әһәмия-тен әйдәүчедип билгели;

— субстанция турында тәгълимат тәкъдим итә, аның атрибутлары һәм модуслары;

— дуализм теориясе авторы була, моның белән фәлсәфәнең материалистик һәм идеалистик юнәлешләрне килештерергә тырышып карый;

— фәнни танып белү һәм «тумыштан булган идеяләр» турындатеория тәкъдим итә

Декартның акылга ия булу һәм танып белүдә беренчелеген раслау – рационализмның төп идеясы

— дөньяда кешегә аңлаешсыз булган күп әйберләр һәм күренешләр бар, (алар бармы? Аларның үзенчәлекләре нинди? Мәсәлән: Алла бармы?
— Галәмнең чиге бармы? һ.б.); аның каравы һәр нәрсәдә шикләнеп бу-ла (әйләнә-тирә дөнья бармы? Кояш яктыртамы? Җан үлемсезме?); димәк, икеләнү чыннан да бар, бу факт ачык һәм дәлилләү кирәкми; икеләнү – фикер үзенчәлеге, димәк, кеше икеләнеп фикер йөртә;

— чынбарлыкта булган кеше генә фикерли ала;

— димәк, фикерләү яшәеш һәм танып белү нигезе;

— фикерләү – акыл эшчәнлеге булганга яшәеш һәм танып белү нигезендә бары тик акыл аша гына була ала.

2. Декартның субстанцияләр турындагы тәгълиматы

Декарт яшәеш мәсьәләсен хәл иткәндә, яшәеш асылын характерлаган база, төп нигезле төшенчәне чыгараргa тели. Шуңа да фәлсәфәче субстанция төшенчәсен чыгара.

Субстанция – үзенең барлыгы өчен үзеннән башка бернәрсә дә таләп ителмәгән, бернәрсәгә дә мохтаҗ булмаган бар булган нәрсәләр ул.

Мондый сыйфат белән (үзенең барлыгы өчен бернидә дә кирәк булмау) бары тик бер генә субстанция ия һәм ул тик Аллаһ гына була ала, ул – мәңгелек, барлыкка китереп,юкка чыгарып булмый торган, чиксез куәтле, бар нәрсәнең чыганагы һәм сәбәбе.

Аллаһ белән тудырылган (яратылган) субстанцияләр (бердәнбер әйберләр, идеяләр) шулай ук субстанциянең төп сыйфатына ия – үзеннән башка үзенең барлыгы өчен бернигә дә мохтаҗ түгел. Тудырылган субстанцияләр бер-берсенә карата гына бәйсез.Югары субстанциягә – Аллаһка карата алар ясалмалы, икенчел һәм аңа бәйле.

Материаль субстанцияләр (әйберләр)

— Төп үзенчәлек – озынлык, ягъни бар материаль субстанцияләр гомуми билгегә ия – озынлык (озынлыкка, киңлеккә, югарылыкка, тирәнлеккә) һәм чиксез бүленә ала.

— Модуслар: форма, хәрәкәт, киңлектәге урнашуы һ.б.

Рухи субстанцияләр(идеяләр)

— Төп үзенчәлек – фикерләү, ягъни рухи субстанцияләр фикерләү үзенчәлегенә ия һәм бүленми.

— Модуслар: хис, теләк,тойгылар.

Кеше тудырылган субстанция буларак

— Бер-берсеннән аерылып торган ике субстанциядән тора – материаль һәм рухи.

— Ике субстаниция дә кушылган һәм яшәгән бердәбер зат, һәм бу аңа табигатьтән өскә күтәрелергә мөмкинлек бирде.

3. Декартның фәлсәфи карашлары

Декарт дуализмы

— Кеше үзендә ике субстанцияне берләштерә, димәк, дуалистик.

— Декартның дуализмы күзлегеннән «фәлсәфәнең төп мәсьәләсе» дә хәл ителә: нәр-сә беренчел – материя яки аңмы бәхәсе мәгънәсез. Материя һәм аң кешедә генә кушыла, ә кеше дуалистик булганга (үзендә ике субстанцияне берләштерә – материаль һәм рухи), шуңа материя дә, аң да беренчел була алмый – алар һәрвакыт бар һәм бербөтен яшәешнең ике төрле чагылышы була.

Танып белү мәсьәләләре

Танып белү мәсьәләләрен өйрәнгәндә фәнни метод

— Аның идеясенең асылы шунда ки, физика, математика һәм башка фәннәрдә кулланылган фәнни метод,танып белү барышында бөтенләй диярлек кулланылмый. Димәк, танып белү вакытында фәнни методны актив кулланып,танып белү процессын күпкә алга күчерергә мөмкин (Декарт буенча: «танып белүне кустарь һөнәрдән җитештерү сәнәгатенә әйләндерү).

— Шушы фәнни метод сыйфатында дедукция тәгъдим ителә (тик гомумидән шәхсигә – математик мәгънәдәтүгел,ә фәлсәфи мәгънәдә).

— Декартның фәлсәфи гносеологик метод мәгънәсе танып белү процессы барышында абсолют чын белемгә таянырга һәм чын логик ысуллар кулланып, акыл ярдәмендә яңа, шулай ук чын белемнәр чыгаруда. Дедукцияне метод буларак кулланып, акыл барлык танып белү өлкәләрендә дә чын белемгә ирешә ала.

Рационалистик-дедуктив методны куллангандагы тикшерү ысуллары

— тикшерү барышында башлангыч положение сыйфатында бары тик чын, абсолют дөрес, акыл һәм мантыйк белән дәлилләнгән, бернинди дә шикләнү тудырмаган белемне генә файдалану;

— катлаулы мәсьәләләрне аерым, берникадәр гадирәк бурычларга бүләргә;

— таныш булган һәм исбатланган мәсьәләләрдән таныш булмаган һәм дәлилләнмәгән мәсьәләләргә эзлекле күчү;

— тикшеренүнең эзлеклелеген, логик чылбырын сакларга, тикшерүнең логик чылбырында бер генә буынны даычкындырмау.

Танып белү мәсьәләләре

Тумыштан булган идеяләр турында тәгълимат. Бу теориянең асылы шунда ки, күпчелек белемнәр танып белү һәм дедукциягә бәйле ирешелә, әмма аерым бер төр белем бар, ул бернинди дә дәлилләүдә мохтаҗлык кичерми. Әлеге хакыйкать (аксиомалар) баштан ук бәхәссез һәм чын. Мондый ише аксиомаларны Декарт «тумыштан булган идеяләр» дип атый, ул һәрвакыт Аллаһ һәм кеше акылында яши һәм буыннан-буынга тапшырыла.

Тумыштан булган идеяләр төре

Тумыштан булган төшенчәләр – Аллаһ (бар); «сан» (бар), «ихтыяр», «тән», «җан», «структура» һ.б. лар;

Танып белү максатлары

— кешенең әйләнә-тирә дөнья турындагы белемен киңәйтү һәм тирәнәйтү;

— бу белемнәрне кеше файдасына табигатьтән алу;

— яңа техник чаралар уйлап чыгару;

— кеше табигатен камилләштерү;

— танып белүнең ахыргы максаты – кешенең табигать өстеннән хакимлеге.

§28. Яңарыш чоры һәм Яңа вакытта Нидерландлар фәлсәфәсе

1. Яңарыш чоры һәм Яңа вакытта Нидерландлар фәлсәфәсе

Яңарыш чоры һәм Яңа вакытта Нидерландлар фәлсәфәсе (XVI-XVII гасырлар)

Яңарыш чоры һәм Яңа вакытта Нидерландлар гуманистик һәм прогрессив фәлсәфәсе барлыкка килүнең алшартлары

— Нидерландларның һөнәрчелек һәм сәүдәдәге күренекле уңышлары (яңа техник чараларны куллану, уйлап чыгарулар, диңгездә йөрү үсеше, коммуникацияләр);

— Европаның башка илләренә караганда иртәрәк иҗтимагый-икътисади мөнәсәбәтләр;

— Европада беренче булып бужуаз-демократик революция (инкыйлаб);

— Халыкның югары белемлелек дәрәҗәсе, китап басу үсеше, гуманизм идеяләрен тарату;

Күренекле фәлсәфәчеләре

— Эразм Роттердамский;

— Гуго Гроций;

— Бенедикт (Барух) Спиноза;

2. Эразм Роттердамскийның «Христос фәлсәфәсе»

Дезидерий Эразм Роттердамский (1469-1536) фәлсәфәче, рухани, гуманист, «Төньяк Яңарышы» вәкиле. Иң күренекле әсәре – «Ахмаклылыкка мактау»

Фәлсәфәнең төп юнәлешләре	**Төп нәтиҗәләр**	**Кешегә хас сыйфатлар (Эразм Роттердамскийга ярашлы)**	
		Яхшы (теләнгән) сыйфатлар	**Яман сыйфатлар (теләнмәгән һәм кайгы бәла китерүче)**
— Урта гасыр схоластикасын тәнкыйтләү һәм көлү; — Яшь христианлыкны мактауда (яшь христианлык идеяләре һәм практикасына кайту – «яшь христианлык Ренессансы» һәм католиклек идеяле, оешкан, сәяси көчләүдән баш тартуда фәлсәфәче хак дин буларак христианлыкны саклап калу юлын күрә; — Әхлакый тәртипкә чакыру («Христос фәлсәфәсен» саклау»); — Дәүләт идеалы буларак көчле, әмма кешелекле монархияне нигезләү; — Әйләнә-тирә дөньяны аңлатырга тырышу һәм анда кеше тәртибенең оптималь юлын табу;	— Дөнья ике яклы диалектикалы) – бар нәрсә дә үзара бәйләнгән, хәтта барлык капма-каршы процесслар, күренешләр бербөтеннең төрле яклары була; — Теләсә ничек барлык көчкә эксцесс, аффектлар, экзальтация, нинди дә булса бер идея белән күзләр томалану – һәрвакыт тынычлык һәм дөрес акыл сакларга;	— азатлык; — тынычлыксөю; — тыйнаклык; — гадилек; — белемлелек; — Хак мәгънә;	— фанатизм; — наданлык; — ирексезләү; — икейөзлелек; — Чамадан тыш акыл катлаулануы – шуңа да схоластиканы – прогрессның «идеологик нигезләрен тәнкыйтьли.

3. Гуго Гроциянең табигый хокук теориясе

Гуго Гроций (1583-1645) – фәлсәфәче, юрист, җәмгыять эшлеклесе, Нидерландның социаль-сәяси һәм хокукый фәлсәфәнең чагу вәкиле

Фәлсәфи тикшеренүләрнең төп мәсьәләләре

— Гносеология (танып белү);

— Дәүләт һәм хокук;

— Сугыш һәм тынычлык мәсьәләсе;

— Халыкара мөнәсәбәтләр

Табигый хокук теориясе

Төп идеяләр:

— Хокук Аллаһ тарафыннан бирелми;

— Хокук кешедә иң баштан ук салынган була;

— Барлы хокукны ике зур бүлеккә бүлеп була – табигый хокук һәм язылган (позитив) хокук;

— Табигый хокук – кеше табигатенә салынган хокук ул(яшәү хокукы, абруйга хокук, азатлык хокукы һ.б.). Ул законда язылганмы, юкмы үтәлергә тиеш;

— Язылган (позитив) хокук – кеше тарафыннан төзелгән һәм рәсми чыганакларда-законнарда һ.б.ларда язылган тәртип нормалары ул;

— Рәсми (язылган, позитив) хокук табигыйлеккә таянырга һәм аңа комачамауламаска тиеш.

4. Баруха Спинозаның фәлсәфи тикшеренүләре

Баруха Спинозаның (Бенедикт (Барух) Спиноза (1632-1677) фәлсәфи тикшеренүләре – Яңа вакыт Нидерландларының нигезләнгән һәм ныклы эшкәртелгән фәлсәфи системасы авторы, Рене Декарт эшен дәвам итүче, Европа рационализмының күренекле вәкиле)

Декартның субстанция теориясе: Декарт теориясенең төп кимчелеге дип Спиноза аның дуализмын санаган, аңарда каршылыклар күрә, ул, Декарт буенча, түбәндәгедән гыйбарәт: субстанция – ул үзенең яшәеше өчен үзеннән башка бернәрсәгә дә мохтаҗ түгел булган асыл; барлык асыллар (субстанцияләр) шул уквакытта башка кемдер (нәрсәдер) тарафыннан барлыкка китерелгән – югары һәм бердәнбер хак субстанция – Аллаһ белән һәм үз яшәешендә аңа бәйле. Монда субстанцияләрнең башка субстаниciядән бәйсез булуы һәм шул ук вакытта аларның барысының да (барлыкка килүдә дә, яшәвенүдә дә) башка субстанция – Аллаһка бәйлелек каршылыгы күренеп тора.

Нигез булып тора

Спинозаның бердәм субстанция турындагы тәгълиматы

— Югары субстанция – Аллаһ һәм аның тарафыннан барлыкка китерелгән башка Субстанцияләр арасында аерма юк

— Барлык асылларны үз эченә туплаган бердәнбер субстанция бар

— Әлеге субстанция әйләнә-тирәне (Табигатьне) һәм Аллаһны үзендә туплый

— Табигать һәм Аллаһ – бер

— Табигатьтән тыш яшәүче һәм ижат итүче, табигатьтән өстен булган Аллаһ юк

— Аллаһ Табигать эчендә

— Тик бердәм Табигать-Аллаһ ижат итү сәләтенә ия, «тудыручы дөнья» була һәм «тудырылган дөнья»ны төзи– аерым әйберләр

— Аерым әйберләр үз-үзлегеннән генә яшәми, алар нибары тик күренешләр генә – бердәм субстанциянең «модуслары» – Табигать-Аллаһ

— Модуслар барлыгының тышкы сәбәбе бердәм субстанция (Табигать-Аллаһ), алар (модуслар) тулысынча аңарга бәйле, димәк, үзгәрешләргә дучар, вакыт һәм киңлектә хәрәкәт итә, яшәешләренең башлангычы һәм ахыры бар.

Табигать – Аллаһ субстанциясе сыйфатлары

— Яши

— Мөстәкыйль һәм кемгә дә булса бәйсез

— Үз-үзенең эчке (модуслар кебек тышкы түгел) сәбәбебар

— Күпләгән үзенчәлекләргә ия (атрибутлар), шуларның иң мөһиме – фикерләү һәм озынлык (әлеге очракта фикерләү һәм озынлык

— Бөтен субстанция үзенчәлеге, Декарттагы аерым модусларныкы кебек түгел)

— Киңлектә һәм вакытта чиксез

— Мәңгелек (тудырып булмый һәм юкка чыгарып булмый)

— Катып калган.

Барух Спинозаның фәлсәфи тикшеренүләр (дәвамы)

Этика мәсьәләләре

Детерминизм мәсьәләсе (табигатьтәге һәр нәрсәнең нигезле булуы)

Танып белү теориясе

Танып белүнең өч баскычы

— «саф хәлдәге танып белү», турыдан-туры кеше акылыннан чыккан һәм бернинди тышкы сәбәпләрдән тормаган, – танып белүнең югары төре;

— Акыл эшчәнлеге нәтиҗәсендә алынган танып белү (фикер йөртү, логик операцияләр), – икенче дәрәҗә,берникадәр чынлык кимрәк;

— Спинозага ярашлы, әйләнә-тирә дөнья чагылышы әлеге юл белән алынган белем дәлилләп булмый, дөрес, тулы түгел һәм өстен-өстен; ул хак белем алганда аеруча әһәмияткә ия түгел.

Этика мәсьәләләре

Ирек һәм кирәклелек үзара бәйләнеше мәсьәләсе

Нәтиҗәләр

— Субстанциядә ирек һәм зарурлык бер бөтенгәкушылалар;

— Аллаһка (Табигать) тулы ирек бирелгән, тик ул катгый зарурлык кысаларында эш итә;

— Модуслар (субстанция гәүдәләнеше – аерым әйберләр) бөтенләй ирекле түгел һәм тулысынча зарурлыкка буйсыналар;

— Модус-кеше башка модуслардан фикерли алуы белән аерылып тора, һәм, димәк, азатлыкка омтыла, тик, шул ук вакытта, модус буларак, ирекле түгел һәм зарурлык «тырнагында» була;

— Күңелендә ирекле булырга теләп, кеше еш кына зарурлык агымы буенча йөзә, ул агымны җиңә алмый һәм зарурлык белән килешергә мәҗбүр була (Спиноза билгеләвенчә, «рухи автомат» була);

— Азатлыкка юл – тышкы зарурлык эчкегә әйләнгәншартлар табу ул;

— Азатлык – танылган зарурлык ул;

Спиноза фикеренчә, кешегә азатлыкның иң югары дәрәҗәсе өчен кирәк булган әйберләр:

— Зарурлыкны субстация буларак максималь танып белү (Табигать-Аллаһ) – барлык асылның тышкы сәбәбе;

— Аффектлардан котылу (сагыш, шатлык, теләк һ.б.) – алар азатлыкка комачаулаганга күрә, кешене буйсындыра һәм зарурлык буенча хәрәкәт итәргә мәҗбүр итә;

Спиноза девизы: «Көлмәскә, еламаска, каргамаска, ә аңларга».

§29. Яңа вакытның инглиз фәлсәфәсе (материализм, эмпиризм, социаль-сәяси юнәлеше)

1. Алшартлар һәм Яңа вакыт инглиз фәлсәфәсенә гомуми характеристика

Яңа вакыт инглиз фәлсәфәсе (XVII – XVIII гасырлар)

Үзгә хас үзенчәлек (специфика)

— Материалистик юнәлгәнлек (Англиянең күпчелек фәлсәфәчеләре, башка ил фәлсәфәчеләренә капма-каршы, мәсәлән, Германиягә, яшәеш мәсьәләләрен материалистик формада аңлатырга тырышканнар һәм идеализмны кискен тәнкыйтьлиләр);

— Эмпиризмның рационализм өстеннән хакимлеге (Англия үз вакыты өчен танып белү мәсьәләләрендә эмпиризм җиңгән сирәк ил булды – фәлсәфи юнәлеш, танып белүдә рольне тәжрибәгә һәм хисси үзләштерүгә бирелә, ә рационализмнан аермалы буларак төп рольне ахылка түгел, тәжрибә һәм хисси үзләштерүгә бирә);

— социаль-сәяси мәсьәләләргә зур кызыксыну (Англия фәлсәфәчеләре яшәеш һәм танып белү асылын, кешенең дөньядагы ролен аңлатырга гына тырышмаган, бер ук вакытта җәмгыять һәм дәүләт барлыкка килү сәбәбен эзлиләр, реаль булган дәүләтләрне оптималь оештыру проектларын чыгаралар). Англия фәлсәфәсе XVIIгасыр өчен бик прогрессив була.

Яңа вакыт инглиз фәлсәфәсе (XVII – XVIII гасырлар)

XVII – XVIII гасыр инглиз фәлсәфәсенең характерына зур йогынты ясаган сәяси вакыйгалар

— XVII гасыр уртасы Оливер Кромвель революциясе (корольнең тәхеттән төшерелүе һәм җәзалап үтерелүе, республиканың аз яшәве, индепендентлар хәрәкәте);

— 1688 елгы «данлыклы революция (инкыйлаб)»;

— протестантизмның католицизмны җиңүе, англикан Чиркәвенең эчке автономиягә ирешүе, аның Рим Папасыннан бәйсезлеге;

— Парламент ролен ныгыту;

— Яңа буржуаз иҗтимагый-икътисади мөнәсәбәтләр үсеше;

Яңа вакыт инглиз фәлсәфәсе вәкилләре

— Фрэнсис Бэкон – эмпиристик (тәжрибәле) юнәлешкә нигез салучы дип исәпләнә;

— Томас Гоббс (дәүләт мәсьәләләренә зур игътибар бирә, «Левиафан» китабы авторы, «иҗтимагый килешү» идеясен тәкъдим итә);

— Джон Локк (дәүләт мәсьәләләрен өйрәнә, Т. Гоббс традициясен дәвам итә);

2. Ф. Бэкон фәлсәфәсендә танып белү мәсьәләсе

Ф. Бэкон фәлсәфәсендә танып белү мәсҗәләсе (Фрэнсис Бэкон (1561-1626) –инглиз фәлсәфәчесе һәм сәяси эшлеклесе (1620–1621 елларда – Бөекбританиянең лорд-канцлеры, корольдән соң икенче зат), фәлсәфәнең эмпиристик (тәҗрибәле) юнәлешенә нигез салучы)

Ф. Бэкон фәлсәфәсе әһәмияте

— Фәлсәфәнең эмпиристик (тәҗрибәле) юнәлешенә нигез салына;

— Гносеология (танып белү турындагы фән) фәлсәфәнең икенчел өлкәсеннән онтология (яшәеш турында фән) дәрәҗәсенә кадәр күтәрелә һәм теләсә кайсы фәлсәфә системасының ике төп бүлегенең берсенә әйләнә;

— Фәлсәфәнең яңа максаты билгеләнә – кешегә аның эшчәнлегендә гамәли нәтиҗәләргә ирешергә ярдәм итү (шуның белән Бэкон киләчәк Америка прагматизмына читләтеп булса да нигез сала);

— Фәнне классификацияләүгә беренче омтылыш ясала;

— Англиянең, шул ук вакытты тулысынча Европаның антисхоластик, буржуаз фәлсәфәсенә этәргеч бирелә;

Ф. Бэкон фәлсәфәсендә танып белү мәсьәләсе

Төп положениеләр

— Фрэнсис Бэконның төп фәлсәфи идеясе эмпиризмның асылы – танып-белү нигезендә фәкать тәҗрибә ятуда;

— Тәҗрибә күбрәк булган саен, (теоретик та, шулай ук практик та) кешелек туплаган (һәм аерым кеше), шулкадәр алар хак белемгә якынрак;

— Хак белем, Бэкон буенча, үзмаксат була алмый;

— Белем һәм тәҗрибәнең төп бурычлары кешегә үз эшчәнлегендә гамәли нәтиҗәләргә ирешергә ярдәм, яңа ачышлар барлыкка килүгә булышлык итү, икътисад үсешенә, кешенең табигатькә өстенлегенә. Моңа бәйле Бэкон тарафыннан аның фәлсәфи кредосын кыскача билгеләгән афоризм әйтә: «Белем–көч»

Индукция танып белүнең төп методы буларак

Үзенчәлекләр

— Индукция – фәлсәфәче күпләгән аерым күренешләрне гомумиләштерү һәм гомумиләштерү нигезендә гомуми нәтиҗәләр алу (мәсәлән, әгәр дә күп кенә металлар эресә, димәк, барлык металлар да бу үзенчәлеккә ия, ягъни эриләр).

— Индукция методын Бэкон Декарт тәкъдим иткән дедукция методына каршы куя, аңа ярашлы, хак белем чын мәгълүматка таянып логик ысуллар ярдәмендә алып була;

— Бэконның индукциясенең Декарт дедукциясеннән өстенлеге – мөмкинлекләрне киңәйтүдә, танып белү процессын интенсификацияләүдә;

— Индукция кимчелеге – аның дөрес булмавында, мөмкин булу характердалыгы (әгәр дә берничә әйбер яки күренеш уртак билгеләргә ия икән, бу шушы сыйныфтан булган барлык әйберләр һәм күренешләр дә шушы билгеләргә ия дигән сүз түгел; һәр аерым очракта индукцияне дәлилләү өчен эксперимент ясау киректе барлыкка килә);

— Индукциянең төп кимчелеген узу юлы (аның тулы булмавын, мөмкин булу характердалыгы), Бэкон буенча, – кешелекнең барлык белем өлкәләрендәкүбрәк тәҗрибә туплауда

Ф. Бэкон фәлсәфәсендә танып-белү проблемасы

Танып белү эшчәнлеге барлыкка килергә ярдәм итүче конкрет юллар

— «Үрмәкүч юлы» – «саф акылдан» белем алу, ягъни рациональ юл белән. Әлеге юл конкрет фактларны, гамәли тәҗрибәне санга сукмый яисә аларның ролен киметә. Рационалистлар реаль чынбарлыктан аерылган, догмалы һәм, Бэкон буенча, «үзләренең акылыннан үрмәкеч оясы үрәләр»;

— «Кырмыска юлы» – мондый белем алу ысулы, игътибарга тәҗрибә генә кабул ителгәндә, ягъни догматики эмпиризм (тормыштан аерылган рационализмның капма-каршысы). Бу ысул шулай ук камил түгел. «Саф эмпириклар» игътибарны гамәли тәҗрибәгә, берсенән-берсе аерылган фактлар туплауга, дәлилләүләргә юнәлтә. Шулай итеп, алар белемнең тышкы картинасын ала, проблемаларны тыштан, «читтән» күрә, әмма өйрәнеләсе әйбер һәм күренешләрнең эчке асылын аңлый, проблеманы эчтән күрә алмыйлар;

— «Бал корты юлы», Бэкон буенча, – идеаль танып белү ысулы. Аны файдаланып, тикшерүче-фәлсәфәче «үрмәкүч юлы» һәм «кырмыска юлы»ның барлык яхшы якларын ала һәм шул ук вакытта аларның кимчелекләреннән азат була. «Бал корты юлы» буенча барып, фактлар җыелмасын тупларга, аларны гомумиләштерергә кирәк (проблемага «тыштан» карарга») һәм, акыл мөмкинлекләрен файдаланып, проблеманың «эченә» кереп карарга, аның асылын аңларга. Шулай итеп, Бэкон буенча, танып белүнең иң яхшы юлы дип индукциягә нигезләнгән эмпиризмны санарга була (фактлар туплау һәм гомумиләштерү, тәҗрибә туплау).

Ф. Бэкон фәлсәфәсендә танып-белү мәсьәләсе

«Өрәк» («потлар»), кешегә каршы төшкән (кешелеклеккә хак белемнәр алуөчен)

Тумыштан килгән кеше ялгышлары, алар танып белү табигатен үз табигатең белән кушудан гыйбарәт

— **Ыру шәүләсе** – танып белүнең тулысынча кеше мәдәнияте (ыру) аша сынуы – ягъни кеше гомумкешелек мәдәнияте кысаларында булганда танып белүне гамәлгә ашыра, һәм бу нәтиҗәгә эз сала, белемнең хак булуын киметә;

— **Мәгарә шәүләсе** – конкрет кеше шәхесенең (танып белүче субъектының) танып белүгә йогынтысы. Нәтиҗәдә, кеше шәхесе (аның юкбарга ышануы, хаталары – «мәгарә») ахыр чиктәге танып белү нәтиҗәсендә чагыла;

Алынган ялгышлар

— **Базар шәүләсе** – сөйләм, аңлау аппаратын дөрес, төгәл кулланмау: сүз, аңлатма, гыйбарәләр;

— **Театр шәүләсе** – фәлсәфәдә яшәп килүче танып белү процессына йогынты ясау. Гадәттә, танып белү вакытында иске фәлсәфә яңа ысул кулланырга комачаулый, танып белүне һәрвакыт тиешле юнәлешкә җибәрми (мисал: урта гасырларда схоластиканың танып белүгә йогынтысы);

3. Ф. Беконның фәннәр классификациясе

Кеше акылының үзлекләре	Нигез буларак хезмәт итә	Ф. Беконның фәннәрклассификациясе
Хәтер		Тарихи фәннәр
Хыял		Хыял
Акыл		Фәлсәфә

Бэкон буенча фәлсәфә предметы:

— Табигать

— Аллаһ

— Кеше

Кешенең танып белү ысуллары:

— Турыдан-туры хисси үзләштерү ярдәмендә тәҗрибәбеләән

— Табигать аша

— Рефлексия ярдәмендә (фикернең үз-үзенә юнәлдерелүе, фикерне фикерләү аша өйрәнү)

4. Т. Гоббс фәлсәфәсе

Томас Гоббс (1588-1679) – Ф.Бэкон укучысы һәм фәлсәфи традицияләренең дәвамчысы

Фәлсәфи фикерләр:

— Теологик, схоластик фәлсәфәне катгый кире кага.

— Кеше эшчәнлегендә гамәли нәтиҗәләргә ирешүдә, фәнни-техник прогресска бу- лышлык итүдә ул фәлсәфәнең максаты дип билгели.

— Эмпиризм (тәҗрибә танып-белү) һәм рационализм (акыл ярдәмендә танып-белү)арасындагы бәхәстә эмпиризм ягында була; Декартның рационалистик фәл- сәфәсен тәнкыйтьли.

— Инанган материалист була.

— Җәмгыять һәм дәүләт мәсьәләләрен мөһим фәлсәфи проблемалар дип саный.

— Дәүләт теориясе эшкәртеп чыгара.

— Беренче булып дәүләт барлыкка килү нигезендә иҗтимагый (бердәм) килешү ята дигән идея тәкъдим итә.

5. Т. Гоббсның танып белү һәм дәүләт турындагы тәгълиматы

Гоббсның фәлсәфи тикшеренүләр предметы

Гносеология (танып белү турындагы тәгълимат): Т. Гоббс танып белү методы сыйфатында индукция һәм дедукцияне бер ук вакытта куллану өчен чыгыш ясый. Кеше танып белүгә тою аша ирешә дип исәпли. Тойгылы танып белү – сизү органнарының (күз, колак һ.б.) әйләнә-тирә дөньядан сигналлар алуы һәм аларның эшкәртелүе. Мондый сигналларны Т. Гоббс «билгеләр» дип атый.

Билгеләр классификациясе

— Сигналлар-хайваннар тарафыннан хәрәкәт яки теләкләрен белгертү өчен чыгарылган авазлар (кошлар «җырлавы», ерткычлар ырылдавы һ.б.лар);

— Тамгалар кеше тарафыннан аралашуөчен уйлап чыгарылган төрле билгеләр;

— Табигый тамгалар табигать «сигналлары» (күк күкрәү, яшен, болытлар һ.б.лар)

— Ирекле коммуникатив тамгалар – төрле тел сүзләре;

— Билге урынындагы «тамгалар» – махсус кодлаштырылган сөйләм, күпләргә аңлашылмагын (фәнни тел, жаргон, дин теле һ.б.);

— Билгеләрнең билгесе – исемнәрнең исеме – универсалияләр (гомуми төшенчәләр).

Җәмгыять һәм дәүләт мәсьәләсе, Гоббс фикере буенча, – фәлсәфәнең максаты – кешегә үз эшчәнлегендә гамәли нәтиҗәләргә ирешергә ярдәм итү, ә кеше конкрет җәмгыяттә һәм конкрет дәүләттә эш итә.

Җәмгыять һәм дәүләт турындагы теория

— Кеше табигате баштан ук явыз;

— Кеше белән хәрәкәт иттерүче көч шәхси табыш һәм эгоизм, ихтыяҗ, страсти, аффектлар;

— Саналган сыйфатлар һәр кешене барысына да хокуклы булуны тоюга китерә;

— Кешенең теләсә нәрсәгә хокуклы булырга һәм башкалар ихтыяҗларына битараф булуы аны барысына да каршы»га китерә, аларда җиңүче юк, ул кешеләрнең үзара бергәләп яшәү мөмкинлеген һәм икътисади прогрессны мөмкин түгел ясый;

— Бергә исән калу максатында кешеләр иҗтимагый килешү төзи, анда алар үзләренең дәгъва итү һәм «барысының да барысына да хокуклы булу»ны чиклиләр;

— Җәмгыять тормышы – дәүләт тормышын тәртипкә салу, «Барысына каршы сугыш»ны туктату, чикле эгоизмны басу өчен иҗтимагый институт (механизм) барлыкка килә;

— Авыр функцияләрне нәтиҗәле башкару өчен дәүләт чиксез көчле булырга тиеш;

— Дәүләт – ныкъ, күптөрле, гаять көчле албасты – «Левиафан», ул үз юлында һәммә нәрсәне йота һәм себереп үтә, каршы торалмаслык көч, әмма ул җәмгыять эшчәнлеген алып бару, тәртип һәм гаделлек тоту өчен кирәк.

6. Дж. Локк фәлсәфәсе. Хакимият бүленеше

Джон Локк (1632-1704) Бэкон һәм Гоббсның күп кенә фәлсәфи идеяләрен үстерә, берничә үз теориясен тәкъдим итә, Яңа вакыт инглиз фәлсәфәсенең эмпиристик һәм материалистик традицияләрен дәвам итә.

Дж.Локк фәлсәфәсенең төп положениеләре

— Дөнья материалистик;

— Танып белү нигезендә бары тик тәҗрибә ята («моңа кадәр тойгыларда булмаганнәрсә кеше акылында юк»);

— Аң – гомер барышында тәҗрибә белән тулган буш бина, (моңа бәйле Локкның аң турында «чиста такта» дигән (кайда тәҗрибә языдып бара) гыйбарәсе бар;

— Тәҗрибә чыганагы булып тышкы дөнья тора;

— Фәлсәфә максаты – кешегә үз эшчәнлегендә уңышка ирешергә булышу;

— Кеше идеалы – тыныч, законнан чыкмаучы, әдәпле кеше, ул үзенең белем дәрәҗәсен арттыра һәм һөнәрендә яхшы уңышларга ирешнә;

— Дәүләт идеалы – хакимиятнең бүленеш законнары чыгаруы, башкаруы (шул исәптән судныкы) һәм федеральга (тышкы сәясәт) нигезләнгә дәүләт. Локк шушыидеяне тәкъдим иткән беренче кеше була һәм бу аның зур казанышы.

§30. Лейбниц фәлсәфәсе. Монадалар турында тәгълимат

Лейбниц фәлсәфи тикшеренүләренең төп юнәлешләре (Готфрид Лейбниц), Яңавакытның күренекле вәкиле, немец фәлсәфәсенә элгәре вәкил.

Субстанция мәсьәләсе

Декарт һәм Спинозаның субстанция турындагы теориясен яңабаштан аңлау

— Декарт һәм Спинозаның субстанцияләр турындагы идеяләрен тикшергәч, Лейбниц аларның камил түгел дигән нәтиҗәгә килә.
— Беренчедән, Декарт дуализмны кабул итми, барлык субстанцияләр бүленеше мәгънәсендә (үз булмышы өчен үзеннән башка бернәрсәгә дә мохтаҗ булмаган асыллар), бер яктан, Аллаһ яраткан, тик аңа бәйсез субстанцияләр, икенче яктан – бар булган – матдига (озайтылган һәм рухи) (фикерләүче).

— Икенчедән, Лейбниц фикеренчә, Спиноза субстанцияләрне бергә берләштереп (Табигать-Аллаһ), Декарт дуализмын уза алмый, чөнки ул барын да модусларга бүлә (бердәнбер әйберләр субстанция чагылышы) ике класска – озайтылган һәм фикерләүче; ягъни Декарттагы ике төр субстанция булган төшенчәләр, Спинозада бер субстанциянең аналогик модуслар төренә әйләнә (чагылыш).

Монадалар турындагы теория (субстанцияләрнең күплеге)

Төп положениеләр

— Бар дөнья дуалистик булмаган, ә бербөтен табигатьле бик күп субстанцияләрдән тора (Декарт һәм Спинозадагы кебек ике төрле);

— Әлеге субстанцияләр монадалар дип атала (грекчадан «бердәнбер», «бер»);

— Монада гади, бүленми, озынлыгы юк, матди-әйбер түгел;

— Монада дүрт сыйфатка ия: омтылыш, теләк, үзләштерү, күзаллау;

— Үзенең асылы белән монада – ул бердәм, өзлексез үз торышын үзгәретеп торучы эшчәнлек;

— Үзенең яшәеше өзлексез булу сәбәпле, монада үзен төшенеп җитә;

— Монадалар абсолют йомык һәм бер-берсенә бәйсез (Лейбниц фикеренчә, «нәрсә булса да керә алырдай һәм аннан чыга алырдай тәрәзәләре юк»).

Монада класс (класс югарырак булган саен, аның акылы һәм иреклек дәрәҗәсе югарырак).

— «Ялангач монадалар» – терек булмаган табигать нигезендә ята (ташлар, җир, файдалы казылмалар);

— Хайваннар монадасы – хис-тойгыга ия, тик үсешмәгән үзаң белән;

— Кеше монадалары (җан)
— аң, хәтер, акылның уникаль фикерләү сәләтенә ия;
— Югары монада – Аллаһ.

Готфрид Лейбниц (1646-1716) – немец математика галиме, юрист, фәлсәфәче – соңгы классик фәлсәфәче дип санала. Рационализм юнәлешенә карый.

Гносеология мәсьәләләре

Эмпиризм һәм рационализмны килештерергә тырышу.

— Барлык белемне ике төргә бүлә«акыл хакыйкате» һәм «факт хакыйкате»;

— «акыл хакыйкате» акылның үзеннән бүлеп чыгарыла, логика ярдәмендә дәлилләнә ала, гомуми кирәк характерда була;

— «факт хакыйкате» – эмпиристик (тәҗрибә) юлы белән алынган белем (мәсәлән, магнит тартымы, суның кайнау температурасы, төрле металларның эрү температурасы); кагыйдә буларак, әлеге белемнәр фактны билгеләп кенә үтә, әмма аның сәбәпләре турында әйтми;

— Тәҗрибәле (эмпиристик, «факт хакыйкате») ихтималлык белеме булуга карамастан, аны белем буларак кире кагып булмый;

— Шулай итеп, танып белү ике белем төренең берсен – рациональ яки тәҗрибә ярдәмендә белем алу аша гына башкарылмый, ә ике төрен үзләштерү кирәк.

§31. XVIII гасыр Француз мәгърифәтчелеге фәлсәфәсе.

Гомуми характеристика

XVIII гасыр француз фәлсәфәсен Мәгърифәтчелек фәлсәфәсе дип атау кабул ителгән. Бу чор фәлсәфә мондый атаманы аның вәкилләренең Аллаһ, әйләнә-тирә дөнья һәм кеше турындагы күнегелгән күзаллауны җимерүгә бәйле ала. Алар үзләренең фәлсәфи тикшеренүләрендә новаторлык күрсәтәләр, туып килүче буржуазия идеяләрен ачыктан-ачык пропагандалый, һәм, ахырда, 1789 – 1794 елгы Бөек француз революциясен идеологик яктан әзерлиләр.

Төп юнәлешләр

Сыйфатламасы

Деизм

Вәкилләр

— Вольтер

— Монтескье

— Руссо

— Кондильяк

— Шәхси Аллаһ идеясен кире к агалар;

— Аллаһ һәм Табигатьне тиңләштерү белән килешмиләр (пантеизм белән);

— Аллаһта барлык булганның башлангычын күрәләр (тик моннан ары түгел);

— Аллаһның табигать һәм кешеләр эшенә тыгыла алуын, тарих барышына, үзе тудырганнан соң әйләнә-тирәгә йогынты ясый алуын кире кагалар.

Атеистик-материалистик юнәлеш: бу юнәлеш яклылар Алла барлыгы идеясен үзен кире кагалар, дөнья һәм кеше барлыкка килүне материалистик һәм табигый-фәнни позициядән чыгып аңлаталар, танып белү мәсьәләләрендә эмпиризмга өстенлек бирәләр.

Вәкилләр

— Мелье

— Ламетри

— Дидро

— Гельвеций

— Гольбах

Француз Мәгърифәтчелек фәлсәфәсенең утопик-социалистик (коммунистик) юнәлеше XVIII гасыр уртасында формалаша башлый.

1789 – 1794 елгы Бөек француз революциясе вакытында һәм ул тәмамланганнан соң таралыша.

Вәкилләр

— Мабли

— Морелли

— Бабеф

— Оуэн

— Сен-Симон

§32. XVIII гасыр француз Мәгърифәтчелегенең деистик фәлсәфә юнәлеше

1. Деизм фәлсәфә юнәлеше буларак деизм

Деизм – фәлсәфәдәге юнәлеш, аның яклылар Аллаһ барлыгын беренчел сәбәп итеп кенә булу ихтималлыгын хуплыйлар, бар булганны тудыручы буларак, әмма Аны киләчәктә әйләнә-тирәгә, кешегә, тарихка йогынты ясаучы булуын кире кагалар, Аллаһны зат рәвешендә кабул итүне дә (кеше сыйфатларын бирүне), табигать белән тиңләшүгә дә каршы чыгалар (пантеизм).

Күренекле французфәлсәфәчеләре

— Вольтер

— Монтескье

— Руссо

— Кондильяк

2. Вольтер фәлсәфәсе. «Мәгърифәтле абсолютизм»

Вольтер (чын фамилиясе – Аруэ) Франсуа (1694 – 1778) – фәлсәфәче, язучы, публицист, француз Мәгърифәтчелегенә нигез салучыларның берсе.

Фәлсәфи карашлар

— Дингә каршы чыгыш ясый, аеруча католицизмга каршы (дингә кагылышлы аның түбәндәге сүзләре бар: «Кабәхәтне сытыгыз!»);

— Аллаһны әйләнә-тирәне барлыкка китерүче итеп исәпли, бар нәрсәне бәйләүче башлангыч дип карый, тик бернинди дә теория, бернинди дә практика аның барлыгын да, Аның юклыгын да дәлилли алмый дип ышана; җәмгыятьтәге тәртипне саклау, кешеләрне буйсындыру (Аллаһ җәзасы куркынычы астында) һәм әхлак кысаларында тоту өчен Аллаһ барлыгын әхлакый-эстетик фикер ягыннан кабул итү кирәклеген таный;

— Танып белү мөнәсәбәтендә эмпиризм һәм рационализмны тәңгәл китерү, өстенлекне беренчесенә бирү;

— Гади халыкка кешелекле мөнәсәбәт һәм аның хокукларын ихтирам итү өчен чыгыш ясый, тик дәүләт идеалы итеп мәгърифәтле хаким җитәкчелегендәге абсолют монархияне исәпли, (ягъни «мәгърифәтле абсолютизм» идеясен тәкъдим итә), шулай ук берничә «мәгърифәтле» монархлар белән язышкан (алар арасында Екатерина IIдә була) һәм дәүләт төзелеше буенча гамәли киңәшләр бирә.

3. Монтескье фәлсәфәсе. «Җәмәгатьчелек килешүе», хакимиятнең бүленеше

Шарль Луи Монтескье (1689 – 1755) – француз фәлсәфәчесе, язучы, юрист, галим (күп кенә өлкәләр буенча)

Фәлсәфи карашлар

— Деизм позициясеннән чыгыш ясый – Аллаһта булдыручыны күрә, тик ул аның кеше эшләренә һәм табигать процессларына кысылуын инкарь итә;

— Аллаһта тәртип саклау һәм әхлак тәрбияләү чарасын күрә;

— Җан үлемсезлеге идеясен кире кага, хакимияткә һәм җәмгыятьтәге йогынтыга дәгъва итүләре, дингә ышанучыларны ялгышлыкка керткәннәре (күп кенә мәсьәләләр буенча) һәм кеше инициативаларын баскан өчен христианлык һәм католик Чиркәүләрне тәнкыйтьли;

— Тарих кешеләр тарафыннан салына, ә Илаһи билгеләнеш көче белән түгел дип исәпләгән;

— Җәмгыять төзелешендә климат һәм географиянең йогынтысын күрә (көньяк илләрендәге кызу климат гадәттә, деспотизмга тартыла, төньяклар суык климатлы – демократиягә, урта климатлы урта Европада деспотизмнан демократиягә һәм киресенчә даими күчәләр;

— Дәүләт барлыкка килгәнче «табигый хәл» булган дип исәпли, монда кешеләр бер – берсе белән хисаплашмыйча үзләренең инстиктларын күрсәтә алалар һәм ихтыяҗларын канәгатьләндерәләр, әмма мондый яшәү мөмкин булмый башлагач, кешеләр «җәмәгатьчелек килешүе» нигезендә дәүләт төзи, ул бер-берсенең хокук һәм җаваплылыкларын тануны карый һәм халык алдындагы хакимият барлыкка килә;

— «Хакимиятнең бүленеше» идеясен тәкъдим итү – ягъни дәүләт хакимиятнең нәтиҗәлерәк эшләве һәм деспотизмны юкка чыгару өчен, властьны закон чыгару, башкару һәм судка бүлү

— Закон өстенлеге өчен чыгыш ясый

Монтескье идеяләре, аларга нигезләнеп хәзерге заман демократик дәүләтләр төзелә

— Закон өстенлеге идеясе

— Хакимиятнең закон чыгару, башкарма һәм судка бүленеш идеясе.

4. Руссоның революцион-демократик фәлсәфәсе. Җәберләнгән күпчелекнең баш күтәрүгә хокукы.

Жан Жак Руссо (1712 – 1778) төп игътибарны социаль-сәяси фәлсәфәгә бүлә, революцион демократия позициясеннән чыгыш ясый

Руссо фәлсәфәсенең төп нигезләре

— Аллаһта дөнья ихтыяры һәм дөнья акылы

— Материяне ясап булмый һәм аны һәрвакыт объектив бар дип исәпли;

— Кеше үлә торган тән һәм үлемсез җаннан тора дип саный;

— Кеше дөньяны танып белү көчендә түгел (аерым алганда, әйбер һәм күренеш асыллары);

— Тулаем алганда дингә, христианлыкка каршы чыга, әмма динне бетерү аркасында әхлак һәм мораль чикләүләр түбәнәюеннән курку өчен дингә алмашка – «гражданнар динен» төзергә тәкъдим итә, «бөек җан культы (Аллаһ)», «дөнья ихтыяры культы» һ.б.лар;

— Эмпиристик (тәҗрибәле) танып белү яклы була;

— Җәмгыятьтәге каршылыкларның төп сәбәбе – ул хосусый милек;

— Халыкның баш күтәрүгә булган хокукын нигезли (җәберләү, хокук һәм милектән мәхрүм ителгән күпчелек паразитар азчылыкны һәм хакимне тәхеттән төшерү хокукына ия һәм үз күзаллаулары буенча җәмгыять төзи ала);

— Гадел, идеаль җәмгыятьтә барысы да тигез хокукка ия булырга тиеш, ә хосусый милек барлык гражданнар арасында яшәү өчен кирәк булган күләмдә (ләкин баер өчен түгел) тигез бүленергә тиеш;

— Хакимият парламент аша түгел, ә гражданнар белән – турыдан-туры җыелыш, җыеннар аша тормышка ашырылырга тиеш

— Киләчәктә дәүләттә бала тәрбияләүнең принципиаль яңа системасы кулланырга тиеш: балалар әйләнә-тирә дөньядан махсус уку йортларында аерып урнаштырылырга тиеш, анда аларны яңа җәмгыять кешеләре – шәхси ирек, үзара ихтирам идеяләрендә, дингә һәм деспотизмга карата түзә алмаслык итеп, һөнәргә ия һәм әйдәүче фәннәрне аңлаучы итеп тәрбияләячәкләр.

5. Кондильяк сенсуализмы
(танып белүдәге хисси тәҗрибәнең өстенлеген нигезләү)

Этьенн Кондильяк (1715 – 1780) җәмгыятьтәге мәсьәләләргә азрак игътибар итә һәм төп көчен танып белү мәсьәләләрен (гносеологияне) тикшерүгә юнәлтә

Кондильякның төп фәлсәфи идеяләре

— дөньяны танып була;

— кеше тышкы дөньяны шулкадәр танып белә алачак, күпмегә аңа үзенең мөмкинлекләре (акылы, сиземе-ләү органнары) моны эшләргә мөмкинлек бирәчәк;

— әйләнә-тирә дөнья барлык белемнең чыганагы булып тора;

— танып белү нигезендә хисси үзләштерү ята (сиземе-ләү органнарының әйләнә-тирә чынбарлыкны кеше акылында чагылдыруы);

— хисси үзләштерү катнашлыгыннан тыш мөстәкыйль рәвештә танып белү юк.

§33. XVIII гасыр француз Мәгърифәтчелеге фәлсәфәсенең атеистик-материалистик юнәлеше

1. Атеизм һәм материализмның гомуми төшенчәләре. Атеистик-материалистик фәлсәфә

Атеистик-материалистик фәлсәфә XVIII гасыр Франциядә Бөек француз революциясенә кадәр һәм аның вакытында таралу ала

Күренекле вәкилләре

— Мелье

— Ламетри

— Дидро

— Гельвеций

— Гольбах

Атеизм – фәлсәфә юнәлеше, аның вәкилләре тулысынча Аллаһ барлыгын, динне инкарь итә.

Материализм – фәлсәфәдәге юнәлеш, әйләнә-тирә дөньяның мөстәкыйль идеаль (рухи) башлангыч белән тууын һәм бар булуын кабул итми һәм әйләнә-тирә дөньяны, аның күренешләрен, кешене табигый фәннәр күзлегеннән аңлата.

Атеистик-материалистик юнәлеш француз фәлсәфәчеләре эшчәнлегенең фәлсәфә һәм гомумән җәмгыять өчен әһәмияте түбәндәгедә:

— Ике әйдәүче фәлсәфә юнәлеше булуын төгәл билгеләделәр – материализм һәм идеализм («Демокрит линиясе» һәм «Платон линиясе»);

— Фәлсәфәне бик күп дини ышанулардан азат итә;

— Субстанциягә төгәлрәк билгеләмә – материя бирелә;

— Аң турында материя үзенчәлеге буларак үз-үзен чагылдыру идеясен тәкъдим итәләр (әлеге вакытта да таралыш алган);

— Тәҗрибәгә кадәргене, сиземнән тыш («саф») белемне тәнкыйтьлиләр;

— Материаль сенсуализм теориясен нигезли һәм тарата (белем нигезендә хисләр ята);

— Барлык бердәм әйберләрнең микрокисәкләрнең төрле комбинацияләре булуы турындагы идеяне тәкъдим итте ләр;

— Хәрәкәтне гадәттән тыш күренеш буларак түгел, ә аның материя үзлегенә игътибар итә;

— Социаль гаделлек идеясен дәлилли;

— Бөек француз революциясен идеологик яктан әзерли.

2. Мелье фәлсәфәсе

Жан Мелье (1664 – 1729) – һөнәре буенча рухани, яшәү барышында Аллаһны һәм динне инкарь итүгә килгән (атеизмга), фәлсәфәче-материалист

Фәлсәфәнең төп положениеләре:

— Гадәттән тыш бернәрсә дә мөмкин түгел ди (шул исәптән Аллаһ та);

— Материяләрдән аеры идеяләр булуына, җанның үлемсезлегенә ышанмый;

— Бар әйләнә-тирә дөнья махсус субстанциядән – материядән тора дип исәпли;

— Барлык әйберләрнең башлангычы материядә, ул мәңгелек, аны тудырып булмый, ул чынлап та бар, үзгәрә һәм үзенә салынган үзенчәлек-хәрәкәт аркасында даимиүсешә;

— Материя кечкенә кисәкчәләрдән тора, аларның комбинацияләре нәтиҗәсендә әйберләр барлыкка килә;

— Танып белү – материянең үз материя чагылышы;

— Күпчелек белемнең чыганагы булып хис-тойгылар тора;

— Социаль антагонизмнарның сәбәбе кешеләрнең «яман ихтыярыннан» физик хезмәттән котылырга теләгәннән туган хосусый милек;

— Абсолютизмны бәреп төшерү, яшәп килүче дәүләт һәм хосусый милекне юк итү өчен чыгыш ясый;

— Җәмгыять сыйфатында киләчәктә тугандаш общиналар берлеген күрә, аның әгъзалары тигез, бергә яши, бергә җитештерү хезмәте белән шөгыльләнә, алган керемне бүлешәләр һәм шатланып яшиләр.

3. Ламетри фәлсәфәсе

Жюльен Ламетри (1709-1751)

Фәлсәфәнең төп положениеләре:

— Идеализм һәм теологияне тулысынча инкарь итә.

— Әйләнә-тирә дөньяны бердәм субстанциянең – тудырып булмый торган, мәңгелек, чиксез материянең төрле чагылыш җыелмасы дип санаган.

— Җан, аң, тойгы, Ламетри буенча, табигый барлыкка килә, материянең үзенчәлегебула.

— Материя бәйсез булганнан, Аллаһның мәңгелек ихтыяҗ юк.

— Дөньяны тулысынча танып белү яклы чыгыш ясый, өстәвенә танып белүдә төпрольне тойгы органнарына калдыра.

— Утилитарист була – кеше яшәешенең мәгънәсе – шәхси бәхет.

— Хосусый милекне кеше иркенең гаранты дип саный.

— Дәүләт идеалы итеп «мәгърифәтле абсолютизм»ны саный.

4. Философия Дидро

Дени Дидро (1713 – 1784) – иң күренекле француз материалист-фәлсәфәчесе. Дидро Мәгърифәтчелеккә зур өлеш кертә, «Фән, сәнгать һәм һөнәрләр энциклопедиясе»н төзүне тәкъдим итә. «Энциклопедия» дини хорафаттан азат һәм әйдәүче фән, сәнгать һәм җитештерү өлкәсендәге белем нигезләре була, буржуаз караш нигезен сала. Аны төзүдә чорның әйдәүче фәлсәфәчеләре – Дидро замандашлары: Вольтер, Монтескье, Кондильяк, Гольбах һәм башкалар катнаша. «Энциклопедия» 20 елдан артык төзелә.

Фәлсәфи карашлар

— Материяне бердәнбер субстанция итеп таный, аның чагылышы итеп бар бердән бер әйберләрне исәпли

— Хәрәкәтне материянең төрлелеге белән аңлата (материянең төрле сансыз күләмдәге өлешләре хәрәкәткә китерә);

— Галәмнең рухи башлангычын кире кага, аңны материя үзенчәлеге дип исәпли;

— Җәмгыять һәм дәүләт нигезендә «җәмгыять килешүе»н күрә, моңардан чыгып, хакимиятнең һәм феодальларның илаһилыгын кире кага;

— Дәүләт идеалы итеп «мәгърифәтле монархия»не исәпли, ә икътисад – акыл белән бүленгән, күпчелек ихтыяҗы булган хосусый милек.

§34. Француз фәлсәфәсенең социалистик-утопик (коммунистик) юнәлеше

1. Утопик-социалистик фәлсәфә һәм аның XVIII–XIX гасыр башы Франциядәге әйдәүче вәкилләре

Социалистик-утопик (коммунистик) юнәлеш XVIII гасырның икенче яртысында – XIX гасыр башында Франция фәлсәфәсендә киң таралыш ала. Бу юнәлеш вәкилләре яшәп килгән иҗтимагый-икътисади һәм сәяси стройны катгый рәвештә тәнкыйтьли, иҗтимагый милеккә нигезләнгән яңа җәмгыять һәм дәүләт төзү проектларын тәкъдим итә, биредә социал-утопистлар тарафыннан гомум тигезлек буларак аңланылган гаделлек идеясе тантана итә. Социалистик-утопик (коммунистик) идеяләр Франциянең 1789 – 1794 елгы Бөек француз сугышына чаклы һәм аның вакытында гади халык катламнары арасында хуплау таба.

Күренекле вәкилләр

— Мабли

— Бабеф

— Сен-Симон

— Фурье

2. Мабли фәлсәфәсе (борынгы (кыргый) коммунизмның өстенлекләре)

Габриэль Мабли (1709 – 1785) – фәлсәфәче, тарихчы, язучы (Кондильякның туганы), Франция фәлсәфәсенең социалистик-утопик юнәлешкә нигез салучыларның берсе

Фәлсәфәнең төп положениеләре:

— Мәгърифәтчелек фәлсәфәсен тулысынча каты тәнкыйтьли (үз чорын «буш сүзләр һәм парадокслар» вакыты дип билгели);

— Материализмны да, деизмны да кире кага;

— Атеистлар, материалистлар, деистлар (ә алар исәбенә шактый күп фәлсәфәчеләр кергән – Маблиның замандашлары һәм ватандашлары) әйләнә-тирә дөньяны һәм кешене өйрәнүгә бик схематик, механик рәвештә карыйлар, халыкның җанын үтерәләр, әдәпкә бернинди игътибар итмиләр дип исәпли;

— Фәлсәфәнең төп билгеләнеше дип әдәп һәм әхлакны таратуны билгели; бу максатка ук көчле, дәүләт ярдәмен тойган, киң таралыш алаган дин дә буйсындырылырга тиеш;

— Декарт дуализм идеясе яклы була, аңа ярашлы кеше матди (тән) һәм рухи башлангычны берләштерә, – моннан, Мабли буенча, кешеләрнең тәртибе һәм гамәлләренә зур йогынты була, көчле теләк, үз-үзенә мәхәббәт, күңелсезлекләрне урап узарга омтылу, рәхәт алуга тартылу;

— кеше табигате аны үзе башка кешеләр белән – җәмгыять белән яшәргә этәрә дип санаган;

— барысы да гомум булган примитив иҗтимагый төзелеш, ә кеше эшчәнлеге үзен һәм ырудашларын тәэмин итүгә юнәлдерелгән булган (баю өчен түгел), «кешелекнең алтын чоры» дип исәпләгән;

— борынгы коммунизмның, «кешелекнең алтын чоры» үлүенең сәбәбе, һәм җәмгыятьтәге башка күңелсезлекләрнең сәбәбе хосусый милек барлыкка килү һәм кешеләрнең сыйныфларга бүленешендә дә дип санаган;

— җәмгыять идеалы итеп борынгы община коммунизмында күрә, сыйныфларга бүленеше булмаган, хакимиятның халыктан аерылмаган, тигезлек, гаделлек, кешеләр туганлыгы тантана иткән, хосусый милексез җәмгыятькә кайтырга чакыра;

— шул ук вакытта үзенең идеаллары тормышка ашырып булмый дип саный, хосусый милек мәңгелек һәм бетереп булмый, сыйныфларга бүленеш һәрвакыт булачак, ә халык көрәшкә күтәрелә алмаячак, күтәрелсә дә, кеше табигатенә бәйле, көчле дәрт, җиңел табыш һ.б. коммунизм кысаларында гына кала алмаячак.

3. Бабеф фәлсәфәсе (хәрби күтәрелеш аша, сәяси һәм икътисади тигезлеккәнигезләнгән коммунистик җәмгыять казанышлары)

Франсуа Бабеф (псевдонимы (тәхүллүсе) – **Гракх Бабеф**) (1760 1797) беренче ком мунист-теоретик һәм практигы дип исәпләнелә.

Фәлсәфәнең төп нигезләре:

— барлык фәлсәфи теорияләрне кире кага, аның фикеренчә, алар яртылаш характер йөртә һәм халыкка бәхет китерү максатына буйсындырылмаганнар;

— яшәп килүче җәмгыять һәм дәүләтне каты тәнкыйтьли;

— төп социаль явызлык дип хосусый милек барлыкка килүен һәм җәмгыятьнең капма-каршы сыйныфларга байлар һәм ярлыларга бүленүендә күрә;

— сыйныфка бүленеш булмаган, хосусый митлексез, җир кем анда эшли, шунысы булган икътисади һәм сәяси тигезлеге булган, бердәм хезмәт һәм җитештерелгәннәрне дәүләтнең барлык кешеләре арасында тигез бүленгән җәмгыять төзеп була дип санаган;

— коммунистик җәмгыять төзүне бары тик ярлыларның байларга каршы революция ясау юлы белән генә ирешеп була дип санаган. Бабеф беренче фәлсәфәче-коммунист була, ул үз идеяләрен гамәлдә кулланып карый. Аның тарафыннан кораллы баш күтәрүгә әзерлек алып барыла, манифестлар төзелә һәм булачак революцион хөкүмәтнең программасы уйланыла. Бу оешма «Тигезлек хакына заговор» дигән атама ала. 1797 елда заговор ачыла, ә Бабеф һәм аның башка көрәштәшләре җәзалап үтерелә.

4. Икътисади детерминизм һәм Сен-Симонның «җитештерү җәмгыяте» фәлсәфәсе

Клод Сен-Симон (1760 - 1825) Франциядәге утопик социализм традициясен дәвам итә

Фәлсәфәнең төп нигезе:

— дөньяны диалектик тануга якын килә (капма-каршылыкның берлеге һәм көрәше);

— социаль физиология теориясен чыгара, биредә җәмгыятьне тулы бер-бөтен организм итеп карый;

— җәмгыять нигезләнүче өлкә итеп икътисадны карый (икътисад, җитештерү мөнәсәбәтләре барысын да билгели – сәясәтне, социаль мөнәсәбәтләрне, дөньяга караш) – икътисади детерминизм;

— җәмгыятьтә икътисад һәм җитештерү мөнәсәбәтләре үсешкән саен, җәмгыять түбән формадан югарыга, бер баскычтан икенчесенә күчә дигән идея чыгара (бу киләчәктәге К. Марксның иҗтимагый-икътисади формацияләр теориясе яралгылары була);

— фәлсәфә максаты дип яхшы, акыллы җәмгыять төзүне күрә;

— Сен-Симон буенча, иң яхшы җәмгыять ул үз әгъзаларына мөмкин кадәркүбрәк ихтыяҗларын канәгатьләндерә алган җәмгыять;

— Сен-Симон иң яхшысы сыйфатында «җитештерү җәмгыятен күрә, ул иерархия принцибы буенча төзелеп, социаль баскыч кешенең сәләтләреннән чыгып билгеләнә («сәләтләр иерархиясе»), нәсел буенча мираска калдыру тыелачак (барысының да мөмкинлекләрен тигезләү өчен, эшсезлек һәм бәйрәм ясауларны туктату, һәрберсенә яңабаштан башлау мөмкинлеге бирү һәм җәмгыятьтә сәләте мөмкинлек биргән дәрәҗәгә ирешү), барысына да мотлак эшләү бурычы куела, ә икътисадка план буенча үсешергә (артык җитештерү яки дефицитны булдырмау һәм барлык җәмгыять әгъзаларының ихтыяҗларын канәгатьләндерү);

— бу җәмгыять белән индустриаль сыйныф вәкилләре җитәкчелек итәчәк (ягъни буржуазия), тик хосусый милек иясе сыйфатында түгел, ә халык хуҗалыгы организмының төрле буыны белән идарә итүче буларак.

Шулай ук Сен-Симон исәпләгән:

— пролетариат һәм буржуазия бер сыйныфка – индустриальгә килеп берләшәчәк;

— киләчәккә оптимистик караган – кешелек идеаль җәмгыять төзүгә дучар ителгән;

— яңа җәмгыять революцион юл белән түгел, ә эволюцион юл белән – даими үсешкән икътисад җәмгыятьнең сыйнфый-антогонистиктан ассоциативка әйләнүенә китерә;

— яшәп килгән динне яңа дин белән алыштыру турындагы теория тәкъдим итә, аныңмәгънәсен шушы лозунг ача: «Кеше кешегә – туган».

5. Франсуа Фурье (1772 - 1837) шулай ук күренекле социалист-утопистларга керә. Аның фәлсәфәсенең түбәндәге төп положениләрен бүлеп чыгарып була:

— буржуаз мораль ялган;

— атеизм хәвефле, чөнки кешене киләчәккә булган өметтән аера;

— кеше, тарих, җәмгыять табигать законнары буенча үсә;

— буржуаз җәмгыять өч төп каршылыкка ия – шәхси ихтыяҗлар арасында(магнатлар, буржуа) һәм иҗтимагый (калган халык), социаль-икътисади (балансланмаган, артыклык яки җитештерү кризисы бирүче), мораль (буржуаз никах һ.б.);

— идеаль җәмгыять – «гармония җәмгыяте», ул гомум хезмәт бурычына, бүленеш кагыйдәләренә, икътисадның югары дәрәҗәсенә, мәхәббәт һәм әхлак иркенә, Аллаһка ихтирамга нигезләнә.

§35. Дөнья фәлсәфәсе буларак, XIX гасыр немец фәлсәфәсе, аның төп юнәлешләре һәм идеяләре

1. XIX гасыр немец фәлсәфәсенең төп юнәлешләре һәм мәгънәсе

гасыр немец фәлсәфәсе

Немец фәлсәфәсенең төп юнәлешләре

— немец классик фәлсәфәсе (XIX гасырның беренче яртысы);

— материализм (XIX гасыр уртасы һәм икенче яртысы);

— иррационализм (XIX гасырның икенче яртысы һәм ахыры), «тормыш фәлсәфәсе».

Мәгънәсе

— кешелекне гасырлар буена борчыган проблемаларны тирәнтен тикшерү, һәм фәлсәфәнең киләчәген билгеләүче нәтиҗәләргә килү;

— ул чорда билгеле булган барлык фәлсәфи юнәлешләрне–субъектив идеализмнан алып вульгар материализмга һәм иррационализмга кадәр берләштерү;

— дөнья фәлсәфәсенең «алтын фонды»на (Кант, Фихте, Гегель, Маркс, Энгельс, Шопенгауэр, Ницше һ.б.) кергән дистәләгән күренекле философларның исемнәрен ачу.

2. Немец классик фәлсәфәсе

Немец классик фәлсәфә XVIII гасыр ахырында – XIX гасырның беренче яртысындатаралу ала

Объектив идеализм

Төп вәкилләре

Иммануил Кант
(1724 – 1804)

Төп идеяләр:

— Ньютон законына нигезләнеп, табигый көчләр тәэсирендә Кояш системасы барлыкка килүе турында аңлатма бирә – киңлектәге бушандырылган материя кисәкчәләренең әйләнеп торган томанлыгыннан;

— кешенең танып белү сәләтенең чиге булуы һәм әйберләрнең һәм күренешләрнең эчке асылын танып булмау турындагы теорияне тәкъдим итә («эчендәге әйберләрне»);

— категорияләр турында тәгълимат чыгара
— фәлсәфә эш иткәнтөп, гомум төшенчәләр

— мораль законны формуласын чыгара («катгый императив»);

— киләчәктәге «мәңгелек дөнья» турындагы идеяне тәкъдим итә, ул сугышларның икътисади яктан уңышсызлыгына һәм аның хокукый тыелуына нигезләнә.

Георг Гегель
(1770 – 1831)

Төп идеяләр:

— яшәеш һәм фикерләүне тиңләштерә

— аңга бәйсез һәм бар нәрсәгә, материаль дөньяга башлангыч булган абсолют идея турында тәгълиматны барлыкка китерә

— Көнбатыш илләрендә таныллу алган объектив идеализм концепциясен нигезли

Фридрих Шеллинг
(1775 – 1854)

Төп идеяләр:

Табигатьне объектив идеализм күзлегеннән тирәнтен нигезли, идея тәкъдим итә, аңа ярашлы, иреклек һәм хокукый строй баштан уктабигатькә салынган.

Субъектив идеализм (Фихте)

Иоганн Фихте (1762 – 1814), субъектив идеализм концепциясен эшкәртүгә зур өлеш кертә, аңа ярашлы кеше өчен бердәнбер һәм төп чынбарлык ул үзе, аның аңы («Мин-концепция» дип аталган).

Материализм (Фейербах)

Людвиг Фейербах (1804 – 1872) немец классик фәлсәфәсендә материалистик юнәлеш вәкиле була. Фейербах идеализмны тәнкыйтьли, дөнья-ның тулы һәм эзмә-эзлекле материалистик картинасын тәкъдим итә. Үз фәлсәфәсендә Фейербах тулы атеист буларак чыгыш ясый, Аллаһ юклыгын дәлилли, аның ясалмалылыгы, кешеләр тарафыннан уйлап чыгарылганлыгы, Аллаһка кешенең тормышка ашыра алмаган идеалларын күчерүе турында әйтә.

Немец классик фәл-сәфәсенең әһәмияте

— фәлсәфә игътибарын традиционмәсьәләләрдән (яшәеш, фикерләү, танып белү һ.б.) кеше асылын тикшеренүгә борып җибәрә;

— аерым игътибарны үсеш мәсьәләсенә бүлә;

— фәлсәфәнең логик-теоретик аппаратын күпкә баетты;

— тарихка тулы процесс буларак карый.

3. XIX гасыр немец материализмының төп юнәлешләре

Людвиг Фейербах фәлсәфәсе (1804 – 1872). Людвиг Фейербахның атеистик һәм материалистик фәлсәфәсе немец фәлсәфәсенә дә, материализмга да кертелә. Бу гадел дә, чөнки Фейербах фәлсәфәсе немец классик фәлсәфәсен тәмамлый һәм немец материализмына нигез салучы, алар арасындагы бүленеш була

Марксизм

— Марксизм фәлсәфәсе

— Политэкономия (икътисади тәгълимат)

— Фәнни коммунизм (социаль-сәяси теория)

Марксизм төзүчеләр

— Карл Маркс (1818-1883)

— Фридрих Энгельс (1820-1895)

Төп идеяләр

— Дөньяның эзмә-эзлекле материалистик картинасын тәкъдим итә;

— Материаль һәм иҗтимагый яшәеш өчен икътисадның ролен күрсәтә;

— Фәлсәфи мәсьәләләрне диалектика күзлегеннән аңлата;

— Тарихны максатчан һәм закончалыклы процесс буларак карый;

— Кеше, җәмгыять, дәүләт барлыкка килү турында тулы картинаны бирә;

— Атеистик позициядән (караштан) чыгыш ясый.

Вульгар материализм

Төп вәкилләр

— Фохт

— Бюхнер

— Молешотт

Фәлсәфә үзенчәлекләре

— Вульгар материалистлар кеше мәсьәләсенә табигый фәннәр позициясеннән карыйлар;

— Табигать законнарын механик рәвештә кеше җәмгыятенә күчерәләр; идеальлекне кире кагалар;

— Аң эшчәнлегенә физиологик процесс буларак карый.

4. Иррационализм, «тормыш фәлсәфәсе»

Иррационализм – яшәешнең һәм тарихның объектив законнарын, диалектиканы кире кагучы, әйләнә-тирә дөньяны һәм тарихны хаос буларак кабул итүче фәлсәфәюнәлеше.
Нигез салучы – **Артур Шопенгауэр**.

Иррационализмга якын **«тормыш фәлсәфәсе»** – ул читкә юнәлгән төшенчә-яшәеш, идея, чимал һәм башкаларны түгел, ә кешенең дөньядагы яшәешен, кеше өчен чын-барлык булган бердәнбер яшәешне игътибар үзәгенә куя. Аңа нигез салучыларның берсе – **Фридрих Ницше**

Нигезенә салына

Фәлсәфәнең заманча юнәлешләре – прагматизм һәм экзистенциализм

§36. Иммануил Кант фәлсәфәсе

1. Кант фәлсәфәсенең чорларга бүленеше

Кант фәлсәфәсенең чорларга бүленеше (1724-1804) – немец (прусс) фәлсәфәчесе, Кенигсберг университеты профессоры, немец классик идеализмына нигез салучы.

Тәнкыйди чорга чаклы

Мөһим мәсьәләләр: яшәеш, табигать, табигать белеме мәсьәләләре. Әлеге мәсьәләләрне тикшергәндә Кант новаторлыгы ул үсеш мәсьәләсенә игътибар итүче беренче фәлсәфәчеләрнең берсе булды.

Шул чор дөньяга караш эзен йөрткән идеяләр:

— Механик законнар баштан ук материягә салынмаган, ә үзенеңтышкы сәбәбе бар
— Әлеге тышкы сәбәп – ул Аллаһ.

Тәнкыйди чор вакытында килеп чыккан фундаменталь фәлсәфи әсәрләр, аларга бәйле үз исемен ала:

— «Саф акыл тәнкыйде»
— «Гамәли акыл тәнкыйде»
— «Фикерләү сәләте тәнкыйде»

Кантның фәлсәфи нәтиҗәләре,аның чоры өчен революцион булган:

— Кояш системасы бушандырылган материя кисәкчәләреннән торган зур болыттан аның әйләнүе барышында барлыкка килгән, бу хәрәкәт итү һәм үзара йогынты ясау нәтиҗәсендә мөмкин булган;
— Табигатьнең вакыт эчендә үз тарихы бар, ул мәңгелек һәм үзгәрми торган түгел;
— Табигать даими үзгәрештә һәм үсештә;
— Хәрәкәт һәм тынычлык чагыштырмача;

— Җирдәге һәр тереклек, шул исәптән кеше дә, табигый биологик эволюция нәтиҗәсе.

2. «Саф акыл тәнкыйде»

Әсәрнең төп идеясе – агностицизм – әйләнә-тирә чынбарлыкны танып булмау. Кантка кадәр күпчелек фәлсәфәчеләр танып белүдә туган кыенлыкларның төп сәбәбе сыйфатында танып белү объектын күргәннәр – меңәр еллар ачылмаган серләре булган яшәеш, әйләнә-тирә дөнья. Кант исә кыенлыклар сәбәбе әйләнә-тирә чынбарлык – объект түгел, ә танып белү эшчәнлегенең субъеты – кеше, дөресрәк, аның аңы дигән гипотеза тәкъдим итә. Кеше акылының танып белү мөмкинлекләре (сәләтләре) чикле (ягъни акыл барын да булдыра алмый). Кеше акылы үзенең танып белү чаралары хәзинәсе белән үз кысаларыннан (мөмкинлекләреннән) чыгарга тырышса, ул хәл-иткесез каршылыкларга (антиномнарга) очрый. Акыл ярдәмендә ике капма-каршы анти-номны – логик дәлилләргә мөмкин – әмма акыл аптырашта кала. Кант буенча, анти- номнар булуы – акылның танып белү сәләтләренең чикләре булуының дәлиле.

Антиномнар

Киңлекнең чиклелеге

— Дөнья вакыт башлангычына ия һәм киңлектә чикләнгән;

— Дөньяның вакыт башлангычы юк һәм ул чиксез.

Гади һәм катлаулы

— Дөньяда бернинди гади нәрсә юк;

— Тик гади элементлардан торган гына түгел, гадидән торганнар да бар.

Азатлык һәм сәбәплелек

— Табигать законнары буенча сәбәплелеккенә түгел, азатлык та бар;

— Азатлык юк.

Аллаһ барлыгы

— Аллаһ бар һичшиксез нинди дә булса асыл кирәк, бар булганның сәбәбе;

— Аллаһ юк. Бернинди дә абстракт асыл юк – бар булганның сәбәбе юк.

Танып белү эшчәнлеге нәтиҗәсе буларак белем классификациясе

— Апостерио белем – кеше тәҗрибә нәтиҗәсендә алган белем. Бу белем бары тик ча-маланган гына була, әмма дөрес түгел, чөнки бу төр белемнән алынган һәр фикер тәҗрибәдә сынап карарга кирәк, һәм мондый белем һәрвакыт хак дигән сүз юк. Мәсәлән, кеше тәҗрибә буенча металларның эрегәнен белә, тик теоретик рәвештә эрүгә дучар булмаган металлар булуы да ихтимал, димәк, тәҗрибәле (эмпиристик, апостериор) белем дә дөрес булмыйча гомумилеккә дәгъва итә алмый.

— Априор белем – тәҗрибәгә кадәр, ягъни акылда башта ук яши һәм бернинди дә тәҗрибәви дәлилләүне таләп итми. Мәсәлән, «Барлык җисем озайлы», «Кеше гомере вакыт берәмлегендә ага», «Барлык җисемнәрнең массасы бар». Бу нигезләмәләрнең һәрберсе тәҗрибәви тикшерү белән дә, ансыз да абсолют дөрес. Мәсәлән, үлчәме булмаган җисем очрату мөмкин түгел. Нибары априор (тәҗрибәгә кадәрле) белем абсолют дөрес һәм ышанычлы, гомум һәм кирәклелек сыйфатларына ия.

— «Үз эчендәге әйбер» – ул акыл белән беркайчан да танып булмаячак әйбернең эчке асылы.

Танып белү процессының схемасы

— Тышкы дөнья иң элек кешенең тою органнарына йогынты ясый (аффицировкалау);

— Кешенең тойгы органнары тышкы дөньяның аффицировкаланылган образларын тойгылар аша кабул итә;

— Кеше аңы тойгы органнары тарафыннан алынган вакланган образларны, хис-тойгыларны системага китерә, нәтиҗәдә кеше акылында әйләнә-тирә дөньяның тулы картинасы барлыкка килә;

— Акылда тойгылар нәтиҗәсендә барлыкка килгән әйләнә-тирә дөньяның тулы картинасы, ул нибары акыл һәм тойгылар татыган тышкы дөнья образы гына, ул реальдөнья белән бернинди уртаклыгы да юк;

— Реаль дөнья, аның образларын акыл һәм тойгы кабул итә, «үз эчендәге әйбер» була – акыл белән гомумән аңлатып булмый торган субстанция;

— Кеше акылы бары тик әйләнәдәге бик күп предмет һәм күренешләрне – «үз эчендәге әйберләрне» генә таный ала, тик аларның эчке халәтен түгел.

Танып белү барышында акыл юлыккан үтеп булмастай чикләр

— Үзенеке (акыл өчен эчке булган) булган чикләр, аның артыннан хәл иткесез каршылыклар туа – антиномнар;

— тышкы чикләр – үз эчендәге әйберләрнең эчке асылы.

Саф акыл структурасы, сигналлар кабул итүче – танылмаган «үз эчендәге әйберләр»образы– әйләнә-тирә дөнья

Сизеп белү формалары – киңлек һәм вакыт. Сизеп белү аркасында аң хис-тойгыларны киңлек һәм вакытка куеп башта системалаштыра.

Акыл формалары – категорияләр гомум төшенчәләр, алар ярдәмендә киңлек һәм вакытның «координат система»сына урнаштырылган беренчел хис-тойгыларны алга таба аңлау һәм системалаштыру. Кантка ярашлы, алар ярдәмендә акыл үз эшчәнлеген башкара: беренчел хис-тойгылар хаосын тәртипкә сала, моңа ярашлы фикерләү эшчәнлегенә дә тәртипкә салу мөмкинлеге барлыкка килә. Кант мондый унике категорияне бүлеп чыгара һәм һәрберсендә икешәр булган аларны дүрт сыйныфка бүлә, шул ук вакытта һәр сыйныфның беренче категорияләре – сыйныф характеристикасының капма-каршысы, өченчеләре – аларның кушылмасы (синтезы).

Акыл формасы – ахыргы югары идеяләр, мәсәлән: Аллаһ идеясе; җан идеясе; дөнья асылы һәм башка идеяләр. Кант фикере буенчафәлсәфә – югары идеяләр турындагы фән.

Сан категорияләре:

— берлек;

— күплек;

— бөтенлек.

Сыйфат категорияләре:

— чынбарлык;

— инкарь итү;

— чикләү.

Мөнәсәбәтләр категорияләре:

— субстанциональлек һәм акциденция;

— сәбәп һәм нәтиҗә;

— үзара йогынты ясашу.

Модальлек категорияләре:

— мөмкинлек һәм мөмкинлек булмау;

— яшәү һәм яшәмәү;

— кирәклек һәм очраклылык.

3. Кантның «Гамәли акыл тәнкыйде»

«Гамәли акыл тәнкыйде» («гамәли акыл» – әхлаклылык)

Төп мәсьәлә «Гамәли акыл тәнкыйдене»

— Әхлак нинди булырга тиеш?

— Кешенең нинди тәртибе әхлакый (әхлаклы) була ала?

Нәтиҗәләр:

— Саф әхлаклылык – барысы белән кабул ителгән иҗтимагый аң, аны аерым индивид үзенеке итеп кабул итә.

— Саф әхлаклылык һәм реаль тормыш арасында (гамәл, ният, кеше ихтыяҗлары)көчле каршылык бар

— Әхлак, кеше тәртибе барлык тышкы шартлардан бәйсез булырга тиеш һәм әхлакзаконнарына гына буйсынырга тиеш

Әхлакый закон, ул югары һәм шартсыз характерлы, Кант аны катгый императив дип атый: «Синең гамәлеңнең максимумы гомуми закончалыкның принцибы була алырдай итеп эшлә»

Катгый императивны заманча аңлату

— Кеше гамәле башкаларга үрнәк булдырдай тәртипле булырга тиеш

— Кеше башка кешегә чара буларак түгел максат буларак кына карарга тиеш,

4. «Фикер йөртү сәләте тәнкыйде»

Төп идея – гомуми максатчанлык идеясе

— Эстетикадагы максатчанлык

— Табигатьтәге максатчанлык (табигатьтә бар нәрсәнең үз мәгънәсе бар)

— Рух максатчанлыгы (Аллаһ барлыгы)

5. И. Кантның социаль-сәяси карашлары

И. Кантның социаль-сәяси карашлары

— Фәлсәфәче кеше баштан ук явыз табигатьле була дип исәпләгән.

— Кешене әхлакый тәрбия һәм әхлак законнарына катгый буйсыну коткарачак дип уйлаган.

— Демократия һәм хокукый тәртипне тарату тарафдары булган.

— Сугышларны иң зур хата дип танылган һәм кешелекнең җинаяте дип санаган.

— Киләчәктә, һичшиксез, «югары тынычлык» урнашыр – сугышлар йә хокук белән тыелачак, яки икътисади файдасыз булачак дип исәпләгән.

6. Кант фәлсәфәсенең тарихи әһәмияте

Кант фәлсәфәсенең тарихи әһәмияте

— Кояш системасының барлыкка килүенә фәнни нигезле аңлатма бирә.

— Кеше акылының танып белү сәләтенең чикле булуы идеясен тәкъдим итә.

— 12 категория чыгара – фикерләү каркасы торган төшенчәләр.

— Катгый императив – әхлакый закон формулировкасын чыгарган.

— Демократия һәм аерым җәмгыять өчен дә, шулай ук халыкара мөнәсәбәтләр өчендә хокукый тәртип идеясен тәкъдим итә.

— Сугышны тәнкыйтли итә, киләчәктә икътисади файдасызлыкка һәм аларны хокукый тыюга нигезләнгән «мәңгелек тынычлык»ны күрәзәли.

§37. Гегель фәлсәфәсе

1. Гегель иҗатына гомуми характеристика

Георг Вильгельм Фридрих Гегель (1770 – 1831) – Гейдельберг, соңыннан Берлин университетлары профессоры, Германиядә дә, Европада да заманының иң абруйлыфәлсәфәчеләренең берсе, немец классик идеализмының вәкиле.

Гегельнең фәлсәфәгә керткән өлеше

— объектив идеализм теориясе (аның үзәк төшенчәсе абсолют идея – Дөнья рухы);

— диалектика гомуми фәлсәфә методы буларак.

Гегельнең мөһим хезмәтләренә керә:

— «Рух феноменологиясе»

— «Мантыйкфәне»

— «Хокук фәлсәфәсе».

Гегельнең социаль-сәяси карашлары:

— дәүләт – Аллаһның дөньядагы яшәү формасы (үз көче һәм «мөмкинлекләре» буенча Аллаһ гәүдәләнеше);

— хокук – булган яшәеш азатлыгының гәүдәләнеше;

— гомуми ихтыяҗлар шәхсигә караганда югарырак, һәм аерым кеше, аның ихтыяҗлары гомуми иминлек өчен корбанга бирелергә мөмкин;

— байлык һәм фәкыйрьлек табигый һәм котылгысыз, бу югарыдан бирелгән чынбарлык, аның белән килешергә туры килә;

— җәмгыятьтәге каршылыклар, конфликтлар – ул явызлык, ә игелекләр – прогресс этәргече;

— дәүләтләр арасындагы каршылык һәм конфликтлар, сугышлар – гомумдөнья-тарих масштабында прогресс этәргече;

— «мәңгелек дөнья» черү һәм әхлакый таркалуга китерә; даими сугышлар, киресенчә, милләт рухын тазарта.

— Гегельнең мөһим фәлсәфи нәтиҗәләренең берсе.

— Яшәеш (материя) һәм идея (аң, акыл) арасында каршылыклар юк. Акыл, аң, идея яшәешкә ия, ә яшәеш аңга. Барлык акылга ия чынбарлыкта бар, ә бар булган чынбарлык акылга ия.

2. Гегель онтологиясе

Гегель онтологиясе (яшәеш турында тәгълимат) (төп идея – яшәеш һәм фикерләүне тиңләштерү)

Абсолют идея

— бердәнбер булучы чын чынбарлык

— әйләнә-тирә дөнья, аның предметлары һәм күренешләренең беренчел сәбәбе;

— аңлы һәм иҗат итә алган Дөнья рухы.

Абсолют рухның читләшү төрләре

— әйләнә-тирә дөнья;

— табигать;

— кеше;

— кеше фикерләве һәм эшчәнлеге аша читләшүдән соң, тарих барышы кабат үз-үзенә кире кайта: ягъни Абсолют рухның схема буенча: Дөнья (Абсолют) рух – читләшү – әйләнә-тирә мохит һәм кеше – фикерләү һәм кеше эшчәнлеге – үз-үзеңне фикерләү һәм кеше эшчәнлеге аша рухны тормышка ашыра – Абсолют рухның үз-үзеңә кайтуы

Читләшү

— материянең һавадан иҗат итүе;

— объект (әйләнә-тирә дөнья) һәм субъект (кеше) арасында катлаулы мөнәсәбәтләр – кеше эшчәнлеге аша Дөнья рухы үзен предметлаштыра;

— кешенең әйләнә-тирә дөньяны хаталы кабул итүе, дөрес аңламавы

Гегель онтологиясендә кеше

— Ул – абсолют идея иясе.

— Һәр кеше аңы – Дөнья рухы кисәге.

— Нәкъ кешедә абстракт һәм йөзсез дөнья рухы ихтыяр, шәхес, характер, үзенчәлеклек ала.

Кеше ярдәмендә Дөнья рухын күрсәтү

— үзен сүз, сөйләм, тел, жест формасында күрсәтә;

— максатчан һәм закончалы хәрәкәт итә – кешенең гамәлләре, хәрәкәтләре, тарих барышы;

— үзен кешенең танып белү эшчәнлеге аша таный;

— иҗат итә – кеше белән тудырылган материаль һәм рухи мәдәният нәтиҗәсе формасында.

3. Гегель диалектикасы

Диалектика, Гегель буенча, – Дөнья рухы һәм ул иҗат иткән әйләнә-тирә дөньяның яшәеш һәм төп үсеш законы

Диалектика мәгънәсе

— барысы да – Дөнья рухы, «ахыргы рух» – кеше, әйләнә-тирә предметлар һәм күренешләр, процесслар – үзендә капма-каршы башлангычлары бар (мәсәлән, көн һәм төн, җылы һәм суык, яшьлек һәм картлык, байлык һәм ярлылык, кара һәм ак, сугыш һәм тынычлык һ.б.лар)

— бу башлангычлар (бербөтен яшәеш һәм Дөнья рухы яклары) бер-берсенә карата каршылыкта торалар, тик бер үк вакытта үзләренең асыллары белән бер һәм бер-берсе белән мөнәсәбәткә керәләр;

— капма-каршылыкларның берлеге һәм көрәше – бөтен дөньяның үсеш һәм яшәеш нигезе (ягъни гомуми барлык һәм үсеш нигезе).

Үсеш механизмы (абстракттан конкретка)

— билгеле тезис бар (караш, яшәү формасы);

— әлеге тезиска һәрвакыт антитезис табыла – аның капма-каршысы;

— ике капма-каршы тезислар үзара бәйләнеше нәтиҗәсендә синтез барлыкка килә – яңа караш, ул үз чиратында үзе тезиска әйләнә, тик югарырак үсеш дәрәҗәсендә;

— әлеге процесс кабат-кабаттан була, һәм булган саен синтез нәтиҗәсендә тагы да югарырак дәрәҗәдәге тезис барлыкка китерә.

4. Рух фәлсәфәсе

Абсолют рухның чагылышлары

Субъектив рух – җан, аерым кешенең аңы («үзең өчен рух» дип аталган).

Объектив рух – рухның киләсе баскычы, «җәмгыятьнең тулаем алгандагы рухы». Объектив яңа рухның чагылышы булып хокук тора – югарыдан бирелгән, баштан ук идея буларак яшәгән (чөнки азатлык кешенең үзенә салынган) кешеләр арасындагы үзара мөнәсәбәтләр тәртибе. Хокук – тормышка ашырылган азатлык идеясе. Объектив рухның хокук белән берәттән башка чагылышы булып әхлак, гражданнар җәмгыяте, дәүләт була.

Абсолют рух – рухның югары чагылышы, мәңге чын хакыйкать.

Сәнгать – кеше тарафыннан турыдан-туры абсолют идеяләрне чагылдыру. Кешеләр арасында, Гегельгә ярашлы, абсолют идеяне «күрү» һәм чагылдыруны тик талантлы һәм гениаль кешеләр генә булдыра ала, моңа бәйле алар сәнгатьне иҗат итүчеләр була.

Дин – сәнгатьнең антитезисы. Әгәр сәнгать – абсолют идея, гениаль кешеләр тарафыннан «күрелгән», ә дин – кешегә Аллаһ тарафыннан ачылган абсолют идея.

Фәлсәфә – сәнгать һәм дин кушылмасы, абсолют идеяны аңлау һәм үсешенең югары баскычы. Бу Аллаһ тарафыннан бирелгән һәм шул ук вакытта гениаль кешеләр – фәлсәфәчеләр белән аңланылган белем. Фәлсәфә – барлык хакыйкатьнең, танып белүнең тулысынча ачылуы. Үз-үзеңнең абсолют рухың («фикер белән әйләндерелгән дөнья» – Гегель буенча) абсолют идея башы белән аның ахыры тоташуы, югары белем.

Гегель буенча фәлсәфә предметы

— табигать фәлсәфәсе;

— антропология;

— психология;

— мантыйк;

— дәүләт фәлсәфәсе;

— гражданнар җәмгыяте фәлсәфәсе;

— хокук фәлсәфәсе;

— тарих фәлсәфәсе;

— гомуми законнар һәм принциплар хакыйкате буларак диалектика.

История, Гегельча, абсолют рухның үзеннән-үзе тормышка ашырылу процессы. Чөнки Абсолют рух үз эченә азатлык идеясен ала, барлык тарих ул кешенең күбрәк азатлык яулый баруы.

Көнчыгыш эрасы (Борынгы Мисыр, Кытай һ.б. Илләр чоры) – җәмгыятьтә тик берәү генә үзен бар дип белә һәм азатлык, барлык тормыш байлыклары белән файдалана ала – ул фараон, китай императоры һ.б.лар, ә калганнар аның коллары һәм хезмәтчеләре була.

Антик-урта гасыр эрасы – бу бер төркем кешеләрнең үзләрен тану чоры итеп билгеләнә (дәүләт башлыгы, аның тирәдәгеләр, хәрбиләр, аристократлар, феодаллар), тик төп масса басылган һәм ирекле түгел, «баштагыларга» бәйле һәм аңа хезмәт итә.

Герман эрасы – Гегель заманы (чоры) барысы даирекле һәм барысы да үзләрен таный.

§38. Субъектив идеализм фәлсәфәсе

1. Субъектив идеализмның гомуми төшенчәсе

Субъектив идеализм фәлсәфәсе

Төп идеяләр

— беренчедән, бердәнбер чынбарлык ул идея була;

— икенчедән, идея бары тик кеше акылында гына яши, ягъни кеше аңы мөһим чынбарлык була, аңардан тыш берни дә юк.

Күренекле вәкилләре

— Брекли

— Юм

— Фихте

2. Джордж Беркли фәлсәфәсе

Джордж Беркли (1685 – 1753) – яңа вакыт инглиз фәлсәфәчесе, субъектив идеалист.

Төп идеяләр

— материя төшенчәсе үзе ялган;

— аерым әйберләр, аерым хис-тойгылар бар, тик бердәм материя юк.

— материализм – фәлсәфәдә тупикка илтүче юнәлеш, материалистлараерым әйберләрнең беренчеллеген дәлилли алмый (алар материя дип атаган) идеягә мөнәсәбәтле;

— киресенчә, идеянең беренчеллеген дәлилләү бик җиңел – теләсә кайсы әйберне әзерләү алдыннан аның идеясе була, кеше аңындагы уе, Аллаһ – иҗат итүче буларак әйләнә-тирәне булдырыр алдыннан булган фикерләве;

— бердәнбер күзгә күренеп торган чынбарлык ул кеше аңы;

— кеше һәм аның аңы үлүе белән бар нәрсә дә юкка чыга;

— идеяләр – ул мөстәкыйль субстрат, ә нәрсәнең булса да чагылышы түгел, әйләнә-тирә дөнья идеяләргә яраклаша;

— идеянең беренчел булуына иң югары дәлил – ул Аллаһ барлыгы; Аллаһ мәңге яши һәм юкка чыга алмый. Шул ук вакытта аның иҗат җимешләре әйләнә-тирәдәге мохит даими түгел, ул уалучан һәм тулысынча аңарга бәйле.

3. Дэвид Юм фәлсәфәсе

Дэвид Юм (1711 – 1776) – инглиз фәлсәфәчесе, субъектив идеалист.

Төп идеяләр

— яшәеш һәм рух мәсьәләсе ахырынача хәл ителерлек түгел;

— кеше аңы идеяләргә тартым;

— кеше үзе концентрацияләнгән идея (бөтен кеше гомере аның идеаль көче артупроцессы ул – тәҗрибә, белем, хисләр);

— үзенең идеаль асылыннан башка (мәсәлән, тәрбиясез, тәҗрибәсез, кыйммәтләрнең системалыгысыз) кеше дөньяны бөтенләй тулысынча кабул итә алдмас иде;

— кеше ике идеаль башлангычтан тора: «тышкы тәҗрибә йогынтысы» – алынган белемнәр һәм кабул ителгән белем һәм тәҗрибә, «эчке тәҗрибә тәэссоратлары» –аффектлар, көчле теләкләр;

— аффектлар, кеше тормышында һәм тарих барышында зур әһәмият уйный.

4. Иоганн Готлиб Фихте фәлсәфәсе. Фихтенең «Мин-концепция»се

Иоганн Готлиб Фихте (1762 – 1814) – немец классик фәлсәфәсе вәкиле, профессор(соңгы яшәү елларында – Берлин университеты ректоры.

Фәлсәфәнең төп төрләре

«Мин-концепция»	Азатлык мәсьәләсе
Аны тәкъдим итүгә сәбәп – Кант фәлсәфәсендәге каршылыклар, ә Фихте аның укучысы һәм тарафдары була. Фихте төп каршылыкны Кантның танып белүче субъектның (кешенең) һәм танып була алмый торган әйләнә-тирәнең («үзендәге әйберләр») бүленешендә күрә. Бу бүленеш, Фихте буенча, акылның танып белү мөмкинлекләре чикле булу идеясе, антиномнар кебек үк, фәлсәфәне ахыргача аның төп бурычын – яшәеш һәм фикерләүне берләштерүне башкару өметеннән мәхрүм итә	Фихте буенча, азатлык – гомум зарурлыкка ирекле буйсыну. Бар кешелек тарихы – азатлык тарату процессы, аның тантанасының юлы. Гомум азатлык нигезе – барысына да хосусый милек бүлеп бирү.

Төп нигезләр	«Мин» нең әйләнә-тирә дөнья белән үзара	«Мин – кеше» һәм «Мин түгел» арасындагы үзара бәйләнеш – «Абсолют Мин» эчендәге дөнья белән уратылган – субъектив рух
— «үзендәге әйберләр» идеясен үзен инкарь итә – акыл белән танып булмый торган реаль чынбарлыкны; — бердәнбер чынбарлык итеп эчке, субъектив, кеше «Мин»ен игълан итә, аңарда бөтен дөнья керә (ягъни яшәешне фикерләү эченә кую юлы белән яшәеш һәм фикерләүне берләштерә, әйткәндәй субъективны, субъектны объектка күчерә); — әйләнә-тирә дөнья тормышы тик субъектив «Мин» эчендә генә була дип исәпли; — фикерләүдән тыш, «Мин»нән тыш мөстәкыйль әйләнә-тирә чынбарлык юк; — «Мин» үзе – кеше акылы гына түгел, ул хәрәкәт, барлыкка китерүче көч, әйләнә-тирә дөнья савыты, чынбарлык өсте, югары субстанция диярлек (Декарт һәм Спиноза фәлсәфәсендә югары субстанция аналогиясе буенча – Аллаһ белән).	**— мөнәсәбәте** («тезис – антитезис – синтез» схемасы буенча диалектик сурәтләнә) — Абсолют Мин үз-үзен фараз итә (Мин Минне фараз итә); — «Мин» «Мин түгел»не фараз итә (барлыкка китерә) – тышкы әйләнә-тирә чынбарлыкны (антитезис); — «Мин» (актив иҗат, башлангыч, субъект, кеше шәхесенең аңы) «Мин түгел» белән элемтәгә керә (пассив башлангыч белән) әйләнә-тирә дөнья) Абсолют Мин эчендә (савыт, югары субстанция).	— гамәли («Мин»нән – «Мин түгел»гә; «Мин» иҗат итә, «Мин түгел»не билгели, үзара бәйләнешнең төп төре); — теоретик («Мин түгел»дән «Мин»гә – икенче сирәгрәк үзара бәйләнеш төре, эмпиристик, тәҗрибә тапшыру, Мин түгел»дән мәгълүмат – әйләнә-тирә дөнья«Мин»гә (конкрет аң). Фихтенең икенче фәлсәфә соравы – азатлык мәсьәләсе. Фихте буенча, азатлык – гомум зарурлыкка ирекле буйсыну. Барлык кешелек тарихы – азатлык тарату процессы, аның тантанасына юл. Гомуми азатлык нигезе – барысын да хосусый милек белән тәэмин итү.

§39. Шеллинг фәлсәфәсе

1. Шеллинг фәлсәфәсенең бүленеше

Фридрих Вильгельм Йозеф Шеллинг (1775 – 1854) немец классик фәлсәфәсенең объектив идеализмының күренекле вәкиле була, Гегельның дусты, соңыннан аның оппоненты. Шеллинг фәлсәфәсенең төп максаты – «абсолютны» аңларга һәм аңлатырга.

Аның өч төп этабы:

Шеллинг фәлсәфәсенең чорларга бүленеше:

— натурфилософия

— гамәли фәлсәфә

— иррационализм

2. Шеллинг натурфилософиясе

Шеллинг натурфилософиясе

— Алдагы концепцияләр табигатьне аңлатулар хак түгел, чөнки беренче очракта табигать кеше аңыннан чыгарыла, ә калган очракларда (Спиноза субстанция теориясе һ.б.лар)табигатьне чикләнгән рәвештә аңлату;

— Табигать ул «абсолют» – бар нәрсәнең беренчел сәбәбе һәм башлангычы, бар нәрсәне колачлап ала;

— Табигать ул субъектив һәм объективның берлеге, мәңгелек акыл;

— материя һәми рух бердәм һәм табигать үзенчәлекләре булып тора, абсолют акылның төрле торышы;

— Табигатьне хәрәкәт иттерүче көч ул аның полярлыгы – эчке каршылыклар һәмаларның үзарабәйләнеше булуы;

— Табигать җанлылыкка ия булган тулы бер организм (тере һәм тере булмаган табигать, материя,басу, электр, яктылык бербөтен);

3. Шеллингның гамәли (социаль-сәяси) фәлсәфәсе

Шеллингның гамәли фәлсәфәсе
(социаль-сәяси характердагы мәсьәләләрне, тарих барышын хәл итә)

Кешелекнең тулаем төп мәсьәләсе һәм фәлсәфәнең төп предметы, Шеллинг буенча, азатлык мәсьәләсе була. Азатлыкка омтылу кешенең үз табигатенә салынган һәм аның тарихи процессының төп максаты була.

Шеллингның гамәли фәлсәфәсенең башка мөһим мәсьәләсе (азатлык мәсьәләсе белән бергә) читләшү мәсьәләсе. Читләшү – кеше эшчәнлегенең реаль чынбарлык һәм азатлык идеясе белән бәйләнешкә керүе нәтиҗәсендә башлангыч максатларга капма-каршы нәтиҗәгә килү.

Нәтиҗәләр:

— тарих барышы очраклы, тарихта үзиреклелек хөкем итә;

— тарихның очраклы вакыйгалары да, максатчан эшчәнлек тә катгый зарурлыкка буйсына, болар алдында кеше көчсез, ул берни дә эшли алмый;

— теория (кеше уй-ниятләре) һәм тарих (реаль чынбарлык) еш кына капма-каршы һәм бернинди уртаклыгы юк;

— тарихта азатлык һәм гаделлек өчен көрәш тагы да көчлерәк коллыкка һәм гаделсезлеккә китергән очраклар еш кына.

§40. Людвиг Фейербах фәлсәфәсе

1. Л. Фейербах материализмын нигезләү

Людвиг Фейербах фәлсәфәсе (1804 – 1872) немец классик фәлсәфәсенең йомгаклау этабы, күренекле вәкилләре – Кант, Гегель, Шеллинг һәм Фихте, немец һәм дөнья фәлсәфәсендә материалистик чор башлангычы итеп исәпләнелә. Фейербах фәлсәфәсенең төп юнәлеше – немец классик идеализмын тәнкыйтьләү һәм материализмны нигезләү.

Материализм: материализм фәлсәфәсе юнәлеше буларак Фейербахка кадәр күптән барлыкка килә (Борынгы Греция – Демокрит һәм Эпикур; Яңа вакыт Англия – Бэкон, Локк; Франция – мәгърифәтче-материалистлар), әмма әйтелгән материалистик фәлсәфә мәктәпләре булган, башлыча, үз чорының эчке милли күренеше һәм эзлексезлек һәм каршылыклылык белән аерылып тора, теологиянең көчле йогынтысында булалар, материалистик идеяләр һәм Аллаһ барлыгы арасында килешкәнлек (компромисс) эзлиләр (мондый компромиссның бер формасы деизм була). Людвиг Фейербах фәлсәфәсе материализмның тирәнтен эзлекле беренче очрагы була.

Төп үзенчәлекләре:

— дин белән тулысынча аерылу (атеизм) һәм күп гасырлык дини йогынтыдан азат булу;

— Аллаһ һәм динне материалистик күзлектән, кеше табигатеннән чыгып аңлатырга тырышу;

— материалистик, фәннең яңа казанышларын исәпкә алып, әйләнә-тирә дөнья һәм кеше мәсьәләләрен аңлату;

— социаль-сәяси мәсьәләләргә зур кызыксыну;

— әйләнә-тирә дөньяны танып белүгә ышаныч.

2. Фейербахның Гегель фәлсәфәсен тәнкыйтьләве

Идеалистик фәлсәфәне тәнкыйтьләү, аеруча Гегельне

— яшәеш һәм фикерләү тантана идеясен инкарь итү;

— Абсолют идея барлыгын инкарь итү – мөстәкыйль субстанция һәм материаль дөнья беренчел сәбәбен;

— Абсолют идеянең материаль дөньяга читләшә (әйләнә) алмавын дәлилләү – әйләнә-тирә дөнья күзгә күренеп тора һәм аны тотып карап була, ә абсолют идея –тик акыл фаразы, Гегель уйдырмасы;

— Фәлсәфә һәм дин берлеген инкарь итү;

— Диалектиканы инкарь итү;

— Фейербах Гегель фәлсәфәсен ясалма, хорафатка дучар, үткәнгә юнәлтелгән, фәннең яңа казанышларына туры килми дип саный.

3. Фейербах антропологиясе

Антропологик материализм теориясе

— бердәнбер булган чынбарлык ул табигать һәм кеше;

— кеше табигатьнең бер өлеше;

— кеше материаль һәм рух берлеге;

— кеше фәлсәфәнең төп кызыксыну объекты булырга тиеш;

— идея үзеннән-үзе яши алмый, ул кеше аңы җимеше;

— Аллаһ аерым һәм мөстәкыйль чынбарлык буларак яшәми; Аллаһ – кеше хыялы җиме-ше;

— табигать (материя) мәңгелек һәм чиксез, беркем тарафыннан барлыкка китерелмәгән һәм беркем тарафыннан юк ителми;

— безне уратып алган бар нәрсә (предмет, күренешләр), – материянең төрле чагылышы.

4. Фейербах фәлсәфәсендә Аллаһ мәсьәләсе

Л. Фейербахның атеистик-антропологик теориясенең төп нигезләре

— Мөстәкыйль чынбарлык буларак Аллаһ юк;

— Аллаһ – кеше аңы тудырган нәрсә;

— Дин – тирән эшкәртелгән мифологик-фантастик идеология һәм чынбарлык белән бернинди дә уртаклыгы юк;

— Диннең таралышы кешеләрнең наданлыгы, аның авыр тормыш шартлары аркасында мөмкин була;

— Дин тамырлары – кешенең тышкы дөнья алдындагы көчсезлек хисендә, аның аңа бәйле булуында һәм сакланмаганлыгында;

— Алла турындагы уй – чамадан тыш көчле акыллы асыл – кешеләрне юата, аның куркуын һәм аффектларын киметә;

— Аллаһ – кеше тарафыннан төзелгән кешенең идеаль образы, кеше үзен ничек күрергә тели, ул шул була;

— Аллаһ чыннан барлыкка китерүче түгел, ул – кеше уйдырмасы, аның акылы, шул ук вакытта чын иҗатчы буларак (ә тудырылган түгел) – кеше.

5. Фейербах гносеологиясе

И. Кант гносеологиясе: кеше акылының танып белү сәләте чиклелеге, әйберләр һәм әйләнә-тирә дөнья күренешләренең эчке асылын танып булмавы (агностицизм) турындагы теория

Үзенчәлекләре:

— Әйләнә-тирә дөньяны танып белеп була, ә акылның танып белү мөмкинлекләре чиксез. Әмма акылның танып белү мөмкинлекләренең чиксезлеге шунда ук тумый, ә кеше эволюциясе, тәҗрибә туплау, фәнни-техник прогресс үсеше нәтиҗәсендә тора-бара үсә.

— Әлеге идеянең асылы (акылның тора-бара танып белү сәләте үсеше һәм аның чиксезлеге турында) фәлсәфәче болай дигән: «Без танып белмәгәнне, безнең нәселебез танып беләчәк».

— Белемнең нигезен субъектив хисләр тәшкил итә, алар нигезендә объектив чынбарлык ята һәм алар акыл белән аңлана.

— Шулай итеп, Фейербах гносеологиясе эмпиристик һәм рациональ алымнарны кушу һәм тигезләү барышында материалистик принципларга нигезләнә.

6. Социаль-сәяси фәлсәфә

Фейербахның социаль-сәяси карашлары

— кеше – ихтыяр, акыл, хис-тойгы, теләкләр бирелгән уникаль (кабатланмас) биологик җан иясе;

— кешенең үз «Мин»ен тулысынча тормышка ашыру бары тик «Син» белән генә (ягъни башка кешеләр белән генә) үзара бәйләнештә мөмкин – кеше бары тик җәмгыятьтә генә яши ала;

— җәмгыятьтәге кешеләрнең элемтә нигезе, җәмгыять үзәге дин булырга тиеш;

— әлеге дин уйлап чыгарылган зат – Аллаһка нигезләнгән булырга тиеш түгел, ә башка принципларга;

— традицион динне читкә ташларга кирәк (христианлык, мөселманлык һ.б.) һәм аны кешеләрнең бер-берсен ярату дине белән Алла һәм кеше табигатенә ныграк җавапбиререлек гаилә эчендәге мәхәббәт дине белән алыштырырга кирәк;

— кешенең яшәү мәгънәсе бәхеткә ирешү булырга тиеш.

§41. Вульгар материалистлар фәлсәфәсе

Төп идеяләре:

— рухны (идеяне) чынбарлык буларак тулысынча инкарь итәләр;

— бердәнбер чынбарлык итеп материяне саныйлар;

— аң артыннан идеальлелек сыйфатын кире кагалар, аңны химик процесс буларакаңлатырга тырышалар;

— атеистлар булалар;

— үзләренең тикшеренүләрендә табигый фәннәр казанышларына таяналар (энергиясаклану законы, материя саклану законы, социаль дарвинизм һ.б.лар);

— географик детерминизм идеяләренә таяналар (кешегә география, климат йогынты-сы һәм башка яшәеш процесслары);

— диалектиканы кире кагалар;

— һәрнәрсәгә бер мәгънәле аңлатмалар бирергә омтылалар, ике төрле аңлауны һәмкаршылыкларны калдыр-мыйлар («кара – ак» принцибы буенча);

— традицион материализм положениеләрен шактый гадиләштерәләр.

Вульгар (француз теленнән – гади, примитив, гадәти) **материализм** – XIX гасырда киң таралу алган фәлсәфә юнәлеше.

Вәкилләр

Яков Молешотт (1822 – 1983), фикерләү физиологик процесс дигән теорияне тәкъдим итә.

Людвиг Бюхнер (1824 – 1899) – фәлсәфәче, вульгар материалист, төп һөнәре буенча табиб – табигать фәннәре белгече. Төп хезмәтләре: «Табигать һәм фән», «Хайваннарның психологик тормышы», «Дарвинизм һәм социализм»

Төп идеяләре:

— Идеалистик фәлсәфи концепцияләрнең нигезсез булуын дәлилләгән;

— Их яхшы һәм дөрес фәлсәфи тәгълимат итеп Людвиг Фейербах фәлсәфәсен исәпли;

— Соңгы «социал-дарвинизм» тарафдары була – тормыш законнарын һәм хайваннарның үзара мөнәсәбәтен механик рәвештә кешеләр һәм җәмгыять тормышына күчерә.

— Һәрнәрсәгә бер мәгънәле аңлатмалар бирергә омтылалар, ике төрле аңлауны һәм каршылыкларны калдырмыйлар («кара – ак» принцибы буенча);

— Традицион материализм положениеләрен шактый гадиләштерәләр.

Карл Фохт (1817 – 1895) – фәлсәфәче, вульгар материалист, һөнәре буенча табиб – табигать фәннәре белгече

Төп идеяләре:

— кеше барлыкка килү турындагы Библия (Инҗил) тәгълиматын тәнкыйтьли;

— кешене маймылның якын туганы дип саный;

— социализм идеясенә дошманлык мөнәсәбәтендә була, чөнки, аның фикеренчә, ул кеше табигатенә туры килми; фикерләү һәм аңны физик-химик процесс итеп күрә – «бавыр үт чыгарган төсле, ми фикер бүлеп чыгара.

§42. Марксизм фәлсәфәсе

1. Марксистик фәлсәфәгә гомуми төшенчә

Марксистик фәлсәфәсе ике немец галимы – **Карл Маркс** (1818 – 1883) һәм **Фридрих Энгельс** (1820 – 1895) тарафыннан XIX гасырның икенче яртысында төзелә һәм тагы да киңрәк тәгълимат – **марксизмның** бер өлеше була, ул фәлсәфә белән берлектә икътисадны (политэкономияне) һәм социаль-сәяси мәсьәләләрне (фәнни коммунизмны) үз эченә ала.

Марксизм һәм марксисистик фәлсәфә барлыкка килүгә этәргән күренешләр:

— Материалистик фәлсәфәгә кадәрге (Демокрит, Эпикур, XVIII гасыр инглиз материалистлары һәм аеруча XIX гасырның уртасындагы Людвиг Фейербахның атеистик-материалистик фәлсәфәсе)

— Фән һәм техниканың көчле үсеше;

— Бөек француз революциясе идеалларын җимерү (азатлык, тигезлек, туганлык, Француз мәгърифәтчелек идеяләре), аларны тормышка ашырып булмавы;

— социаль-сыйнфый каршылыклар һәм конфликтлар үсүе (1848 – 1849 еллар, реакция, сугыш, 1871 елгы Париж коммунасы);

— буржуазиянең революция (инкыйлаб) алды булудап консерватив көчкә әверелүе, традицон буржуаз кризисы(никах, әхлак).

Марксизмга нигез салучыларныңтөп әсәрләре:

— К. Марксның «Фейербах турындатезислар»;

— К. Марксның «Капитал»;

— К. Марксның «1844 елгы икътисади-фәлсәфи кулъязмалар»;

— К. Маркс һәм Ф. Энгельсның «Коммунистик партия манифесты;

— К. Маркс һәм Ф. Энгельсның «Изге гаилә» һәм «Немец идеологиясе»;

— Ф. Энгельсның «Табигать диалектикасы»;

— Ф. Энгельсның «Анти-Дюринг»ы;

— Ф. Энгельсның маймылның кешегә әйләнү процессы барышында хезмәтнең роле»;

— Ф. Энгельсның «Гаиләнең, шәхси милекнең һәм дәүләтнең барлыкка килүе».

2. Марксистик фәлсәфәнең төп юнәлешләре

Тарихи материализм:

— кешеләр үзләренең һәр иҗтимагый үсеш баскычында үз эшчәнлекләрен тәэмин итү өчен аерым, объектив, аларның ихтыярына бәйсез булган җитештерү мөнәсәбәтләренә керәләр (үз хезмәтеңне сату,материаль җитештерү, бүлү);

— җитештерү мөнәсәбәтләре, җитештерүче көчләр дәрәҗәсе икътисади системаны барлыкка китерә, ул дәүләт һәм җәмгыять институтларына, иҗтимагый мөнәсәбәтләргә нигез булып тора;

— әйтелгән дәүләт һәм иҗтимагый институтлар, иҗтимагый мөнәсәбәтләр икътисади базиска (нигезгә) карата өскорма сыйфатында чыгыш ясый;

— җитештерүче көчләр һәм җитештерү мөнәсәбәтләре үсеше дәрәҗәсенә, билгеле нигез төре һәм өскормага карап, иҗтимагый-икътисади формацияләр бүленеп чыга – борынгы община строе (җитештерү көчләр һәм җитештерү мөнәсәбәтләренең түбән дәрәҗәсе, җәмгыятьнең яралгылары); кол биләүчелек җәмгыяте (икътисад колларга нигезләнә); азия

— җитештерү ысулы – махсус иҗтиагый-икътисади формация, аның икътисады массалы, коллектив, ирекле кешеләрнең – эре елгалар үзәнлекләрендәге (Борынгы Мисыр, Месопотамия, Кытай) игенчеләрнең хезмәте дәүләт тарафыннан катгый идарә ителүенә нигезләнә; феодализм (икътисад эре җир милегенә һәм буйсынучы крестьяннар хезмәтенә нигезләнгән);

— капитализм (ирекле, әмма җитештерү чараларына милекче булмаган ялланган эшчеләр хезмәтенә нигезләнгән сәнәгать җитештерүе; социалистик (коммунистик) җәмгыять – киләчәк җәмгыяте, җитештерү средстволары дәүләт милегендә (иҗтимагый) булган тигез хокуклы кешеләрнең ирекле хезмәтенәнигезләнгән;

— җитештерү көчләре үсеше җитештерү мөнәсәбәтләре, иҗтимагый-икътисади формацияләрнең һәм иҗтимагый-сәяси строй үзгәрешенә китерә;

— икътисад дәрәҗәсе, материаль җитештерү, җитештерү мөнәсәбәтләре дәүләт һәм җәмгыять язмышын, тарих барышын хәл итә.

Диалектик материа-лизм:

— фәлсәфәнең төп мәсьәләсе яшәеш файдасына хәл ителә (яшәеш аңны билге- ли);

— аң мөстәкыйль асыл буларак түгел, ә материянең үз-үзен чагылдыру үзенчәлеге буларак аңлана;

— материя даими хәрәкәттә һәм үсештә була;

— Аллаһ юк, Ул идеаль образ, кешелеккә аңлашылмаган күренешләрне аңлатыр өчен кеше фантазиясе җимеше, һәм кешелек дөньясына (аеруча аның томана өлешенә) юаныч һәм өмет бирә; Алла әйләнә-тирә чынбарлыкка бернинди дә йогынты ясамый;

— материя мәңгелек һәм чиксез, даими рәвештә үз яшәешенең яңа формаларын кабул итә;

— гамәл (практика) үсешнең мөһим факторы кеше тарафыннан әйләнә-тирә чынбарлыкны үзгәртүе һәм кеше тарафыннан кешене үзен үзгәртүе;

— үсеш диалектика законнары буенча бара – капма-каршылыклар берлеге һәм көрәше, күләмнең сыйфатка күчеше, инкарь итү.

3. Икътисади теория

Төп нигезләр

— Җитештерү средстволары – уникаль товар, югары дәрәҗә хезмәт функциясе, яңа товар җитештерүгә булышлык итүче. Яңа товар җитештерү өчен җитеш- терү средстволарыннан тыш аларны хезмәтләндерүче көч кирәк, – ягъни «эшче көче».

— Капитализм эволюциясе барышында төп эшче мас- саны җитештерү средстволарыннан читләштерү процессы бара һәм, димәк, хезмәт нәтиҗәләрен- нән. Төп товар – җитештерү средстволары – азчылыкны тәшкил иткән милекчеләр кулында тупла- на, ә җитештерү средстволарына ия булмаган һәм мөстәкыйль хезмәт хакы чыганаклары юк төп хезмәт массалары, үзләренең мөһим ихтыяҗларын канәгатьләндерү максатында җитештерү средстволары милекчеләренә хезмәт хакы өчен ялланган эшчеләр булып мөрәҗәгать итәргә мәҗбүр була.

— Ялланган эшче көчләр җитештергән продукт бәясе аларных хезмәтенә караганда югарырак (хезмәт хакы төсендә), Марк буенча, алар арасындагы аерма өстәмә кыйммәт була, аның бер өлеше капиталистның кесәсенә керә, ә бер өлеше киләчәктә тагы да зуррак өстәмә кыйммәт алыр өчен яңа җитештерү средстволарына салына.

— Бу хәлдән чыгу юлын марксистик фәлсәфәгә нигез салучылар яңа, социалистик (коммунистик) иҗтимагый-икътисади мәнәсәбәтләр урнаштыруда күрәләр

Социалистик иҗтимагый-икътисади мөнәсәбәтләр урнаштыру тәртибе

— Җитештерү средстволарына хосусыймилекне бетерү

— Кешенең кешене эксплуатацияләвен һәм чит хезмәт нәтиҗәләрен бер төркем кешеләр тарафыннан үзләштерүне бетерү

— Хосусый милек җитештерү средствосын иҗтимагыйга алыштыру

— Җитештерү продуктын һәм хезмәт нәтиҗәләрен җәмгыятьнең барлык әгъзалары арасында гадел бүлү

§43. Огюст Контның позитивизм фәлсәфәсе

Позитивизм – фәлсәфә юнәлеше, аның асылы фәлсәфәне ныклы фәнни нигезгә бастыруга омтылудан гыйбарәт. Позитивизм фәлсәфи фикер агымы буларак XIX га- сырның 30нчы – 40нчы елларда барлыкка килә, зур эволюция юлы үтә (махизм, не-опозитивизм, постпозитивизм һ.б.лар.). Безнең заманда да киң таралыш тапкан һәмпопуляр.

Позитивизмга нигез салучы дип Огюст Конт (1798 – 1857) исәпләнелә – француз фәлсәфәчесе, Сен-Симон укучысы. Шулай ук аның үсешенә Джон Милль (1806 – 1873) һәмГерберт Спенсер (1820 – 1903) да зур өлеш кертә.

Огюст Конт фәлсәфәсе

Позитив белем

— фәлсәфи белем абсолют төгәл һәмдөрес булырга тиеш;

— аңа ирешү өчен фәлсәфә танып белүдә фәнни ысул кулланырга һәм башка фәннәр казанышына таянырга тиеш;

— фәлсәфәдә фәнни белем алу өчентөп юл – эмпиристик күзәтү;

— фәлсәфә тик фактларны гына тикшерергә тиеш, ә аларның сәбәбен түгел, әйләнә-тирә дөньяның «эчке асылын» һәм башка фәннән ерак булган мәсьәләләрне;

— фәлсәфә кыйммәтлелек ысулыннан һәм тикшерү барышында бәһалау характерыннан азат булырга тиеш;

— фәлсәфә «фәннәр патшабикәсе», аерым гомум-теоретик дөньяга караш булуга омтылырга тиеш түгел – ул нәкъ фәнни (ә башка түгел) средствоарсеналына таянучы конкрет фән булырга тиеш, һәм башка фәннәр арасында үзенең урынын биләргә тиеш.

Эволюция ике төрлелеге

интеллектуаль үсешстадияләре

— теологик (дингә нигезләнгән дөньяга караш);

— метафизик (дөньяга караш, интеллектуаль үсеш системасыз, ихтимал белемгә нигезләнгән үсеш);

— позитив (фәнгә нигезләнгән).

техник үсеш стадияләре

— традицион җәмгыять;

— индустриальгә кадәрге җәмгыять;

— индустриаль җәмгыять.

§44. Шопенгауэр, Ницше, Дильтейның классик булмаган идеалистик фәлсәфәләр

1. Классик идеалистик фәлсәфәгә гомуми төшенчә. Аның немец классик фәлсәфәгә карата мөнәсәбәте

Классик идеалистик фәлсәфә үзенең максаты итеп немец классик фәлсәфәне тәнкыйтьләүне куя, аеруча Гегельне, яңа ысуллар кулланып түгел, ә искеләрен (материалистлар һәм позитивистлар эшләгәнчә). Классик булмаган фәлсәфә вәкилләре дөньяны «классик»лар кебек идеализм күзлегеннән аңлатырга, әмма иске идеализм, гегельгә чаклы һәм классикка чаклы күзлегеннән, (мәсәлән, платонча һ.б.) һәм иске классик идеализмга кадәрге кысаларында яңа, оригиналь ысуллар табарга тырышалар.

Төп юнәлешләре

Иррационализм (Шопенгауэр)	«яшәү фәлсәфәсе» (Ницше, Дильтей)

Немец классик фәлсәфәсе (аның гәүдәләнеше булып Кант, Фихте, Шеллинг һәм аеруча Гегель иҗаты булды) дөнья фәлсәфә үсешенә зур өлеш керттеләр һәм үз вакыты өчен максималь дәрәҗәдә яшәеш, аң, башка фәлсәфи мәсьәләләрен идеализм күзлегеннән асылын аңлатып бирделәр.

Немец классик фәлсәфә тәнкыйде юнәлеше (XIX гасырның икенчеяртысы)

— Л. Фейербах, К. Маркс и Ф. Энгельсның материалистик фәлсәфә белән күрсәтелгән «сулдан тәнкыйть»;

— классик булмаган идеалистик фәлсәфә белән «уңнан тәнкыйть»

2. Иррационализм. Артур Шопенгауэр фәлсәфәсе

Иррационализм табигатьтәге логик бәйләнешләрне, әйләнә-тирә дөньяны бөтен һәм закончалыклы система буларак кире кага, Гегельнең диалектикасын һәм үсеш идеясенүзен тәнкыйтьли.

Иррационализмга нигез салучы дип **Артур Шопенгауэр** (1788 1860) санала.

Шопенгауэрның фәләсәфәсе тулаем алганда пессимистик рух, кеше мөминлекләренең әйләнә-тирә дөньяга һәм үз тормышына йогынты ясый алуына ышанмау.

«Дөнья ихтыяр һәм гәүдәләнеш буларак» китабында фәлсәфәче җитәрлек нигезләү логик законын чыгара. Бу законга ярашлы, хак фәлсәфә объекттан да (материалистлар кебек), суъекттан да (субъектив идеалистлар кебек) гына түгел, ә тик аң факты булган күзаллаудан гына чыгып эш итәргә тиеш.

Үз чиратында күзаллаулар (ә объектив чынбарлык һәм танып белүче субъект түгел) объект һәм субъектка бүленә.

Волюнтаризм, аңа ярашлы, әйләнә-тирәдә төп хәрәкәт иттерүче көч ул – ихтыяр.

Ихтыяр, Шопенгауэр буенча, – абсолют башлангыч, бар нәрсәнең тамыры, бар нәрсәне билгели алучы һәм аңа йогынты ясаучы идеаль көч. Ихтыяр шулай ук югары космос принцибы, ул галәм нигезендә ята.

Шопенгауэр ихтыярны әйберләрнең гомуми асылы буларак аңлатканда кантианлыкка таяна, төгәлрәк Кант теориясенә, аның ярдәмендә аңда әйләнә-тирә әйберләрнең бары тик образлары гына чагыла, ә аларның асылы ачылмаган табышмак булап кала («үз эчендәге әйбер).

Тулаем алганда фәлсәфәче карашы пессимистик ха- рактер йөртә. Кеше нигезенә һәм аның аңына Шопен- гауэр ихтыярны салуга карамастан, ул кешенең таби- гать өстеннән генә түгел, үз-үзе өстеннән дә хакимлекитәчәгенә ышанмый.

— әйләнә-тирә дөнья кеше аңында туган дөнья гына ул;

— дөнья асылы, аның әйберләре, күренешләре ул «үз эчендәге әйбер түгел», ә ихтыяр;

— күренешләр дөньясы һәм асыл дөньясы, димәк, күзаллаулар дөньясы һәм ихтыярдөньсы була;

— кешенең ихтыяры аның гамәлләрен билгеләгән кебек, бөтен дөньяда хәрәкәт итүче гомуми ихтыяр, предметлар һәм күренешләр ихтыяры дөньядагы тышкы вакыйгалар- ны, предметлар хәрәкәтен, куренешләр барлыкка килүен китереп чыгара;

— ихтыяр тере организмга гына түгел, җансыз табигатькә дә «аңсыз», «йокымсыраган» ихтыяр буларак хас;

— әйләнә-тирә асылы белән ихтыярның тормышка ашырылуы.

3. Фридрих Ницшенең «Яшәү фәлсәфәсе»

Фридриха Ницшенең (1844 – 1900) «Яшәү фәлсәфәсе» хәзерге көнчыгыш фәлсәфәнең элгәре концепциясе була, аларның нигезендә кеше һәм аның тормышы проблемалары ята, – прагматизм, феноменология, экзистенциализм һ.б.

Фәлсәфә максаты, Ницше буенча, – кешегә тормышта мөмкин кадәр үз урынын табарга, әйләнә-тирә дөньяга күнегергә ярдәм итү.

Әлеге фәлсәфәнең үзәк төшенчәсе -тормыш төшенчәсе, ул танып белү субъектының дөньяны барлыгы аспектында булуы, конкрет кеше өчен бар булган бердәнбер чынбарлык.

Яшәү һәм әйләнә-тирә дөнья нигезендә ихтыяр ята.

— «яшәүгә ихтыяр»;

— кешенең үзе эчендәге ихтыяр («эчке үзәк»);

— идарә итеп булмый торган, аңсыз ихтыяр көчле теләк,омтылыш, аффектлар;

— «хакимиятне сайлап алу мөмкинлеге ихтыяр».

Соңгы төр – «хакимияткә ихтыяр»га – фәлсәфәче аерым игътибар бүлә. Ницше буенча, «хакимияткә ихтыяр» күбрәк яки азрак дәрәҗәдә һәр кешегә хас. Үзенең табигате буенча «хакимияткә ихтыяр» үз-үзеңне саклау инстинктына якын, кеше эчендә яшерелгән хәвефсезлеккә омтылуның чагылышы һәм аның гамәлләренең хәрәкәт иттерүче көче булып тора. Ницшега ярашлы, һәр кеше (дәүләт кебек үк) аңлы яки аңсыз рәвештә тышкы дөньяда үзенең «Мин»ен киңәйтергә омтыла.

4. Вильгельм Дильтейның «Яшәү фәлсәфәсе»

Фәлсәфи фикерләр

— Дильтей Гегель фәлсәфәсен тәнкыйтьләп чыга, аңарда әйләнә-тирә дөньяның бар төрлелеге һәм кеше гомеренең уникальлеге фикерләүгә (идеягә) барып тоташа. Фикерләү урынына Дильтей фәлсәфә нигезенә «яшәү» төшенчәсен салырга тәкъдим итә.

— Дильтейга ярашлы, фәлсәфә материя, аң, диалектика һ.б. турында «схоластик» бәхәсләрен туктатырга һәм игътибарны аерым бер феномен буларак яшәүне өйрәнүгә юнәлтергә тиеш.

— Фәлсәфәче тарих – прогресс ягына юнәлүче, алдан билгеле һәм законча лыклы процесс дигәнгә ярашлы концепцияләрне инкарь итә. Дильтей буенча, тарих – очраклылык, хаос, чоңгыл чылбыры, ул үзенә аерым кешене дә, тулы милләтләрнедә тартып алып керә ала. Тарихка йогынты ясап булмый.

Яшәү – кешенең дөньядагы яшәеш ысулы

Тормыш билгеләре

— бөтенлек;

— төрле рухи башлангыч барлыгы;

— югары дөнья белән аерылгысыз берлеге.

Өченче бүлек. Төп фәлсәфи проблемалар

§45. Яшәеш

Онтология – фәлсәфәнең яшәеш проблемасын өйрәнүче үзәк бүлекләренең берсе, ә яшәеш проблемасы үзе – фәлсәфәдә иң мөһиме. Фәлсәфәнең аякка басуы нәкъ яшәеш мәсьәләсен өйрәнүдән башланып китә. Борынгы һинд, борынгы кытай, антик фәлсәфә беренче чиратта онтология белән кызыксына, яшәеш асылын аңларга омтыла

Яшәеш – бар асылны үзенә керткән реаль бар булган, тотрыклы, мөстәкыйль, объектив, мәңгелек, чиксез субстанция.

«Яшәеш» фәлсәфи категория эчтәлеген ачучы позицияләр

— Әйләнә-тирә дөнья, предметлар, күренешләр реаль бар; ул (әйләнә-тирә дөнья) бар

— әйләнә-тирә дөнья үсешә, эчке сәбәбе бар, үз-үзеңдә хәрәкәт итү чыганагы

— материя һәм дух – бердәм, әмма шул ук вакытта капма-каршы асыллар, реаль бар

— субстанцияләр – мөстәкыйль асыллар, ул үзеннән башка ул бернәрсәдә дә мохтаҗ түгел.

Яшәешнең юклыгы – яшәеш белән бердәм халәт (шулай ук реаль) һәм аңа капма-каршы.

Яшәешнең төп формалары

— материаль (матди) яшәеш – материаль булган (озынлык, масса, күләм, тыгызлыкка ия) җисем, әйбер, табигать күренешләре, әйләнә-тирә дөнья

— идеаль яшәеш – идеаль бар булган мөстәкыйль чынбарлык кебек индивидуальләштерелгән рухи яшәеш һәм объективлаштырылган (индивидуальдән тыш) рухи яшәеш

— кеше яшәеше – материаль һәм рухи (идеаль) берлеге буларак кеше яшәеше, кешенең үз-үзеннән генә яшәеше һәм аның материаль дөньяда яшәеше

— социаль яшәеш, ул кешенең җәмгыятьтәге һәм җәмгыятьнең үзенең яшәешеннән үз эченә кертә (тормыш, бар булу, үсеш).

— ноуменаль яшәеш («ноумен» сүзеннән – үз-үзеннән әйбер) – яшәеш, ул аны читтән күзәтеп торучының аңыннан тыш бар була

— феноменаль яшәеш («феномен» сүзеннән күренеш, тәҗрибәдән алынган)

— күренгәндәй яшәеш, ягъни танып белүче субъект аны ничек күрә, шундый яшәеш

Яшәешнең юклыгы – нәрсәнең булса да тулысынча юк булу, абсолют берни түгел.

§46. Материя (материаль яшәеш)

1. Материаль яшәеш һәм «материя» төшенчәсенә төп якын килү юлы

«Материя» төшенчәсенә якын килү

Материалистик ысул, аңа ярашлы, материя яшәеш нигезе ул, әбашка яшәү формалары– рух, кеше, җәмгыять – материя тудырган; материалистлар билгеләвенчә,материя беренчел һәм үзебелән булган яшәешне гәүдәләндерә;

— Объектив-идеалистик ысул – материя беренчел идеаль (абсолют) рухның тудырган нәрсәсе буларак объектив бар була;

— Субъектив-идеалистик ысул – материя мөстәкыйль чынбарлык буларак бөтенләй юк, ул тик субъектив (кеше аңында гына яшәүче) рухның продукты (феномен – бар кебек тоелган күренеш, «галлюцинация»);

— Позитивистик – «материя» төшенчәсе ялган, чөнки аны фәнни тикшерү тәжрибәсе белән дәлилләп булмый.

Материягә хас сыйфатлар

— Хәрәкәт барлыгы;

— Үз оешканлык;

— Киңлек һәм вакыт эчендә урна- шуы;

— Гәүдәләндерүгә сәләт.

Материя төзелеше элементлары

Җансыз табигать баскычлары

— Субмикроэлементар (кварк, глюон, суперструннар – материянең иң вак кисәкчәләре, атмнарга караганда да кечерәк);

— Микроэлементар (кварклардан торган адроннар, электроннар);

— Төш (атом төше);

— Атом (атомнар);

— Молекуляр (молекулалар);

— Бердәнбер әйберләр дәрәҗәсе;

— Макроҗисем баскычы;

— Планеталар дәрәҗәсе;

— Планеталар системасы дәрәҗәсе;

— Галактика дәрәҗәсе;

— Галактика системалары дәрәҗәсе;

— Мегалактика дәрәҗәсе;

— Галәм дәрәҗәсе, тулысынча дөнья.

Социум (җәмгыять) Социум баскычлары

— Аерым индивид;

— Гаилә;

— Төркем;

— Төрле дәрәҗәдәге коллективлар;

— Социаль төркемнәр (сыйныф, стратлар);

— Этнослар;

— Милләтләр;

— Расалар;

— Аерым җәмгыять;

— Дәүләтләр;

— Дәүләтләр берләшмәсе;

— Тулаем алганда кешелек.

Тере табигать баскычлары

— Күзәнәккә кадәрге (ДНК, РНК, аксым);

— Күзәнәкле;

— Күп күзәнәкле организмнар баскычы;

— Төрләр баскычы;

— Популяция баскычы;

— Биоценозлар;

— Тулаем биосфера дәрәҗәсе.

2. Хәрәкәт

Хәрәкәт – материянең аерылгысыз үзенчәлеге

Үзенчәлекләр

— материянең үзеннән барлыкка килә (аңа салынган капма-каршылыклардан, аларның берлегеннән һәм көрәшеннән);

— бөтенесен эченә алучан (барысы да хәрәкәт итә: атомнар һәм микрокисәкчәләр бер-берсеннән читләшәләр һәм тартылалар; тере организмнарның даими эше бара;

— йөрәк, ашкайнату системасы эшли, физик процесслар башкарыла; химик элементлар, тере организмнар хәрәкәт итә, елгалар хәрәкәт итә, табигатьтә әйберләр әйләнеше бара, даими җәмгыять, Җир үсешә, башка күк җисемнәре үз күчәре һәм Кояш (йолдызлар) тирәли хәрәкәт итә; йолдыз системалары галактикада хәрәкәт итә, галактика – Галәмдә);

— даими (һәрвакыт бар; бер төрле хәрәкәт формасы туктавы яңа формалар барлыкка килү белән алыштырыла).

Хәрәкәт төрләре

— механик хәрәкәт

— физик хәрәкәт

— химик хәрәкәт

— биологик хәрәкәт

— социаль хәрәкәт

Хәрәкәт типлары

сыйфатлы – материянең үзен үзгәртү, эчке структураны үзгәртеп кору һәм яңа материаль объектлар һәм аларның яңа сыйфатлары барлыкка килү.

— Динамик хәрәкәт – иске форма кысаларында эчтәлек үзгәрүе, элекке материаль формаларның «потенциалын ачу».

— Популяцион хәрәкәт – объект структурасының кардиналь үзгәреше, ул тулысынча яңа объект барлыкка килүгә, материянең бер формасыннан икенчесенә күчүгә китерә. Популяцион хәрәкәт – үзгәрешләр эволюцион да, шул ук вакытта «эмменталь» да (бер нәрсә белән дә аңлатып булмаган «шартлау» юлы белән») барлыкка килә.

күләм, сан – материя һәм энергияне киңлектәда күчерү

3. Материянең үзоешканлык сәләте

Материянең үз оешканлыгы – тышкы көчләрдән башка үз-үзеңне тудыру, камилләштерү, үз-үзеңне җитештерү

Флуктуация – материягә даими хас очраклы чайкалу һәм тайпылу.

Диссипатив структура – материянең яңа тотрыксызхәле, флуктуация нәтиҗәсендә барлыкка килә

Диссипатив структура үсеше вариантлары

— «диссипатив структура» ныгый һәм ахыргача яңа төр материягә әйләнә, тик энтропия шартларында – тышкы мохиттәге энергия агымыннан – һәм динамиктипта үсешә башлый

— «диссипатив структура» таркала һәм үлә – яки эчке көчсезлек нәтиҗәсендә, табигыйлек булмаганда, яңа элемтәләрнең ныклы булмавында, ягъни энтропия юклыганнан – тышкы мохиттән килүче энергия

Синергетика – материя- нең үзоешканлыгы турындагы тәгълимат. Рус фәлсәфәчесе И. Пригожин синергетика төп нигез салучысы.

4. Материянең вакыт һәм киңлектә урнаштырылуы

Мәсьәләгә якынаю юлы

Субстанциональ (Демокрит, Эпикур) – вакыт һәм киңлекне аерым чынбарлык итеп саналганнар, материя белән берәттән мөстәкыйль субстанция, ә материя һәм киңлек, вакыт арасындагы мөнәсәбәт субстанцияара буларак караганнар.

Реляцион (лат. теленнән relatio – мөнәсәбәт) (Аристотель, Лейбниц, Гегель) – вакыт һәм киңлекне материаль объектлар үзара бәйләнешеннән барлыкка килгән мөнәсәбәтләр буларак кабул иткәннәр.

Төп положениеләр

— вакыт – материя яшәеше формасы, ул материаль объектларның озак яшәешен һәм үсеш процессында әлеге объектларның эзмә-эзлекле үзгәрешләрен (халәте үзгәрүен) чагылдыра

— киңлек – материя яшәеше формасы, ул материал объектлар эчендәге элементларның озынлыгын, төзелешенең үзара бәйләнешен һәм материаль объектларның үзара бәйләнешен характерлый

— Вакыт һәм киңлек үзара тыгыз бәйләнгән. Киңлектә булганнар, бер үк вакытта вакыт эчендә дә бара, вакытта барган, киңлектә була

Альберт Эйнштейнның (XX гасыр уртасы) чагыштырмалылык теориясе. Әлеге теориягә яраштылы, киңлек һәм и вакыт чагыштырмача, һәм алар материал җисемнәрнең үзара бәйләнеш шартларына бәйле чагыштырмача. Теория реляцион теориянең дөреслеген дәлилләде, ягъни вакыт һәм киңлекне материя эчендәге мөнәсәбәтләр буларак аңлыйлар, вакыт һәм киңлеккә мәңгелек, үзгәрешсез зурлык буларак элеккеге карашларны үзгәртте.

5. Материя үзенчәлеге кебек чагылыш

Чагылыш – матди системаларның алар белән хезмәттәшлек итүче башка матди системаларның үзлекләрен үз эченә ала алуы. Чагылышның матди дәлиле булып түбәндәге эзләр (башка матди объектның икенче бер матди объекта чагылышы) тора: җирдәкеше эзләре, кеше аяк киемендәге җир эзләре, тырналган эзләр, кайтаваз, предметларның көзгедә чагылышы, сулыкның шома өслеге.

Аң – чагылышның югары дәрәҗәсе (төр). Материалистик концепциягә яраштылы, аң – югары оешкан материянең чагылдыру сәләте ул.

Биологик

Биологик чагылышстадияләре:

— ярсучанлык

— сизгерлек

— психик чагылыш

Химик

Физик

Механик

Социология

§47. Аң. Гомуми төшенчә,төп алымнар һәм, килеп чыгышы

1. Фәлсәфәдә аң мәсьәләсендә төп якынаю юллары

Аң: әлеге вакытта фәлсәфә чыннан да аң барлыгы һәм аерым, идеаль табигатьле (асыл) булы турында чыннан да дәлилли ала – әлеге нигезләмәне материалистлар да кабул итә, тик шул ук вакытта идеаль аң материядән җитештерелгән дип исәплиләр.

Аң мәсьәләсенә якынаю юллары

Физикализм – аң мәсьәләсенә чиктән тыш материалистик якын килү, аңа ярашлы, аң мөстәкыйль субстанция буларак юк, ул материя дәвамы гына һәм физика һәм башка табигый фәннәр карашыннан аңлатыла.

Физикализм таянган фәнни фактлар

— кешенең баш мие чыннан да катлаулы табигать «механизмы» була, материя оешуның югары дәрәҗәсе;

— конкрет кешенең аңы баш миеннән башка яши алмый, ә баш мие – биологик орган – кешелек ясалма интеллект барлыкка китерү мөмкинлеге алды, аның иясе – машина (компьютер) матди объект;

— кеше организмына медикаментоз йогынты аңда чагылырга мөмкин (мәсәлән, психотроп матдәләр куллану).

Солипсизм – аң табигатенә карата икенче чиктән тыш караш, аңа ярашлы, индивид аңы – бердәнбер чын чынбарлык, ә материаль дөнья – аның күренеше (субъектив идеализм – Беркли, Юм, Фихте һ.б.)

Аңның идеальлеге физикалистларның логик дәлилләре барып төртелгән бердәнбер проблема.

— кеше уенда яшәүче образларның материаль характеристикалары юк – масса, ис, төгәл үлчәме, формасы

— аң образлар өсеннән

«хакимлек» итәргә мөмкин – арттырырга, киметергә, аларны чакырырга, «юарга»

— беркемгә дә читтән башка кеше аңын «күрергә» туры килмәде (баш миенә операция ясаучы хирург микроскоп астында тик соры төстәге җисемне күрә – нейроннар, әмма операция ясаган кешенең образларын да, фикерләрен дә күрми).

Объектив идеализм – аңның да, материянең дә барлыгын таный, тик аңга беренчел (иҗади) рольне бирәләр һәм аны «дөнья аңы»ның бер өлеше буларак, индивид шәхесеннән аерым карыйлар

Физикализмның тармаклары

— «тәңгәлләек теориясе» (Д. Амстронг, Дж. Смарт) – рухи процессларны башка тән процесслары белән тәңгәлләштерә – кан әйләнеше, тын алу, баш мие процесслары белән);

— «элиминация» теориясе (Ф. Фейербенд) – «рух», «рухи» төшенчәсен үзен аңлатырга тырыша, искергән һәм фәнни булмаган, юк-барга ышану (чирләр сихерчеләр белән барлыкка килә белән тиң);

— вульгар материалистлар теориясе (мәсәлән, Фохтаның «ми», бавыр үт чыгарган кебек үк, фикер, уй бүлеп чыгара дигән карашы).

Уртача материализм – аңны материянең үзенә башка бер күренеше дип санаганнар, югары оешкан материянең үз-үзен чагылдыру (хәер, аның артында идеальлек сыйфатын таныйлар) – Россия фәлсәфәсендә киң таралыш алган караш

2. Аңның килеп чыгу мәсьәләсенә төп якын килү юллары

Космик (илаһи) караштан аң материаль вәкилләрдән – тер организмнар, кешедән бәйсез рәвештә үз-үзеннән бар. Аң турыдан-туры космостан «чыга» (башка вариант – Алла акылыннан), бердәм, бүленми, асылы белән бербөтен. «Дөнья аң»ы кисәкчәләре тере организманр һәм кеше аңы формасында табигатьтә таратылган.

Якын теорияләр

— монад теориясе (монадология) – иң элек Лейбниц тәкъдим итеп, Даниил Андреев белән үстерелгән, аңа ярашлы дөньяда бик зур күләмдә бүленми торган һәм үлемсез монадлар бар – беренчел рухи берәмлекләр, аларда Галәм энергиясе һәм алар аң һәм ултудырган материянең нигезе булып тора;

— Шарден теориясе, аңа ярашлы аң – кеше өстендәге асыл, «эчке ягы», материя «мие»;

— Толбет теориясе, аңа ярашлы Галәм – гигант акыл, аң – кырларның үзара бәйләнеш нәтиҗәсе, алар материяне барлыкка китерәләр;

— Рейзерның психосфера теориясе, аңа ярашлы Галактика – гаять зур акыл, ул кеше баш мие белән элемтәгә керә һәм аның акылын «тукландыра»;

— гилозоизм теориясе, аңа ярашлы бар материя (тере, терек терек түгел, живая, неживая,аның бар чагылыш) җаны бар, җанлылыкка ия –материя үзенчәлеге.

«Биологик» караштан: аң – тере табигать тудырган һәм барлыкорганизмнарга хас.

Төп теорияләр

— хайваннар тормышы кинәт уйланылып бармый, ә аларның аңынабуйсына, мәгънәгә ия;

— инстинктлар тумыштан гына түгел, ә тормыш дәверендә тупланган, алынган да булуы ихтимал;

— хайваннар гомер буена тәҗрибә туплыйлар һәм аны яхшы куллана беләләр;

— хайваннар белән ясалган күп кенә хәрәкәтләр (аеруча югарылар – песи, эт, приматлар һ.б.) катлаулы (мәсәлән, аулау) һәм зур аң эшен таләпитә;

— хайваннарга үз «әхлагы хас, үз-үзен тоту кагыйдәләре, гадәтләр,сыйфатлар, көрәш, лидерлык, тәэсирчелек һ.б.

«Кеше» карашыннан аң

– кешенең баш мие продукты һәм тик кешегә генә хас, ә хайваннар аң белән түгел, инстинктка ия. Әлеге караш аеруча XIX гасыр уртасыннан XX гасыр уртасына кадәр киң таралыш таба.

§48. Аң табигатен материалистик аңлату. Чагылдыру теориясе

1. Чагылдыру теориясе

Чагылыш теориясе (аң табигатен материалистик аңлату), аң ул югары оешкан материянең материяне чагылдыру сәләте

Чагылыш табигате белән – ул материаль объектларының үзара бәйләнеш вакытында үзендә башка материаль объектлар эзен калдыру сәләте

Чагылышның элементар формалары

Механик	Физик	Химик	Биологик (тере организмга хас)

Формалар

— **Ярсучанлык** – биологик чагылышның гади формасы – тере организмнарның (хәтта үсемлекләрнең) әйләнә-тирә дөньяның предмет һәм күренешләренә (тере һәм терек булмаган) реакциясе. Мисал – кибү, эсседә яфракларның бөтерелүе, яңгырдан соң аларның формасы үзгәрүе (элекке хәленә кайтулары), көнбагышның «Кояш артыннан» хәрәкәтләнүе.

— **Сизгерлек** – киләсе, биологик чагылдыруның тагы да югарырак формасы – тере организмнарның әйләнә-тирә дөньяны тойгы-сиземләү рәвешендә чагылдыру.

— **Психик чагылыш** – тойгыларны системалаштыру, аңлау, тере организмнарның үз-үзен тотышларын әйләнә-тирә мохиткә яраклашу масаты белән үзгәртә алу сәләте, барлыкка килгән стандарт һәм стандарт булмаган вакыйгаларга төрлечәреакция ясау, алардан дөрес чыгу юлы табу.

— **Аң** – биологик чагылышның югары формасы. Кешегә һәм, өлешләтә югары хайваннарга хас. Аң – әйләнә-тирә дөньяның тулырак чагылышы һәм аны аңлау, абстракцияләү, үз-үзен тикшерү сәләте фикерләү аркасында яңа фикер алу – ягъни аңныңүз-үзенә юнәлгәнлеге – фикерләүгә), предметлата-гамәли эшчәнлеккә сәләтлелек.

2. Кеше аңының төп үзенчәлекләре

Кеше аңының төп үзенчәлекләре

Идеальлелек – ул аңның үзгә бер төрле, материаль булмаган асылы.

Интенциональлек – предметка юнәлгәнлек. Аңның интенциональлеге түбәндегеләрнең булуын таләп итә: аң предметы (аң нәрсәне «күрә») һәм формалары (ул предметны ничек кабул итә).

Аңның идеаторлыклыгы – идеяләрне уйлап чыгару һәм тормышка ашыру сәләте – гади чагылдыру кысаларыннан чыкканэчке мөстәкыйль эш.

Абстракт идеяләр эшләп чыгару сәләтлелеге – кеше аңының хайваннар аңыннан төп аермасы. Әлеге сәләтнең нәтиҗәсе буларак, мәгълүмат тапшыру һәм тарату системасы эшләп чыгару тел барлыкка килү була. Идаторлылык аркасында кешелек эволюциясе һәм үсеше, аңның тирәнәюе мөмкин була.

Аңның идеаль үзенчәлекләре

— Материаль дөньяга капма-каршы

— Материядән бәйсез

— Кайбер очракта материягә карата беренчел

— Тотып булмый торган, материаль чаралар ярдәмендә танып булмый

Аң формалары

— үзләштерү, кабул итү

— аңлау, төшенү

— бәяләү

— хәтергә төшерү

— хыялга бирелү

— тормыш тәжрибәсе

Аң предметы

— әйләнә-тирә дөнья, аның предметы, күренешләре;

— үзенчәлекле, мөстәкыйль дөнья, югары дөнья белән бәйле һәм бәйсез.

§49. Диалектика

1. Диалектиканың гомуми төшенчәсе һәм үсеше

Диалектика – хәзерге фәлсәфәдә кабул ителгән барлык асылның үсеш теориясе һәм аңа нигезләнгән фәлсәфи ысул. Диалектика теоретик яктан материя, рух, аң, танып белүне һәм башка чынбарлык аспектларын чагылдыра.

Диалектиканың төп проблемасы – нәрсәүл үсеш?

Үсеш – материянең гомуми үзенчәле- ге һәм төп билгесе: **материаль һәм идеаль объектларның үзгәреше**, өстәвенә гади түгел (механик) үзгәреш, ә үзгәреш үзлегеннән үсү кебек, аның нәтиҗәсе югары оешу баскычына күчүе була.

Үсеш – хәрәкәтнең югары формасы.

Нигез була

Хәрәкәт шулай ук материянең эчке үзенчәлеге һәм әйләнә-тирә чынбарлыкның уникаль күренеше була. Хәрәкәт үзенең бөтенлеге, өзлексезлеге һәм бер үк вакытта каршылыклары булуы белән характерланса да, (хәрәкәт итүче җисем киңлектә даими урын биләми – хәрәкәктнең һәр хәрәкәте вакытында җисем билгеле урында була һәм шул ук вакытта ул анда инде булмый). Хәрәкәт шулай ук материаль дөньяда элемтә ысу-лы да була.

Диалектика законнары

Үзенчәлекләре

- әйләнә-тирә чынбарлыкның бар өлкәләрен дә чолгап ала;
- хәрәкәт һәм үсешнең тирәнтен нигезләрен ачып сала – аларның чыганакларын, искедән яңага күчү, иске һәм яңаның бәйләнеше механизмы.
- капма-каршылыкларның берлеге һәм көрәше
- күләмнең сыйфатка күчүе
- инкарьне инкарь итү

2. Бердәмлек һәм капма-каршылыклар көрәше законы

Бердәмлек һәм капма-каршылыклар көрәше законы барлык асыл капма-каршы башлангычлардан булуынан гыйбарәт, алар табигате буенча бердәм булып, көрәштә һәм бер-берсенә каршы торалар. Мәсәлән: көн һәм төн, кайнар һәм суык, кара һәм ак, кыш һәм җәй, яшьлек һәм картлык, һ.б. Бердәмлек һәм капма-каршы башлангычлар көрәше – эчке хәрәкәт чыганагы һәм бар асылның үсеше.

Бердәмлеккә һәм Гегельнең капма-каршылыклар көрәшенә махсус караш

— Гегель буенча, һәр предмет, күренеш ике төп сыйфатка ия – тәңгәллек һәм аермалык.

— Тәңгәллек предмет (күренеш, идея) үз-үзенә тигез, ягъни әлеге предмет нәкъ шул предмет дигәнне аңлата. Шул ук вакытта үз-үзенә тәңгәл предметта аның кысаларыннан чыгарга омтылучы, аның тәңгәллеген бозарга теләүче нәрсә бар.

— каршылык, бердәм тәңгәллекләр һәм үзенчәлекләр арасындагы көрәш, Гегель буенча, предмет үзгәрешенә (үз-үзеннән үзгәрүгә) – хәрәкәткә китерә. Мисал: бар булган идея, үз-үзенә тәңгәл була, шул ук вакытта үзенә аның кысаларыннан чыгарга ниятләүче үзенчәлек салынган; аларның көрәше нәтиҗәсе – идея үзгәреше (мәсәлән, идеализм карашында идеянең материягә үзгәрүе).

Көрәшнең төрләре

— ике якка да файда китерүче көрәш (мәсәлән, даими ярышу, болай эшләгәндә һәр як икенчесен куып җитә һәм сыйфат ягыннан югарырак үсеш баскычына менә);

— бер як һәрвакыт икенчесе өстеннән өстенрәк була торган көрәш, җиңелүче як саклана һәм җиңүчегә «ярсыткыч» булып тора, шуңа бәйле җиңүче як югарырак үсеш баскычына менә;

— антагонистик көрәш, монда бер як икенчесен юк иткән хәлдә генә исән кала ала.

Башка төр үзара бәйләнешләр

— булышлык (ике як та көрәшмичә бер-берсенә ярдәм күрсәтә)

— теләктәшлек, бердәмлек (яклар бер-берсенә турыдан теләктәшлек күрсәтми, әмма уртак кызыксынулары була һәм бер юнәлештә хәрәкәт итәләр);

— нейтралитет (яклар төрле ихтыяҗга ия, бер-берсенә булышмыйлар, әмма үзара көрәшми дә);

— мутуализм – тулы үзарабәйләнеш (нинди булса да бер эш башкарыр өчен ике як та бергә хәрәкәт итәргә тиеш, автоном гына бер якта эшли алмый).

3. Күләм хәрәкәтләренең сыйфатка күчү законы

Үзенчәлекләр

— Сыйфат – яшәешкә тиң билгелелек,предметның билгеле характеристикаларының даими системасы һәм элемтәсе.

— Күләм – предмет яки күренешнең исәпләү параметры (сан, күләм авырлык, үлчәм һ.б.).

— Үлчәм – күләм һәм сыйфат берлеге.

— Билгеле күләм үзгәрешләреннән соң мотлак сыйфат та үзгәрә.

— Әмма сыйфат берөзлексез үзгәрә алмый. Сыйфат үзгәреше үлчәм үзгәрешенә китерә торган мизгел килеп җитә (ягъни сан үзгәреше йогынтысында сыйфат үзгәреше барлыкка килгән координат системасы) предметның асылы тамырдан үзгәрә. Мондый мизгел «төен» дип атыла, ә күчеш үзе фәлсәфәдә «сикереш» дип аңлана-ла. Мәсәлән: 100 градусовка җиткәндә суның сыйфаты тамырдан үзгәрә – парга әйләнә (ягъни җылыту барышында элеккеге «координатлар системасы» җимерелә – су һәм элекке элемтә системасы). 100 градуста әлеге очрак төен була, ә суның парга әйләнүе сикереш. Шул ук күренеш суны суытканда һәм ноль градуста бозгаәйләнүендә күзәтелә.

— Табигатьтә һәрвакыт үзәк мизгелне билгеләп булмый.

4. Инкарьне инкарь итү законы

Инкарьне инкар итү законы яңа искене инкарь итә һәм аның урынын ала дигән сүз,тик үзе дә тора-бара яңадан искегә әйләнә һәм үзеннән яңарак булган белән инкарь ителә. Мәсәлән: иҗтимагый-икътисади формацияләрне алыштыру (тарих процессына формацион якын килүдә); «буыннар эстафетасы»; мәдәният, музыка һ.б.ларда зәвык үзгәреше.

Иске формаларның яңалары белән инкарь ителүе – алга бара торган хәрәкәтнең сәбәбе һәм механизмы

Үсеш юнәлеше турындагы төп карашлар – фәлсәфәдә бәхәс тудыра.

Үсеш – алга баручан процесс, түбән формадан югарыга күчеш, ягъни күтәрелә бара торган үсеш.

Үсеш буталчык, бернинди дә юнәлеше юк. Практика күрсәтүенчә, өч каратан хакыйкатькә икенчесе якынрак: үсеш күтәрелә бара торган да, кимеп бара торган да була ала, гәрчә гомум тенденция күтәрелә бара торганга кайтып кала.

Үсеш линияле бармый (туры сызыктан), ә спираль буенча, шуның белән бергә һәр спираль чорнамы элеккесен кабатлый, тик яңа, югарырак дәрәҗәдә.

Үсеш күтәрелә бара торган да, кимеп бара торганда була ала.

5. Төп принциплар һәм диалектика категорияләре

Инкарьне инкар итү законы яңа искене инкарь итә һәм аның урынын ала дигән сүз, тик үзе дә тора-бара яңадан искегә әйләнә һәм үзеннән яңарак булган белән инкарь ителә. Мәсәлән: иҗтимагый-икътисади формацияләрне алыштыру (тарих процессына формацион якын килүдә); «буыннар эстафетасы»; мәдәният, музыка һ.б.ларда зәвык үзгәреше.

Диалектиканың төп принциплары

Гомум элемтә әйләнә-тирә дөньяның бөтенлеген, аның эчке берлеген, үзара бәйләнешен, аның компонентлары – предмет, күренеш, процессларның үзара бәйләнештә булуын аңлата.

Элемтә төрләре

— тышкы һәм эчке;

— турыдан-туры һәм аралаштыручан;

— генетик һәм функциональ;

— киңлек һәм вакыт;

— очраклы һәм закончалыклы

Системалылык – ул күпләгән элемтәләр әйләнә-тирә дөньяда тәртипсез итеп түгел, тәртипкә салынып булганы аңлата. Әлеге элемтәләр бербөтен система барлыкка китерә, монда алар иерархик тәртиптә урнаша. Моңа бәйле әйләнә-тирә дөнья эчке максатка юнәлтелгәнлеккә ия.

Сәбәплелек – бер элемтәикенчесен тудыра.

Предметлар, күренешләр, процессларның эчке яки тышкы сәбәбе була. Сәбәп, үз чиратында, нәтиҗә тудыра, ә элемтә тулаем алганды сәбәпнәтиҗәле дипатала.

Тарихилык әйләнә-тирә дөньяның ике аспектын билгели:

— мәңгелек, тарих, дөньяның юкка чыгарылмавы;

— аның барлыгы һәм вакыт эчендә үсеше.

Диалектика категориясе – фәлсәфә диалектик проблемаларның асылын ачу өчен нигезләнгән гомуми төшенчәләр

— асыл һәм күренеш;

— форма һәм эчтәлек;

— сәбәп һәм нәтиҗә;

— бердәнбер, үзенчәлекле,гомуми;

— мөмкинлек һәм чынбарлык;

— зарурлык һәм очраклылык.

§50. Диалектика альтернативалары

Диалектика барлык асыл үсеше турындагы бердәнбер теория түгел. Аның белән берлектә охшаш фәлсәфи кызыксыну предметлы (үсеш) башка теорияләр дә бар, алар шулай ук фәлсәфи методлар була. Гадәттә, болар диалектикага капма-каршы теорияләр.

Диалектикадан аермалы метафизика

— иске һәм яңаның элемтә мәсьәләсе буенча – әгәр диалектика иске һәм яңа арасында элемтә барлыгын таный икән, метафизика тулысынча аларны кире кага, ул яңа искене тулысынча этәреп чыгара дип исәпли;

— хәрәкәт итү сәбәбе мәсьәләсе буенча – метафизикага ярашлы, хәрәкәт материянең үзеннән чыга алмый, хәрәкәтнең сәбәбе тышкы беренчел этәргеч була;

— күләм һәм сыйфат элемтәсе буенча – метафизика тарафдарлары алар арасында үзара бәйләнеш күрмиләр; алар фикеренчә, күләм сыйфатка бәйле үзгәрә(арту, кимү һ.б.), сыйфат сыйфатка бәйле үзгәрә (ягъни үзеннән үзе яхшыра, начарая);

— хәрәкәт юнәлгәнлеге мәсьәләсе буенча үсә – әгәр диалектика үсеш күтәрелә бараторган спираль буенча барса, ә метафизика я турыга, я божра буенча, яки үсеш юнәлешен бөтенләй танымый;

— фикерләү системасында – әгәр фикерләүнең динамик ысулы «тезис – антитезис – синтез» адымнарына кайтарып калдырылса, метафизик «яки – яки», «шулай булмаса, димәк бу» формулаларына нигезләнә, ягъни метафизик фикерләү сыгылмалы түгел һәм бер яклы;

— чынбарлыкка мөнәсәбәтле – диалектика дөньяны аның төрлелегендә күрә («дөньяны төсле итеп күрү»), ә метафизика – бертөрле, «кара-ак» принцибы буенча;

— танып белүгә мөнәсәбәтле – диалектикага ярашлы, танып белү ипләп кенә һәм максатчан абсолют хакыйкатькә бару процессы, ул танып була торган (чагыштырмача) хакыйкатьне эзлекле танып белү аша (ягъни бердәмлеген исәпкә алып, гадидән катлаулыга һәм абсолютка); метафизикага ярашлы, тойгылардан өстен һәм коры фикергә нигезләнгән характер йөрткән тәжрибә ысуллары ярдәмендә абсолют хакыйкатьне шунда ук танып белеп була ди;

— әйләнә-тирә дөньяга мөнәсәбәтле – диалектика дөньяны бөтен һәм үзара бәйләнешле итеп күрә, метафизика – аерым әйбер һәм күренешләрдән торган итеп.

«Негатив» диалектика гомум диалектиканың тотрыклы постулатларын җимерә, догмага әйләнгән положениеләрне алып ташлый, үз-үзенә дә, әйләнә-тирә дөньяга да тәнкыйдирәк карыйлар.

Төп идеяләр

— диалектика «негатив» – тәнкыйди генә булырга мөмкин, диалектика бар искегә игътибар итәргә тиеш түгел;

— диалектика даими, һәр предметта, күренештә тәнкыйть өчен сәбәп эзләргә һәрнәрсәне шик астына куярга, тәнкыйтьләргә, кире кагырга тиеш;

— яңа тулысынча һәм кире кайтарымаслык итеп искене кире кагырга һәм шулай уктәнкыйтьләнергә тиеш, тагы да яңаракны эзләргә (ягъни диалектика алга һәм урында тукталып тормыйча, алга гына барырга, бар каршылыклар аша үтәргә тиеш);

— «негатив» (тәнкыйди) диалектиканың объектив мәгънәсе юк, ул бары тик аңга гына мөнәсәбәте бар, чөнки ул тик аңны гына инкарь итә һәм тәнкыйтьли;

— инкарьне инкарь итү беркайчан да позитивка күчәргә тиеш түгел (идеал табуга),барлык чынбарлык күренешләрен дә даими инкарь итәргә һәм тәнкыйтьләргә кирәк.

Фәлсәфи якын килү юллары (ысул, алымнары), диалектикага альтернатив, әмма мөстәкыйль теорияләр булмаган.

Релятивизм – танып белүнең әзер нәтиҗәләрен интерпретацияләү.

Эклектика – ирекле кушу нигезендә теоретик хакыйкатьләр төзү, таркалган фактларны берләштерү, ясалма интеллектуаль конструкцияләр төзү.

Софистика – асылы белән ялган, әмма ялган сөземтәләрдән төзелгән сөземтә формалары буенча дөрес дип кабул ителгән, ялгыш дөрес дип бирелгән.

Догматизм – нинди дә булса положениеләрне исбатланмаган буларак үзләштерелә, тик абсолют хакыйкать, фикерләүдәге, әйләнә-тирә дөньяга карата сыгылмалылык булмау.

§51. Фәлсәфәдә кеше, шәхес проблемасы.

Кешенең иҗтимагый табигате

1. Кеше һәм шәхеснең гомуми төшенчәсе

Кеше – үзенчәлекле җан, табигать күренеше, бер яктан, биологик башлангыч, икенчедән, рухи яктан – тирән абстракт фикерләүгә, әгъза сөйләм, югары белемгә, мәдәният казанышларын үзләштерүгә, социаль оешманың югары дәрәҗәсенә ия булучы.

Шәхес – ул кешенең тумыштан булган сыйфатлары, социаль мохиттә үсеш алган һәм сатып алынган белемнәр, күнекмәләр, кыйммәтләр, максатлар җыелмасы. Шулай итеп, кеше – ул социаль-биологик җан иясе, өстәвенә, хәзерге цивилизация шартларында тәрбия, законнар, әхлакый нормалар нигезендә кешенең социаль башлангычы биологик башлангычны контрольдә тота.

Шәхеснең нормаль үсешен тәэмин итүче шарт факторлар

— Яшәү, үсеш, җәмгыятьтә тәрбияләнү – кешенең нормаль үсеше өчен үзәк шарт, аңарда теләсә нинди сыйфатлар үсеше, шәхескә әйләнү.

— Биологик индивидның социаль-биологик шәхескә әйләнүдә практика, хезмәт зур әһәмияткә ия. Билгеле бер эш белән шөгыльләнгәндә генә, өстәвенә кешенең үз кызыксынулары һәм тартылышы булган эш белән шөгыльләнгәндә, ул җәмгыятькә файдалы булачак. Кеше үзенең социаль әһәмиятлелеген бәяли алачак, шәхеснең бар кырларын ача алачак.

Фәлсәфәдә бүлеп чыгарылган шәхес сыйфатлары (тумыштан һәм яшәү барышында алынган гадәтләр, фикерләү сәләте һәм тәртибе):

— **Позитив әхлакый** сыйфатлар : гуманизм, кешелеклелек, намус, вөҗдан, тыйнаклылык, киң күңеллелек, гаделлек, тугрылык, һ.б.

— **Җәмгыять белән гаепләнүче** әхлакый сыйфатлар: тәккәберлек, оятсызлык, тупаслык, әрәмтамаклылык, курка-клык, нигилизм

— **Җәмгыятькә файдалы** сыйфатлар: ихтыяр, кыюлык, акыллылык, осталык, максатчанлык, үз карашыңбулу, илсөярлек.

2. Хаҗәтләр һәм ихтыяҗлар классификациясе

Хаҗәтләр һәм ихтыяҗлар булуы – һәр кешегә хас сыйфат. Төрле хәҗәт һәм ихтыяҗлар иерархиясе барлыгы, аларның конфликты, көрәше җәмгыять үсешенең эчке двигателе була. Әмма ихтыяҗлар төрлелеге прогресска булышлык итә һәм җимерү нәтиҗәләренә китерми, тик бары хаҗәт һәм ихтыяҗлар чикле антагонистик, үзара юкитүгә юнәлтелгән (кеше, сыйныф, дәүләт һ.б.) булмаса һәм гомум ихтыяҗлар белән бәйләнештә була.

Хаҗәтләр – кешедәр эшчәнлеге нигезе, теге яки бу гамәлне эшләү өчен стимул. Хаҗәтләрне канәгатьләндерү – кеше бәхетенең мөһим компоненты. Һәрҗәмгыятькә билгеле хаҗәт дәрәҗәсе һәм аларны канәгатьләндерү өчен мөмкинлекләр туры килә. Җәмгыять ныграк үсешкән саен, хаҗәтләр сыйфаты югарырак.

Биологик (табигый) гомерне саклау, туклану,үрчү һ.б.

Җәмгыять белән формалаштырылучы

— Рухи-эчке дөньяны баетырга омтылу, мәдәният кыйммәтәренә тарту

— Материальлаеклы тормыш дәрәҗәсе белән тәэмин итү

— Социаль – һөнәри сәләтләрне тормышка ашыру, җәмгыять тарафыннан лаеклы бәя алу

Ихтыяҗлар – хаҗәтләрнең конкрет гәүдәләнеше, нәрсә дә булса да кызыксынуы

— Шәхси (индивидуаль)

— Төркем

— Сыйнфый

(социаль төркемнәр – эшче, укытучы, банкир, номенклатураихтыяҗы)

— Иҗтимагый (бар җәмгыятьнең) мәсәлән, тәртип саклауда

— Дәүләт барлык кешелек ихтыяҗы (мәсәлән, атом-төш сугышын булдырмау

— Материаль һәм рухи

— Нормаль һәм нормаль булмаган

— Озак вакытлы һәм якында гына

— Рөхсәт ителгән һәм рөхсәт ителмәгән

— Гомуми һәм антагонистик

Фәлсәфә бүлеге

3. Социаль нормалар һәм аларның шәхескә йогынтысы

Социаль нормаларның җәмгыять өчен әһәмияте

Социаль нормалар – җәмгыятьтә кеше тәртибен тәртипкә салучы кабул ителгән гомуми кагыйдәләр.

— Җәмгыятьтәге тәртипне, тигезлекне саклый

— Кешенең яшерен биологик инстинктларны басалар һәм кешене «мәдәниятләштерәләр»

— Кешегә җәмгыять тормышына яраклашырга ярдәм итәләр, социальләштерергә

Төркем нормалары – тар коллективлардагы махсус нормалар, (Якын һәм дус компанияләр нормалары, җинаять төркеме нормалары, секта нормалары һ.б.)

Әхлак нормалары кешеләрнең гомум тәртип вариантларын көйли. Алар шактый иҗтимагый мөнәсәбәтләрне үзенә җәлеп итә, һәркем (яки күпчелек) белән таныла; таләпләр башкарылу механизмы кешенең үзеннән яки аның намусыннан тора. Җәмгыять әхлак нормалары бозучыны тәнкыйтьли.

Махсус (һөнәри) нормалар теге яки бу һөнәр ияләренең тәртибен көйли (мәсәлән, төяүчеләр, сезонлы эшчеләр нормалары дипломатларныкыннан аерыла, артистлар, хәрбиләр һ.б. арасында да аерым тәртип нормалары.

Хокук нормалары

Үзенчәлекләр

— Махсус дәүләт органнары вәкилләре белән урнаштырыла

— Гомум мәҗбүри характерда була

— Формаль билгеләнгән (язма формада төгәл формулировка бирелгән)

— Билгеле бер иҗтимагый мөнәсәбәтләрне тәртипкә сала

— Дәүләт көче белән ныгытылган (иректезләү куллану мөмкинлеге, законны бозучыларга карата махсус дәүләт органнары тарафыннан җинаятьчеләргә карата законга яраштылы җәза күрү)

4. Эшчәнлек һәм индивидны шәхескә әйләндерер өчен аның әһәмияте

Эшчәнлек – билгеле нәтиҗәгә юнәлдерелгән тулы, системалы, эзмә-эзлекле гамәлләр

Хезмәт – эшчәнлекнең төп төре

Үзенчәлекләре

— Хәзерге үсешкән җәмгыятьтә хезмәт – югары социаль кыйммәтләрнең берсе. Кешене хезмәттән аерсаң, ул үз мотивациясен югалта һәм социаль сөйкемлелеген югалта, ул шәхескә тискәре йогынты ясый. Киресенчә, кешегә һәм җәмгыятькә файда китерүче хезмәт кеше потенциалын күтәрә.

— Хезмәт кеше аңы формалашуына, кеше сәләте, тулаем алганда эволюция үсешендә зур роль уйный.

— Хезмәт һәм аның нәтиҗәләре аркасында кеше хайваннар рәтеннәнчыга, югары оешкан җәмгыять төзи.

5. Шәхеснең тормыш позициясе һәм аның төрләре

Тормыш позициясе – кешенең әйләнә-тирә дөньяга карата аның уйлары һәм гамәлләрендә чагылыш тапкан мөнәсәбәте

Пассив (конформистик) тормыш позициясе әйләнә-тирә дөньяга буйсынуга, хәл-вакыйгаларга ияруга юнәлтелгән

— **Авторитар-конформистик** – (кеше үз тәртибендә аерым, бик абруйлы һәм авторитетлы кеше тәртибенә карап көйли, гадәттә, җитәкче).

— **Төркемле-конформистик** – (аерым кеше, башка төркем әгъзалары кебек ук,төркемдә кабул ителгән кагыйдәләргә катгый рәвештә буйсыналар.

— **Иҗтимагый-конформистик –** (аерым индивид җәмгыять нормаларына буйсына һәм «агымсу буенча йөзә» әлеге тәртип тоталитар дәүләт гражданнарына хас.

Актив тормыш позициясе, әйләнә-тирә дөньяны үзгәртүгә, хәл-ситуацияне контрольдә тотуга юнәлтелгән

— Актив, башка индивидларга карата мөстәкыйль тәртип, тик төркем лидерына гына буйсыну.

— Җәмгыять нормаларына буйсыну, әмма Төркемдә, коллективта лидерлыкка омтылу.

— Җәмгыять нормаларын санга сукмау һәм үзеңне җәмгыятьтән тыш табаргатырышу – җинаятьчеләр бандасында, хиппилар арасында, башка асоциаль төркемнәрдә очрый.

— Җәмгыять нормаларын кабул итмәү, әмма мөстәкыйль яки башкалар ярдәме белән әйләнә-тирә чынбарлыкны үзгәртергә омтылу (мисал: революционерлар – Ленин һәм башкалар).

6. Шәхес тәрбияләү

Тәрбияләү – индивидны социаль нормаларга, рухи мәдәнияткә өйрәтү, аны хезмәткә һәм киләчәк тормышка әзерләү

Үзенчәлекләр

— Шәхес тәрбияләү кешенең җәмгыятькә нормаль керү, аның яраклашуы, җәмгыятьнең үзенең гармонияле яшәве өчен кирәк

— Тәрбияне җәмгыятьнең төрле институтлары тәэмин итә: гаилә, мәктәп, яшьтәшләр төркеме, армия, хезмәт коллективы, югары уку йорты, һөнәрчелек төркемнәре, гомумән җәмгыять үзе

— Тәрбияче буларак, үрнәк буларак аерым кеше чыгыш ясарга мөмкин: мәктәптә укытырга, абруйлы яшьтәше, командир, начальник, мәдәният вәкиле, сәясәт эшлеклесе

— Масса-күләм мәгълүмат чаралары да шәхес тәрбияләү буенча әһәмиятле, шулай ук рухи һәм материаль мәдәният казанышлары (китап, күргәзмә, техник төзелешләр һ.б.)

Тәрбия максатлары

— Кешене җәмгыятьтәге тормышка әзерләү (аңа материаль, рухи мәдәният, тәҗрибә тапшыру)

— Шәхеснең иҗтимагый кыйммәт сыйфатларын үстерү

— Җәмгыятьтә гаепләнелүче сыйфатларны юкка чыгару яки бастыру, нейтральләштерү

— Кешене башка кешеләр белән үзара бәйләнештә булуга өйрәтү

— Кешене хезмәткә өйрәтү

§52. Җәмгыять

1. Иҗтимагый яшәешнең төп өлкәләре һәм җәмгыять тормышының төп өлкәләре

Җәмгыять – тору мәйданы, чор, традицияләр, мәдәният белән берләштерелгән кешеләрнең эшчәнлек һәм яшәү системасы. Җәмгыять – объектив чынбарлык, эчке структурасы, бөтенлеге, законнары, үсеш юнәлеше булган яшәеш барлыгы формасы.

Иҗтимагый яшәеш яклары

— Объектив як, ягъни аң һәм кеше ихтыярыннан башка яшәгән нәрсә тормыш шартлары, кешеләр ихтыяҗы, материаль җитештерү хәлен белү һ.б.

— Субъектив як – кеше аңы һәм ихтыяры, аларның җәмгыятькә мөнәсәбәте, омтылышлары, карашлары.

Җәмгыятьнең төп тормыш өлкәләре

— Икътисади

— Социаль

— Сәяси

— Рухи

2. Икътисади өлкә

Составы

Икътисади өлкә – база, җәмгыять тормышында билгеләүче

— Производство (җитештерү)

— Булу

— Алмаш

— Материаль байлыклар куллану (икътисади өлкә эчтәлеге)

Материаль җитештерү (җәмгыять тормышының икътисад өлкәсе)

— Җәмгыять яшәешенең материаль нигезен барлыкка китерә

— Җәмгыять алдында торган проблемаларны хәл итүгә булышлык итә

— Турыдан-туры социаль структурага йогынты ясый (сыйныфлар, социаль төркемнәр)

— Сәяси процессларга йогынты ясый

— Рухи өлкәгә йогынты ясый турыдан-туры эчтәлеккә дә инфраструктурага да. Рухи өлкә вәкиле (мәктәп, китапханә, театр, китаплар)

Формалар

Икътисади мәйдан – хуҗалык тормышы барган җир

Икътисад идарә институтлары эшчәнлеге

Җитештерү көчләре – кеше, аның белеме, хезмәт осталыгы, җитештерү чаралары.

Җитештерү: чимал, материал, бина, төзелешләр, транспорт һ.б.

Материаль байлыклар житештеру ысуллары

Җитештерү мөнәсәбәтләре җитештеру барышында кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләр

— Мөнәсәбәтләр җитештерү чаралары . Бу җитештерү мөнәсәбәтләрен билгеләүче төп элемент, чөнки аларга ия зат чынбарлыкта икътисад хуҗасы була һәм шартлар куя ала. Ә башкалар тик үзләренең хезмәтләрен хосусый милекчеләргә хезмәт хакы бәрәбәренә тәкъдим итә.

— Хезмәт бүленеше нигезендә эшчәнлек алмашу мөнәсәбәте

— Материаль җитештерү белән байлыкларны бүлү буенча мөнәсәбәтләр

Фәлсәфә бүлеге

3. Социаль өлкә

Социаль өлкә – хезмәт бүленешенә,җитештерү чаралары милегенә һәм милли факторга нигезләнгән җәмгыятьнең эчке корылыш системасы (социаль төркем, милләт, халыклар)

Җәмгыятьнең социаль өлкәсенә мөнәсәбәтле төп якын килү

— Сынфый, аңа ярашлы, җәмгыять зур төркемнәргә бүленә – сыйныфларга (кагыйдә буларак, милекчеләр һәм милекче булмаганнар, гадәттә, антагонистик, алар арасында сыйнфый көрәш бара); марксистик фәлсәфәдә таралган

— Стратификацион, аңа ярашлы, җәмгыять социаль төркемнәр төрлелегеннән тора – профессиональ, демографик һ.б. Бер-берсен тулыландыручы һәм үзара бәйләнешкә керүче. Көнчыгыш фәлсәфәгә хас.

Җәмгыятьнең социаль структура элементлары

— Сыйныфлар

— Стратлар

— Катламнар (икътисади бүлешештә генә түгел, традицияләргә дә нигезләнгән)

— Кешеләр, шәһәрләр һәм авыллар

— Физик һәм акыл хезмәте вәкилләре

— Социаль-демографик төркемнәр (ирләр, хатыннар, картлар, яшьләр)

— Милли берлекләр

Хәзерге җәмгыятьнең үсеш юнәлеше

— Аны бертөрлегә әйләндерү, каршылыкларны, стартлар арасындагы аерманы шомарту.

— Структура катлаулануы, микро дәрәҗәгә кадәр страталарның бүленеше – кече төркемнәр.

Гражданлык җәмгыяте – социаль төркемнәрне берләштерүнең югары дәрәҗәсе җәмгыять, аның әгъзалары үзләрен бербөтеннең гражданнары дип исәплиләр, гомум бурычлар куялар, законнарны, әхлакый традицияләрне ихтирам итәләр.

Социаль мобильлек – бер социаль төркемнең икенчесенә күчү мөмкинлеге (мәсәлән, крестьян – эшчеләр санына, эшченең – интеллигенция санына, интеллигентның – эшмәкәрләр санына)

Үзенчәлекләр

Социаль мобильлек – җәмгыятьнең нормаль яшәү нигезе, һәр кешенең тормышта урын табуы, аның бәхете. Кагыйдә буларак, түбән социаль мобильлек тоталитар дәүләтләргә һәм тирән икътисади һәм рухи торгынлыкта булган дәүләтләргә хас.

Икенче яктан, югары социаль мобильлек, революция (инкыйлаб) яки реформа (үзгәртеп кору) сызыгында торган демократик, динамик үсештә булган җәмгыятьләргә хас.

Югары дәрәҗәле демократияле, әмма түбән социаль мобильлек булган, югары дәрәҗәдәге тормышлы илләрдә бер стратадан икенчесенә күчү йә бөтенләй мөмкин түгел, йә бик читен. Бу җәмгыятьнең үтә җыйнаклыгы, кечкенә зурлыкта, әгъзаларның катгый үзара бәйләнештә, традицияләр көче, җәмгыятьтәге урыннарның инде «алынган булуыу» белән аңлатыла.

Көнчыгыш җәмгыятьләренең социаль

Мобильлек төрлелеге

Югары дәрәҗәле мобильлек булган илләр – АКШ, Италия, Япония

Уртача дәрәҗәле мобильлек булган илләр – Канада, Бөек Британия

Түбән дәрәҗә мобильлек булган илләр – Голландия, Швейцария, Дания

4. Сәяси өлкә

Җәмгыятьнең сәяси өлкәсе – социаль төркемнәр ихтыяҗын яклаучы учреждениеһәм оешмалары җыелмасы, җәмгыять белән идарә итүне башкара.

Җәмгыятьнең сәяси системасы элементлары

— дәүләт һәм дәүләт органнары;

— сәяси партияләре;

— җәмгыять оешмалары;

— профсоюзлар;

— башка институтлар

Дәүләт – дәүләт хакимиятен башкаручы органнар системасы.Дәүләтнең төп функцияләре:

— вәкиллек (төрле сәяси, социаль төркемнәр ихтыяҗын яклау);

— регулятив – җәмгыятьтә тәртип саклау, иҗтимагый процесслар белән идарә итү);

— саклый торган – гражданнарны тышкы һәм эчке хәвеф-хәтәрдән саклау;

— тышкы сәясәт;

— интеграцион.

Сәяси тормышның төп мәсьәләсе – хакимият мәсьәләсе.

5. Рухи өлкә

Рухи тормышның төп элементлары

Рухи эшчәнлек – аң эшчәнлеге, аның барышында фикер һәм тойгылар, образлар һәм кеше, материаль һәм рухи дөнья турындагы күзаллаулар барлыкка килә.

Рухи эшчәнлек барышында **рухи ихтыяҗларга** ярашлы рухи кыйммәтләр тарала һәм кулланыла (кешеләр белән үзләштерелә, кабул ителә).

Рухи эшчәнлек нәтиҗәсендә **рухи кыйммәтләр** туа, мәсәлән, әхлакый, дин нигезләре, фәнни теорияләр, матур әдәбият.

Кешенең индивидуаль аңы – аның тарафыннан яшәешнең аерым якларын үзләштерү.

Кешеләр арасындагы аралашу, рухи кыйммәтләр белән үзара алмашу **рухи мөнәсәбәтләр** дип атала.

Иҗтимагый аң – кешеләрнең иҗтимагый гамәлләренән, аларның җитештерү, гаиләкөнкүреш һәм башка эшчәнлекләреннән барлыкка килгән тойгы, кәеф, идея, теория, әдәби һәм дини образлар, төрле карашлар, яшәешнең төрлелеген гәүдәләндереше.

Иҗтимагый аң элементлары

Гадәти аң – җәмгыять һәм аның әгъзаларының әйләнә-тирә чынбарлыкны турыдан-туры кабул итүе. Теоретик аң – яшәешне югары гомуми кабул итү.

Иҗтимагый аң формалары

— сәяси;

— хокукый;

— әхлакый;

— фәнни;

— дини.

Иҗтимагый психология – тойгылар, ихтыяҗлар, омтылышлар, максатлар, идеаллар, йолалар, традицияләр, кеше һәм гомумән җәмгыять хаҗәтләре.

Иҗтимагый идеология – карашлар системасы, җәмгыятьтә кабул ителгән юнәлешләр, социаль катламнар ихтыяҗын чагылдыручы, иҗтимагый-сәяси строй.

§53. Җәмгыять һәм табигать

1. Җир шары планетасы – тормыш башлансын өчен бар кирәк шартларга ия

Җир шарының өстенлекләре (башка планеталар белән чагыштырганда) тормыш башлану өчен:

— Кояш – Җир шары һәм башка Кояш системасы планеталары аның тирәсендә әйләнүче йолдыз – уртача үлчәмле һәм уртача көчкә ия: артык зур («кайнар») һәмбик кечкенә (салкын) йолдызлар тирәсендә яшәеш була алмый;

— Җир Кояштан оптималь аралыкта – 150 млн. км ераклыкта тора (шул исәптән,әгәрЖир 10–15 млн. км Кояшка якынрак булса, ул көйгән чүлгә әйләнер иде әгәр дә 10–15 млн. км – Кояштан ераграк булса, боз белән капланыр иде);

— Җир уртача зурлыкта: бик кечкенә планеталар (Меркурий, Плутон) үз тирәсендә атмосфера барлыкка китерү һәм башка яшәү шартлары тудырыр өчен бик көчсез тарту көченә ия; киресенчә, гигант-планеталар (Юпитер, Сатурн) артык тарту көченә ия, үзе тирәсендә үтәргә кыен тышчасы бар (атмосферага охшаш), бу яшәеш барлыгына киртә булып тора;

— Җирнең атмосферасы бар – махсус газлы тышча, ул, беренчедән, Җирне кояш һәм башка радиациядән, башка космос йогынтысыннан саклый, икенчедән, кислород һәм азоттан тора – сулау һәм тере организмнар бар булу өчен кирәкле матдәләр; өченчедән, Җиргә тиз җылынырга һәм тиз суынырга мөмкинлек бирми, температура тигезлеген саклый;

— Җир суга ия – яшәеш өчен шулай ук кирәкле элемент.

2. Табигатьнең төп өлешләре

Литосфера – (грекчадан – таш тышча) – Җир шарының өске каты катламы, аңа Җир кабыгы һәм мантиянең өске өлеше керә (Җир эчендәге эрегән катламы)

— Җир йөзенең каты өслек нигезен барлыкка китерә (ә тормыш бары тик җир өслегендә генә була ала, чөнки Җир эчендә кайнап торган масса – магма һәм үзәктә – тимер төш);

— Үзендә файдалы казылмалар бар;

— Махсус органик катламга ия – үсемлекләр өчен шартлар тудыручы туфрак, алар, үз чиратында, кеше һәм җәнлекләр өчен ризык булып тора.

Атмосфера – Җир тирәли газлы-парлы тышча. Атмосфера катламы бик юка: аның 75проценты Җир өстеннән 10 км биеклектә урнашкан. Югарырак – ирекле атмосфера катламнары, ул барлык күләменең нибары 25 процентын тәшкил итә һәм 30–50 км тарала, аның артында ачык космос.

Функцияләр:

— Җирне ачык космос йогынтысыннан саклый;

— Җирнең кызуын һәм туңуын туктата, уңай температура режимын тудыра;

— Азотка ия (80% тирәсе) – барлык тере организмнар составында булган матдә, һәм кислород (20% тирәсе) – сулау өчен кирәкле матдә (газ), водород белән кушылып су барлыкка китерә (ягъни яшәеш булсын өчен кирәкле табигый элементка ия).

3. Җәмгытьнең төп өлешләре

Җәмгыять – кешеләрнең тормышы һәм эшчәнлеген оештыру формалары җыелмасы, индивидларның бербөтен бердәм яшәү системасы (үзара мөнәсәбәт, үзара бәйләнеш, тәртип, традицияләр, мәдәният)

Хәзерге галимнәр белән бүлеп чыгарылган җәмгыятьнең төп өлешләре (Ферсман, Плотников, Дьяконов һ.б.)

Антропосфера – кешеләрнең биологик организм буларак яшәү өлкәсе.

Социосфера – кешеләр арасындагы катлаулы иҗтимагый мөнәсәбәтләр өлкәсе.

Биотехносфера (техносфера) – кеше һәм кешелекнең техник йогынтысы таралышы өлкәсе.

Гидросфера – Җир шары өсте (литосфера) һәм атмосфера арасындагы су тышчасы. Су тозлы океан, диңгез, күл, тозсыз күлләр, елга сулары, бозлыклар төрендә) җир өстенең шактый зур өлешен каплый – якынча 70 процент. 30 процент җир өсте – материк һәм утраулар төсендә коры җир тәшкил итә.

— Гидросфера булганга атмосфера һәм литосферада (аларның үзара бәйләнеше нәтиҗәсендә) суның табигатьтәге әйләнеше башкарыла, ул үсемлек һәм хайван организмнары- ның нормаль үсешенә булышлык итә;

— су-җәнлекләр һәм үсемлекләр составының бер өлеше (кеше организмының зур өлеше – 80 процент тирәсе – судан тора);

— су (диңгезләр, океаннар, елгалар, күлләр һ.б.) су асты үсемлекләре һәм җәнлекләре, балыкларының яшәү мохите (алар җир өстендә яшәүчеләрдән ким түгел);

— яшәү иң элек суда барлыкка килгән, аннары гына диңгез һәм океаннарның тере организмнарының бер өлеше коры җиргә күчкән дигән фикер бар.

Биосфера – тере организмнар яшәү мохите («яшәеш белән тулы Җир катламы»). Биосфера – тулы үзара бәйләнгән организм.

— Аңа бөтен литосфера һәм гидросфера керә;

— Атмосфераның түбән катламнары (якынча коры җир өслегеннән 10 км);

— Җир асты катламнары – 10 км тирәнлеккә кадәр, шул исәптән 0,5–1 км океан төбенә кадәр.

4. Табигатькә антропоген йогынты. Экология проблемасы

Экология проблемасы – әйләнә-тирә мохитне кешенең зарарлы йогынтысыннан саклау проблемасы

Тудырды

Табигатькә антропоген йогынты (ягъни кеше һәм аның эшчәнлегенең йогынтысы). Бүгенге антропоген йогынтының төп проблемасы (һәм хәвефлелек) кешелек ихтыяҗларының чиксезлеге белән чиксез фәнни-техник мөмкинлекләрнең туры килмәве табигатькә һәм табигатьнең үз мөмкинлекләренә йогынтысында

Үзенчәлекләр

— Җәмгыять, дәүләт, кешенең техник җиһазланышы үскән саен (катлаулы хезмәт кораллары, машиналар) табигатьнең кешегә йогынты ясавы кимеде, ә кешенеңтабигатькә йогынтысы (антропоген йогынты) көчәйде.

— XVI–XIX гасырлардан башлап, кеше өчен файдалы шактый фәнни ачышлар эшләнелгәч, уйлап табылган әйберләр барлыкка килгәч, җитештерү мөнәсәбәтләре катлаулана, кешенең табигатькә йогынтысы даими һәм һәр җирдә була башлый. Табигать кеше тарафыннан мөстәкыйль чынбарлык итеп түгел, ә кеше ихтыяҗларын канәгатьләндерүче чимал чыганагы буларак кабул ителә.

— XX йөздә, планлы фәнни-техник прогресс берничә тапкыр тизләнгәч, һәм фәнни-техник революциягә әверелә, антропоген йогынты катастрофик дәрәҗәгә җитә.

— Әлеге вакытта техника дөньясы (техносфера) мөстәкыйль чынбарлыкка әйләнде дисәң дә була (заманаңның супер техник ачышлары кешенең табигатькә йогынты ясау мөмкинлекләрен чиксез ясый, гомум компьютерлаштыру һ.б.), ә табигать тулысынча диярлек кешегә буйсындырылган.

Кешенең табигатькә зарарлы йогынтысының иң хәвефлеләре:

— җир асты казылмаларының кимүе – барлык тарих эчендә, аеруча XX гасырда кешелек рәхимсез һәм чиксез күләмдә файдалы казылмаларны үзләштерә, бу Җирнең эчке резервларын саегайтуга китерде (катастрофик хәлгә якын) (мәсәлән, энергия чыганаклары запасы – нефть, таш күмер, табигый газ – инде 80-100 елдан тулысынча бетү ихтималы бар.

— Җирнең пычрануы, аеруча сулыклар, җитештерү калдыклары белән атмосфераның пычрануы;

— үсемлекләр һәми хайваннар дөньясын юкка чыгару, техник үсеш (юллар, заводлар, электр станцияләре һ.б.) үсемлек һәм хайваннарның гадәти яшәеш рәвешен, флора һәм фауна балансын бозган шартлар тудыру;

— урманнар киселүе (урманнар – атмосфераны мөһим тазарту факторы);

— атом-төш энергиясен хәрби һәм тыныч тормыш максатларында куллану, җир өсте һәм җир асты атом-төш шартлаулары.

5. Социаль экология

Социаль экология – кешене, аның шәхесен, сәламәтлеген, тулаем җәмгыятьне фәнни-техник прогресс нәтиҗәләреннән саклау. Әлеге проблематика еш кына заман экзистенциалистлары иҗатында кагыла («кеше тормышы фәлсәфәчеләре») – Ясперс, Хайдеггер, Камю, Сартр һ.б.

Җәмгыятьнең һәм техниканың кешегә йогынтысы

— хәзерге заман кешесе артык мәгълүматлы җәмгыятьтә яши (гәзит, телевидение), ә шулай ук кибернетикага ныграк бәйлегә әйләнә (компьютерлар, компьютер челтәрләре, саннар, виртуаль чынбарлык һ.б.);

— урбанизация үсә – хәзерге вакытта күп кешеләр зур шәһәрләрдә яши, гадәттә анда 10–25 миллион халык яши һәм югары технологияләр кулланыла (Мехико, Токио, Нью-Йорк, Лос-Анджелес һ.б.). Кешеләр мегаполис ритмына буйсыналар, үзләренең үзенчәлекләрен югалталар («кеше – тузан бөртеге» проблемасы);

— кеше үсешкән җәмгыять һәм дәүләтнең көчле йогынтысын тоя – әхлак, традицияләр, законнар, салым системасы, хокук саклау системасы, сәяси институтлар.

Социаль экология бурычы – кешене максималь җәмгыять һәм фәнни-техник прогрессның негатив тискәре йогынтысыннан саклап калу.

6. Бер илдә яшәүче халык проблемасы

Кеше, җәмгыять һәм табигать мөнәсәбәтләре арасындагы аерым бер проблема булып хәзерге заманда җирдә яшәүче халык проблемасы төп проблема булып тора, ул киләчәктә тагын да актуальлерәк булачак һәм ахыр чиктә кешелекнең төп мәсьәләсенә әйләнәчәк.

Халык үсеше

Проблеманың аспектлары

— халык үсеше кешелекнең сан ягыннан артуына китерә, ә димәк, аның ихтыяҗлары, ул табигатьне күбрәк файдалануга китерә;

— халык үсеше барышында җәмгыятьтәге каршылыклар артуы ихтимал, чөнки прогресс халык үсеше артыннан һәм байлыклар арасына да җитешмәскә мөмкин (шуның белән галимнар арасында халыкның тыгызлыгының «критик массасы», «чиге» турында сорау бәхәс тудыра, ягъни Җирнең максималь күләме никадәр булуы, аны узу һәркемгә дәхәвефле булачак;

— халык сыйфаты мәсьәләсе – җәмгыятьнең, гаиләнең материаль мөмкинлекләр җитәрме (аеруча гаиләдә югары туым – 8–10 бала булган аз үсешкән илләрдә) җәмгыять тарафыннан балаларга тәрбия, белем, дәвалау, игътибар бирелерме? Күп кенә Азия һәм Африка илләрендә, халык саны чамадан артык үсешә. Әлеге тенденция бер яктан, тууым артыннан контроль булмавыннан (Кытайдан тыш) һәм аның мөмкин булмавы, икенче яктан – традицияләр, хәер, икътисади яктан бу үрчемүзен акламый. Азия һәм африкадагы табигый үсеш яшәү сыйфаты, үсеп килүче буын сыйфаты түбәнәюенә китерә (наданлык, физик хәлсезлек һ.б.), аерым гаиләгә һәм дәүләткә хәл ителмәгән проблемалар тудыра.

Халык үсеше түбәнәюе

Төп сәбәпләр

— югары оешкан техноген җәмгыять кешедән күп көч таләп итә (белем алу, эш). Гаиләгә һәм балаларга вакыт калмый. Күпчелек Көнчыгыш илләрендә ике бала үстерү традициягә әйләнде, еш кына – бер бала тәрбиялиләр;

— реформалар барышында аякка басучы дәүләт гражданнары, үзләренең фәкыйрьлеге, социаль якланылмаганлыгы, тормыш авырлыгы сәбәпле, йә бөтенләй бала тапмыйлар, яки минимум (берәү) белән чикләнәләр.

7. Мальтус законы

Мальтус законы (Томас Роберт Мальтус, 1766 – 1834). Әле 1798 елда Мальтус («Халык үсеше законының тәжрибәсе») китабында чик барлыгы һәм кешелек аңа ирешергә тиешлеген дәлилли. Бу халыкның геометрик прогрессиядә барганы белән аңлатыла, ә фәнни-техник үсеш – арифметикта (ягъни прогресс бар, тик халык үсеше артыннан өлгерми).

Әлеге гипотизаны дәлилләүче халык үсеше динамикасы

— яңача елларны санау тәртибеннән алып Христос туганнан башлап – 230 млн;

— 1000 ел – якынча 300 млн (мең ел эчендә халык ике тапкыр да артмаган – 1,5 тапкырдан кимрәккә саны үскән);

— 1850 ел – 1 миллиард;

— 1930 ел – 2 миллиард;

— 1976 ел – 4 миллиард;

— 1987 ел – 5 миллиард;

— 2000 ел – 6 миллиард;

— 2025 ел – 8 миллиард (көтелә).

Әгәр дә элегрәк халык икеләтә артсын өчен 1000 ел кирәк булса, 1850 елдан алып моның өчен 80, 46, 50 ел кирәк була – ягъни әлеге вакытта халык 50 ел саен икеләтә арта бара. Галимнар санавынча, Җир 60 миллиард кешене туендыра ала. Әлеге заман темплары буенча барса, «критик» чик инде 2150 – 2200 елларда ук килеп җитәчәк.

Халыкның чамадан тыш арту куркынычына бәйле кешелек хәл итәргә тиешле проблемалар:

— Азия һәм Африкадагы халык үсешен киметү (чөнки Көнчыгыш илләрендә тискәре динамика һәм алар киресенчә, халык үсешендә мохтаж), артымны дәүләт сәясәте аша контрольдә тоту, аз балалы гаиләләрне хуплап бәләкләү;

— Җирнең кешелекне туендыруның яңа мөмкинлекләрен һәм кешелек үсеше чиген кичектерүне эзләү (60тан 100 млрд. кадәр һәм алга таба).

8. Техноген һәлакәтен булдырмау чаралары

Техноген һәлакәтне булдырмау өчен кешелек нәрсә эшләргә тиеш

— табигатькә хәвефле антропоген йогынтыны туктату яки киметү;

— экологик мәсьәләләрне хәл итү;

— социаль экологиягә игътибар бүлү – кешене мәгълүмати-техноген җәмгыять тоткынына әйләндермәскә;

— Җир ресурсларын рәхимсез куллану белән бәйле булмаган яшәеш өчен яңа чималлар табу;

— туучылар санын контрольдә тоту, халык арту проблемасын хәл итү, аның сан һәм сыйфат тигезлеген саклау.

§54. Танып белү (гносеология)

1. Танып белүгә гомуми төшенчә

Танып белү – кеше аңындагы чынбарлыкның махсуслаштырылган актив чагылдырылу процессы. Танып белү барышында яшәешнең төрле чикләре билегеләнә, әйберләрнең тышкы ягы һәм асылы, әйләнә-тирә күренешләр тикшерелә, шулай ук танып белү эшчәнлеге субъекты – кеше – кешене тикшерә, ягъни үз-үзен. Заман гносеологиясе нигездә гностицизм принципларына нигезләнә.

Танып белү буенча кеше гамәлләре төрләре

Кеше әйләнә-тирә дөньяны турыдан-туры танып белү (ягъни йә үзе өчен нәрсә булса да яңаны ача, яки кешелек өчен);

Кеше әйләнә-тирә дөньяны башка буын вәкилләре танып белү эшчәнлеге нәтиҗәләре аша таный (китап укый, өйрәнә, матди һәм рухи мәдәният төрләренә тартыла.

Танып белү проблемасына төп якын килү юллары

Гностицизм: гностицизм тарафдарлары (кагыйдә буларак, материалистлар) әлеге һәм киләчәк танып белүгә оптимистик карыйлар. Алар фикеренчә, дөньяны танып була, ә кеше танып белү өчен чиксез мөмкинлекләргә ия. Материалистлар танып белүне процесс дип саный, аның барышында материя үзенең чагылдыру сәләте аша – аң үзен-үзе өйрәнә;

Тарих принцибы – предмет һәм күренешләрне тарихи барлыкка килү һәм үсеше контекстында карау;

Агностицизм: агностиклар (еш кына – идеалистлар) кешенең танып белү сәләтлелегенә, яки гомумән дөньяның танып белеп булуына ышанмыйлар, яки аны өлешләтә генә танып була дип исәпләләр.
Агностиклар арасында иң таныльганы Иммануил Кант. Аның тарафыннан агностицизмның эзлекле теориясе тәкъдим ителә. Идеалистлар танып белүне идеаль акылның мөстәкыйль эшчәнлеге дип саныйлар.

Танып белү принциплары

Диалектика принцибы танып белүгә диалектик якын килүне күз уңында тота (ягъни үсеш күзлегеннән), диалектика законнары, категорияләре, принципларын куллану;

Практика принциплары – танып белүнең төп ысулы итеп парктиканы тану – кешенең әйләнә-тирәне һәм үз-үзен үзгәртү буенча эшчәнлеге;

Чынбарлыкны иҗади чагылдыру активлыгы принцибы;

Хакыйкатьнең конкретлык принцибы – конкрет шартларда нәкъ индивидуаль һәм дөрес хакыйкатьне эзләү.

2. Танып белү төзелеше

Танып белү структурасы

Танып белүче субъект – кеше – акылга ия һәм кешелек туплаган, шул ук вакытта җәмгыять танып белү арсеналын үзләштергән җан, үз тарихы барышында материаль һәм рухи мәдәниятне туплаучы тулаем җәмгыять үзе – танып белү нәтиҗәләренә ия булучы.

Танып белү объекты – әйләнә-тирә дөнья (бар төрлелегендә яшәеш), ягъни субъектның танып белү процессы юнәлгән өлеше.

Хакыйкать – объектның субъект тарафыннан адекват һәм тәңгәл чагылдырылуы.

Ялгышу – субъект тарафыннан әйләнә-тирә чынбарлыкны адекват булмаган, ялган чагылышын тануы,чынбарлыкка туры килмәүче танып белү нәтиҗәсе.

Бәя – субъект (аң) тарафыннан әйләнә-тирә чынбарлыкны категория, закон, төшенчә, булган кыйммәтләргә таянып логик төшенү.

Практика – кешенең әйләнә-тирә дөнья һәм үз-үзен үзгәртү буенча конкрет эшчәнлеге. Практика танып белүнең төп формасы була һәм танып белү вакытында хакыйкать критерие булып тора.

Практиканың төп төрләре

— Материаль җитештерү;

— Идарә итү эшчәнлеге;

— Фәнни эксперимент.

Практиканың функцияләре

— Хакыйкать критерие;

— Танып белү нигезе;

— Танып белү максаты;

— Танып белү нәтиҗәсе.

Тоеп танып белү чынбарлыкны чагылдыручы тойгылар сиземләвенә һәм мантыйкка нигезләнә.

Рациональ танып белү акылга, аның мөстәкыйль эшчәнлегенә нигезләнә.

Рациональгә танып белүгә интуитив танып белү якын, аның вакытында хакыйкать кешегә мөстәкыйль рәвештә аңсыз дәрәҗәдә килә.

§55. Тарих фәлсәфәсе

1. Тарихи процесска карата төп карашлар, якынаю юллары

Тарихка ике төрле караш

Тарих – тәртипсез, очраклы процесс, мантыйк, закончалык, юнәлешләрдән азат (мәсәлән, иррационалистлар).

Тарих – максатчан, закончалыклы һәм мантики процесс (бу категориягә күпчелек фәлсәфәчеләр карый).

Тарихка якынаю юллары

Формацион якынаю юлы

Цивилизацияле якынаю юлы

Культурологик якынаю юлы

Башка якынаю юллары

Гегельчә якынаю юлы тарихка карата.

Гегель, кешенең үз-үзен тану, иреклек критериен нигезгә салып, тарихны кешене азат итүнең максатчан һәм закончалыклы процессы итеп таный

Гегель бүлеп чыгарган тарихи процесс этаплары

— Көнбатыш (Кытай, Мисыр һ.б.) – үзен һәм бары тик бер кеше генә ирекле, калганнары аның коллары дип аңлый;

— Антик (Греция, Рим, Урта гасыр) – үзен һәм бер төркем кеше генә ирекле дип аңлый. Кеше катламы – «өстәгеләр»; калганнар аңа хезмәт итә һәм аңа бәйлелектә тора.

— Алман – үзен һәм барлык иреклекне аңлый.

Позитив якынаю юлы (әлеге вакытта бераз үзгәртелгән төстә киң таралу алды)

Огюстом Конт бүлеп чыгарган җәмгыять үсеше стадияләре

— Традицион;

— Индустриальгә кадәр;

— Индустриаль.

Бүгенге Көнчыгыш фәлсәфәчеләре бүлеп чыгарган җәмгыять үсеше стадияләре

— Традицион;

— Индустриальгә кадәр (аграр);

— Индустриаль;

— Индустриальдән соңгы.

2. Маркс, Энгельс, Ленинның формацион якынаю юллары

Формацион якын килүне марксизмга нигез салучылар – К. Маркс һәм Ф. Энгельс тәкъдим, В.И. Ленин үстерелә.

Үзенчәлекләр

— Иҗтимагый-икътисади формация үзе белән җитештерү мөнәсәбәтләре җыелмасын гәүдәләндерә, җитештерү көчләре үсеше дәрәҗәсе, иҗтимагый бәйләнешләр, тарихи үсешнең билгеле бер этабындагы сәяси строй

— Бар тарих иҗтимагый-икътисади формацияләр алмашының закончалыклы процессы буларак карала. Һәр яңа формация алдагысында әзер була, аны инкарь итә һәм үзе дә яңарагы белән инкарь ителә. Һәр формация җәмгыятьне оештыруның югарырак тибы була.

— Формацион якынаю юлы дөнья фәлсәфәсендә киң таралыш тапты, аеруча социалистик һәм постсоциалистик илләрдә. Аның үзенең өстенлекле һәм кимчелекле яклары бар.

— Өстенлекләре – тарихны объектив закончалыклы процесс буларак, икътисади үсеш механизмнарын тирәнтен эшкәртү, реальлек, тарихи процессны системалаштыру.

— Кимчелекләре – башка факторларны исәпләмәү (мәдәни, милли, кинәт туган), артык схемалылык, җәмгыять үзенчәлекләреннән аерым булуы, линиялелек, гамәлдә тулысынча дәлилләнмәве (кайбер җәмгыятъләр белән төшерелеп калуы колбиләүчелек, капиталистик формацияләр, линиялелек бозылуы, өскә-аска сикереше, коммунистик (социалистик) формациянең икътисади яктан бөлү).

Бер формациядән икенчесенә күчү механизмы

— Иҗтимагый-икътисади формациядә ике төп компонент бар – базис һәм өскорма. Базис – җәмгыятьнең икътисады, ул җитештерү көче һәм җитештерү мөнәсәбәтләреннән тора. Өскорма – дәүләт, сәяси һәм иҗтимагый институтлар. Бер иҗтимагый-икътисади формациядән башкага күчү икътисади базис үзгәрешләренә китерә.

— Җитештерү көчләре даими үсә, камилләшә, ә җитештерү мөнәсәбәтләре шул ук килеш кала. Конфликт барлыкка килә, яңа дәрәҗәдәге җитештерү көчләре белән искергән җитештерү мөнәсәбәтләре арасында каршылык туа. Иртәме-соңмы, көчләп яисә ирекле рәвештә икътисади базиста үзгәрешләр барлыкка килә – җитештерү мөнәсәбәтләре йәэкренләп, йә аны яңага алыштыру юлы белән яңа җитештерү көчләре дәрәҗәсенә килә.

— Үзгәргән икътисади базис сәяси өскорма үзгәрешенә илтә (яки ул яңа базиска яраклаша, яки тарихның хәрәкәтләндерүче көчләре белән себерелеп түгелә) – яңа, югарырак дәрәҗәдә булган иҗтимагый-икътисади формация барлыкка килә.

Маркс буенча биш иҗтимагый-икътисади формация

Беренчел община формация-се

— примитив хезмәт оештыру формалары (механизмнарны сирәк куллану, гадәттә – индивидуаль кул, сирәк – коллектив эш (ауга йөрү, игенчелек);

— хосусый милек милек булмавы – хезмәт чаралары һәм нәтиҗәләренә гомуми милеклектә;

— тигезлек һәм шәхсиирeклек;

— җәмгыяттән аерылган көчләп тагылган хакимият юклыгы;

— иҗтимагый яктан йомшак оешканлык – канкардәшлек билгесе ягыннан кавемнәргә оешып, бергәләп карарлар кабул итә алырлык дәүләтләр булмавы.

«Азия җитештерү ысулы» эре елгалар буенда урнашкан борынгы Көнчыгыш җәмгыятьләрендә таралыш ала (Мисыр, Кытай, Месопотамия) Азия җитештерү ысулы үз эченә ала:

Характеристика

— икътисад нигезе буларак ирригация игенчелеге;

— төп җитештерү чараларына хосусый милек булмавы (җир, ирригация корылмаларга);

— җир һәм җитештерү средстволарына дәүләт милеге;

— дәүләт контроле (бюрократия) астындагы ирекле общинникларның массалы коллектив хезмәте;

— үзәкләштерелгән, көчле, деспотизмга корылган хакимият булуы. Алардан кол биләүчелек иҗтимагый-икътисади формация тамырдан аерылып тора:

— җитештерү средстволарына хосусый милек барлыкка килә, шул исәптән «тере», «сөйли алучы» – колларга да;

— социаль тигезсезлек һәм иҗтимагый (сыйнфи) бүленеш;

— дәүләт һәм хакимият.

Кол биләүчелек иҗтимагый икътисади формация:

Характеристика

— җитештерү средстволарына хосусый милек барлыкка килә, шул ук исәптә «тере», «сөйләшә белүче» –коллар;

— социаль тигезсезлек һәм иҗтимагый (сыйнфый) бүленеш;

— дәүләт һәм хакимият.

Феодаль иҗтимагый икътисади формация

Характеристика

— җир милегенең эре махсус игенчеләр сыйныфы – феодаллар;

— иреклеләр хезмәте, тик феодал крестьяннардан икътисади бәйле булганнар (сирәк – сәяси);

— ирекле һөнәр үзәкләре – шәһәрләрдәге аерым җитештерү мөнәсәбәтләре.

Капиталистик иҗтимагый икътисади формация

Характеристика

— икътисадта төп рольне сәнәгать уйный башлый;

— җитештерү средстволары катлаулана
– механикалаштыру, объединение труда;

— җитештерү средстволары буржуазия сыйныфына;

— төп эшне буржуазиядән икътисади яктан бәйле булган ялланган ирекле эшчеләр башкара.

Коммунистик (социалистик) формация

Характеристика

— җитештерү чараларына шәхси милек булмавы;

— җитештерү чараларына дәүләт (иҗтимагый) милеге булуы;

— шәхси милекчеләр эксплуатациясеннән азат булган эшче, крестьян, интеллиген- ция хезмәте белән;

— барлык җәмгыять әгъзалары арасында бердәм җитештерү продуктларын гадел тигез бүлү;

— җитештерү көчләренең югары дәрәҗәдә булуы һәм хезмәтнең югары оешканлыгы.

3. Тойнбиның цивилизацион якынаю юлы

Арнольд Тойнбиның (1889 – 1975) якынаю юлы

Цивилизация төрләре

Кешелек тарихында якты эз калдырган төп цивилизацияләр читләштереп булса да башка цививлизацияләргә (аеруча дини яктан) йогыныты ясый.

— Шумер;

— Вавилон;

— Миной;

— Эллин (грек);

— Кытай;

— Индус;

— Ислам;

— Христиан;

— Кайбер башка цивилизацияләр.

Локаль цивилизацияләр, кагыйдә буларак, милли кысаларда чикләнә.

Иглаек локаль (милли) цивилизацияләр, Тойнби буенча, кешелек тарихында 30 тирәсе исәпләнелә Америка, германия, рус һ.б.

Цивилизация – рухи традицияләр, охшаш тормыш алып бару, географик һәм тарихи кысалар белән берләшкән тотрыклы кешеләр берләшмәсе. Тарих – линияле булмаган процесс. Бу Җирннең төрле почмакларындагы берберсе белән бәйләнеше булмаган цивилизацияләрнең туу, яшәү һәм үлү процессы.

Тарихны хәрәкәт иттерүче көчләр

— Цивилизациягә тыштан ясалган каршы килү (уңайсыз географик урын, башка цивилизацияләрдән артта калу, хәрби агрессия);

— Каршы төшүгә цивилизациянең җавабы;

— Талантлылар эшчәнлеге, алла тарафыннан сайланылган шәхесләр (бөек кешеләр).

Цивилизациянеңэчке төзелеше

— Иҗади азчылык;

— Инерт (сүлпән) күпчелек.

Үзенчәлекләр

— Иҗади азчылык сәлпән күпчелекне үз артыннан алып бара, цивилизациягә каршы булган һәр нәрсәгә җавап бирү өчен.

— Иҗади азчылык һәрвакыт күпчелекнең язмышын хәл итә алмый. Күпчелек азчылыкның көчен басучан, аны йота ала. Бу очракта үсеш туктала, торгынлык башлана.

Һәр цивилизация үткән стадияләр

— туу;

— үсү;

— чатнау;

— дезинтеграция, циви- лизациянең үлүе һәм юкка чыгуы.

4. Шпенглерның культурологик якынаю юлы

Освальд Шпенглерның (1880 – 1936) якынаю юлы

Үзенчәлекләре

— Әлеге якынаю юлының үзәк төшенчәсе – мәдәният – дин, традиция, матди һәм рухи торомыш җыелмасы

— Мәдәният – үзидарәле, аерым әһәмияткә ия булучы,чикләнгән, аерымланган чынбарлык.

— Мәдәният туа, яши һәм үлә.

— Шпенглерның «мәдәният» төшенчәсе Тойнбинең «цивилизация» төшенчәсенә якын, әмма Шпенглер «цивилизация»се Тойнбинекенә караганда башка мәгънәгә ия. Культурологик якынаю юлы кысаларында цивилизация – мәдәниятнең югары үсү дәрәҗәсе, мәдәният үсешен төгәлләүче, аныңүлүенә кадәрге чор.

— Культурологик якынаю юлы аеруча XX гасырның беренче яртысында киң таралыш ала.

Шпенглер бүлеп чыгарган сигез мәдәният

— Һинд;

— Кытай;

— Вавилон;

— Мисыр;

— Антик;

— Гарәп;

— Рус;

— Көнчыгыш-европа.

5. Тарихи процесска карата башка якынаю юллары

Тарихи процесска карата башка фәлсәфи якынаю юллары

Гегельчә якынаю юлы

Гегель, нигез критерие итеп кешенеүзен, иреген тануын алып, тарихны кешене азат итүнең максатчан һәм закончалыклы процессы итеп карый һәмөч этабын бүлеп чыгара:

— көнчыгыш (Кытай, Мисыр һ.б.) – үзен таный һәм бары тик бер генә кеше ирекле итеп кабул итә – идарәче, башкалар – аның коллары;

— бары тик бер төркем генә (кешеләр катламы) ирекле, – «өстәгеләр»; калганнар аңа хезмәт итә һәм аңаргабәйлелектә тора;

— герман – үзен таный һәм барысы да ирекле.

Позитив якынаю юлы

Позитив якынаю юлы берникадәр үзгәртелгән төстә бүген киң таралыш алды. Позитивчылар (Огюст Конт) җәмгыятьнең түбәндәге үсеш баскычларын бүлеп чыгаралар:

— Традицион;

— Индустриальгә кадәрге;

— Индустриаль

Әлеге классификация нигезендә көнбатыш фәлсәфәчеләре арасында кешелек үз үсешендә түбәндәге баскычларны үткән дигән фикер киң таралыш ала:

— Традицион;

— Индустриальгә кадәрге (аграр);

— Индустриаль;

— Индустриальдән соңгы җәмгыять.

§56. Киләчәк

1. Фәлсәфәнең алдан күзаллау функциясе. Киләчәкне алдан күзаллау мөмкинлеге һәм аның төп аспектлары

Алдан күзаллау функциясе – фәлсәфәнең төп функцияләренең берсе, аның мәгънәсе һәм билгеләнеше киләчәккә булган күзаллауларны нигезле ясау.

Киләчәкне нигезләүдә түбәндәге аспектларны бүлеп чыгаралар:

Онтологик аспект күзаллау яшәешнең үз асылыннан – аның объектив законнарыннан, сәбәп нәтиҗә бәйләнешеннән ук мөмкин дигәннән гыйбарәт.Диалектикадан чыгып, һәр үсеш механизмының сыйфат ягыннан сикереше үзгәрешсез кала, шуңа да киләчәкне күзаллап була.

Гносеологик аспект танып белү мөмкинлекләре чиксез булганлыктан (илебез фәлсәфәсенә ярашлы), ә алдан күзаллау мөмкин булуга нигезләнә.

Логик аспект – логика законнары хәзергедә дә, киләчәктә дә үзгәрешсез кала.

Нейрофизиологик аспект аң һәм баш миенең чынбарлыкны алдан чагылдара алу мөмкинлегенә нигезләнә.

Социаль аспект кешелек үз тәжрибәсеннән чыгып киләчәк моделен булдырырга омтылудан гыйбарәт.

2. Футурология һәм социаль күзаллауның гомуми төшенчәсе

Хәзерге көнбатыш фәнендә аерым фән – **футурология** бүленеп чыгаралар. Немец галиме Флехтхайм (XX гасырның 40нчы еллары) аңа нигез салучы дип исәпләнелә, ул бу терминны да үзе тәкъдим итә.

Киләчәкне күзаллау белән шөгыльләнгән танылган галим һәм фәлсәфәчеләргә Г. Парсонс, Е. Ханке, И. Бестужев-Лада, Г. Шахназаровны һәм башкаларны кертеп була.

1968 елда махсус «Рим клубы» оешмасы төзелә, аның бер юнәлеше – кешелек үсешен күзәллау булып тора.

Социаль күзаллау аерым үзенчәлекле төр булып тора. Ул җәмгыятьтәге процессларны күзаллау белән шөгыльләнә.

Шулар арасында **өлкәләрдәге процесслар:**

— җитештерү мөнәсәбәтләре;

— фән һәм техника;

— мәгариф;

— сәламәтлек саклау;

— әдәбият, сәнгать, мода;

— төзелеш;

— космосны үзләштерү;

— халыкара мөнәсәбәтләр.

Дүртенче бүлек. Рус фәлсәфәсе

§57. Рус фәлсәфәсенә гомуми сыйфатлама

1. Рус фәлсәфәсенә гомуми төшенчә һәм үзенчәлекле сыйфатлары

Рус фәлсәфәсе – дөнья фәлсәфә фикеренең феномены. Аның феноменлыгы рус фәлсәфәсенең Европа һәм дөнья фәлсәфәсеннән аерым (автоном), мөстәкыйль үсешендә, ул Көнбатышның күп фәлсәфи юнәлешләре – эмпиризм, рационализм, идеализм һәм башка юнәлешләре йогынтысына бирелми. Шул ук вакытта рус фәлсәфәсен тирәнлек,җентекле, кайвакыт Көнбатыш өчен аңлашылмаган үзенчәлекле тикшерү проблемалары аерып тора.

Рус фәлсәфәсенең үзенчәлекле сыйфатлары:

— дини йогынтысының бик нык көчле тәэсире, аеруча православие һәм мәҗүсилек-нең;

— фәлсәфи фикерләрне җиткерүнең үзенчәлекле формасы – сәнгать иҗаты,әдәби тәнкыйть, публицистика, сәнгать, «эзоп теле» (бу сәяси азат булмау һәм каты цензура белән аңлатыла);

— бөтенлек, барлык фәлсәфәчеләрнең дә аерым бер проблематика белән генә түгел, барлык актуаль мәсьәләләр белән шөгыльләнергә омтылуы;

— әдәп һәм әхлак мәсьәләләренең зур роле;

— конкретлык;

— киң массалар арасында таралуы, гади халыкка аңлаешлы булуы

Рус фәлсәфәсенең предметы:

— кеше проблемасы;

— космизм (космосны бердәм бербөтен организм буларак кабул итү);

— мораль һәм әхлак проблемалары;

— Россиянең тарихи үсеш юлын сайлау проблемасы – Көнчыгыш һәм Көнбатыш арасында (рус фәлсәфәсенең аеруча үзенчәлекле проблемасы);

— хакимият проблемасы;

— проблема государства;

— социаль гаделлек проблемасы (әлеге проблема белән рус фәлсәфәсенең бик яхшы катламы «сугарылган»);

— идеаль җәмгыять проблемасы;

— киләчәк проблемасы.

Рус фәлсәфәсенең төп баскычлары (этаплары):

— борынгы рус фәлсәфәсе тууы һәм Русьнең яшь христиан фәлсәфәсе чоры;

— татар-монгол изүе, үзәкләштерелгән рус дәүләте туган, аякка баскан һәм үсешкән чорлары фәлсәфәсе (Мәскәү Русе һәм Россия);

— XVIII гасыр фәлсәфәсе;

— XIX гасыр фәлсәфәсе;

— XX гасыр рус һәм совет фәлсәфәсе.

2. Яшь рус фәлсәфәсе (барлыкка килү чоры һәм яшь христианлык)

Борынгы рус фәлсәфәсе барлыкка килү чоры һәм Русь дәүләтендәге яшь христианлык фәлсәфәсе IX-XIII гасырларга карый (Борынгы рус дәүләте – Киев Русе барлыкка килүдән алып феодаль таркалуга һәм татар-мангол яулавына кадәрге чор).

Яшь рус фәлсәфәсенең төп темалары:

— мораль һәм әхлакый кыйммәтләр;

— христианлыкны аңлату, аны мәҗүсилек белән бәйләргә омтылу;

— дәүләт;

— хокук;

— табигать.

Вәкилләре:

— Иларион (төп әсәре – «Закон һәм Бәрәкәт турында сүз», биредә христианлык анализлана һәм популярлаштырыла, аның Русьтәге хәзерге һәм киләчәк роле билгеләнә;)

— Владимир Мономах (төп әсәре – «Үгет-нәсыйхәт», үзенчәлекле мораль-әхлакый кодекс, биредә нәсел вәкилләренә үгет-нәсыйхәт бирелә, яхшылык һәм явызлык, батырлык, намуслык, ныклык-чыдамлык проблемалары анализлана, һәм башка мораль-әхлакый мәсьәләләр);

— Климент Смолятич (төп әсәре – «Фома пресвитерга мөрәҗәгатьнамәсе», төп фәлсәфи тема – акыл, танып белү проблемасы);

— Филипп Пустынник (төп әсәре – «Елау», ул җан һәм тән үзара мөнәсәбәте, бәдәни (материаль) һәм рухи (идеаль) проблемаларына кагылышлы.

3. XII-XVII гасыр рус фәлсәфәсе

XII-XVII гасыр рус фәлсәфәсе монгол-татар изүеннән азат итү, үзәкләштерелгән Рус дәүләте (Мәскәү Русе) аякка басу һәм үсеше чорына туры килә.

Бу чор фәлсәфәгә хас төп темалар:

— рус рухлыгын саклау;

— христианлык;

— азатлык өчен көрәш;

— дәүләт төзелеше;

— танып белү.

Шушы чор күренекле фәлсәфәчеләр арасында:

— Сергий Радонежский (XIV гасыр –фәлсәфәче-рухани, христианлыкның көч һәм куәт, универсальлек һәм гаделлек аның төп идеаллары була; рус халкын берләштерү, монгол-татар изүен бәреп төшерү;

— Философий (XVI гасыр.) – шулай ук христианлык белән шөгыльләнә, христианлыкның күчемлелеге идеясен яклап чыга («Мәскәү – Өченче Рим») Рим – Константинополь – Мәскәү;

— Максимилиан Грек (1475 – 1556) мораль-әхлак кыйммәтләре, тыйнаклык, аскетлыкны яклый, монархия һәм патша хакимияте идеологы була, аның төп максатлары итеп халык турында кайгырту һәм гаделлек дип таныла;

— Андрей Курбский (1528 – 1583) оппозицион социаль-сәяси фәлсәфә идеологы, патша хакимиятенең деспотизмын чикләү, азатлык, хокук, катламлы-сайлаулы монархия өчен чыгыш ясый, читтән торып Явыз Иван белән бәхәс алып бара;

— Нил Сорский, Вассиан Патрикеев – Чиркәү реформасы өчен чыгыш ясыйлар, Чиркәү мәгънәсезлеген, күрсәтмәлелекне юкка чыгару, Чиркәүне халыкка якынайту, «нестяжательләр» хәрәкәте идеологлары булалар («иосифляннарга» каршы көрәшәләр – элеккеге чиркәү кагыйдәләрен саклаучы яклылар);

— Аввакум һәм Никон – Чиркәү яңарышы өчен көрәшәләр, әмма идеологик мәгънәдә; Никон – гореф-гадәтләрне үзгәртеп коруга һәм Чиркәүне дәүләтнеке белән беррәттән тагын бер хакимият дәрәҗәсенә күтәрү өчен, Аввакум – иске гореф-гадәтләрне саклау өчен;

— Юрий Крижанич (XVII в.) – схоластика һәм аның рус теологиясендә таралышына каршы чыга; беренчедән, гносеология (танып белү) мәсьәләләре белән шөгыльләнә; икенчедән, рациональ һәм тәҗрибәле (эмпиристик) танып белүне тәкъдим итә; барлык нәрсәнең беренчел сәбәбе итеп Аллаһны күрә.

4. XVIII гасыр рус фәлсәфәсе (материализм һәм социаль-сәяси фәлсәфә)

XVIII гасыр рус фәлсәфәсе үз үсешендә ике төп этапны кертә.

— Петр реформалары чоры фәлсәфәсе;

— XVIII гасыр уртасы һәм икенче ярты материалистик фәлсәфәсе.

Беренче юнәлешкә (Петр реформалары чорына) Феофан Прокопович, В.Н. Татищев, А.Д. Кантемир иҗатлары керә.

Алар фәлсәфәсенең төп юнәлешләре социаль-сәяси:

— монархия төзелеше мәсьәләләре;

— император хакимияте, аның илаһилыгы һәм ныклыгы;

— император хокуклары (хөкем итү, кичерү, үз-үзенә мирасчыны билгеләү һ.б.;

— сугышлар һәм тынычлык.

М.В. Ломоносов, А.Н. Радищев материалистик юнәлешнең төп вәкилләре булды.

М.В. Ломоносов (1711 – 1765) фәлсәфәдә механик материализм яклы була. Рус фәлсәфәсендә материалистик традициягә нигез сала. Шулай ук аның тарафыннан матдәнең атомик («корпускуляр») төзелеш теориясе тәкъдим ителә, аңа ярашлы, әйләнә-тирәдәге барлык предметлар һәм материя тулысынча иң кечкенә бөртекләрдән («корпускул»лардан, ягъни атомнардан) – материаль монадлардан. М.В. Ломоносовның аллага карашы – деизмнарча. Бер якта, ул Тудыручы Аллаһның бар булу ихтималлыгын кабул итә, әмма икенче якта, Аллаһны чиктән тыш көч һәм мөмкинлекләргә ия дип исәпләми. Ломоносов фәлсәфәсендә этика, мораль, әхлакка зур роль бирелә.

А.Н. Радищев (1749 – 1802) та эзмә-эзлекле материалистик позициядә тора. Яшәешнең материалистик башлангычларын дәлилләүдән тыш, Радищев социаль-сәяси фәлсәфәгә дә зур игътибар бирә. Аның кредосы – самодержавиегә каршы көрәш.

5. XIX һәм XX гасыр рус фәлсәфәсенең төп юнәлешләре

XIX гасыр рус фәлсәфәсе үзенә берничә юнәлешләрне кертә:

— декабристлар;

— монархик;

— көнбатышчылар һәм славянофиллар;

— революцион (инкыйлаби)-демократик;

— атеистик;

— теологик;

— космизм фәлсәфәсе.

XX гасыр рус (һәм совет) фәлсәфәсе күбрәк түбәндәге төрләрдә күрсәтелә:

— марксизм-ленинизм фәлсәфәсе;

— космизм фәлсәфәсе;

— табигый-фәнни фәлсәфә;

— «рус чит ил» фәлсәфәсе.

§58. XIX гасыр рус фәлсәфәсе

1. XIX гасыр рус фәлсәфәсенең төп юнәлешләре

XIX гасыр рус фәлсәфәсенең төп юнәлешләре.

— Декабристлар фәлсәфәсе

— Көнбатышчылар һәм славянофиллар фәлсәфәсе

— Чаадаев фәлсәфәсе

— Консерватив дини һәм монархик фәлсәфә

— Язучылар Ф.М. Достоевский һәм Л.Н. Толстой фәлсәфә системасы

— Революцион-демократик фәлсәфә

— Либераль фәлсәфә

2. Декабристлар фәлсәфәсе

Декабристлар фәлсәфәсенең төп юнәлеше – социаль-сәяси.

П. Пестель, Н. Муравьев, И. Якушкин, М. Лунин, И. Киреевский, В. Кюхельбеккер һәм башкалар иҗаты белән күрсәтелә.

Төп идеяләр:

— Табигый хокук өстенлеге

— Россия өчен хокук строе кирәклеге

— Крепостной хокукны бетерү һәм анда эшләүчеләргә җир бирү

— Кешенең шәхси азатлыгы

— Самодержавиене закон һәм сайлап куелган органнар белән чикләү яки аны республика белән алмаштыру.

3. П.Я. Чаадаевның тарихи фәлсәфәсе

Тарихи фәлсәфә (П.Я. Чаадаев иҗатында чагыла, 1794 – 1856)

Кеше фәлсәфәсе

— Кеше, Чаадаев буенча, материаль рухи субстанцияләрнең кушылмасы

— Кеше тормышы коллективта гына булырга мөмкин

— Туганнан алып үлгәнчегә кадәр коллективта булып (җәмгыятьтә), кеше кеше, шәхес була.

— Коллектив (иҗтимагый) аң тулысынча индивидуаль, субъективны билгели

— Коллективтагы тормыш – кешене хайваннардан аерып торган төп фактор.

— Чаадаев индивидуализм, эгоизм, хосусый, тар файда алу ихтыяҗларын иҗтимагыйга каршы куюга каршы чыга.

Тарих фәлсәфәсе

— Чаадаев буенча, тарихи процесс нигезендә Илаһи Аллаһтан күрү ята. Илаһилык гәүдәләнеше – үзәк булып торган христианлык.

— Россия дөнья тарихи процессыннан «төшеп калды», аның киләчәге – дөнья тарих киңлегенә кайту, Көнбатыш кыйммәтләрен үзләштерү, тик үзенең гасырлар буена яшәп килгән үзенчәлеге аркасында гомумкешелек цивилизация кысаларында тарихи миссиятне үтәү.

— Тарихка, дәүләт һәм халыклар язмышына йогынты ясый алучы иң мөһим факторларның берсе, фәлсәфәче фикеренчә, ул географик фактор.

— Чаадаев исәпләвенчә, үзәк хакимият диктаты, крепостнойлы хокукны барлыкка китергән деспотизмлы самодержавиенең төп сәбәбе – Россиянең чиксез мәйданы.

4. «Көнбатышчылар» һәм славянофиллар фәлсәфәсе

«Көнбатышчылар» вәкилләре – А.И. Герцен, Н.П. Огарев, К.Д. Каверин, В.Г. Белинский заман көнбатыш фәлсәфәсенең фәлсәфи традицияләрен (материализм, эмпиризм) яхшы үзләштерә һәм аларны рус фәлсәфәсенә күчерергә тырышалар.

«Көнбатышчылар»ның төп постулатлары

— Россиянең башка цивилизациядән аерым, «уникаль» тарихи юлы юк. Россия дөнья цивилизациясеннән артта калды һәм үз эчендә бикләнде (консервалап куйды үзен).

— Россия өчен иминлек – Көнбатыш кыйммәтләрен үзләшерергә һәм нормаль цивилизациле ил булырга.

«Славянофиллар» вәкилләре – А.С. Хомяков, И.В. Киреевский, Ю.Ф. Самарин, А.Н. Островский, агайлы-энеле КС. и И.С. Аксаковлар көнбатышчыларның оппонентлары булалар.

«Славянофиллар»ның төп постулатлары

— Россиянең тарихи яшәеш нигезен православие һәм общиналы яшәү рәвеше тәшкил итә.

— Рус халкы үзенең менталитеты белән Көнбатыш халыкларыннан нык аерыла (изгелек, соборлык, тәкъвалык, коллективлык, динсезлеккә каршы ярдәмгә килү, индивидуализм, Көнбатышка конкуренция).

— Теләсә нинди реформалар,рус туфрагына көнбатыш традицияләрен күчерү иртәме – соңмы Россия өчен фаҗига белән тәмамлана.

5. Ортодоксаль-монархия һәм дини фәлсәфә

Ортодоксаль-монархия фәлсәфәсе (декабристлар һәм башка рәсми идеология белән килешмәгән фәлсәфи юнәлешләргә каршы барлыкка килә)

Ортодоксаль-монархия фәлсәфәсендә дини юнәлеш

XIX гасыр уртасында төп лозунг:
«Православие, самодержавие, халыкчанлык».

Максатлары – яшәп килүче иҗтимагый-сәяси һәм әхлакый тәртипне саклап калу, оппозиционфәлсәфәне нейтральләштерү.

«Славянофиллар»ның төп постулатлары

Төп темалар:

— Дөнья бербөтенлеге

— Яшәү һәм үлем проблемасы

— Мораль һәм дөрес (мораль) яшәү рәвеше проблемасы

Үзенчәлекләр

— Федоровка ярашлы дөнья бербөтенлеге. Табигать (әйләнә-тирә дөнья), Аллаһ, кеше бербөтен һәм үзара бәйләнгән, ихтыяр һәм акыл аларны тоташтыручы буын

— Аллаһ, кеше һәм табигать бер-берсенә йогынты ясый, үзара бер-берсен өстиләр һәм даими энергия белән алмашалар, үзенең нигезендә дөнья акылына ия.

— Кеше тормышының «хакыйкать мизгеле» дип Федоров аның ахыры булуын исәпли, ә иң зур явызлык – үлем. Кешелек барлык ызгышларны ташлап, иң мөһим мәсьәлә – үлемне җиңү хакына берләшергә тиеш.

— Фән һәм техника үскән саен, киләчәктә үлемне дә җиңеп булачак, әмма ул үлемне күренеш буларак юкка чыгару юлы аша ирешелми (чөнки бу мөмкин түгел), ә яшәешне яңа ысуллар белән тергезү, җанландыру аша була.

— Федоровча, яңадан терелү мөмкинлеген Иисус Христос бирә.

— Дошманлык, дорфалык, кешеләр арасындагы бәрелешләрдән баш тарту һәм моральнең югары образларын тану. Барлык кешеләрнең мораль тормышы – бар проблемаларны хәл итү һәм бар дөньядагы бәхеткә ирешү.

— Кеше тәртибендә чикле эгоизм да, альтруизм да ярамый. «һәркем белән һәм һәркем өчен» яшәргә кирәк.

К.Н. Леонтьев (1831 – 1891) фәлсәфәсе

Үзенчәлекләр

— Леонтьев фәлсәфәсенең төп юнәлешләренең берсе – рус тормышы күренешләрен тәнкыйтьләү. Аның үзәгендә үсеп килүче капитализм була. Леонтьев фикеренчә, капитализм – «оятсызлык һәм әшәкелек», халыкның юкка чыгу юлы, Россия үлеме.

— Россия өчен исән калу юлы – капитализмнан баш тарту, Көнбатыш Европадан ябылуһәм аны ябык православие-христианлык үзәгенә әйләндерү (Византия кебек).

— Россияне коткаруның төп факторлары булып православиедән тыш самодержавие, общиналык, җитди катлам бүленеше.

— Тарихи процессны Леонтьев кеше тормышы белән чагыштырган. Кеше тормышы кебек үк, һәр халык дәүләт тарихы туа (барлыкка килә), җитлегә һәм сүнә. Әгәр дәүләт үзен-үзе сакларга теләмәсә, ул үлә.

— Дәүләтне саклау нигезе – эчке деспотик берлек. Дәүләтне саклап калу максаты көч куллануны, гаделсезлекне, коллыкны да аклый.

— Кешеләр арасында тигезсезлек – Аллаһ теләге һәм шуңа бу табигый һәм акланган.

6. Ф.М. Достоевский (1821–1881)

Ф.М. Достоевский фәлсәфәсе

Үзенчәлекләр

— Ф.М. Достоевский Россия киләчәген капитализмда да һәм социализмда да күрмәгән, рус «милли туфракка» нигезләүдә – гореф-гадәтләр, традицияләрдә.

— Дәүләт һәм кешенең язмышын хәлиткечнең рольне дин уйнарга тиеш. Кеше рухи дөньясы нәкъ диндә нигезләнә. Ул кешене гөнаһ һәм явызлыктан саклаучы калкан.

— Достоевский фәлсәфи карашларында мөһим рольне (бөтен әдәби иҗаты сугарылган) кеше проблемасы алып тора. Достоевский кеше тормыш юлының ике вариантын бүлеп чыгара – Илаһи кеше һәм Аллаһ-кеше.

Кеше тормыш юлының ике варианты:

— Илаһи кешесе юлы – кешенең абсолют азатлык юлы. Кеше барлык авторитетларны инкарь итә, шул исәптән Аллаһны да, үз мөмкинлекләрен чиксез дип исәпли, ә үзен – барын да эшләргә хокуклы дип исәпли, үзе үк Аллаһ урынына Аллаһ булырга тырыша. Достоевский буенча, әлеге юл һәлакәтле һәм әйләнә-тирәдәгеләргә, шул ук исәптән кешенең үзенә дә хәвефле. Бу юлдан баручы бөлүкичерәчәк.

— Аллаһ-кеше юлы – Аллаһ юлы буенча бару, бар гадәтләр һәм гамәлләрдә аңа таба омтылу. Мондый юлны Достоевский дөрес, хак һәм кешене коткара алырдай юл дип саный.

7. Л.Н. Толстой фәлсәфәсе

Л.Н. Толстой (1828 – 1910), үзенә бер төрле дини-фәлсәфи доктрина – толстовлык тудыра

Толстовлык асылы:

— күп кенә дини догмалар тәнкыйтькә дучар ителергә һәм церемониаль, культ, иерархия буларак атып ташланырга тиеш;

— дин гади һәм халыкка аңлаешлы булырга тиеш;

— Аллаһ, дин – бу яхшылык, мәхәббәт, акыл һәм намус;

— яшәү мәгънәсе – камилләшү;

— Җирдәге төп явызлык – үлем һәм көч куллану;

— нинди дә булса проблемаларны хәл иткәндә көч кулланудан ысул буларак баш тартырга кирәк;

— кеше тәртибе нигезендә явызлыкка сабыр булу ятарга тиеш;

— дәүләт – үлеп баручы институт һәм, ул көч куллану аппараты буларак, яшәргә хокукы юк;

— барысына да теләсә нинди ысуллар белән мөмкин кадәр дәүләткә комачауларга,аны игътибарсыз калдыру – чиновникларга эшкә йөрмәскә, сәяси тормышта катнашмаска һ.б.

8. Революцион-демократик фәлсәфә

XIX гасыр рус фәлсәфәсендә революцион-демократик юнәлеш

Вәкилләре:

— Н.Г. Чернышевский – народниклар – Н.К. Михайловский, М.А. Бакунин, П.Л. Лавров, П.Н. Ткачев;

— анархист П. Кропоткин;

— марксист Г.В. Плеханов.

Барлык вәкилләргә уртак

Әлеге юнәлешләрнең гомуми үзенчәлеге социаль-сәяси юнәлешле булулары. Аталган барлык агымнарның бөтен вәкилләре яшәп килүче иҗтимагый-сәяси һәм икътисади стройны инкарь иткән.

Төрле агымнарның үзенчәлекләре

— Н.Г. Чернышевский килеп туган яшь капитализм кризисыннан чыгу юлын «җиргә кайтуда» (Россиянең аграр иле булу идеясенә), шәхси иреклек һәм тормышның община рәвешенә корылуында күрә.

— Народниклар капитализмны урап узып һәм рус халкының үзенчәлекле булуын исәпкә алып, турыдан-туры социализмга күчү өчен чыгыш ясый. Алар фикеренчә, яшәп килүче стройны бәреп төшерү өчен һәм социализмга күчү өчен бар чараларны да кулланырга мөмкин, шуларның их уңышлысы террор дип саныйлар.

— Анархистлар дәүләтне саклауның әһәмиятен күрмиләр һәм аны (бастыру механизмы) барлык бәлаләрнең чыганагы дип саныйлар.

— Марксистлар Россиянең киләчәген К. Маркс һәм Ф. Энгельс тәгълиматына ярашлы, дәүләт милке өстенлек итүе белән социалистик итеп күрәләр.

9. Либераль фәлсәфә

Либераль юнәлеш

Иң күренекле вәкилләренең берсе ру фәлсәфәчесе В.С. Соловьев (1853 – 1900). Аның фәлсәфәсенең төп идеаллары булып:

— Бар нәрсәнең берлеге идеясе – яшәешнең барлык якларының беләшүе һәм гармо-ниядә булдуы (материаль, рухм һәм башкалар);

— Кеше яшәшенең төп аспекты буларак әхлак идеясе (әхлакның түбән дәрәҗәсе – хокук, югары – мәхәббәт);

— Прогресс идеясе – буыннарның гомуми бәйләнеше буларак

— Барысын да кабаттан терелтү идеясе: тереләрне дә (рухи воскрешение), шулай укүлеләрне дә (тән-рухи), кеше төп максат буларак омтылылрга тиеш.

— Яхшылык гәүдәләнеше буларак алла идеясе;

— «Аллаһ-кеше» идеясе – Аллаһка, яхшылыкка, әхлакка таянуга нигезләнгән шәхеснең тормыш юлы.

— София идеясе – гомуми Илаһи акыл;

— Соловьев буенча, өч идеядән торган рус идеясе: «Изге Русь» (Мәскәү – Өченсе Рим), «Бөек Русь» (Петра I реформалары) һәм «Ирекле Русь» (декабристлар һәм Пушкин рухы).

§59. XIX гасыр рус фәлсәфәсе

1. XIX гасыр ахыры – XX гасырлардагы рус фәлсәфәсенең төп юнәлешләре

XIX гасыр ахыры – XX гасыр рус фәлсәфәсенең төп юнәлешләре:

— «Алтын гасыр» фәлсәфәсе (дини фәлсәфә, космизм)

— Табигый-фәнни фәлсәфә

— Совет фәлсәфәсе

— Чит илдәге рус фәлсәфәсе

Нигез булып торучы үзенчәлекләр

— Совет традицияләренең көчле йогынтысы (мәсәлән, материализм, тарихка карата формацион якын килү);

— Аның төрле юнәлешләренең яңаруы, берләшүе (совет, чит ил һ.б.), догмалардан азат итү, дөнья күләм фәлсәфәгә якынаю

2. XIX гасыр ахыры – XX гасыр рус дини фәлсәфә

Россиянең рухи тормышының XIX гасырның 90нчы еллары – XX гасырның 10нчы елларчоры «Алтын гасыр» дип атала. Бу дәвергә рус әдәбияты, сәнгате, фәлсәфәсенең яңарышы (Ренессансы) туры килә.

С.Н. Булгаков (1871 – 1944) барлык христиан чиркәүләрен бердәм христиан «экуменик» Чиркәүгә берләштерү идеясен тәкъдим итә.

— Җирдәге бар бәлаләрнең сәбәбен фәлсәфәче таркалуда күрә. Җәмгыятьтә – ул икътисади, сәяси, рухи өлкәгә бүленү һәм аларның эчендәге бүленешләр.

— Туган хәлдән чыгу юлын Булгаков барысын да бердәм, абсолют һәм чиксез көчле Аллаһ белән һәм бердәм христиан Чиркәүгә берләштерүдә күрә.

— Булгаков кешенең язмышы Илаһи алдан билгеләнүе һәм кешенең үлеменнән соң Аллаһ алдында җавап тотасы идеясе яклы.

Дин юнәлешенең күренекле вәкиле фәлсәфәче һәм рухани П.А. Флоренский була (1882 – вафат булу көне бәхәсле – 1937 яки 1943, Соловкида төрмәсендә вафат була).

— Флоренский дөньяны бер-берсенә бәйләнгән бербөтен итеп күзаллый. Бербөтен дөнья каршылыклардан тукылган. Мәсәлән, тәртипсез, буталчык һәм мантыйклы дөнья, Аллаһның берлеге һәм ныклыгы һ.б.

— Белем акылга турыдан-туры ачыла.

— Флоренский киләчәктә яңа техник ачышлар ярдәмендә материя һәм рухүзара бәйләнеше, вакыт һәм киңлекнең чагыштырмачалыгы, тотрыксыз булуына яңача аңлатма табылачак дигән идея тәкъдим итә. Флоренский идеясе кван механикасы өлкәсендәге ачышлар, Эйнштейнның чагыштырмалылык теориясе һ.б. физика-математика ачышларына бәйлерасланды.

3. Космизм фәлсәфәсе

Космизм – космосны, әйләнә-тирәне (табигатьне) кешене үзара бәйләнгән бербөтен итеп караган фәлсәфә юнәлеш. Юнәлешнең иң күренекле вәкилләре– Н.В. Бугаев, В.И. Вернадский, К.Э. Циолковский, А.Л. Чижевский.

А.Л. Чижевскийның фәлсәфи системасы

Төп положениеләр

— Җирдәге тормыш үсеше (биосфераның) эчке сәбәпләре буенча гына түгел, бер үк вакытта космосның көчле йогынтысы астында була.

— Җирдәге барган процессларда, биосфера тормышында төп ролне,Чижевский буенча, Кояш уйный. Кояш активлыгы хайваннар хәленә, су күтәрелү һәм су кимүгә, социаль катаклизмнарга сугыш, инкыйлабларга йогынтыясый.

— Чижевский үзенең идеяләрен фән теле белән түгел, ә шигырь, әдәби әсәрләр белән ирештергән.

— Чижевский фәлсәфәсе Көнбатышта үзенчәлекле, оригиналь, әмма фәнни туфрагы булган дип табыла.

Н.В. Бугаевның фәлсәфи системасы

Төп положениеләр

— Бөтен космос чиксез күп рухи берәмлекләрдән монадлардан тора.

— Монадлар үзендә энергия, белем, «үткәннәр истәлеген» туплый.

— Космик монадларның яшәеше һәм үзара бәйләнеше аркасында җир-дәге һәм галәмцивилизациясе булуы мөмкин.

К.Э. Циолковскийның мәңгелек идеясе

Теория асылы

— Материя нигезендә кечкенә кисәкчекләр – атомнар тора. Атомнар, төрле формага кереп, материаль җисемнәрнең төрлелеген хасил итә.

— Әйбер, җисем таркалганда бөтенләй югалмый – ул атомнарга бүленә, алардан яңа әйберләр һәм җисемнәр барлыкка килә. Галәмдә атомнар әйләнеше яши, ә материя, даими рәвештә формасын үзгәртеп, саклана.

— Циолковский фән һәм техника мөмкинлекләренә, кешенең галәмне яулавын һәм киләчәктә планета ара цивилизацияләр белән аралашуга ышана.

В.И. Вернадскийның Ноосфера теориясе

Теория асылы

— Кеше эволюциясе нәтиҗәсендә аның әйләнә-тирә табигатькә эшчәнлеге үзгәрүе көчәя. Кеше тормышы, акылы аның материаль һәм рухи культурасы нигезендә ноосфера барлыкка килә.

— Ноосфера даими рәвештә киңәя һәм яшәешнең башка өлкәләрен үз эченә ала бара. Биосфера (тормыш мохите) даими, әмма эзлекле рәвештә ноосферага күчә.

— Киләчәктә ноосфера Җирдә әйдәүчегә әйләнәчәк һәм космоска күчәчәк.

4. Табигый-фәнни фәлсәфә

Табигый-фәнни фәлсәфә табигый фәннәр белгечләре-галимнар ижатында чагыла.

Материалистик юнәлеш вәкилләре
(Сеченов, Менделеев, Тимирязев)

Үзенчәлекләр

— Яшәешне табигый фәннәр – биология, химия, физика, медицина күзлегеннән карап эш иткәннәр.

— Дөньяның атомнарга корылуы дәлилләнә, атомның катлаулы төзелеше һәм атомның эчке төзелешеннән һәм атомнар конфигурациясеннән чыгып әйбернең төрлелеге.

— Табигый фәннәр белгечләре-фәлсәфәчеләр танып белү мөмкинлеге ихтималлыгын фарызлый, аның механизмын өйрәнә, аңны материалистик аңлау яклы була.

Социаль-сәяси юнәлеш, иң мөһиме, Мечников һәм Ковалевский ижатларында күрсәтелә.

Үзенчәлекләр

— Әлеге галимнар җәмгыятьне күп факторлы табигатьле булган бер бөтен итеп карый.

— Җәмгыятькә йогынты ясаучы факторларны өйрәнләр (географик, климат, икътисади һ.б.).

— Җәмгыять үсеше, алар фикеренчә, объектив законнар буенча бара.

5. Совет фәлсәфәсе

XX гасырның 20нче елларыннан башлап һәм XX гасырның 90нчы елларына кадәр рәсми рус фәлсәфәсе (СССРның башка халыклар фәлсәфәсе кебек үк) совет фәлсәфәсе буларак үсә.

Үзенчәлекләр

— Материалистик характерда булып, марксистик фәлсәфә кысаларында үсә (диалектик һәм тарихи материализм), бу аны берникадәр догматик ясый

— Совет фәлсәфәсенә В.И. Ленин ижаты зур йогынты ясый. Ленин марксистик-материалистик тәгълиматны үстерегә һәм аны Россия шартларына яраклаштырырга тырыша.

Совет фәлсәфәсе үсешенедә өч этап

— 1917–30нчы еллар рәсми марксизм-ленинизмның көчле йогынтысы барышында бәхәсләр дәвам ителү вакыты.

— 30–50нчы еллар – фәлсәфәнең тулысынча идеологияләнү чоры. Совет фәлсәфәсе рәсми хакимиятның хезмәтчесенә әйләнә; И.В. Сталин карашлары шактый фәлсәфи мәсьәләләргә көчле, йогынты.

— 50–80нче еллар – совет фәлсәфәсенең мөстәкыйльлеге яңара.

Совет фәлсәфәсендә якты эз калдыручы күренекле исемнәр:

— Н.И. Бухарин (аң, психика проблемалары.

— А.А. Богданов (система теориясе – «тектология»).

— А.Ф. Лосев (кеше, тарих проблемалары).

— А.М. Деборин (материализмны ижади аңлау).

— Л.Н. Гумилев (тарих, этногенез мәсьәләләре).

— М.К. Мамардашвили (кеше, мораль, әхлак проблемалары).

— В.Ф. Асмус (киң тикшеренүләр тезмәсе).
— Ю.М. Лотман (җәмгыять, фәлсәфә, тарих).

60–80 елларда совет фәлсәфәсенең шөгыльләнгән төп юнәлешләре

— Кыйммәтләр проблемасы;

— Марксизм-ленинизмны яңача аңлату проблемасы, «чын маркска», «чын ленинга»кайту;

— Гносеология проблемасы;

— Аң проблемасы;

— Идеальлелек проблемасы;

— Мәдәният проблемасы;

— Фәлсәфи ысуллар проблемасы.

6. «Рус чит ил» фәлсәфәсе

«Рус чит ил» фәлсәфәсе – эмиграциядә, төрле чит ил дәүләтләрендә барлыкка килгән, аерым бер төр фәлсәфи юнәлеш

П.С. Мержковский фәлсәфәсе(1864-1941)

— кеше һәм Аллаһның үзара мөнәсәбәт проблемасын эшкәртә.

— Мережковскийның кеше һәм җәмгыять идеаллары – христианлык, гармонияле изге күңелле шәхес.

Мережковский буенча, кеше шәхесе үз гомерендә өч этап үтә:

— мәҗүси;

— христианлык белән танышу;

— кешенең эчке тулы гармониясе, аның христианлылык белән кушылуы.

Л. Шестов фәлсәфәсе (1866-1938)

— Экзистенциализмга якын, төп темасы – кеше, аның тормышы, гамәлләре, хокуклары.

— Шестовка ярашлы, кеше һәм кеше тормышы уникаль (кабатланмас)

— Кеше тормышы тышкы хәлләргә бәйле түгел.

— Кеше үз хокуклары һәм ихтыяҗларын актив рәвештә тормышка ашырырга хокуклы.

— «Герой» ачыктан-ачык үзен җәмгыятькә каршы куя ала.

Питирим Сорокин (1889 – 1968)

Нигез булып торучы төшенчәләр

— Стратификация – җәмгыятьнең күпләгән социаль төркемнәргә бүленеше (керем дәрәҗәсе, һөнәр, милләт һ.б.) – стратлар.

— Халыкның социаль мобильлеге – бер стратадан икенчесенә күчү мөмкинлеге

Үзенчәлекләр

— Сорокин үз фәлсәфәсенең төп темасы итеп кеше һәм җәмгыять проблемасын итеп куя.

— Тарих – кыйммәтләр алышынуы процессы.

— Фәлсәфәче фикеренчә, кешелек өчен әлеге чорда рухсызлык, фән һәм техниканың чиксез үсеше зур хәвеф тудыра.

Н.А. Бердяев (1874 – 1948) фәлсәфәсе

Төп положениеләр

— Әйләнә-тирә дөньяда иң югары кыйммәт – азатлык;

— Азатлык, «соборлылык» (рух һәм ихтыяр бердәмлеге) кеше яшәешенең нигезен тәшкил итә;

— Кеше азатлыгына тыштан килгән хәвеф яный;

— Әлеге хәвеф иң элек гомуми ихтыяр һәм басу механизмы булган җәмгыять һәм дәүләттән килә; җәмгыять һәм дәүләт кешене буйсындырырга тырыша, аның индивидуальлеген баса; кеше бурычы – үзенчәлеген саклап калу, җәмгыять белән дәүләткә үзен ассимиляштерергә бирмәү;

— Кеше тормышында төп рольне дин дә уйный.

— Аллаһ әхлак символы, кешегә үрнәк булырга тиеш;

— Аллаһ һәм кеше арасындагы мөнәсәбәтләр «тигез» булырга тиеш; Аллаһ – хуҗа ролендә, кеше – аның колы ролендә булырга тиеш түгел;

— Кеше Аллаһка омтылырга тиеш, әмма үзен Аллаһ белән алыштырырмаска.

Үзенчәлекләр

— Бердяев буенча, СССРда төзелүче социализм (коммунизм) рус милли характердан чыга (бердәмлек, үзара булышучанлык, тигезлеккә омтылу, гаделлек, коллективлык).

— Россия Көнчыгышның да, Көнбатышның да ягын кабул итәргә тиеш түгел. Ул алар арасында арадашчы булып үзенең тарихи миссиясен башкара.

— Россиянең тарихи миссиясе – Җирдә – «Аллаһ Патшалыгы» төзү (ягъни үзара мәхәббәткә һәм шәфкатькә корылган җәмгыять)

— Бердяевның фәлсәфәсе эсхатологик юнәлешкә ия (киләчәктә «ахырзаман»ны ни гезли).

Бишенче бүлек. Хәзерге Көнбатыш фәлсәфәсе

§60. Америка прагматизмы. Джон Дьюи фәлсәфәсе новаторлыгы

1. Дж. Дьюиның Америка прагматизмының гомуми төшенчәсе, аның Америка фәлсәфәсендәге роле һәм урыны.

Прагматизм – идеалистик фәлсәфә юнәлеше, аның төп максаты – фәлсәфи сорауларны өйрәнгәндә абстракт хакыйкатьне табу түгел, ә кешеләргә гамәлдә аларның конкрет тормыш мәсьәләләрен хәл итәргә ярдәм итүче конкрет чаралар табу («проблемалы ситуацияләрне хәл итү»).

Прагматизмга нигез салучылар: Америка фәлсәфәчеләре Ч. Пирс һәмУ. Джемс исәпләнелә.

Джон Дьюи (1859–1952) киләчәктә прагматикларның тәгълиматларын үстерүгә, хәзерге прагматизмның аякка басуын һәм үсешенә зур өлеш кертә.

Дж. Дьюиның Америка фәлсәфәсендәге роле һәм урыны

— Дьюи – 30 дан артык китап һәм 90нан артык фәлсәфә, социология, педагогика һәм башка фәннәр буенча фәнни мәкаләләр авторы.

— Аның фәлсәфәсе СССРда һәм Европада киң таралу алмый, әмма АКШта һәм башка инглиз телле илләрдә популяр була.

— Дьюи казанышларына традицион фәлсәфә стереотипларын җимерүне (фәлсәфи фундаментализмны) һәм мөһим фәлсәфи проблемаларга новаторларча каравын кертәләр.

2. Дж. Дьюи эмпиризмы (тәҗрибә-фәлсәфәнең төп төшенчәсе)

Фәлсәфи юнәлеше буенча Д. Дьюи эмпирист була, ягъни үз тикшеренүләрендәтәҗрибәгә мөһим роль бирә. Атап әйткәндә, Д. Дьюи

— Беренчел этәргеч идеясен инкарь итә, барлык асылның беренчел сәбәпне эзләнүдә дип таба;

— Фәлсәфәдә үзәк төшенчәсе дип тәҗрибә төшенчәсе дигән фикер тәкъдим итә, барлык фәлсәфи тикшеренүләрне дә аның тирәсендә төзергә кирәк дип исәпли.

— Тәҗрибә дип кеше аңында булган тумыштан яки тормыш эчендә тупланган һәр нәрсәне аңлый;

— Кеше аңына тәҗрибә иясенә буларак төп рольне бүлә;

— Тәҗрибә тормышның барлык өлкәләрен дә үз эченә ала дигәнне күз уңында тотып, тәҗрибәне хисси, чамадан тыш хисси (спиритик, рухи), дини, мораль, шулай ук әдәби, социаль, мәдәни һәм бакшкага бүлә.

3. Прагматизм фәлсәфәсе һәм фәлсәфи системасы максаты

Фәлсәфә максаты (Дьюи, Джемс һ.б.лар буенча) – кешегә тәҗрибә агымында куелган максатка таба бару юнәлешендә һәм аңа ирешүдә ярдәм итү. Әлеге идея Америка прагматизм фәлсәфәсе нигезендә ята.

Үзенчәлекләр

— Америка прагматиклары (Джемс) тәҗрибә фәлсәфә белән тыгыз элемтәдә хакыйкатьне табарга ярдәм итә дип исәпләгәннәр, ул яңа тәҗрибә алуга китерә һәм алгатаба максатка ирешүгә илтә (ягъни тәҗрибә чылбыры эчендә тәҗрибә һәм куелган максат арасында бәйләүче буын булып тора)

— Дьюи әлеге идеяне новаторларча үстерә һәм фәлсәфә бурычларына аныклык кертә.

4. Тәжрибәне камилләштерү юллары. Социаль яңартып төзү идеясе

Дьюига ярашлы фәлсәфәнең төп бурычы тәжрибәне дөрес кулланып, берничә максатка ирешү дигән сүз генә түгел, ә фәлсәфә аша тәжрибәне үзен үзгәртү, аны кеше тормышының бар өлкәләрендә дә даими камилләштерүдән гыйбарәт.

Социаль яңартып төзү үз эченә түбәндәгеләрне кертә:

— Милек мөнәсәбәтләрен камилләштерү, бу мөмкин кадәр күбрәк кешеләргә милектән өлеш чыгару, бер яктан, милекчеләр арасында милекне ваклап бирү. Икенче яктан, милекне җитештерү-хуҗалык максатларында максималь берләштерү (милекне акционләштерү турында сүз бара);

Үзенчәлекләр

— Дьюи кешелек дөньясының тормышның барлык өлкәләрендә дә югары нәтиҗәләргә ирешүенә игътибар итә(аеруча фән һәм техникада – ягъни җитештерү өлкәсенә яңа фәнни методлар, югары технологияләр кертүгә бәйле фәнни-техник революция ясады)

— Шул ук вакытта фәнни методлар да, югары технологияләр дә җәмгыять, әхлак, тәжрибә белән идарә итүдә бөтенләй кулланылмый.

— Димәк, тәжрибәне фәнни метод һәм югары технологияләрне файдаланып үзгәртеп була, әйтергә кирәк, бу фәнни метод һәм технологияләрне иң элек мәгарифкә кертергә кирәк (башлангыч, урта, югары) һәм мәгариф аша.

Аңны камилләштерү (шулай ук фәнни методлар нигезендә).

Социаль яңартып төзү

— Милек мөнәсәбәтләрен камилләштерү, ул мөмкин кадәр кешеләргә милектән өлеш бүлеп бирү, милекчеләр арасында милекне ваклап бүлеп бирү, һәм аны җитештерү хуҗалык максатларында максималь берләштерү (милекне акцияләштерү турында сүз бара);

— Акционләштерү һәм милек мөнәсәбәтләренең башкача камилләштерү – кешене үз хезмәте нәтиҗәләренә якынайту, хезмәт нәтиҗәләренең бер өлешен үзләштерүче паразитар катламны киметү (эре ялгыз милекчеләр, эш бирүчеләр, монополистлар һ.б.);

— Матди җитештерү байлыкларын гаделрәк бүлү;

— Ярлылык белән көрәш, дәүләтнең даими рәвештә гражданнарның мул тормышын яхшырту турында хәстәрлек күрү;

— Кеше хокукларын тәэмин итү һәм демократик дәүләт корылышын камилләштерү;

— Җәмгыятьтә тәртип урнаштыру, кеше тормышының барлык өлкәләре һәм эшчәнлеге белән идарә итүне камилләштерү;

— Эчке һәм халыкара конфликтларны йомшарту.

5. Дж. Дьюиның фәнни метод турындагы тәгълиматы

Төп положениеләр

— Ысул – кеше тәжрибәсе барышында белем алу һәм алынган белемне куллану тәртибе (процесс);

— Фәннең һәм фәнни методның төп бурычы –кешенең үз максатларына оптималь ирешү;

— Фәнни ысул никадәр максатларга ирешүдә ярдәмләшүдән аның хак булуы тора; ягъни максатка ирешү барышында кулланылган метод, – хакыйкый (дөрес);ә максатка илтмәгән метод, яки аңа ирешүне катлауландырган метод, – ялган;

— Димәк, фәнни метод кешенең уңышлы эшчәнлеге өчен, максатларга ирешү коралы булып тора.

Максатка ирешү чарасы буларак кулланылган метод **инструментализм дип атала.**

Дьюди инструментализм һәм диалектика идеяләреннән ясаган нәтиҗәләр

— «Гомумән методлар» булуы мөмкин түгел (я практик нәтиҗәгә юнәлтелмәгән методлар игътибарга лаек түгел);

— Конкрет максатларга ирешү өчен конкрет методлар яши;

— Димәк, методның конкрет эшләү тәртибен ачыкларга кирәк.

Методның конкрет механизмын эзләү өчен Д. Дьюи проблемалы ситуация һәм аны хәлитү юллары турындагы тәгълиматны тәкъдим итә

Тәгълимат асылы

— Методка ихтыяҗ (тәжрибә буларак) киләчәк хәрәкәтләргә комачаулаучы актуаль шикләнү булганда барлыкка килә;

— Әлеге актуаль шикләнү «проблемалы ситуацияне» тудыра – конкрет (теләсә нинди) тормыш ситуациясен, аларны конкрет адымнар ярдәмендә хәл итәргә кирәк;

— Проблемалы ситуацияне хәл итү еш кына альтернативалар сайлауга бәйле (карарларда һәм гамәлләрдә;

— Фәнни метод максаты – проблемалы ситуацияне хәл ителгән ситуациягә әйләндерү;

— Фәнни метод проблемалы ситуацияне хәл итү барышындагы процесс вакытында гамәлгә ашырыла;

— Димәк, фәнни метод (аның конкрет гамәлне гәүдәләндерүендә) проблемалы ситуацияне хәл ителгән ситуациягә әйләндергән вакыттагы адымнар ул.

Конкрет адымнар

— Кыенлыклар, каршылыкларга очрау тойгысы (гадәттә шомлы, аңлатып булмый торган) – әлеге очракта кирәк: бу шомның чыганагын ачыклау; проблемага төшенү; проблема нидән гыйбарәт булуын ачык билгеләү;

— Булган проблема анык итеп билгеләнгәч, билгесез ситуация проблемалыга әверелә; бу этапта: ахыргы максатны анык куярга; мөмкин булган кыенлыкларны аңлап-төшенү кирәк;

— Гипотеза тәкъдим итү (эш-хәрәкәтләрнең эзмә-эзлеклеген хәл итү), бу проблеманы хәл итүгә, проблемалы ситуацияне юкка чыгаруга китерәчәк;

— Гипотезага тәнкыйди анализ; куелган максатны хәл итүнең һәр этабында гипотеза гамәлләрен теоретик модельләштерү (тәжрибәгә нигезләнгән алдан күзаллау);

— Ахыргы карарны кабул итү, модельләштерелгән гипотезаны тормышка ашыру, проблемалы ситуацияне хәл итү, кулланылган гипотезаны тәжрибә ярдәмендә дөреслеген (нәтиҗәгә ирешкән очракта) яки ялган булуын (нәтиҗәгә ирешә алмаганда) тикшереп карау.

Д. Дьюиның фәнни методка туры килгән белемнәре

— үзлегеннән төзәтү мөмкинлеге (яңа алынган тәҗрибәдән чыгып, уңайдан да,тискәредән дә);

— хәрәкәт итү сәләте (кулланылган фәнни метод әйләнә-тирә чынбарлыкны гына чагылдырырга тиеш түгел, теләсә нинди хәлдә хәрәкәт итергә тиеш);

— дөреслек (максатка китергән методлар гына дөрес һәм киләчәктә куллануга лаеклы).

6. Дж. Дьюи гносеологиясе.

Танып белүдәге идеализм һәм материализм проблемасы

Танып белүнең югары төре – саф идеяләрне күзәтү – азларга гына мөмкин, әмма, «саф идеяләр» тотрыклы, даими һәм универсаль булганга, алар теория һәм практика белән (тәҗрибә белән) тикшерелгән дөрес белем бирә – «эпистима».

Турыдан-туры, хисси танып белү барысына да хас, әмма әйләнә-тирә дөнья үзгәреп торучан һәм тотрыксыз булганга күрә, «докса» бирә– дөрес булмаган белем (фаразлар, фикерләү) чын белем дәрәҗәсенә менеп җитә алмаган кешеләр.

Югары рухи эшчәнлек (саф идеяләрне күзәтү аша рухи танып белү), бик белемле һәм физик эш белән шөгыльләнмәгәннәргә махсус әзерлекле кешеләргә хас.

Хисси белем физик эш белән шөгыльләнүче, гадәттә, белеме булмаган кешеләргә – эшчеләр, крестьяннар, сәүдәгәрләргә һ.б. хас.

Кешеләрнең тарихи хезмәте түбән физик эшчәнлек һәм югары рухига бүленүгә бәйле булуга нигезләнеп, ике төрле дөньяга караш (һәм танып белү) яшәп килә.

Материалистик

Идеологик

Үзенчәлекләр

— Материализм һәм идеализм арасындагы бәхәс (дөньяга караш, танып белү ысулы белән) хезмәтнең тупас физик эшчәнлек һәм югары рухига бүленгән вакытта актуаль булган һәм яшәгән;

— Физик һәм акыл хезмәте арасындагы кырлар югала барган саен, алар якынайган саен материализм һәм идеализм арасындагы конфликт кими бара, аралар шомара;

— Киләчәктә, Дьюи буенча, акыл хезмәте физик эш белән кушылган чакта, аларның чикләре югалачак, материализм һәм идеализм арасындагы конфликт та юкка чыгачак.

— Нәкъ акыл хезмәте җиңеп чыкканга, физик эшне йотканга күрә (ә киресенчә түгел)һәм ахыр чиктә җиңүгә ирешкәнгә, идеализм материализмны ахыргача җиңәчәк һәм төп дөньяга караш һәм танып белү ысулына әйләнәчәк;

— Әлегә атап әйтелгән процесс булмады,шуңа да идеалистик та һәм материалистик та танып белү ысулларын кулланырга кирәк, тик югары акыл эшчәнлеге тора-бара тупас физик хезмәтне кысрыклап чыгарганга күрә, ике төр танып белү ысулын кулланып (идеалистик һәм материалистик), идеалистикка авышырга кирәк.

Дж. Дьюи фәнни метод теориясе һәм проблемалы ситуация турындагы тәгълиматнытөзегәндә ясаган ачыш

— Дөрес белем һәм фәнни методны дөрес куллану проблемалы ситуацияне хәл ителгәнгә әйләндергәнгә күрә, бу яңа ситуация бөтенләй башка сыйфатка ия була;

— Димәк, танып белү танып белү объектының сыйфат ягыннан үзгәрүенә китерә, танып белү предметының гомумән булмышын үзгәртә.

7. Дж. Дьюиның социаль фәлсәфәсе. Әхлак проблемасы

Дж. Дьюи иҗатында социаль фәлсәфә һәм әхлак проблемасының төп мизгелләре:

— кешелек дөньясы омтылырга тиешле бердәнбер «югары байлык-игелекләр» юк;

— максат һәм байлыклар плюрализмы бар;

— максат һәм байлыклар абстракт була алмый, алар конкрет;

— төп байлык-игелекләр – сәламәтлек, байлык, намус, яхшы исем, дуслык, җәмгыять ягыннан югары бәя, укымышлылык, гаделлек, уртачалык, киң күңеллелек;

— кешеләрнең күбесе әйтелгән игелекләргә омтыла, өстәвенә гомумән игелекләргә түгел, ә аларның конкрет үлчәменә;

— теләсә кайсы игелеккә ирешү ул тәжрибә үзгәрүе сыйфатында була;

— димәк, барлык очракта да үсеш үзе төп әхлакый максат була;

— әхлакый дини кануннар (үтермә, урлама һ.б.) абсолют характерга ия түгел (мәсәлән, сугышта дошманга карата) һәм конкрет аерым бер очракта гадел (яки гадел түгел);

— демократия кешелек гомум яшәешенең оптималь формасы булып тора;

— «максат чараларны аклый» лозунгы үзенең асылы белән дөрес түгел һәм кире кагылырга тиеш;

— максатлар чараларга тәңгәл килергә тиеш, ә чаралар – максатларга; начар чараларкуллану мотлак рәвештә максатның сыйфат ягыннан үзгәрүенә китерәчәк (максатлар чараларга тәңгәлләшүгә китереләчәк);

— демократия көчләү, сугышлардан баш тартырга һәм тынычлык чараларын гына кулланырга тиеш (бу барлык кешелеккә дә кагыла);

— җәмгыять социаль каршылыкларны, социаль төзеп коруларны тигезләүгә мохтаҗ;

— социаль төзеп коруларның төп этәргече – фәнни методлар һәм мәгариф һәм әхлакта югары технологияләр куллану.

§61. Психоанализ

1. Психоанализга гомуми төшенчә

Психоанализ – аңсыз эшләнгәннең ролен, кеше һәм җәмгыять тормышындагы башка психик процессларны аңлатучы хәзерге фәлсәфә юнәлеше.

Психоанализга нигез салучы австрия галиме – психиатр Зигмунд Фрейд (1856–1939) исәпләнә. .

Фрейдның төп ачышлары:

Аңсыз эшләнелгән – һәр кешегә хас булган махсус үзгә психик чынбарлык, аң белән янәш бара һәм күпчелек дәрәҗәдә аңны контрольдә тота

Аңсыз эшләнгәннең аерым бер яшәеш формасы – төшләр. Фрейд буенча, төшләр – бу кешенең яшерен омтылышларын тормышка ашыру, реаль чынбарлыкта тормышка ашырылмаганнар белән бәйле.

Этәреп чыгару реакциясе (аңлыдан аңсыз эшләнгәнгә) тискәре тойгылар, тискәре тәҗрибә, ягъни психик саклану ысулы буларак, тигезлек һәм психик сәламәтлекне бозучы барлык нәрсә.

Тискәре тойгылар, тормышка ашмаган теләкләр – аңсыз эшләнгәнгә этеп чыгарылган барлык нәрсә, «очраклы», «тиз, эчке сәбәпләр аркасында туган» хәрәкәт, гамәлләр, ялгыш сүз, язудагы хата, «мәзәкләкләр» рәвешендә иртәме, соңмы үзен сиздерә.

2. Фрейд тәкъдим иткән психиканың топографик һәм динамик схемалары

Психиканың топографик схемасы

Үзенчәлекләр

— Аңсыз эшләнгәннәр үзе белән зур коридорны хәтерләтә, биредә кешенең төрле уйлары, теләкләре, тойгылары үз сәгатен көтеп тора.

— Аң – зур булмаган кабинет, бирегә даими рәвештә килүчеләр «чакырыла»: кешенең уйлары һәм теләкләре.

— Алгы бүлмә һәм бүлмә арасында сакчы тора, ул аңга бары тик аңа яраклы уйларны гына кертә.

— Кайвакыт сакчы китә, йоклый, һәм «яраксыз килүчеләр» кабинетка – аңга үтеп керә ала.

— Әмма соңыннан алар кабат йокыдан уянучы сакчы тарафыннан алгы бүлмәгә чыгарыла.

Психиканың динамик схемасы

Психика өч катлам буларак тәкъдим ителә – Ул (Оно), Мин, Чиктән тыш – Мин

— «Ул» – аңсыз эшләнелгән дөньясы, биредә кешенең уйлары һәм теләкләре соклана.

— «Мин» – кеше аңы, психиканың бар компонетлары арасындагы арадашчы.

— «Чиктән тыш-Мин» – шәхескә басым һәм йогынты ясаучы тышкы чынбарлык,

— «Тышкы цензура»: законнар, тыюлар, әхлак, мәдәни традицияләр.

Үзенчәлекләр

— «Мин» үзенә «Ул»ны буйсындырырга тырыша. Моны бик сирәк эшләп була. Гадәттә, «Ул» яшерен яки ачык формада «мин»не үзенә буйсындыра.

— Фрейд «Мин»не җайдак һәм ат белән чагыштыра: җайдак («Мин») беренче карашка атны контрольдә тота, аңа әмерләр бирә, тик ат («Ул») – җайдактан көчлерәк һәм чынбарлыкта җайдакны үзендә алып бара. Кайчак җайдак бөтенләй контрольне югалта һәм ат белән бергә чабарга, ул кайда алып бара, шунда барырга мәҗбүр була.

— Шулай ук «Чамадан тыш-Мин» – нормалар һәм тыюлар – еш кына «Мин»не буйсындыра.

Кеше «Мин»е (Фрейд буенча – «бәхетсез кеше Мине») өч яктан көчле басым тоя:

— аңсыз эшләнгәннәр («Ул»);

— тышкы дөнья;

— нормалар, тыюлар («Чиктән тыш – Мин»).

3. Психиканың төп нигез факторлары

Кешенең психикасы белән идарә итүче һәм юнәлтүче төп факторлар

— Рәхәтлек – психика компаска охшаган, ничек тә булса рәхәтлек юлларын эзли;

— Кысрыклау – психика тыю салынган теләк һәм идеяләрне (җәмгыятькә каршыларны, сексуаль) аңсыз эшләнгәннәргә кысрыклап чыгара.

Аңсыз эшләнелгәннәргә этеп чыгарылган, «цензура»ны үтмәгән теләкләр, фикерләр сублимациягә дучар була – башка «рөхсәт ителгән» социаль эшчәнлек һәм мәдәни иҗат төрләренә әйләндерелә.

4. Фрейдның беренче һәм икенче психологик системалары

Беренче психологик системага ярашлы, аңсыз эшләнгәннәр нигезендә «либидо» ята –сексуаль омтылыш, сексуаль инстинкт

Либидо үзен түбәндәгеләрдә эзли:

— Сексуаль гамәлләрдә;

— Тормышның башка өлкәләрендә сексуаль энергиянең сублимация (үзгәрешләр) аша сексуаль булмаганга.

Сексуаль импульс өч төрле тормышка ашырыла ала:

— Турыдан-туры ясалган хәрәкәт аша (сексуаль, йә сексуаль булмаган) «иреккә чыгарыла»;

— Аңсыз эшләнгәннәргә этеп чыгарыла;

— Боеккан, реактив төшенчәләр аша (оят, әхлак) энергиядән ваз чиктерелә.

Кешенең психик эшчәнлеге ул аның сексуаль инстинкт үзгәреш процессы. Әлеге теория Европада ризасызлык тудыра.

XX гасырның 20нче елларында Фрейд икенче психологик система уйлап чыгара, биредә ул аңсыз башкарылганнарның энергиясе барлыкка килү проблемасына яңача карый.

Үзәк төшенчәләр һәм системаның асылы:

— Кешенең конструктив тәртибе, тудыру нигезендә Эрос (тормыш инстинкты) ята. Аңа бәйле кеше үзенең ихтыяҗларын тәэмин итә һәм нәселен дәвам итә.

— Танатос (үлем инстинкты) кешене деструктив эшчәнлеккә этәрә, аңа «ят» һәм хәвефле тоелганнарның җимерә.

— Кеше тормышы – Эрос һәм Танатосның даими үзара бәйләнеше.

5. Кеше мөнәсәбәтләре, кеше массалары, мәдәният проблемалары

Фрейд кеше мөнәсәбәтләренә, кеше массалары, мәдәният мәсьәләләренә аерым игътибар бүлә.

Үзенчәлекләр:

— Кешелек җәмгыяте бары тик аңсыз башкарылган гадәтләр, теләк-омтылышлар, дәртне үзара бастыру шарты булганда гына яши ала, югыйсә җәмгыять эчтән җимереләчәк.

— Бастырылган энергияне массакүләм сублимацияләү һәм аның мәдәнияткә әйләнүе бара.

— Җәмгыять бастырылган энергиянең алмаштыргычын ритуалларны тудыра.

— Ритуал – коллектив аңсыз башкарылганнар – этеп чыгарылган теләкләрне тормышка ашыру формасы. Ритуаллар шактый күп – дин, әхлак, сәнгать, шигърият, музыка, тамаша, массакүләм чаралар.

Фрейд ясаган нәтиҗәләр:

— Цивилизация үскән саен кеше дәрте ныграк бастырыла бара.

— Бу массакүләм психозга, гомум халыкдепрессиясенә (төшенкелеккә) китерә;

— Һәм тагы да катлаулырак, үткен ритуаллар төзү кирәклегенә китерә.

6. Масса (халык төркеме) феномены

Халык төркеме (масса) феномены Феномен асылы:

— Бастырылган теләкле шактый кеше массага, төркемгә оеша һәм үз энергиясен лидерга (җитәкчегә) юнәлдерә. Төркемнең һәр әгъзасын, тулаем массаны, төркем лидерын тиңләштерү процессы бара.

— Төркемнең (халыкның) һәр әгъзасы автоматик рәвештә үзенә лидер (башлык) сыйфатларын, ә башлык (лидер) үзенә масса сыйфатын күчереп ала.

— Кешеләрнең массага берләшүе, лидер белән тиңләштерелүе «аңсыз» халык өерендә кыйммәтләр, көч (төркемгә һәм лидерга бәйле булу аркасында), хәвефсезлекнең үзен юкка чыгаруга булышлык итә.

— Халык өере агрессив, җиңел кабызып җибәрелүчән, кискен, аяусыз.

— Халык төркеме лидерының ролен бары тик ачык психик аномалияле, үзенең үзенчәлекле булуына үзе дә ышанган һәм үзе артыннан халыкны алыпбарырга сәләтле шәхес кенә башкарып чыга ала.

7. Неофрейдизмның төп юнәлешләре

Фрейд тәгълиматы нигезендә аның дәвамчылары – Альфред Адлер, Вильгельм Райх, Густав Юнг, Эрих Фромм неофрейдизм фәлсәфи агымына нигез салалар.

Г. Маркузе (1898 1979) теориясе (маркузианлык)

Теория асылы

— Маркузеның төп әсәре – «Одномерный Человек» («Бер үлчәмле Кеше»). Аның асылы заман «бер үлчәмле җәмгыять»нең нормаль, әмма «бер үлчәмле», тик бер юнәлештә-кулланукысаларында гына теләк, кызыксынулар, мавыгуларга ия булган кеше тәрбияләүдә.

— Кулланучы – кеше тора-бара «шөреп»кә, җәмгыятькә бәйлегә әйләнә, шәхес буларак вакланa, үзенең табигый теләкләрен баса, ягъни үзен-үзе баса.

— Әлеге хәлдән чыгуны, бер үлчәмле җәмгыятьне «ерып чыгуны» Маркузе тулысынча сексуаль азатлыкта һәм иркенлектә, сексуаль революциядә күрә.

Эрих Фроммның кеше яшәешенең каршылыклы булуы проблемасы

Каршылыклар нигезе

— Патриархат һәм матриархат;

— Гуманистик һәм авторитар аң;

— Хакимият һәм буйсыну;

— Ия булырга омтылу һәм гади генәяшәү

— Шәхси яшәеш (тормыш тарихы) һәм тарихи яшәеш (тарих);

— «Фәләннән азат булу» һәм «Фәлән өчен азат булу» – негатив һәм позитив азатлык;

— Фәлсәфә максаты – бу каршылыкларны гомум мәхәббәт тарату ярдәмендә хәл итү, «яшәү теләге» «үлү теләге»нә тәреп чыккан чакта.

Карл Густав Юнг (1875 – 1961) теориясе

Теория асылы

— Юнг буенча, кешенең тормыш (сексуаль генә түгел) энергиясе, тормыш каршылыкларына очрап, индивидуаль аңсызлыкка түгел, ә архетиплар рәвешендәге гомуми аңсызлыкка күчерелә;

— Архетиплар – универсаль образлар, гомумкеше этеп чыгарылган тормыш энергиясе «код»ы. Алар күргән төшләр эчтәлеге, акылына зыян килгән авырулар саташуы, парапсихологик эффектлар, хыяллар, галлюцинация-саташулар булырга мөмкин.Архетиплар – кешелекнең «шифрланган» тарихы;

— Фәлсәфә максаты – кешегә архетипларны «чишәргә», аларның мәгънәсен, ә алар аша – үзеңне һәм әйләнә-тирә чынбарлыкны аңларга ярдәм итү.

Альфред Адлер (1870-1937) теориясе

Теория асылы

— Кешенең «бөек» гамәлләре, чамадан тыш активлыгы, артык омтылучанлыгы нигезендә, шулай ук психик чирләрендә кимчелеклелек комплексы ята

— Кеше бизнеста, сәясәттә, фәндә, сәнгатьтә, шәхси тормышта уңышка ирешеп, компенсацияләргә тели.

Вильгельм Райхның фрейд-марксизмы (1897 – 1957)

Теория асылы

— Кешенең нормаль яшәве һәм эшчәнлеге нигезендә космик табигатьле сексуаль энергия ята.

— Җәмгыять кеше энергиясен котылгысыз рәвештә баса, аның аффектлары мораль, мәдәният, этикет ярдәмендә.

— Кеше мәдәният кысаларында яшәүгә дучар ителә, гомум яшәеш нормаларына, башка кешеләргә ияләшергә, җитәкчегә, хакимияткә буйсынырга тиеш – бу кешенең нервлы хәленә китерә, аның чын «Мин»е, мөстәкыйльлеге үлүенә китерә.

— Кешене бердәнбер коткару чарасы – мәдәниятнең абруен тулысынча төшерү (мораль, тыюлар, субординация), иркен тоту, сексуаль революция.

§62. Хәзерге теологик фәлсәфә

1. Теологик фәлсәфәгә төшенчәсе

Теологик мәктәбе

Каралган сораулар

— Барлык яшәешне булдыручы буларак Аллаһ барлыгы;

— Аның иң югары иҗат җимеше – кеше яшәеше, кеше тормышы

Хәзерге теологик фәлсәфәнең үзенчәлекләре

— технологик фәлсәфә кешегә якынайды;

— байтак догмнардан азат булды;

— социаль гармонигә, әхлак, әдәпкә, халыклар арасындагы татулыкка зур игътибар бүлә башлады.

2. Неотомизм

Хәзерге теологик фәлсәфәнең иң абруйлы агымы – неотомизм. Күренекле вәкилләре – Э. Жильсон (1884–1978), Ж. Маритэн (1882–1973), Ю. Бохельский (1902 елда туган), Е. Корет (1919 елда туган), К. Ранер (1904–1984), Ф. Ван Стенберген (1904 елдатуган), К. Войтыла (әлеге Рим папасы Иоанн Павел II, 1920 елда туган).

Үзенчәлекләр

— Неотомизм нигезе – Фома Аквинский тәгълиматы. Үзәк принцип – ышану һәм акыл гармониясе.

— Хәзерге неотомистлар материя һәм идея арасындагы каршылыклар, гностицизм һәм агностицизм, эмпиристик һәм рациональ танып белү формасы өстеннән күтәрелергә омтылалар,

— Рим папасы Иоанн Павел II (К. Войтыла) католиклар Чиркәве хаталарын танып үткәннәр, шул исәптән, индульгенция тарату, инквизиция учаклары, фәнне әзерлекләүләр өчен гафу үтенергә тиеш дигән идея тәкъдим итә.

Неотомистлар максаты

— Католицизм һәм католиклар фәлсәфәсенең дөреслеген, хак булуын дәлилләү;

— Католицизмны хәзерге шартларга яраклаштыру;

— Католицизмны гади кешеләргә якынайту.

Тәгълиматның төп өлешләре

— Үз чиратында, онтология (яшәеш турындагы тәгълимат) һәм табигый теологиядән (Аллаһ турындагы фәлсәфә) торган гомум метафизика;

— Кулланма метафизика – әйләнә-тирә дөнья һәм кеше турындагы тәгълимат;

— Гносеология;

— Натурфилософия

Төп идеяләре

— Креационизм (әйләнә-тирә дөньяның Алла тарафыннанаратылуы);

— Ачыш (үзендәге Аллаһны – Инҗилдә (Библиядә);

— Асыл һәм яшәешне бүлеп карау (эссенцияләр һәм экзистенцияләр);

— Асыл һәм Аллаһтагы яшәеш берлеге;

— Кешенең Аллаһка охшашлыгы;

— Кеше – материаль һәм рухи субстанцияләр берлеге. Неотомизм җәмгыятькә, кыйммәтләргә, әхлаккә аеруча игътибар бирә.

3. Хәзерге технологик фәлсәфәнең башка юнәлешләре

Тейярдизм

— Хәзерге теологик фәлсәфәгә нигез салучы – Пьер Тейяр де Шарден (1881 1955).

— Тейяр де Шарденның максаты: феноменология – үзендә фән казанышларын һәм теологик фәлсәфәне берләштерә, Галәм нигезләрен аңлатып биргән комплексы фән төзи.

— Тейяр де Шарден фәлсәфәсенең мөһим принциплары – эволюционизм, аңа ярашлы,дөньядагы һәрнәрсәгә (тере, җансыз табигатькә) эволюция хас.

— Үзенең юнәлеше буенча тейярдизм теологик фәлсәфәсендә реформатор агымы була, күпчелек табигый фәннәр казанышларына таяна, католицизмның күп кенә догмаларын тәнкыйтьли.

Азат булу теологиясе Үзенчәлекләр

— төп идея – кешенең мөмкин кадәр үзен иркен тотышы;

— Латин Америкасында киң таралыш ала.

Теологик фәлсәфәнең протестант юнәлеше

— Либераль теология (шлейермахер, гарнап, трельч)

— Кризис теологиясе (барт, нибур);

— Экзистенциональ теология (тиллих);

— «Демифоногизацияләнгән христианлык» (бультман);

— Динсез христианлык – больхьоферра. Бу тәгълиматларның төп идеяләре исемнәрендә үк салынган.

§63. Хәзерге позитивизм фәлсәфәсенең төп юнәлешләре

1. Позитивизмның төп төшенчәләре һәм үсеш этаплары

Позитивизм – XIX гасырның 30-40нчы елларында барлыкка килгән фәлсәфә юнәлеше. Вәкиле – Огюст Конт, 1798–1857.

Теория асылы

— Фәлсәфә фәнни сыйфатлардан азат ителергә һәмышанычлы фәнни белемгә генә таянырга тиеш.

— Позитивистлар фикеренчә, фәлсәфә тик фактларны гына өйрәнергә тиеш (аларның эчке асылын түгел), барлык бәяләүдән бушанырга, тикшеренүләрдә нәкъ фәнни чараларга таянып эш итәргә (теләсә кайсы башка фән кебек үк), фәнни методка таянырга.

Позитивизмның төп үсеш баскычлары

— классик позитивизм (О. Конт һәм Г. Спенсер);

— махизм; неопозитивизм;

— неопозитивизм;

2. Махизмның гомуми төшенчәләре һәм төп проблемалары

Махизмны еш кына «позитивизмның икенче формасы» дип атыйлар. Аны Э. Мах (1836 –1916) һәм Р. Авенариус барлыкка китерүче дип исәпләнелә.

Төп идеяләр

— Позитивизм. (Аны Э. Мах (1836 – 1916) һәм Р. Авенариус барлыкка китерүче дип санала)Махизмның төп идеясе – фәлсәфә нигезендә тәнкыйди тәҗрибә ятарга тиеш (моңа бәйле бу юнәлешнең икенче исеме дә бар – эмпириокритицизм).

— Эмпириокритицизм субъектив-идеаллистик позициядән чыгыш ясый: әйләнә-тирә дөньяның барлык предметлары, күренешләре кешегә «тойгы-сиземләү җыелмасы» буларак күз алдына килә.

— Димәк, әйләнә-тирәне өйрәнү кеше тойгы-сизүләрен тәҗрибә ярдәмендә тикшерү буларак кына мөмкин.

— Кеше тойгы-хисләре барлык фәннәрдә булганга күрә, фәлсәфә булырга тиешле: беренчедән, интегратив, «гомуми» фән булырга, икенчедән, кеше тойгы-сиземләве турында ышанычлы фән булырга, абстракт фәнни төшенчәләрне тойгы-сиземләү теленә күчерергә (мәсәлән, масса, үлчәм үзеннән-үзе генә яшәми, ә кеше масса һәм үлчәм белән тойган-сиземләгән төшенчәләр бар).

Үзенчәлекләр

— Үзенең субъектив идеализмы булганга күрә эмпириокритицизм позитивизмның үз принциплары белән өлешләтә аерыла, шуңа ул киң таралыш алмады.

3. Неопозитивизмның гомуми төшенчәләре һәм төп проблемалары

Неопозитивизм XX гасырның беренче яртысында һәм уртасында популяр була һәм киң таралыш ала.

Төп вәкилләре:

— «Вена түгәрәге» фәлсәфәчеләре (М. Шлик – нигез салучы; аның дәвамчылары Р. Карнап, О. Нейрат, Г. Рейехенбах);

— Львов-Варшава мәктәбе вәкилләре (А. Тарский, Я. Лукасевич);

— Б. Рассел (1872 – 1970);

— Л. Витгенштейн (1889 – 1951).

Төп идеяләре

— неопозитивизмның төп идеясе – фәлсәфә фән теленең логик анализы белән шөгыльләнергә тиеш, чөнки тел, фән теле кебек үк, – кеше әйләнә-тирә дөньяны позитив (ышанычлы, фәнни) кабул итә алырдай төп чара.

— Фәлсәфә текст, билге, төшенчә, билге системаларының эчке элементләрен, билгеләрдәге семантиканы (мәгънә) логик анализлау белән шөгыльләнергә тиеш (герменевтика белән якынайта).

— Верификация принцибы – фәннең барлык нигезләләрен тәжрибә фактлары белән чагыштыру. Положение, төшенчә бары тик шунда гына мәгънәгә ия, кайчан фән өчен кызыклы, кайчан верификацияләп була – фактлар ярдәмендә тәжрибәле тикшерүгә дучар итү.

— Элеккеге фәлсәфәнең күпчелек проблемалары (яшәеш, аң, идея, Аллаһ) – верификациягә ярамый, ә димәк, бу проблемалар псевдо проблемалар була, ышанычлы фәнни рөхсәте булмаган. Алар фәлсәфәдән алып ташланырга тиеш.

— Неопозитивизмның башка төп максаты (фән теленә логик анализ ясаудан тыш) фәлсәфәне метафизик (ышанычлы фәнни хәл ителә алмаучы) проблемалардан азат итү.

4. Постпозитивизмның гомуми төшенчәсе һәм төп проблемалары

Потивизмның өр яңа варианты булып постпозитивизм булды (XX гасырның икенче яртысы һәмахыры). Аның төп вәкилләре: К. Поппер (1902 – 1994), Т. Кун (1992 елда туган) санала.

Үзенчәлекләре

— постпозитивизм символларны (тел, фәнни аппарат) беренчел логик тикшерүдән читкә китә һәм фән тарихына мөрәҗәгать итә.

— постпозитивизмның төп максаты – фәнни белемнең (тел, төшенчәләрнең) төзелешен (неопозтитивистлар кебек) түгел, ә фәнни белем үсешен тикшерү.

— постпозитивизм фәлсәфәгә тулаем алганда, танып белү проблемаларына карата үз мөнәсәбәтен йомшарта.

— постпозитивистлар фикеренчә, фән мәгънәсе һәм фән теле арасындагы катгый каршылык булмаган кебек үк, теориянең дөреслеге һәм аның верификацияләнүе (тәҗрибәне фактлар белән тикшерү мөмкинлеге) арасында бернинди дә мәҗбүри үзара бәйлелек юк, шулай ук верификацияләнмәгән проблемаларны (метафизик, фәнни булмаганнарны) фәлсәфәдән алып ташларга кирәк димәгән.

— фән үсешенә килгәндә, постпозитивистлар фикеренчә, фән җитди линия буенча үсми, ә сикереп-сикереп, бер менеп китә, бер төшә, әмма гомум тенденция үсеш һәм фәнни белемне камилләштерүгә юнәлдерелгән.

Постпозитивистларны кызыксындырган төп мәсьәләләр

— Яңа теория ничек барлыкка килә?

— Ул ничек танылу ала?

— Фәнни теорияләрнең, шул исәптән туган һәм конкурент булган, критерийларын чагыштыру ничегрәк?

— Тарафдарлар арасында альтернатив теорияне аңлау мөмкинме?

Хәзерге заман постпозитивизмның төп проблемалары

— проблеманы фальсификацияләү (бозып күрсәтү), берничә ялган яки дөрес булмаган фактны тапканнан соң фәнни теориядән тулысынча баш тартырга кирәкме икән;

— фәнни теорияләрнең дөреслеге проблемасы – Фәнни теорияләрнең дөреслеген нинди критерияләр буенча тикшерү;

— Рациональлек проблемасы. Нәрсә ул фәндәге рациональлелек;

— фәнни теорияләрнең үлчәнешлелек проблемасы. Фәнни теорияләрдә нинди критерийлар буенча аларның туганлыгын, үлчәнешлелеген ачыкларга кирәк;

— антагонистик теория вәкилләренең уртак караш ноктaларын табу, аңлау проблемасы.

§64. Герменевтика

1. Герменевтиканың төп төшенчәләре

Герменевтика – аңлату, интерпретация, төшенү теориясе һәм гамәлен тикшергән фәлсәфә юнәлеше. Үзенең атамасын Аллаһ һәм кешеләр арасындагы арадашчы булган борынгы грек Аллаһы Гермеска бәйле алган – Аллаһ ихтыярын кешеләргә һәм кешеләртеләген Аллаһ аларга җиткергән.

Төп принциплар

— Герменевтиканың төп идеясе: бар булу – аңлашылган булу.

— Тикшерү предметы, гадәттә, текст була.

— Герменевтика герменевтик ситуацияләр барлыкка килү белән туа – текстны дөрес төшенү һәм дөрес аңлатып бирү кирәк булган очракларда

Герменевтиканың төп мәсьәләләре

— Аңлау ничек мөмкин?

— Аңлау эчендә яткан яшәеш, асыл нәрсәдән гыйбарәт?

Нигез төшенчәләр

— «Герменевтик өчпочмак» – текст авторы, текстның үзе һәм укучы арасындагы үзара мөнәсәбәт.

— «Герменевтик бөжра» – танып белү процессының цикллы характеры.

2. Герменевтиканың мөһим вәкилләренең төп идеяләре

Герменевтиканың төп вәкилләренең төп фәлсәфи юнәлешләре

Ф. Шлейермахер (1768-1834) теориясе

Төп тәгълимәтләре

— Текстны аңлатып бирү барышында ике төрле ысул – грамматик һәм психологикны кулланыла. Беренчесе ярдәмендә «тел рухы» ачыклана, икенчесе ярдәмендә «автор рухы».

— герменевтика (текстны аңлатып бирү) автор рухы һәм укучы рухы тугандаш кына булганда мәгънәгә ия. Әгәр дә автор укучыдан бик ерак икән, текст герменевтиканың барлык тырышлыгын салсаң да, ул беркайчан да ахыргача аңлашылган булмаячак һәм автор һәм укучы бер-берсенә охшаш икән, текстта бернинди дә яшерен мәгънә калмаячак, һәм ул аңлатуга мохтаҗ булмаячак.

— аңлауга ике юл ярдәмендә ирешелә: беренчедән, дивинация – әсәр авторы рухы белән ясалма рәвештә берләшү;

— икенчедән, чагыштырулар – фактларны һәм башка мәгълүматны чагыштыру.

— дивинацияләү чагыштыру белән чиратлашырга тиеш һәм киресенчә. Укучы ахыргача тел тәртибен, автор рухына төшенгәч, текст тулысынча аңлашылачак.

Беренче герменевтлар эшләре

Урта гасыр теолог-схоластлары (Фома Аквинский һ.б.), алар Инҗил (Библия) текстына салынган илаһи идея мәгънәсен «чишү» белән шөгыль-ләнәләр.

Герменевтиканың төп вәкилләренең мөһим фәлсәфи юнәлешләре (дәвамы)

М. Хайдеггерның (1889-1976) экзистенциаллар турындагы тәгълиматы

Үзенчәлекләр

— Яшь Хайдеггернең карашлары үзендә герменевтика һәм экзистенциализмны берләштерә һәм герменевтиканың яшәеш (онтологик) ягына түгел, ә танып белүгә (гносеологик) багышланган

— кеше яшәеше, Хайдеггер буенча, баштан ук герменевтикалы (аңлауга нигезләнгән).

Экзистенциаллар – кешенең яшәү шартлары

— салынганлык – кеше яшәеше фикерләү белән түгел, ә аның дөньяда булу факты белән билгеләнә, кеше иң элек «салынган», ягъни ул бар, ә аннары гына фикерли);

— аңлау – кеше үзенең аңлый башлавын ачыклый, ә аңлау – аңлату һәм төшендерү ул (кеше үзенең дөньядагы яшәешен билгеле бер образда аңлатып бирә, һәм бу аңлатма үзенең яшәү мәгънәсен, үзенең бу тормыштагы урынын аңлау дип кабул итеп була.

Ганса Гадамер (1900–2001) теориясе

Төп нигезләр

— Ганс Гадамер фәлсәфәнең танып белү (гносеология) позицясеннән аңлау (герменевтика) позициясенә күчәргә тиеш дип чакыра.

— Кеше гомере буена, беренчедән, тәжрибә туплый, (әйтергә кирәк аның күпчелек өлешен башка буын туплаган тәжрибә тәшкил итә, – «дөнья тәжрибәсе»), икенчедән, «дөнья тәжрибәсенә» үз өлешен кертә.

— «Дөнья тәжрибәсе»н үткән буыннан бүгенгесенә һәм бүгенгесеннән киләчәк буынга тапшыру, башлыча,китаплар аша – текстлар, «тел» аша башкарыла.

— Димәк, текстлар теленә төшенү, аны аңлау фәлсәфәнең әйдәп баручы юнәлешләренең берсе булырга тиеш.

П. Рикер (1913–2005) теориясе

Төп нигезләр

— Поль Рикер фәлсәфәсенең үзәк төшенчәсе – шәхес. Шәхес – барлык кешелек мәдәниятын иҗат итүче.

— Фәлсәфә максаты – кеше субъективлыгын аңлау методын барлыкка китерү.

— Шундый метод итеп Рикер «регрессив-прогрессив» методны тәкъдим итә, аның асылы кешене аның өч үлчәме – үткәне, бүгенгесе һәм киләчәгә аша аңларга кирәк дигәннән гыйбарәт.

— Рикер буенча, кеше шәхесе телеологик – киләчәккә юнәлдерелгән.

§65. Экзистенциализм (Кьеркегор, Ясперс, Сартр, Камю һәм Хайдеггерның экзистенциональ фәлсәфәсе)

1. Гомуми төшенчәләр. Экзистенциализм караган төп проблемалар

Экзистенциализм – фәлсәфә юнәлеше, аның төп предметы – кеше һәм аның проблемалары.

Экзистенциалистик фәлсәфә түбәндәге күренешләргә җавап булып туа. Фәлсәфәче-экзистенциалистлар игътибар иткән проблемалар:

— Бөтен дөнья сугышы алдыннан, беренче һәм икенче дөнья сугышы вакытында һәм алар арасында кешелекне ялмап алган әхлакый, икътисади һәм сәяси кризислар;

— Фән һәм техниканың көчле үсеше һәмтехник казанышларны кешегә каршы куллану (хәрби техника, автомат, пулемет, мина, бомбаларны камилләштерү, хәрби хәрәкәтләр барышында агулы матдәләр куллану һ.б.);

— Кешелек дөньясы һәлак булуы хәвефе (атом-төш коралы уйлап табу һәм куллану, якынлашып килүче экологиккатастрофа);

— Катылыкны көчәйтү, Кешегә карата кешелексез мөнәсәбәт (ике дөнья сугышында, концлагерь, хезмәт лагерьларында 70 миллион кеше һәлак булуы);

— Тулысынча кеше шәхесен изүче фашистик һәм башка тоталитар режимнар таралуы;

— Кешенең табигать һәм техноген җәмгыять алдында көчсезлеге.

Экзистенциализм тарафыннан каралган проблемалар

— Кеше шәхесенең уникальлеге, аның хисләре, кичерешләре, өметләренең, гомумән алганда тулысынча гомернең тирәнлеге;

— Кешенең эчке дөньясы һәм әйләнә-тирә тормыш арасындагы гаҗаеп каршылык;

— Кешенең ераклашу проблемасы (җәмгыять, дәүләт кеше өчен бөтенләй чит, кешене санга сукмаган чынбарлык, аның «минен» бастырыклый);

— Кешенең ялгызлыгы, ташланганлыгыпроблемасы (кеше әйләнә-тирә дөньяда ялгызы гына, аның үзен иркен тоярга координат системасы юк;

— Тормыш мәгънәсезлеге проблемасы;

— Эчке сайлау проблемасы;

— Кешенең үз эчке һәм тышкы «Мин»ен, тормыштагы урынын эзләү проблемасы.

2. Сёрен Кьеркегор фәлсәфәсе – экзистенциализмның барлыкка килүе

Экзистенциализмга нигез салучы Сёрен Кьеркегор фәлсәфәсе (1813-1855)

Экзистенциализм барлыкка килү сәбәпләре

Ул шундый сорау куйды: ни өчен фәлсәфә шулкадәр күп мәсьәләләрен – яшәеш асылы, материя, Алла, рух, танып белү чикләре һәм механизмы белән шөгыльләнә – һәм бөтенләй диярлек кешегә игътибар бирми. Алай гына да түгел, конкрет кешене аның эчке рухи дөньясы, гомуми, абстракт борчылулар белән, гадәттә, аны кызыксындырмаган һәм аның көндәлек тормыш мәсьәләләрендә эретә?

Кьеркегор фәлсәфә кешегә, аның кечкенә проблемаларына борылырга, аңа аңлаешлы һәм аның өчен яши алырдай хакыйкатьне табарга ярдәмләшергә, кешегә эчке сайлауда һәм үзенең «Мин»ен аңларга ярдәм итәргә тиеш дип исәпли.

Фәлсәфәче билгеләгән төшенчәләр

— Чын булмаган яшәү – кешенең тулысында җәмгыятькә буйсынуы, «бөтенесе белән тормыш итү»,
«башкаларныкы кебек үк тормыш», «агым буенча йөзеп», үзенең аңсыз «Мин»еннән башка», шәхесенең кабатланмаслыгыннан башка, чын багланышын тапмыйча;

— Чын яшәү – җәмгыять изүеннән чыгу, аңлы сайлау, үзүзен табу, үз язмышы хуҗасына әйләнү.

Чын яшәешне яралу вакытында кешенең өч баскычы

— Эстетик чорда кеше тормышы тышкы дөнья тарафыннан билгеләнә. Кеше «агым буенча йөзә» һәм ләззәт алуга омтыла.

— Этик чорда кеше аңлы сайлау ясый, аеруча үзен сайлый, хәзер аны бурыч төшенчәсе хәрәктләндерә.

— Дини чорда кеше үзенең вазифасын тирән, тулысынча аңлый, тышкы дөнья аңа әһәмиятле түгел, ул аңа каршылык булып тора алмый. Шул вакыттан һәм соңгы көннәренә кадәр кеше барлык михнәтләрне һәм тышкы хәлләрне җиңеп «үз тәресен үзе алып бара» (Иисус Христоска охшатып).

3. К. Ясперс фәлсәфәсе

Карл Ясперс (1883 – 1969) – немец фәлсәфәчесе – XX гасырда иң беренчеләрдән булып экзистенциялистик проблемаларны күтәреп чыга (1919 елда – Беренче бөтен дөнья сугышы тәмамлангач чыккан «Дөньяга карашлар психологиясе» китабында).

Фәлсәфә үзенчәлекләре

— Ясперска ярашлы, кеше «ташландык», мәгънәсе булмаган тормыш белән яши – «барысы кебек». Шул ук вакытта ул үзенең чынбарлыкта кем икәнен дә аңлап бетми, үзенең яшерен сәләтләрен, мөмкинлекләрен, чын «Мин»не белми.

— Әмма аерым очракларда чын табигате, бирелгән яшерен сыйфатлары тышка чыга. Ясперс буенча, чиктәге ситуацияләр – тормыш һәм үлем арасында, кешегә мөһим булган, киләчәгә өчен әһәмиятле булган ситуацияләр.

— Бу вакыттан кеше үзен таный һәм үз-үзенә әйләнә, ул югары яшәеш белән трансцедентальлеккә кагыла.

— Кешенең барлык тормышы аңлы яки аңсыз рәвештә трансцеденциягә юнәлдерелгән – тулысынча энергиянең иреккә чыгуына һәм ниндидер югары абсолютлыкка төшенүгә.

— Кеше трансцеденциягә, абсолютка якынлаша, энергияне азат итә, «трансценденталь шифрлар» аша үз-үзен аңлый.

Трансцеденталь булганның «шифр»лары:

— эротика, секс;

— үзеңнең эчке дөньяң белән берлек үз-үзең белән килешеп яшәү;

— азатлык;

— үлем – яшәеш ахыры.

4. Ж.П. Сартр фәлсәфәсе

Жан-Поль Сартр (1905-1980) фәлсәфәсе һәм аның сайлау проблемасы. Фәлсәфәнең төп төшенчәләре һәм положениеләре:

— Сартр фәлсәфәсенең үзәк төшенчәсе – «үзем өчен яшәеш».

— «Үзем өчен яшәеш» – кеше өчен иң югары чынбарлык, иң элек аның өчен үзенең эчке дөньясы беренчел булып тора. Әмма ул «башкалар өчен яшәеш» – башка кешеләр белән төрле мөнәсәбәтләр аша гына үзен тулысынча кеше итеп аңлый ала. Кеше «башка» берәүнең мөнәсәбәте аша гына үзен күрә һәм кабул итә.

— Кеше яшәешенең мөһим шарты, аның «үзәге», активлык нигезе – азатлык.

— Кеше үз азатлыгын табып, аны сайлауда тормышка ашыра, тик гадидә түгел, икенчелдә (мәсәлән, бүген нинди кием кияргә), ә тормыш өчен әһәмиятледә, язмыш хәлиткечтә, кайчан карар кабул итеүдән баш тартып булмый, (яшәү һәм үлем мәсьәләсе, экстремаль ситуацияләрдә, кеше өчен тормыш өчен хәлиткеч мәсьәләләрдә). Мондый хәл итү карар төрен Сартр экзистенциаль сайлау дип йөртә. Экзистенциаль сайлау кабул итеп, кеше үзенең язмышын бик күп еллар алга билгели, бер яшәештән икенчесенә күчә.

— Бөтен гомер – төрле «кечкенә тормышлар» чылбыры, үзенчәлекле «төеннәр» белән тоташтырылган төрле яшәеш өзеге – экзистенциональ карарлар белән. Мәсәлән: һөнәр, тормыш иптәше, эш урыны сайлау, һөнәрне алыштыру карары, көрәштә катнашырга карар кабул итү, сугышка бару һ.б.

— Сартр буенча, кеше азатлыгы абсолют (ягъни нисбәтсез). Кеше тели алганга күрә генә дә ирекле. Мәсләп, төрмәдә утырган кеше ни булса да теләгән чакта ирекле: төрмәдән качарга, утыруын дәвам итәргә, үз-үзенә кул салырга теләгәндә. Кеше ирекле булырга дучар ителгән (теләсә нинди хәлләрдә, тышкы чынбарлыкка буйсынудан тыш, ләкин бу да сайлау булып тора).

— Азатлык проблемасы белән беррәттән жаваплылык проблемасы да туа. Кеше эшләгән һәр нәрсә өчен, үз-үзе өчен җаваплы («Минем белән булган бөтен нәрсә, – минеке»).

— Бердәнбер нәрсә өчен кеше җавап бирә алмый, – үзенең тууы өчен. Әмма башка барлык нәрсәдә дә ул ирекле һәм ирке белән бар жаваплылык белән кулланырга тиеш, аеруча экзистенциональ (язмышны хәлиткеч) сайлау ясаганда.

5. А. Камю фәлсәфәсе

Альбер Камю (1913-1960) һәм аның мәгънә проблемасы

Төп нигезләмәләр:

— Кеше гомере асылында мәгънәсез. Күпчелек кешеләр үзләренең кечкенә хәсрәтләре, шатлыклары белән, дүшәмбедән якшәмбегә кадәр яшиләр, еллар үткән саен гомеренә максатчан мәгънә бирмичә. Ә кемнәр тормышларына мәгънә салган, энергия сарыф итәләр, алга омтылалар, һәм иртәме, соңмы алда үлем торганын аңлыйлар. Барысы да үләчәк – гомерләрен мәгънә белән тутыручылар да, тутырмаучылар да. Кеше гомере – абсурд, (мәгънәсез) (тәрҗемәдә – нигезе булмаган).

— Нәтиҗәдә, гомер мәгънәсез, тышкы дөньяда түгел (уңыш, уңышсызлык, үзара мөнәсәбәтләрдә), кешенең үз яшәешендә.

Мәгънәсезлек дәлиле, тормышның нисбәтсез булуы:

— үлемгә кагылу – аңа кагылганда, аеруча кинәт һәм якыннан, күп нәрсә, элегрәк кеше өчен әһәмиятле тоелган мавыгулар, карьера, байлык – үзенең әһәмиятлелеген югалта һәм мәгънәсез, яшәеш өчен тормаган итеп тоела;

— әйләнә-тирә дөнья, табигать белән кисешү – кеше меңәр ел яшәп килгән табигать алдында көчсез («мин үләннәр исен тоям һәм йолдызларны күрәм, тик Җирдәге бернинди белем дә миңа бу дөнья минеке булуына ышаныч бирми»).

6. М. Хайдеггер фәлсәфәсе

Мартин Хайдеггер (1889 – 1976) фәлсәфәсе (фәлсәфә предметы һәм бурычын экзистенционалистик аңлау нигезләрен үзен эшкәртү белән шөгыльләнә)

Төп төшенчәләре:

— Экзистенция – кеше үзен караткан яшәеш, кеше яшәеше конкретлык белән тулы булуы; аның тормышы нәрсәсе бар, шунда, бу аның өчен асыл булып тора да инде.

— Кеше яшәеше әйләнә-тирә дөньяда бара (фәлсәфәче тарафыннан «дөньядагы яшәеш» дип атала). Үз чиратында «дөньядагы яшәеш» түбәндәгеләрдән тора:

— «Башкалар белән яшәеш» кешене үзен эченә суырып ала, аның тулысынча ассимиляцияләнүенә, шәхси үзенчәлекләрен бетерүгә, «барысы да кебек»кә әйләндерүгә юнәлтелгән.

— «Үз-үзенең яшәеше» «башкалар белән яшәеш» белән бер ук вакытта «Мин»нең башкалардан аерылып торганда гына мөмкин.

— Димәк, кеше үз-үзе булып калырга теләп, «башкаларга» каршы торырга тиеш, үзенең охшашлыгын якларга тиеш. Бары тик шул вакытта гына ул ирекле булачак.

— Әйләнә-тирә дөньяда үзенең охшашлыгыңны яклау – кешенең төп мәсьәләсе һәм хәстәре.

7. Экзистенциализм киләчәге

Экзистенциализм фәлсәфәсе үсешенең алшартлары

— Экзистенциализм фәлсәфәсе хәзерге Көнбатыш Европада бик популяр һәм аның өчен актуаль

— Кешенең хәзерге вакыттагы проблемасы, аның әйләнә-тирәдәге тормышы, үз-үзен эзләве, кабатланмаслыгын саклавы, яшәү мәгънәсенә бәйле фәлсәфи тикшеренүләргә авырлык үзәге кушылу тенденциясе күзәтелә.

— Әлеге мәсьәлә (кеше тормышы, аның проблемалары) киләчәктә материя һәм аңның беренчеллеге проблемасын икенче планга этәреп, фәлсәфәнең төп мәсьәләсенә әверелергә мөмкин.

СӘЯСӘТ

Кереш сүз

Политология – сәяси эшчәнлек теориясе һәм практикасы тамырлары белән кеше цивилизациясенең ерак үткәненә китүгә карамастан, иң яңа иҗтимагый фәннәрнең берсе. Политология сәяси хакимият формалашуның һәм үсешенең закончалыгын, аның эшчәнлеге рәвешләрен һәм ысулларын, дәүләттә тормышка ашыруны ачып бирә торган фән булып тора. Политологиянең төп максаты – сәясәт һәм сәяси хакимият, сәяси мәнфәгатьләр, мөнәсәбәтләр, аң, сәяси процесслар, сәясәт субъектлары мәдәнияте һәм эшчәнлеге, җәмгыятьнең сәяси тормышын оештыру һәм тиешле сәяси системалар турында белемнәр җыелмасын бирү. Политология илдә бара торган сәяси күренешләргә һәм вакыйгаларга дөрес ориентлашырга, үз карашларына ия булырга, сәяси карарларга һәм теге яки бу сәясәтчеләр, сәяси партияләр лидерларына һәм иҗтимагый сәяси хәрәкәтләргә анализ ясарга, бер сәяси режимның икенчесеннән аермасын аңларга ярдәм итә.

Теләсә кайсы дәүләттә хәзерге заман гражданинның демократик культурасы формалаштыруның бер факторы булып политология нигезләрен белү тора. Әлеге белемгә ия булмаган шәхес буйсыну һәм алдану объектын тәшкил итәргә мөмкин. Нинди һөнәр иясе булуына карамастан, сәяси белемнәр һәм мәдәният һәрбер кешегә кирәк, чөнки җәмгыятьтә яшәп, ул башка кешеләр һәм дәүләт белән котылгысыз хезмәттәшлек итәргә тиеш. Мондый белемгә ия булмаган шәхес сәяси уеннарда уенчык булырга, сәяси мөнәсәбәтләрдә активрак көчләр тарафыннан алданырга һәм коллык объектына әверелергә мөмкин. Гражданнарның массакүләм сәяси грамоталыгы бөтен җәмгыятькә дә кирәк, чөнки ул залимлек һәм тиранлыктан, дәүләт һәм иҗтимагый оешмаларның кешелексез һәм икътисади яктан нәтиҗәсез формаларыннан саклый. Сәяси белем һәм күнекмәләр бигрәк тә гамәлләрендә һәм фикер йөртүендә зур радикализм белән аерылып торучы, төрле утопик идеологияләргә һәм демагогик өндәмәләргә артык бирелүче яшь буынга кирәк. Россия дәүләте үсешенең хәзерге заман шартларында сәяси фән нигезләренә ия булу, аның җәмгыятен уңышлы үзгәртеп коруда мөһим шарт булыптора. Политологияне белү кешегә демократиянең төп кыйммәтләрен һәм нормаларын үзләштерергә, үз язмышы һәм башка кешеләр язмышы өчен

җаваплы карарлар кабул итүгә сәләтле үзешчән субъект статусын формалаштырырга мөмкинлек бирә.

Политология җәмгыять турындагы фәннәр арасында билгеле бер урын алып тора. Бу урын сәясәтчеләрнең җәмгыять тормышында әһәмияте бик зур булган сәясәтне өйрәнүе белән билгеләнә. Сәясәт җәмгыятьнең барлык өлкәләре белән бәйле һәм аларга актив йогынты ясый. Ул илләр һәм халыклар язмышына, алар арасындагы мөнәсәбәтләргә йогынты ясый, кешенең көндәлек тормышына тәэсир итә. Сәясәт, сәяси төзелеш, демократия, сәяси хакимият, дәүләт мәсьәләләре барлык гражданнарга, һәркемнең мәнфәгатьләренә кагыла. Шуңа күрә сәясәт, сәяси тормыш проблемалары җәмгыятьнең һәр әгъзасы өчен актуаль әһәмиятен беркайчан да югалтмаган һәм хәзер дә югалтмый.

§1. Нәрсә ул сәясәт?

1. Политология термины грек теленнән кергән polit (сәяси тәртип, гражданлык хокукы, хакимиятне тормышка ашыру) һәм logos (өйрәнү) сүзләреннән ясалган. Политология сәясәт турындагы фән буларак билгеләнә. Нәрсә соң ул сәясәт?

2. Сәясәт – кешеләрнең үзара хакимият һәм җәмгыять белән идарә итү буенча күпкырлы мөнәсәбәтләре, эшчәнлек, тәртип, юнәлеш, караш һәм аралашулар дөньясы ул. Сәясәтнең төп факторлары булып иҗтимагый (этник) төркемнәр һәм аларның мәнфәгатьләрен чагылдыра торган сәяси оешма, институт, хәрәкәт һәм лидерлар санала.

Сәясәтнең максаты, уртак бурычларны һәм аларга ирешүнең килешенгән чараларын билгеләү юлы белән бергә, кеше өчен уңайлы юнәлештә җәмгыять үсешенә юнәлеш бирүдән гыйбарәт. Сәясәт 2,5 мең ел элек барлыкка килгән.

3. Сәясәт ул – бер үк вакытта фән дә, сәнгать тә. **Фән** буларак, ул кешелек дөньясы-ның иҗтимагый үсеш законнары белән танышып, аларны кулланып, сәяси тормышка йогынты ясый башлаган вакыттан алып исәпләнә. Сәясәт – **сәнгать,** чөнки ул сәяси процессларның субъектив яклары белән эш итә һәм тәҗрибә, интуиция, көч һәм хыял (фантазия) куллануны таләп итә.

4. Сәясәт терминын борынгы грек фәлсәфәчесе **Аристотель –** (безнең эрага кадәр 384-322 еллар) керткән. Аның билгеләмәсе буенча, **сәясәт** – ул «гомум иминлеккә» һәм «бәхетле тормышка» ирешүгә хезмәт итә торган цивилизацияле бердәмлек формасы.

§2. Сәясәт төзелеше

Сәясәт төзелеше үз эченә түбәндәгеләрне ала:

— җанлы субъектлар (катнашучылар)

— элементлар (сәяси хакимият, сәяси мөнәсәбәт, сәяси аң, сәяси мәдәният, сәяси оешмалар)

Сәясәт субъектлары – дәүләт хакимиятен тормышка ашырырга ярдәм итә яки аңа йогынты ясый ала торган индивидлар, социаль катлам һәм төркемнәр, оешмалар.

Сәясәт субъекты буларак социаль институтлар да (сәяси партияләр, профсоюзлар, чиркәү, массакүләм мәгълүмат чаралары, дәүләт, халыкара оешмалар, мәсәлән, Берләшкән Милләтләр Оешмасы, Европа парламенты), шулай ук социаль берлекләр (катлам, сыйныф, милләт, элита, масса, һөнәри төркемнәр) һәм аерым шәхесләр (сәяси лидерлар, гади гражданнар) карала.

Сәясәт элементлары

Сәяси мөнәсәбәтләр: сәясәт субъектлары – килешү, партнерлык, конфликт, хакимлек формаларының үзара бәйләнеше һәм сәяси тормышта катнашучылар арасында буйсындыру.

Сәяси оештыру: шәхес, төркем, җәмгыять мәнфәгатьләрен белдерә торган дәүләт һәм дәүләтнеке булмаган институтлар җыелмасы.

Сәяси хакимлек: үз ихтыярыңны башкаларга тагу мөмкинлеге һәм сәләте.

Сәяси мәдәният: сәяси психология һәм сәяси идеология, сәяси катнашлык мотивлары (идея, хис, кичерешләр, кыйммәтләр, бәяләү).

Сәясәт субъектлары: дәүләт хакимиятен тормышка ашыру процессында катнашучы индивидлар, социаль төркемнәр, катламнар, массалар, оешмалар.

Сәясәт субъектларының сәяси мөнәсәбәтләренә түбәнләгеләр керә: үз эшчәнлегендә таянган сәяси ихтыяҗлар, максат, күрсәтмә, кыйммәтләрне исәптә тоту, ышанулар, идеаллар нигезендә дәүләт хакимиятен бүлү һәм файдалану мөнәсәбәтләре.

Сәяси аң эчтәлеге үз эченә формалашкан бәяләү, мәгънә һәм фикерләр системасын ала.

Сәяси психология хис-кичерешләр нигезендә тормышка ашырылган реаль чынбарлыкны бәяләүдән һәм сәяси тормышта катнашудан барлыкка килә. Сәяси катнашлык рациональ аңлап, күзаллаулар системасына нигезләнеп төзелә.

§3. Сәясәтнең вазифалары һәм аңа хас сыйфатлар

Рационализаторлык вазифасы

Сәясәт конфликтларны һәм каршылыкларны рациональләштерә (камилләштерә), аларны кисәтә яки чишә.

Идарә итү яки тәртипкә салу вазифасы

Сәясәт әһәмиятле мәнфәгатьләрне һәм җәмгыятьнең төрле төркемнәре ихтыяҗларын гына түгел, ә аларның үзара бәйләнешен тәмин итә, сәяси карарлар кабул итү белән йогынты да ясый. Сәясәт иҗтимагый мәҗбүр итү һәм көч куллану юлы белән иҗтимагый процесслар белән идарә итә һәм аларны тәртипкә кертә.

Гуманитар вазифа

Шәхес иреге һәм хокукын гарантияләү, җәмгыятьтә тәртип, гражданлык тынычлыгы һәм оешканлык урнаштыру аша чагыла.

Сәяси гомумиләштерү вазифасы

Сәясәт төркем һәм шәхси мәнфәгатьләрне тормышка ашыру өчен киң мөмкинлекләр ача, үзгәртелгән эшчәнлекнең тәҗрибә һәм күнекмәләрен тапшырып, иҗтимагый роль һәм вазифаларны нәтиҗәле башкарып, шәхесне иҗтимагый мөнәсәбәтләргә кертә.

Мобилизацияләү һәм гомуми эшчәнлекне нәтиҗәле файдалануны тәэмин итү вазифасы

Сәясәт мотивацияләү механизмы төзү аркылы аларны тормышка ашыра, индивидның иҗтимагый ихтыяҗларын канәгатьләндерү өчен нәтиҗәле мөмкинлекләр бирә, хакимият ярдәмендә аның иҗтимагый статусын үзгәртә.

Җәмгыятьнең бөтенлеген һәм тотрыклыгын тәэмин итү вазифасы

Сәясәт киләчәк өчен проектлар әзерли, иҗтимагый ориентирлар билгели, аларны тормышка ашыру өчен кирәкле ресурслар таба.

Сәясәткә хас сыйфатлар

— Шәхси һәм гомуми, шәхес һәм социаль бөтенлек (төркем, ил, кешелек) мәнфәгате мөнәсәбәте – без сәясәт дөньясына үзебезнең шәхси мәсьәләләребезне хәл иткәндә генә кермибез, ә аларны шәхси мәнфәгать кысаларыннан ерак торган бурычлар бәйләнешеннән, башка бик күп кешеләр бу мәсьәләләр белән мәшгуль булуыннан чыгып хәл итәбез.

— Сәясәтнең теләсә кайсы төре дәүләтнең яшәеше һәм эшләү проблемаларын хәл итү белән бәйле – җәмгыятьне гомуми кызыксындырган мәсьәләләрне хәл итүгә корылган социаль институт.

— Кешеләр массасы мәнфәгате һәм эшчәнлеге белән бәйләнеш.

— Аек акыл белән анализлауны таләп иткән, шартлар төрлелеге һәм сәяси эшчәнлек компонетларын исәпкә алган үзәкләштерелгән эшчәнлек.

— Хакимлек итәргә яратучан холык, мәҗбүр итү сәләте, кешеләр хәрәкәтен бер максатка юнәлтү өчен ихтыяри йогынты ясау.

§4. Политология: объект һәм предмет, аның вазифалары

Политология объекты – сәясәт, җәмгыять тормышының сәясәт өлкәсе. Объект дәрәҗәләре:

— сәяси системаларның гомум үсеш һәм алмашыну закончалыклары, төшенчәләр һәм категорияләр;

— реаль сәяси процесслар (сәяси эшчәнлек теорияләре һәм ысул эшкәртмәләре төзү);

— сәяси институтларны конкрет тикшерү, хәл-вакыйгалар, субъект, объектларны анализлау.

Политология предметы – сәяси хакимиятнең үсеш һәм эшләү законча-лыклары.

Политологиянең төп ысуллары:

— диалектик;

— системалы;

— тәртип, үз-үзеңне тоту;

— тәртип, үз-үзеңне тоту;

— структур-функциональ;

— чагыштырма;

— конкрет–тарихи;

— норматив;

— институцион;

Политологиянең вазифалары

— Теоретик-танып белү вазифасы – сәясәт һәм аның җәмгыятьтәге роле турындагы белемне формалаштыра;

— Дөньяви караш – ул сәяси эшчәнлекне билгеле бер күзал-лауда күрергә ярдәм итә.

— Методологик вазифа, ягъни сәяси фәннәр нәтиҗәләре ае-рым сәяси теорияләргә нигез булырга, хезмәт итәргә мөмкин дигәнгә кайтып кала;

— Тәртипкә салу вазифасы сәяси белемне сәяси хәрәкәткә ту-рыдан-туры йогынты ясаганнан туплаудан гыйбарәт;

— Фаразлау (прогноз бирү) вазифасы – сәяси күренешләр үсешен прогноз аша ачып бирү тенденциясе;

— Бәяләү (аксиологик) – вакыйгаларга төгәл бәя бирә.

§5. Политология ысуллары

Методлар (ысуллар) – белем алу чаралары, конкрет алымнар (бу очракта сәясәт турында). Политология фәнендә теоретик һәм эмпиритик социаль аң традицион методлары кулланыла.

Теоретик аң алымнары:

— Диалектик. Сәяси чынбарлык күренешләренең сыйфат ягыннан үзгәреп торуын исәпкә алуны, сәяси процессларның каршылыклы булуын, сәяси тормышның өле шләре һәм компонентлары бәйләнешен күздә тота.

— Системалы. Сәясәт өлешләрнең (табигать, икътисад, мәдәният, кеше психологиясе) үзара бәйләнеше аша формалашкан бербөтен күренеш итеп карала.

— Формальләштерү. Сәяси күренешләрне һәм тулы сәяси системаларны охшашлы- клары буенча чагы-штырырга, тәңгәлләштерергә, аларның уртак һәм аермаларын табарга, компонетларның, бәйләнешләрнең, сәяси тормышның юнәлешләренең төрлелеген ачыкларга ярдәм итә торган математик аппарат кулланырга мөмкинлек бирә.

Эмпиристик аң ысуллары – конкрет сәяси күренешләр турында яңа белем алу өчен чара һәм алымнар.

— Сурәтләү. Сәясәт фәнендә кабул ителгән терминнарның әһәмиятле сыйфатларын, сәяси тормыштагы ча-гылышын күзәтү һәм ныгыту.

— Анкета формалары (әңгәмә, интервью, сорау алу). Ул җәмгыять фикерен белү, сәяси процесста кат-нашучыларның позицияләрен аңлау өчен кулланыла.

— Статистик методлар. Алар ярдәмендә төрле эмпиристик мәгълүматны туплап гомумиләштерү күзалла-на.

— Семиотик методлар (билге системасы турындагы фән) аеруча нәтиҗәле, чөнки сәясәтнең күпчелек күренешләре (процедура, гореф-гадәт, тантаналар, ритуал, сәяси документлар стиле) үзе белән билге, сим-волик системаны, шартлы мәгънәле предмет һәм хәрәкәт гәүдәләндерә.

— Герменевтик методлар. Аларның максаты объектларны ныгытып куюда гына түгел, ә сәяси күрене-шләрне, сәясәттәге субъектлар хәрәкәтенә салынган мәгънәне аңлауда.

§6. Россиядә һәм чит илләрдә политологиянеңбарлыкка килүе һәм үсеше

2,5 мең ел кешелек тарихы эчендә сәяси фикер берничә **төп юнәлеш аша үтә:**

— **Борынгы Көнчыгыш сәяси фикере** (Мисыр, Иран, Кытай, Вавилон). Бу этапка сәяси күзаллауларның мифологик формасы хас; хакимиятнең илаһи башлангычытурындагы караш хакимлек итә;

— **Борынгы Греция һәм Борынгы Рим сәяси тәгълимате.** Дәүләт төзелеше анализлана, аның төрләре билгеләнә, җитәкчелек итүнең идеаль формалары ачыклана;

— **Урта гасыр сәяси тәгълимате.** Сәяси хакимиятнең теологик теориясе дәлилләнә;

— **Яңарыш һәм Мәгърифәтчелек чоры.** Сәяси карашлар теологиядән азат ителә; кешенең хокукы һәм иреге проблемалары, дәүләт белән идарә итүләрне чагылдыра;

— **Яңа чор сәяси тәгълиматы.** Хакимият идеологиясен формалаштыру бара, хакимият бүленеше кирәклеге нигезләнә. Хокукый дәүләткә сыйфатлама ясала, буржуаз демократия механизмы һәм аңа ярашлы кеше хокукы һәм ирке концепциясе формалаша.

Октябрь инкылабы җиңгәннән соң, барлык иҗтимагый фәннәрне сәясәтләндерү һәм идеологияләштерүгә бәйле сәясәт фәнен мөстәкыйль рәвештә укытудан туктыйлар, һәм мондый хәл Россия югары уку йортларында 1990 елга кадәр дәвам итә.

XIX гасыр башында **сәяси социология** барлыкка килә. 1857 елда Фрэнсис Ливер Колумбия университетында сәяси фәннәр кафедрасы төзи, аның нигезендә 1980 елда сәяси фәннәр мәктәбе барлыкка килә. XIX гасырның икенче яртысында сәяси фәннәрне АКШның күпчелек университетларында укыта башлыйлар, ә Европада исә сәяси белем бирү 70нче елларда гына җәелдерелә.

Узган гасырның 70нче еллар ахырында сәясәт фәнен Россия университетларында да укыта башлыйлар. Ул вакытта аның дүрт **юнәлеше** була:

— либерализм (Б.Н.Чечерин, П.И.Новгородцев);

— консерватизм (В.С. Соловьев)

— радикализм (большевизм һәм анархизм белән тәкъдим ителә – В.И.Ленин, М.А.Бакунин, П.Л. Лавров)

— социал-реформизм һәм меньшевизм (Ю.О. Мартов, Г.В. Плеханов)

§7. Сәяси тормыш

«Сәяси тормыш» төшенчәсен сәяси терминологиягә Дэвид Лэйн кертә. Ул яшәешнең институцион һәм хәрәкәт карашларын сәясәт белән берлектә карарга мөмкинлек бирә, бу аның **сыйфатларында** да чагыла:

Сәяси тормыш җәмәгатьчелек мәнфәгате һәм идарә итү өлкәсе буларак хезмәт итә, ә аның иң мөһим коралы – һәрвакыт оешма көчен кулланган хакимият, мәҗбүр итү, авторитет йогынтысы, алар урынына исә дәүләт, партия, берләшмәләр, хәрәкәтләр һәм башка социаль институтлар чыгыш ясый ала.

Сәясәт сәяси мөнәсәбәтләр итеп төзелгән иҗтимагый һәм сәяси институтлар, оешмалар өлкәсе һәм үзара тәэсир итешү буларак, шулай ук сәяси мөнәсәбәтләрнең субъект хәрәкәте буларак та чыгыш ясый.

Сәясәтнең эшлекле, актив сыйфаты кешелек тормышының күп кенә якларына: икътисад, мәдәният, фән, әдәпкә йогынты ясый ала.

Сәясәт тормышына һәрвакыт кеше массалары җәлеп ителә: сыйныфлар, этник һәм һөнәри берлекләр, юнәлеш, сәяси вакыйгаларның нәтиҗәсе аларның активлыгыннан тора.

Сәяси тормыш үзәге – шәхес һәм дәүләт арасындагы бәйләнеш төрлелеге.

Сәяси тормышка йогынты ясаучы тышкы факторлар:

— сәяси проблемалар тудыручы һәм юл сайлауга, аларны чишү мөмкинлекләренә йогынты ясый торган табигать мохите элементлары (территория, ресурс, климат)

— җәмгыятьтәге икътисади мөнәсәбәтләр

— техника үсеше (хәрби аспект), мәгълүмат тарату тизлеге арту

— сәяси мөнәсәбәтләрдә (керем, шөгыльләнү төре, белем дәрәҗәсе) катнашучыларның объектив торышларын үзендә беркеткән җәмгыятьнең иҗтимагый төзелешенең статус характеристикасы һәм аларның үзләренең җәмгыятьтәге урыннарын билгеләүләре

— этномилли җәмгыятьләрнең характеры

— кешеләрне туплый торган төп фактор – дин

— кешеләрнең сәяси тормышында катнашуында, халык темпераментында, лидерларның характер үзенчәлекләрендә чагылучы җәмгыятьнең сәяси психологиясе.

— идеология – рухи берләшү һәм идарә итү чарасы, ул сәяси мөнәсәбәтләр өлкәсендә кеше хәрәкәтенә юнәлеш бирә, ихтыяр, сәяси хәрәкәткә омтылыш формалаштыра;

— массакүләм мәгълүмат чаралары, алар тәкъдим иткән һәм аңлатып биргән мәгълүмат

§8. Сәяси тәртип

Сәяси эшчәнлекне анализлаганда, **сәяси тәртип төшенчәсе** аның мезанизмын, төзелешен, максатларга ирешү алымнарын ачыкларга ярдәм итә, төрле сәяси эшчәнлек чагылышын аерым хәрәкәт, элемент системасында бергә тоташтыруга китерә.

Сәяси тәртиптән чыгып, сәясәттә канашучыларны берничә **категориягә** бүләләр:

— **Лидерлар** – сәяси хәрәкәт башында торалар, авторитетлары, йогынтылары белән куелган максатларга ирешергә ярдәм итәләр.

— **Активистлар** – лидерлар һәм иярүчеләр арасындагы арадашчылар, хәрәкәттә катнашучыларны оештыралар, лидерларны ирешелгән нәтиҗәләр һәм кыенлыклар турында хәбәр итәләр, массалар тәртибенең стратегиясе һәм тактикасына төзәтмәләр кертәләр.

— **Иярүчеләр (эзеннән баручылар)** – оешмада төрле дәрәҗәдәге активлык һәм катнашу тәртибе белән характерлана. Лидерлар тәкъдим иткән максатларны куәтли, һәм аларны үз мәнфәгатьләренә хас дип исәпләләр.

— **Фикер лидерлары** – үзләренең акыл эшчәнлеге ярдәмендә (мәсәлән, публицистика аша) проблемалар әйләнәсендә эмоциональ һәм акыл киренкелек мәйданы тудыралар, оештыру күзлегеннән чыгып, катнашучыларның хәрәкәтенә йогынты ясамыйча, аларны гомум игътибар объектына әверелдерәләр

§9. Сәяси эшчәнлек

Сәяси эшчәнлек

Сәяси эшчәнлек – ул оешканлыгын һәм хакимият функцияләрен тормышка ашыра торган индивид һәм төркемнәр үзара бәйләнеше.

Сәяси эшчәнлеккә хас сыйфатлар

— Иҗтимагый бөтенлекнең яшәү ихтыяҗын, гомуми проблемаларының тупланышын көчәйтү

— Дәүләтне, аның институтларын бу проблемаларны хәл итүнең төп чарасы буларак кабул итү

— Сәяси хакимиятне куелган максатка ирешүнең төп чарасы буларак куллану

Сәяси эшчәнлек торышы

Сәяси читләшү – кеше һәм сәяси хакимият мөнәсәбәтенең торышы, ул кешенең шәхси проблемаларын хәл итүгә юнәлдерү, сәяси тормышка каршы куя. Читләшү өлкәсендә сәясәт кеше мәнфәгатенә, тормыш проблемаларына катнашы булмаган эшчәнлек итеп кабул ителә, ул сәяси хакимият белән бәйләнеш булуын кирәк дип санамый. Монда йөкләмә, салымнар системасы аша хакимият, дәүләт белән нибары мәҗбүри бәйләнеш корыла.

Сәяси пассивлык – бу субъект (индивид, иҗтимагый төркем) үз шәхси мәнфәгатен башкармый торган сәяси эшчәнлек. Ул башка иҗтимагый төркем сәяси йогынтысы астында тора. Пассивлык – ул билгеле бер эшчәнлек һәм сәясәт формасы, иҗтимагый төркем үзенекен түгел, ә аңа ят сәяси мәнфәгатьләрне тормышка ашыра. Конформизм – сәяси пассивлык төре, иҗтимагый төркем тарафыннан сәяси кыйммәтләр системасын үз мәнфәгатьләренә туры килмәсә дә, үзеңнеке итеп кабул итү.

Индивид һәм иҗтимагый төркемнең **сәяси активлык критерийлары** үз мәнфәгатьләрен сәяси хакимияткә йогынты ясауга омтылуга яки аны файдалануга хезмәт итә.

Сәяси активлык **эчтәлеге** аны барлыкка китергән проблема үзенчәлегеннән, бурычлар туу вакытыннан, шулай ук катнашучылар составыннан чыгып үзгәрә.

Сәяси активлыкның төп сыйфатлары:

— Гражданнарның омтылышлары ныгуы белән гадәти сәяси активлык формалары һәм катнашлыгыннан тыш хәрәкәт итүе; катгый оештырылган сәяси партияләр (фиркалар) урынына оешмаган сәяси хәрәкәтләргә өстенлек бирү

— Гражданнарның берләшүе еш кына бер мәсьәләгә бәйле барлыкка килә, аны хәл итүгә юнәлтелми

— Сәясәт белән кызыксынган гражданнар саны арта, әмма бер үк вакытта фиркаләр саны кими

— Үзләрен теге яки бу көчләргә, структураларга бәйләмәгән кешеләр саны арта, ягъни алар сәясәттәге урыннарын бәйсез күрсәтә

§10. Сәяси прогресс

Сәяси прогресс

Сәяси прогресс – сәяси мөнәсәбәтләрнең камилләшү сызыгы, сәяси системада төрле иҗтимагый мәнфәгатьләрнең тулылануы буенча юнәлдерелгән үсеш.

Сәяси прогресс критерийлары

Сәяси эшчәнлекнең стимуллар характеры: сәяси прогресс барышында тышкы стимуллардан эчкегә күчеш барлыкка килә, боерыклардан жәлеп итүгә күчеш ясала, кешеләрнең сәяси тәртибе эчке аңлы дәлилләүне тәртипкә салу, сәяси хәрәкәт субъекты башлангычы әһәмияте үсә

Сәяси мөнәсәбәтләр структур дифференцация дәрәҗәсе, вазифалар төрлелеге. Югары үсеш турында җәмгыятьтә башкару, законнар чыгару һәм суд хакимияте барлыгы дәлилләп тора

Билгеле бер сәяси мөнәсәбәтләр системасы кысаларында төгәл, тәнкыйди бәя бирә алучы махсус компонент яки орган булуы. Бу рольне иҗтимагый фикер, ирекле басма, хөкүмәткә бәйсез тикшерү оешмалары башкара

Сәяси функцияләрне тормышка ашыруда белемнең әһәмияте, сәясәт өлкәсендәге планлаштыру һәм идарәлекне тәртипкә салу; сәяси аңның салмак кына мифология күзаллауларыннан, мистик символика, чынбарлыкны дини яктан аңлатудан чыгуы

§11. Сәяси катнашлык

«Сәяси катнашлык» термины төрле һөнәри булмаган сәяси эшчәнлек формаларын билгеләгәндә кулланыла. Дәүләт аппараты һәм хөкүмәте белән бәйле булмаган сәяси актив кешеләр аның эшчәнлегенә йогынты ясарга омтылганда барлыкка килә.

Сәяси катнашлык төрләре:

— вазифалар бүлү белән бәйле төрле сайлауларда, сәяси кампанияләрдә даими катнашу

— башка кешеләр һәм институтлардан чыккан тышкы йогынтыга җавап булган сәясәттәге кешеләрнең хәрәкәтләре

— сәяси оешма, хәрәкәт, партияләрдәге эшчәнлек

— дәүләт органнары кысаларында сәяси вазифалар башкару, аның функцияләрен башкаруга җәмәгатьчелек ярдәме, җәмәгатьчелекне сәяси институтларның эшчәнлеген контрольгә тотуга җәлеп итү

— сәяси җыелышларда катнашу, сәяси мәгълүматны аңлау һәм тапшыру, сәяси бәхәсләрдә катнашу

— митинг, демонстрация, забастовка, ач тору, буйсынмау кампанияләре кебек эш формалары аша сәяси институтларга турыдан-туры йогынты ясау

— сәяси процесслар барышына мөрәҗәгатьләр, хатлар аша тәэсир итү, сәяси лидерлар, дәүләт һәм сәяси оешма, хәрәкәт вәкилләре белән очрашу

§12. Сәяси хакимият

Хакимиятнең асылы кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләргә максатчан, акыллы, тәртип урнаштыра алу сәләтеннән гыйбарәт. Хакимият иҗтимагый мөнәсәбәтләрне төрле чаралар: көчләү, мәҗбүр итү, күндерү, дәртләндерү, куркыту ярдәмендә тәртипкә сала.

Традицияләр, демократик процедуралар (рациональ-хокукый чыганаклар), табигый сәләт (харизма) хакимият чыганаклары була ала.

Сәяси практикада югары хакимияткә, гадәттә, төрле чыганаклар кулланып ирешәләр. Билгеле бер вакытта алар арасында төп чыганак буларак демократик процедураларны кулланырга мөмкин.

Хакимиятнең түбәндәге төрләре бар: сәяси, икътисади, иҗтимагый, законнар чыгара торган, башкарма, суд, мәгълүмати, хәрби, яшерен. Сәяси хакимият – шуларның төп төре. Бу аның җәмгыятьтәге һәм дәүләттәге тормышны үз эченә алып, юнәлеш бирү һәм тәртипкә салуыннан тора.

Хакимият чыганаклары:

— көч

— байлык

— җәмгыятьтә биләгән урын

— оештыру, белем һәм мәгълүмат

Сәяси хакимият – кешенең тәртибе, эшчәнлегенә авторитет, хокук, көчләү ярдәмендә билгеле дәрәҗәдәге йогынты ясап, үз ихтыярыңны тормышка ашыру мөмкинлеге һәм сәләте. Сәяси хакимиятнең табигате объектив.

Хакимиятсез җәмгыятьтә хаос туа, шуңа да хакимиятнең төп максаты, аеруча сәясәтнең – иҗтимагый һәм дәүләт тормышы процессы белән идарә итүне тәртипкә салу.

Хакимият билгеләре:

— Хакимиятнең ихтыяри өстенлек алуы

— Махсус идарә итү аппараты булу

— Җәмгыять тормышын тәртипкә салуда монополия

— Җәмгыять һәм шәхескә карата мәҗбүр итү (көчләү) хокукына ия булу, легитимлык, суверенлык

§13. Сәяси хакимиятнең легитимлыгы

Легитимлык

Легитимлык сүзе латин теленнән алынган (legitimus – законлы) алынган. Легитимлык –хакимият һәм аның хакимлегендәгеләр арасындагы мөнәсәбәтләр. Ул хакимият кыйммәтләрен, аның идарә итү хокукын ирекле танудан тора. Легитимлык хакимиятнең яшәп килгән сәяси институтларда күндерә алу формалаштыру һәм аны тотып тору сәләте белән бәйле.

Хакимиятнең легитимлыгы һәм законлыгы – бер-берсенә каршы килә торган төшенчәләр. Легальлек хакимиятнең юридик яктан нигезләнеп, аның хокук нормаларына (юридик характеристика) тәңгәл килүен аңлатса, легетимлык – ышаныч һәм хакимиятне аклау (әхлакый характеристика). Закон чыгара торган теләсә кайсы хакимият, хәтта популяр булмаган, ләкин закон үтәүне тәэмин итүче легаль хакимият буларак карала. Шул ук вакытта ул легитим булмаска, халык белән кабул ителмәскә дә мөмкин.

Легитимлы хакимият төрләре

Традицион

Бу төр хакимият гореф-гадәтләргә, хакимияткә буйсынуга, урнаштырылган типларның какшамасылыгына нигезләнә.

— **Патриархализм** – хуҗаларга һәм традицияләргә бәйлелек. Бу төр хакимият – чиста традицион хакимият төре.

Конституция буенча Советлар Союзы федерация була, ә мөстәкыйльлекне куллану алымнары һәм тормышка ашыру буенча – унитар. Үзбилгеләнү хокукы, хәтта аерым мөстәкыйль дәүләт төзүгә кадәр, СССРның барлык республикалары конституцияләрендә язылган була. Һәм 90 нчы еллар башында ул барлык союздаш республикалар тарафыннан кулланыла.

СССР таркалгач, Россия алдында яңа дәүләтчелек төзү, яңа Конституция кабул итү мәсьәләсе килеп туа. Россия хәзерге вакытта федерация хасил итә, әмма фактта федерациядән конфедерациягә күчү процесслары нык сизелә.

Россиядә конституцион-килешү федерациясе барлыкка килде, ягъни Конституция белән федерациянең үзәк һәм субъект арасындагы мөнәсәбәтләр ике яклы килешүләргә нигезләнә. 1998 елда мондый инде кырык килешү төзелә.

§47. Россия Федерациясендә дәүләт хакимияте

РФ Президенты:

— Дәүләт башлыгы

— РФ Конституциясе, кеше, гражданин иреге һәм хокуклары гаранты

— РФ суверенлыгын, аның бәйсезлегенә һәм дәүләт бөтенлеген саклауга чаралар күрә

— Дәүләт хакимиятеның органнарына йогынты ясый ала һәм килешеп эшләүне тәэмин итә

— Дәүләтнең эчке һәм тышкы сәясәтенең төп юнәлешләрен билгели

— РФ ил эчендә һәм халыкара мөнәсәбәтләрдә вәкиллеген тәкъдим итә

Федераль җыелыш РФнең вәкиллек һәм закон чыгару органнары була. Ул ике палатадан тора: Федерация Советы һәм Дәүләт думасы.

Федерация советы эшчәнлегенә түбәндәгеләр керә

— РФ субъектлары арасына чикләрнераслый

— Президентның хәрби һәм гадәттәнтыш хәлләр турындагы указларнықабул итә

— РФ Президентын сайлауны билгели һәм аны вазифасыннан төшерә

— Конституцион Суды судьяларын һәм Генераль прокурор вазифаларына билгели

— РФ Кораллы көчләрен чит илләрдә куллану мөмкинлеген кабул итә

Дәүләт Думасы эшчәнлегенә түбәндәгеләр керә

— РФ Хөкүмәт рәисе вазифасына билгеләүгә ризалык бирә

— Хөкүмәткә ышаныч мәсьәләсен хәлитә

— РФ Үзәк банкы рәисе вазифасына билгели һәм азат итә

— Амнистия игълан итә

— РФ Президентына карата аны урыныннан бушату өчен гаепләүләр чыгару

РФ хөкүмәте

— Башкарма хакимиятне тормышка ашыра

— Федарель бюджетны билгели һәм аның үтәлешен тәэмин итә

— РФдә бердәм финанс-акча сәясәтен алып баруны тәэмин итә

— Мәдәният, фән, мәгариф, сәламәтлек саклау, иҗтимагый, экология өлкәләрендәдәүләт сәясәтен алып баруны башкара

— Федераль милек белән идарә итә

— Гражданнарның ирке, хокукы, закончалыкны тәэмин итә

— Илне саклау, дәүләт хәвефсезлеген, РФнең тышкы сәясәтен тормышка ашыру өченчаралар күрә

РФнең судлары

Конституцион суд:

— РФ Конституциясенә аңлатма бирә

— РФ Президентына карата гаепләнүләрне күтәреп чыгу мәсьәләсе тәртибен карый

— Дәүләт хакимияте органнары арасындагы компетентлык бәхәсләрен хәл итә

— Федераль законнарның туры килүе, РФ дәүләт хакимияте органнарының норматив актлары һәм РФ Конституциясенең федерация субъектлары турындагы эшләрне хәл итә

Югары Суд гражданлык, җинаять һәм башка эшләр буенча югарысуд органы булып тора, барлык гомум юрисдикация судларының суды.

Югары арбитраж суды икътисади бәхәсләрне хәл итү буенча һәм башка арбитраж судьялар караган эшләр өчен югары суд була.

§48. Гражданнар җәмгыяте

Гражданнар җәмгыяте – демократик дәүләтләрдә формалашкан һәм үсеш алган кешеләр берлеге. Алар җәмгыятьнең барлык өлкәләрендә ирекле рәвештә дәүләтнекебулмаган төзелмәләр (берләшмә, оешма, ассоциация, берлек, үзәк, клуб, фондлар) һәм дәүләтнеке булмаган мөнәсәбәтләр – икътисад, сәяси, социаль, рухи, дини һәм башкалар челтәре итеп күрсәтелә.

Гражданнар җәмгыятенең төзелеше

— дәүләтнеке булмаган иҗтимагый-икътисади мөнәсәбәтләр һәм институтлар (милек, хезмәт,эшмәкәрлек)

— дәүләткә бәйсез җитештерүчеләр һәм эшмәкәрләр (шәхси фирмалар), хосусый милекчеләрҗыелмасы

— иҗтимагый берләшмәләр һәмоешмалар

— сәяси партияләр һәм хәрәкәтләр

— тәрбия һәм дәүләтнеке булмаган мәгариф өлкәсе

— дәүләтнеке булмаган массакүләм күләм мәгълүмат чаралары системасы

— гаилә

— чиркәү

Гражданнар җәмгыяте билгеләре

— кеше һәм гражданнарның ирке һәм хокукларын тулысынча тәэмин итү

— үзидарәлек

— аны барлыкка китерә торган төзелмәләрне һәм төрле төркемнәрнең конкурентлыгы

— ирекле барлыкка килүче иҗтимагый фикер һәм плюрализм

— гомуми хәбәрдарлык һәм кешенең мәгълүмат хокукын реаль тормышка ашыру

— тормыш эшчәнлеге үзара килешкәнлекпринцибына нигезләнә

— икътисадның күп тормыш тәртибенә таяныуы

— легитимлык һәм хакимиятнең демократикхарактеры

— хокукый дәүләт

— кешеләрне лаеклы тормыш белән тәэмин итүгә нигезләнгән дәүләтнең көчле иҗтимагый сәясәте

§49. Гражданлык җәмгыяте барлыкка килү сәбәпләре

Хосусый милек гражданлык җәмгыятенең барлыкка килүе һәм аның эшләвенең, үз-үзе оешкан көчле иҗтимагый структурага әйләнүенең беренче сәбәбе була. Хосусый милек үзенең төрлелегендә гражданлык мохитенең яшәешен кирәк дип таба. Шәхси предприятие, җир, күчемсез милек (шул ук вакытта арендага бирелүче); керем китерүче кыйммәтле кәгазьләр, процент бирүче акча берәмлекләре; язучылар, композиторлар, уйлап табучылар, фәнни эшчеләр ия булган акыл милеге – болар барысы да хосусый милек.

Ирекле базар икътисады. Демократик җәмгыять башка ирекләр белән хуҗалык си- стемасын да күз уңында тота. Бу законнарны үтәп, эшмәкәрлек белән шөгыльләнергә була. Әмма базар законнарына ялгызың гына каршы торуы кыен. Бу бурычны җиңеләй-тү өчен, эшмәкәрләрнең төрле оешмалары булышлык итә.

Дәүләт үз гражданнарының мәнфәгатьләрен һәм ихтыяларын мөмкин кадәр канәгатьләндерергә тиеш. Дәүләткә конкрет гражданнарның мәнфәгатьләре турында мәгълүмат бирү системасы булдыру зарур. Аларны бары тик дәүләтнең үз көче һәм чаралары белән генә канәгатьләндереп була. Мондый зарурилыкның сәбәбе демакратик җәмгыятьтәге гражданнарның ихтыяҗ төрлелегеннән туа. Бу гражданлык җәмгыяте үз халкына ирек бирүе белән бәйле.

Гражданлык җәмгыяте барлыкка килүе һәм үсеше

Иҗтимагый иреклек, демократик дәүләт идарәлеге, сәяси эшчәнлекнең иҗтимагый өлкәсе һәм сәяси дискуссия булуы

Ачыклык һәм аның белән бәйләнгән гражданнарның югары мәгълүматлылыгы, хуҗалык торышын билгели торган барлык шартларны реаль бәяли алу, иҗтимагый мәсьәләләрне күрү һәм алар- ны хәл итү өчен чаралар күрү

Тиешле законча- лык һәм конститу- цион га- рантияләр

Тарихи типлар:

— Община (нинди булса да җәмгыять)

— Иҗтимагый мәгариф (катлам, иҗтимагый төркем, сыйныф)

— Илнең гражданнары җыелмасы буларак җәмгыять

— Гражданнарның дөньяви берлеге

§50. Россия Федерациясендә гражданлык җәмгыятеформалашу шартлары

РФдә гражданлык җәмгыяте формалашу шартлары:

— җитештерү чараларының (коллектив һәм шәхси) хуҗалары институтын төзү, икътисади көндәшлекне, активлыкны, мөстәкыйльлекне, хуҗалык итүче субъектларныңтигезлеге үсешен булдыру

— аерылгысыз сәяси хакимиятне ликвидацияләү, хакимият вәкаләтләрен децентрализацияләү һәм яңадан бүлү

— кешенең үзаңын иреккә кую, шәхси абруйны ныгыту, үз көченә һәм мөмкинлекләренә ышану, иҗтимагый-сәяси мәсьәләләрне хәл итүдә пассивлыгын җиңү,сәяси мәсьәләләрне мөстәкыйль рәвештә кую һәм хәл итүдә сәләт һәм әзерлекнеһәм активлаштыру

§51. Конституционализм

Абсолютист-монархия идарәсеннән демократиягә күчү дәүләт һәм гражданлык җәмгыя-тенең хокукый нормаларга буйсынуыннан, **бердәм конституционализм системасын** тәшкил иткән хакимият бүленеше принцибын кертеп җибәрүдән башлана.

Конституционализм типлары

чын	**уйдырма**

Тарихи үрнәкләре

Англия-Америка конституционализмы индивидның иреген нигезләнә һәм дәүләтнең гражданлык җәмгыяте тормышына йогынты ясауны рөхсәт итми.	Евроконтитенталь конституционализм дәүләт тәртибе һәм милли бердәмлек идеясенә, дәүләтнең махсус роленә, шәхес азатлыгын тәэмин итүгә нигезләнгән	Россия конституционализм хакимият бөтен тулылыгы белән монарх кулында сакланган хәлдә югары хакимият институтлары булдыруны аңлата.

Классик хокукый билгеләмә буенча конституционализм, парламентаризм һәм абсолютизм кебек үк, конкрет идарә итү формасын аңлата.

Абсолютизм – хакимият тулысынча монарх кулында булган дәүләт формасы..

Конституционализм, хокукый дәүләт формасы буларак, абсолютизм формасына каршы тора, анда дәүләт һәм граждан җәмгыяте арасындагы мөнәсәбәтләр хокукый нормалар белән регламентлаштырыла.

Халык вәкиллеге (парламент) һәм хөкүмәт (башкарма хакимият) арасындагы мөнәсәбәтләр хакимият механизмында 2 принцип – парламентаризм яки конституционализмның берсе өстенлек алуына бәйле.

Парламентаризм дигән сүз хөкүмәтнең парламент карарларына бәйлелеген аңлата, ә **конституционализм** исә хөкүмәтнең парламент ихтыярыннан бәйсезлеген күздә тота.

Конституционализмның формаль-хокукый ягы җәмгыятьтә дәүләтнең халык вәкиллеге билгели торган төп закон булуын, хакимият тармакларының төрле өлкәләрендә дә вәкаләтләрнең бүленешен һәм күләмен билгели.

Конституционализмның Англия-Америка моделе игътибарны төп кыйммәт буларак иреккә акцент ясый, дәүләтнең үз бурычларын билгели торган гражданлык җәмгыяте тормышына йогынты ясамый.

Көнбатыш Европада дәүләт һәм гражданлык җәмгыяте арасында конституционализм башкача юнәлеш ала һәм башка – евроконтинентальмодель хасил итә.

§52. Россиядә гражданлык җәмгыяте формалашу

Россиядә гражданлык җәмгыяте формалашу

Россия Федерациясендәге хәзерге икътисади **реформалар** шәхеснең гражданлык иреген нигезе буларак хуҗалык азатлыгын тәэмин итәргә тиеш. Хосусыйлаштыру шәхси затларга дәүләт милкенең аерым бер өлешен сатып алырга мөмкинлек бирә.

Хезмәт коллективлары һәм дәүләт предприятиеләре арендалау, акционер нигезендә объектлар, сәнәгать, сәүдә, хезмәт күрсәтү өлкәсенә сатып алу хокукы алды.

Россиядә гражданлык җәмгыяте формалашуның икътисади, сәяси һәм юридик нигезләре аның **Конституциясендә** дә беркетелгән. Россия демократик хокукый дәүләтбуларак санала.

Илдә икътисади киңлекләрнең бердәмлеге, товарларның, хезмәт күрсәтүнең һәм финанс чараларының иркен күчеше, намуслы конкуренция, икътисади эшчәнлекиреге гарантияләнә.

Россиядә гражданлык җәмгыяте формалашуы хокук һәм иреген генә түгел, шул ук вакытта гражданлык җаваплылыгы, бәйсез суд һәм прокуратура, камил законнар чыгаруны да күз уңында тота. Россиядә гражданлык җәмгыяте үсеш алсын өчен, икътисади һәм сәяси тотрыклылык кирәк.

Россиядә гражданлык җәмгыяте төзелү барышында иҗтимагый күренешләрне сөй-ләшү һәм килешүләр процессы кысаларында хәл итүтенденциясе күренә.

Ике нәтиҗә

Гражданлык җәмгыяте безнең илдә беренче, ләкин бик әһәмиятле адымнар ясый.

Бездә гражданлык җәмгыяте төзелү аерым бер үзенчәлекләргә ия, әмма ул Көнбатышның демократик илләр юлыннан үсеш ала.

§53. Сәяси партияләр

Сәяси партия – иҗтимагый төркем һәм сыйныфның үз мәнфәгатьләрен белдерә торган, идеологик гомумилеге булган һәм сәяси хакимлек өчен көрәшә торган актив һәм оешкан өлеше.

«Партия» термины латин теленнән «өлеш», «төркем» дигәнне аңлата. Борынгы Дөньяда киң таралыш алган була. Әмма сәяси партияләр парламентаризм үсеш алгач кына(XVII-XIX гасырларда) барлыкка килә.

Башта алар парламентта эшләүче элита клублары булалар. Парламенттан тыш, алар үзләрен сайлаулар вакытында гына күрсәтә. Партияләр оешма буларак теркәлми, әгъзалык төшенчәсен дә кабул итмиләр. Нибары XIX гасырда, миллионлаган кеше сайлау хокукы алгач кына, яулап алганнарны саклау өчен махсуслаштырылган оешмалар буларак яки сәяси хакимиятне төшерү партияләре барлыкка килә.

Борынгы Грециядә партияләр формалашуы идарә итүче көчләр билгеле бер сәясәт алып бару өчен халыкны үз ягына җәлеп итәргә тырышуга сәбәпче була. Борынгы вакытта партияләр хакимият өчен көрәш яки хакимиятне саклау, җәмгыятькә йогынты ясый торган корал буларак кулланыла. Хәзерге төсендә сәяси партияләр тарихи күзлектән чагыштырмача күптән түгел генә барлыкка килә. Башта Англиядә XVII гасырның 70-80 елларында **тори** (консерваторлар) һәм **виглар** (либераллар) партияләре төзелә. Алар король хакимитяенә йогынты ясарга үзара көрәшә торган җитәкчелек итүчесыйныфларның партияләре була.

XVIII гасырның беренче яртысында ук сәяси партияләр барлык көнбатыш илләрендә дәтөзелә. Беренче чиратта бу илләрдә хакимиятне яулаган **буржуазия партиясе** төзелә.XIX гасырның 20-30 елларында партия төзүләр АКШта да тәмамлана. Бу вакытта буржу-азия мәнфәгатьләрен яклаган зур ике партия (демократлар һәм республиканнар) бар- лыкка килә. Алар бүген дә иң көчлеләре булып кала.

XIX гасырда Европада партияләр төзү процессын төп аермалы ягы – ул баштаюгарылар партияләре, ә аннары XIX гасырның икенче яртысында сәяси хакимият өчен көрәшергә кирәклеген төшенгән түбәннәр партияләре формалаша башлый.

Икенче аермалы ягы – аларның барысы да иң мөһиме дип ике бурычны: парламенттагыкүпчелекне яулау һәм сайлаучы өчен көрәшне куялар.

§54. Партияләрнең билгеләре, вазифалары һәм төзелешләре

Партияне башка сәяси көчләрдән аерып торган билгеләрне Дж.Лапаломбара һәм М.Вейнер формалаштыра

— Партия – ул оешма, ягъни шактый вакыт бергә оешкан кешеләр берләшмәсе. Озак вакыт эш итүе аны фракция, өер, клиентелалардан аера, чөнки болар һәммәсе дә барлыкка килә һәм тиз юкка чыга.

— Милли җитәкчелек белән даими элемтә тота торган урындагы тотрыклы оешмаларбулуы.

— Партия максаты – хакимиятне яулау һәм аны тормышка ашыру. Аны тормышка ашыру омтылышы партияне кешеләр төркеменнән аерырга мөмкинлек бирә. Әгәр дә партия хакимият сайлауларында яулап алырга ниятли икән, парламенттагы депутатлар эшчәнлеге аша аны тормышка ашыра.

Партиянең вазифалары җәмгыятьнең сәяси структурасында тоткан урынына, эшчәнлекнең конкрет шартларына һәм төренә бәйле була.

Җитәкчелек итүче партия, мәсәлән, хакимиятне формалаштыру, дәүләт органнарында кадрларны урнаштыру кебек үзенчәлекле вазифаларга ия булса, оппазицион партиянеңмондый вазифалары юк.

Аның өчен иң мөһиме – хөкүмәтнең эшчәнлеген тәнкыйтьләү һәм хакимиятне яулап алугаәзерлек.

Аермаларына карамастан, бөтен партияләрнең дә узара охшашлыгы бар. Алар түбәндәгеләр:

— Зур иҗтимагый төркемнәрнең кызыксынуларын ачыклау, формалаштыру, канәгатьләндерү

— Кешеләрнең билгеле бер өлешен активлаштыру, бердәмләштерү

— Сәяси хакимлек һәм аны куллану өчен көрәш, бу көрәшнең төрен, чарасын, алымын үзгәреп торган хәл барышында билгеләү

— Җирле һәм югары хакимият органнарын формалаштыру буенча сайлап алу компанияләрен әзерләү һәм уздыру, алардан үз тарафдарларыңны алга чыгару, аларныңпарламент эшчәнлегенә контроль оештыру

— Партия идеологиясен эшләү, эшкәртү,җәмгыять үсешенең политик программасын булдыру һәм тормышка ашыру,җәмгыяви фикер формалаштыру һәм пропагандалау

— Җәмгыятне өлешчә һәм тулаем сәяси яктан тәрбияләү

— Партия өчен, дәүләт аппараты һәм төрле иҗтимагый оешмалар өчен кадрларныәзерләү һәм тәкъдим итү, идарә итү элитасын формалаштыру

Партиянең төзелеше

Партия аппараты	Гади әгъза	Партия тарафдарлары

§55. Партияләр типологиясе (классификациясе)

Сәяси партияләрнең классификациясен түбәндәге критерийләр буенча билгелиләр:

— Эшчәнлекнең һәм программаның иҗтимагый юнәлеше буенча. Бу кретерий буенча партияләр иҗтимагый-демократик, либераль-демократик, коммунистик, сыйныфлаштырылган, милли, фашистик, дини, дәүләтчән-патриотик, халыкчан партияләргә бүленәләр

— Эшчәнлекләрнең нигезләгән идеяләре буенча: доктриналь (үз идеологияңне яклау), прагматик (эшчәнлекнең практик максатына юнәлдерелгән), харизматик(конкрет сәяси лидерлар тирәсендә берләшкән)

— Программаны үтәү алымнары буенча: революцон (җәмгыятьтә сыйфатлы радикаль үзгәрешләр булдыру өчен берләшүчеләр), реформалаштырылган (җәмгыяви тормышны кискен үзгәрешләрсез яхшыртуга берләшүчеләр)

— Сәяси эшчәнлекнең характеры буенча: реакцон, консерватив, уртача, радикаль,экстремистик, рәсми

— Сәясәткә мөнәсәбәте һәм дәүләт хакимиятенең югары органнарында вәкиллелекбуенча: идарә итүче һәм оппазицон (легаль, ярым легаль, легаль булмаган)

§56. Партия системалары

Сәясәт системасы – хакимият өчен көрәштә катнашучы һәм аны тормышка ашыраторган (идарә итүче һәм оппазицон) партияләр бердәмлеге.

Сәясәт системасы сәяси партияләрнең торышыннан, үзара мөнәсәбәтләреннән, сәясәтсистемасының төреннән оеша. Бу шушы илдә гамәлдә булган **сәяси партияләр бердәмлеге**, аларның бер-берсе белән эшчәнлеге.

Сәясәт системасының табигате һәм үзенчәлекләре бу яки башка илнең күп факторларына бәйле җәмгыятьнең сәяси өлгергәнлек дәрәҗәсе, аның сәяси үзаңы һәм мәдәнияте, тарихы, гореф-гадәтләре, милли составы, дини хәле, иҗтимагый сыйныфлаштырылганлыгы. Партия системасының формалашуына гамәлдәге законнар, конституция һәм сайлау законнары йогынты ясый.

Партия системасы төрләре:

— сәяси режим характерыннан чыгып: демократик, авторитар, тоталитар партия системалары

— хакимият өчен көрәшүче яки аңа йогынты ясарга теләүче партияләр саныннан чыгып: бер партияле (бары бер партиянең хокукы тәэмин ителә һәм җәмгыятьтә сәясихакимиятне тормышка ашыру), ике партияле (җиңгән очракта ике партиянең берсенә закон чыгару органында урын бирелә яки аның кандидатларын президент һәмвице-президент урыннарына кую), күп партияле (бу очракта бер партия да күпчелексайлаучыларның тавышын туплый алмый, шуңа күрә хөкүмәт күбрәк коалицияле була, ягъни ике яки берничә партия вәкилләреннән тора)

— партияләрнең төрле сәяси статуслы булуыннан чыгып: мажоритар, өстенлек итүчеһәм коалицион

§57. Партия системаларының төрләре

Партия системалары сан һәм сыйфат критерийларыннан чыгып бүленә. Саны ягыннан түбәндәге төрләргә аералар:

— Бер партияле (монопартия) системада бердәнбер партия дәүләт хакимиятен монополиягә ала. Ул тоталитар һәм авторитар режимнарга хас. Бер партияле системаның яхшы яклары да бар – иҗтимагый төркемнәрне берләштерү сәләте, аларның төрле мәнфәгатьләрен гармонияле куша алуы, ресурсларны туплавы һәм аларны көнүзәк мәсьәләләрне чишү өчен тотыну. Каршы көчләрнең булмавы аны тоткарлыкка, бюрократизмга дучар итә.

— Ике партияле система. Берничә партиядән торып, шуларның икесе өстенрәк, абруйлырак була. Бөекбританиядә ул – лейбористлар һәм консерваторлар, АКШта –республиканнар һәм демократлар. Ике партиялелек системасы парламент ярдәменә таянган тотрыклы хөкүмәт төзергә мөмкинлек бирә. Әмма ике партияле системаның кимчелекле яклары да бар, шуларның берсе – чираттагы сайлауларда оппозиция җиңсә, сәяси курсның кискен үзгәрү ихтималлыгы.

— Күп партияле система. Ике яки аннан артык партияләр булуын күз уңында тота.Партияләр саны иҗтимагый ихтыяҗлар булуын чагылдыра. Мондый партия системасы килешү һәм юл куюга омтыла, чөнки бер партия дә өстен түгел.

Сәяси «авторитеты» буенча дүрт төрле партия аерыла

Мажоритар партияләр – абсолют күпчелек мандатлар алган һәм үз сәяси курсын үткәрү хокукына ия

Мажоритар сәләте булган партияләр – хакимиятта партияләр чиратлашып торса, киләсе сайлауларда алар җиңәргә дә мөмкин

Өстенлек итүче партияләр – чагыштырмача күп депутат урыннарын алганнар

Миноритар партияләр – иң аз мандатка ия

§58. Россиядә партия системалары

Россиядә партияләр барлыкка килгәннән үк, аның кайбер **үзенчәлекле** яклары була:

Россиядә партияләр төзелүе Көнбатыш Европага караганда соңракбашлана

Партияләр түбәнге катлаудан башлана (атап әйткәндә, эшчеләр сыйныфыннан)

Россиядә эшчеләр партиясе революцион буларак төзелә, төп максатлары – революцион, радикаль, корал юлы белән хакимият яулау

Югары катлау партияләре Беренче рус революциясеннән соң гына 1905 елның 17 октябреннән генә барлыкка килә

Россиядә күп партиялелек шул сәбәпле озак үсә алмады – 1917 елның октябренә кадәр генә; үсеш алмаган булып калды, чөнки партияләр күпсанлы булмый, ә иң мөһиме – алар хакимияткә сизелерлек йогынты ясый алмыйлар. 1917 елгы Октябрь революциясеннән соң Россиянең күп париятлелек тарихы өзелә. Ул нибары 80 елдан соң гына тергезелә.

Шул вакыттан алып Россия күп партиялелеге берничә этап үтә:

— 1986-1998 еллар – формаль булмаган иҗтимагый оешмалар үсеше

— 1988-1989 еллар – халык фронты һәм партиягә каршы структуралар эшчәнлеге

— 1990-1991 еллар – партияләр төзелүнең беренче дулкыны (1990 елда ЛДПР һәм КПРФ демократик платформасы төзелүе. 1991 елда Ирекле Россия халык партиясеоештырыла)

— 1990-1993 еллар – 1991 елның августыннан соң башланган партия төзелешенең икенче дулкыны» (Икътисади ирек партиясе, Консолидацион партия, Крестьяннарпартиясе)

— 1993 елның ахыры-1995 еллар – Дәүләт Думалары арасындагы чор. Бу вакытта формалашкан системаны радикаль җимерелә һәм яңа сәяси партияләр барлыккакилә (ПРЕС, «Выбор России» блогы, «Яблоко»)

— 1995 елдан соң – консолидация һәм исән калу этабы.

Бүген Россиядә 50 ләп партия эш итә

§59. Басым төркеме

Басым төркеме – актив үз мәнфәгәтьләрен кәнагәтләндерә һәм билгеле бер максат ярдәмендә сәяси хакимиятнең структураларына йогынты ясый торган җәмгыять оешмасы.

«Төркем басымы» төшенчәсе гражданлык җәмгыятендә, сәяси факторда барлык- ка килә торган иҗтимагый төркем мәнфәгатьләренең динамик әйләнешен ача. Төркем басымы – төгәл билгеләнгән оешу структурасына ия, төпле вазифалары һәм һөнәри кадрлар аппараты булган формаль гражданнар берләшмәсе. Төркем басымы илнең сәяси тормышына йогынты ясарга мөмкин, еш кына көче буенча ул сәяси партиянең йогынтысыннан өстен чыга.

§60. Лоббизм: билгеләмә һәм аның төрләре

Лоббизм – кемнең дә булса сәяси яки икътисади карашларын протекцияләү, аги-ацияләү һәм дәүләт хакимияте органнарында яклау. Лоббизм сәяси хакимият белән катгый бәйләнгән. Шундый закончалык күзәтелә: күбрәк чын хакимият булган җирдәлоббизм ешрак күзәтелә. Лоббизм – хакимият билгесе.

Лоббизмның тулы институты оешуы өчен ике шарт булуы кирәк:

— җәмгытьтә иҗтимагый дифференциация, катламнарга бүленү нәтиҗәсендә күп төрле мәнфәгатьләр булу

— сәяси плюрализм нигезендә хакимияткә юл табу мөмкинлеге, гадәттә, ул демократик режим өчен хас

Лоббизм төрләре

Вакыт гамәленә карап: «бер тапкыр була торган лоббизм» һәм «даими лоббизм»	**Мәнфәгать характерларына карап төрләре:** сәяси, иҗтимагый, авыл хуҗалыгы, сәнәгать, финанс	**Лоббированиенең объект һәм субъект мөнәсәбәтләренә карап төрләре:** плюралистик (билгеле бер халык катламнары ягыннан дәүләт органнарына өстәп аска таба басым ясый) һәм корпорация (нинди дә булса төркем белән аларга лояль һәм ышанычлы ярдәм итү турындагы хакимиятнең яшерен килешүе дәүләт органнарына өстенлек бирүгә алмаша)	**Хакимиятнең нинди юнәлештә «сорау хәл» ителүенә карап лоббизм түбәндәге төрләргә бүленә:** закон чыгаручы, башкарма һәм суд лоббизмы

Хакимият органнарының кайсы дәрәҗәсендә башкарылыуына карап: федераль һәм урындагы лоббизм.

§61. Лоббизмның уңай һәм тискәре яклары

Лоббизм абруе:

— Идарә карарларына тәэсир итеп, дәүләт хакимият органнарын һәм идарәсен «фор-мада тотарга» мәҗбүр итә, күпмедер мәгънәдә контрольдә тота, аның белән яры- ша, аңа зур динамик һәм сыгылмалык өсти

— Гражданлык җәмгытенең үз оешмасының коралы буларак карала, аның ярдәме белән мобильләшә, иҗтимагый ярдәм яки берәр закон проектының оппозициясе,сәясәткә тәэсир итә, сыгылмалык өсти

— Иҗтимагый һәм дәүләтнеке булмаган структураларның (ассоциация, берләшмә, иҗтимагый оешма) иҗтимагый азатлыгы принцибын тормышына ашыра сыгылма-лык өсти

Лоббизмның кимчелекләре:

— милли мәнфәгатьләргә зыян китерү белән лоббизм чит ил мәнфәгатьләрен канәгатьләндерү коралы булырга мөмкин

— кайчагында дәүләткә хокуксыз йогынты ясау үткәргече булырга мөмкин, хәтта җинаять төрләренә кадәр (ришвәтчелек, коррупция), алар хакимиятнең нигезенҗимереп торалар

— идарәчелекне, урындагычылыкны, милләтчелекне саклау һәм аның үсешен тәэминитү өчен хезмәт итү факторы була ала, «махсус ихтыяҗлар»ны канәгатьләндерүнең иң чик формаларын ныгыта

— үзендә җәмгыятьнең халык хакимияте нигезләрен «юдыру» куркынычын яшерә,демократик институтларны хакимиятнең аерым төркемнәре коралына әйләндерәләр

— лоббистик чаралар билгеле шартларда иҗтимагый гаделсезлек формасында чагылырга мөмкин

— гадәттә, чыннан да кирәкле идарәчелек карарларының юлын яба, кыйммәтле иҗтимагый ихтыяҗларга каршы төшә, чиновниклар мәнфәгатенә ярдәмләшә

— кайвакыт тотрыклы һәм оператив дәүләт сәясәтен үткәрергә комачаулый, чөнки ул бюджетны кабат-кабат бүлүгә юнәлтелергә мөмкин, еш кына кыйммәтләр үзгәрүгә китерелә, хакимиятнең бер тармагын ныгытып, икенчесен хәлсезләндерә

— гадәттә, чыннан да кирәкле идарәчелек карарларының юлын яба, кыйммәтле иҗтимагый ихтыяҗларга каршы төшә, чиновниклар мәнфәгатенә ярдәмләшә

Лоббизм бөтен җәмгыятькә дә файда китерсен өчен, тиешле шартлар булуызарур: демократик институтлар һәм нормаларның реаль кулланылуы, икътисади һәм сәяси тотрыклык, мәгълүмат чаралары иреге, тотрыклы гражданнар җәмгыяте, кап- ма-каршылыксыз хокукый тәртипкә салу.

§62. Сәяси мөнәсәбәтләр

Сәяси мөнәсәбәтләр – иҗтимагый төркемнәр, шәхесләр, иҗтимагый институтларның җәмгыять төзелеше һәм идарәлеге буенча бәйләнеше. Идарә итү һәм иҗади процесслар һәм мөнәсәбәтләрне тәртипкә салу ихтыяҗы барлыкка килгән вакыттан килә һәм бу мөнәсәбәтләр дәүләт катнашында башкарыла.

Сәяси мөнәсәбәтләр характеристикасы

Сәяси мөнәсәбәтләр кешеләрнең аңы катнашында барлыкка килеп, эш-гамәлләрдә, хәрәкәтләрдә, процессларда, иҗтимагый төркем, партия, дәүләтләр арасында чагылыш таба.

Сәяси мөнәсәбәтләрнең актив, эшлекле характерына бәйле, алар кешеләрнең эчке һәм тышкы сыйфатларына йогынты ясый. Икътисад үсешенең алдынгы кыйммәтләрен урнаштыру ашаҗәмгыятьнең икътисадый тормышына йогынты ясала; сәяси чаралар аша, дәүләт механизмы ярдәмендә мәдәният, фән, дин үсешенә булышырга яки, киресенчә, тотрыкларга мөмкин, бер әхлак кыйммәтләре системасына ярдәм итеп, икенчеләрен басарга мөмкин.

Сәясәт өчен җәмгыятьнең төрле якларына йогынты ясауның төп коралы – хакимият, мәҗбүр итү, оешма көчен кулланып, авторитар йогынты ясау, ул партия, берләшмә, дәүләт, хәрәкәтләр һәм институтлар булырга мөмкин. Алар күп кешенең ихтыяр көче һәм хәрәкәте нәтиҗәсендә барлыкка килә.

Сәяси мөнәсәбәтләр яшәешенең ике формасы

Сәяси эшчәнлек – аңарда сәяси мөнәсәбәтләрнең хәрәкәтчәнлеге чагыла, аларның кешеләрнең иҗтимагый көчләренә бәйле булганы ачыклана.

Сәяси оешма – сәяси мөнәсәбәтләрнең төзелешен, аларның билгеле норма һәм тәртип буенча төзелгәнен чагылдыра. Бу төр икенче төрле институциональ дип тәйөртелә.

§63. Сәяси конфликт

Сәяси конфликт – билгеле бер сәяси мәнфәгать һәм максатлардан гыйбарәт булган иҗтимагый көчләрнең капма-каршы килүе.

Конфликт формалашу дәрәҗәләре:

— шәхесара дәрәҗәдә

— төркем дәрәҗәсендә

— җәмгыять системасы бүлеге дәрәҗәсендә

— төбәк һәм глобаль дәрәҗәдә

Уңай вазифалары:

— стабильләштерү ролен башкара

— җәмгыятьтәге каршылыкларны хәл итү һәм җәмгыятьне яңарту

— кыйммәтләрен икенче төрле билге ясап стимуллаштыра

— яңа структуралар вакытына кристаллизацияне тизрәк ясый

— катнашучыларның белемен яхшыртуны тәэмин итә

Тискәре вазифалары:

— җәмгыятьне дезинтеграция һәм дестабилизациягә китерергә мөмкин

— кешеләрнең үлеменә һәм матди кыйммәтләр юкка чыгаруга китерергә мөмкин

— хакимият мөнәсәбәтләрендә начар үзгәрешләргә китерергә мөмкин

§64. Сәяси конфликтны хәл итү шартлары

Сәяси конфликт рөхсәт шартлары

- конфликтны ачу
- конфликтны анализлау
- хәл итүнең юлларын һәм алымнарын эзләү
- актив эзлекле максатка ирешә торган конфликтны нейтральләштерү буенча гамәлләр кылу

Конфликт тулысынча бетерелгән дип санарга була, әгәр

- конфликтка китерә торган иҗтимагый каршылыкның төп сәбәбе хәл ителгән булса
- элегрәк дошман булган яклар нигезендә үзара ышаныч хезмәттәшлеккәкүчсә
- хезмәттәшлек буенча шартлар тарафыннан килешүче яклар тотрыклы рәвештә башкарылса

§65. Сәяси плюрализм

Сәяси плюрализм – конкуренция аркасында вәкаләт өчен дәүләт хакимияте органнарында күптөрле сәяси көчләрнең барлыкка килү принцибы. Мәнфәгатьләр каршылыгын, төрле як тарафдарлары арасында дискуссиядә төрле карашлар булуын күздә тота.

Сәяси плюрализма асылы җәмгыятьтәге төрле төркемнәрнең мәнфәгать төрләрен чагылдыра торган фикер, караш, позиция төрлелегендә. Сәяси плюрализм җәмәгать аңында һәм сәяси практикада күренә, ул җәмгыятьнең билгеле бер структураларына йогынты ясый һәм төрле сәяси институтларда, партиядә, хәрәкәтләрдә, фронтларда, ассоциацияләрдә, фракцияләрдә, шулай ук төрле дәрәҗәдәге вәкиллекле органнарында чагылыш таба.

Плюрализмның **иҗтимагый кыйммәте** шунда: индивидка үз фикерен аңлату мөм- кинлеге бирелә, билгеле бер мөмкинлекләр тигезлеге урнаштырыла, җәмгыятьтәге барлык төркемнәргә дә түзем булу карала.

Сәяси плюрализм **күп партиялелек**, фикер конкуренциясе белән бәйле. Ул барлыксәяси көчләрнең конституция һәм закон кысаларында легаль көрәшне күз алдында тота, кечкенә төркемнәр үз структурасын саклап калу мөмкинлеген бирә.

Сәяси плюрализ компонентлары:

— сәяси идеяләр төрлелеге һәм оештыру формалары

— моноцентризмны кире кагу

— кешеләр берләшмәсе, партия һәм бүтән законлы оештыру иреге

— каршы килгән карашларга ихтирамлы мөнәсәбәт

— оппозиция көче һәм аларның чиксез эшчәнлеге

— хакимиятләрнең бүленешен чикләү, үзәк хакимият

— хакимиятнең сәяси структураларының алмашу ихтималы бар

Сәяси плюрализмга хас билгеләр

— идеологик төрлелек

— дәүләти яки мәҗбүри буларак, нинди дә булса идеологияле билгеләүне тыю

— дәүләтнең дөньяви характеры

— сәяси күп төрлелекне һәм күп партиялелекне тану

— закон каршында барлык иҗтимагый берләшмәләрнең тигезлеге

§66. Сәяси культура

Сәяси культура – сәяси процесс субъектлары эшчәнлегендә чагылыш тапкан, күчүчәнлек нигезендә җәмгыятьнең сәяси тормышын тәэмин итә торган һәм тари- хи рәвештә формалашкан, чагыштырмача тотрыклы кыйммәтләр, күрсәтмә һәм ка-рашлар, күзаллауларның, тәртип модельләре системасы.

Җәмгыять үз-үзен мәдәнияттә таный һәм чагылдыра. Рухи мәдәният тормышыннан һәм үсешеннән, мәдәни кыйммәтләр сыйфатыннан җәмгыятьнең акыл потенциалы һәмүз проблемаларына төшенү, аларны хәл итү дәрәҗәсе дә бәйле.

Сәяси культура гомуми мәдәниятнең бер өлеше булып санала. **«Сәяси мәдәнит» төшенчәсендә** сәясәт һәм аның иҗтимагый аңының органик рәвештә берлеге чагыла.

§67. Сәяси культура вазифалары

Сәяси культура вазифалары аның асылыннан чыга һәм җәмгыятьнең сәяси системасында аның әһәмиятен характерлый.

Сәяси мәдәният вазифалары аның асылыннан чыга һәм җәмгыятьнең сәяси системасында әһәмиятен характерлый.

Интегратив вазифа

Гомуми кабул ителгән сәяси-мәдәни кыйммәтләр нигезендә яшәп килгән сәяси система һәм җәмгыять тарафыннан сайланган сәяси строй кысаларында килешүгә ирешү. Сәяси мәдәният сәяси тормыш нигезен формалаштыра һәм идарә итү нәтиҗәлелеген арттыруга ярдәм итә.

Коммуникатив вазифа

Сәяси процесста катнашучылар арасындагы мөнәсәбәтләрне көйләргә, шулай ук буыннан буынга сәяси мәдәниятне тапшырырга һәм сәяси тәҗрибә тупларга мөмкинлек бирә.

Регулятив вазифа

Күрсәтмә, максат, мотив һәм тәртип нормалары кебек кирәкле сәяси кыйммәтләрне иҗтимагый аңда формалаштыра һәм ныгыта.

Тәрбияви вазифа гражданин, шәхесне сәясәтнеңтулы субъекты буларак форлаштырырга мөмкинлек бирә, кешеләрне сәяси гомуми-ләштерергә өйрәтергә ярдәм итә.

§68. Сәяси мәдәният төзелеше

Сәяси мәдәният төзелеше өчкә бүленә: сәяси аң мәдәнияте, сәяси тәртип мәдәнияте, сәяси институтлар эшчәнлеге мәдәнияте. Үз чиратында бу өч структура тагы да кечкенә өлешләргә тармаклана:

Сәяси аң мәдәнияте

өчкә бүленә:

— сәяси күзаллаулар һәм карашлар

— сәяси күрсәтмәләр

— сәяси кыйммәтләр, традицияләр, гореф-гадәтләр, нормалар

Сәяси тәртип мәдәнияте үз эченә түбәндәгеләрне ала:

— сәяси катнашу

— сәяси эшчәнлек

Сәяси институтлар эшчәнлеге мәдәниятеөчкә бүленә:

— электораль процесс мәдәнияте

— иҗтимагый-сәяси конфликтларны кабул итү һәм көйләү

— сәяси карарлар кабул итү һәм аларны тормышка ашыру мәдәнияте

§69. Сәяси мәдәнияткә хас сыйфатлар

Сәяси мәдәнияткә хас сыйфатлар:

— Ул тотрыклы, кабатланып килә торган бәйләнешләрне, сәяси процесстагы эле- ментлар арасындагы мөнәсәбәтләрне терки, сәяси тәжрибәнең тотрыклы якларынныгыта

— Җәмгыять үсеше тарихының табигый продукты була, сәяси коллектив иҗатнәтиҗәсе

— Гомуми характерда була – сәяси мөнәсәбәтләр сәяси мәдәният белән сугарыла

— Төп халык массасының сәяси аңы һәм сәяси тәртибен характерлый һәм сәяси суб- культура суммасына гына кайтарылып калмый

§70. Сәяси мәдәният төрләре

Сәяси мәдәният үз эченә өч төрнең сәяси юнәлешләрен кертә: патриархаль, буйсынучан һәм актив катнашу- га юнәлтелгән. Конкрет җәмгыятьтә аларның берсе өстенлекалырга мөмкин. **Шушы өч идеаль юнәлеш төре сәясәт мәдәниятенең өч төренә нигез була: патриархаль, буйсынучан һәм катнашу мәдәнияте.**

Патриархаль сәяси мәдәният

Урындагы кыйммәтләргә нигезләнә (клан, кабилә, ыру кыйммәтләре) һәм патриотизм, кода-кодагыйлык, коррупция формаларында чагылырга мөмкин. Индивид глобаль сәяси мәдәнияткә ныкбәйле түгел һәмконкрет сәяси роль башкармый. Бу сәяси мәдәният төре яшь бәйсез дәүләтләргә хас, аларда сәяси мәдәният урындагы субкультура халкы белән күрсәтелә.

Буйсынучан сәяси мәдәният

Индивидның пассив һәм читләштерелгән мөнәсәбәтен күзаллый. Ул сәяси аңлы булса да,традицияләргә таяна.
Хакимияткә буйсынып, индивид аңардан төрле байлыклар (социаль пособие, гарантияләр) өмет итә һәм диктаттаншикләнә.

Катнашу мәдәнияте сәяси активлык

Катнашучанлык һәм рациональлек белән аерылып тора. ГраждаННар законлы чаралар (сайлау, демонстрация) ярдәмендә сәясәткә һәм хакимияткә йогынты ясарга омтылалар.

§71. Сәяси субкультуралар

Җәмгыятьнең сәяси мәдәнияте абсолют бер төрле генә була алмый. Төрле берләш- мәләрнең ихтыяҗ төрлелеге барлык илләрдә дә бер-берсеннән аерылып торган сәясимәдәният модельләре – субкультуралар барлыкка китерә. Алар арасыннан политоло- гиядә иң мөһим булган түбәндәге **субкультура төрләрен бүлеп чыгалар:**

Сәясәт бүлеге

Дини субкультуралар

Дини субкультуралар илнең аерым төбәкләре арасындагы төрлелек белән билгеләнә. Төбәк сәяси мәдәниятенә климат, билгеле табигый ресурслар булуы, төбәкнең икъ- тисади махсуслаштырылуы, аның гомуми хезмәт бүлү системасындагы урыны кебек факторлар җитди йогынты ясый. Ул кешеләрнең яшәү рәвешенә, мәдәниятнең гомумидәрәҗәсе һәм сәяси-мәдәни дәрәҗәсенә йогынты ясый торган икътисади төрлелекне тудыра.

Социкътисади субкультуралар

Социкътисади субкультуралар төрле икътисади статусы булган һәм яшәү рәвешендә аермасы булган, сәяси тормышта мөһим роль уйный торган төрле төркем (иҗтимагыйкатлам, сыйныфлар) яшәешенә шарт булырга мөмкин.

Эшмәкәрләр катламы өчен, мәсәлән, иң актуаль сәяси кыйммәтләр – икътисади ирек, тотрыклык, гражданнар җәмгыяте ягыннан дәүләтне контрольдә тоту, карарлар кабул итүдә катнашу.

Этнолингвистик субкультура

Этнолингвистик субкультура тел, тиешле социаль төркемнең этник үзенчәлекләре белән бәйле. Бу төркемнәрнең сәяси мәдәниятенә этник үзаң һәм милли характер ке-бек факторлар йогынты ясый. Сәяси кыйммәтләр, артык күрү һәм күрсәтмәләр этник факторларга караганда икенчел.

Дини субкультуралар

Дини субкультуралар дин билгеле бер төркемнең гомуми төп мәдәниятенең яңадан җитештерү элементы булып чыгыш ясаганда барлыкка килә.

Яшь ягыннан

Яшь ягыннан төрле буын вәкилләренең төрле сәяси кыйммәтләр системаларын чагыл- дыра. Гадәттә, бу субкультура өлгергән җәмгыятьтә очрый. Сәяси мәдәнияты гомере узган сәяси чынбарлык шартларында формалашкан өлкән буынның иске сәяси режим тәжрибәсе белән йончымаган яшьләрнең сәяси күрсәтмәләреннән аермалы сәяси ка- рашлары бар. Яшь аермасы тотрыклы системаларда сәяси мәдәниятка чагыштырмача аз йогынты ясый.

§72. Россиянең сәяси мәдәнияте үзенчәлекләре

Россиядә буйсыну сәяси мәдәнияте өстәмә сыйфатлар белән баетылды, бу аның үсешенә цивилизацион, георгафик, тарихи факторларның йогынты ясаудан гыйбарәт

Беренче. Сәяси юнәлешләрнең буйсыну тибы, гадәттә, гомум кабул ителгән бар халыкның хакимияткә буйсыну гадәте, дисциплиналык, социаль гарантияләр, тигезлек кебек кыйммәтләр яклы булуы белән характерлана. Россиядә сәяси мәдәният икеяклы һәм үзе белән ике социокультура агымынның үзара йогынтысын күрсәтә, алар төрле кыйммәтләр системасына таяна.

Икенче. Россия сәяси мәдәниятының таркау

һәм бертөрле булмавы аның таратучылары мөнәсәбәтләренең конфронтацион характерда...

Өченчедән, урта гасырдан башлап, сәяси юнәлешләрнең өстенлек итүе хакимлек идарә итүче сыйныф кулларында туплана. Сәяси көч туплану процессыгаять зур россия киңлекләрен үзләштерү технологик, матди һәм коммуникация инфроструктура үсеше булмаган хәлдә бары тик көчле князь һәм аларның дружиналары белән генә тормышка ашырылып була иде.

Дүртенчедән. Ирекле индивидның һәм җитешкән гражданнар җәмгыяте булмавы сәяси тормышның идарә итүче сыйныф кулында тупланыына китерә. Сәяси яктан хокуксыз булган халыкка идарә итүчеләр күрсәтмәләрен үтәргә генә кала.

Нәтиҗә: мәдәният сәяси тәртип өлгеләрен барлыкка китерә, XX гасырның революци-он тетрәнүләренә карамастан, алар бүгенге шартларда да актуальлеген югалтмый.

§73. Сәяси аң

Сәяси аң – теоретик һәм көнкүреш белем, бәяләү, кәеф һәм хисләр системасы, алараша социаль субъектлар (индивид, төркем, сыйныф, берләшмәләр) сәясәт өлкәсен аңлауга ирешелә.

Ясалу юллары:

— Иҗтимагый-сәяси чынбарлыкны тәнкыйди аңлау, кешеләрнең хисси күзаллаула-рын әкренләп рационаллаштыру, аларда булган мәгълүматны гомумиләштерү

— Теге яки бу идеалларының гаделлегенә ышаныч эмоциональ тарту

— Партия һәм сәяси хәрәкәтләр максатларын аңлау, гражданнар тәртибен бәһалау һәм формалаштырган нормаларына җәлеп итү

Килеп чыгу шартлары:

— Кеше тарафыннан үзенең төркемгә каравын, төркемгә тәңгәл килүен аңлау

— Кеше тарафыннан үзенең билгеле бер сәяси позициягә керүен ачыклау, хокук, ирек, хакимияткә йогынты ясау мөмкинлеге булган субъектның гражданлык статусын ачыклавы

— Төркем мәнфәгатьләренең сәяси хакимият белән элемтәгә кермичә тормышка ашырылып булмавын аңлау

Сәясәт бүлеге

Сәяси аң вазифалары:

— танып белү – әйләнә-тирә сәяси мохит турында белем системасы бирә

— бәһалау – сәяси вакыйгалар, сәяси тормышта үзеңнең урыныңны билгеләргә ярдәмитә

— регулятив – сәяси катнашлыкка карата юнәлеш бирә

— берләштерүче (интеграцияләүче) – гомуми кыйммәтләр, идея, күрсәтмәләре ниге-зендә җәмгыятнең социаль төркемнәрен берләштерүгә ярдәм итә

— прогноз бирү – сәяси процессның эчтәлеге һәм характерын алдан күрә белүгә ни-гез тудыра

— норматив – гомум кабул ителгән киләчәк образы тудыра

§74. Сәяси аң төзелеше

Сәяси аң төзелеше

Субъект карашы буенча

— Массакүләм – сәяси тормышта катнашучы һәм аңа йогынты ясый алучы теге яки бу кешеләр берләшмәсенең реаль хәрәкәт итүче сәяси аңы

— Төркемле – конкрет зур (сыйныф, социаль төркем һәм катлам) һәм сәясәткә йогынты ясаучы кече төркемнәр (сәяси элита, басым ясау төркеме) гомуми аңы

— Шәхси – сәясәтне шәхес тарафыннан аңлап, аңарда катнашуны тәэмин итүче танып белү, мотивация һәм кыйммәтләр компонентлары системасы

Чынбарлыкны чагылдыру тирәнлеге буенча

Гадәттәге – кешеләрнең тормыш тәҗрибәсенә нигезләнә.

Аның үзенчәлекләре:

— Каршылыклылык
— Өзеклелек
— Системалы булмавы
— Югары эмоциональлек
— Тотрыклык һәм тәртипкә инерцияле йогынты

Чагылу ысулы: иҗтимагый психология

Фәнни-теоретик – билгеле бер иҗтимагый төркемнәр ярдәмендә сәяси процессны максатчан тикшерү ниге-зендә формалаша.

Аның сыйфатлары:

— Бөтенлеге
— Системалыбулуы

Чагылу ысулы: иҗтимагый идиология.

§75. Сәяси психология

Сәяси психология – сәяси мөнәсәбәт һәм мәнфәгатьләрне иҗтимагый-психологик формада чорналган һәм ныгыта торган, субъектта сәяси тәртипкә турыдан-турыюнәлеш һәм мотивлар бирүгә юнәлтүче торган сәяси үзаңның аерылгысыз өлеше.

Үзенчәлекле билгеләре

— гражданнарның үзара һәм хакимият институтлары белән хезмәттәшлеге гамәлимөнәсәбәтләре нигезендә турыдан-туры активлык процессында формалаша

— сәяси вакыйга һәм процессларның чагылышы еш кына шартлы

— аңның хисси һәм эмоциональ элементлары төп роль уйный

— кешеләрнең киләчәккә юнәлтелгән мәнфәгатьләрен түгел, ә көндәлек мәнфәгать һәм ихтыяҗларын чагылдыра

— төрле идеологияләр йогынтысына дучар ителә һәм аларның үзара көрәше процес-сында барлыкка килә

— бик тиз үзгәрү һәм сәяси шартларга сизгерлек сәләтенә ия

Сәяси политология элементлары

— кешеләрнең сәяси эшчәнлегенең билгеле бер мотивларын тудыра торган хис һәм эмоцияләр

— индивидуаль-психик үзенчәлекләр (ихтыяр, хәтер)

— кешенең тумыштан килгән һәм темперамент, демографик һәм яшь үзенчәлекләрен көйли торган психофизик сыйфатларда чагылыш таба торган физиологик механизмнар

§76. Сәяси коммуникация

Сәяси коммуникация сәясәтнең үзенчәлекле иҗтимагый-мәгълүмати кыры буларакчыгыш ясый. Ул сәяси эшчәнлекне структуралаштыра һәм аңа яңа төс бирә торган мәгълүматне тапшыру, җибәрү, алмашу процессларыннан гыйбарәт.

Сәяси элитадан халык массаларына юнәлгән сигналларның бер яклы булуын күздә тотмый, ә сәясәткә төрлечә йогынты ясый торган җәмгыятьтәге формаль булмаган аралашу процессларын да күз алдында тота.

Сәяси хәбәрләрнең өч төп тибы

боерык хәбәрләр
(боерык, ышандыру)

саф мәгълүмати
(реаль яки уйдырмахәбәрләр)

фактик
(сәясәт субъектлары арасында контакт урнаштыру һәм аны саклау сәясәтбелән бәйле хәбәрләр)

Аралашуның өч төп ысулы: формаль булмаган багланышлар, иҗтимагый-сәяси оешмалар (институтлар), массакүләм мәгълүмат чаралары. Сәяси коммуникациядә язылган яки әйтелгән сүз белән эш итәләр, әмма ул мәгънә белдерүче төрле билге, символ, сигнал ярдәмендә дә гамәлгә ашырылырга мөмкин.

§77. Сәяси идеология

Сәяси идеология – грек теленнән idea – төшенчә, logos – белем сүзләренән алынганһәм билгеле бер иҗтимагый төркем һәм катламнар, милли оешмаларның кызыксыну, ихтыяҗ, максат һәм идеаллары күзлегеннән чыгып, сәяси яшәешне нәзари (концептуаль) аңлауны эченә алган идеяләр, карашлар, күзаллаулар системасын белдерә.

Ул сәяси хакимият яисә аңа йогынты ясау ярдәмендә теге яки бу төркем гражданнарның мәнфәгатьләрен һәм максатларын белдерә һәм яклый торган системалашканкүзаллаулар җыелмасын белдерә.

Идеология термины XVII – XVIII гасырлар чигендә Франциядә барлыкка килә һәмфранцуз тикшеренүчесе А Дюстют де Траси тарафыннан кулланылышка кертелә.
Башта бу термин белән «иядеянең табигый барлыкка килешен» һәм «иллюзор фикерләрне фаш итүне» өйрәнәчәк яңа фәнне атарга телиләр.

Сәяси-иҗтимагый караш буларак идеология ышану көченә ия булган һәм эчтәлеге кыйммәтле фикерләрне тәшкил иткән үзенчәлекле феномен булып санала.

Идеологияләр XIV гасырда – Яңарыш чорында, секуляризация процессына бәйле беренче иҗтимагый кризис чорында, ягъни иҗтимагый һәм шәхси аңның азат булуыннан башлана.

§78. Идеология үзенчәлекләре һәм аның вазифалары

Идеологиянең җәмгыять тормышындагы роле ул башкарган вазифаларга нигезләнә. Сәяси идеологияләр сәяси карашлар сыйфатында чыгыш ясаган һәм ышандыру көченә ия булган кыйммәтләрне үз эченә ала. **Моңардан чыгып, түбәндәге вазифаларны аерып чыгарарга мөмкин:**

— **Юнәлдерүче (ориентацион) вазифа.** Ул, җәмгыять, иҗтимагый прогресс, шәхес,хакимият, идеология турындагы төп күзаллауларны үз эченә алып, кеше эшчәнлегенә мәгънә һәм юнәлеш системасы билгели.

— **Мобилизацияләүче вазифа.** Камил булган җәмгыять идеалын тәкъдим итеп, сәяси идеология сәяси эшчәнлек турыдан-туры мотивы сыйфатында чыгып карап һәм җәмгыятьне, аны тормышка ашыру өчен иҗади төркемнәрне мобилизацияли.

— **Интегратив вазифа.** Сәяси идеология, сәяси хәрәкәткә мәгънә биреп, аңа теләсәкайсы шәхси һәм төркем мәнфәгатьләреннән өстен чыккан әһәмият сала. Сәяси идеология шәхси ихтыяҗларга каршы тора һәм шуның белән интегратив фактор буларак хезмәт итә.

— **Амортизацион вазифа.** Сәяси эшчәнлек, интерпретация ысулы буларак, сәяси идеология вакыйгаларда, атап әйткәндә, җәмгыять, төркем, индивидларның ихтыяҗлары һәм аларны канәгатьләндерү өчен реаль мөмкинлекләр туры килмәгәночракларда иҗтимагый киеренкелекне киметү өчен хезмәт итә.

— **Билгеле бер иҗтимагый төркем ихтыяҗларын чагылдыру һәм аларны яклау вазифасы.** Аның асылы сәяси идеологиянең нинди дә булса иҗтимагый төркемнең ихтыяҗлары нигезендә барлыкка килүеннән һәм аларны башка төркемнәр ихтыяҗына каршы куюдан гыйбарәт.

Сәяси идеология санап үтелгән вазифалары аны башка сәяси аң формаларыннан аерып торган **ике үзенчәлегенә бәйле. Алар – тоталь әһәмияткә (яки глобальлеккә) дәгъва итү һәм нормативлык.** Теләсә кайсы сәяси идеология башка идеологияне бастырырга тырыша, үзенең дөньяны үзгәртүгә юнәлтелгән бөек бурычы турында таныту һәм күтәреп чыккан идеяне тормышка ашыру өчен барлык мөмкинлекләрне куллана. Идеология тарафдарларының үзе тараткан кыйммәтләр һәм норма-ларга бирелгәнлеген таләп итә.

§79. Идеологияләрне төркемләү критерийлары

Сәяси идеологияләр **ике критерий буенча бүленә**: 1) күрергә теләгән җәмгыять моде-ле тәкъдим итү буенча 2) аны тормышка ашыруның прогрессы һәм технологиясе буенча

Хәзерге вакытта дөньяда берничә төп идеология төре хакимлек итә:

Уң идеологияләр ирекле конкуренция, базар, хосусый милек һәм эшмәкәрлеккә нигезләнгән прогресс идеясен җәмгыять белән бәйлиләр. Уң идеологияләр бертөрле түгел, алар ультра уңнардан алып (фашизмның барлык төрләре, расизм), либерал-демократик (либерализм, демократизм) сәяси идеологияләренең тулы спектрын үз эченә ала.

Сул сәяси спектр социаль прогресс җәмгыятьнең тигезлеккә ирешү, социаль гаделлек, шәхесне һәрьяклап үсеше өчен шартлар тудыру юнәлешендә даими үзгәргән идеологияләрне тәкъдим итә. Сул идеологияләр шулай ук бертөрле түгел: коммунистлар идеологиясе җәмгыятьне үзгәртүдә радикаль алымнарга өстенлек бирә, ә социал-демократлар исә революцион чаралар куллануга кискен карый һәм эволюцион юлны, ягъни реформаларны хуплый.

§80. Либерализм

Либерализм – дәүләт эшчәнлеге өлкәләрен чикләү белән берәттән, шәхес иреген һәм индивидның башка гражданлык һәм сәяси хокукларын яклый торган тәгълимат һәм иҗтимагый-сәяси агым. Либерализм, идея агымы буларак, XVII гасыр уртасында Ан- глиядә барлыкка килә. Аңа нигез салучы – Джон Локк (1632-1704). Әкренләп буржуаз стройга күчү барышында либерализм Көнбатыш Европа буенча тарала һәм XIX гасыр уртасына төп идеологиягә әверелә. Бу вакытка аның төп принциплары һәм максатлары билгеләнеп бетә.

§81. Неолиберализм

XX гасырның беренче утыз елындагы тирән кризис либерализмның иҗтимагый тигезсезлек үсеше процессын туктату буенча мөмкинлекләре чикле булуын ачыклый, ул либераль сәяси доктринаны билгеле модернизацияләүне таләп итте. Классик либерализм нигезендә барлыкка килгән һәм 50-60нчы елларда үсеш алган неолиберализм хәзер көчле агым буларак үзен таныта. Аның асылы хосусый милекнең абсолют кыйммәте, гражданнарның хокук һәм ирке белән берлектә иҗтимагый мәнфәгатьләрне һәм дәүләтнең икътисадта гына түгел, төрле иҗтимагый программаларда да катнашлыгын исәпкә алмыйча мөмкин түгеллегеннән гыйбарәт.

Неолиберализм дәүләтнең иҗтимагый вазифаларын киңәйтү һәм аның икътисади һәм иҗтимагый өлкәгә кысылу чиге турында тезис кабул итә. Идарәчеләр һәм идарә ителә торганнар арасындагы сәяси рольләрне катгый бүлү турындагы нигезләмә барлык сәяси көчләр консенсусы турындагы тезис белән алмашынды. Гаделлек, дәүләтне хокук белән чикләү, хөкүмәтнең әхлак кыйммәтләре һәм принципларына юнәлүе, массаларның сәяси процесста катнашуы, элиталар конкурентлыгы сәяси системаның мөһим казанышлары итеп билгеләнде. Мондый модернизацияләү нәтиҗәсендә иске либерализм неолиберализмга әйләнә, аның төп мәгънәсен түбәндәге формула белән күрсәтеп була: дәүләт базар системасының законсызлыгыннан һәм негатив нәтиҗәләреннән шәхесне сакларга тиеш.

§82. Консерватизм

Консерватизм – ул тарихи барлыкка килгән дәүләт һәм иҗтимагый тормыш формаларын (аеруча аның гаилә, милли үзенчәлекләр, дин, милектә тормышка ашырылган кыйммәтләр нигезен) саклау һәм яклауга юнәлтелгән идея-сәяси тәгълимат һәм агым.

Консерватизмның төп принциплары	Консерватизмның төп идеяләре
Җәмгыять – ул тамырлары белән ерак тарихка тоташкан нормалар, гореф-гадәт,институт системалары	Индивидның иҗтимагый тормышы традицияләр нигезендә төзелергә тиеш
Яшәп килгән институт теләсә кайсы теоретик схемадан уңайлырак дип исәпләнелә	Милли бөеклек идеясе
Дәүләт авторитетына таяну	Җәмгыятькә социаль тигезсезлек хас һәмсәяси конкуренция хас
Кеше табигатен бәяләгәндәге пессимизм,кеше акылына карата скептицизм	Иҗтимагый тормышка сәясәтнең активкатнашлыгыннан баш тарту
Кешеләр арасында социаль тигезлекмөмкинлеге	Парламентаризмга һәм сайланган хакимият институтларына түбәнсетеп карау
Хосусый милек – шәхси ирек һәм социальтәртип гаранты	

§83. Неоконсерватизм

Неоконсерватизм – ул классик консерватизм һәм либерализм идеяләрен берләштер- гән идеология. Неоконсерватизм XX гасырда традицион консерватизм, либерализм һәм технократизм кушылмасы буларак туа. Аның вәкилләре: теориядә – : А.Хайек, сәясәттә – Р.Рейган, М.Тетчер, Ж.Ширак.

Неоконсерваторлар дәүләткә сабыррак мөнәсәбәттә, аның җәмгыять белән идарә иткәндә катнашлыгын кабул итәләр, әмма бу катнашлык чикле булырга тиеш. Сәяси методларның түбән нәтиҗәлелеге бу проблемалар табигате иҗтимагый түгел, ә шәхси булуы белән билгеләнә, һәм алар индивид көче һәм активлыгы аркасындауңышлырак чишелә.

Неоконсерватизмның төп идеяләре:

— Фәкать базар мөнәсәбәтләре генә кеше һәм җәмгыятьнең реаль үсешенә алып бара

— Класссик демократия тормышка ашырылмый һәм зарарлы, элиталарның хакимияте һәм демократиясе бер-берсе белән яраклашырга тиеш

— Ирек һәм тигезлек тәңгәл түгел

§84. Социал-демократизм

Социал-демократизм – эволюцион үсеш, демократик социализм һәм әкренләп реформалар ярдәмендә аңа ирешүгә юнәлдерелгән иҗтимагый-сәяси агым.

Җәмгыять тормышының матди аңлатмасы	Сәяси хакимият формасы буларак,һәртөрле диктатураны кире кагу
Бөтен халык хезмәт ияләренең кызыксыну күзлегеннән чыгып, җәмгыять күренешләренә анализ ясауга якын килү	Демократик парламентаризм принципларына чын күңелдән бирелгәнлек
Ахыргы һәм агымдагы максатларның гуманистик характеры	Сәяси плюрализмга юнәлгәнлек һәм мөһим проблемаларны чишкәндә консенсус
Иҗтимагый коллективизм	Куелган максатларга ирешүнең тыныч һәм демократик ысуллары приоритеты
Тарихи оптимизм	Базар механизмы һәм экономиканыхөкүмәт тарафыннан җайга салу

Идея эчтәлеге буенча социал-демократизм марксизмнан шактый аерыла.

II Бөтендөнья сугышыннан соң кайбер Европа илләрендә (чынлыкта Сканди- навия илләрендә) социал-демократлар хакимияткә парламент механизмы аша килә башлыйлар һәм реформа программаларын тормышка ашыралар, үз тео- рияләренең дөреслеген исбатлый башлыйлар. 100 ел дәвамында социал-демократ-лар һәм марксистлар арасында үсә барган тарихи бәхәсне социал-демократлар файдасы-на чишелгән дип санап була.

§85. Коммунизм теориядә һәм практикада

Коммунизм – ул революцион, икътисади һәм иҗтимагый теория. Аңа К.Маркс (1818- 1883) һәм Ф.Энгельс (1820-1895) тарафыннан 40 нчы елларда нигез салына. Г.В.Плеха- нов (1856-1918), В.И.Ленин (1870-1924) һәм башка дәвам итүчеләр ярдәмендә үстерелә.

